ISSN 0206–4189

# казан утлары

9.2001



# YAZUÇILARIBIZ ÇİT İLLƏRDƏ



Renat Xaris Dalay lama belən. *Estoniə, iyün, 2001 yıl*




Raul' Mirxəydərov İspaniənen Marbelyə şəhərendə. *İyül, 2001 yıl.*

# Казан утлары
# Qazan utları

2001

9

(947)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***



*БАШ МӨХӘРРИРЕ*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Аяз Гыйләҗев**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Салих Маннапов**
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Альбина Әхмәтова, Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова, Асия Рәхимова** (баш бухгалтер).


---


✉✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 49-36-63,
гамәли хезмәткәрләр — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИЖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Әхсән БАЯН. Тик бер юл илтә Тәңрегә. *Шигырьләр* ..... 5
Факил САФИН. Саташып аткан таң. *Роман* ..... 10
Флера ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. Хаклык ихтыяры ача йөзне. *Шигырьләр* ..... 73
Әдип МАЛИКОВ. Тылсымлы хатлар *(Яңа әсәрдән өзек)* ..... 78
Шамил МАННАПОВ. Шигъри вәхиләр ..... 114

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Фатих УРМАНЧЕ. Гасырларны кичкән гүзәллек ..... 120
Гөлчәчәк ГАЛИЕВА. Чын сәнгать әсәре булсын ..... 130

ТАРИХ

Миркасыйм ГОСМАНОВ, Алсу АРСЛАНОВА. Бер гыйбрәтле тарихи хезмәт хакында ..... 134

КОРЪӘН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ

13—Рәгыд (күкрәү сүрәсе) ..... 152
14—Ибраһим сүрәсе ..... 155

СӘНГАТЬ

Марат ЗАКИР. Моң хикмәте. *(Җырчы, мөгаллим Миңгол Галиев белән әңгәмә)* ..... 159
Кыям МИҢЛЕБАЕВ. «Исемсез» олуг исем иясе ..... 166

КИТАП КҮЗӘТҮ

Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ. Америкада татар әдибәсе ..... 170

ЮМОР-САТИРА

Рөстәм ЗАРИПОВ. Төш. *Шигырьләр* ..... 176

НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

Айгөл НУРЕТДИНОВА. Әкиятләр ..... 180

УКУЧЫ СҮЗЕ

Рәхим ТЕЛӘШОВ. Беренче татар дәүләте кайчан төзелгән? ..... 187

ЮБИЛЕЙЛАР

Rədif ĞATAŞ. Mənge yəş xıyal ..... 188
Əzhər ĞABİDİ. Şiğerlər ..... 189
Liliə ĞATAULLİNA. Əsərlərendə—yaqtaşları *(Yazuçı Xənif Xəyrullinnıŋ tuuına 70 yıl)* ..... 190
Ижтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 191

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: Ф. САФИН «Мнимый рассвет» *(окончание)*; воспоминания А. МАЛИКОВА «Волшебные письма» *(окончание)*; стихи А. БАЯНА, Ф. ГИЗЗАТУЛЛИНОЙ, Ш. МАННАПОВА.
«Литературная критика»: статьи Ф. УРМАНЧЕ «Образ Сююмбики в современной татарской поэзии» и Г. ГАЛИЕВОЙ «Взгляд на современную прозу».
«История»: М. УСМАНОВ и А. АРСЛАНОВА анализируют новую книгу венгерского ученого А. Рона-Таш посвященную древне-венгерской истории.
Коран на татарском языке.
«Искусство»: М. ЗАКИР беседует с певцом М. Галиевым; статья К. МИННЕБАЕВА о творчестве скульптора А. Абдрашитова.
«Книжное обозрение»: М. ВАЛИЕВ. «Татарская писательница в Америке».
«Юмор-сатира»: стихи Р. ЗАРИПОВА.
«Детский мир»: сказки А. НУРТДИНОВОЙ.
Слово читателя.
В номере отмечаются 75-летие А. Габиди и 70-летие Х. Хайруллина.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Золотая осень»—фотоэтюд; поэт и ученый Рифат Джамал (Курбанов).

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and Poetry": F. SAFIN'S novel «The imaginary dawn» (ending), A. MALIKOV'S memoirs «The magic letters» (ending); the verses of A. BAIAN, F. GIZZATULLINA, SH. MANNAPOV.
"Literary criticism": F. URMANCHE'S article "Suimbika in morden Tatar poetry"; G. GALIEVA'S article about morden prose.
"History": M. USMANOV'S and A. ARSLANOVA'S analysis about A. Rona-Tash's new book.
"Life and religion": Koran in Tartar language.
"Art": M. ZAKIR'S talk with singer M. Galiev; K. MINNEBAEV'S article about sculptor A. Abdrashitov's creative works.
"Book review": M. VALIEV'S article «Tatar writer in America»
"Humour and satire": R. ZARIPOV'S verses.
"Child word": A. NURTDINOVA'S fairy-tales.
Reader's word.
Commemoratung the 75th Anniversary of A. Gabidi and 70th Anniversary of H. Khairullin
The diary of social and cultural life.
In our covers: "Golden autumn"—photoetude, poet and scientist Rifat Jamal (Kurbanov).

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-34-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянен компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 21.08.2001 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы $70X108^1/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 8219 Заказ А-348
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2001 ел.

Şiğriət

Шигърият



# Әхсән Баян

## ТИК БЕР ЮЛ ИЛТӘ ТӘҢРЕГӘ...

### Тарихи бәет

Ерак мәшрикътан мәгърибкә чаклы,
Җәелеп-җәйрәп, бөек ил ята.
Җиргә бөркеттән төшкән күләгә
Сузылып килә тарих буйлата.

Татар галәме! Килгән күршеләр
Хакимлек өчен фатиха сорап.
Заманнар кичкәч, Мәскәүдән—соңрак,
Барып, без хәер сораган сымак.

Гасырлар шаһит, шаһит кавемнәр:
Таралган дәүләт, гүя сихердән.
Үлгән бөркеттән калҗа, каурыйлар
Йолкып, козгыннар ләззәт кичергән.

Бөек бөркеттән карачкы ясап,
Үз күреп, шуны күккә чөйгәннәр.
Кыйтгалар ката канатлар җәйгән
Бөркетне, гүя, алар җиңгәннәр.

Җиңелү рас та... сихер тик бүтән:
Котырган чума, сәбәп шул икән.

---

Әхсән БАЯН *(1927) —шагыйрь, прозаик, драматург. Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, күпсанлы китаплар (шигырь, роман, повестьлар, мәкаләләр һ. б.) авторы. Казанда яши.*

Мәгърибкә чаклы килеп мәшрикътан,
Зәхмәти чума тантана иткән.

Күзгә күренмәс җәя тартылган,
Күзгә күренмәс уклар атылган.
Берләшеп шулай дошманнар белән,
Аерган чума илне халкыннан.

Гайрәтен, дәүләт, төйнәп йодрыкка,
Яу чаба чыкса, җиңәчәк булган.
Кузгалган әмма яшертен чума,
Илне үзәктән җимерә торган.

Хөсет, көнчелек, өстенлек—афәт
Дулаган илдә, мисле гарасат.
Мисле баһадир йөргән сатлык ир,
Ил башын җиңгән яман, кара чир.

«Хөсет, үч, мәкер—иң явыз чума,
Илнең, гавамның сулышын бума!»—
Далада оран юктай югалган,
Дәүләт таралган, ә чума ... калган.

«Бетәр, туктармы ул берәр заман?!»—
Яңгырый аваз гасырлар ката...
Уйда, җиһанда—мәгърибтән башлап
Мәшрикъка чаклы җәйрәп, ил ята.

## Урамдагы сабый кызга

Киң урамда кояш бәйрәм итә,
Аңа кушыла кызлар тавышы.
Чәчәк сайлый кызлар, сөенечләре
Челтер-челтер—гүя язгы су.

Ә кибеттә алтын сайлый кызлар,
Чәчәк кенә җитми, күрәсең.
Меңнәр түли кызлар, байлык каян?—
Гөнаһларга килми керәсем.

Яннарында егет карчыгалар
Уяу йөри—алыпсатарлар.
Киштәләрдән коньяк, шәраб сайлый
Яңа урыс, яңа татарлар.

Карашлары балкый тантаналы,
Рекламалар яна гүяки.
Чакыралар кафе-рестораннар:
«Кәеф-сафа кор син, безгә кил!»

Ә урамны каплый күләгәләр.
Төсләр сүнә, бәхет югала.
Киң ишекнең тышкы тын төбендә,
Кулын сузып, утыра кыз бала.

И сабыем! Алчы, ал тиеннәр,
Җәл түгел дә, күбрәк калмаган.
Кичә генә юк идең бит монда,
Каян килдең, кайсы заманнан?

Күзгә яфрак төсле йөзләреңә
Сызланмыйча ничек карыйм соң?!
Иреннәрең сүзсез кыймылдыйлар—
Кемне шулай, кемне каргыйсың?

Иреннәрең сүзсез кыймылдыйлар—
Бу дөньяга хак сүз әрәмдер...
Нишлик, җаным, түзик: сабырлыклар
Алтыннарга, бәлки, әйләнер.

*

Томаннарны җилләр алып китә,
Көн күтәреп ала төн чыгын.
Кош коткара оча белмәс килеш
Җиргә ялгыш төшкән кошчыгын.

Мәхәббәтнең соңгы хатын гашыйк
Ташласа да кичен ерткалап,
Җил очырган сөю кисәкләрен
Җыеп карый таңда ул кабат.

Эзлә димим төнге караңгыда.
Көндез—кояш балкып торганда,
Эзләмичә табу мөмкиндер ич,
Кирәклеген бераз тойганда?

Дәрья комлыгында яткан ташны
Бер ниятсез ала кемнәрдер.
Беләм, илем, моңнарымны минем
Күтәрерсең әле син дә бер...

## Шахтер кыз

*Ф. Г.*

Еллар аны аямаган,
Айкаган да чайкаган.
Айкый-чайкый, кердәй юган—
Җаны чиста, сау калган.

Капланмаган, тапланмаган
Яшьлегенең йөз агы.
Кершән, сөрмә генә булган
Ташкүмернең тузаны.

Җир астында атлар җигеп,
Ташлар ташып йөргәндә,
Төшмәгән бер дә түбәнгә,
Төшкән бары тирәнгә.

Гомер үренә менгәндә,
Күрдек—һич абынмады.
Туган кыр киңлекләреннән
Китсә дә—аерылмады.

Теләгем кабул буласын
Әйтәм бугай белеп тә:
Уйлары калсын тирәндә,
Ә юллары—биектә.

Бәхет белән берлектә.

## Гомерем чишмәсе

Әй, туган авылым чишмәсе,
Тынгысыз тибешеңнән
Яратылган минем йөрәк,
Холкы-фигыле—синнән.

Җир йөзендә чишмәләр күп,
Берсе дә тик син түгел.
Син—минеке, башкасы ким
Булмаса да, тиң түгел.

Чишмә казып чыгарсам да,
Җиде кат җир астыннан,
Саф булса да, көч тапмадым
Мин аның шифасыннан.

Сулкылдыйсың, шук ургыйсың,
Көләсең чылтыр-чылтыр.
Миннән башка син булсаң да,
Синнән башка мин юктыр.

Башланган гомерем синнән,
Синдә туган җыр башым.
Мин киткәч тә: «Ул—бар, ул—бар!»—
Дип чылтырар, чыңларсың.

## Тау чәчәге

Ирәндектә үскән тау чәчәген
бүләк иткән кыз—исемдә
иртәсен дә, кичен дә.
Таңда көлеп әйткән сүзләрен, һай,
Саклый чәчәк зәңгәр төсендә.

Арабызда инде урман-таулар.
Араларның күпмелеген
белми, сизми тик күңел.
Күккә ашкан таулар, еллар да, һай,
Безне аера торган чик түгел.

Шул чаклардан килгән таңгы нурлар
чәчәк төсле бизәп күкне,
сөйли безнең берлекне.
Уйларыбыз сыман уз чикне, һай,
Чаңк-чаңк иткән Ирәндек бөркете!

## Картлык дустыма

**Шәмнәр кебек зифа иде,**
**Төзек иде буй-сының.**
**Тумыштан шулай тормышның**
**Шау-шуына кушылдың.**

**Мәйдан тоттың, җиңдең, оттың,**
**Егылсаң, булмадың хур.**
**Хәсрәт-михнәтләр чиккәндә,**
**Калдың төз, калдың горур.**

**Сулар ага, җилләр кага,**
**Заманнар белми туктау.**
**Кичкән елларың җыелып,**
**Өелде аркаңда тау.**

**Адәм угылы! Бөек сорау**
**Билгесе инде сының.**
**Күкрәкләрең—җиңү тулы...**
**Вакытка тик буйсындың.**

**Тик бер юл илтә Тәңрегә,**
**Тармаклары юк аның.**
**Моның өчен сине кем дә**
**Гаепләмәс, туганым.**

## Гозер

**Вакыт буйлап барганымны**
**Яшәү диеп уйладым.**
**Мин—бәндә—ача алмадым**
**Иң зур серен дөньяның.**

**Ачышларым азмы-күпме**
**Була язгандыр, беләм.**
**Тик алар юк, чагыштырсаң**
**Ачылмаган сер белән.**

**Күпләрнең тыңлап сүзләрен,**
**Күп мәзәкләр аңладым.**
**Яшәлдеме, юкмы ләкин,**
**Чынлап белә алмадым.**

**Сөяләр дип алдандыммы,**
**Әллә үзем алдадым.**
**Мәхәббәтме, юкмы ләкин,**
**Чынлап белә алмадым.**

**Яшәүләрнең, бәндәләрнең**
**Күрдем чынын, ялганын.**
**Дөнья дигән табышмакның**
**Җавабын табалмадым.**

**Бир гомер, Тәңрем, тапканчы**
**Хакыйкатьнең азагын!**
**Аны белми китәргә мин:**
**«Риза!»—дия алмамын.**

❦

**Ак каенга башлар куеп, икәү**
**Сөйләшәләр яфрак телендә.**
**Яфракларны—хыял һәм хисләрне**
**Саный белер, белсә, җил генә.**

**Алар тойган, алар кичергәнне**
**Тик йолдызлар аңлар, аңласа.**
**Беркем дә юк Җирдә, алар гына**
**Галәм белән серләр алмаша...**

**Садә җаннар уйлый шулай: тик без**
**Ачтык диеп бөек серләрне.**
**Тик беләбез: кабатлыйлар бары**
**Без калдырып киткән сүзләрне.**

**Бүген безнең ничек уйлаганны**
**Белмәсеннәр әйдә. Аңлагач,**
**Көлеп чайкарлар баш, зифа каен**
**Ерак көздә калгач ялангач.**

*1996–2001*

**Факил Сафин**

# САТАШЫП АТКАН ТАҢ

РОМАН

Кыш ахырларында «мәдрәсә», «Хөсәения» сүзләре студентлар теленнән бөтенләй төшеп калды.

Татар гомер бакый сабак алучы җан иясен «шәкерт» дип атап йөртте. Бусы да яңа хөкүмәткә ярап бетмәде. Студент! Килеп чыгышы, тамыры кайдандыр бу сүзнең, анысын уйлап торыш юк, тиз арада шәкертләр яңа атамага ияләнергә тиеш булдылар. Ияләнмиме соң адәм баласы, әллә нәрсәләргә ияләнә ул! Баштарак йөдәп беттеләр бетүен, әмма дөрес итеп әйтергә өйрәнделәр тәки. Әхмәтсафа, укучы башка яшьләр кебек үк, һәр яңалыкны дәррәү күтәреп алып, тиз арада гамәлгә кертеп җибәрү тарафдары булды. Иске атамалардан арыну—инкыйлабның җиңүле алга баруына дәлил иде. Мөгаллимнәре әйткәнчә, алар—яңа тормышның беренче карлыгачлары. Яшь сәвит иленең тоткасы булачак өр-яңа кадрлар булып җитешәчәкләр. Шушы уйлардан сөенеп, җан-фәрман тырышып, бар күнелләрен белем алуга салдылар.

Февраль ахырлары... Бу якларда җәй эссе булган кебек, кыш та суык килә. Чатнама суыклар башланды. Мәдрәсәне тиешенчә җылыта алмыйлар, шуңа күрә студентлар хәтта йоклаганда да өсләрендәге бишмәтләрен салмыйлар. Ай буе юынмыйча яшәделәр дисәң дә ярый. Төс-кыяфәтләр мактанырлык түгел. Студентлар әкренләп бер-берсенә охшап баралар—хөртиләнә эшләр, хөртиләнә...Хөкүмәт төрледән-төрле шигарь уйлап табарга оста булса да, хәерчелеккә тәгәрәгән илне бөтәйтерлек хәле юк иде. Аның каравы көн саен җыелыш яки кичә оештырыла. Анда ике сүзнең берендә «хәрби коммунизм», «яңа икътисади сәясәт» дигән серле һәм ымсындыргыч гыйбарәләр еш яңгырый. Андый чакларда Саттар Әхмәтсафаның колагына пышылдый:

—Дөрес...ләкин алай түгел ул...

Халык хәерчеләнде. Элекке бае, урта хәллесе эшсез-җирсез көн иткән сукбай хәленә төштеләр. Барысы да тигез хәзер—барысы да сәвит хөкүмәте үзенә бердәнбер таяныч итеп күргән ярлы-ябагай катлавына күчеп бетеп бара. Болай булса, дөнья революциясе дә ерак йөрмәс.

...Салкын бүлмәдә Әхмәтсафа Иләк каласыннан килгән Зиннәт

---

Ахыры. Башы 8 санда.

Габдрәшитов исемле студентка хисаптан дәрес хәзерләргә булыша иде. Зиннәт укуга ни сәбәптәндер соңга калып килде. Җитмәсә, хисап кебек төп фәннән белеме чамалы икәнлеген белә торып, аны хәзерлек курсының (шулай ук яңа сүз!) икенче сыйныфына, ягъни Әхмәтсафалар укыган сыйныфка кертеп утырттылар. Егет үзе тырыш болай. Башкалар эчләренә төшкән суыкны куарга теләп, бераз ял итеп, шаярып—күңел ачып алган чакларда да, ул баш күтәрми дәрес хәзерләп утыра. Бу хәлне иң беренче Мәҗит килештермәде. Инсәсенә салган иске кайры туны якасына төрткән борынын кинәт өскә чөеп, тәкәббер тавыш белән Зиннәткә дәште:

—Туган, күңеленә авыр алма, институт диләр моны, шәкертләр бет симертеп яткан сала мәдрәсәсе түгел. Ышы гап-гади мәсьәләне дә чишә алмагач, нинди студент ди инде син? Булмый, булмый!..

Янәшәсенә озын чәчләре маңгаена сибелгән, күзен чепиләндереп, иренен кысып, теш арасыннан сөйләшергә яратучы Фатыйх Сәгыйтов килеп басуын күреп, тагын да зәһәрләнә.

—Казна ашын ник ышындый наданнарга әрәм итәләр микән?—диде ул һәм түшәмгә элеп куйган борынын кабат тун якасына кадап куйды. Кем кем, әмма Мәҗитнең—хисаптан үз башы белән бер мәсьәлә чишә алмаган кешенең Зиннәттән көләргә маташуы үзе бер көлке булганга, бүлмәдәгеләр ана күтәрелеп тә карамадылар.

Фатыйх Сәгыйтов та аңа тиз генә җавап бирмәде. Әгәр янәшәдә башкалар күренмәсә, акыл сатып, гәп куертып торуны урынсызга саный ул. Үзен тыңлаучылар булмаса, кем дәшсә дә, җавап кайтарып тормастан, каты адымнар белән йә бүлмәдән үк чыгып китә, йә ятагына барып ава. Әгәр инде тыңлаучы табылса, шуны гына көтеп торган диярсең, үт суы кушылган бер-ике җөмлә атмый калмый. Бу юлы дәшми калу мөмкин түгел иде. Бүлмә тулы кеше...

—Татарны электән надан муллалар харап итте, хәзер аларга алмашка надан Зиннәтләрне әзерләп чыгарабыз...—«Зиннәтләр» дигән арада утлы карашы Әхмәтсафаны, Сәгыйтьне, шигырь язып мәшәләнүче Габдулла Амантайны, Саттарны, Әптерине, кыскасы—бүлмәдәге һәркемне өтеп чыгарга өлгерде. Бүлмәдәшләрен җай чыккан саен «мие кипкән тиле, надан» дип үртәүдән тәм тапкан Фатыйх Сәгыйтов, укуга омтылышы көчле булган Тозиле егете Зиннәтнең җанына кагылып китә алуына куанып, ләззәтле мизгелләр кичерә иде.

Үзен наданлыкта, булдыксызлыкта гаепләгәндә Зиннәт колагына кадәр кызара. Кичке ашка да бармый, башын дәреслектән күтәрми утыра иде. Шулай соңга калып килүенә сызланып, укуда иптәшләрен һаман куып тота алмавы өчен үзен битәрләп туя алмый иде кебек.

Беркөнне Сәгыйтовның чираттагы «мунчасыннан» соң, алдында яткан хисап дәреслегенә сенеп бетәрдәй булып, газап кичерүче Зиннәт янына Әхмәтсафа килеп утырды. Зиннәтнең туя ашамаудан яңаклары эчкә суырылып кергән. Керфекләренә яшь бөртеге эленгән...Янына Әхмәтсафаның—уен-көлкегә һәвәс Каргалы егетенең килеп утыруына да артык әһәмият бирмәде. Хәтта бөрешеп калган кебек тоелды: Мәҗит белән Фатыйхка иш табылды дип уйлады булса кирәк. Китабын бер читкә ташлап, урыныннан кузгалып китмәкче иде, нигәдер тыелып калды.

Әхмәтсафа Зиннәтне тынычландырырга тырышып, иплә генә сүз башлады:

—Дустым, инде башка фәннәрдән безне куып җитеп киләсең, әфәрин. Хисапка килгәндә...без болай итик...—Әхмәтсафа егеткә җан инә башлавын тоеп, ышанычлы тавыш белән дәвам итте.—Мин сиңа хисаптан дәрес эшләргә булышам, ә син миңа урыс теленнән ярдәм итәрсең.

Зиннәтнең йөзе балкып китте. Якты күзләре белән Әхмәтсафага күтәрелеп карады. Ирен читләрендә соңгы вакытларда сирәк күренгән елмаю пәйда булды. Базык гәүдәле, киң күкрәкле зәңгәр күзле бу егетнең чын күңелдән аңа ярдәм кулы сузарга җыенуын аңлап алган Зиннәт, үз-үзен белештермичә, сыйныфташын кочаклап алды.

—Риза, димәк?..—дип, егетне читкә этәрә төште Әхмәтсафа һәм ана кулын сузды. Зиннәтнең суыктан кызара төшкән кечкенә кулы Әхмәтсафаның зур учына кереп кенә чумды.

—Мин синнән чын урыс ясыйм!—дип, шапырынып җибәргәнен дә сизми калды Зиннәт.—Мин бит гел урыс малайлары белән уйнап үстем. Шөкер, урысчам сынатмады монда.

Зиннәт белән шулай тиз аңлаша алуы Әхмәтсафаның күңеленә хуш килде. Фатыйх ягына караш ташлады. Тегесе ятагыннан күтәрелә төшеп, бу ике егетнең сөйләшүенә колак салып тора иде. Моны күргәч, тавышын күтәрә төшеп, килешүгә нокта куйды:

—Әйдә, Зиннәт, шушы күркә муеннарга күрсәтик әле, кемнең кем икәнен. Берәүләр—тун бете,—ул Мәҗит ягына баш какты,—берәүләр—балак бете булганлыкларына куанып йөри бирсеннәр.—Бу сүзләре белән Фатыйхны ятагына кузгалмаслык итеп беркетеп куйды.—Без синең белән кешеләр булып калыйк. Якты, мәгърифәт үренә күтәрелик. Җыен әтрәк-әләм бездән көлү түгел, яныбызга килүдән шүрләп торсын. Бергә булыйк!—дип, Зиннәтнең алдында яткан хисап дәреслегенә үрелде.—Бүгеннән башлыйбыз. Көн дә кергән хисапның бер генә дәресен аңламый калу да ярый торган эш түгел, иптәшкәй.

Шундый көннәрнең берсендә алар янына институт директорының сәяси эшләр буенча урынбасары Заһид Шәркый белән Гайшә Мөхәммәдова (ул әдәби кичәләр үткәрү өчен җаваплы студентка) килеп бастылар. Алардан бераз арттарак беренче күрүдә үк егетнең йөрәгенә ут салып өлгергән Заһидә зонгырт күзләрен елтыратып тора.

Керүчеләрне күргәч, Әхмәтсафа урыныннан сикереп торуын сизми дә калды. Бу кадәр каударлануының сәбәпчесе, әлбәттә, Заһидә иде. Ул башкалардан битәр, Заһидәгә дәшкән кебек, сөйләнгән булды:

—Дәрес әзерлибез,—диде ул. Каушавын яшерергә тырышса да, барып чыкмады.

Гайшә, ерылып китәргә генә торган авызын бар хутына җәеп, егетне үчекләп алды:

—Әй без, тагын, кузна уйныйсыз дип торабыз...—Заһид Шәркыйга аңлатасы итте.—Безнең Әхмәтсафа круглый отличнога гына укый. Әле тагын бер яктан ачылды—бер дигән мөгаллим икән үзе—Зиннәттән математик ясый инде. Кайчан гына койрыкта сөйрәлгән Зиннәт, безне ырып-ерып дигәндәй алга үрмәкли, әйеме Заһидә?!

Заһидә авыз ачып сүз әйтергә өлгермәде, Заһид Шәркый, кулын Әхмәтсафаның иңсәсенә салды:

—Афәрин, егет икәнсең. Шулай, бер-берегезгә ярдәм итеп укуыгызга чын күңелдән куанам,—диде һәм рөхсәт сорап тормастан Зиннәтнең дәфтәрен алып актара башлады.—Катлаулы нәрсәләр бар монда...—дип, ул янә бер мәртәбә Әхмәтсафаның эшен хуплавын белдерде.—Афәрин, иптәш Дәүләтъяров, афәрин.

«Иптәш» дип дәшү шулкадәрле ят һәм шул ук вакытта кешене үсендереп җибәрә икән, Әхмәтсафа бер баскыч югары күтәрелгәндәй булды. Биеккә чөелгән арада күз чите белән генә Заһидәгә дә караш ташларга өлгерде. Заһидә исә күзен аска төбәп, дәшми басып торуын белә иде.

Заһид Шәркыйның Әхмәтсафаны мактап алуы, озын колак Мәҗитнең кай җиренәдер ярамады.

—Кем кемне өйрәтәдер бит әле,—диде, саңгырау тавыш белән.—Зиннәт үзе башлы егет. Ярдәм итәм дип, маңгаеңны идәнгә бәрсәң дә булмый ул. Булырдайның нәмәсеннән билгеле, ди. Ышы бу дөньяда үзенә файдасы булмаса, кеше бармагын да селкетми. Зиннәт Әхмәтсафаны урысчага өйрәтә. Нишләп анысын искә алмыйсыз?—диде ул, борынын лыш-лыш тартып.

—Дәүләтъяров, бу хакта үзе әйтергә тиеш иде дә, маладушничить итә...—дип, сүзгә кушылды Фатыйх Сәгыйтов.—Ә сез аны иптәш дисез...—

диде ул, мыскыллы тавыш белән.

«Моны юридик белеме булган Ленин дигән бәндә куллануга керткән. «Иптәш» сүзен хөкем-мәхкәмә эшләрендә йөрүчеләр, бигрәк тә прокурор дигәннәре яратып куллана. Ленин шул прокурор булырга хыялланып та, була алмагач, бу сүз белән фиркадәшләрен атап йөртә башлый. Прокурор гаепләүче. Иптәш сүзен яраткан икән, димәк ки, Ленин да башкалардан гаеп эзләп йөрүче инде», -дигән иде ул бервакыт.

Көтмәгәндә Фатыйхның ана бәйләнүеннән аптырап калган иде.

Бәхеткә, сүзгә Саттар кушылды. Саттар Ишбулдин институтта иң көчле егетләрнең берсе. Яхшы укый, уку эшләре комиссиясенең актив әгъзасы иде.

—Нигә үзегез башта ярдәмгә килмәдегез Зиннәткә?!—диде ул кайнарланып. Мәҗит белән Фатыйх шундук тынып калдылар.—Әхмәтсафа, гомумән, институтта беренче булып, артта калган сыйныфташларга ярдәм эше оештыруның инициаторы булды. Син, Мәҗит, үзең урыс теленнән, хисаптан чеп-чи надан.—«Надан» сүзен болай мангаена чәпеп әйткәч, Мәҗитнең күзе урыныннан кубып, колак артына тәгәрәп, кире оясына кайтып утыра алмый азапланды.—Зиннәттән көлеп йөргәнче, аннан үзенә өстәмә дәрес бирүен үтенсәң, яхшырак булыр иде. Синең аркада сыйныфыгыз «ташбака» исеме алды.

Мәҗит, Саттарның һөҗүмен кире каккандай, сынар кулын канат сыман җилпеп алды да, ишеккә ташланды. Аның:

—Харап, Каргалыда икән укымышлылар,—дип, мыгырданып үткәнен Заһид Шәркый көлемсерәп карап калды.

Заһид Шәркый — патша армиясендә хезмәт иткән солдат. Гражданнар сугышында да катнашкан. Өстенә һәрвакыт шинель киеп йөри, аягында, кайсы сугыштан калганы билгесез, башы тишелгән, шулай да, яхшы итеп каралтылган ботинка. Нәзек, озын буйлы әлеге мөгаллим барлык студентларның да яраткан укытучысы иде. Аның төп вазифасы—институтта сәяси—агарту эшләрне оештыру булгач, дәресләрдән соң үткәрелә торган барлык чаралар өчен дә турыдан-туры җавап бирә иде.

Көтмәгәндә купкан бәхәс шулай көтмәгәндә басылып та калды. Заһид монда керүләренең сәбәбен аңлатты:

—Сез, яшьләрнең яраткан шагыйре Такташ Оренбурдан китәргә җыена. Афзал Таһиров белән сөйләштек тә, институтта шагыйрьнең саубуллашу кичәсен үткәрергә булдык. Кызлар инде кичәнең сызмасын да төзеп куйганнар. Аның белән танышып чыктым, күңелле генә үтәр сыман дигән фикер туды миндә.—Ул үгезне мөгезеннән дигәндәй, Әхмәтсафа янындагы буш бүкәнгә килеп утырды да йомышын әйтеп салды.—Кичәнең ярты уңышы—алып баручыларда. Сиңа, Әхмәтсафа шушы эшне тапшырабыз. Заһидә белән икегез ерып чыгарсыз дип уйлаштык...

Заһидәнең күзендә яшь чагылып китте, ул, артка борылып, борын тирәләрен җыештырып алды. Гайшә кызны чын-чынлап шелтәләп тә ташлады:

— Җитте, Заһидә! Ничә тапкыр әйтергә кирәк сиңа?! Такташ китә дип бөтен институт кызлары яшь түгә башласа—туфан калкыр. Кичәне көймәләргә төялеп, күз яшьләре дингезендә үткәрергә туры киләчәк. Такташ—әйбәт шагыйрь. Аны шуның өчен хөрмәт итәбез, яратабыз. Бер син генә түгел, барыбыз да!—дип, басым ясап әйтте ул. Аннан шаяртуга күчте.—Безнең егетләребез кимме шагыйрь Такташтан?—Шул арада Әхмәтсафага күз кысып алырга өлгерде. —Әйеме, Әхмәтсафа!

Такташ өчен Заһидәнең болай үрсәләнүен күреп, егетнең йөрәге кысылып куйды. Шулай да, үз-үзен җиңеп, Заһид Шәркыйдан кичәнең сызмасын аңлатуын үтенде. Аңышкач, көттереп кенә:

—Нәрсә әйтергә дә белгән юк...—диде, кичәне тиешенчә алып барып чыгуына ышанып җитмичә.—Минем әле мондый зур сәхнәгә чыкканым, кичәләр алып барганым юк. Куркыта...

—Кара әле моны! Сәхнәдән куркам ди. Кеше ышандырырсың.

Нәмә сөйләп торырга—чын артист инде ул!—дип, Гайшә егетнен салпы ягына салам кыстырды.—Такташның шигырьләренен ятлап, декламация сөйләп тә жибәрсә...

—Дөрес,—дип, Гайшәне куәтләде Заһид Шәркый.—Аннан, гимнастик күнегүләр ясар дип тә ышанып торабыз. Афзал агай синең турникта кыланмышларынны шаккатып сөйли әнә.

Студентларны Һади Такташ дигән мишәр егете белән нәкъ менә Афзал Таһиров—физкультура укытучысы таныштырды да инде. Егетнең бүгенге татар дөньясында иң көчле, соклангыч шагыйрь икәнлеген дә кызып-кызып ул аңлатты. Аеруча, Афзал абыйсы Әхмәтсафаны үз итә иде. Аның дөньяга карашын үзгәрткән, укуына зур йогынты ясаган кешеләрнең берсе—Афзал Таһиров иде.

Афзал Таһиров—утыз яшьне үтеп баручы, һәр нәрсәгә сәяси күзлектән карарга һәвәс кеше иде. Җинел адымнар белән барышыннан ук ниндидер ашкыну, тыелгысыз дәрт сизелә. Студентларны бөтенләй шаккатырганы—ул кышкы чатнама суыкларда да яланбаш йөри. Озын чәчле, ыспай гәүдәле, хәрбиләрчә шакаеп—гәүдәсен төп-төз тотып йөрергә ярата. Физик яктан да көчле укытучы иде. Аның янәшәсендә Такташ малай гына сыман. Яшь аермасы шактый булса да, күрәсең, бик дуслар, еш кына институтка да бергәләп киләләр. Аларны тагын якынайткан нәрсә—икесе дә «Юксыллар сүзе» дигән гәзиттә эшлиләр. Афзал Таһиров—мөхәррир, ә Такташ шул ук гәзиттә җаваплы сәркәтип. Әхмәтсафа бу эшләрнең кайсы ни дәрәҗәдә җаваплы икәнлеген аерып әйтә алмаса да, кемнең—баш, кемнең түш икәнен яхшы белә. Шулай икәүләп сөйләшә-сөйләшә институт бинасына килеп керәләр алар. Гаҗәбе—моңарчы тыныч кына яшәп яткан бинага әллә нәрсә була—мизгел эчендә шау-гөр килеп тора башлый ул. Иң беренче күзгә ташланганы шул—Такташны кызлар сырып ала. Һай яраталар, һай үз итәләр аны кызлар! Каян сүзен табып бетерәләр диген. Кыскасы, юк-бар сораулар биреп шагыйрь егетне аптыратудан да шәп шөгыль бар микән алар өчен?!.. Һади күкнең жиденче катында. Аның үзенә бу хәл ошый, әгәр Афзал Таһиров җиңеннән эләктереп, мәжбүриләп диярлек ияртеп алып китмәсә, яшь-җилкәнчек, бигрәк тә кызлар белән инде, дөньясын онытып сәгатьләр буе сөйләшеп торыр иде.

Физкультура дәресләре махсус җиһазландырылган бүлмәдә үтә. Афзал абыйның горурлыгы иде ул. Мактана төшеп кабатларга ярата:

—Мондый бүлмә Оренбурда гына түгел, якын-тирә шәһәрләрдә дә юк әле. Снарядларны,—шушы сүзне ул аеруча басым ясап әйтә,—бөтен Рәсәй буйлап җыйдым. Үз кулларым белән көйләдем, беркеттем. Көчем әрәм китәр микән, дип, курыккан идем, шөкер, үземә эшләргә насыйп булды.—Әлеге сүзләрне Такташка да әйткән иде. Аңлатма биреп китәсе итте.—Берара губерна мәгариф бүлеген җитәкләргә туры килде миңа. Нургали Надиев, ул чагында мәдрәсә директоры, көн саен яныма килә дә, физкультура бүлмәсе ясарга хыяллануы хакында сөйли.Тел төбе аңлашыла—мондый зур эшне башкарып чыгу өчен таяныч кирәк. Мин якладым, булышырга сүз бирдем. Ахыргача үземә ерып чыгарга да туры килде. Шуңа күрә, гәзиттә эшләсәм дә, физкультура дәресен кемгәдер бирәсем килмәде. Бигрәк тә, менә шундый егетләр бар чакта,—дип, җай чыкса, Әхмәтсафаны үз ягына чакырып китерә.

—Дәүләтъяров, әйдә әле тәннәреңне язып ал. Күрсәт һөнәреңне!—дип, әмер бирә егеткә.

Әхмәтсафага шул гына кирәк тә. Көне буе шушы бүлмәдә бикләп яткырсалар да риза. Иң элек аякларын өскә күтәреп, кулы белән йөреп китә. «Эһ» тә итми бүлмә буйлап бер әйләнеш ясап чыга. Аннан мәтәлчек атып китә. Берсендә һөнәрен Такташка да күрсәтергә туры килде. Егетнең бу кадәр кылануына Такташның күңеле булып, килгән саен, Афзал агайдан узып, Әхмәтсафадан гимнастик күнегүләр ясавын үтенә. Үзе читтән карап, бу хәлгә хәйраннар калып, дөньясын оныта, кулларын уып, ара-тирә сөйләнеп ала:

—Выт бит әй! Сөяге юк инде моның, сеңердән генә тора бу...

Такташның юк кына нәрсәгә дә исе китүенә, чын күңелдән сөенә алуына Таһиров үзе дә куанып, Әхмәтсафаны дәртләндергәннән дәртләндерә:

—Әй афәрин... Әй булдыра... «Күпер» ясап та күрсәт...Сальто дигәнен дә ясап җибәрсәң. Һо-оп...Менә мондый егетләр бар бездә!—ди ул ахырда.

Әхмәтсафаның арырга исәбе күренми. Ял итеп тормыйча, әнә сыйныфташлары янына китеп, аларга күнегүләр ясарга булыша. Монысы да Таһировның күңеленә хуш килә.

—Дәрескә килеп житә алмый тоткарлансам, шушы егеткә ышаныч. Тумыштан спортчы бу егет. Әле бокс, йодрык сугышы белән җенләнде. Институтта түгәрәк ачып йөри. Кулларын күр аның! Крестиян малае бит—кирәк кадәр бер-бер кулы. Яшьләр үсә,—ди ул, хискә бирелеп.—Без яшьлекне патша окопларында исраф иттек, революция ялкынында яндырдык...

Такташ аны тынычландырырга ашыга:

—Алай димә, Афзал әзи. Кая әле сиңа картаю! Картлык—карт аю, синнән ерак йөри әле. Җәһәннәмгә олаксын сиңа киләсе картлык,—ди ул, көлеп.

Һади бер-ике кичәдә Әхмәтсафаның декламация сөйләвен дә ишетеп сокланды. Егет үзе артык салмак холыклы булгангамы, алар танышып-дуслашып китә алмадылар. Шулай да Такташ аны үз итеп, якын итеп йөри, очрашканнарда да хәл-әхвәл сораша, укуы белән кызыксынмый китми иде. Саубуллашу кичәсен Әхмәтсафаның алып баруын Афзал Таһировтан үзе үтенгән икән. Һәм Заһид Шәркый бу үтенечне егетнең үзенә дә житкерде менә.

Кичәгә бер атналап кына вакыт калып бара. Озакка сузар чама юк. Такташ үзе сорагач, Әхмәтсафа каршы килү хакында уйламады да. Баштагы кыенсынып торуны онытып, шунда ук сызманы дикъкать белән карап чыктылар. Әхмәтсафа тәкъдиме белән студентлар оркестры чыгышы да программага кертелде. Ул халык көйләре уйнарга тиеш булды. Оркестрга кушылып җырларлык җырчылары да бар. Аннан сүз шагыйрьнең үзенә бирелеп, әле «десерт» өчен генә берничә шигырен укып, сәхнәдән төшеп торачак. Төрле номерлар күрсәтеләчәк, студентлар Такташ шигырьләрен өйрәнеп, декламация сөйләячәкләр, соңыннан инде, сәхнә тулысы белән шагыйрь карамагында. Тамашачылар хушланганчы шигырьләрен укысын...

...Алдагы көннәрдә янып-пешеп репетицияләр үткәргәндә, Әхмәтсафа үз янында Заһидә булуын тоеп, аеруча илһамланып йөрде. Кыз үзе дә егеткә битараф түгел сыман, тик ниндидер көч аның хисләрен богаулап тота. Әхмәтсафа ятышсыз егет түгел, кайсы гына кызга тартылса да, моны теге кыз язмыш бүләге дип кабул итәр иде,һичшиксез, сөенә-сөенә егеткә дуслык кулын сузар иде. Бу хакта ана Гайшә инде ун мәртәбә әйтте. «Әгәр күңелемдә башка егет булмаса, ике дә уйламый шушы Әхмәтсафаның башын әйләндерер идем,»—дип тә ычкындырганы да бар. Заһидә авыр сулап куйды ул чакта. Менә бит ничек, Гайшәнең күңеле күңел дә, Заһидәнекендә таш микәнни?.. Күңел түрендә балкып янган йолдыз—зәңгәр күзле, шаян табигатьле мишәр баласы—Такташ булуын белмиме ахирәте?!. Белә... Имеш, шагыйрьгә, буй житмәслек йолдызга үрелеп, кысыр хәсрәттән саргаеп кипкәнче, әнә—янында бәхет кошың, шуны эләктер, дип әйтәсе килүе аның. Их, күңелнең җилкенүен шулай, салкын акыл ихтыярына буйсындырып, янадан мәңге кабынмаслык итеп сүрелдереп булса иде дә... Кызның уй-теләкләрен аңлаучы юк. Аннан көләләр генә. Хәер, нигә анда әллә кемнәр әллә ни сөйләми—тел сөяксез, мәхәббәт утында янган йөрәкнең берсендә дә эше юк—януы яну. Көтмәгәндә дөрләп кабынган күңел утын сүндереп булмый икән. Заһидәнең уе—гел Такташ тирәсендә бөтерелә. Шушы егет белән саташып, хыялланып бетә бугай инде. Төннәрен Такташ дип мендәрен кысып кочаклап ята. Саташулы халәттә шыбыр тиргә батып уяна,

янәшәсендә әле генә үзенә сыенып яткан «мәхәббәт төенчегенең» кинәт юкка чыгуына риза булмаган хыялы чынбарлык белән шактый озак тарткалаша әле. Мәхәббәттән иләсләнгән җан эчен җыя алмаган бәпкә белән бер икән ул. Бүген көндез баскычка абынып егылуы да Такташ аркасында. Нәкъ шушы мәлдә Һадиның тузган чәченә кунган җепшек кар бөртекләрен кагарга дип сак кына үрелгән иде. Тегесе зәңгәр күзләрен нурландырып, дәшми генә елмаеп тора. Хәерсезгә каршы, әлеге хыялый мизгел кызның күнеленә баскычтан күтәрелеп барган чагында килеп керде шул. Һәм...Заһидәнең бөтен сыйныф алдында мәтәлеп китүе белән тәмамланды. Их син сөю, әх-ти мәхәббәт! Кайсы вакытта, кем күңелендә ни рәвешле кабынып китмисең син...Көтмәгәндә, уйламаганда кемнәрне утларга салып тилертмисең дә кемнәрне хыял офыгы аръягына илтеп ташламыйсың. Бераз гына, зәррә кадәре генә акылга буйсынсаң иде син! Болай ук булмас иден, яшь җанны зиһенсез-һушсыз калдырмас идең, хәсрәт-сагышлардан шаштырыр чиккә җиткермәс идең. Мәхәббәт—һәркем башына ишелеп төшәргә мөмкин булган ихтыярга буйсынмаучы йөгәнсез һәм дуамал хис; дөньяның иң оста табиблары да дәвалый алмый торган өянәк. Мәхәббәтне мәхәббәт белән генә дәвалап була. Югалту ачыларын, җәбер-золымнарны да вакыт оныттыра ала, мәхәббәт ялкынын гына сүрелдерә алмыйдыр ул. Ходайның иң зур җәзасы—адәм баласын зиһенсез калдыру. Җавапсыз мәхәббәттән акылдан язган кешеләр хакында да ишеткәне бар кызның. Димәк ки, һич арттыру түгел, Заһидәне Ходай шушы сынауга дучар иткән. Ахыры хәерле бетсен.

Репетиция вакытларында Әхмәтсафа белән Заһидә бер-берсе каршында үзләрен җайсыз-уңайсыз хис ителәр. Әйтерсең, кызның егет алдындамы, әллә егетнең кыз алдында ниндидер гаебе бар. Һич кенә ачылып китә алмыйлар—сөйләгән сүзләре, кыланмышлары табигый килеп чыкмый. Моны күреп торган Гайшә бер үртәлсә, мәсьәләнең төбен аңлаудан ерак булган Заһид Шәркый тәмам гаҗиз кала иде.

...Кичә көне ( кичә үтәчәк кич дисәк, дөрес булыр) килеп җитте. Ашханә (мондый тамаша-кичәләр беренче каттагы ашханәдә үтә иде) күз ачып йомганчы студентлар белән шыгрым тулды.

Алгы рәттә, нәкъ Заһидәнең хыялындагыча, кояштай балкып шагыйрь үзе утыра. Ул, Афзал Таһировтан калышмаска теләпме, кыш көне яланбаш, өстенә җинелчә юка пәлтә киеп йөри. Пәлтә аңа шундый килешә, озын чабулары аяк йөзенә җитә язгангамы, урта буйлы гәүдәсен шактый калку да күрсәтә әле. Шагыйрьгә самимилек, хөрлек төсмере өстәп муенында ак шарф ята. Күзләре исә диңгез зәңгәрлеген хәтерләткән шикелле, һәрхәлдә мондый чисталыкны йә биек күкләрдән, йә төпсез диңгездән генә табарга була торгандыр. Шагыйрь белән янәшә, әдәби түгәрәк җитәкчесе, йөзеннән беркайчан да басынкы елмаю китмәгән Шәриф Камал утыра. Алар белән беррәттән үзен дәрәҗәлерәк тотарга яраткан Афзал Таһиров, институтның башка мөгаллимнәре тезелешеп киткән.

Сул яктан, гадәт буенча кызлар урын алды. Алар тилгәннән качып, әнкәләренең канат астына борын төртеп маташкан тавык чебиләре кебек, аз санлы мөгаллимәләр тирәсенә сырышалар. Болай карап торуга бик юаш, бичара вә мескен тоела алар. Янәшәдә укытучылар булса, тыныч кына үз алларына оеп, суфиланып утыралар. Тәүфыйк ияләре инде менә. Укытучы-мөгаллимнәр килеп җиткәнче бу чәчбиләр гайбәт сатып, шаугөр килеп хәлдән тайгандыр дип бер генә кеше дә уйламас. Әгәр чит-ят кеше күреп тормаса, кызлар шактый бәйсез кыланалар, үзләрен үчекләп маташкан егет аламалары белән әрепләшеп алырга да күп сорамыйлар. Һәрхәлдә, аңлашыла торгандыр, шушы рәвешле бер урынга дистәләгән кыз җыелган җирдә үзгә бер тормыш кабынып китә. Егетләр яшәгән бүлмәгә ялгыш кына бер кыз килеп керсә дә, хиссият тиз үзгәреп китүчән бит. Шушы вәзгыятьне искә алганда, залда аерым күтәренкелек, аерым бер атмосфера хөкем сөрә. Залда утырган Такташ, Шәриф Камал,

Афзал Таһиров сыман әдипләрнең булуы гына менә сәбәпче дисәк, хакыйкатькә хилафлык китерү булыр иде. Мондый күтәренке рухның сәбәбен ара-тирә сүзгә мавыгып, онытылып киткәләсәләр дә чыгырдан чыкмаган, мөгаллимәләрнең ачуларын китермәслек итеп сак кына көлешкән—чыркылдашкан кызлардан эзләсәк яхшырак булмас микән?!.

Концерт, алдан уйланганча, матур гына башланып китте. Оркестр «Каз канаты» көен уйнап, күңелләрдәге очынуларны баса төште, аннан «Ком бураны» көе уйналып, йөрәкләр тибешен шушы кичәгә кирәк кадәренчә ешлыкка житкерде. Моңлану—сыктап, сыкрап утыру түгел, жанның вакыты белән татлы, вакыты белән якты, вакыты белән тирән һәм серле халәт кичергән мәле. Оркестр уйнаганда күңел офыклары киңәеп китте, уй-хисләр тагын да жанлырак, нурлырак сыман тоелды, янәшәдә утырган кешеләр дә жанга якынрак, ягымлырак күренгән кебек. Мондый күтәренкелек залны жылытып, кунаклар өс киемнәре белән утыруны килештермичә, пәлтәләрен салып, урындык артларына элеп куйдылар. Чыгыш арты чыгыш игълан ителеп, чират шагыйрьгә житте.

Шагыйрь алкышлардан кыенсынган сыман салмак кына урыныннан күтәрелде, тыйнак кына башын иде. Сәлам шикелле сары чәчләреннән серле дулкын йөгерде. Килешә, һай килешә иде шагыйрьгә бу рәвеше. Шундук Такташның йөзендә дәрт, тәвәккәллек хасил булды. Ул, күп уйлап тормастан, артык биек булмаган сәхнәгә жиңел генә сикереп менде дә, йөзенә үк сибелеп төшкән чәчләрен учы белән артка сыпырып куйды. Юри эшләгән кебек—кулын алуга чәчләр жайсыз гына янә таралып төште. Шагыйрьнең исе дә китмәде. Булгач-булсын инде дигәндәй, башын кинәт артка чөеп, тыңлаусыз чәчләрен янә артка ташлады. Ни хикмәт, моңарчы бирешми, каруланып торган чәч көлтәсе, шушы кисәк хәрәкәтне генә көткән икән—баш түбәсенә ипле генә ятты да куйды. Шушы тыңлаусыз чәчләре серле көчкә ия икән: алар белән мәш килеп, булашып алган арада Такташ залдагы кызларның күңелен яулап, аларны «аһ» иттерде дә куйды.

Шагыйрь башта тамашачыларга яхшы таныш «Караңгы төннәрдә», «Жил сөйли» кебек шигырьләрен укыды. Зал мәрткә киткән кебек тын да алмый тыңлап утыра. Тамашачы шигырьдә эреп бетеп барганда, шагыйрь аларны уятып, жиргә төшерәсе итте. Ул сәхнә алдынарак килеп, беренче рәттә утырса да, моңарчы игътибардан читтән кала биргән, шигырьләр тәэсирендә йөзенә алсулык кабынган, шуның нәтижәсендә бигрәк тә чибәр күренгән кызга төбәп, берничә сүз әйтүне кирәк тапты:

—Жәмәгать, сөекле тамашачыларым, бүген мин сезнең янга бер кунак кызы алып килдем. Ул—сәяси курсларда белем алучы Гөлсем туташ...

Бөтен зал, әлеге бәхетле туташның йөзен күрә алмаудан гажиз калып, алга тартылып куйды. Гөлсем туташ кыю икән, тартынып тормады, битенә кунган көләч елмаюын сүндермичә урыныннан күтәрелде. Залга борыла төшеп, башын жиңелчә иеп алды һәм кире урынына утырды. Сул якка укмашкан кызлар дөньясы каш-керфек тибрәнешләре, йөзләрендә уйнаклап алган сәер чалымнар, кисәк ташланган яндыргыч карашлар белән бу хәлнең гайре табигый булуын, хәтта ки гафу да ителмәскә мөмкин икәнлеген (Без оештырган кичәгә чит кызлар ияртеп килүләрмени, жүләр шагыйрь?! Без үзебез аннан кимме?.. Бу адымың белән безне ничекләр кимсеткәнеңне аңлыйсыңмы син!?.) сәхнәдәге шагыйрьгә искәртеп маташты маташуын, әмма юкка гына тырыштылар, ахрысы. Такташны болай гына акылга китереп булмаганлыгын тиз аңыштылар. Шагыйрьнең күзенә Гөлсем туташтан башка беркем дә күренми иде. Институт кызлары ихтыярына буйсынудан үткән, «кулдан ычкынган» иде. Такташ бу үзгәрешләрне бөтенләй сизми, һаман Гөлсем туташка мөкиббән хәлдә торган килеш, кызларны урыннарына кузгалмаслык итеп беркетеп куйган янә ике-өч жөмлә ыргытты:

—Шушы көннәрдә генә «Таң кызы» дигән шигырь яздым. (Ул

«шиырь» дип әйтә иде.) Бу шиырьне мин Гөлсем туташка багышладым. Хәзер бу әсәрне сезнең игътибарыгызга тәкъдим итәм.—Такташ Гөлсем туташка карап ягымлы елмайды, дустанә баш иеп алды.

Такташ залда диварларны ватардай булып уйнап алган кара дулкынны тоеп алган иде инде. Үзенең ялгышлык, хата җибәрүен дә чамалады. Шигырьнең Гөлсем туташка багышлануын, бәлки, әйтмәскә дә кирәк булгандыр? Анысы мөмкин эш түгел, нәкъ шушы сүзләрне ишеттерү өчен чакырды бит ул әлеге кичәгә сөйкемле туташны. Шигырьне хәзер түгел, икенче бүлектә, иң ахырдан укырга кирәк булгандыр, бәлкем. Хисләр иркендә иде шул, уйлап җиткерә алмады, бигайбә, кызлар голәмәсе. Һич тә сезгә карата явызлык булып чыгар димәгән иде лә... Сүз—чыпчык түгел, әйтте, авыздан чыгып ычкынды. Кире тотып алып, тел артына салып куеп булмый. Ул аеруча күтәренкелек һәм җилкенү белән, залда утыручы кызларга карап, укый башлады. Шигырьнең уртасына җиткәндә инде аңнар саташа, зиһеннәр менә-менә ычкынырга әзер сыман иде. Шагыйрь исә укый да укый:

Таң кызы, Гөл, ник чыктың да юлларыма,
Бәхет гөлен тотып нечкә кулларыңа,
Маңгаемнан үбеп мине, ник югалдың,
Тагын кире төренеп таң нурларына?

Әсәрнең шигъри көче, шагыйрьнең уку осталыгы һәм үз-үзен сәхнәдә тотышы залны тәмам әсир иткән иде. Шушы мизгелләр эчендә, сөйләсәң, кеше ышанмас нәрсә булып алды—кызлар Такташны тулысынча гафу итеп өлгергәннәр иде инде. Чөнки Ул шигырьне озын керфекләре арасына үзе дә кереп югалыр хәлгә җитеп, башын түбән иеп, колакларына кадәр кызарып утырган кунак кызы—Гөлсем туташка түгел, ә нәкъ менә аларга, кызлар утырган якка карап укыды бит. Шигырьнең аларга, фәкать аларга гына төбәп укылуы институтта белем алучы кызларның барысына да көн кебек ачык иде. Шулай булуы алар арасыннан беркемне шикләндерми дә иде. Залга якты дулкын таралды. Теге чакта минут эчендә хәлсезләнеп аяк астына егылган яшьлек хисләре яңадан күтәрелеп, җан түрендә урын алдылар. Ул гына да түгел, кызларның һәммәсе шагыйрьгә теләктәш иде. Аның саф сөюдән шул кадәрле тилмерүен күз алларына китереп, хисләр ташкынына түзә алмыйча, яшь коеп утыралар иде. Шагыйрь кадәр шагыйрь шулай өзгәләнсен әле... Иң изге хисләрен, мәхәббәтен, язмышын, гомерен шушы таш бәгырьле туташка тапшырып Такташ һич кенә дә дөрес эшләмәгән шул. Бер дә кинәш бирерлек дуслары, иптәшләре юк микәнни соң янында?.. Булса, ни карыйлар, нигә аны дөрес юлга күндермиләр, ә? Сөеп-сөелеп кенә яшәргә тиешле шушы изге җанның күкрәгенә сөю хәнҗәре батыр да, янадан егетне утка сал, күзләрен күгәртеп көттереп йөр, янына да килмә, имеш. Харам бу туташка шагыйрьнең мәхәббәте. Лаек түгел ул аңа, мыскал хәтле дә лаек түгел. Менә бит ничек—егетне сөю газапларына дучар ит тә, үзең шуннан тәм, ямь табып, качышлы уйнап йөр!.. Тамашачы кызларның барысында да Гөлсем туташка карата нәфрәт хисләре уянып өлгерде. «Кыланчык, мәгънәсез... Шагыйрьнең хисләрен кадерсезләргә, аның белән шулай уйнарга ярыймы соң?...» Кызлар ара-тирә ачулы карашларын Гөлсем туташ ягына ыргыткалап алалар. Гөлсем туташның исә үз хәле хәл. Керфекләре эченә кереп йомылган ул, урындыгына бөтенләй сеңеп бетеп, тын да алмый утыра.

Такташ шигырь укылып беткәнче үк үзенең «аклангандыгын» сизеп алды. Котырынып кул чабулар-алкышлар астында, баштагы мәлдәгечә уңайсызланган кыяфәт белән тамашачыларга башын иде. Алкышлар көчәйде генә. Шагыйрь, кулын күкрәгенә куеп, бераз гына тын торды, янә баш иеп алды. Шунысы гаҗәп, салам чәчләре инде башына чат ябышканнар, һич кенә дә хуҗаны кыен хәлдә калдырып маңгайга ишелеп тормыйлар иде. Такташ сәхнәдән сикереп төште һәм күңелендә уйнаган

тантаналы хисләр эчендә урынына барып утырды. Утырган унайга, үз итеп Гөлсемнең кулына кагылгандай итте. Моны күреп алган берничә кыз әлеге хәрәкәтне «бик үк урынлы түгел» дип таптылар. Шулай да ана үпкә саклаучы беткән иде инде. Бу минутларда Такташны кичерергә онытып, һаман һушсыз көе сәхнә артында басып торучы бер генә кыз заты калды—ул Заһидә иде.

Шагыйрьдән соң да берничә номер башкарылды. Кыз һуш җыя алмый әле... Заһидәнең халәтен аңлаган Гайшә, кызның җилкәсеннән тотып, җилтерәтеп алды:

—Исенә кил, ахирәтем,—диде ул. Заһидәнең әллә кая төбәлгән төссез карашын күреп, Гайшәнең җаны куырылды.—Сәхнәгә чыгасың хәзер. «Әхмәтсафа Дәүләтъяров Такташның «Үтерелгән пәйгамбәр» дигән шигырен укый,»—дип әйт. Җитте!..—Ул чын-чынлап ачулана башлады.—Концертны өзсәң, бел—Заһид Шәркый институтта бер көн тотмый сине!

Шушы сүзләр тәэсиреннән булса кирәк, Заһидә айный төшеп сәхнә уртасына атлады. Тамагын кырып алуы сәер тоелды.Ул әллә нинди һавалы, ачулы һәм шул ук вакытта тормыш өчен бик тә мөһим нәрсәне мәңге табылмаслык югалткан чарасыз хәлдә залга карап торды да, батырланып авызын ачты:

—Сөекле шагыйребез Һакташ... Такташ...—Шушы сүзләрдән соң, ни әйтергә икәнен оныткандай, туктап калды.

Беркайчан да сабырлыгын җуймаган Шәриф Камал Заһидәнең сүзләрен рифмага-көйгә салып, дәвам иткән булды:

Һакташ, Такташ,
Син бит миңа якташ...

Зал көлеп җибәрде. Шушы хәл Заһидәне бөтенләй чыгырыннан чыгарды, «беткән баш беткән, ник җимерелми дөньясы» дигәндәй, залдагы көлешкән тавышларга битараф кына кулын селтәп, дәвам итте:

—Сөекле шагыйребез... э-э... Кадалып китсен, оныттым... Әхмәтсафа... Пәйгамбәр... э-э... Үзең әйт инде...Торма күзенне шардай ачып...—дип кычкырды да сәхнәдән чыгып йөгерде.

Әхмәтсафа чыккач, көлүләр тагын көчәйде. Заһид Шәркый басып, залга ачулы караш ташлагач кына тынды студент халкы. Тик эш узган иде инде. Егет әсәрне укып китә алмый азапланды. Афзал Таһировның үзенә төбәлгән җылы карашын тотып алгач кына, җан иңде. Әхмәтсафа ачык тавыш белән:

—Һади Такташ. «Үтерелгән пәйгамбәр,»—диде һәм шигырьне укый башлады. Әхмәтсафа, билгеле, Такташка караганда кайтыш укый иде, әмма шигырьне аңлап, аның эченә кереп укуы тамашачыларга шулай ук әйбәт тәэсир итте. Инде шигырьнең:

Кояш—шаһит: илем, иркем өчен
Сугышып йөрдем, әнкәй, ул күрде!
Зөбанилар, явыз зөбанилар,
Алар... Алар мине үтерде.—

дигән юлларына житкәндә күпләр тетрәнеп тешләрен кыскан иде. Кайберәүләрнең күзендә энжедәй яшь елтырап, битләре буйлап аска тәгәрәде. Алар аны сөртергә уйламыйлар да. Беркем беркемнән кыенсынмый, барысы да Такташның кодрәтле шигыре тәэсирендә, барысы да икенче дөньяда—Такташның шигъри дөньясына кереп югалган иделәр.

Шигырь укылып беткәч, гөрләтеп кул чаптылар. Әхмәтсафа пәрдә артына кереп китәм дигәндә, шигырьдән үзе дә тәэсирләнгән Һади Такташ сәхнәгә кабат сикереп менде һәм:

—Булдырдың, брат, рәхмәт,—дип, нык итеп егетнең кулын кысты.

Әхмәтсафа сәхнә артына чыккач та үзен кулга алырга тырышты. Аның күңелен тырнап торган нәрсә—Заһидәнең сәхнәдә ялгышып, сәер хәлдә чыгып китүе иде. Ул аның өчен борчыла, кызны юатасы,

тынычландырасы килә. Ләкин Заһидә сәхнә артындагы кечкенә бүлмәдә юк иде. Сәхнәдә Такташ яна шигырьләрен укый, ана котырып кул чабалар. Заһиданең залда булмавына иманы камил, ашханәнең тар коридорына чыгып йөрде. Анда да кызны таба алмады... Күнелсезләнеп, кире сәхнә артына әйләнеп кайтты. Заһидә юк икән, аңа кичәне берүзе алып барып, төгәлләргә туры киләчәк инде...

Ә сәхнәдән Такташ тавышы килә. Ул канатлана-канатлана шигырь укый иде.

## IX

—Акыллы кеше беркайчан да революция ясамый!—моны Мифтах мөгаллим әйтте.—Бу эшкә, әгәр аны эш дип әйтергә яраса, йә наданнар алына, йә хөсет күнелле, явыз ниятле бәндәләр кулы белән ясала түнтәрелеш. Иң куркынычы—жанында кемнәндер ни өчендер үч алу тойгысы котырган иблисләр генә яскана инкыйлабфәлән дип. Акыллары томаланган бәндәләр саташа ул революция дигән нәмәрсә белән.

—Безнең жәмгыять авыру иде. Патша Рәсәе дип аталган бина череп беткән иде. Сүтмичә, жимермичә мөмкин түгел иде,—дип, аңа каршы төшүен дәвам итте губкомнан килгән вәкил.—Яңа тормышны үз кулларыбыз белән төзергә тиеш без. Кемдер килеп рәхәт дөньяга чыгарыр дип уйлау—хата! Үзебезгә охшаганча, жаныбыз теләгәнчә төзелер ул тормыш.

—Авыру иде дисең, вәкил туган. Авыру кешене кулын кулга, аягын аякка аерып ташламыйлар, ә түземлек, сабырлык белән дәвалыйлар, аякка бастыралар. Аңлашылмый—кемгәдер нәрсәдер ошамый дип, булганны ват, туздыр, сүтеп ташла, жимер. Кем төзер кабаттан аларны?.. Ә бит төзергә, янабаштан шушы ук нәрсәләрне корырга туры киләчәк. Кешеләрне аклар, кызыллар дип, төсләргә аерасыз. Яшелләр, каралар дип тә сөйләүчеләр табыла. Аңлы рәвештә болай халыкны аерымлауның нәтижәсе аяныч булачак. Инде халыкның бәгыренә—дингә үреләсез. Монысы да гафу ителмәячәк! Рухыбызның көч алыр чишмәсе—диндә. Әгәр бу эшегездән туктамыйсыз икән, дин-иман юлында шәһит киткән меннәрчә батырларыбыз рухы сезне гафу итмәс!—Мифтах хәзрәт сәвит ызбасында утырган активка шелтәле караш ташлады. Ишек төбендәге почмакта бер-берсенә сыланып утырган Әхмәтсафа, Саттар, Әптериләргә төбәп күңелендәге рәнжүен әйтмичә булдыра алмады.—Сез, оланнар, ялгыш юлга кергәнсез. Әйе, заманында мин үзем дә Каргалыга яна тәртип урнаштыру нияте белән ашкынып килдем. Тик булганны ватып, жимереп түгел. Монарчы авылда хөкем сөргән кадими тәртипләргә каршы көрәшнең берләнбер вә дөрес юлы—балаларга жәдитчә белем бирү иде исәбем. Бу юлга өндәгән беренче кешеләрдән идем. Бәхетемә каршы, теләктәшләрем күп булып чыкты ул чакта. Чөнки минем әйткәннәрем, өйрәткәннәрем халыкка анлаешлы иде. Әйе, тәгълим-тәрбиядә яңалык, үзгәрешләр кирәк иде, әйе, балаларга дини белем белән беррәттән нигезле дөньяви белем бирү дә кирәк иде һәм мин кадимилек сазлыгына кереп баткан хәзрәт, имамнар белән тартыша-тартыша жәдитчә укытуны башлап жибәрдем. Сез минем иң беренче шәкертләрем булып, башыгыздан кичкән хәл-әхвәлләрнең барысына да шаһит булдыгыз. Безнең укыту бинасына ут төртергә маташтылар, мең бәлаләр белән юллап кайтарган әсбапларны туздырдылар, үземә, шәкертләремә кул күтәрүләр дә булды. Аталарыгызга кадимчеләр ниләр генә ишеттермәде... Түздек, тешне кысып түздек, күпме куркытсалар да, үгетләсәләр дә юлдан тайпылмадык. Халыкның күпчелеге яңача укыту ягында булды, шул көч бирде безгә. Әмма мин дингә, иманга тузан бөртеге кадәр дә кер төшермәдем. Иман безнең калебтә, ул инде мең еллар буе ныгыган, алтын-мәржәннәрдән дә асылрак

вә кыйммәтләрәк бер халгә килгән. Изгеләрдән дә изге иманга кизәнәсез икән, бик нык ялгышасыз, ай-һай нык ялгышасыз... Сак булыгыз оланнар! Әгәр дә ки хәзер туктап калмасагыз, киләчәктә башларыгызга күп бәлаләр китерәчәк бүген кылган гамәлләрегез.

Мифтах хәлфә чыгып киткәч, сәвит йортында тынлык урнашты. Авыр хәлдә калган сыман хис иттеләр яшьләр. Губком вәкиле генә сөенечен яшерә алмады: чакырусыз-нисез килеп, жыелышны тарата язган хәлфәгә ачуы чыккан иде аның. Ярый әле чыгып китә белде. Мифтах хәлфәнең авылда, бигрәк тә яшьләр арасында мөгаллим-остаз буларак, нинди абруйга ия булуын үз күзләре белән күрде ул бүген. Шушы мөхтәрәм зат чыгып киткәч, вәкил монарчы кулдан ычкынган тезгенне тагын үз кулына эләктерде.

—Ничек әйләндерә башны, ә?—диде ул йөзен чытып.—Белеп сөйли... Совет хөкүмәтенең таянычы, алтын баганасы яшь көчләрдә икәнен аңлый. Күр син аны, шәрә артын умарта авызына китереп тәрәсе нәмә! Йә әйтегез, быелгы елны җәй буе яңгыр яумыйча, игеннәрнең янып-көеп бетүендә сәвит хөкүмәтенең ни гаебе бар? Ә бит корбан бәйрәмендә, ягъни-мәсәлән, гаеттә вәгазьчеләрнең һәркайсы сәвит хөкүмәтенә ябырылдылар, дини бәйрәмне коткы тарату, пропаганда өчен файдаландылар. Сез, кыю яшьләр,—вәкил дә ишек катында утырган яшьләргә мөрәҗәгать итте,—гаеткә каршы чаралар үткәреп дөрес эшләдегез. Теләгегезгә ирештегез дә. Муллалар сезнең басымга чыдый алмадылар. Унбер мәхәлләнең берсендә дә тыныч кына гает намазы укылмады, гаеттән файдаланып калырга ашыккан дошманнарга сәвиткә каршы корткычлык эшләре алып барырга ирек бирмәдегез. Так держать, Әхмәтсафа иптәш!—дип, үзенә якынрак утырган Әхмәтсафаның кулын кысты.—Без өлкән буын,—губком вәкиленең үзен «өлкән буын» дип атавы бераз көлкерәк тоелды, чөнки кызыл гаскәрләр ягында бераз сугышып йөргән һәм яраланып шактый госпитальләрдә аунаган яшь кенә кеше иде әле ул,—сезнең белән горурланабыз. Монарчы татар дөньясында «икенче Мәккә» дип аталган Каргалы авылында кыю яшьләрнең дини хорфатларга беренчеләрдән булып каршы төшүләре, һөҗүмчән чаралар оештырулары губком тарафыннан игътибарсыз калмас!

...Урамга чыккач, егетләр озак кына сөйләшмичә бардылар. Аллагы көннәрдәге күңелне кыздырып торган җилкенү, көрәш дәрте сүнгән, сүрелгән, җанда авыр бушлык кына иде. Көзнең соңгы ямьле көннәре үтеп бара, озакламый яңгырлар башланыр дип тә хафаланмый күңел. Сәбәбе шул: башка еллардан аермалы буларак, көзге кыр эшләре инде әллә кайчан тәгәлләнде. Җәй буе җиргә өч-дүрт тамчы яңгыр тамдымы, юкмы. Илгә корылык килде. Игеннәр матур гына тишелеп чыктылар да, рәхимсез кыздырган эссе кояш нурларына түзә алмыйча саргаешып, кибеп беттеләр. Иң бәхетле дигән кешеләр дә, күп булса өч-дүрт капчык икмәк җыеп алдылар үз җирләреннән. Халыкны курку хисе басты—илгә шомлы адымнар белән шыр сөякле кулларын сузып ачлык дигән афәт килә. Ачлык котылгысыз иде. Ара-тирә сәвит җитәкчесе Зарифның: «Өметсезлеккә бирелмик, үз кулларыбыз белән яулап алган сәвит хакимияте күрә торып халыкны ачтан үтермәс,»—дип, күңелләрдә ышаныч, дәрт уятырга тырышса да, күпне күргән авыл мужигы моңа әллә-ни ышанмады. Сәвит хөкүмәтенең ярдәмгә килүе мантыйкка сыешлы түгел. Башта «продразверстка» дип, аннан «продналог» дигән булып, халыкның амбарларындагы соңгы икмәген дә талап алып чыгып киткән хөкүмәткә кул селтәгән иде инде алар. Революция дигәннәренә дә ышаныч беттегә чут. Дүрт еллап гомер үтте—һаман җимерү, һаман булганны тартып алу, халыкны талау. Төзегән бернәрсәләре күренми. Мондый илнең үзенә дә, хөкүмәт башында торганнарга да, әлбәттә, ышаныч юк. Авыз ачып әйтүе генә ансат түгел—авылда гаскәр булмаган чак сирәк, әгәр эчендә генә асраган уй-фикерләренне тышка чыгарып түксәң, дошман элемент дип, шәһәр төрмәсенә илтеп ябарга күп сорамаслар. Кулга алулар булгалап

тора, аннан кайткан кеше генә күренми. Бер япсалар, нык ябалар сәвитнекеләр... Халыкка ни күрсәтер бу хөкүмәт, бер Ходай үзе белә. Халык дәшмәскә өйрәнә башлады. Бары дини йолаларны үтәгәндә—мәчеткә намазга җыелгач яки гает көннәрендә була торган вәгазьләрдә генә эчне пошырган хәлләр турында ачыктан-ачык сөйләргә мөмкин иде. Шушы хәлне истә тотып, губком, мәчетләрдә намаз укуларны чикләүче карарлар кабул итте. Урындагы фирка әгъзаларыннан, яшьләр оешмасында торучы комсомоллардан гаеткә каршы төрле чаралар үткәрүне таләп итә башлады. Бу—Мәскәүдән үк бирелгән күрсәтмә иде. Диннең тамырына балта чабылса, иман корый. Имансыз халык белән теләсә нәрсә эшләргә мөмкин булуын коммунист түрәләр яхшы аңлыйлар иде шул.

Авыл өстендә шомлы тынлык. Үз тыкрыкларына борылып китә башлаган Әхмәтсафаны Саттарның тоныкк тавышы туктатты:

—Иртәгә мастерскойга төшәсеңме?

—Соңгы көн булыр инде, укырга китәбез бит...

—Шушы хикмәтләр белән йөреп, уку истән дә чыгып киткән,—дигән булды Саттар.

Быел җәй Әхмәтсафа көткәнчә булып чыкмады. Нигәдер Сакмар түрендәге урманнарны кисүдән тыйдылар. Гариф иртә яздан ук артельгә кешеләр туплап, агач хәзерләү нияте белән Урал ягына китеп барды. Ышанып көткән өйлек бүрәнәнең тәтемәячәген аңлап алган Мостафа агай, барлы-юклы акчаларын җыештырып, сәүдә эшенә тотынып карамакчы иде, беренче сәфәрендә үк уңышсызлыкка очрады. Орски ягыннан вак-төяк сатып алып, Оренбурга кайтып барганда, соңгы вакытта күбәеп киткән угрылар юлына каршы төшеп, әйберләрен талап алганнар. Үзен кыйнап, инде үлдегә санап бер чокырга ташлап киткәннәр. Ходайның рәхмәте беләндер инде, Мостафа агай аңына килеп, якындагы станцага барып житә алган. Миһербанлы бәндәләр очрап, аларның ярдәме белән көч-хәл Оренбурга, Гомәр абзыйларына кайтып егылган иде ул. Озак кына, өендә кан төкереп ятты. Көзгә кергәндә Госманның Кырымда, Перекоп дигән җирдә үлеп калуы турында хәбәр китерделәр. Бу хәбәрдән Мостафа агай бөтенләй биреште. Шәмсия Госманның үлү хәбәрен ишеткәч, нигәдер җилкенеп йөргән кебек иде, Әхмәтсафа беркөнне күреп алды, үги инәй лапаста үкси-үкси елый иде. Елады-елады да, үләне көеп беткән ишек алдында нидер эзләгән кыяфәттә бер әйләнде, ике әйләнде, өч әйләнде, аннан бер ни булмагандай башын туры күтәреп, авыз эченнән мөнәҗәткә охшаган нәмәрсә көйләп өйгә кереп китте. Аңламассың бу хатын-кызны... Хәлфи исенә төштеме, әллә яшьли әрәм булган йомшак күнелле Госманны җәлләп елыймы, монысын инде Әхмәтсафа белә алмады.

Әхмәтсафа белән Саттар, алдагы елда уку елына бераз мая туплап булмасмы дип, Каргалыда итек тегү мастерское оештырып җибәргәннәр иде. Әхмәтсафа, үзенең «каеш» кушаматына тугры булып, тире-күн эшенә оста булып чыкты. Белмәгәнен инде тернәкләнә башлаган әткәсеннән сорашты. Саттарның әтисе якын-тирәдә данлыклы итек тегүче оста иде. Үз осталыгын малаена да өйрәтеп өлгергән икән, эш шактый матур башланып китте. Үзләренә ярдәмгә тагын ике-өч егетне алдылар, алар арасында шактый үсеп, егеткә әйләнеп барган Әхмәтхан энесе дә бар иде. Башта, тәжрибә өченгә үзебезнеке үзебезгә ярар дип, үзләренә итек тегеп киделәр. Тырыша торгач, ярыйсы килеп чыкты тагын. Итек-кәвеш эзләп шәһәргә йөрүдән туйган хәллерәк кешеләрнең дә егетләргә йомышлары төшә башлады. Аз-маз керем күренә башлагач, егетләрнең күнелләре күтәрелде, эш алга китте.

Яшьләрнең артель оештырып, үз көннәрен үзләре күрергә омтылулары хуплауга лаек иде. Губкомның яшьләр бүлегеннән озын чәчле бер егет килеп, яз көне сәвит рәисе булып сайланган һәм фиркага да кереп алган Зариф абзый ярдәме белән авылда беренче яшьләр оешмасы—комсомол төзелде. Комсомолга керүчеләргә кызыл билетлар

тапшырдылар. Бу оешмада торучыларның дингә каршы булып, үзләрен «Алласызлар оешмасы» дип тә җибәрүләрен ишеткәч, Шәмсия өйдә кара тавыш кубарды. Мостафа агай үзе дә улының һөнәргә өйрәнеп йөргән җирдән Ходайга каршы баручы кәфер бәндәләргә кушылуын хупламады. Бөтен бәлане кызыл билеттан күреп, Шәмсия бер көнне Әхмәтсафаның сәке астындагы китаплар кәрҗиненнән егетнең билетын табып алып, мичкә ыргыткан иде. Моңа каршы протест йөзеннән Әхмәтсафа бер ай чамасы өйгә кайтмый, мастерскойда кунып йөрде. Протестка теләктәш булып Әхмәтхан да кушылды. Ул да озакламый комсомол булып китте. Боларны Мостафа агай авыр кичерде... Малайларның бөтенләй әздән чыгу куркынычы алга килеп баскач, уллары янына Бибкәйне йөгертте ул. Егетләр дә бу хәлдән матур итеп чыгу ягын уйлап, пошыналар иде. Бибкәй килеп:

—Әткәй икегезне дә өйгә кайтсыннар, диде... Кеше көлдереп йөрмәсеннән диде,—дип, такмаклап бетермәде, Әхмәтсафа сөенеченнән сеңлесен кочагына ук күтәреп алды.

Көттереп торыш юк, егетләр башларын түбән иеп, Тайфә карчыкның өенә кайтып керделәр. Әткәләре аякка басып, йорт арасында йөри башлаган иде. «Фетнәче» улларын күргәч «ә» димәде, «җә» димәде, аларга кырын карап, бер генә мәртәбә «аһ»ылдап алды да, өйгә кереп сәкегә менеп ятты...

Мифтах хәлфә мастерскойга итеген төзәттерергә биргән иде. Шуны алырга килгәч, комсомолга кергән егетләрнең күңел кылларын тартып карарга уйлады. Үзләренең ни кылганнарын беләме алар, егетләр белән ныклап сөйләшүче булганмы, үзләре бу хакта төптән уйлаганнармы? Хәлфәне шулар кызыксындыра иде.

—Оешмага кергән көннән сез инде кешеләр түгел, балакайлар...

—Кем соң без алайса?—Саттар үзе дә сизмәстән Мифтах хәлфәнең шелтәле сүзләренә сорау биреп ташлады.

—Сез инде, балакайлар—әгъзалар хәзер. Һәркайсыгыз кәмсәмүл әгъзасы булып чутланасыз. Башкалардан аерым бер генә эш тә майтарырга тиеш түгелсез. Сүзегездән шуны аңладым. Гел бергә, гел төркем белән гамәл кылу. Бер-берегезгә кендек белән береккән кебек. Әле ул кылган гамәлне дә өстәгеләр кушуы буенча эшләргә тиеш буласыз. Өер кануны шундый—үз белдегең белән нидер эшләргә маташу һәрвакыт гаеп санала. Андыйларны җәза көтә.

Саттар Мифтах хәлфәнең соңгы сүзләрен килештерми, кистереп әйтеп куйды:

—Өер түгел... Оешма! Яңа тормыш төзү өчен җанын да кызганмый торган яшьләр керә безнең комсомол оешмасына! Без ячейкада әгъза булуыбыз белән горурланабыз. Ә сез әгъза дисез...

—Өер—ни, оешма—ни, ике чабата—бер кием бу очракта. Әгъза дими ни дисең—сез инде кәмсәмүл дигән хикмәтле организмның аерым бер әгъзаларын тәшкил итәсез. Тик шунысын белеп торыгыз—сез бу организмның куллары, бармаклары, эчәкләре кебек кенә. Башы да түгел, аягы да. Сез организмны яшәтү өчен иң шапшак эшләрне башкарырга тиеш. Шунысыз яши алмый ул. Өстәгеләр исә шуның сезгә бөтенләй күренмәгән чистарак, матуррак өлеше барын да беләләр. Организмның рәхәт, ләззәт чигә торган өлешләре дә була. Аңысы инде сезгә караңгы...

—Комсомолда демократия,—диде моңарчы сүзгә кушылмаган Әхмәтсафа.—Әгәр ул бозыла икән, безнең беркайчан да авыз ябып тормаячакбыз.

—Саттар дөрес әйтте, сез оешмага кергәндә ант иттегез. Җаныбыз да җил түгел, дидегез. Хәзер нинидер демократия дисез. Җаныгызны демократия дигән серле нәрсәгә алыштыргансыз икән, ул демократия дигәннәре ни төслерәк була? Капшап, тотып караганыгыз бармы?.. Мин таныш сезнең оешманың демократиясе белән. Акка кара белән язылган—азчылык күпчелеккә буйсына. Өстәгеләрнең кушканы түбәндәгеләр өчен

мәҗбүри диелгән. Шулай бит. Нәрсә килеп чыга? Ике төрле демократия бар икән. Берсе—өстәгеләр өчен, икенчесе—астагылар, ягъни түбәндәгеләр, сезнең кебекләр өчен. Өстәгеләр оешмасы миңа да, сезгә дә караңгы, балакайлар. Сез түбәндәгеләр оешмасы. Түбәнгә һәрвакыт ышанучан, әйткәнне үтәргә яратучылар җыела. Йомшак күңелле, ияреп китәргә яратучан кешеләр алар. Оешмасы да зәгыйфь холыклы булып чыга аларның. Шулай булмаса, кемнедер яңа тормышка чыгарам дип, җанны корбан итәргә җыенамы адәм баласы? Кем өчен, ни өчен? Өстәгеләрнең сез баласы кебек—кушканны гына үтәп, тәүфыйкъле булып кына йөрергә тиеш буласыз. Һәр кылган гамәлегез өстәгеләр өчен аңлаешлы һәм аларның мәсләгенә туры килсен. Менә нәрсә көтәләр алар сездән. Шулай булмаса, тыңлаусыз баланы шелек белән суктырган кебек, сезгә дә эләгә инде... Шелек кенә булып калса ярый да. Сез бит әле җаннарыгызны бирергә дип атлыгып торасыз.

—Мәгънәсез рәвештә гомер белән хушлашырга уйлаган юк анысы, —диде Әхмәтсафа уйчанланып.—Халыкны яңа тормышка чыгару, аларны бәхетле итү, аның хәсрәтен үзенә алу теләге начармыни, хәлфә абзый?

—Аның бөтен хикмәте дә шунда шул. Башкалар хәсрәтен үзеңнеке итәргә җыену чик-чаманы югалту дигән сүздер, балакай. Халык зур төшенчә ул. Аның хәсрәт-кайгысы дәрьядыр. Кайсын үзегезгә аласыз? Шунысы да бар—кайсы хәсрәтен кеше сезгә бирер икән... Һәркайсы үтә шәхси була бит аның. Халык дип гомуми әйтү туры җаваптан качу өчен генә кирәк ул. Хакимнәр халык дигәндә бервакытта да үзләрен истән чыгармыйлар. Киресе булса, алар тарафыннан эшләнгән иң зур ахмаклык булыр иде ул... Һәр гамәлне үз файдасына бора хакимнәр. Хаким ихтыяры—беренче, халык—икенче. Сез исә—халык беренче, дип. адарынып йөргән байгышлар. «Яңа тормышка чыгарыгыз»,—дип гариза-үтенеч белән бирәр кеше яныгызга килдеме әле?

Мифтах хәлфәнең көтелмәгән соравыннан, Саттар югалып калды.

—Кем алай йөрсен инде...—диде ул битараф тавыш белән. Мифтах хәлфәнең акыл сатуыннан туя башлаган иде ул. Губкомнан әллә никадәр эш кушып җибәрделәр. Һәр көнне шулай гомер уздырып, Мифтах хәлфә кебекләрнең фәлсәфәләрен тыңлап утыруга калса...

—Мин дә шулай уйлыйм шул.—Мифтах хәлфә хәйләкәр көлеп куйды.—Сезгә бирәү дә гариза күтәреп килмәс. Башкалар турында уйларга сезгә өстән кушалар. Шулай бит? Вәт сез уйлыйсыз инде... Кеше турында уйлап, кысыр хәсрәтләр белән йөргәнче, балакайларым, үзегез хакында күбрәк уйласагыз, һөнәрле, белекле кешеләр булып житешсәгез, күбрәк файдалырак булмас микән? Милләткә дим. Сезнеңчә—халыкка дисәк тә ярый. Берүк, кеше рухына, кеше җанына саксыз кагыла күрмәгез. Акылы үзендә булган кеше аның турында уйлауга мохтаҗ түгел. Шуны аңлагыз. Аһ, шәкерткәйләрем, кеше булып калсагыз иде сез, адәм баласы икәнлегегезне онытмасагыз иде...—Соңгы сүзләрен хәлфә ничектер егетләрне якын итеп, ышаныч белән әйтте.

Мифтах хәлфәнең сүзләре дөрес иде. Оешма булгач, аңа күрсәтмә бирүчеләр күбәя икән. Саттарны, комсомол ячейкасы рәисе буларак, губкомга чакырып, корбан бәйрәменә каршы чаралар планы тоттырып җибәргәннәр әнә. Моңа кадәр бер дә дин-иманга каршы килердәй гамәл кылмаган егетләр башта шик-шөбһәгә төштеләр. Бергә җыйналгач, күмәклекнең көче шундадыр да, бәлки, кыюрак, тәвәкәлрәк кылланучылар да табылды. Аларга башкалар кушылды, шулай итеп гаеткә каршы кичтә яшьләр җыены үткәрергә карар кылдылар. Губком әлеге адымны ике куллап хуплады. Өстәгеләрнең мондый теләктәшлеге яшьләрне тагын да дәртләндерде. Ячейка әгъзалары арасында гаетне бөтенләй үткәрттермәскә дигән фикер ягында торучылар да табылды. Әгәр Саттар белән Әхмәтсафа бу фикерне якласалар, күпчелек аларны яклар иде. Тик егетләр Мифтах хәлфә белән булган бәхәсне искә төшереп, артык кискен адымнан сакланырга сүз куешкан иделәр.

Яшьләр үзләренчә мәш килделәр, жыенга ныклап хәзерләнделәр. Мондый зур чараны беренче мәртәбә үткәргәч, хәстәрен күрми булмый шул. Гади чара гына түгел, гаеткә каршы чара ич... Авылдагы сәләтле, бу эштән шүрләмәгән яшьләрне жыеп, концерт әзерләделәр. Каравыл йортын клуб иттеләр, сәхнә ясадылар.

Бәйрәм алды киче житте. Жыенга килүче булмас дип курыкканнар иде, яшьләр жыелды тагын. Әхмәтсафа, гадәттәгечә, үзенен гимнастик күнегүләрен ясап күрсәтте, декламация сөйләде. Кемдер жырлады, кемдер скрипкада уйнады. Ут чыгарып биеп тә жибәрделәр. Кыскасы, яшьләр өчен менә дигән кичә булды. Ахырда Саттар яшьләрне гаеткә бармаска үгетләде. Анысы да шома гына үтте. Иң соңгы кеше булып коммунист Зариф чыгыш ясады. Ул инде яшьләрне үзләре бармау белән беррәттән, өйдәге өлкәннәрне дә гаеткә жибәрмәскә чакырды. Монысына да каршы әйтүче, ыгы-зыгы куптаручы табылмады. Саттар белән Әхмәтсафа жыенның шулай матур, шома гына үтеп китүенә сөенеп, өйләренә кайтып киттеләр.

Икенче көнне, гаеткә киткән жиреннән, Мостафа абзый яшьләренә тыгылып кайтып керде. Авыл картлары аны мәчет янына якын китермәгәннәр. «Баланны урыс-кәфер иттерден, иманны таларга ябышкан эт үстереп ятасың,»—дип, каһәрләп, каргый-каргый таяк-таш атып кире өенә куып жибәргәннәр иде. Дин әһелләренең әйтүенә караганда, комсомоллар төнлә мәчет ишекләренә аркылы такта кадаклап куйганнар, гыйбадәт кылып төн үткәрергә жыенган мәчет картларын кыйнап, урамга чыгарып ташлаганнар. Барысын да исәпкә алсак, картларның ярсуы ни дәрәжәдә икәнлеген аңлавы кыен түгел...

Мостафа абзый үзенең болай тиз кайтып керүенә аптырап калган Шәмсиягә бер сүз дәшмәде, сәке түренә намазлыгын жәеп, ялгызы гает намазына утырды.

Әхмәтсафа белән Әхмәтхан лапастагы сәндерәдә яталар иде. Әгәр бу вакытта өйгә керсәләр, тетрәндергеч күренешкә тап булырлар иде. Мостафа агайның төсен жуйган күзләреннән сытылып чыккан ачы яшьләр бите буйлап чал сакалына агып төшә. Алдындагы намазлыгы чыланып бетүенә дә игътибар итмәстән, намаз укуын да онытып, шушындый изге бәйрәмнең ямен жибәргән, иманнан жәяүләп качкан бәдбәхетләрне ләгънәтли-каргый елый. Имансыз кавем арасында, картлар әйткәнчә, улы Әхмәтсафаның да булуына шикләнми иде ул. Дөньяны болгатучыларның башында Саттар белән Әхмәтсафаның йөрүе беркемгә дә сер түгел бит, нинди шик булсын ди.

Йөрәккә кара кан булып оешты әлеге тынгысыз көннәрнең шаукымы. Яшьләр бу эштә үзләренең катнашы булмавын исбат итәргә тырыштылар, картлар аның саен аларга каһәрләрен яудыра тордылар. Мостафа хастага әйләнде. Аягына басып, ишек алдында мәрәләп йөри башлаган иде, хәбәре биш елга бер килгән Фәтхулла авылга кайтып төште. Шәмсия бу хәбәрне ишетү белән һушсыз калды. Тәвәккәлләп, беренче ире янына, биатасы йортына төшеп киткән иде, кара хәсрәт эчендә кайтып керде. Фәтхулла аның белән сөйләшеп тә тормаган. Хатынның шашынып, тиләрә язып елавына да, туктаусыз Биккол адәме сөйләгәннәрне кабатлавына да игътибар итеп тормаган, ишеккә генә төртеп күрсәткән:

—Бар, Шәмсия, йөрмә монда, ирең янына кайт!—дип бер генә ырылдаган, имеш.

Шуннан соң Тайфә карчыкның өендә яшәүчеләргә жәһәннәм тормышы башланды.

Әхмәтсафа бу уку елына үзе белән Әхмәтханны да алып китәргә уйлаган иде. Шәмсия кул арасына керердәй бердәнбер баланың да калага китүенә һич кенә дә риза булмавын сиздерде. Жай чыккан саен Мостафаның колак итен ашавын белде.

—Кая жибәрмәкче буласың Әхмәтханны?—диде ул, бер көнне

ысылдаулы тавыш белән.—Өендә бер урыс булуы җитмәгәнме?.. Йорт арасында йөрергә, эшләргә кеше калмый. Үзең билсез калдың. Аркылы ятканны алып, торкылы сала алмыйсың. Ул малаеннан да язасың киләме?

Мостафа бер сүз дә эндәшмәде.

...Әхмәтсафа белән Әхмәтхан Оренбурга китәсе кичне йокларга соң гына яттылар. Үзләренә күрә, җитдиләнеп әзерләнделәр, сәфәр чыгар алдыннан барысын хәстәрләп, кат-кат күздән кичереп мәш килделәр. Башка вакытта сәндерәгә менеп кунаклагач та йокы бүсә башламыйча, әле озак кына сөйләшеп, киләчәк матур тормыш хакында әллә нинди хыяллар корып яталар иде. Бу юлы исә өйдә генә йокларга булдылар. Әткәләре сүзен тыңлап инде. Уллары кичке аштан соң сәндерәләренә чыгып шылмакчы иде, кисәк кенә әткәләре телгә килде:

—Кырпак төшәр вакыт җиткәнче яттыгыз бит инде ул сәндерәгездә... Бүген өйдә, рәхәтләнеп җылыда йоклагыз...

Әткәләре белән бәхәскә кереп торасы итмәделәр. Югыйсә, егетләр сәндерәне үз итеп өлгергәннәр иде. Өйдә күзгә йокы керми генә менә. Өй тынлыгын бозып, авыз ачып сүз әйтеп тә булмый. Әвен базарына китә алмыйча, әйләнеп-тулганып озак яттылар шулай...

Таң туганда, йокымсырап китә алдымы Әхмәтсафа, юкмы, үги әнисенең инрәүле тавышыннан сискәнеп, сикереп үк торып утырды.

—Әхмәтсафа, тор, ...әткәгез...

Гайре табигый хәл булганлыгын аңлап алырга өлгергән иде ул. Йөрәге күкрәк читлеген каерып атардай булып бәргәләнә башлады. Колак пәрдәләре ертылыр дәрәҗәдә колагы шаулап алды. Бер мәлгә берни ишетми торды. Сәер сыкрау авазлары чыгарып башы гүли. Дөнья тоныкшауга күмелде. Ул таралып йоклап яткан Әхмәтханга эндәшеп тә тормастан, аягына итекләрен җәһәт кенә кигәндәй итте дә, әнкәсе артыннан чыгып йөгерде. Ишек алдында берәү дә юк. Тып-тын... Лапас ягыннан күңелне өтеп сыктау тавышы яңгырап алды. Ул шунда атылды. Лапас капкасы, беркайчан булмаганча, киереп ачып ташланган. Үги әнкәсе, кемдер килеп үзен шушыннан кубарып алудан курыккан сыман, капка баганасын ике куллап кысып кочаклаган да, үксеп елый иде. Әхмәтсафа Шәмсия янына килеп басты.

—Ни булды? Әткәй... кайда?—диде ул калтыранган тавыш белән.

Таң шәфәге дөньяга нурын чәчә башлаган мәл иде бу. Шушы сүрән яктылыкта Әхмәтсафа Шәмсиянең коточкыч йөзен күреп алды:

—Атагыз... үзенә кул салган... Башына җиттегез... Бәдбәхетләр...— Шәмсия лапас эченә бер адым атлады да, кире чигенде. Куркуыннан дер-дер калтырый иде ул. Лапас эченә ишарәләп, пышылдап диярлек баягы боз салкыны бөркелгән сүзләренә ачыклык керткәндәй өстәп куйды.—Бау белән... Сәндерә астында...

...Әткәсен җирләгән көннәр кара төш кенә сыман. Аның үлеменә һич ышанасы килми Әхмәтсафаның. Зиһенен җыя алмый байтак көннәр йөрде ул. Бәгырьне талкыган нәрсә шул—әткәсенең мондый аяныч үлемендә туган-тумача, күрше-тирә фәкать Әхмәтсафаның гаебен күрде. Әгәр ул динсезләнеп, көферләнеп йөрмәсә... Мәчет ишеген аркылы такта белән кадаклап куймаса... Мәчет картларын кыйнамаса... Шушы хәлләр аркасында, Мостафа мәчеткә йөрүдән мәхрүм калмаса... Ул чакта җанын хурлarлык сүзләрне күп ишетергә туры килде егеткә.

Мондый хәлдә озак йөрү мөмкин түгел иде. Әхмәтханны укырга алып китү мөмкин түгел—ул Кәкре Бәдертдингә батрак булып ялланды. Әхмәтсафа исә сонара төшеп Оренбурга ялгызы гына укырга китеп барды. Әткәсенең кырыгын үткәреп, атна-ун көн вакыт үткәч, авылга кайткан иде, Тайфә карчыкның бикле өе генә каршы алды аны. Карчык үзе, Хәлфетдин югалгач, Каргалыга кайтмый да диярлек, каладагы кызында тора иде. Әхмәтсафа, аптырап, энесе янына йөгерде. Әхмәтхан, нәкъ әткәсе шикелле, сабыр гына хәлне аңлатып бирде. Шәмсия әнкәләрен, Бибкәйне дә ияртеп, Фәтхулла үз янына алып киткән икән...

Гөнаһасына кермик, Шәмсия башта бик каршы булган. Ирнең кайтып кергән көннәрдәге дуамаллыгы күнелен суытканмы, үзе генә белгән башка сәбәпләр дә булганмы, анысы инде безгә караңгы, әмма Фәтхулла аны кире үз янына кайтырга үгетләргә килгәч, Шәмсия кырт кискән. «Ходай язганга күнәргә кирәк, өлешемә төшкәне шулдыр, балалар балигъ булмыйча, ике аягымнын берсен читкә атламыйм!»—дип, Фәтхулланы куып дигәндәй кайтарып җибәргән. Шәмсиянен үз өе дә унтугызынчы елгы янгында көлгә әйләнгән иде, Фәтхулла юк-бар сәбәп табып, тагын тавыш чыгара калса, бөтенләй йорт-жирсез калудан да курка иде, ахры. Ничекләр сөйләшеп аңлашканнардыр, үткән атнадан бирле Шәмсия Фәтхулла белән кире кушылганнар. Кабат никах яңартып, бергә-бергә яши башлаганнар иде.

Әхмәтсафа, сеңлесе Бибкәй өчен борчылып, аягы һич кенә дә тартмаса да, Фәтхулла өенә юл тотты. Шәмсия белән Фәтхулла алдан сөйләшеп куйганнар идеме, икесенең дә сүзе бер булды: «Бибкәй өчен борчылма. Безгә ул үз балабыз кебек якын. Какмабыз, сукмабыз, кеше арасында ким-хур да итмәбез,»—дип, Әхмәтсафанын күңеленә жылы салдылар. Шәмсиядәге үзгәрешне күреп хәйран калырлык иде. Йөзе яктырып киткән, күз карашы әүвәлгечә нурлы, ягымлы иде. Әхмәтсафага да каты кагылмады. Кунакка сый-хөрмәт күрсәтергә тырышты. Үги инәй кат-кат әйтте:

—Берегезне дә чит итмибез. Аптырап, кангырып йөрмәгез! Кайчан кайтып керәсегез килсә, шунда кайтыгыз. Ишек ачык, булганча сыен куярбыз. Үзегез дөнья көтә башлаганчы, сыйдырырбыз, иншалла,—диде ул. Аның тавышында ачу да, рәнжү дә сизмәде Әхмәтсафа. Һәр сүзен Фәтхулла жөпләп торгангамы, Шәмсия бигрәк тә үз итеп сөйләде.

Сөенерлеге дә бар шул Шәмсиянең. Фәтхулла белән ике ара көйләнгән. Хатынга соңгы елларда күрмәгән ир назы татыган, барлык аңлашылмауларга нокта куелган иде. Моның өчен Фәтхулла аз тырышмады. Теге чакта Шәмсиянең башын әйләндереп, аны чарасыз калдырган, ягъни үлде хәбәрен ирештергән Биккол адәмен барып тапты солдат. Күргән-кичергәннәрен дә Шәмсиягә жентекләп сөйләп бирде. Чыннан да алар Биккол кешесе белән бергә булганнар, чыннан да Фәтхулла яраланган булган. Яраларын ямап шактый вакыт госпитальдә аунаган. «Үз аягым белән кайтып кергәч, барысын да аңлатырмын»,—дип, хат язуны кичектереп торган. Терелеп чыккач, кайтырга әзерләнеп йөргән көннәрдә революция башланган. Ата—улны, инә—кызны белми торган мәхшәр... Тагын фронт, тагын үлем белән йөзгә-йөз очрашулар. Язасы хат һаман язылмый кала биргән, ирештергән хәбәрләреннән берәве генә килеп житкән... Биккол адәменә килгәндә, ул жанына шактый гөнаһ алган булып чыкты. Аны, Фәтхулланы үлде дип, ялган хәбәр әйтергә күндерүче—Шәмсиягә күзе кызып йөргән Вәлкәй хажи булган икән. Шәмсиянең барлык күргәннәренә дә шушы ялган хәбәр сәбәпче булганга, инде ялганны Фәтхулла үзе фаш иткәч, ирнең күңеле кисәк йомшап, ул Шәмсиянең аягына килеп егылды. Әхмәтсафа килеп кергән вакыт—ир белән хатынның тормыш иләгендә аяусыз иләнеп тә исән-имин кавышырга насыйп булуына тәмам ышанып бетеп барган чаклары, еллар үтеп тә сүрелмәгән мәхәббәт учагының кабат тернәкләнә башлаган мәле иде.

* * *

Декабрь айларында ачлык бөтен дәһшәте белән үзен сиздерә башлады. Шәһәр урамнары хәер сорашып йөрүче бала-чага, сукбайлар белән тулды. Кышкы салкын иртәләрдә урамнарда туңып үлгән кеше гәүдәләре күренә башлады. Бөтен Идел, Урал буйларыннан халык Урта Азия якларына кузгалды. Бу кузгалыш монарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән һижрәткә тиң иде. Анда барып элгәшә алу—исән калу дигән сүз. Анда, бары анда гына икмәк бар дип уйлыйлар иде. Кызганычка каршы, бу бичараларның күпчелеге ярты юлга да барып житә алмый,

хәлсезләнеп Оренбурда төшеп калалар. Бәхет эзләүчеләр торган саен арта, калада хәл торган саен мөшкелләнә бара. Ачлыкның һөҗүмен туктатып калу мөмкин түгеллеген аңлау зиһеннәрне тагын да чуалта, җанның җегәрен суыра иде. Берзаман урамда яткан мәетләр янынннан тыныч кына үтеп китәргә ияләнә башладылар. Үлемгә, афәткә ияләнү үзе зур куркыныч. Кешенең киләсе көннәргә өмете киселү, һәрнәрсәгә, һәркемгә ышанычы бетү дигәнне аңлата иде мондый чарасыз битарафлык. Әхмәтсафаның бердәнбер куанычы дип әйтикме, җан тынычлыгы дип әйтикме, энесе Әхмәтхан белән сеңлесе Бибкәйнең чагыштырмача тук тормышта яшәүләре иде. Әхмәтханга килсәк, батрак тормышы җинелдән түгелдер, тик эше авыр булса да, ачлык галәмәтен күрми, хуҗа миһербанлы бәндә булып чыкты. Ә Бибкәйнең хәлләре бигрәк тә әйбәт. Үги инәй белән үги әткәсе бу зәп-зәңгәр күзле, тузгак чәчле сөйкемле кызыйдан башка тормышларын күз алларына да китерә алмыйлар. Бибкәй—аларның үз кызлары, үз сөйкемле сөякләре. Тегесе дә шулай бәләкәй көенчә, каян өйрәнгән диген, ярый да белә, үзен яраттыра да белә иде.

...Институт бинасы, күмер булмау сәбәпле, ягылудан туктады. Суык сөякләргә үтә. Дәресләр йокы бүлмәләрендә үткәрелә башлады, ашау ягы такы-токыланды. Өйдән ярдәм итәрлек булмаган студентларның кайберләре ачлыктан шешенеп, дәресләргә йөри алмас хәлгә килделәр. Аларга аз гына ярдәм итү дә зур мәсьәләгә әйләнеп бара. Бүлмәләргә буржуйка мичләре куелды куелуын, тик ягар утын юк. Утын табу студентларның үзләренә йөкләнде. Бүлмәдәшләрнең берәрсе каяндыр ярма, бәрәнге кебек ризык таба калса, аны бергә пешереп, бергә ашап, бераз тамак ялгап—сипләп алган булалар. Оренбурда туган-тумачалары булганнарның да хәлләре шәптән түгел. Тамакны ныгытып булмаса, хет җылы өйдә төн чыгармын дип, Әхмәтсафа бер-ике мәртәбә Гомәр абзыйларына барып караган иде, кунак шәкертне сыйлау, җылыту түгел, карт белән карчыкның үзләренең хәле мөшкел булып чыкты—ашарларына ризык, ягарга утыннары юк иде. Әхмәтсафа, үзеннән өзеп булса да, аларга аз-маз азык илткәли башлады, килсә утын хәстәрен дә күрә иде.

Шулай булса да, студентлар тормышында истә калырлык хәлләр булгалый. Беркөн, кич кенә Гомәр абзыйларыннан кайтып керсә, бүлмәләрендә җанлылык хөкем сөрә. Курсташлары, моңарчы буш торган караватт тирәсенә өелешкәннәр, нидер сөйләшәләр, көлешәләр. Әхмәтсафа, бу галәмәткә аптырабрак тора иде, Сәгыйть көр тавыш белән, аны үзләре янына чакырды:

—Егет, ник туктап калдың? Каушама, түрдән уз, таныш, Муса килде бит!..

Әхмәтсафаның аяклары ирексездән, егетләр янына атлады. Шәрә караватта күзләрен елтыратып утыручы бүлтәйгән иренле, чандыр гәүдәле егеткә караш ташларга өлгерде. Шушы буламыни инде Муса дигән шагыйрь?.. Шагыйрь сүзе ничектер серле янгырый. Бу сүзнең иясе дә хикмәтле заттыр кебек тоела. «Шагыйрь сүзе—телнең таҗы!»—дияргә ярата иде Мифтах хәлфә. Сүтеп-сүтеп тә сер очын табып бетереп булмаган бер йомгак сыман күз алдына китерә иде шагыйрьләрне Әхмәтсафа. Мусаны исә шагыйрь дияргә дә тел әйләнми. Ябык, кечкенә буйлы. Каян килеп сер йомгагы булсын ул? Сер төенчеге дисәң генә инде. Муса бик тере, хәрәкәтчән булып чыкты. Әхмәтсафа аягын өстерәп егетләр янына килеп җиткәнче, караватыннан очып кына төште дә, күрешергә дип кулын сузарга да өлгерде. Мусаның салкынча, арык кулын ныгытып кысарга да уңайсыз. Әхмәтсафаның башыннан шундый уй сызылып үткәнне сизгән шикелле, Муса яна танышының кулын шатырдатып кысып алды.

—Әйдүк, туган,—диде Муса. Егет үзен мондагы һәркемнән өлкән хис иткән кебек сөйләшә. Һәм бу шулай иде дә бугай.—Сәгыйть әйтеп өлгерде, Муса Җәлилов дигәннәре мин булам инде.—Ис китмәгән рәвештә өстәп тә куйды.—Шигырьләр язам... Егетнең тавышы Әхмәтсафа күргән шагыйрьләрнекенә бер дә охшамаган. Әнә, Такташның тавышы нинди

матур яңгырашлы, үзе йомшак, шул ук вакытта көчле дә. Мусаның исә тавыш дисәң хәтерен калыр—юка гына... Кабыгы әрчелмәгән бәрәнге кебек шома тавыш.

—Әхмәтсафа Дәүләтъяров...

—Беләм, ишеткән бар,—диде Муса көлемсерәп. Ул янә караватына килеп утырды.

Менә шунда бугай хикмәт. Ачык йөз белән елмаеп сөйләшүе, башкаларны игътибар белән, көлемсери төшеп тыңлавы егетне ничектер өлкәнәйтеп җибәрә, башкаларга караганда бер башка өстен куя сыман иде.

Ул үзен сырып алган егетләргә аңлаткандай, сөйләнеп алды:

—Авырып китмәсәм, мин дә сезнең кичәләрдә теләп катнышыр идем дә... Озакка кереп ятарга туры килде. Госпитальдә чагында Гайшә килгәләп йөрде минем янга. Шәп декламатор Дәүләтъяров белән читтән торып таныш инде мин. Аннан үткән ел Мостафага—безнең авылга губкомнан иптәшләр еш киләләр иде. Шәһәр тормышы, ТИНОдагы хәлләр белән таныштырып тордылар. Шулай, белми дип уйламагыз, монда «шылт» итсәгез дә, ул хәбәр атна эчендә миңа килеп ишетелде.—Ул янә елмайды. Мусаны яхшы белгән, аны сагынып беткән иптәшләре күнелле шаулашып алдылар.

—Гайшә—синең магнитың инде. Тикмәгә йөрмисең егет! Шул магнит тартып китергәндер әле бүген дә монда үзеңне,—диде Габдулла Амантай.

—Мостафада да тик ятмадың. Без дә күзсез-колаксыз түгел, Муса агай. Бөтен губернага яхшы атың чыкты, даның таралды,—дип, көлә-көлә сөйләнде Сәгыйть, кунакның салпы ягына салам кыстыргандай. Сәгыйть, хәйләкәр төлке, ялгышмады. Бу сүзләрне ишетү Мусаның үзенә дә бик күнелле иде, ул шул арада эшем иясенә әйләнеп, җитдиләнеп китте.

—Яшьләр, балалар белән эшләүне һәркайсыбызның намус эше, бурычы дип саныйм. Мин генә түгел, губкомдагы иптәшләр дә шулай уйлый. Иптәш Ленинның һәр чыгышы яшьләр, балалар тормышын яңача үзгәртү рухы белән сугарылган. Партиянең һәр адымы шуңа юнәлтелгән. Без аларны кулланма итеп алып, тормышка ашыру юлында ару-талуны белмәскә тиешбез.

—Сәяси курсларда укып, чын комиссарга әйләнгәнсең,—диде Фатыйх Сәгыйтов.—Ә ачлык хакында ни әйтә иптәш Ленин? Халык кырылып бетмәсме?

—Бетмәс,—диде Муса. Сүзләре ышанычлы булсын дигән төсле, тып итеп идәнгә басты.—Чит илләр, бигрәк тә Америка ярдәм күрсәтүне оештырды инде. Без аны Оренбурда да сизәбез.—Муса җитди эше исенә төшкән сыман, кашын җыерып бер мәлгә тын торды. Чыннан да, китәргә җыена икән, ашыгып саубуллаша башлады.—Ярый, егетләр, хушлашабыз. Без—сәяси мәктәп курсантлары кулга мылтык тотып, төннәрен шәһәрне сакларга чыгабыз.—Әхмәтсафа шуны күзәтеп алды—Муса үзенең һәр сүзенә, һәр гамәленә ышаныч белән карауларын тели иде. Бу юлы да, шикләнергә урын калмасын дип, аныклый төште.—Складларны, кибетләрне сакта тотарга туры килә. Шәһәр тулы ышпана, угры. Дошман элементларының күп булуын да истән чыгармаска кирәк, егетләр.—Ул, «сине оныта язганмын, гафу ит, туган» дигән кебек, кисәк кенә Әхмәтсафага төбәп сөйли башлады.—Шулай, Дәүләтъяров иптәш, көрәш бер генә минутка да тынмый илдә. Сез дә читләшмәгез! Бу көрәштән читләшү—аңлы рәвештә дошман тегермененә су кою белән бер. Безнең иман, безнең инану бер—илдә социализм төзү. Кирәк булса, яңа тормыш өчен корбан да булырбыз. Тик шуны хәтердә тотарга кирәк—ул корбаннар эзсез югалмаячак! Алар яңа тормышның беренче ташлары, кызыл кирпечләре булачак. Ә каһарманнардан аккан кан ул ташларны ябыштырачак иң нык лы җилем булыр,—диде акыл биргәндәй. Хәзер инде, бу сүзләрдән соң, каршыларында чандыр гәүдәле, йолкыш кыяфәтле үсмер түгел, бәлки әзмәвердәй Муса торганына беркем дә шикләнми иде бугай.

Корбаннар хакындагы ялкынлы сүзләреннән Мусаның күзенә яшьләр килгән иде. Әхмәтсафа үзәге өзелердәй булып аны да, үзен дә жәлләп куйды. Ни өчен йөрәге урыныннан купты?.. Бу минутта ул аны һич кенә дә аңлата алмас иде. Келт итеп исенә Мифтах хәлфәнең яна тормыш хакындагы сүзләре төште дә, аркасына салкын тир бәреп чыкты. Сәер иде бу халәте. Менә сина сер төенчеге! Күңелен әллә нишләтеп жибәрде бит кана!.. Муса, Әхмәтсафадагы үзгәрешне сизгән кебек, аңа тагын бер мәртәбә сынаулы караш ташлады да, серле елмаеп, чыгу ягына кузгалды.

—Акыл бирү жиңел лә ул, тамак ачыкса, күзгә әпәйдән башка бер нәрсә дә күренми,—диде Фатыйх инде чыгып киткән Муса белән бәхәскә кереп. Ул лыштыр-лыштыр атлап, буржуйка янына китте. Бүген аның кизү көне икән. Төн житкәнче ничә тапкыр бәхәскә керер: кемнедер тәнкыйть итәр, кем беләндер әрепләшергә өлгерер, әмма шунысы хак—бүлмәгә жылы төшүе икеле бүген.

Кайчандыр бергә сабак алган иптәшләре Мусаны озата чыгып киттеләр. Бүлмәдә ике-өч кенә студент калды.

—Менә кем икән ул Муса...—диде Саттар зур яңалык ачкандай.

Шушы аз гына булып алган очрашу Әхмәтсафа өчен дә эзсез үтмәде. Ул әле баягы уйларыннан арына алмый. Һәрхәлдә, күңеле урынына утыра алмый азаплана. Нинди сер, көч бар иде шушы арык, кечкенә гәүдәле үсмернең сүзләрендә. Аңа тартылмыйча мөмкин түгел, аның һәр сүзендә мәгънә бар кебек. Һәр сүзе астында әлегә үзенә аңлашылып бетмәгән алдагы тормышның кануннарына ишарә бар иде сыман. Корбаннар... Таш-кирпечләр... Кан... Мифтах хәлфә әйтмешли, ул сөйләгәндә күзне кыса төшеп: «Дөрес, ләкин алай түгел ул!»—диясе килә. Нинди шайтан котырта болай?.. Әхмәтсафа тәмам буталып бетте. Ә бит Муса ни хакында сөйләгәнен үзе яхшы белгән кебек... Башкаларның да шуңа төшенүен, белүен, үзләштерүен тели иде шикелле. Шул чагында гына ул сине үзенә иш итәр, синең белән эч серләрен уртаклашыр, очрашканда иптәшләрчә кулын сузар. Үзенә тулысынча ышанмаганнарга ул борылып та карамаячак. Әхмәтсафа ышанамы аңа? Беренче күрүдән, беренче сөйләшүдән соң ук әйтүе кыен. Иң сәере шул—Муса яңа танышының үзенә ышануын бик тели иде бугай. Кат-кат аңа сынаулы караш ташлавында шушы мәгънәне, шушы ихтыярны тотып алды Әхмәтсафа...

Соныннан, шагыйрьнең дусларыннан белде: Мусаның үткән ел әтисе үлеп киткән. Үзе озак кына авырып яткан. Укуын өзәргә туры килгән. Аннан туган авылында яшьләр оешмасы төзегән, шактый маһирлык күрсәтеп өлгергән егетне укытучыларның губерна съезды делегаты итеп сайлаганнар. Быел жәй ачлыктан качып Оренбурга килгән булган. Шул ачлык аркасында аздан ышпаналарга ияреп китмәгән. Фатыйх дөрес сукалый, ачыкканда Ленин сүзләре тамак туйдырмый икән. Мусаның бәхетенә каршы, элекке хәлфәсе Нургали абый Надиев очратып, аны мең бәлаләр белән хәрби-сәяси мәктәпкә курсант итеп урнаштырута ирешкән. Монда нәкъ менә шагыйрьлеге ярдәм иткән, диделәр... Муса кулына корал тотып, ак бандаларга каршы көрәшеп йөргән. Соңгы айларда янә авырып китеп, госпитальдә яткан. Терелеп чыккач та, беренче эш итеп, үзенең сабакташлары янына килгән. Боларны ишеткәч, чыннан да, Муса Әхмәтсафа алдында ике-өч башка үсеп китте. Аңа ихтирамы артты. Ышанырга була иде Мусага...

* * *

Кыш урталарында мәгариф институтына житәкче булып монарчы хәрби-сәяси курсларда мөгаллимлек иткән Нургали Надиев кайтты. «Хөсәения» мәдрәсәсендә эшләп, шәкертләр арасында абруй казанган. Таләпчән, әмма миһербанлы шәхес. География һәм хисап укыта иде. Институт директорының хәрби эшләре буенча урынбасары итеп Заһид Шәркый билгеләнде. Бу ике укытучы артыннан монарчы хәрби-сәяси

курсларда укыган яшьләр дә институтка күчеп килделәр. Алар арасында Муса да бар иде.

Муса тулай торакта бер генә кич кунды.

—Монда озак түзеп булмас,—диде ул, кизү торган Әхмәтсафага. Бүлтәебрәк торган, салынкы иреннәрен бөрештереп, башын югары күтәрә төшеп, һавага әкрен генә җылы тынын бөркеде. Авыздан чыккан тын, аксыл пар-томанга әверелеп, сыек агым булып түшәмгә табан күтәрелә башлады. Бу күренешкә мәгънәле итеп карап торгач, тагын кабатлады.— Озакка түзмәм мин монда, туган. Әле авырудан терелеп тә житмәгән мәхлук бит мин.

Әхмәтсафа ни дип әйтергә дә белмәде. Соңгы вакытларда тулай торакны жылыту өчен утын табу бер бәла булса, озак вакытлар ачлы-туклы яшәү дә үзен нык сиздерә. Хәлле гаиләдән дигән студентларга да өйләреннән ярдәм килү өзелде. Авыллар ачыга иде. Авылга карап торган шәһәрнең хәле биш мәртәбә мөшкелрәккә әйләнде. Әле күптән түгел генә студентларның гомуми жыелышы булып, профсоюз комитетына сайлаулар үткәрделәр. Профком рәисе итеп оештыру эшләренә маһир Фатыйх Исхаков, ә аның урынбасары, хужалык эшләре өчен жаваплы итеп Әхмәтсафа Дәүләтъяров сайланды. Үзләре комитетка үтмәгәнгә эчләре пошып йөрүчеләр үткәндә-сүткәндә бәйләнеп калалар:

—Әй, комитетчик, кайчан жылыга тиендерерсез студентларны? Нигә утын ягын кайгыртмыйсын?!. Алайса ник сайлап куйдык сине профкомга?..

—Әхмәтсафа, ашханә эшен тикшерүне оештырырга кирәк. Көннән-көн шулпа сыегая бит... Әллә үзең дә поварлар белән әшнәләнеп киттенме?

Монысы инде ачыктан-ачык яла ягу. Бу сүзләрне иң еш кабатлаганы Мәжит иде. Әмма үпкәләшеп, анлашып вакыт үткәреп йөрисе юк, хәлләр житди төс алды—ачлыктан котылу чарасына керешергә кирәк иде.

Профком жыелышы үтеп, ике көн үтүгә Әхмәтсафа «Орлес»ка (Оренбур агач эшкәртү заводы) барып, институттан алган кәгазе янына губкомнан яздырып алган белешмәне дә кушып, завод житәкчеләре белән килешү төзеп кайтты. Килешү буенча студентлар завод эшчеләренә культура—агарту хезмәте күрсәтүне үз өсләренә алдылар. Кирәк чакта эшче көчләр белән дә тәэмин итәргә туры килер, ә завод үз чиратында гамәлгә ярамаган агач, такта кисәкләреннән институтка да өлеш чыгарырга ризалашты. Шулай итеп суыктан котылу мөмкинлеге табылды.

Бу Әхмәтсафаның жәмәгать эшчәнлегендә беренче жиңүе иде.

Гомәр ага егетнең жәмәгать эше дип янып йөрүенә каршы килмәсә дә, бу хакта фәлсәфә куертып алды. Ул көнне Әхмәтсафа «Орлес»тан кайтышлый, шактый олыгаеп баручы агайның хәлен белешмәк булып, сугылып кына китмәкче иде. Гомәр абзыйларга килеп кергәч үк гәүдәгә рәхәт жылылык сарылды. «Май кебек өйләре»,—дияр иде берәү булса, суыктан мондый өйгә килеп кергәч. Агайның да кәефе күтәренке, Әхмәтсафаның керүенә сөенеп, карчыгына чәй куярга кушып, кунакны түр якка чакырды. Соңгы вакытларда сирәк тиенгән мондый рәхәтлекнең сәбәбен дә әйтеп өлгерде: Жаек аръягындагы касабчы туганы бер олау утын китереп бушаткан, шактый гына ризык та калдырып киткән. Агайның кат-кат сөенеп әйтүенчә, аларны жәннәт капкасы төбендә калдырып киткән икән.

—Менә син, Әхмәтсафа энем, жәмәгать эшләре белән йөреш, дисен... Бездән дә үтте ул дәвер. Жәмәгать, милләт файдасына шактый игелекле гамәлләр кылынгандыр. Кем исәпкә алган аларны? Жәмәгать файдасы диләр бит аны шуның өчен дә. Жегәрең, дәртең ташып торганда нидер эшлисе килә, милләтне тәрәккый жибәрәсе килә. Вәт, эшләп тә куясың күңеленә яткан бер гамәлне. Аны кычкырып та йөреш юк, кеше күрсен дип тә уйламыйсың. Кемдер рәхмәт әйтсә, сөенеч, билгеле. Күбесе эзсез үтә инде андый эшнең. Әйтәм бит, ул жәмәгать дигәнең андый нәрсәгә тиз ияләнә. Сине һәрдаим шулай башкалар кайгысы белән көеп, алар хәсрәте белән янып яшәргә тиеш дип уйлый башлый. Кылган гамәленә күз йома, сүлпәнләнсәң—ризасызлыгын белдереп сөрән сала. Эшне, энем,

рәхмәт әйтсеннәр өчен эшләмиләр аны. Башкалар файдасына кылган гамәленә тау кадәр рәхмәт көтеп йөргән кеше—җүләр кеше ул. Иң зур җүләрлек шул. Игелек кыл да елгага сал, халык белмәсә, балык белер... Синең белән гәпләшә башлагач күңел кузгалып куйды. Гөрләп тора иде шул җәмәгать тормышы калада. Эш күрсәтүне егетлеккә саный торган идек. Җаның кушканга, вөҗданың әйдәкләгәнгә кылына андый гамәл. Ә син сайлап куйдылар, ышаныч күрсәттеләр дип, авыз ерып утырасың...

—Дөресе шул булгач...—Әхмәтсафа Гомәр агайның тел төбен аңлап бетерә алмый иде. Шуңа күрә тагын да ни дип әйтергә дә белми, туктап калды.

—Хагын хак та, агын ак та, кара дияргә кушкач, кара дибез инде... Шулаймы?—Гомәр агай көлеп, егет алдына икмәк кисәге куйды.—Әйдә, чәеңне эч әле. Мине тыңлап утырсаң... Карт кешенең үткәннәрне исенә төшереп үтә гомере. Эт картайса—койрыгын сөйрәр, адәм картайса—үткән гомерен сөйләр, ди... Мин карап-күзәтеп барам, сәвит хөкүмәте халыкны бушка эшләтергә күнектермәкче була. Әле шимбә өмәсе дип пыр тузалар. Ул өмәләр атнага биш көн уза башлады бугай. Һәркем җәмәгать эше дип чабулый, һәркем эшлекле, мин сиңа әйтим. Ил ачлыктан кырылып бетеп бара.

—Шуның өчен дә йөрү бит инде, Гомәр абзый. Ничек тә бәндәләргә җиңеллек китереп булмас микән дию. Бүген «Орлес»ка барып, студентларга утын китерү мәсьәләсен хәл кылдым. Начар түгелдер бит? Мин йөрмәсәм кем йөрер?

—Һәй егет, мактанасың килә. Эш күрсәтергә маһир син, анысына сүзем юк. Кешеләр белән уртак тел таба алуың да әйбәт. Эчкерсез күңелле, булдыклы егет. Дәүләтьярныкы икәнлегең әллә каян күренеп тора. Мин шуны төшенеп бетә алмыйм—утын ягын кайгыртучы кеше бардыр бит мәдрәсәдә? Ул нишләп йөри бу вакытта?

—Аның да эше җитәрлек. Монда минем сүз үтә, шуңа күрә мин йөрим.—Әхмәтсафа бу сүзләрне чын күңелдән әйтте.—Элекке чор түгел, Гомәр абзый. «Моны эшлим, монысын эшләмим,»—дип, үз көебезне көйләп йөрер вакытлар үтте инде. Яңа тормыш шулай гына төзелә ала. Ирекле, аңлы хезмәт...

—Җитте, энем, тирән керә төрәнең, көчлек килмәсен.—Гомәр агайның тавышына мыскыл кушылган иде.—Шуны гына әйт әле, син заводта утын кайгыртып йөргән вакытта башка шәкертләр кайда булдылар?

—Кайда дип... Дәрестә инде...

—Синең сабак калды инде болай булгач. Хәлфәң ни дияр?

—Сүз әйтмәс, Гомәр абзый. Директорның махсус рөхсәте белән йөрим бит мин... Мөһим эш артыннан чапканны укытучылар аңлый. Начар билге куймаслар.

—Менә ничек килеп чыга—башкалар белем ала, син җәмәгать эшендә. Моның өчен сиңа яхшы билге дә куялар. Шулай бит?

—Шулайрак булып чыга. Хәзер заман шундый.

Гомәр агай көйләп алды:

—Заман кемнең заманы..."Идегәй" батыр турында кыйссаны беләсеңме? Укыганың бармы?

—Булмыйча! Мифтах хәлфә бикләтте дә әле.—Әхмәтсафа көттереп тормыйча, кайчандыр күңеленә бикләгән юлларны яңартты:

Илем өчен илсенеп,
җирем өчен җирсенеп,
Халыгым өчен яхшы уем.
Күкрәк тулып җилсенеп,
Көрәшкәнне халыгым
Аңладымы—белалмам!
Аңламаса халыгым,
Аңламастан үлалмам!

Идегәй кебек шөһрәтле каһарманнар да халыкка хезмәт итеп, аның өчен тиешле әҗерен аласы килгән бит, Гомәр абзый. Һәрхәлдә, үзен анлауларын, ил батыры итеп санлауларын теләгән, кылган гамәлләре өчен рәхмәт тә ишетәсе килгәндер. Ил өчен, халык өчен хезмәт итү бүген генә килеп чыккан нәрсә түгел инде...

Гомәр агай җавапны көттермәде:

—...Бозгынлыкта калган ил—
Аның көне кемгә охшар?
Кичәге киткән атамның
Менгәне—кеше аты икән,
Сауганы—кеше биясе,
җиккәне—кеше дөясе.
Алты айлык агыр йортыннан
Урын тапмый, атамның
Киселеп китте җөясе,
Аның көне кемгә охшар?..

Шулай, энем... Мин һич тә сине халык, ил мәнфәгате өчен гамәл кылма, димим. Дөрес анла. «Агач башын җил борыр, адәм башын сүз борыр,»—дигән ул кыйссада. Үземнекен тукып, анышмыйча, сине эздән чыгарасым килми. Кулыңнан килгәч, сиңа бик күп өярләр әле ул җәмәгать эше дигәннәрен. Син эшләрсен, аннан башкалар файда күрер. Тирәндә һәрвакыт бушбугазлар тулганыр, кылган гамәлләреннең әҗере дә шуларга эләгер. Андыйлар—әрсез, шома, хөсет күнелле була. Мин Дәүләтьяр ыруының иң карт кешесе, үземнән соң җөянен—нәсел җебенең нык булып калуын телим. Шул чагында гына бу дөньядан тыныч күнел белән китә алам. Үзең дә анлап бетермәстән, төрле ызгышларга юлыгып, яшьтән җегәреңне юк дауларга әрәм итмә, дим. Синең тирәдә шома кешеләр күп йөрер. Булдыклы затларны ярата алар. Җәмәгать эшлеклесе дигән булып, укуыңны онытып, башкалар эшләргә тиешле эшне син майтарып йөреп, ахыр чиктә, надан калып, кеше хуры булып бетүеннән дә куркам. Җәмәгать эше дигән нәрсә, әрсез-алабайларга киләчәктә түрәлеккә юл ача. Белеменә, кулыңнан эш килгән асыл затлар түгел, сүз сөйләп шомарган фәхеш бәндәләр менеп атлана ияргә бу заманда. Синең кебек егетләрне сытып кына үтәчәк алар. Сак бул, энем, куркыныч дәвер килде сезгә...

Нургали Надиев егетнең булсынга йөрүенә куанып, очрашканда болай гына узып китми инде. Хуҗалык эшләренә караган мәсьәләләр хакында фикер уртаклашудан да тайчанмый. Шундый ышаныч бар чагында сынатасы киләме соң! Аннан мондый вәзгыять егетнен үзенә дә ошый. Башка студентларның төшләренә дә керми, син исә олы кешеләр—директор, аның урынбасарлары белән кул биреп исәнләшәсен, хәл-әхвәл сорашмый җибәрмиләр сине. Зарланып тормыйсын, билгеле. Хәлләр ничек кенә хөрт булса да, зур кешеләр янында егет булып каласың килә, зарланмыйсың. Гомәр агай дөрес әйткән, Әхмәтсафага эшне өеп кенә торалар. Каян табып бетерәләр диген. Егет исә тапшырылган һәр эшкә җаваплы карый, кушканны гына көтеп тормый, үзе оештыра, үзе таба. Әхмәтсафа кайгырта башлаганнан соң утын дип хәсрәтләнәсе бетте менә. Мондый булышчы табылуына директор сөенә иде.

Шулай җилкенеп йөргән көннәрдә тулай торакка кайтып кергән Мусаның нәкъ үзенә карап, бәйләнгән сымаграк, кат-кат «салкын монда, төзеп булмас,» дип сөйләнүен өнәп бетермәде Әхмәтсафа. Хәзер түзәргә булыр, әле атна-ун көн чамасы мондагы хәлне күрсәң... Уйлары Әхмәтсафаның йөзенә чыккан иде. «Нәрсә эшләргә соң? Һәркем шулай сукранып, ыңгырашып утырса, кемдер китереп бирер дип уйласа, билгеле, түзеп булмас. Бөтен тулай торагың белән катып үләрсең»... Әхмәтсафаның карашы шелтәле иде. Һәр нәрсәгә үтә сизгер, каршылыклы хәлләрдән

оста итеп чыгарга өйрәнеп килүче Муса, Әхмәтсафаның карашын тиз тотып алды, зарлануыннан туган унайсыз хәлне төзәтү юлына басты:

—Дустым, зарланып эш чыкмас.—диде ул, әле яна гына дөньясы жимерелгән кебек, сыктап торуын онытып.—Мин бүген үк кызлар белән сөйләшәм. Үзешчән сәнгатьтә катнашучы, әле мин белеп бетермәгән егетләр дә бардыр.—Ул инде Гайшәдән кемнең нинди рәк артистлык һөнәре барлыгы хакында белешкән иде. Гомумән, яшьләрне үз тирәсенә туплау өчен ана артык тырышлык та кирәк түгел иде сыман, ике-өч жөмлә әйтүгә тирәсендә кыз-кыркын бөтерелә башлый. Кызлар янына егетләр тартыла. Муса үзе гел читтә калган шикелле тоела. Әмма егет беркайчан да дилбегәне кулыннан ычкындырмый. Яшь-жилкенчәкне кыздырып жибәрү осталыгына ия ул, моны яхшы аңлый, кирәк чакта бу осталыкны эшкә жигеп тә алгалый иде. Әле генә үзен шелтәләп торган Әхмәтсафага күз кысты.—Үзең дә сәхнә йолдызына әйләнеп барасың икән. Синең кебек егетләр кирәк мина. Язган ике-өч пьесам бар. Мин монда укып йөргән элекке елларда сәхнәдә уйнаган идек. Сәгыйть яхшы белә инде.—«Пьеса» сүзе ишетелүгә алар янына елышкан Алишев, Мусаның сүзен раслап, дустанә баш селкеде.—Менә бит егетләр әлдә онытмаганнар,—диде Муса, күңеле булып.—Шул пьсаларымны яңадан карап чыгам, бәлки тагын эшкә ярарлар.—Ул житди тонга күчте.—Шәһәрдә мәктәпләр, балалар йортлары, эшче коллективлары аз түгел, студентларның шефлык рейдлары оештырырбыз. Бәлки ашау ягын да кайгыртырга мөмкин булыр.

Сәгыйтьнең аксыл йөзенә яктылык таралды. Мусаны хуплавын белдереп, күгәрчендәй гөрелдәп алды:

—Шәп булыр ие ул, Муса. Әхмәтсафа бер үзе ике-өч әртисне алыштыра. Декламация дә сөйли, спортчы да...

—Нинди шагыйрьләрнең әсәрләрен укыйсың,—дип кызыксынды Муса. Хәзер инде ул бая Әхмәтсафа каршысында шәлперәеп басып торган кызганыч кыяфәтле малай-шалай түгел. Дилбегә Муса кулында иде.

Әхмәтсафа кинәт үзенең артистлык һөнәренә бәйләнә башлауларына кыенсынып кына җавап бирде:

—Тукай... Сәгыйть Рәмиев... Дәрдмәнд... Санап үткән шагыйрьләрне авылдагы мөгаллимебез Мифтах хәлфә ярата иде. Безгә дә өйрәтте әсәрләрен. Корбан гаете алдыннан Мифтах хәлфәнең рәнжешле сүзләрен искә төшереп, төртелеп калды.

—Шәп, бу шагыйрьләр белән яшәргә була!—диде Муса белдекле кыяфәт белән.—Тик алар иске бит инде. Искегә тисәң, исең китәр. Яңалар белән кызыксынмыйсыңмы?

—Такташ...—диде Әхмәтсафа көттереп кенә. Әле һаман колагында Мифтах хәлфәнең шелтәсе ишетелгән кебек иде: «Имансызланып йөрергә укыттыммы мин сезне? Шуңа өйрәттемме? Искелеккә каршы чыкканда, юлыгызда очраган һәр нәрсәне бетерегез, күмегез, яндырыгыз, дип үгетләдемме? Йә әйтегез, халыкның рәнжеше, күз яшьләре өстендә яңаны төзеп булырмы? Һай акылсызлар, башсызлар...»

—Такташ сезнең башларыгызны яхшы әйләндергән,—диде Муса, Әхмәтсафаны уйларыннан бүлеп.—Кызганыч, әсәрләрен гәзитләрдән укысам да, үзе белән танышырга өлгермәдем. Мин Оренбурдан киткәндә, ул килеп житмәгән иде булса кирәк; кабат килгәндә—ул юк иде инде. Такташ әлегә янага хезмәт итми. Карт шагыйрьләр эзеннән бара,—дип, Такташны бик өнәп бетермәвен сиздерде Муса.—Бу хакта без Ченәкәй белән сөйләшкән идек. Ул да шушы фикердә.—Ченәкәй Оренбурда билгеле шагыйрь. Күпләр аны зур шагыйрьгә саныйлар. Тик, нигәдер, Ченәкәй һәр кичәдә дип әйтерлек җилкенүле чыгышлар ясап та, студентлар каршында артык абруй казана алмый. Такташ катнашкан бер кичәдә чыгыш ясап янды ул, шул чагында абруена көя төште. Шуннан бирле Такташны сөйми, ахры. Күрәсен, Такташны өнәп бетермәвен Мусага да әйтеп өлгергән. Алар дуслар булса кирәк. Мусаның сүз сөреше үк

Ченәкәйне хәтерләтә.—Газраилләр, пәйгамбәрләр, Кабил, Һабил, күкләр, патшалар... Таң кызлары... Юк, безнен өчен түгел болар!—дип, кистереп үк әйтеп ташлады Муса.

Әхмәтсафа, Мусаның Такташка ябырылуын килештерми, ана каршы төшәсе итте.

—Такташны яраталар. Бигрәк тә яшьләр ярата... Шигырьләре дә әйбәт.

Мусаның бәхәскә керергә исәбе юк иде. Әхмәтсафа белән икесе арасындагы киеренкелек йомшарырга өлгермәде, тагын бәхәсле мәсьәләгә килеп төртелделәр. Ул хәрби-сәяси курсларда укыган чакта бирелгән ярыйсы ук таушалган шинелен киеп, чыгып китәргә җыена башлады. Шулай да, әңгәмәгә ноктаны үзе куярга тиешлеген искәрткән шикелле, акыл сатып алды:

—Көрәш, бәхет җырлары кирәк безгә. Яшьләрне шул рухта тәрбияләү лазем, Әхмәтсафа дустым. Эшче сыйныфына хезмәт итәрлек әдәбият тудырырга тиешбез. Менә кайда ул безнең юл! Яшьләрне революцион романтикадан биздерү җинаятькә тиң. Утны су белән кушып булмаган кебек, иске вәзен, өслүб, мәүзуг та чүпкә очарга тиеш. Идея саташуларыннан туктарга вакыт, дускай... —Ул, сүзләренең башкаларга никадәр көчле тәэсир итүен тойган хәлдә, чыгу ягына борылды.—Мин бүгеннән Ченәкәй фатирында тора башлыйм. Мохтаҗлык кичерүче булса, ятакны башка бирәүгә дә бирергә рөхсәт,—дип, авыр адымнар белән ишеккә табан атлады. Авыруыннан һаман терелеп җитә алмавы хак иде Мусаның.

—Ченәкәй белән яшәргә була. Ул хәзер ашханә мөдире. Акмаса да тама,—диде Фатыйх Сәгыйтов. Нинди сәбәп аркасында моңарчы бәхәскә кушылмый торгандыр, үзе дә аңлап җитми иде бугай, үкенгәндәй, Муса артыннан сөйләнеп калды. Кеше күзенә күренә белә. Әле күптән түгел «Авыру комсомолец» шигырен губком съездында сөйләп, уныш казанган. Хәзер күкнең җиденче катында йөри. Егет дөрес әйтте—ялан саен сәхнәгә сикереп менеп, иске шагыйрьләрнең әсәрләрен сөйләргә маташу—сәяси сукырлыкка тиң.—Ул Әхмәтсафага төртмәле караш ташлады. Фатыйх үзе кичәләрдә чыгыш ясамый, башка чаралардан да читтәрәк йөрергә тырыша. Ә инде эшкә йомгак ясаганда, иң беренче чәчрәп чыгып, башкалар өстенә тәнкыйть уты яудыручы ул иде. Мондый чакта аны тыям димә. Аны хуплап сүзгә Мәҗит кушыла. Әлеге ике тәнкыйть остасы эшкә керешсә, эһ тә итми, теләсә нинди җыелышның астын өскә китереп ташлыйлар. Бу ике көч бергә кушылса, аларны җинү турында уйлама да. Хакмы, нахакмы—уйлап тормыйча, тәнкыйть корбаны өстенә кара түгәләр генә. Янадан, аларның хаксыз икәнлеге ачыклангач та, кыенсыну, вөҗдан газабы кичерү юк. «Карга карганың күзен чукымый»,—дияләр дә, бетте -китте, вәссәлам шуның белән.

Шушы ике студент аркасында чак кына бәлагә тарымады Әхмәтсафа. Күңел түрендә утырган үпкә юшкыны әле кубып та төшмәгән, шуңа күрә ул Фатыйхның сүзләренә игътибар итмәгән сыман, үз эше белән мәшгуль булып, дәшми генә утыра бирде. Башкалар да сүзгә кушылмадылар.

...Американың ачларга ярдәм итүче җәмгыяте, башка күп төбәкләрдәге кебек үк, Оренбурда ашханә оештырды. Мөдир итеп Төхфәт Ченәкәйне билгеләп куйдылар. Шагыйрь буларак абруе артык зур булмаса да, яшьләр Ченәкәйне үз итәләр, очрашып, сөйләшеп йөриләр иде. Ашханәгә дә юлны тиз таптылар алар. Мөдирнең вак-төяк йомышларын үтәп, бераз гына тамак ялгап алырга җай да чыккалый иде. Анысы өчен дә Ченәкәйгә мең рәхмәт яудыра студент халкы. Бер көнне Әхмәтсафаны чакыртып китерде Ченәкәй. Дәрес вакыты булса да (Гомәр агайның теге көнге сүзләре ярап куйды. Егет хәзер дәресләрне калдырмаска тырыша), Ченәкәйнең гозерен аяк астына салып булмый, Заһид Шәркыйдан рөхсәт алып, китте мөдир янына. Эш хәйран гына икән. Ашханә почмагына тау булып өелгән буш капчыкларны ишек алдына алып чыгып, он тузаныннан

кагарга, дистәләп-дистәләп санап, яхшылап төреп куярга кирәк. Әхмәтсафа эшкә карусыз, җан-фәрман тотынды. Беренче капчыкны селкеп җибәргә, үзен он тузаны күмеп китте. Тирә-якта ак тузан өермәсе, егетнең башында бер фикер бөтерелә: капчыкларның һәркайсында аз гына булса да он калган икән, нигә аны болай исраф итәргә?.. Берәр җәймәгә сак кына кагып, җыеп алсаң, кич студентлар белән чумарлы аш пешеререлек он җыела түгелме соң? Һәм шулай эшләде дә.

Ул тулай торакка кайтып кергәндә дәресләре бетмәгән иде әле. Сыйныф кабинетлары суык булу сәбәпле, дәресләр тулай торак бүлмәсендәге почмакта үтә, Әхмәтсафа, башкаларның игътибарлы карашын күрмәмешкә салышып, үзенең караваты янына килеп чүмәште. Тумбочка эченнән күп укылудан таушалып беткән «Юксыллар сүзе» гәҗитен алып идәнгә җәеп салды һәм бишмәт кесәсеннән, барысын да биһуш калдырып, ап-ак он бушата башлады. Сыйныфтагыларның укуда кайгысы китте. Һәркайсының миен бер сорай бораулый: бу кадәр онны каян, ничек юнәткән Әхмәтсафа?..

Егет үз эше белән мәшгуль. Күңеленнән Ченәкәйгә рәхмәт укый. Ул Әхмәтсафаның он җыеп мәшәләнгәнен күрсә дә, күрмәмешкә салынды. Берәү булса, тавыш чыгарып та маташыр иде. Кесә бушап калгач, Әхмәтсафа, гадәтенчә, ашыкмый гына гәзитне төреп, караватт астыннан кечкенә сандык тартып чыгарды. Онны шушы сандыкка салып, бикләп куйганчы сыйныфташларының күзе гел анда булды. Әйе, бу гамәлне барысы да күреп торды, Әхмәтсафаның исә аны яшерергә исәбе дә юк иде. Эшеннән соң, зур канәгатьләнү белән кулын чалбар балакларына сөрткәләп алган булды. Аннан зур эш кыруына тамчы да шикләнми, дәрес тыңларга, үз урынына килеп утырды.

Бу араларда чит илләрдән килгән ярдәм хисабына студентларның ашавы бераз яхшыра төшкән иде. Әхмәтсафа сандыктагы онга әлегә кагылмаска, бар чагында бүредәй, юк чагында шүредәй кыланган студентларның ризыклары такы-токыга калганчы сабыр итәргә булды. Әмма беркөнне бүлмәдә шау-шу китте. Фатыйх белән Мәҗит Әхмәтсафаны угрылыкта, ачлар өлешенә кул сузуда гаепләп комсомол комитетына шикаять язып керткәннәр икән. Комитет мондый сигналны колак читеннән генә үткәреп җибәрә алмый, хәлнең чорына күрә гадәттән тыш булуын исәпкә алып, югарырак оешмаларга дә хәбәр итеп өлгергән. Зур җыелыш уздырырга боерык бирделәр югарыдан. Көн тәртибендә бер генә мәсьәлә: «Әхмәтсафа Дәүләтъяровның җинаятен тикшерү».

Суыктан качып, җыелыш Әхмәтсафа яшәгән бүлмәдә үткәрелде. Аны алып баруны Фатыйх Исхаковка тапшырдылар. Ул шикаятьне укып, аңлатма өчен сүзне Әхмәтсафага бирде. Бу хәлдән бөтенләй югалып калган егет кыюлыгын җуеп бетерә язган иде. Онның каян килеп чыгуын бәян итеп бетергәнче шыбыр тиргә батты. Бүлмәдәш егетләрнең барысы да онның ни рәвешле Әхмәтсафаның кесәсенә «килеп кергәнен» беләләр иде. Онның һаман да сандыкта саклануын исбат итәргә теләгәндәй, йөгереп барып караватт астыннан теге сандыкны җилтерәтеп өстерәп чыгарды, ачып, кечкенә төргәкне комитет әгъзаларына алдына алып салды, өстәл уртасынарак шудырды:

—Сүз шушы он хакында бара. Угрылык турында исемә дә кереп чыкканы юк,—диде ул, акланырга теләп.—Егетләр белә: бергәләп тотарга иде исәп...

—Каргалыда туып-үс тә, угры да булма,—диде Мәҗит, тавышына үт ачысы чыгарып.—Гомер-гомергә угрылар оясы бит ул авыл.

Мәҗиткә кушылып Фатыйх Сәгыйтов та Әхмәтсафаны гаепләп маташты. Шушы ике студентка түбән сыйныфта укучы авылдашы Кәрим Хәрәмуллин да кушылды. Әхмәтсафа өчен сәере шунда, моны студентларның күпчелеге онытмагандыр—Кәрим институт баскычына аяк басуга кире борылып кайтып китәргә тиеш иде. Керү имтиханының беренчесен үк бирә алмады. Әхмәтсафага килеп ялынды. Аның тырышлыгы белән

генә институтка кабул ителгән иде. Этне ияртсәң сукма, ди, бүгенге көнгә кадәр Әхмәтсафа аны читкә какмый, үз энеседәй якын күреп, ярдәм итеп йөри иде. Тегесе дә шомарды, ни кирәк булса да, хәзер авылдашы янына йөгереп килеп житә. Менә шушы Кәрим чәрелдек тавышы белән, гаепләпме гаепли Әхмәтсафаны:

—Дәүләтъяровлар гомер бакый ярлы кешенең канын эчтеләр Каргалыда. Сәүдәгәр нәселеннән ул. Әхмәтсафаның әтисе Мостафа да байбәтчә иде. Сәвит хөкүмәтенә байлыгын бирмәс өчен үз-үзенә кул салды.

Әхмәтсафаның йөзенә тимгелләр бәреп чыкты. Шушы минутта, әтисенә тел тигезгән өчен Кәримне бугазлап атарга әзер иде. Әтисенең фажигале үлемендә үзен гаепле сизеп йөргәнлектән, ана болай да авыр, жанында кузгалмас авыр таш яткан шикелле. Инде шушы хөрәсән, әти-әнисе олыгаеп барганда дөньяга килгәнгә авылда «бүлтерек» кушаматы тагылган Кәримне мәңге гафу итмәсен тоеп, алга укталды.

—Яп авызыңны, «бүлтерек»!—Әхмәтсафаны мондый ярсулы рәвештә күргәннәре юк иде, барысы да тынып калдылар. Кәримнең генә туктарга исәбе юк иде, чәрелдәвен белде:

—Шулай инде ул, туры әйткән байбәтчәгә түгел, туганына да ярамый. Байлар алар хезмәтчеләрен изеп өйрәнгән. Хезмәтченең кулы сынса, жин эчендә, башы ярылса, бүрек астында. Авыз ачып сүз әйтә алмый. Минем авызны томалый алмассың, Әхмәтсафа! Ул дәверләр үтте инде. Без ярлы-ябагайга көн килде, иптәш Ленин дилбегәне безнең кулга тоттырды.

Әхмәтсафа күреп алды, Кәрим урынына чүгүгә, янында утырган Мәжит аның кулын кармап алып, нык кына кысып куйды. Тегесенең сөенечтән, авызы колагына житте.

Кәримнән соң сүзне Саттар алды.

Ул Әхмәтсафаны яклап бер сүз дә әйтеп тормады, чөнки аның өчен дустының гаепсезлеге ике икең дүрт сыман. Мостафа абзыйның вафатыннан соң Әхмәтсафаның нинди рухи газаплар кичерүен дә яхшы белә, комсомол билеты белән булган хәл дә күпләр өчен таныш, шуна күрә, ул Кәримгә төбәп сөйләде:

—Кәрим,—диде ул, ачулы тавыш белән,—әгәр син тәмәке тартып маташкан булып, авылга ут салмасаң, бүген ул кадәр үк мохтажлык кичермәс иде Каргалы халкы. Мостафа абзыйга тел тигерү түгел, аның рухы алдында тезләнергә кирәк сиңа. Онытма, авыл дөрләп янганда олы абзыйлар сине әләктереп алып, утка ыргытмакчы булганда, кем аралап алды үзеңне, ә? Әгәр Мостафа агай килеп житешмәсә, синнән шул көндә көл-күмер генә кала иде.

Кәрим үзендә һичнинди гаеп күрми, урыныннан чәпчеп алды:

—Синең атаң әләктерде мине, ул башлады!..

Саттар сүзләрен теш арасыннан саркытып, дәвам итте:

—Инде, үткән жәй кем килеп егылды безнең мастерскойга? Үзегезнең янга алыгыз, ачтан үләбез, дип, кем ялынды? Барыбыз да каршы төшкәндә кем сине яклады? Кем сине институтка укырга кертте?

—Харап икән...—диде Фатыйх Сәгыйтов.

Саттар китергән дәлилләр Әхмәтсафаның гаепсезлеген раславын күпләр шәйләп алган иде. Жыелыштагылар белән беррәттән, президиумдагылар да Кәрим ягына яндыргыч караш ташлап алгаладылар. Алар инде Әхмәтсафага теләктәшлек күрсәтеп утыруларын яшермиләр иде.

Сәгыйтов кына моның белән килешмәвен белдерде.

—Бер ярлы малайга ярдәм күрсәткән дә, хәзер Әхмәтсафа Дәүләтъяров судан ак, сөттән пакь булып калган икән. Ул башкаларга ярдәм кулы сузган булып, ин беренче үз ягын кайгырта. Берәр гаеп эшләсә, аннан шуны калкан итеп куя. Бүгенге кебек...

—Миңа да аның ярдәме зур булды,—дип сикереп торды Зиннәт Әбдерәшитов.—Әхмәтсафа булмаса, ул укуда ярдәм итмәсә, мин бүгенге уку алдынгысы булмас идем, йә инде күптән институтны ташларга туры

килер иде. Әхмәтсафа чын иптәш, чын дус ул!

Эшнең үз файдасына борыла төшүен тоеп, Әхмәтсафаның тамак төбен нидер яндырып алды, күзләре дымланды. Нахак эштә гаепләнгән чакта да болай ук җебемәгән иде, иптәшләре дәррәү күтәрелеп, яхшы гамәлләрен саный башлагач, бөтенләй күңеле сыпылып, түземлеге сизерәгән чүпрәккә әйләнеп бара түгелме соң? Ул үз-үзен кулга алырга тырышып, урында таптанып алды. Аның һаман гаепләнүче сыйфатында басып торуына эче пошып, Фатыйх Исхаков президиумдагыларга сорау бирде:

—Әллә иптәш Дәүләтъяровка утырырга рөхсәт итәбезме? Мәсьәлә ачык шикелле. Гаепләрлек хата эшләнмәгән. Шулай да, иптәш Дәүләтъяров, шул чакта барлык иптәшләреңә онны каян алуыңны әйтеп, аны олы сергә әйләндермәсән, имеш-мимешкә юл калмас иде. Безгә шикаять кергән икән, аны тикшерми кала алмыйбыз. Һәр очракта дөрес карар кабул итеп, тиешле чарасын күрергә тиешбез,—дип, Әхмәтсафа урынына утырган арада, аклангандай сөйләнеп алды.

Әхмәтсафаны яклап Ченәкәй, Муса Җәлилов сөйләделәр.

Гайшә Мөхәммәдованың:

—Әгәр Әхмәтсафа булмаса, тараканнар шикелле катып үләдериек, —диюенә, күңелле генә көлешеп тә алдылар. Шунысы ачык, Әхмәтсафа Дәүләтъяров, үзе дә сизмәстән, күпләр алдында абруйлы иптәшкә әверелгән, күпләргә ярдәм кулы сузарга өлгергән иде инде.

Гаҗәпләндергәне шул булды, җыелыш беткәч, аның янына Кәрим килде. «Буржуйка» дип аталган тимер мич тирәсендә күп маташкангадыр инде, күмер-көл тузанына баткан, каралып беткән кулын Әхмәтсафага сузды:

—Иптәшләрнең сине яклап, хатадан аралап алуларына сөенеп утырдым. Алгы көннәрдә мондый хәлләргә төшмә инде, парин. Авылдашыңны тикшерә башласалар, бигрәк кыен икән,—дип сөйләнгән булды. Әйтерсең, җыелыш Әхмәтсафаны гаепсез дип тапмаган, аны акламаган, фәкать кайбер студентларның яклаулары аркасында гына, Әхмәтсафа җәзадан котылып калган. Кәримнең тел төбендә шушы фикер ярылып ята иде.

Әхмәтсафа Кәрим Хәрәмуллинның кыланмышына үртәлсә дә, аның бу гамәлен тулысынча бәяләп бетерерлек хәлдә түгел иде. Алда әйтелгәнчә, шактый хисләнеп тә киткән иде егет, шуңа күрәдер Кәримнең үзенә сузылган кулына бармак очын тигереп алды. Саттар белән Муса аны көтеп торалар иде, ашыгып алар янына китеп барды. Тегеләре исә, ул килеп җитүгә аны ике яктан култыклап алдылар. Муса нидер сөйләп, Әхмәтсафаны тынычландырырга тырышмакчы иде, Саттар Әхмәтсафаның Кәримгә кул биреп торуын килештерми, шелтәләп алды:

—Беркатлы булма инде, Әхмәтсафа. Шул «Бүлтерек»кә кул биреп торасың. Бер саткан кеше мәңге сатачак, дустым. Бүгеннән мин аңа тамчы да ышанмыйм.

—Достоевскийның князь Мышкины сыман без...—диде Әхмәтсафа уйлана төшеп.—Кәрим кебекләр беркайчан да игелекнең кадерен белмәячәкләр, аларның үз туксаны туксан. Андыйлар башкаларны ишетү түгел, үз күңелләрен дә тыңлап азапланмыйлар. Җаннары пычранган саен үзләрен дөньяда ышанычлы тоталар бит алар. Ә без һаман яхшылыкка, яктылыкка омтылабыз. Шулай гына яши алабыз. Тормыш кануннары кырыс, күңелләрендә мәрхәмәт тулып ашкан кешеләрне бөтереп кенә ала да, кирәгенчә файдалана, кирәге юк дип тапкач, таптый, сыта, изә.—Болар Гомәр агайның сүзләре иде...

—Шулай да шат мин,—диде Муса җилкенеп.—Бүген ялганга, явызлыкка каршы тора алуыбызны күрсәттек бит. Димәк, көч, хаклык безнең якта. Әгәр дә Кәримгә, аны котыртучыларга үч саклап, яңа җәнҗаллар чыгарып йөрсәк, акылны, җегәрне юкка сарыф итү генә булыр иде. Әхмәтсафа бик матур фикер әйтте. Без йөрәк тавышына колак салырга өйрәнергә тиешбез.

* * *

Заһидә... Озынчарак аксыл йөзле, үз уйларына бикләнеп йөрергә ярата торган кыз Әхмәтсафаның бөтен күңелен биләп алды. Әгәр, Заһидә жир читендә берәр кичәдә катнаша, дисәләр, Әхмәтсафа шунда барып житәргә дә әзер иде. Репитиция вакытларында Заһидә дөньясын онытып шаяра, көлә, бөтенләй ачылып китә. Андый чакта Әхмәтсафа чибәр кыздан күзен алмый, сихерләнгән сыман, гел ана карап тора. Кызның ачлы-туклы яшәүдән сулыгып калган йөзенә сизелер-сизелмәс алсулык та жәелә, күзләрендә очкын кабына. Ара-тирә егет ягына яндыргыч караш ташлап та алгалый. Мизгел эчендә хыялы күккә чөелә, чәчәк ата, жимешләнергә дә өлгерә. Хыялы чынга күчсә, кызның озын керфекләре арасына яшеренгән конгырт күзләренә текәлеп озак, бик озак карап торыр иде ул, башында бөтерелеп тә, әле теле белән бер мәртәбә дә әйтеп карамаган әллә нинди назлы сүзләр пышылдар иде... Хыял кысыр өмет кенә булып ала шул. Кичәләр үтә дә китә, әйтеләсе сүзләргә чират житми кала. Институт коридорында кара-каршы очрашсалар, Заһидәне алыштырып куйганнармыни—күрсә дә күрмәмешкә сабышыр, сүз катсаң, мәнге жавап кайтармас. Боек күңелле, сәер табигатьле бер кызга әйләнә дә куя. Әйтерсең, кичә генә бер сәхнәдә янәшә тормаганнар, шаян такмаклар әйтешеп, тамашачыларны көлдермәгәннәр, житәкләшеп пәрдә артына кереп китмәгәннәр, тынмас алкышлар астында кабат чыгып, куллары кулда килеш тамашачыларга килештереп баш иеп тормаганннар. Кызып китү генә булды микәнни? ...Барысы жилгә очканмыни соң?!. Кызның, онытылып китеп, сәхнә артында бер мәл үзенә сыенып торуы да әкият йәки төш кенәме?... Юк, төш түгел, өн иде бит. Тәненең кайнарлыгы егетнең күкрәген һаман жылытып торган сыман, югыйсә.

Бүген инде Заһидә башка кыз. Башка кыз дию дөрес тә булмас, үз эзенә төшкән, кире үз халәтенә кайткан дисәң хак булыр. Ул—Такташ белән саташкан. Ул—мәхәббәт колы. Ул—жавапсыз мәхәббәте белән бәхетле. Кыз әле һаман да зәңгәр күзле шагыйрь егетнең каладан тиз генә, көтмәгәндә китеп баруын һичничек башына сыйдыра алмый. Кайсы тарафларга китеп югалганын белсә, Такташ янына кош сыман очып китәргә әзер самими жанлы, үз хисләре, үз уйлары белән яшәүче шигъри күңелле кызга әйләнә дә куя. Кызның күңелендәге яшьлек үҗәтлеге тудырган хыял белән өретелгән хис-уйларын куып чыгарып, аны үзенеке генә итә алмавына Әхмәтсафа аз газапланмый. Тик ничек, ни рәвешле кызның күңелен яулап алырга? Монысына ул һичбер жавап таба алмый. Ике арада Такташ дигән кыя ята шул, аны алып ташларга егетнең кодрәтеннән килми. Моны ул үзе дә, Заһидә дә яхшы төшенделәр булса кирәк. Мәхәббәт—пар канатлы булса гына бәхет китерә! Гашыйклар-ны ике канатында биек зәңгәр күкләргә күтәреп, әллә кайларга, жан ашкынган бәхет утравына алып китәргә сәләтле булмагач нинди мәхәббәт булсын инде ул... Сыңар канатлы мәхәббәт кызганыч шул, бик кызганыч. Оясын давыл туздырган, канатын кыяга бәреп имгәткән бөркетне генә күз алдыгызга китереп карагыз—Әхмәтсафаның хәле шул бөркетнекеннән жиңелрәк дисезме?.. Сөю газабын ул яшерен генә, беркемгә сиздермәскә тырышып, ялгызы гына кичерә. Ни хәл итәсең? Беренче мәхәббәт диләр шул аны. Егет йөрәк мәсьәләсендә бөтенләй тәжрибәсез. Укуда, хужалык эшләрендә күрсәткән елгырлыгын, тапкырлыгын һәм тырышлыгын бу өлкәгә дә күчерә алса, кем белә, бәлки, Заһидәнең йөрәген яулап алырга мөмкин дә булыр иде. Әмма егетнең күңеленә кем тарафыннан, кайчандыр әйтелгән: диндә вә мәхәббәттә көчләү юк, дигән сүзләр ныклап кереп утырганнар. Белә бит инде, бер генә халык та бер генә динне дә яуларсыз, көрәшләрсез кабул итмәгән. Хак мәхәббәткә ия буласың килә икән, күз ташларга иренмә—әнә Гаяз Исхакый хәзрәтләре: «Тартышуда гына табарсың үз хакыңны!»—дип акка кара белән язып куйган. Ни хәл итәсең, егет мәхәббәт өчен даулашырга әзер түгел иде. Бар күңелен, жанын ·

мәхәббәт итеп Такташка салган кызны хыялый уйлардан аралап алырга көчсез, чарасыз иде ул.

Ә Мусага нәрсә? Анын Гайшә белән борчагы пешә. Кичәләргә дә рәхәтләнеп бергә йөриләр, институтта очрашсалар: авыз—авызда, каян сүз табып бетерә торганнардыр, Әхмәтсафа исе китә—ничек шулай кызлар белән озаклап-озаклап, тәмләп сөйләшергә мөмкин? Хәер, Муса сөйләргә оста инде анысы, үзен тынлаучы гына булсын. Шуна күрәдерме, дус итеп йөргән сабакташларыннан берәү каядыр барырга җыенса һәм моны Муса белеп алса, тегесе Муса белән барырга атлыгып торамы-юкмы—анысы артык әһәмиятле түгел, сабый баладай күзләрен мөлдерәтеп:

—Дускай, мине дә алып бар әле!..—дип әйткәнен әллә тагын үзе сизми дә кала. Аннан, бу үтенеченен бик тә мөһим берәр вакыйга белән бәйләнгәнен искәрткән сыман, өстәп тә куя.—Ул якларда күптән булганым юк...—Әгәр барасы җир якын, көн саен үтеп-сүтеп йөргән юл өсте булса, Муса монда да җай таба, ияреп бару теләген кире какмалы түгел.—Бергәләп урам һавасын сулап, сөйләшеп барырбыз...—ди.

Үзе яшәгән фатирга да кунаклар алып кайтырга ярата ул. Тулай торактан киткәч, шагыйрь һәм укытучы Төхфәт Ченәкәй торган ярым җир астындагы бүлмәгә күчкән иде Муса. Ченәкәй кызганып үзе чакырып китергән иде, ахры. Бүлмә дисән, хәтерен калыр, подвал инде шунда. Менә шул подвалга көн дә кемнедер ияртеп кайтып керә ул. Мона Ченәкәй артык ачуланмый бугай, шуна күрә Муса үзен хуҗаларча тота, каралып беткән чәйнекне тимер мичкә кайнатырга утырта. Су шаулап чыккач, калай кружкадан авызларны пешерә-пешерә («чәй» дип атасан бик үк дөрес булмас) сыек сары су шопыралар. Кайчакта, кунагына карап, Ченәкәй үзенен «запасын»—ипи кисәкләрен дә чыгара. Әхмәтсафаны Ченәкәй нигәдер үз итте, шуна мондый сый еш эләгә иде.

Мусаны тынлап баруы рәхәт. Урамга аяк басуга сүзгә керешә, анын кыйсса-хикәятләре бетәсе түгел, юл буе такылдый, үткән юлны сизми каласын. Сөйләгәннәрен тынласан, исен китәр, әллә тагын илле ел гомер сөргән, дөньялар гизгән ил агасы! Кисәктән каршыларына суыктан бөрешеп, йөгерә-атлый килүче кыз-кыркын килеп чыкса, Муса шып туктап, Әхмәтсафаны җиненнән эләктереп ала һәм ана акыл бирә башлый:

—Кызларны күрсәгез, ди, Ченәкәй, һич кенә дә битараф үткәреп җибәрмәгез, ди. Туктап, йөзенә карагыз, йөзен күрергә тырышыгыз, ди. Йөзен күрсәтмәсә, берәр чарасын табарга тырышыгыз—йә сүз катыгыз, сак кына этеп җибәрегез, ди. Артыннан да карап калыгыз: гәүдәләре ничек, атлаулары килешлеме? Һәр кызнын үзенә генә хас сөйкемле чалымнары була икән. Ченәкәй белми әйтми, кызлар мәсьәләсендә профессор дисән дә була. Ул мина әйтте, мин сина тапшырам. Зиһен сандыгына салып куярга тырыш син, егет. Бу дөньяга ике килмәгән лә... Кызлар үзләренә игътибар иткәнне бик яраталар, ә син...—дип, Әхмәтсафага җинелчә генә төртеп ала Муса.—Заһидә, дип, кибеп-корып, озакламый аяк та сузарсын әле. Заһидә шәп кыз, борчагын пешми икән, акылынны җуйма. Кызлар күп булыр ул, ә син берәү генә, һәркайсы өчен акылдан язсан... Кызлар мәсьәләсендә балыкчыдан үрнәк алу кирәк, дустым. Кармак сал да, тартып ал. Эләксә—балык синеке, эләкмәсә—хафаланып утырма, кармагынны җый да, башка күлгә күч...—Муса шундый оста сөйли, Әхмәтсафа ышанмый тора: Муса үз сүзен сөйлиме, әллә кызлар хакында ана Ченәкәй шулкадәр «дәрес»ләр биреп өлгергәнме?!. Сөйләвенә караганда, инде Муса өчен бу мәсьәләдә бернинди сер юк, аны берничек эздән чыгара алмассын. Гайшә белән сөйләшкәндә дә Ченәкәй биргән сабакны истән чыгармый гына сөйләшә микән? Алай булса... Кая йөрәк, ин кадерле хисләр кая? Чын күнелдән кызлар белән сер уртаклашмагач сон. Муса әйткәнчә, кармак салып йөрүче генә булсан, алдашу килеп чыга түгелме?.. Юк, Муса шаярта гына торгандыр, Заһидә белән уртак тел таба алмавыннан, кыюлыгын җинеп, кыз белән ачыктан-ачык сөйләшергә батырчылык итмәвеннән көлеп кенә сөйли бугай ул.

...Бүген дә шулай Мусаны тынлый-тынлый фатирларына килеп керергә өлгермәделәр, Ченәкәй яткан урыныннан сикереп торып, сәер хәлдә бүлмә буйлап йөренә башлады. Бүлмә салкынча, Ченәкәйнең инендә озын шинель, аягында иске штиблет ботинкалар. Ул өстәлдәге калай чәйнектән кружкага су агызып шопырдатып эчте дә, караватта янәшә утырган Муса белән Әхмәтсафага игътибар да итмәгән сыман, әрнүле тавыш белән шигырь укый башлады:

Инде үтсен тормышымның төннәре, кыш көннәре,
Инде гомеремнең кояшлы нурлы язын каршылыйм.
Күзләремнән нур түгелсен, сүзләремнән—энҗеләр,
Мин дә балкыйм, нурланыйм бер—көн булыйм, бер яктырыйм...

Муса, өстен салып, чөйгә элеп куйды. Әхмәтсафа да караватта утыруын килештермичә, пәлтәсен мыштым гына салып, ишек катындагы бүкәнгә чүмәште.

Төхфәт Ченәкәй—озынча йөзле, кыска иякле, киң маңгайлы чибәр генә кеше иде. Озын, нечкә муенына житү чәчле зур гына башны тотып тору жинел түгел иде бугай, Ченәкәй башын түбән иеп, эре-эре атлап бүлмә буйлап тагын бер әйләнде дә, монарчы жанында йөргән авыр уйларын берьюлы тышка бәреп чыгаргандай, инрәп алды:

—Бармы дөньяда бәхет, егеткәйләрем? Бармы дөньяда безне аңлаучылар? Жир астында сөрсеп ятудан кайчан туктарбыз да, якты дөньяга кайчан чыгарбыз без?—Ченәкәйнең күңеле төшенке чакларда кабатларга ярата торган әлеге сүзләрен Әхмәтсафа бер генә ишетмәде инде.

Бу сүзләр Мусага да яхшы таныш. Ул үзенә хас акыл бирүчән тавыш белән, Төхфәт абыйсын тынычландырырга кереште:

—Килер, Төхфәт абый, килер ул вакытлар. Кояш чыгар безнең баш өстендә. Көннәр жылыныр, агачлар яшәрер, орлыклар шытар. Без яшәргә килгәнбез, ирек кояшы үзенекен итәчәк, салкын кыш үтәчәк ул, үтәчәк.

Төхфәт Ченәкәй кашларын жыерып торды да, көлемсерәп, Мусага карап алды. Аннан карашын аның юлдашына күчерде:

—Ирек дисез инде ә?.. Бәхетле булу өчен күпме ирек кирәк кешегә, уйлап караганыгыз бармы?

Бу сүзләрнең үзенә төбәлгәнен аңлап алган Әхмәтсафа юаш кына тамак кырды.

—Ирек, хөрлекне бизмәнгә салып үлчәп, күпме кирәк, шуның кадәр алып буламыни инде. Кануннар тәэмин итәргә тиеш шәхес ирегең...

Ченәкәй мыскыллы елмаеп, түшәмгә бакты.

—Һи-и, егеткәем!.. Кануннарны кем чыгара соң безнең дәүләттә? Жыен жулик, төрмә каргасы, шымчы-жәсуслар хакимлектә... Без исә шул кануннарның колы булып, салкын подвалда кандала туйдырып ятабыз. Ирекнең тәмен яхшы татыйбыз. Ха-ха!..

Бәхәскә катнашып киткәнсең икән, ярты юлда калып булмый инде.

—Ирек—беренче нәүбәттә жаваплылык дигән сүз. Бәлки иң мөһиме—үз алдыңда жаваплы булудыр да... Максим Горькийны искә төшерик. Тулы иректә, азат хәлдә яшәргә дучар булуның коточкыч жәза икәнен раслап күрсәтә бит ул. Ларрага төшкән жәзадан Ходай сакласын. Кешенең иреклек дәрәжәсен мохит билгели.

—Ирекнең чиге юк!—диде Муса, белдекле тавыш белән. Төхфәт абыйсы башлап жибәргән бәхәс аңа ошап китте булса кирәк. Ана үз уйларын ачыктан-ачык әйтергә шүрләми иде егет. Муса өчен Оренбурда Төхфәт Ченәкәйдән якын кеше юк. Чибәр, буй-сынына тел-теш тидерерлек түгел Төхфәт абыйсы аны ач үлемнән йолып калды. Мусаның язган һәр шигыре өчен сөенеп, аңа дәрт һәм куәт биреп торучы, иренмичә, әдәбиятта бар белгәнен шәкертенә тапшыручы—язу осталыгына өйрәтүче остаз да. Турысын әйтергә кирәк, Муса өчен Төхфәт Ченәкәй әтисе кебек якын бер кешегә әйләнгән мәрхәмәтле зат иде.—Чикләүләрне бетерү өчен тәзелә яңа дөнья. Тартышлар аша без чын ireккә киләчәкбез. Кан коелыр, жан

кыелыр, әмма көрәшчеләр тоткан юлларыннан чигенмәсләр, шул чагында без чын ирекнең ни-нәрсә икәнен белербез. Әлегә, безнен бүгенге хәлне күздән кичерсәк, бу сүзләр көлке тоелыр, билгеле... Әмма хаклык кояшы чыкты инде. Бу салкын кышнын гомере озын калмады. Ирек маршын җырлап азат көннәргә барачакбыз әле, барачакбыз, Төхфәт абый.

—Бирсен Ходай!—диде Төхфәт баягы ярсуыннан сүрелә төшеп.—Менә Әхмәтсафа кызык сүз әйтте бит әле. Мохит һәм шәхес иреге мәсьәләсенә кагылып китте ул. Монын төбендә зур сер, хикмәт ята. Мохит, әйтик, түрәләр, бергә яшәгән, эшләгән кешеләр таләбенә буйсынасын икән, алар корган спектакльгә катнашасын икән, син кирәкле дип саналасын, буйсынмыйсын икән—синең беркемгә дә кирәген юк. Син тулы иректә, сине күрмиләр, танымыйлар, син артык кашыкка әйләнәсен. Тормыш ул—уен, егетләр. Кем моны анлый, андыйларга яшәү рәхәт. Анламаганнар өчен яшәү михнәткә әйләнә.—Ченәкәй Мусанын күнелсезләнә төшүен күреп алды. Төхфәт абыйсынын Әхмәтсафа фикеренә генә колак салуын өнәп бетерми иде, ахры ул. Кычкырып сорап куйды:

—Дөрес әйтәмме, Муса?..

Муса баш какты. Көтмәгәндә башланып киткән бәхәс Төхфәткә кызык тоелды, дәвам итәсе килде:

—Шунысы да бар, егетләр, ирек хакында төрлечә фикер йөртергә була. Уйлап караганыгыз бармы, ни өчендер «ирек» дигәч, кешеләрнен йөзләре яктырып, иреннәренә елмаю куна,—диде ул. Мусанын хисләреннән айный алмый торуын күреп, төбәп аңа сүз катты.—Менә син Муса, үзен «ирек» дип сөйлисен, ә эчендә нииндидер шайтан бар шикелле, гел кытыклап кына тора кебек. «Ирек» дигәндә, уйныйсын килә, шаярасын килә, мәтәлчек атасын килә, җанда гына түгел, акылда да җиңеләю тоела. Бәс, шулай булгач, бу сүзнен асыл мәгънәсе астында көлкеле хыялый бер җилкенү—ирония ята түгелме соң? Соңгы вакытта миңа шулай тоела башлады,—диде дә, янә шигырь юлларына күчте:

Гөлләр елмайган, кырлар нурланган,
Бөтен җир-күге нурга чорналган...
Шашам, ашкынам... Шатланам чиксез
Азат мин, азат! Бәхетем офыксыз!..

Шигырь Әхмәтсафага таныш, ул—Бабичнын «Бәхетем» шигыре иде.

—Аh, Бабич, җан дустым!—диде Төхфәт абый. Күзләрендә яшь күренде анын.—Кая син, нигә килеп кермисен дөньямны нурландырып. Кайсы иблиснен кулы күтәрелде сина, кемнәр һәлак итте сине,—дип өзгәләнде ул. Караватына утырды да, башын ике кулы белән кочып, сүзсез калды.

Әхмәтсафага нигәдер күнелсез булып китте, тыны кысыла башлады, ул чыгу ягына кузгалды. Ни сәбәптәндер, үзе үк ияртеп килгән сабакташына Муса бер сүз катмады, ишектән чыгып баручы егетне нииндидер битараф караш белән озатып калды...

* * *

Ашханәдән чыгып, ашыга-ашыга тулай торакка күтәрелгәндә, Әхмәтсафаны Мусанын көр тавышы туктатты.

—Дустым, кая чабасын, куып җитеп булмый,—диде ул. Әхмәтсафанын артыннан әллә чыннан да шактый йөгергән, еш-еш сулыш ала, шулай да күзләрендә көләч чаткылар уйный.—Бүген балалар йортында кич утыру була. Шәриф ага Камал Салих Сәйдәшне музыка уйнарга чакырган...—Муса, мөһим хәбәр әйттем, инде үзен хәл ит, дигәндәй, беркавым сүзсез торды.

—Кем әйтте?—диде Әхмәтсафа аптырый төшеп. Тагын бер баскыч

өскә күтәрелде.—Әллә кайларда, әллә нәрсәләр була торгандыр инде, дускай,—диде, Мусаның тел төбен аңлап бетермәвенә ишарә итеп.

—Ченәкәй әйтте,—дип, Муса, гадәттәгечә, аның җиңен тартып куйды. —Әйдә, без дә барабыз. Үземә генә күңелсез булыр өлкәннәр арасында. Икәү булсак...

—Безне анда чакыручы юк бит?—диде Әхмәтсафа чакырусыз-нисез олуг әдип Шәриф Камал каршысына килеп басуларын күз алдына китереп. Аннан ул Салих Сәйдәшевне күргәне булса да, аның белән бөтенләй таныш түгел. Белгәне шул—Салих Сәйдәшев музыка мәктәбе директоры, музыка мәктәбе укучылары студентлар кичәсендә катнашса, иң алгы рәттә Сәйдәш тә (музыка мәктәбе шәкертләре яратып, аны «Сәйдәш» дип кенә атап йөртәләр иде) була. Музыка тактына башын кагып алулары, шәкертләре уйнаганда төгәлсезлек китсә, кинәт кулларын җәеп, уңайсызланган шикелле көлемсерәп куюын да күргәне бар, тик болай, Муса әйтте дип кенә, ул катнашкан кичәгә барып керү...

Ул, сәбәп табылганга куанып, Муса тәкъдименә каршы төште:

—«Орлес»ка чакыралар бүген. Эшче куллар җитми икән, булышуыбызны сорадылар.

Мусаның Әхмәтсафа белән дә, башкалар белән дә «Орлес»ка—Оренбур агач яру заводына берничә мәртәбә барганы бар. Эшкә дисәң, җебеп тора торганнардан түгел, башкаларга салынмый, иренми, тирләп-пешеп, янып эшли. Егетнең бу сыйфаты бары тик мактауга лаек. Кайбер чакта Әхмәтсафа җәлләп тә куя аны: арык кына, үсмерлектән яңа чыгып килүче егет кисәге, кайда нинди чара үткәрелсә, шунда катнашырга тырыша; барысына өлгерергә омтыла, укуда булсын, эштә булсын һич кенә сынатасы килми; нindидер серле көчләр йөрткән сыман тоела үзен. Менә хәзер дә, Әхмәтсафаның «Орлес»ка барырга җыенуын белгәч, Муса, керфек кагып алганчы, бүгенге кичнең планын «төзеп» тә куйды:

—Бик яхшы, дустым,—диде ул, тавышында канәгатьләнү төсмере дә чагылып китте.—Иң элек бергәләп балалар йортына кереп чыгарбыз. Мин анда «Авыру комсомолец» шигырен укып алырмын, син балаларга гимнастик күнегүләр ясап күрсәтерсең. Шәриф абый бик яратып карый синең кыланганнарны. Күрерсең, безнең чыгышларны ошатып кабул итәчәкләр,—диде, Әхмәтсафага кире чигенер урын калдырмыйча.—Аннан «Орлес»ка китәбез...—Сер әйткәндәй, тавышын баса төшеп өстәп тә куйды.—Мин «Орлес» заводына багышлап поэма язарга йөрим әле, дустым. Башымда материал бар да сыман, шулай да утырып язарга әзерлек җитми кебек.

Оренбурда эре завод-фабрикалар юк дәрәҗәдә. «Орлес»—алар арасында иң зурларыннан санала иде, шушы завод хакында Мусаның поэма язарга җыенуы Әхмәтсафага яңалык, күңелле яңалык иде. Ул, Мусаның ниятен хуплавын белдереп, шагыйрь дустын кочаклап ук алды һәм алар күңелле сөйләшә-сөйләшә тулай торакка табан атладылар.

...Муса суга караган тылсымчы шикелле булды: балалар йорты директоры Шәриф Камал аларны сөенеп каршы алды. Алар кичә барган бүлмәгә сак кына кереп, урыннарын алырга өлгермәделәр, Шәриф абый Мусаның колагына иелеп, программага алар килү сәбәпле, үзгәрешләр кертүен әйтте. Әхмәтсафага карап елмаеп алды.

—Бу егет тә күнегүләр ясар бит инде,—диде ул.—Мондагы балалар күргән нәрсә түгел, бәлки егеттән үрнәк алып, үзләре маймыллана башларлар.—Тыенкы гына көлеп куйды балалар йорты директоры.—Әле Сәйдәш уйный, аннан Ченәкәйнең шигырьләрен тыңлыйбыз, аннан Мәҗит тә чыгыш ясап алыр...—дип, ул, алгы рәткә, үз урынына китте. Мәҗит Илдар—Оренбурның шәһрәтле артисты икәнен яхшы белә Әхмәтсафа. Мондый кичәләр янында чыгыш ясап, хур булып бетмәсәләр ярый инде.

Әхмәтсафа, игътибар белән сәхнәдә—бераз гына залдан күтәренке итеп эшләнгән төштә пианино уйнаучы чибәр кешегә карап алды. Тамашачылар музыка авазлары тәэсирендә иде, шылт итүче юк. Барысы

да шушы гаять чибәр кешенең пианино клавишлары өстендә үтә бер жинеллек белән йөгерүче аксыл, нәфис бармакларына бакканнар да, сокланудан авызларын ачып, тып-тын калганнар. Әхмәтсафа да таң калды. Уйнаучының бармак хәрәкәтләрен ул, жәйге матур иртәдә, назлы жил иркендә Сакмар суында вак-вак дулкыннарның бер-берсен куышып, якты кояш нурларында уйнап-шаярып йөгерешкәненә генә тиңли ала иде. Бүлмәдәге һәркем—музыка әсире... Монарчы колак ишетмәгән әллә нинди серле көй уйный иде Сәйдәш абый. Озын коңгырт чәчләре маңгаена сибелеп төшә дигәндә генә, ул башын артка чөеп ала. Мондый чакта аның йөзендә сизелер-сизелмәс уйнаган сихри нурлар, чәчләренең тынлаусыз дулкынлануы да, гәүдәсенең музыка көенә тирбәлеп-сыгылып алуларына кадәр Такташны хәтерләтә иде. Хәтта күзләренең зәңгәрлеге дә тач Такташныкы. Бер мәл, онытылып китеп, пианино янында Заһидә басып торган сыман да хис итте егет...

Заһидә исенә төшкәч, музыкант, ул уйнаган көйләр тагын да тәэсирлерәк тоелды. Заһидәне үзләре белән чакырмавына үкенеп тә куйды. Югыйсә, каршы очраган иде бит кыз, алар Муса белән кичәгә жыенып чыгып барганда. Хәтта ки, Мусаның шаяртып нидер әйтүенә колак салмастан, Әхмәтсафага карап сүз катмакчы да булган иде, егетнең, әллә бик тә мөһим эшкә соңга калудан курыккан сыман ашыгуданмы, әллә жавапсыз мәхәббәттән исәнгерәп йөрүенә чик куярга теләпме, кызга артык игътибар итмәстән, тәкәллефсез генә үз янынннан горур гына үтеп баруын күреп алгач, дәшми калган иде. «Их!..» дип, янә бер сызланды Әхмәтсафа. Азга гына тукталган булып, бер-ике кәлимә сүз әйтешеп алсалар, ни булыр иде?! «Әйдә!»—дисә, бәлки килгән дә булыр иде. Шушы музыканы тыңлап, күңеле юаныр, боек жаны ачылып китәр иде. Бәлки шушы кичә, нәкъ бүгенге кичә бер-берсенең күңеленә ачкыч табарга ярдәм итәр иде. Егет, дөрестән дә, кызның үзенә булган салкын карашын һаман үзгәртми йөрүенә үпкәли дә язган иде бугай инде, шул үпкәләвен жиңеп, бүген кызга дәшсә, дөньялар бөтенләй икенче төс алып китәр иде бәлки... Хәзер үкенеп утыруда ни файда, Муса дөрес әйтә: кызларның чак кына керфек сирпеп алуында да мең битлек китапка сыеп бетмәслек сер ята, аңлый гына белергә кирәк, ди ул. Кирәктер дә, менә Әхмәтсафа әлегә сыната шул, Заһидәнең күңеленә һичничек юл таба алмый...

Сәйдәш уйнаган музыка жанны актара. Бер мәлдә, дәртле, кояшлы сыман. Икенче мәлдә күңелне шөбһә, сагыш аһәңнәре күмеп китә. Шушы сагышлы-дәртле моң астында аңлатып булмаслык югалту ачылары бар сыман. Ә бармаклар йөгерә дә йөгерә. Андый нәфис, озын бармакларны беренче күрүе Әхмәтсафаның. Юк, кеше бармаклары болай ук хәрәкәтчән, тыңлаучан булмас, гайре табигый зат иядер аларга... Күңел һаман саен музыка әсирлегендә бәргәләнә. Хәзер инде Сакмар өстендәге дулкыннарның иртәнге назлы тибрәнүләрен яр буендагы камышларның чәбәләнеп өзгәләнүләре, талларның суга ятып бәргәләнүләре, акчарлакларның илереп елаулары алыштырды кебек. Дулкыннар агарып өскә күтәреләләр, бер генә тынга суга кунарга батырчылык иткән акчарлакларны әллә кайларга, офык аръягына чөеп жибәрәләр. Акчарлакларда кеше язмышы ачык төсмерләнә иде кебек. Әйе. Сәйдәшнең уйнавын яхшы төшенә, Әхмәтсафа. Сәйдәш кеше күңеленең эзләнүләрен, үз-үзен табарга омтылып өзгәләнүләрен, шушы юлда кеше язмышына очраган бихисап яктылыклар, дулкын-өермәләр хакында сөйли иде. Омтылышлар, юлда очраган киртәләр, табу-югалтулар, жиңүләр, кире чигенүләр, мәхәббәт һәм нәфрәт, яшәүнең мәңгелеге, гомернең чикләнгәнлеге... Музыка аша шулкадәрле катлаулы нәрсәләр хакында сөйләргә, башкалар белән бәхәскә керергә, килешергә йә килешмәскә, үзеңнең карашларыңны расларга мөмкин икәнлеген егет монарчы белми иде. Әлеге кичәгә алып килүе өчен Мусага мең рәхмәт әйтсән дә аз булыр. Инде көй сагышка чорналып сүндем, беттем, киселдем дигәндә, тагын кояш чыга, тагын көн яктыра, тагын яшисе килү теләге көчәя. Тормышка мәхәббәт тә бар бу көйдә,

бер мәлдә күнел кубарылып куя, шом, дөньяга ләгънәт тә ачык чагылган кебек. Сәйдәшнең уйнавы-уйнау, бармак араларыннан агыла да агыла моң. Әйе, аксыл пианинонын кайсыдыр кыллары чиртелеп хасил булган көй түгел бу, нәкъ менә Сәйдәшнең җанында яралып, анын бармаклары аша тышка саркылган моң иде.

Башка чыгышларны да Әхмәтсафа шушы моң тәэсиреннән аерыла алмый карап утырды. Әнә Муса үзенең шигырен укый. Моңарчы йөрәгенә якын кабул итеп килгән «Авыру комсомолец» шигыре дә нигәдер ул кадәр үк тәэсир итмәде. Бу шигырьне Муса музыка мәктәбендә белем алучы Мәгыйзә исемле кызның пианинода ул чорда яшьләр арасында популяр булган «Титаникның һәлакәте» вальсын уйнавы астында укырга ярата иде. Бүгенге кичәгә Мәгыйзә килгән, һәм, моны әлбәттә, Муса алдан ук белеп торган йәки алдан ук сөйләшеп куйганнар, Муса эшне пешереп бетерүне ярата, югыйсә шулкадәр ашкынып килмәс тә иде. Музыкасыз гына «Авыру комсомолец»ны укуны ул башына да сыйдыра алмый... Мусаның укуы залга киеренкелек өстәде, көрәш рухын янартты, әмма Сәйдәш уйнавындагы табигыйлек юк иде анын чыгышында. Дөресен әйтергә кирәк,чын күнелдән язган шигырь, чын күнелдән укый, күздән яшьләр дә килә, әмма ни сәбәп, ул сине күкләргә алып менеп китми, фәкать җанны газаплый торган хисләр өермәсе генә күтәрелә, кызгану хисе көрәш рухын басып китә. «Менә безнең баштан нинди авырлыклар үтте, менә без нинди язмышка дучар булдык, менә ни рәвешле яна тормыш төзүгә үзебезне корбан кылдык. Кызганыгыз безне!..»—дигән сыманрак. Әхмәтсафаның игътибар иткәне бар—тамашачылар Мусаның шигырен мөкиббән китеп тыңласалар да, ул укып бетергәч, нигәдер зал җинел сулап куя. Бүген дә шулай булды.

Әхмәтсафа күнегүләр ясый башлагач, көтмәгәндә Сәйдәш пианино янына барып утырды да, башта уйнаган көен кабат уйнап җибәрде. Егет үзен күкнең җиденче катында итеп хис итте. Бу юлы көйдәге күләгәләр каядыр таралган, ул яктыра төшкән, дәртле һәм ашкынулы төсләр өстенлек итә иде. Әхмәтсафа чыгышын тәмамлап, тамашачыларга баш игәндә генә исенә килде. Моңарчы татымаган гүзәл мизгелләр кичергән иде ул чыгышы вакытында; гәүдәсенен очышларын сизмәде, ә менә хәрәкәтләренең төгәл, җыйнак булуын тоеп, белеп торды.

Кичә тәмамланып, артистлар һәм шагыйрьләр бер-берсенең чыгышын хуплап-мактап торганда, алар янына борчулы кыяфәт белән Шәриф Камал килеп басты:

—Станцадан хәбәр китерделәр, балалар йортына дип күмер кайтарганнар. Шушы төндә үк бушатып бетерергә кушалар. Көндез булса бер хәл, эшчеләр табарга булыр иде дә... Төнгә каршы кемне табасың? Халык таралып бетте өенә.—Ул күнелсезләнүен яшерергә тырышып, тын калды.

Шул чагында Муса үзенең булганлыгын янә бер мәртәбә раслады:

—Мин хәзер хәрби-сәяси курсларга йөгерәм,—диде ул. Шул арада шинелен киеп тә өлгерде.—Син «Орлес»ка үзең генә барасың инде, дустым. Күмерне кулдан ычкындырып булмый, курсантларны күтәрергә кирәк,—диде үтә эшлекле тавыш белән. Бу минутта чыннан да ул барысына караганда да бер башка өстен тоелды.—Шәриф абый, станцага барып, кәгазь эшләрен карый тор, без бер сәгатьтән килеп җитәрбез,—дип, җавап көтеп тормастан чыгып йөгерде.

—Шәп егет!—дип калды анын артыннан Шәриф Камал.—Нинди эшкә алынса, шул килә кулыннан. Шәп!.. Ничек барысына өлгерә, исем китә.

—Кайтып караватка ауган унайга йоклап та китә,—диде Ченәкәй, бүлмәдәше хакында. Ул аны үз малае кебек ярата иде, шуны сиздергәндәй өстәп тә куйды.—Ял ит бераз, бу дөньяның тишек-тошыгы бетмәс анын, һәркайсына бөке булып бетә алмассың, дип тә карыйм. Кая ул, әллә аңа әйтәләр, әллә стенага, колагына да элми...

## X

Печән чемчекләгән тай шикелле яз кояшы кар ятмасын кимерә. Күзгә сыман ялтырап яткан юка кар элпәсе тыгыз, дымык жил басымына түзә алмый челтер-челтер уала; чана эзләренә кар суы тибеп чыккан. Кыштан тәмам күшеккән жаннарга яз сулышы бөркелде. Болай барса, тиздән Сакмар бозы күтәрелә башлар дип, Каргалыдан килеп укучы яшьләр: Әхмәтсафа, Саттар, Рәхим, Надир һәм, әлбәттә, алардан бер адым да калмый торган Кәрим килеп кушылды, авылга кайтып килергә булдылар. Егетләрнең шау-гөр килеп жыенуларын шәйләп алган Муса, йөзен нәүмизләндереп бер Әхмәтсафага, бер Саттарга карап алды. Бик тә әһәмиятле эш майтарырга тиешле булып та, иптәшләренең аны искәрмичә китеп баруларын өнәмичә, аларны ачыктан-ачык шелтәләгәндәй, гадәттәгечә, иреннәрен бүлтәйтеп, инде егетләргә мәзәк сыман тоела башлаган сүзләрен кабатлады:

—Мине дә алып барыгыз әле, Каргалыга!.. Күрәсем килә...

Саттар көлеп жибәрде.

—Иренмәсәң, әйдә, жыен якташ. Каргалы юллары такыр, унбиш китәр, биш кайтыр, диләр бездә. Кимеп түгел, артып кайтыйк әле...

—Каргалыда ни калган?—диде Кәрим, төксе генә. Әмма аның сүзләренә игътибар итүче булмады, шаярып-көлешеп, Мусаны юлга әзерли башладылар.

Үзләре белән Мусаның Каргалыга кайтуы яшьләр өчен бер күңелле вакыйгага әйләнде. Чөнки Муса булган жирдә сөйләшергә сүз табыла, сүзгә мавыгып, кайтып житүенне дә сизми каласың. Шунысы да бар, Муса кайта икән, димәк, авыл яшьләре белән нинди дә булса кичә оешты дигән сүз. Күзгә кергәч, студент халкы калага, укуга китеп беткәч тынып торган авылга жан инә. Янадан да сагынып сөйләрлек, алга табан үзләренә үрнәк булырлык кичәләрне тансыклаган инде авыл яшьләре.

...Язгы кояш яңакларны иркәли, муенга сырпалана-сырпалана куенга үрмәли. Рәхәт дуслар белән бергә авылга кайтулар! Сүз башта кызлар тирәсендә куерыбрак китмәкче иде. Димәк, әллә никадәр серләр, хикмәтләр сөйләнеп ташланачак сәфәр барышында. Муса, күз кырые белән генә Кәримгә карап алды да, һәркем ачык ишетерлек итеп:

—Бүрәнә башы тишек егетләр,—диде. Әле генә шау-гөр килеп барган юлчылар Мусаның тел төбен аңлап, сүздән калдылар. Үзләре дә беләләр, Кәримнең гадәте шул—ул башкаларның сөйләшкәнен мыштым гына тыңлап тора да, жай чыгу белән, ишеткәннәрен түкми-чәчми икенче берәүгә житкерә. Аның бу гадәтен Муса әле күптән түгел үз жилкәсендә татып та карады.

...Беркөнне тулай торак бүлмәсенә янып-пешеп килеп керде ул. Йөзләре алсуланган, маңгаена тирләр бәреп чыккан. Бүлмәгә кергән уңайга, беркемгә бер кәлимә сүз катмастан, почмактагы зур савыттан каралып корымланып беткән калай кружка белән су чумырып алды да, каударланып иреннәренә китерде. Ул, дәресләр тәмамлану белән «Орлес»ка киткән иде, күрәсең, эше саллы булган: әле бит анда халык алдында чыгыш ясап, дөнья хәлләрен сөйләп кенә калмыйсың, авыр участокта эшләүчеләргә ярдәм итәсең—шулай булганда гына эшче халкы синең сүзенә колак сала. Соңыннан, эш беткәч, уйнарга да ярый дигән кебек, әбәд вакытында бергәләп ашханәгә барып, тамак ялгап алу мөмкинлеге дә бар. Мусаның шулай кабынырдай булып килеп керүен Әхмәтсафа шаяртып, үзенчә борды:

—Әллә, Муса дус, Жаек аръягыннан ук чабып килденме? Ашыкмасаң да әллә ни булмас иде, Гайшәң музыка түгәрәгендә, тиз генә чыкмас...

Муса, кызлар турында сөйләшергә һәвәс булса да, бу юлы битараф кына кулын селтәп куйды:

—Кызлар кайгысы юк әле монда...—Бу сүзләрне һич тә Гайшәгә карата якты хисләренең булмавын гына түгел, ә шушы мәлдә күңелендә

тулышып-ташып шигъри утлар уйнавыннан хискә бирелеп әйткән иде.— «Орлес»ка барып, эшчеләр белән сөйләшеп кайттым.—Муса шулай купайтыбрак җибәрергә ярата, иптәшләре мона күнегеп баралар. Чыннан да, Муса барган һәр эш-гамәлнең мәгънәсе кинәя төшә. Ул инде башкаларның кайдадыр, нидер майтарырга ниятләп «аллага тапшырган» гадәти барып-кайтуы гына түгел. Мөһим вакыйгага әйләнеп куя, халык алдында сөйләнгән сүзләр дә гадәти телмәр, нотык кына булмый. Менә бит, Муса ничек әсәрләнеп сөйли:—«Орлес» миндә яна фикерләр уятты. Эшчеләрне тынлагач, киләчәккә ышаныч, өмет кабынды җанда. Завод эшчесе кулы аша үткән агач-такталардан илнең яңа нигезе төзеләчәк бит, егетләр! Их, егетләр! Болар бит кабатланмас вакыйгалар! Мин бу хакта зур әсәр язачакмын. Әлегә хыял, шулай да кайбер юллары инде күнелдә йөри:

Менә—
Таң аллана...
Гудок тавышы
Эшче торды, өйдән кузгалды;
Гудок—чәен эчте;
Гудок—эшче
Завод эченә кереп югалды;
Таңгы гудок—эшкә;
Көндез—ашка;
Тагын эшкә;
Эшче гудок белән;
Эшче ана
Йөрәк тибеше белән ышанган.

Муса әле генә укыган шигырь тәэсиреннән, хисләреннән айнырга өлгермәде, Фатыйх Сәгыйтов кашларын җыерып, шигырь юлларын тәнкыйть утына да алды:

—Кая монда яңа тормыш, яңа үрләр чаткысы?.. Чәй эчү, ашау... Бәйләнгәнсең шул гудокка. Нәрсәсе бар инде аның? Гудок—чудак... Хи-хи...

Муса аптырабрак калган иде, ярдәм сораган шикелле, иптәшләренә текәлде. Әхмәтсафа Фатыйхка каршы төште:

—Минемчә, гудок монда урынлы кулланылган. Ул күп нәрсә хакында сөйли. Гудок—заводның эш ритмы, гудок—үткәннәр хакында сөйләүче хәтер дә, заводның бүгенгесе дә, аны киләчәккә дәртләндерүче көч тә. Гудок—ул эш, шаулап торган тормыш символы. Исегездә булса, кайчан гына завод хәрабә хәлендә иде, хәзер инде тернәкләнеп килә. Муса дөрес әйтә, гудок тавышы бүгенге көндә илнең йөрәк тибеше ул, өмет, ышаныч уятучы көч...

Муса, Әхмәтсафаның җилкәсенә кулын салды һәм арган тавыш белән:

—Рәхмәт, дустым. Мин бу юлларны нәкъ синенчә уйлап яздым. Завод-фабрикалар хәрәкәткә килсә, тормыш рәтләнәчәк безнең. Мин моңа ышанам,—диде.

Шушы сөйләшүнең Кәрим барысын да «өзеп» ташлаган да, Мусаның Гайшәгә карата уйнапмы, уйлап бетермичәме әйткән сүзләрен аерып алып, кызның үзенә җиткергән:

—Муса «миндә Гайшә кайгысы юк», дип әйтте. Юкка өметләнмә, ул хәзер борынын күтәрде. Синең кебек авыл кызлары ике ятып, бер төшенә дә керми, завод кызларына күз ата башлаган ул. Телендә «Орлес» та «Орлес». Әйтерсең, дөньяда шуннан башка нәрсә юк...

Бу хәлләрдән соң Мусага Гайшә белән аңлашулары шактый авыр булды. Төзәтеп булмас кебек күренә башлаган иде аралар, Әхмәтсафа ярдәмгә килде, Мусаның әйткән сүзләре һич кенә дә кызны кимсетү яки ике арадагы мөнәсәбәтләрне өзү нияте белән әйтелмәгәнен үзенчә

оста итеп исбат итте. Ахырда, Гайшә йомшап, Әхмәтсафаны шелтәләп тә алды:

—Кеше арасын көйләп йөргән буласың тагын... Һаман-һаман да болай йөрсәң, кара аны, егет, Заһидәдән колак кагасың!

—Заһидә Такташка гашыйк шул. Башка кеше күзенә күренми...—дигән булды Әхмәтсафа. Тыштан сиздермәскә тырышса да, йөрәген нәрсәдер яндырып үтте. Коридор идәненең сары буявы әле күгелҗем, әле шәмәхә төскә кереп уйнап алды. Шулай да сүзен әйтеп бетерергә көч тапты.—Кызлар күнелен белеп бетереп булмый инде... Кайсы китапны алып карасаң да, шушы мәңгелек чишелмәс мәхәббәт төенено тап буласың. Бездән генә калган нәрсә түгел...

...Каргалыга кайтучылар юлга чыккандагы уенчаклыктан чигеп, җитдиләнә төштеләр. Авылга кайткач, яшьләр кичәсе үткәрү хакында сөйләшә-сөйләшә атлый бирәләр, Әхмәтсафа гына уйларыннан арына алмый. Үзе юлдашлары белән кичә хакында сөйләшә, күнелендә исә—Заһидә. Баш очындагы кояш яктысын нәкъ менә Заһидәнең нурлы күз карашларыннан алган кебек, дым йөгереп коңгырт төстә таралып алга сузылган чана эзе дә Заһидәнең күпереп торган чәч толымнары сыман. Их, кызларны аңламассың...

Кич җитте. Берәүләр—ызба-читальня, икенчеләр—«кызыл почмак» дип атап йөрткән бинада яшьләр кичәсе үткәрделәр.

Иң элек авыл советы рәисе Зариф абзый җыелган халыкны агымдагы эшләре белән таныштырды, аннан Әхмәтсафа үзенә хас осталык белән илдәге хәлләр турында сөйләде. Халыкның сораулары күп иде.

—Син, энем, бик грамотный инде, әйт әле, иген игеп көн күрүдән башканы белмәгән Рәсәйдә ни өчен мондый афәт—ачлык килеп чыкты?.. Мондый гына корылык элек тә була иде, бу кадәр үк кырылмый иде халык ачлыктан. Аңлап бетереп булмый, аңыштыр әле...

—Әмрикә күпме ашлык бирде микән сәвиткә? Биргәнме, юкмы, әллә халыкның кырылып бетүен көтәме?

—Алманнар ни уйлый микән? Дөрес булса, эрвәлүтсияне алар ясаткан диләр Лилинга? Вагоны белән акча биргән, диләр... Булгандыр, шулай булмаса, бүтән халыкның башы җитәрдәй эш түгел бу, иеме, энем?.. Көлке түгел, сәмәгүн эчеп, тозлы кыяр ашап пич башында яткан кавемдә эрвәлүтсия кайгысы ди... Һем...

—Әле сугыш бетәме җылы якларда? Бохара якларында халык бик усал, көнем өчен түгел, денем өчен дип яши. Бездә генә ул теләсә нинди малакасус динебезне мыскыл итеп, таптап йөри. Анда барып эләксәң...

Әхмәтсафага мондый сораулар таныш иде. «Орлес»та да, ТИНО шефлыкка алган Чебенле авылында да күп бирделәр әлеге сорауларны. Ашыкмый гына, фикерен үзенчә дәлилләп, мисаллар китереп, тиешле урыннарда саннар белән дә «уйнап» алып, төпле җавап кайтарды. Сөйләгәннәренә ышаналармы, юкмы—анысы икенче мәсьәлә, мәгәр яратып тыңлыйлар.

Арадан бер абзый:

—Мостафаның бу малае тел тегермәне тартырга оста икән, каян өйрәнгән, гүпчим сала хәчтрүше димәссең,—дип, башкаларны көлдереп тә алды. Икенчесе, җавап кайтарган булды:

—Дәүләтъяр нәселеннән бит. «Каеш»ныкылар.

Әхмәтсафа сорауларга тәфсилле җавап бирергә тырышып, вакытны шактый исраф итте бугай, пәрдә артында Мусаның ике-өч мәртәбә йөткергәләп алуын ишетте. Ызба-читальнянын бер өлешен өйдән алып килгән чаршаулар белән бүлеп, «сәхнә» ясаганнар иде, пәрдә читен кайтара төшеп, кемдер ачулы ысылдап алды:

—Җитте, Әхмәтсафа, тукта... Вакыт... Таң әтәчләре кычкыра тиздән...

Егет авылдашлары алдында югалып калмавына сөенеп бетә алмады. Аның авыл халкына бераз хәтере дә калып йөргән чаклары иде. Теге чакта, гает көннәрендә яшьләр кичәсе үткәреп йөргәне өчен мәчет картларыннан әр-җәбер сүзләре ишетеп, жаны аз бәргәләнмәде. Әткәсенең вафатын да шушы вакыйгага китереп бәйләгәннәр иде, шул истән китми йөрәкне өшетә һаман, әрнүле хатирәләр күңел түрендә әле дә авыр таш сыман бөялеп торалар иде. Инде менә бераз җиңел булып китте. Аерым кешеләргә рәнжеп булса да, тулаем авыл халкына үпкә саклап йөрү егетлек түгел икәнлегенә төшенде. Әнә ничек үз итеп, яратып, хәтта сорауларга җавап биргәндә аның өчен борчылып, ярдәм итәргә тырышып утыралар. Үзен бик тә белдеклегә санап, тенкәсенә тия башлаган Чөлди Хәйбушен: «Җитте, Чөлди, йөдәтмә адәм баласын, алманнан ничә вагун акча кайтканын каян белсен ул? Лилин аңа килеп хисап ясаганмы кем акчасына эрвәлүтсия ясаганын?!.»—дип, шелтәләп туктаттылар. Ул, бәхәс куертып тормастан, тыңлаучыларга «рәхмәт» әйтте дә, пәрдә артына ашыкты. Кичәдә аның да катнашасы, авылдашларына «артист» булып та күренәсе бар иде.

Пәрдәне бер якка тартып куйдылар. Кичәнең икенче өлеше башланды.

Беренче булып сәхнәгә Муса килеп чыкты. «Бу кечкенә буйлы егет кисәге ни кырыр микән?»—дигәндәй, тамашачыларның кызыксынулы карашлары аңа төбәлде. Бу карашларны Муса үзе дә сизде, ахры, сәхнә уртасында бер генә тын тукталып торды, аннан, ниндидер бер тәвәккәллек белән, тагын бер-ике адым атлап, сәхнәнең алдына, идәнгә тәгәрәшкән бала-чага янына ук килеп басты һәм үз хисләреннән айнымаган кыяфәттә, әллә кайдан, ерак үткәннәрдән дәшкәндәй әкрен генә «Авыру комсомолец» шигырен укый башлады. Тамашачылар аның «р» авазын әйтеп бетерә алмавына сәерсенеп утырсалар да, шагыйрьнең сөйләү куәсенә тиз ияләштеләр. Тора-бара Мусаның тавышы ныгыды, сәхнәләрдә шигырь сөйләп, спектакль уйнап егет шактый остарган иде, тамашачылар аның һәр сүзен «йотып» кына барганына төшенгәч, йөзе алсуланып чыкты, ул инде сәхнә иркендә, үз стихиясендә, чын күңелдән, җаны-тәне белән бирелеп шигырь укый, уку дию генә чынлыкка туры килеп тә бетми торгандыр, ул кечкенә спектакль уйный, тамаша оештыра иде. Ызба-читальняда кем бар, хәтта сәхнә артындагы иптәшләре—бу шигырьне ничә мәртәбә ишеткән сабакташлары да сулыш алырга базмый Мусаны тыңлый иделәр.

Әхмәтсафа Муса шигырь укыганда Бибкәй сеңлесе белән алда уйналачак спектакльнең сүзләрен кабатлап алмакчы иде дә, кая ул, уникенче яше белән бара торган түгәрәк йөзле, сөйкемле кыз пәрдә артына яшеренә төшеп, мөкиббән китеп, Мусадан күзләрен ала алмый тора иде. Әхмәтсафа шөбһәгә төште. Муса чыгышы тәмамланугa пәрдәне беразга гына ябалар да, Муса үзе үк язган «Варенье» дигән кечкенә тамаша күрсәтеп алырга әзерләнгән иделәр. Тамашада өч бала катнаша—ике малай һәм бер кыз. Әле авылга җыенганда ук, кемнәр нинди рольләр уйнасы билгеле иде. Әхмәтсафа—йорт хуҗасының малае, Сәттар—аның дусты, ә менә Әхмәтсафаның, ягъни хуҗа малаеның сеңлесе ролен Пәрвaз уйнарга тиеш иде. Алар һәркайсы бу тамашаны дистәләрчә күреп, үзләре дә уйнап, ятлап бетергәннәр иде, тик Пәрвaз Каргалыга кайтмады, аны ялынып-ялварып ахирәте Заһидә үз авылларына утырмага алып кайтып киткән иде. Монысына да хафаланмадылар, «сеңелкәш» ролен чандыр, кечкенә буйлы Муса, яки Надир да бик әйбәт башкарып чыккан булыр иде, тик, Тайфә карчыкның өенә кайтып кергәч, Муса башта нәкъ менә Әхмәтсафаларга тукталырга булды, югыйсә Сәттар, Надир, алардан өлкәнрәк сыйныфта укучы Кадыйр—Муса белән күптәнге дуслар аны үзләренә чакырсалар да ул, елмая төшеп «рәхмәт» әйтеп, чакыруларны кире кайтара торды. Белә иде бит, югыйсә—Әхмәтсафаларда тамак ягы да кысынкырак, кайтуын түземсезлек белән энесе белән сеңлесеннән

башка күтәп торучы да юк. Ятим кешенең хәле билгеле инде. Шулай да Әхмәтсафа янында туктальрга булды. Әхмәтсафа, бердән, башкаларга карата үтә сизгер һәм ихтирамлы булса, икенчедән, аның белән эч серләрен бүлешү рәхәт. Дусты аны ярты сүздән аңлый. Мусаның иң сөймәгәне—фикерен тыңлап бетермәстән аны бүлдерү, белдекләнеп, әңгәмәнең кызуын сүрелдерерлек сүз кыстырып кую. Тисә—тиенгә, тимәсә—ботакка, шәкелендәге сөйләшүне Муса җен урынына күрә. Әхмәтсафага ул җәһәттән тел-теш тидерерлек түгел, әңгәмәдәшен сабыр гына тыңлап бетерә, аннан соң, өлкәннәрчә төпле итеп, үз сүзен әйтеп куя. Менә Муса гаҗәпләнеп тә карый иде—әле унжидесе дә тулмаган егет, ә фикер йөртүе—нужа кичереп, дөнья куган авыл агаеныкы шикелле. «Олпатлык җитми безнең милләткә», дигән сүзләрне ишеткәне бар иде элекке елларда. Әхмәтсафа аңа үз ишләре арасында олпатлык өлгесе сыман тоела иде. Моның шулай икәнен ятим калып, энекәше белән сеңлесенә бердәнбер терәк булуыннан; аларның һәркайсын үзе укыган чорда ачлыктан, ялангачлыктан җәфа чикмәслек итеп авылның хәллерәк кешеләренә урнаштырып, вакыты булган саен Каргалыга ашыгуыннан; үзенә тиешле студент паегыннан аларга өлеш калдырып, ара-тирә Оренбурда яшәүче Гомәр абзыйсы җибәреп торган күчтәнәчләрне дә күз карасыдай саклап авылга алып кайтуыннан; азга гына булса да туганнарының күңелләрен күреп, бер генә кичкә булса да Тайфә карчык йортына аларны үз канаты астына җыеп, хәл-әхвәлләрен белешеп, сөйләшеп-гөрләшеп алырга җай табарга тырышуыннан да күрергә буладыр. Әйе, аны авылда дүрт күз белән көтеп торалар иде. Әхмәтсафа моны белеп тора, шуңа күрә вакыт табып кайтып килә алса, атна буе туганнары белән очрашу тәэсире белән йөри, андый чакта ул аеруча киң күңеллегә, сүзчәнгә әйләнә, кәефе, кем әйтмешли, җырлап тора иде.

Менә бүген дә Тайфә карчык өенә кайтып керүгә, Әхмәтсафа карчыкка ике-өч шакмак шикәр, кәгазьгә төреп, үтә саклык белән хәстәрләп алып кайтып җиткергән такта чәй кисәген биреп, шуның өчен карчыктан бетмәс-төкәнмәс рәхмәт сүзләре, догалар һәм теләкләр гөнҗәләсе алырга өлгермәде, атылып Әхмәтхан килеп керде. Малай, инде аны авыз тутырып үсмер егет дип атасаң да ярый, ныгып килә, төпле, ышанычлы егет булачагы сөйләшүеннән, абыйсына ихтирамлы карашыннан сизелә иде. Ул арада Тайфә карчык чәй өлгертеп, аларны өстәл янына кыстый башлады һәм шул чагында... кечкенә өйнең ишеге ачылып китте дә, өйгә якты нурлар чәчеп, бер кызчык килеп керде һәм Әхмәтсафаны кочып алды. Үзе назлы тавыш белән сөйләнә:

—Абый-җаным, сагынып беттем! Нишләп кайтышлый безгә кагылып, мине алып китмәдең?.

Муса бер мәлгә сөйкеле баланы гүзәл пәри кызына тиңләпме, телдән калды. Өй, әйтерсең, ниндидер ым ихтыярына буйсынып, зураеп, иркенәеп китте, кызның бераз иркә, ягымлы тавышыннан түшәмнәр биегәеп каядыр чиксезлеккә омтылды кебек. Тирә-якта—нурлар балкышы, өй эче мизгел эчендә яктырып, икенче төс алды; барысының да карашлары үзгә хәзер—ягымлы, җылы иде. Кызчыкның килеп кергән унайга барысын да үзенә каратып, үз ихтыярына буйсындыруы чыннан да гаҗәп иде. Кызчыкның Әхмәтсафаның теленнән дә төшермәгән сеңлесе Бибкәй икәнлеген Муса төшенеп өлгергән иде. Бибиҗамал исемле кечкентәй кызчыкка моннан дүрт-биш еллар элек «Бибкәй» дип комиссар Шамил Усманов, хәзер инде атаклы язучы икәндәшкәнен дә белә ул. Аның әсәрләрен Муса үзе дә йотлыгып укый, Шәриф Камал, Афзал Таһиров, Заһид Шәркыйны әйткән дә юк инде. Усмановны еш искә алалар, яна әдәбиятыбызның нәкъ ул иҗат иткән юнәлештә үсәчәгенә шикләнмиләр иде. Өйгә шаулап-гөрләп килеп кергән әлеге «пәри кызы»на килсәк, Шамил Усманов «исем куйган» көннән башлап кызга барысы да Бибкәй дип кенә дәшәләр, ул үзе дә шул исемен генә ярата. Бибиҗамал дип дәшә калсалар, хәзер авызын турсайта.

Бибкәй, сайрар коштай тынып тормый, авызыннан тылсымлы сүзләр чәчә-сибә Әхмәтсафа тирәсендә бөтерелә. Абыйсы бу очрашудан чиксез канәгать иде, сенлесенен сырмасын салдырып, табын янына утыртты һәм, бар дөньясын оныткан шикелле, «кунакларны» сыйлау хәстәрен күрә башлады.

Бибкәй әле һаман үги әнисе белән Фәтхулла абзый йортында яши икән. Үзләренең балалары булмаганлыктан, Шәмсия түти белән Фәтхулла абзый инде Бибкәйне үз кызларыннан ким күрмиләр, хәтта Бибкәйнең абыйсы кайткан саен аның янына ашыгуына бераз көнләшеп тә карыйлар иде сыман.

Чәй эчеп, тамак ялгап алгач, Әхмәтхан—Әхмәтсафаның малайлыкка ялланып, тамак хисабына эшләүче энекәше, хуҗасы янына ашыкты, хәтта бүген булачак кичәгә дә килү-килмәве хакында тәгаен генә әйтә алмады ул. Хәзер малларга күз-колак булуның иң кирәк чагы. Бияләр колынлый, сыерлар бозаулый, сарыклар бәрәнли торган, ягъни мал-туарның үрчем вакыты. Үч иткәндәй, артым төнлә, яки таңга табан була. Төннәрен күз йомып алырга да туры килми икән көнлекче малайга. Көн туса—бетмәс-төкәнмәс башка эшләр. Әхмәтсафа энесен: «Түз инде, энекәш, бу авыр чорлар үтәр. Сабыр итик, безнең кешечә яшиселәр алда әле. Менә укып кына бетерим дә...» дип, үгет-нәсихәтләр биреп озатты.

Мусаның башына кызык фикер килде—әгәр Бибкәйне тамашага катнаштырсаң? Кыз бик чая, зирәк күренә. Сәхнә артыннан әйтеп, ярдәм итеп торучы—суфлер барлыгын да искә алсаң... Шунысы да бар бит әле: тамашадагы кыз, Бибкәйдән аермалы буларак, артык «сүзчән» түгел, күбрәк хәрәкәт, йөз уйнату-мимикалар аша аңлата әйтәсе фикерен. Моны Муса, әгәр рольдә уйнарга кызлар табылмыйча, малай кешегә уйнарга туры килсә дип, махсус шулай эшләде, Әхмәтсафа сенлесен күндерә алса, тамаша бермә-бер отышлы чыгачак иде. Бу фикерен ул Әхмәтсафаның колагына пышылдап кына әйткән иде, егетләрнең «сере» үзенә кагылганын сизеп алган Бибкәй, матур күзләрен зур ачып, әле абыйсына, әле Мусага карап алды. Йөзеннән үпкәләү чалымнары йөгереп үтте. Әхмәтсафа, эшне озакка сузмастан (сенлесе көйсезләнергә дә күп сорамый), Бибкәйне юмалау эшенә кереште:

—Бибкәй, үскәнем, синең бит тамашалар күргәнең бар, әйеме?

Бибкәй аптырап калды. Бая гына зур булып ачылган күзләр, кысылып бетә язып, керфекләре челт-челт итеп уйнап, ачылып-ябылып куйды.

—Тамаша?.. Теге, апалар биеп, абыйлар җырлаган чакны әйтәсеңме? Госман абыйны солдатка алгандагы төслеме?..

—Әйе,—дип җанланып китте Әхмәтсафа. Шул ук вакытта Госман абыйсы исенә төшеп, күкрәк турысында нәрсәгәдер сулкылдап куйды. Абыйсы киткәннән бирле хәбәр бирмәде. Кайда йөри, исәнме, юкмы, бер нәрсә дә билгеле түгел иде. Үзен кулга алып, Әхмәтсафа сүзен дәвам итте.—Бүген без тамаша күрсәтәбез халыкка, анда уйнарга бер кыз кирәк, син уйнап чыга алсаң, әнә, Муса абыең киләсе кайтуда сиңа бик матур яулык җибәрәм, ди, минем арттан.—Сүзен әйтеп бетермәстән, гаҗәпләнүдән авызы ачылып, ирене салына башлаган Мусага күз кысып алды: «Ни сөйләгәнемне беләм, янәсе, эшне бозып куя күрмә!» Моны аңлап алган Муса инде Әхмәтсафаның үзеннән арттырып җибәрде:

—Чынлап әйтәм, Бибкәй. Иң матурын сайлап алам яулыкның. Әле мин синең турында да тамаша язмакчы булып торам.

—Минем турында... тамаша,—диде Бибкәй. Ул югалып кала язды. Шулай, тик торган кеше турында да тамаша уйнап буламы?.. Абыйлар әллә шаяртып, әллә чынлап сөйлиләр, аңламассың. Бибкәйнең мәзәк рәвештә йөзе чытылып алды.

—Тамаша шул...—диде Муса, ул арада Әхмәтсафаның: «Арттырып җибәрмә!»—дигән кинаяле карашын тотып, аңа: «Хафаланма!»—дигәнне аңлатып, күз кысарга да өлгерде.—Бер бик тә чибәр ятимә кыз булган. Нәкъ синең кебек. Исеме Бибкәй булган. Ятимә булгач, аны кыерсыткан-

нар, шул чагында бик матур бер егет аның шундый авыр яшәвен белеп алып, аны коткарырга дип, көрәшкә ташланган. Егет әллә нинди авырлыклар үткән, әмма кызны коткарам дигән вәгъдәсендә торган, аны золымнан аралап алган. Билгеле, синең турында ук булмый тамаша, тик сине күргәч башыма килде әлеге уй-ният. Димәк, языла калса, тамашаның сәбәпчесе син буласың. Бел, Бибкәй, игелек җирдә ятмый, яхшылык һәрвакыт явызлыкны җиңә. Син бүген тамашага катнашсаң, бик зур игелек эшлисең безгә.

Сүзгә Әхмәтсафа кушылды:

—Каргалыда сәхнәгә күтәрелгән беренче карлыгач буласың. Бусы да саваплы эш, сеңлем, бусы да җиңү. Яңа тормыш менә шундый кечкенә һәм зур җиңүләрдән төзелә инде. Синең уеныңны күреп, сиңа башка кызлар иярер. Кечкенә нәрсә, ә мәгънәсе зур—яшь илебезнең нигез ташларын салышуга тиң ул. Без, сеңлем, үзебез төзегән илдә бик бәхетле яшәрбез. Моның өчен искедән килгән чарасызлыкка, һәртөрле тыюларга, чикләүләргә бик-йозак салырга кирәк. Яңа тормышка ияреп кермәсеннәр алар...

Муса кашын җыерып куйды. Әхмәтсафа мондый чыгышларны «Орлес» заводы эшчеләре алдында күп ясады ясавын, әмма сеңлесе белән дә нәкъ шундый ук агарту эшләре алып баруы... Белмим, Бибкәйнең зиһене бу сүзләрне сыйдыра алырмы, әллә матур гына башланган сүзне бозып кына бетерерме?

Әмма Бибкәй ул уйлаганга караганда зирәк булып чыкты. Моңа охшаш сөйләшүләр элек тә аз булмаганмы, һич тә югалып калмыйча, ачык тавыш белән ярып салды:

—Миңа яулык та кирәкми, карлыгач та буласым килми, ә сәхнәгә чыгып, тамашада уйнасым килә. Мин бәләкәй кыз түгел инде, мәктәптә укыйм! Анда төрле тамашалар күрсәтәбез, әти-әниләр алдында чыгышлар да ясыйбыз.

Бибкәйнең бу сүзләре егетләргә канат куйды. Алар кызга тамашаның эчтәлеген бәйнә-бәйнә сөйләп төшендерделәр. Кем нәрсә әйтергә тиеш, Бибкәйнең сүзләре нинди, ул аны кайчан әйтә, нәрсәләр эшләргә тиешлеге хакында җентекләп аңлатып, тамашаның тәүге репетициясен дә ясап алдылар. Сөендергән шул иде—Бибкәйгә тамашаның эчтәлеге ошады, тик шунысы бар—Муса белән Әхмәтсафа «варенье» дип, шәһәрчәләп күпме кабатласалар да, кызый үҗәтләнә-үҗәтләнә «вәринҗе» ди. Тегеләр ныклап үгетли башлагач: «Шәһәрчә әйтсәм, миңа беркем дә ышанмаячак»,—дип, егетләрне тәмам аптыраштa калдырды.

...Тамаша башланды. Әхмәтсафа белән Саттарның очрашып сөйләшүләре, Әхмәтсафаның дустының өендә тәмле нәмәрсә булуы хакында сер чишүен, аннан атылып өйгә кайтулары, пыр тузып, вареньены эзләүләре, анысының биек шүрлектә икәнлеген күреп алгач, анда менә алмый иза чигүләр, инде алып, тәмлекәйдән авыз итәбез дигәндә генә, чыр-чыр килеп сенелләре—Бибкәйнең килеп керүе, ике малайның, тотылмаска тырышып җан-фәрман кылануларын күреп тамашачылар эчләре катканчы көлделәр. Моның уен гына икәнен онытып, шау-гөр килеп, сәхнәдәгеләргә көч биреп утырдылар. Бу кадәр унышны Муса үзе дә көтмәгән иде. Уен беткәч, тамашачылар тагын бер мәртәбә уйнауны таләп итә башлагач кына исенә килде ул. Озакламый тагын киләчәкләре хакында антлар эчеп ышандыргач кына, җыелган халык тынычлана төште.

Тамашачыларның таралырга ашыкмавын күреп, Муса «Ятим бала» дигән шигырен сөйләп, әле генә шау-гөр килеп утырган тамашачыларны күзләреннән яшьләр сөртергә мәҗбүр итте.

Каргалыдан Әхмәтсафа—энесе, сеңлесе өчен сөенеп килсә—шөкер, исән-саулар, Муса—тамаша өчен канатланып килде—татар дөньясына билгеле Каргалы авылы халкы алдында иҗади имтихан тоткандай хис итте ул үзен. Тамашачылар аны яраттылар, халыкка кирәкле эш майтаруына

инанып кайтты. Аны тагын да зуррак иҗат эшләренә илһамландырды бу сәфәр. «Бибкәй кыз» турындагы пьесаны һичшиксез язарга кирәк дип уйлады ул, юлдашларының шаяртып сөйләшеп, көлешеп баруларына игътибар итмәстән. Оренбурда ТИНО шәкерте булып йөрү генә аны инде канәгатьләндерми. Мусаның киләчәк иҗат планнары хакында сүз чыккач, бер әдәби түгәрәк утырышында, Әхмәтсафаның чишелеп китеп, Шәриф ага Камал алдында әйткәне бар:

—Сина, Муса, Казанга бару кирәктер. Анда башка тормыш, башка сулыш. Юкка гына Тукай, ярыйсы гына тормышны ташлап, Җаектан Казанга юл тотмагандыр. Белем йортлары да, театрлар да, матбугат та Казанда. Оренбурны бөтенләй татар дөньясыннан читләштереп, күр инде, Казакъ иленең башкаласы итеп куйдылар бит. Туганнарымны кешечә урнаштыра алсам, ике дә уйламый, укуымны дәвам итәргә Казан каласына китәчәкмен!..

Әхмәтсафаның сүзләрен Шәриф Камал тыныч кына тынлап утыра иде, түзмәде, егет белән килешкәнен белдереп, җөпләп куйды.

—Казан башка.. Казан кайната да, чарлый да ул. Такташка да әйттем бу хакта. Ул инде Казанда чыныгу алып карады. Әлегә әзер түгел, әзи, ди. Ташкентка юл тотты. Вакытыңны юкка сарыф итәсең, дидем. Казан кайтарачак аны тагын, тартып кайтарачак.

Муса Такташ турында сүз чыкса, кабынып китә, аны нигәдер хуплап бетермәвен сиздерергә ашыга иде. Бу юлы да әйтмичә түзмәде:

—Такташ бит ул пролетариаттан ерак йөри. Бар язганы гел фәрештә дә, пәйгамбәр турында. Эшче, кристиян тормышын кем язар дип уйлый микән? Аның язганнары кемгә кирәк?..

Шәриф ага Камал хәйләкәр елмайды.

—Такташ инде хәзер үк зур шагыйрь саналырга хаклы. Әле ул әйтәчәк үз сүзен. Шагыйрь ул мишәр егете, шагыйрь! Ә син әйткән пәйгамбәр, фәрештәләр турына килсәк, безгә үз динебезне ныклап белергә, кирәк булса әсәрләрдә кулланырга да кирәктер. Рухыбызның мең еллык мирасын бер селтәнүдә юкка чыгарырга ярамый. Яңа иманга ышанып, үз иманыңнан ваз кичү гафу ителмәслек ялгыштыр. Рухи бушлыктан да куркыныч нәрсә юк...

Мусаның күңеле кытыкланып, Шәриф агасына чынлап рәнҗеде бугай. Түгәрәк утырышы беткәнен көтеп, бүлмәнең аргы почмагында серләшеп утырган Гайшә белән Заһидәгә дә игътибар итмәстән, җәһәт атлап чыгып китте. Моны күреп алган Гайшәнең йөзенә кызыл тимгелләр бәреп чыкты, керфеге яшькә чыланды. Мусаның болай үпкәләү дәрәҗәсенә җиткәнен берсенең дә күргәне юк иде әле, гомумән, аны үпкәли белми дип йөриләр иде, баксаң, аның иң нечкә җире—иҗат мәсләгенә кагылышлы мәсьәләсе икән бит...

Әхмәтсафа язгы якты көндә, Оренбурга кайтканда, үз уйларына бирелеп атлаучы Мусага карап, шушы сөйләшүне искә төшерде. Житлегеп киләләр, дөньяга карашлары тамырлана. Сакмар урманнары артында күгелҗемләнгән биек калкулыклар аларга еРактан ук үрелеп карый, нәрсәдер кисәтә, нәрсәгәдәр өметләндерә, туктамаска, алга барырга рухландыра кебек. Ә алда ниләр көтә соң? Шушы сорау юлдашларының барысын да борчый, һәркайсы нәүмизләнеп, үз уйлары белән бергә-бер калып шуңа җавап эзли. Язгы көндә оеп утырган Сакмар урманы да, аксыл томанга уралып беткән ераклыклар да дәшмиләр иде... Шунысы ачык, киләчәкнең ишекләрен беркем дә киереп ачып куймаган, яулыйсы үрләрне үзләренә яуларга, ирешәсе хыялларга үзләренә житәргә туры киләчәк; ижтиһад итәргә, чигенмәскә, алда—кырыс тормыш һәм билгесезлек көтә аларны.

## XI

Нургали Надиев, институт директоры, кызып-кызып дәрес аңлата иде, ишек шакыдылар. Кемнең ашыгыч йомышы төшкәндер, шакучы кабалана иде бугай, директор кадәр директорны болай саксыз рәвештә, ишекне күгәненнән кубарырдай итеп дөбердәтеп, дәресен өзәр дәрәҗәгә җиткереп чакырып чыгарган кеше юк иде әле. Нургали Надиев, гыйлем иясе, карап торуга йомшак, басынкы кеше сыман тоелса да, белем, тәрбия эшләренә килгәндә үтә дә таләпчән, хәтта бераз кырысрак та кеше иде. Кисәк булган әлеге хәлдән директорның чандыр гәүдәсе сискәнеп китте, бу хәлне шәкертләре сизеп торганын абайлап, кыенсынды да бугай, арыган йөзенә кызыл тимгелләр бәреп чыкты, ул «кем йөри анда, юк-бар эш белән борчып» дигәндәй, үтә ризасызлык белән ишеккә таба атлады.

Әхмәтсафа тәрәзә аша мул нурларын яудырган язгы кояштан хозурланып утыра иде, хәтта дәрестә икәнен оныта язган иде, ишек дөбердәткән уңайга күз алдында бөтерелгән сурәтләр, манзаралар мизгел эчендә таралып, очып беттеләр. Егет үзе дә Нургали Надиевтан ким хафаланмады. Ләззәтле иде уйлары, яшәү ямен тойган кебек булган иде, менә сина мә, шапылдап шушы сыйныфына кире төшеп утыр инде. Ә егетнең хыял дөньясы шәпләп эшкә керешкән иде бит!.. Имеш, Каргалыда алар гомер кичергән өй түрендәге алма бакчасы янып көлгә әйләнмәгән. Барысы да элеккечә тыныч, хозур, дөньяның үз җае белән агышы. Язгы ямьле көн икән, алмагачлар шау чәчәктә, менә киерелеп ишек алды капкасы ачылды, пар атка утырып чыгып киткән әтисе белән әнисе шәйләнеп калды. Әнисе Әхмәтсафага табан борылып нидер әйтергә теләгән иде, «ярый инде, үзең беләсең» дигән сыман, яктырып елмайды да, саубуллашкан төсле кулын изәп кенә алды. Әтисе—күп сөйләшергә яратмый торган Мостафа агайның кулында каеш дилбегә. Кыяфәте җитди, чак кына дилбегәне бушатсаң, хәзер дулап чабып китәргә торган шәп атларны капкадан чыкканчы көч-хәл белән тыеп барды да, капкадан чыгуга дилбегәләрне бушатып та җибәрде. Әхмәтсафа, әүвәл, үзен янна-рына алмауларына әткәсе белән әнкәсенә үпкәләгән сымаграк иде, инде алар шундый тизлек белән күздән югалгач, капка төбендә бераз торды да, бу аерылышуга ризалашкан кебек, җәһәт кенә капканы ябып куйды һәм баядан бирле күңелен ымсындырып торган якка—бакча ягына борылды. Бакчага кереп шау чәчәккә күмелеп утырган алмагачларга сокланып карап тора иде, күзенә күренә дип тора: бакча түреннән алмагачларның үзләрен көнләштерерлек ак күлмәктән, ап-ак нәфис өрфия шәл бөркәнгән гаҗәеп сөйкемле кыз килеп чыкты. Үтә килештереп, назландырып кулларын алга сузып торган кыз—Заһидә иде... Егет, бар дөньясын онытып, Заһидәгә табан томырылды, кай арада кыз янына барып җиткәндер, шул шәпкә кызның нәзек биленнән эләктереп алып, кавырсындай җинел гәүдәсен үзенең күкрәгенә кысты, алсу йөзләреннән, күзләреннән шашып-шашып үбәргә иде исәбе... нәкъ шушы кадерле, кабатланмас хыялый мәлдә ишек шакыды да инде теге бәндә. Их, кем икәнен белергә... Дәрестән соң чыгып арт сабагын укытасы иде үзенең. Әйе, мондый пырдымсызны тәпәләп алу һич тә начар гамәлгә чутланмас иде. Әхмәтсафа нәүмизләнгән җанында уйнаган әрнүле хисләрен тыя төшеп, ишек ягына карап алды. Ишек артында Заһид Шәркыйның апты-раулы, гасабилы йөзе күренеп калды. Бу кеше тиккә йөрмәс, хәер, юк йомышын бар итеп йөргән булса да, аңа кул күтәрелмәс иде... Директорга җиткерәсе хәбәре җитди булгандыр, болай сабырсыз кыланмас иде.

Нургали Надиев сыйныф бүлмәсенә шактый вакыттан соң гына керде. Кызып-кызып дәрес биргән җирдән ашыгыч чакырып алынган директорның басынкыланып килеп керүеннән үк шәкертләр нииндидер көтелмәгән хәл булуын аңлап алганнар иде. Директорның какча йөзе

тагын да суырыла төшеп, иреннәре күгәреп кысылган. Ул өстәл өстендә чәчелеп яткан әсбапларын җыеп маташкан булды, бик сиздерергә тырышмаса да, борчылуын һич баса алмый, сыйныф журналына үрелгән кулы хәйран калтырый иде.

Дәрес бетәргә күп калмаган иде инде. Нургали Надиев арыган тавыш белән:

—Дәрес бетү белән икенче катка төшәбез. Линейкага... Дәүләтъяров, сыйныф синең җаваплылыкта кала,—дип, авыр адымнар белән бүлмәдән чыгып китте.

Дәрес беткәнен хәбәр итеп кыңгырау шылтырады. Үзләрен нинди яңалык көтүе белән үтә дә кызыксынган студентлар, Әхмәтсафаның ни булса да әйтүен көтеп тормастан, ишеккә ташландылар, мондый чакта була торган хәл—институт коридоры корт күчедәй гөжләп алды, барлык сыйныфлар да сөйләшә-көлешә, әлеге ашыгыч җыйналу хакында фаразлап-гөманлап икенче катка ашыгалар иде.

Сафларга тезелгән студентлар, бер читтәрәк торган гаять борчулы Нургали Надиевны, башка укытучыларны күреп, тиз арада тынычланып, җитдиләнеп калдылар. Нииндидер күңелсезлек булган, юкса бу кадәрле хафаланмаслар иде укытучылар.

Сафлар алдында әрле-бирле йөренгән Заһид Шәркый, кемнеңдер әйтүен көтеп тормастан, урта бер җиргә басты, нидер әйтергә авыз ачкан иде, директордан узып эш йөртүен чамалап алды ахры, исенә килеп, «вакыт җитте, без әзер» дигәнне аңлаткандай, Нургали Надиев ягына карап, башын селкеп алды. Нургали ага сүз куертып тормады, «рөхсәт» дигәнне аңлатып ым какты. Заһид Шәркыйның арык куллары йодрыкланган, киеренкелектән бит мускуллары уйнаклап тора. Ул тирән тын алды, йөткереп куйганнан соң, тавышына четерекле хәбәр җиткергәндә генә була торган җитдилек төсмере чыгарып, шомлы буяулар өстәп сүз башлады:

—Иптәшләр, шәкертләр, укытучылар, тәрбия фронты работниклары! Яшь совет власте җиңү арты җиңү яулап, барлык фронтларда да каршы көчләрне тар-мар итә-итә, буржуазия, капитализм калдыкларын җәһәннәмнең тирән базына чәнчелдерә барып яңа, шаңлы тормышка табан дөлдел атларда җилдереп бара.—Әхмәтсафаның хәтерендә дәрес вакытында туган әкияти манзара яңарды: әткәсе белән әнкәсе нәкъ менә дөлдел атларда каядыр чыгып баралар иде бит... Шәркыйнең калтыраулы тавышы егетне тиз кайтарды чынбарлыкка.—Әйе, искелекне туздыру җиңел түгел. Безгә, эшче-крестьянга беркайчан да җиңел булмады, бүгенге көндә дә шулай.—Нотыкчы: «Алга табан да җиңел булулары икеле»,—дип әйтергә теләгән иде бугай, сәяси хата китәчәген искәреп, төртелеп калды.—Без... ни... безнең бу көрәшләрдә түккән каннарыбыз эзсез югалмас, бәхетле киләчәкнең мең аршынлы колачлары офыкта инде бүген үк шәйләнә, ашкынулы адымнарыбызны тизләтеп, шунда табан барабыз. Безне алга барудан бер генә көч тә туктата алмас!.. Юлыбызны беркайчан да ялгыштырмабыз!..

Заһид Шәркый кереш сүзен тәмамлагач, «бу өлеше саллы гына килеп чыкты», дип уйлап, канәгать кенә тамак кырып алды. Инде барысы да түземсезләнеп көткән төп мәсьәләгә күчте:

—Бүген,—диде ул, тавышын әкеренәйтә төшеп,—безгә бик күңелсез хәбәр җиткерделәр... Әйтүе авыр, әмма бу хәбәрне ирештерүне миңа йөкләделәр.—Заһид күзләренә чытылып чыккан яшьләрен йодрыгы белән җәһәт кенә сөртеп алды.—Әйе, дошманнар бетмәгән, бар әле дошман. Алар усал, алар явыз. Бүген...—Шәркыйнең тавышы үрсәләнеп-чиелдәп алды,—губерна комсомол комитетыннан хәбәр китерделәр. Безнең якын дустыбыз, сезнең яраткан укытучыгыз Габдулла Туишны, Чебенле авылы крестияннарына яңа тормыш төзүдә ярдәм итәргә киткән ару-талу белмәс тынгысыз комсомол иптәшебезне дошманнар үтереп ташлаганнар...

Студентлар сафы, киеренкелектән, аркандай тартылып куйды.

Әхмәтсафа Чебенле авылында өч көн элек булып кайткан иде. Ачлык елдан соң бераз тернәкләнеп килгән авылда дошманнар яшеренеп ятуы, хәтта кемнеңдер гомерен өзәргә мөмкин икәнлекне күз алдына да китерә алмады. Каравыл өендә, чаршау белән бүленеп алган иске тимер караватта төн куна иде. Көн туса—авыл советында, йомышы төшкән кешеләргә ярдәм итеп, эш кәгазьләре тутырып мәш килде, кич яшьләр, комсомол ячейкасы әгъзалары белән уеннар оештырдылар. Дошман яки явыз ниятле кеше булырга мөмкинме Чебенледә?

Әхмәтсафа ишетелгән хәбәрдән тетрәнеп, башында чәбәләнгән уйларын тәртипкә китерергә тырышты. Габдулла Туиш губкомның яшьләр белән эшләү бүлегеннән килде. Көләч йөзле, гражданнар сугышында авыр яралануы билгесе—сул аягына аксап йөри, тарих укыта, шактый белемле, мәгълүматлы мөгаллим. Институтта түгәрәкләр көне житсә, кичәләр оештырылса кызлар янына елышып, аларны сөйләндерергә, көлдерергә бик һәвәс иде. Шул сәбәптәндер, Заһид Шәркый хәбәре иң беренче чиратта кызлар күңелен кузгатты, сафларда кызларның мышык-мышык борын тарткалаганы ешайганнан ешая иде.

—Еламагыз...—диде Заһид Шәркый тешләрен кысып.—Дошманнарга үч итеп еламагыз!..—Ул тавышына тимер салкынлыгы чыгарырга тырышып, Габдулла Туишның кыскача гомер юлын сөйләп алды. Шәкертләрнең нинди яхшы мөгаллимне югалтуы хакында сөйләгәндә, институтның салкын таш стеналарына кадәр сызланды кебек.—Әлегә Габдулла иптәшнең ни рәвешле, кемнәр тарафыннан һәм нәрсә өчен шәһит киткәнлеген белмибез. Әмма аның яшь гомерен дошманнар өзүе факт... Аның якты истәлеген, революциянең меңләгән-миллионлаган корбаннарын яд итеп, «Матәм маршы»н жырларга тәкъдим итәм.—Заһид Шәркыйнең яшьле күзләре Әхмәтсафа янәшәсендә торган Зиннәткә төбәлде. Зиннәт—институт күләмендә танылган жырчы санала, революция бәйрәмнәрендә, башка чакта күмәкләп жырларга туры килсә, ачык янгыравыклы тавыш белән ул жыр башлап жибәрә, аны бүтәннәр күтәреп ала.

Зиннәт үзенә төбәлгән күзләрнең ни әйтергә теләгәнен яхшы аңлады, ярты адым алга атлады, күкрәген киерә төшеп тын алды да, жыр башлады. Әмма жыр... гажәеп күтәренке рухта иде:

Кузгал, уян, ләгънәт ителгән
Коллар һәм ачлар дөньясы!
Дошманнан үч алсын түгелгән
Үксезләр, коллар күз яше...

Әхмәтсафа, шуны чамалап, Зиннәткә нык кына төртеп алды. Зиннәт шып туктап калды. «Матәм маршы» урынына Сәгыйть Сүнчәләй тәржемәсендә өйрәнгән «Бәйнәлмиләл» жырлый башлаган иде ул. Егетнең тигез жирдә абынуын өнәп житкермәгән Заһид Шәркый көчсез тавышы белән «Матәм маршы»н үзе башлап жибәрергә мәжбүр булды:

Сез хак корбан булдыгыз шәриф юлда,
Халык хакы өчен тартышканда,
Туп, мылтыкка каршы торып үлдегез,
Газиз халык өчен атышканда...

Линейка тәмамлангач, укытучылар белән бергә институтның комсомол активистлары да Нургали Надиев бүлмәсенә жыйналып, Габдулла Туишны жирләү мәрәсиме өчен комиссия төзеделәр. Эшләр бүлештеләр. Төп вазыйфа—күмүне оештыруга житәкчелек профкомның хужалык эшләре рәисе Әхмәтсафа Дәүләтъяровка йөкләнде. Оештыру эшләре тәгәлләнеп, ат алып Чебенле авылына бару хакында фикер алышканда, ишек киерелеп ачылды, аннан ачудан агарынган, күз бәбәкләре киерелгән... Габдулла Туиш килеп керде. Ул, тәмам аптырашта калган, күзләрен челт-мелт йомып торган жәмәгатьчелеккә көтелмәгәнчә кискен тавыш белән ике-өч кәлимә сүз ыргытты:

—Сез, нәмә, анагызны корт чаккырлары, башка эшегез юкмы?.. Исән кешене үтереп, күмеп куярга җыенасыз, панимаешь! Каян чыккан сүз ул? Әнә, мине күргәч Пәрваз һушыннан язып егылды, «үлгән кеше кайтты», дип кенә әйткәнен ишетеп калдым. Шунда әйттеләр, кызлар... Панимаешь... Үләсегез бик килсә, үзегез карагыз, панимаешь...

Заһид Шәркый, дустын кочаклап алырга теләп, аңа табан талпынып алды. Габдулланың ачулы йөзеннән шүрләпме, ярты юлда туктап, авыз эченнән мыгырданып куйды:

—Соң бит... Галин хәбәр җибәрде... Чебенле... Дошманнар үтергән, дип... Менә әле линейка җыеп, «Матәм маршы» җырлап...—Дөресен әйткәндә, беренче мәлдә, Шәркый матур башланып, ямьле тәмамланган чараның шулай көтмәгәндә көлкегә әйләнеп калуын өнәп тә бетерми иде...—Үлмәгәнсен икән,—диде ул салкын гына.

—Ни чыкмаса, синнән чыга Заһид,—диде Габдулла үртәлеп.—Соң, Алла колы, мин бит кичә Сакмарга киттем, губком йомышы белән. Каян барып чыгыйм ди Чебенлегә. Үзең озатып калдың бит, ә?—диде ул, өзгәләнгән кыяфәт белән.—Бу циркtан соң мин шәкертләремнен күзенә ничек карыйм? Мин дәрес биреп маташкан булырмын, алар көлеп утырырлар шунда.

Нургали Надиев, Габдулла Туишның исән-имин әйләнеп кайтуына сөенсә дә, шундый кыен хәлдә калуларына уңайсызланып, Заһидка кырын караш ташлап, аклангандай итте:

—Минем истә иде лә ул Сакмарга китүен. Кинәт бит... Көтелмәгән хәбәрдән исәнгерәп калдым. Шулай була инде: атай үлеп ята, көлеп эчләр ката...

—Кем уйлаган, кем уйлаган, -дип сөйләде Заһид Шәркый, һәм, кинәт, ишеккә ташланды.—Әйдә, Габдулла, губкомга, Галин янына! Барып кайтыйк әле!.. Каян килеп шундый хәбәр тараткан ул, белешик, җавабын институт каршында үзе тотсын,—диде, кызуланып чыгып барышлый.—Әхмәтсафа син дә бар, шаһит булырсың, тиз генә киенеп чык, көтеп торабыз.

—Әле шаһит, әле шаһит,—дип көлемсерәп сөйләнде Нургали Надиев.—Гаепләне табып, чарасын күрү начар булмас иде. Сабаклар өзелде, укуның рәте-чираты калмады. Шулай булса да, дәресләргә, иптәшләр, дип,—дәртле атлап чыгып китте. Габдулла Туишның исән-имин кайту сөенече йөзенә бәреп чыккан иде аның.

...Институт вәкилләренен килүен түземсезләнеп көтеп торганлыгы әллә каян күренеп тора: Заһид Шәркыйнең башы ишектән кереп житәргә өлгермәде, комсомолның губерна комитетында эшләүче Галин эре тешләрен ыржайтып, шаркылдап көлеп җибәрде:

—Нәрсә, артына салам кыстырган кигәвендәй кыланасың, Шәркый?—диде ул, башкаларга игътибар итмәстән.—Астына су җибәрдемме? Хи-хи...

Галин нечкә тавышын хихылдап көләргә көйләп бетерә алмады, Габдулла, аның изүеннән эләктереп, көчле куллары белән стенага терәп куйды:

—Синең эшеңме Галин? Мине теге дөньяга озатуны оештырып йөрисең икән. Дус, иптәш дип йөргән мин җүләр.

Галин бу кадәр җенләнеп ябышуын көтмәгән иде Габдулланың. Яшькелт күзләрен шар ачып, ярдәм сорагандай Заһидка, аннан Әхмәтсафага карап алды, көч-хәл белән иреннәрен кыймылдатып:

—Җибәр... Син нәрсә, акылдан шаштыңмы? Буып үтерәсең...—дип кенә әйтә алды.

Габдулла суына төшеп, кулларын ычкындырды. Галин карчыгадан ычкынган чебеш сыман, түрдәге өстәл артына, үз урынына атылды. Ул инде үзен кулга алырга өлгергән иде, муенын боргалап алды да, чыраен сытып теш арасыннан гына:

—Утырыгыз, аңлашырбыз,—дигән булды. Комачтай кызарган йөзен

күрсәтмәскә тырышып, өстәл тартмасына иелеп, ниндидер кәгазьләр актаргандай итте, аннан соң гына сүз башлады:

—Иптәш Туишев, беренче ишетүең түгел, мин губкомда яңа йолаларны гамәлгә кертү өчен җавап бирәм. Комиссия рәисе. Син моны яхшы беләсең, Габдулла иптәш!—диде ул рәсми тонда. Эрелек төсе чыгарып, астан әле Шәркыйгә, әле Туишка карап, хәйләкәр кыяфәттә сораган булды,—Бүген нинди көн әле?

Габдулла белән Заһид бер-берсенә карашып алдылар да, җавап бир, мәгънәсендә Әхмәтсафага төбәлделәр.

—Нинди көн?—дип кабатлап сораган булды Заһид Шәркый.

—Беренче апрель,—диде Әхмәтсафа көттереп кенә.

—Менә-менә...—дип куанды Галин, муен тирәсен ышкып алып.—Бу хакта, әлбәттә, губкомнан хәбәр көтеп ятарга тиеш түгел идегез. Беренче чиратта сез, Заһид иптәш, һәм... син, комсомол әгъзасы булган яшь иптәш. Искелекне бетерәбез дип лаф орабыз, ике сүзнең берендә яңа йолалар, яңа гадәтләр дибез, ә үзебез?.. Шушы матур, язгы көндә беренче апрель—алдау көне икәнлеген берегез дә уйлап та карамасын инде! Көлке бу, просто тавык көләрлек хәл. Кая комсомол ялкыны, кая монда яңалыкка омтылу, кая монда, канса да канис, көрәш рухы?.. Юк, юк бит, иптәш Юсупов?—дип, Заһидның инде күптән онытылган үз фамилиясен искә төшерде Галин.—Ә бит бу алдау көнен чын совет бәйрәме итеп үткәрергә булыр иде. Алдау-алданулар, бер-береңне шаяртып алулар. Шуның бик матур үрнәген мин сезгә үзем күрсәтергә мәҗбүр булдым, бигайбә. Күңелле түгелмени—үлгән дип уйлаган иптәшегез, революция солдаты сез матәм үткәргән минутта исән-имин үз аягы белән кайтып керсен әле! Хи-хи... Тагын нәстә кирәк сезгә, нинди үрнәк көтәсез? Үзегез оештыра белмәгәч... Губкомның ныклы контролендә булыр бу бәйрәм моннан соң.

—Шәп иттең инде, иштең ишәк чумарын...—диде Габдулла үзе белән шулай усал шаяртуларына әрнүен яшерә алмыйча.—Мине нинди коега төртеп төшерүегезне аңламыйсың бугай, Галин. Шәп казыгансың коены... Үлем белән шаяралармыни?!

—Йә инде, бала-чага булма...—Галинның тавышы үпкәле иде.—Кеше казыган коега төшү ул кадәр үк үкенечле түгел, үзең казыганга төшмә син. Революция ясап йөргәнсең, үзең печтек тә аң кермәгән кеше сыман сүлисең... Шаярту бу, просто дусларча шаярту... Адәм көлдереп йөрмәгез, барыгыз, кайтыгыз. Мин әйткәннәр хакында кат-кат уйлашыгыз...

Заһид Шәркый исә, Галин әйтмешли, шундый «простой вопроста» сәяси сукырлык җибәрүенә, беренче мәртәбә ил-күләм үткәрелә торган совет бәйрәменә—алдашу көненә карата шундый да битарафлык, игътибарсызлык күрсәтүенә үкенеп, ишек катында тора иде. Башкалар артыннан ул да дәшми-тынмый кайтырга кузгалды.

—Алдау көне... Алдау көне...—дип сөйләнде Габдулла Туиш тынычлана алмый.—Алдашу нинди бәйрәм булсын ди, ялган җитәрлек бу илдә болай да...

—Җитте, тынычлан,—диде Заһид.—Үзең генә түгел монда, яшь кеше булуын да онытма!—Бусы: «Әхмәтсафа алдында теленә ни килде, шуны сөйләп барма!»—дигән иде, ахрысы.—Аптырыйм мин,—диде ул, як-ягына сәер каранып.—Нәрсә булган инде—шаяртып алган иптәш. Шуның белән беткән-киткән, син һаман үпкәләп барасың. Аң җитми әле безгә, революцион аң, зирәклек җитми...

## XII

Алдагы елда Әхмәтсафага укырга туры килмәде. Ачлык галәмәте үтеп, халыкка бераз җан инә башлаган чор иде бу. Хәер, Әхмәтсафаны институтка тартып торучы серле җеп өзелде бит—укулар беткәч үк Заһидә, ничә курс тәмам итүе хакында белешмә алды

да, Такташ артыннан Ташкентка китеп барды. Саубуллашып китте. Соңгы көннәрнең берсендә институтның аулак почмагында Заһидә белән күзгә-күз очраштылар алар. Заһидә үзенең Ташкентка китәргә җыенып йөргән әйткәч, әллә институтның биек түшәме өстенә җимерелеп төште—Әхмәтсафаның аны томаланып, шактый вакыт зиһенен җыя алмый торды.

Кыз, Әхмәтсафаның тәмам бетәшкән төстә каршында торуына ачуы килепме, кырыс тавыш белән өстәп куйды:

—Җегет булсаң, җебеп торма! Теләсәң, поездга озатып куярсың. Ә мин Такташны барыбер эзләп табачакмын. Синең белән дуслар булып калырбыз.

Әхмәтсафа, үзен кулга алып, ни өчендер, кызны бу хәвефле юлга чыкмаска үгетлисе итте:

—Ашыкма, Заһидә. Укуыңны бетер, Ташкентта, теге... Такташың да качмас. Бәлки бергә китәрбез ул чагында.

—Илдә чыпчык үлми,—диде Заһидә, Әхмәтсафаның «бергә китәрбез» дигән сүзләрен ишетмәмешкә салышып.—Такташны һич кенә дә күңелемнән куып чыгара алмыйм, аның өчен мине битәрләмә, зинһар. Ул минем җанымны, вөҗүдемне биләп алды. Матур җегет иде. Татар тотып карамый ышанмый дигәндәй, мәнә минем дә шул матурлыкны тотып карыйсым килә.—Кыз әллә чын сөйли, әллә, гадәтенчә, шаяртуга күчеп алды, егет аңышып бетми тора иде, Заһидә сүзне икенчегә борды.—Хәзер бөтен татар Ташкент ягына сыптыра. Бу якта калып, ачлыктан кырылып бетәсе килми кешенең. Быел җәй ничек булыр? Барысы да Ходай кулында бит, Әхмәтсафа.

Кыз китәм дип хыялланган, аны бу уеннан кире кайтарып булмаячагы көн кебек ачык иде. Әнә бит, ничек фәлсәфә сатарга тотынды. Кычыткан чыпчыгы шикелле сикергәләп йөргән кызчык димәссең.

—Акылны Ходай юкка гына бирмәгән кешегә. Бернәрсә дә юкка бирелмәгән. Акыл булгач, уй дигән нәрсә дә бар. Башка уй килеп кергән икән, инде аның да хуҗасы—Ходай дигән сүз. Ходай язмаган эш булмас, мин тәвәккәлләп юлга кузгалам, дустым.—Заһидәнең керфек очында көмештәй яшь тамчысы елтырап китте.—Барып урнашкач та кызларга хат язармын, алар хәбәремне җиткерерләр...—Ул, җавап көтмәстән, йөгерә-атлый беренче катка төшеп китте.

Әхмәтсафа кызны озатырга бармады. Күңелендә үҗәтлекме, үпкә хисеме кузгалды, хәер, анысы артык мөһим түгел иде инде, ни булса да булды—кызның китүен бик авыр кабул итте ул. Заһидә киткән көннән бирле аягы институтка тартмый тек тартмый инде. Күңелне юатырлык бер нәрсә бар—бу җәйдә, ниһаять, үзләре элек яшәгән Сакмар очындагы нигезләренә өй салып керергә җыена башладылар. Бу эшне бигрәк Гомәрхан абыйсы ашыктырды. Аның һич кенә дә Тайфә карчык йортында яшисе килми иде. Үзе сугыштан кайтып керүгә үк хәллерәк кешеләрдә батрак булып ялланды, соңгы кышта Зариф, «башлы егет» дип, аны авыл советына секретарь итеп эшкә алды. Сәвит тирәсендә йөри торгач, бераз унга-сулга карый башлады. Утлар-сулар кичеп кайткан солдат йортсыз-нисез йөрсен инде. Моның белән ничек килешмәк кирәк?.. Янып көлгә әйләнгән нигезләре, йөрәген әрнетеп, шул килеш таралып ята. Язгы чәчүләр бетү белән Әхмәтсафа белән киңәште дә, Бәдертдин байда күнлекче малай булып йөргән Әхмәтханны чакыртып алды. Авыл советы сәркатибенә бай абзый карышырга батырчылык итмәде, үзләренең көннәре санаулы гына калып баруын ул чамалый иде инде. Егетләр эшкә җан-фәрман тотындылар. Ихата арасын яхшылап чистартып, яңгыннан калган чүп-чарны Сакмарның биек ярыннан аска түктеләр. Абыйлары янына уникенче яшен тутырып килүче сөйкемле кыз Бибкәй дә килеп җитте. Ул һаман да үги әнисеннән аерылмый, Шәмсия белән Фәтхулланың асрамага алган кызлары булып яши иде. Атна дигәндә йортка нигез салынды...

Әхмәтсафа үткән ел яшьләр белән бергәләп оештырган итек тегү

мастерскоендагы эшне җанландырып җибәрде. Ана Саттар да килеп кушылды. Булышчылары да табылды, иң мөһиме, мастерскойны авыл советы рәисе Зариф абзый үз итә, үткәндә сүткәндә кереп чыга, кулыннан килгәнчә егетләргә булыша иде.

...Җәй урталары житкәч: «Якын-тирәдә угрылар йөри, совет хакимиятенең дошманнары яңадан баш калкыта икән,»—дигән хәбәрләр ишетелә башлады. Авыл активистлары, коммунистлар Зариф абзый житәкчелегендә ЧОН отряды төзеделәр. (ЧОН—«часть особого назначения» дигән сүзләрне кыскартып әйтү—жирле партия ячейкалары тарафыннан төбәктә контрреволюциягә каршы көрәшү, тәртип булдыру, дәүләт милкен саклау өчен төзелгән отряд). Отряд әгъзалары төннәрен авылны төрле угры-каракльардан, дошманнардан саклау нияте белән кизү оештыра башладылар.

Гомәрхан да өйгә мылтык күтәреп кайтып керде бер көнне.

Әхмәтсафа мылтыкны күргәч, кызып китте, авылны саклаучылар сафында булмавына үкенеп тә куйды хәтта. Нинди гажәп хәлләр булмас дисең, ә ул, комсомол башы белән, төннәрен башын чикмән астына яшереп ятсын ди!.. Әлеге уйларын икенче көнне мастерскойга килгәч, Саттарга да сөйләде.

—Авылның комсомол ячейкасы бар, алар нигәдер кымшанмыйлар бит,—диде Саттар Әхмәтсафаның кайнарланып сөйләвен бүлдереп.—Өлкәннәр йөри дип... Аларның күпчелеге гражданнар сугышында булган, утны, суны кичеп кайтканнар. Бездә ни корал юк, ни әйткән кеше дә юк.

—Кем әйтсен безгә?!—дип янә кызып китте Әхмәтсафа.—Ни өчен комсомол соң без, шундый эшләрдән читтә йөргәч? Мусадан үрнәк алырга кирәк безгә—мылтык күтәреп дошманнарга каршы йөргәндә, үзе дә мылтык буе гына иде.

—Каян алабыз мылтык?—дип сорады Саттар.—Кулга таяк тотып чыгып булмый бит. Аннан барыбер яшьләрне күтәрергә кирәк. Комсомол ячейкасы ни уйлый?.. Шәһәрдә кыш буе таракан симертеп яттылар да, хәзер эшем иясе булган булып, безнең эшкә кысылып йөриләр диючс табылмас дисеңме?

—Димәсләр! Дөрес аңлату бездән тора. Үзебездән башларга кирәк,—диде Әхмәтсафа, ышанычлы тавыш белән.—Мылтыкка килсәк, Гомәрханның мылтыгы өйдә тора, үзе төнлә авыл советында кунып йөри. Ана шундый фәрман бирелгән. Инде бер атна буладыр, өйгә көндезләрен генә кайтып китә. Мылтыгы хакында онытты да бугай инде. Аңа нәрсә, сәвиттә корал житәрлек...

—Бездә ау мылтыгы бар,—дип сүзгә кушылды Рәхим.—Әткәй чормага яшереп куйган иде, ике-өч ел тузан җыеп ята шунда, хәзер ауга йөрер чак түгел, алып төшеп чистартсан...

—Чынлап еласан, сукыр күздән яшь чыга,—дип куанып сөйләнде Әхмәтсафа.—Ә син таяк дисең. Менә өчебезгә ике мылтык булды. Беребез, чыннан да таяк белән йөрер. Корал эшләр, ир мактаныр, сугыша белсән, таяк та корал.

...Караңгы төн. Сакмар ягыннан Каргалы очына табан тавыш тынсыз гына шәүләләр шуышкан кебек. Төнге күк йөзен алама болыт кисәкләре камап алган, шул әләм-сәләм болыт арасыннан сирәк кенә ай карап ала, ул чагында йөрәктәге шом тарала төшә, шәүләләр пышылдап кына, үзләренең кай тирәдә йөргәннәрен чамалап алалар, якын-тирәдә хәвеф-хәтәр булмавына ышангач тагын алга атлыйлар. Болар Әхмәтсафа, Саттар, Рәхим—ягъни төнгә авылны дошманнардан сакларга чыккан яшьләр иде.

Шактый йөреп тә, шикләнерлек нәрсә күренмәгәч, егетләр тынычлана төштеләр, карангыга даияләштеләр, аннан мылтыклар да яхшы иптәш, ышанычлы терәк, алар бар чагында курку читә икән, егетләр кыюланып, нигә чыкканнарын оныта язып гәпләшеп баралар иде, зират тыкрыгыннан каршыларына әзмәвердәй карачкы килеп чыкты.

Егетләр, көтелмәгән хәлдән аптырап, телдән калдылар. Рәхимнең кулындагы мылтыгы төшеп китте.

—Кемнәр йөри? Кая бару әле?—диде кырыс тавыш. Аның Зариф абзый тавышы икәнен шәйләп алдылар.

Әхмәтсафа тотлыгып, җавап бирде:

—Ком... комсомоллар... без. Кизүдә...

Зариф мыскыл иткәндәй көлеп куйды:

—Сүз әйтмәс борын комы коелып беткән комсомоллар икән әле.— Ул, җәһәт иелеп, Рәхимнең мылтыгын җирдән күтәреп алды.— Комсомоллар түгел сез—хәчтрүшләр! Нишләп кизү хакында авыл советы белми, теркәлми-нитми кем чыгарга кушты сезгә?

Әхмәтсафа батыраеп китте:

—Бөтен активистлар угры-дошманнарга каршы күтәрелде. Шундый чакта без яшьләр йоклап ятарга тиешме? Сөйләштек тә чыктык менә...

—Кемнәр соң сез, балакайлар,—дип Зариф шырпы сызып җибәрде. Сүрән яктыда егетләрне төсмерләп, көлә төшеп санап алды:

—Әхмәтсафа, Саттар, Рәхим... бәй студентлар түгелме соң сез? Авыл комсомоллары үз белдекләре белән кизүгә чыккан дип торам тагын. Аларга да задание бирелгән, аларның эше башка. Ә син «Каеш»—молодец! Шулай да сак йөрегез, егетләр. Бүтән көннәрдә өлкәннәр белән җыйнаулашып чыгарсыз, каршыгызга очраган беренче кешене күрү белән мылтыгыгызны җиргә ташларлык булгач, чыкмасагыз да сүз юк.

Рәхим аклангандай сөйләнеп, Зариф кулындагы мылтыкка үрелде:

—Бавы күгәреп беткән, каһәр төшкеренең... Каршыга шәүлә килеп чыккач, җилкәдән тартып кына алыйм дигәнием... Өзелде, шайтан...

Егетләр көлешеп алдылар. Зариф абзый ничек көтмәгәндә пәйда булса, шулай ук караңгылык эченә кереп, юкка да чыкты.

Кизүчеләр авыл башына чыгып, озын сөзәк калкулык буйлап сузылган юл буенда тукталдылар. Тирә-юньне үзләренчә җентекләп күзәтеп торсалар да, шик-шөбһә төшәрлек нәрсә дә булса сизелмәде. Төн тәнгә авышкач, тәннәргә суык үрмәли башлады, керфекләргә мыскаллы йок асканнармыни, ябылабыз-ябылабыз дип кенә торалар, тизрәк кайтып сәкегә авасы килә. Мастерскойга да төштән соң гына җыелырга сүз куешып, кайту ягына борылганнар иде, ерактан йомшак кына ат тоягы тавышы ишетелде. Иң гаҗәбе—шул арада аларның өстенә үк диярлек бер җайдак килеп чыкты, егетләр үзләре дә сизмәстән, юл читендәге уйсу җиргә чүктеләр. Болай соңга калып килүче мосафир кем булыр? Зариф абзый белән очрашу чирканчык алдырган иде, бу юлы егетләр шактый кыю булырга тырышып, җайдак килгән якка текәлделәр.

Җайдак, һичшиксез, алар яныннан ук үтәчәк иде. «Бәлки кем икәнен чамалап та булыр?»—дип уйлап алды Әхмәтсафа. Әмма ат, алар поскан җиргә йөз-йөз илле адым кала, юлны ташлап, бакча киртәләре буйлап Сакмарга табан төшеп китте. Сәер, бик сәер иде бу хәл. Егетләр алдан сүз куешкандай, җайдак артыннан кузгалдылар. Гаҗәп бит кеше дигәнен—әле генә үзләренең шәүләләреннән өркеп, шикләнеп йөргән кизүчеләр чын эшкә керешкәч, бөтенләй курку белмәс кешеләргә әйләнделәр дә куйдылар. Күкрәктә ашкынып типкән йөрәк тә куркып түгел, ә шушы сәер хәлне тизрәк ачыкларга, эшнең төбенә төшәргә ашыктырып җилкенә иде. Ахыр чиктә, уйласаң, егетләр татлы йокыларын калдырып, ни дип михнәт чигеп йөрделәр? Дошман йә угры тотабыз дип, кайнарланып чыктылар бит кизүгә... Менә, бирим дигән колына, чыгарып куяр юлына, ди, шикле бер җайдак килеп чыкты. Аның урамга кермичә, ниндидер яшерен нияте бар сыман, авыл читеннән Сакмар ягына төшеп китүе көтелмәгән, әмма бу катлаулы көрәш чорында булырга бик тә мөмкин хәл иде. Кем генә йөрмәс диген мондый болганчык чакта, кемдә нинди ният юктыр дисең? Шуңа күрә егетләрнең берсендә дә икеләнү-курку тойгысы калмады. Сак кына, җайдакның артыннан барып, аның кем икәнен, нинди ният белән килүен ачыкларга, моның

өчен, ин кимендә, аның кемнең йортына кереп китүен чамалап калырга кирәк иде. Инде юлчы Сакмарны кичеп, аръякка китмәкче икән, бигайбә, егетләрдә мылтык бар, атып шау-шу кубарачаклар. Авылдагы ЧОН отряды йокы бүсеп ятмый торгандыр, күтәрелеп чыксалар, бу жайдакның эше хәл ителде дигән сүз. Аларда ат та бар, корал да житәрлек. Сәер юлчы исә, әрәмә-урман арасында озак яшеренеп йөри алмас, егетләрнең белүенчә, анда да яшеренгән кизүчеләр бар. Тиз шәйләп алырлар.

Жайдак бер дә ашыкмый төсле тоелды егетләргә. Алар, хәтта артык якынаеп, вакытыннан алдан үз-үзләрен ачмас өчен, адымнарын акрынайтырга мәжбүр булдылар.

Әйе, жайдакның яшь-жилкенчәк кенә булмыйча, чандыр, озын гәүдәле икәнен дә искәреп була иде инде—дөньяга таң нурлары сирпелеп, күк түре күтәрелә төште. Бу хәл егетләрнең дә эшен кыенлаштырды. Жайдак исә, һич кенә дә Сакмар аръягына чыгып китү турында уйламый иде, бакча буен үтеп, аскы урамга борылды, бер ихата янының узганда, атны кинәт уңга борды да, лапас каралты артларына кереп юкка да чыкты. Егетләр адымнарын тизләттеләр. Юлчы ташландык йортның жимерек киртә арасыннан түр бакчага чыккан, анда исә берничә хужалык—каралты артлары аша үтеп, әллә алдан хәзерләнеп куелган, әллә анысы да жимерелеп беткән булган—аратасыз киртәлек аша аулак тыкрыктан чыгып каршы як урамга үткән. Озакламый аның үзен дә искәрделәр. Жайдак үзенә генә таныш сукмаклар буйлап бара, аның бу авыл кешесе икәнлегенә шик калмаган иде инде. Ул икенче бер тыкрыктан Сакмар буендагы соңгы урамга чыгып барган жирдән, янә уңга каерып, бакча артына үтте, атыннан сикереп кенә төшеп, лапасның арт капкасын ачып, атын эчкә үткәрде, үзе жинел хәрәкәтләр белән тыкрык киртәсен рәткә китерде һәм ачык капкадан лапас эченә кереп сеңде. Эчтә хатын-кыз тавышы ишетелеп калды, ана каршы тыенкы гына ир-ат нидер жавап кайтарды, шуннан башка ник бер тавыш әсәре булсын... Егетләр инде тыкрык ягына ук чыгып торган лапас янына килеп життеләр, тынланган булдылар, әллә жайдакны аты-ние белән жир йотты, шым иткән тавышфәлән юк иде...

Әхмәтсафа Саттарның колагына иелә төшеп:

—Фәтхулла абый бит бу. Алар ихатасы,—дип пышылдады.

—Беләм,—диде Саттар.—Бездән ерак тормыйлар ич инде алар.—Тик Фәтхулла абыйның аты юк бит аның. Каян кайтып килеше микән болай?

Рәхим, тынын кысып, ыслап алды:

—Фәтхи атсыз торыр ди... Аларның нәселе ат карагы бит. Кәсепләре шул. Димәк, Фәтхи янә шул шөгыленә керешкән, сугыштан кайткач.

—Нишлибез?—дип, аптырап сорап куйды Әхмәтсафа. Болай гына ихатага барып кереп булмый, аннары бит әле, сеңлесе Бибкәй дә шушы йортта. Алар йорт хужасының шикле эшен фаш итәргә йөриләр, кызчык бер хәбәрсез йоклап ята торгандыр.

—Тире жыеп, күн эшлибез,—диде Саттар, белдекле кыланып.—Зариф абзыйны табарга кирәк, әллә кайда йөрми торганнардыр әле. Без үзебез ни эшли алабыз? Бар, Рәхим, урамны әйләнеп чык, кизүчеләр очраса, хәбәр салырсың. Без монда—лапас ышыгында көтеп торабыз. Мылтыкны калдыр мина, сиңа кирәге юк аның.

Бер сәгатьләп вакыт үтте, инде таң атты, тирә-як яктырып, бөтен нәрсә уч төбендәгедәй күренә иде, арып-талып, өстерәлеп диярлек Рәхим кире алар янына килеп егылды:

—Беркем юк урамнарда, хет бөтен авылынны талап алып китсеннәр. Хәтта авыл советы ишеге дә бикле. Шакып та карадым, ачучы юк,—диде ул зарланып.

—Яктыра башлауга, таралышып беткәннәрдер. Авыл мужигы бит алар. Тиздән көтү кузгала,—диде Саттар.—Монда таптанып торып булмый, әйт, Әхмәтсафа, нишлибез?

—Без ни өчен чыктык соң?—диде Әхмәтсафа, бәхәскә урын калдырмыйча.—Авылны дошманнардан, угрылардан сакларга дипме? Шикле нәрсә бар икән, белергә кирәк. Хәзер үк ишекләрен шакып уятабыз Фәтхулла абзыйны. Сорыйбыз, каян кайткан, кайда йөргән?..

Рәхим каршы төште:

—Фәтхулла абзый нинди дошман булсын инде... һем... Кеше бимазалап йөрмәек. Әйдәгез, кайтаек та ятаек. Болай да аяк атлар хәл калмады.

—Кайтасың килсә—кайт. Мин эшне өзми, ярты юлда калдырмаячакмын,—диде үҗәтләнеп Әхмәтсафа һәм урамга табан атлады. Ана Саттар белән Рәхим дә иярде.

Капканың эшермәсен шудырып, эчкә үттеләр. Икеләнү, шөбһәләр юкка чыкты. Әхмәтсафа башта саграк, бераздан катырак итеп ишек шакыды. Өй эченә җан инде, кемдер нык басып өйалдына чыкты, ишекнең келәсен өскә чөйгән унайга, егетләр һич көтмәгәнчә, хужа кеше дәшминитми, ишек катына кемнәр килүен дә белешеп тормастан, авыр ишекне шартлатып ачып та җибәрде. Егетләр, төн уртасында нәкъ Зариф абыйны очраткан чактагы кебек үк, үзләренә терәлә язып ак күлмәк-штаннан өрәктәй басып торган Фәтхуллага карап, телсез калдылар.

Фәтхулла исә, исе дә китмәгән кыяфәт белән:

—Ни бар «Каеш», нигә кайтып ятмыйсың инде?—дип сорады. Әйтерсең, егетләрнең кизү торуын да, артыннан сагалап төшүләрен дә яхшы белә иде ул.

Әхмәтсафага җан керде:

—Кизүдә без...—диде ул, шыр җибәрделәр дип уйламасын дигәндәй сүзләрен ачык һәм кычкырып әйтергә тырышып. Фәтхулладан шүрләргә исәпләре юк икәнлеген белдерергә теләп, шул кимәлдә сүзен дәвам итте.—Мәнә сезнең ихатага бер атлы кеше кереп китте. Шуңа аптырап, белешергә дип кердек.

—Атлы кеше?—дип, кайтарып сораган булды Фәтхулла. Мылтыклар тотып, бик мөһим эш башкарган кыяфәттә торучы кизүчеләргә бер тын карап торды да, кин күңелләләнеп, аларны өйгә үтәргә кыстый башлады.

—Килгәнсез икән, керик инде, сөйләшербез, белешербез дигәндәй...

Әхмәтсафа авыз ачып сүз әйткәнче, Рәхим җавап бирергә өлгерде:

—Кереп-нитеп тормыйбыз, Фәтхулла абый. Ат сезнең ихатага керде. Юлчының кем икәнен әйтегез дә, без авыл советына барып, теркәтеп куябыз. Озаклап сөйләшеп торырга, вакыт юк. Инде, озакламый көтү кузгала, ашыгабыз,—диде ул, сабырсызланган кыяфәт белән.

—Уң аякка итек кигәч, сул аякка чабата элеп йөрмиләр бит, энекәшләр, әйдә, килгәнсез икән, ишек төбендә туктап калмагыз. Бездә тәртип шундый,—дип, Фәтхулла Әхмәтсафаның җиң башыннан эләктерде дә, өйалды эченә суырып та алды. Аның артыннан, башын түбән иеп, елан авызына ирексез кереп баручы куян баласы шикелле, Саттар кереп китте. Рәхимнең башы эшләде, ул:

—Минем вакыт юк, кайтышлый кереп, хәбәр салырсыз,—дип кырт борылды да, капкага йөгерде.

—Һәй, чикерткә,—дип калды аның артыннан Фәтхулла,—йөрисез шунда, ком иләп...—Рәхимнең болай чыгып сызуына ачуы килде, ахры. Егетләрнең эчләренә җылы йөгерде.

Өйгә үттеләр. Шәмсия аяк өстендә иде инде. Аптыраулы карашын Фәтхуллага төбәп алды. Тегесе мәгънәле генә күз кысты:

—Карчык, егетләр килгән, бар әле, кар базыннан катык алып чык, төн буе кизү торып карыннары ачкандыр, минем дә тамак ялгап аласы килә. Син кергәнче без гәп куерта торырбыз.

Шәмсия «ә» димәде, «җә» димәде, башындагы яулыгын әйбәтләп бәйләгәндәй итте, чөйдән бишмәтен эләктереп, мич аралыгына кереп китте, кулына ташаяк күтәреп янә өстәл янына килеп тәрәзәгә күз салды, шуннан соң гына чыгып китте.

—Түргә, өстәл янына үтегез,—диде Фәтхулла аптырашып торган егетләргә.—Мылтыгыңны әнә почмакка куясыңмы соң?—Бусы Әхмәтсафага төбәп эндәшүе иде.

Әхмәтсафа, «юк» дигәндәй башын селкеп алды да, өстәл түренә кереп утырды. Мылтыгын бот арасына кыстырды. Саттар исә кыенсынып кына Әхмәтсафа янындагы букәнгә чүмәште. Фәтхулла егетләргә көлемсерәп карап торды да, аларның каршыларына килеп утырды һәм җитди итеп сүз башлады:

—Әй дөньялар..—диде ул сызланган сыман.—Бар иде заманалар, үтте-китте, юк инде...

Әхмәтсафа каш астыннан Фәтхуллага карап алды.

Фәтхулла озын пычак алып, йөзенә бармак тигезеп, үткенләгән тикшергәндәй итте, аннан җәһәт үрелеп, өстәл уртасында чигүле япма астыннан түгәрәк ипи әләктереп алды, бисмилласын әйтеп, күкрәгенә терәп ипи кисә башлады. Үзе сөйләнә бирде:

—Бик ерак сәфәрдән кайттым, егетләр, ерак сәфәрдән. Ну уңышлы булды юл. Инде күргәнсез икән, яшереп торыш юк, бер казакъ баеның нәселле чаптарын урлап кайттым... Төн чыкканчы йөз чакрым гына юл үтелгәндер. Авылга кайтып кергәндә генә аруы сизелде, мәхлукның.

—Ат урладың?—дип гаҗәпләнеп сорады Әхмәтсафа.

—Нигә гаҗәпләнәсең, энекәш? Әллә беренче ишетүеңме? Бу кәсеп Каргалы белән бергә яралган бездә. Сәүдәгәрләр нигез салган кала бит бу. Аны болай гына авыл-сала дип йөргән булалар. Тегенди-мондый калаларны орып бирә ул Каргалы. Каргалы да түгел әле ул, Кыр-кала дип аталган әүвәл. Аннан телгә кереп киткән Каргалы булып.

Авыллары Каргалы,
Бар да тимер арбалы.
Каргалыдан үткән чакта
Күлмәк-штан калмады,—

дип зар елап җырлый торган булган элекке мөсафирлар. Угрылар күп булган монда. Ат каракларына тел тигезмәгез, алар икенче чутта. Теләсә кем эше түгел ул ат урлау. Менә шул, энекәшләр, кайда патша—шунда алдашу, кайда сәүдә—шунда урлашу. Һәр халыкның үз кәсебе. Менә урысларны ал—аларда юлбасарлык, башкортларда—кыз урлау матур гамәл, йола санала, каф тавы халкы—кеше урлап, кәсеп итә. Аларда иң үтемле мал—кеше. Хайван урынына да күрмиләр кешене. Татарда исә—мондый кәсептән—ат урлау. Шунысы бар—ат хуҗасы да зыянланмаска тиеш, урланган ат та исән-сау килеш башка кулларга тапшырылырга тиеш. Бу канун. Ат урлаганда кан түгелү булдыксыз бәндәләр гамәле. Кергән табышның да зәкяте тиешенчә түләнергә тиеш. Ятим карт-карчыкка, ятим-җилпегә. Бу-яктан, Аллага шөкер, ата-баба йоласына хилафлык китергән юк, инде ничә ел ятимнәргә ярдәм итеп, тамакларын туйдырып, өс-башларын карап торабыз,—дип, Әхмәтсафага карап елмайды.—Шулаймы, Әхмәтсафа энекәш? Ачлык елны пар канатлы гаиләләр дә бала-чагаларын саклап кала алмадылар әнә, рәттән кырылып беттеләр. «Каеш»ныкылар, шөкер, барысы да исән, барысы да имин.

Әхмәтсафа, бу сүзләрне кызышып тыңлап утырды. Колакларына кадәр кызарды. Йокы дигән нәрсә әллә кая качты, маңгаена тир бәреп чыкты. Саттар да тавыш-тынсыз тыңлып утыруын белә. Фәтхулла исә дәвам итте:

—Йорт башларга исәплисез икән. Дөрес эшлисез, Тайфә карчыкның тавык алачыгына сыеша алмыйсыз инде сез. Бик матур үсеп киләсез. Сеңлегезне дә үз яныгызга алырсыз. Мин быелдан калмам, Хива ягына китәргә исәп. Анда туганнар бар. Иркен тормышта яшиләр. Монда нәрсә бар?.. Рәт бетеп бара яшәргә, жить итәргә. Әхмәтсафа, иртүк әзер булып торыгыз, Шәмсия җиңгәң белән кызыл балчык, салам кайтара башлыйбыз, саман кирпече суга башларга кирәк. Болай йөрсәгез, быел кышка тагын өйсез каласыз. Без киткәч, белмим, сезгә ярдәм кулы сузучы булмас шикелле. Сәвиттән әләккән эш юк, талау ягын шәп белә, ярдәм итү ягын кайгырта

башласа гына эше кәяләп китә. Шәмсия җингән, балалар үсеп җиткәнче, ташламыйм, дип, җан тартышканга гына, китүне кичектереп тордым.— Фәтхулла бераз тын торгач, өстәп куйды.—Иптәш егетләрен дә ярдәм итәрләр. Шулай бит, Саттар?

Саттар «риза» дигәнне белдереп баш какты. Ул арада Шәмсия килеп керде. Ап-ак катык тулы ташаягын өстәлгә утыртып, сиздермичә генә Фәтхуллага кагылып алды да, түр якка кереп китте.

—Әйдәгез, энекәшләр, тамак ялгап алыйк,—дип кашыкка үрелде хуҗа. —Аннан лапаска кереп, атны карарбыз. Нindirәк нәмәрсә микән ул?

Әхмәтсафаның зиһене тәмам таралган иде. Менә бит, шушы ат карагы Фәтхулланың ярдәме белән көн күреп яткан бит алар. Үзе дә туганнары да. Начармы бу, яхшымы? Ул бигрәк тә Саттардан унайсызлана. Ичмасам, аның алдында әйтмәскә иде. Комсомол диген... Ат карагы—кәсеп, имеш.

Саттарның исә дустының башында чабышкан уйларда бер эше дә юк, сыпырта гына катык белән ипине. Әллә тагын ел буе тамагына тәгам ризык капмаган.

—Әйдә, әйдә, җебеп утырма, «Каеш», кашыкка үрел,—диде Фәтхулла. «Җебегән» сүзе аның күнеленә нык тия икән, башына шаулап кан йөгерде. Бу сүзне ана Заһидә әйткән иде, әллә соң, ул чыннан да бер җебегән, бәрәңге боламыгы? Бу очракта нәрсә эшләргә? Ә бит дөрес әйтә, Фәтхулла, әгәр ярдәм итүче булмаса, алар быел тагын өйсез калалар, тагын кайсы кая таралып кыш чыгачаклар. Ул әкрен генә ипигә үрелде.

Ашап алганнан соң, ишек алдына чыктылар. Каргалыдагы күп кешеләрнекеннән аермалы буларак, Фәтхулланың ишек алды шактый киң, ихатасы төзек иде. Фәтхулла алдан, аның артыннан мылтык күтәргән Әхмәтсафа, иң арттан Саттар лапас эченә үттеләр. Фәтхулла лапас бүлмәләренең әле берсен, әле икенчесен ачып күрсәтте, гаҗәпкә каршы, атның эзе дә юк иде лапаста. Фәтхулла, аптыраган кыяфәттә, ике кулын җәеп җибәрде:

—Ай күрде, кояш алды, энекәшләр. Аттан җилләр искән икән инде. Бигайбә, күрсәтеп булмады,—дип, ат тире исе сеңеп калган лапаста үзләрен генә калдырып чыгып та китте. Чыгып барышлый, әйтеп кенә куйды:

—«Каеш» озак юанма, кояш күтәрелгәндә килеп җитәрбез. Бүгеннән эшкә башлыйбыз. Тегенди-мондый сүз кузгатып та йөрмәгез. Файдасыз сүздән дә кадерсез нәрсә юк дөньяда. Үзегез шаһит, монда ат-фәлән күрмәгән, ахры. Сез күргән җайдак кем булгандыр—миңа карангы. Анысын бер Алла белә. Минем бер катышым да юк ул эшкә...

—Ну иштек ишәк чумарын...—диде ачынып Әхмәтсафа,—Әйт, Саттар, син барысын да үз күзләрең белән күрдең, үз колакларың белән ишеттең. Нишлибез хәзер?..

Саттар, юкка хафаланма, дигәндәй, кулын гына селтәп җибәрде.

—Оясыннан егылган чәүкә баласы шикелле тыпырчынма, дустым. Беренчедән, мин бернәрсә дә ишетмәдем; икенчедән, Шәмсияттәйнең катыгы бик шәп булды әле, шуна күнелем булып тора; өченчедән, кайтышлый Рәхимгә кереп чыгам, бераз йокы туйдырып алабыз да, сезгә өмәгә киләбез. Фәтхулла абзый дөрес әйтә, быелдан да калырга ярамый, өй җиткерергә кирәк. Ә ат мәсьәләсен оныт син. Тотылмаган карак түгел. Күреп торасың, без катык көтеп утырганда, Шәмсия абыстай аткарган чаптарны. Кая, ничек, анысын үзләре генә белә...

Шулай итеп, өй мәшәкатьләре белән көзгә дә килеп керделәр. Кырпак кар яуган көннәрнең берсендә Фәтхулла абый белән Шәмсия Хива ягына кузгалдылар. Озаткан чагында Бибкәй Шәмсияне кочаклап үкси-үкси елады. Ана кушылып Шәмсия яшь түкте, Фәтхулланың да күзләре чыланды. Авыр аерылышу булды бу.

Әхмәтсафа исә кыш буе итек текте. Кече туганнарын мәктәпкә бирде, ничек тә кеше арасына кертү, белемле итү иде исәбе. Гомәрхан көн-төн эштә, тормыш ярыйсы гына җайланып китте сыман бу елда.

## XIII

Белемгә омтылуы көчле булгандыр инде Әхмәтсафаның, ел буе институтны, мөгаллимнәрне, сабакташ дусларын сагынып яшәде. Көннәр көзгә авыша башлагач, Гомәрхан белән кинәштеләр дә, Әхмәтсафа укуын дәвам иттерергә булды.

Институтка ул ашкынып килде. Бу зур бинаның һәр ташы аннан сорау ала кебек: «Һәй, егет, ел буе кая югалып тордың?.. Яңа тормыш төзибез дип кайларга гына барып, кемнәр алдында гына нотык сөйләп йөрмәдең. Ә үзең ни майтардың шушы бер ел эчендә? Монда чакта бик актив идең, институтта һәркемгә таныш, һәркемнең йомышы төшәрлек шәкерткә әйләнеп баруына да шаһит без. Синең өчен куанып туймый идек, менә сиңа мә—суга төшкән сыман, юкка чыктың. Синең болай күздән югалуыңа барыбыз да пошаманга төшкән идек, әле дә ярый, менә янә ишекләрне ачып, белем йортына килеп кердең. Рәхим ит, югалып торуыңа үпкә-сапкабыз бетте, нык холыклы бул, егет бул! Белем алу—инә белән кое казу, бирешмә, иҗтиһад ит!»

Өске катка күтәрелеп барганда каршысына таныш кызлар очрады. Алар инде житкән кызлар, соңгы курста укыйлар. Туктап, шаярта төшеп, хәл-әхвәлләрен сорашмакчы булды.

—Миннән башка исән-имин яшәдегезме, кызлар? Ни хәлләр бар? Бу дөньяда яшәүләр ничек?—диде ул, уенын-чынын кушып.

—Каршыда торма әле, бүкән,—дигән тупас сүзләр ишетте җавапка Әхмәтсафа. Аптырап, күзләрен зур ачып, кызларга карады да катып калды. Ни булган боларга? Шушы ике-өч баскыч үткән арада кызлар Әхмәтсафага төбәп тә, бер-берсенә дә нинди генә тупас, хәтта сүгенү сүзләре әйтеп бетермәделәр. Кая Нургали ага Надиев, Заһид Шәркый ни карый?!. Мондый тупас сүзләрне тире фабрикасының сасы бүлемтәләрендә эшләүче ирләрдән дә ишетергә туры килмәде аңа. Болар чыгырдан чыккан сыман кыланалар. Әхмәтсафа колаклары кызарганын тойды.

Тулай торак бүлмәсенә керде... Күп сабакташлары юк иде инде. Муса Казанга китеп барган, бу хакта, әлбәттә, Әхмәтсафа белә иде, бергә сөйләшкән, серләшкән чакларда үзе үк Мусаны Казанга, Тукай әйтмешли театрлы, мәгърифәтле Казанга китәргә аз димләмәде. Гайшәгә хатлар язып торуын да белә. Казан Мусаны зурлап каршы алган. Рабфакта белем эсти, газета-журналлар белән элемтә тота, язучылар, зыялылар белән аралаша, китап чыгару артыннан йөри икән. Кыскасы, Мусаның хәлләре начар түгел. Дусты өчен сөенде Әхмәтсафа. Күп студентлар, Башкортстанның пайтәхете Стәрлетамактан Уфага күчерелгәч, анда китеп барганнар. Сәгыйть Агишев та Уфага киткән. Бу самими дустын бик сагынган иде, күрешүләр насыйп булмаган икән.

Дусларның кайсы кая таралып бетүен белгәч, егет бераз пошаманга төште. Шулай да иң аптыратканы—кызларның сәер кыланышы иде. Авыз ачып сүз әйтеп өлгермисең, сиңа нинди генә әшәке сүзләр ишеттереп өлгерми алар. Алар өчен Әхмәтсафа ояла, үзләренең исләре дә китми, кисәтү ясап өлгермисең, начар сүзләр белән керендерәләр дә, мөһим бер эш башкарган кыяфәттә китеп баралар. «Болар белән төзерсең яңа дөньяны. Белем учагы саналган бинада, әдәп-әхлакның тоткасы—педагоглар әзерләүче мәркәз саналган җирдә сафлыкның, гүзәллекнең, инсафлыкның гәүдәләнеше саналырга тиешле татар кызлары шулай кылансын инде... Ул, форсат табып, бу хакта сыйныфташы Саимә белән сөйләшеп карамакчы иде, тегесе авызын гына ерды:

—Исең китмәсен ишәк б...Berебез дә алтын к... төшмәгән. Туфрактан яралганбыз, туфракка китәсе, китап сүзе генә сөйләп яшәп булмас инде. Әнә минем әби илле ел «Йосыф» китабын көйләп йөргән-ние бар? Нәмәсеннән башка бер нәмәсе дә калмаган карчыкның,—дип шаркылдап көлә-көлә Әхмәтсафаның касыгына нык кына төртеп,—һәйт, ...тиең бармы, егет?—дип шәрран ярды. Көтелмәгән бу хәлдән сәерсенеп читкә атылган

Әхмәтсафаны эзәрлекләвен дәвам итеп, кыз куллары белән егеткә әллә нинди хәрәкәтләр күрсәтеп, үзенен шушы гамәленнән зерә дә күнеле булып, шаркылдый бирде. Әхмәтсафа, аңа сүз кушуына үкенеп, сыйныф бүлмәсенә кереп шылу ягын карады. Яшереп торасы юк, яшь күңел һәркайда матурлык эзли, менә шушы сөрсегән сүзләрдән тәмам колагы тонып, җаны бәргәләнеп йөргән көннәрдә очратты ул матурлыкны. Очратты һәм... тәне эсселесуыклы кызышып алды. Бу мизгелне ул инде беркайчан да онытмаячак! Саимә белән сөйләшеп торганда, аны сөйләшү дип әйтергә яраса, турыларыннан басынкы адымнар белән чандыр гәүдәле чибәр бер кыз үтеп китте. Ул кызый Саимәнең сүзләрен ишеттеме, юкмы, анысы егеткә караңгы, әмма гәптәшенең авызын иләмсез ачып шаркылдап көлүенә оялып, керфекләрен аяк очына төбәп, тизрәк бу мәхшәрдән котылырга иде дигән кыяфәттә иреннәрен турсайта төшеп үтеп барышы егет игътибарыннан читтә калмады. Моны Саимә дә сизеп алды.

—Чибәрме?—диде хәйләкәр елмаеп.—Икенче сыйныфта укый. Атбасардан килгән. Бик харап инде, әле бер егеткә дә күз салганы юк. Юашлыгын аркасында Заһидә белән дә борчагын пешмәде. Егет булса ут булсын, ут булмаса юк булсын. Ирләр ул, егеткәем, нык куллы булырга тиеш, сугып ексын, тартып торгызсын. Вәт шундыйларга тартыла кызлар. Бу кызыкай ипле күренә, Заһидә кебек кысыр өмет юллап йөрүче түгел. Сиңа нәкъ шундый кызлар кирәк тә бит. Танышып кара, бәлки сине үз итәр чибәр туташ. Әй тәрбияле дә инде. Шундыйларны женем сөйми,—дип такылдап та алды.

Кызларның бер-берсен уздырып ямьсезләнеп йөрүенә гарык булды Әхмәтсафа. Гаҗәбе, мона башка бер егет тә борчылмый кебек, кызлардан тупас сүз ишетсәләр, алардан өч-дүрт мәртәбә арттырып җавап кайтаралар. Бу кадәр шакшы сөйләшүдән институтның затлы бинасы җирәнеп йөзен чытып тора, хәтта чарасызлыктан җиргә чүккән сыман иде.

Бер җай чыкканда, Зиннәттән бу хәлнең сәбәбен сорамый булдыра алмады.

—Моның белән Нургали абзый Надиев та, башка мөгаллимнәр дә көрәшеп карадылар. Әле дәрестә сүгенә башлаганнар иде, бәхетен, ул хикмәтләрне күрмәден. Мөгаллимнәр ничә мәртәбә дәрес өзделәр, ничә мәртәбә җыелыш җыйдылар, тыешлы гына булмады. Җыелышка губкомнан Галинны чакыртып китерергә өлгерәләр «сүгенү оешмасы» кызлары. Бушка тегермән тартырга Галинга куш инде. Мөгаллимнәрне куркытып, аларны яман сүгеп, искелек калдыклары дип хәкарәтләп-куркытып бетерә дә, губком исеменнән җыелышны оештыручыларга шелтә чәпи. Кулында власть булгач, нишләсә дә килешә, күпкә сузмый, җыелышны шунда ук ябып тарата һәм, зур эш кырган кыяфәттә, «сүгенү оешмасы» кызлары белән чыр-чу килеп кич үткәрә.

—Нинди «сүгенү оешмасы» ул тагын?

—Кызлар Галинның турыдан-туры житәкчелегендә шундый оешма төзеделәр. Искелеккә каршы көрәшнең иң үтемле чарасы, имеш. Һәрхәлдә, шулай аклыйлар гамәлләрен. Аңа каршы чыгып азапландык, билгеле. Гайшә, Пәрвәз, тагын берничә кыз, егетләр мона каршы протест митингысы да оештырып карадык. Юк, үз туксаннары туксан, каһәрләрнең. Ә барысы да шул Галиннан, губкомның шыр надан бәндәсеннән башланды. Ул үткән ел институтта «яңа совет йолаларын гамәлгә кертү» түгәрәге оештырды. Беренче көнне үк яшьләргә ябырылды: имеш, без дөрес сөйләшмибез, советча аралашмыйбыз, мәхәббәтне дөрес аңламыйбыз. Бер-берең белән кешечә, матур итеп гәпләшү, аңлашу мещанлык дип бәяләнде. «Болай мулла кызлары кебек әдәпле аралашу—советча яшәү үрнәге була алмый»,—дип кистереп әйтте. Гади һәм үтемле сөйләшергә өйрәник дип, яшьләрнең башларын әйләндерә торгач, тәки үзенекенә иреште: кызлар тупас һәм хәшәп сүзләр өйрәнеп алдылар—бу өлкәдә түгәрәк эшчәнлеге нәтиҗәле булды. Егетләр кызларны да уздыра башладылар. Хәтта әшәке сөйләшү буенча сыйныфлар арасында ярышлар да ачтылар. Шулай, дускай, башкаларга ияреп үзгәрсән—

сине акыллыга саныйлар, үзгәрмәскә маташсан—шыр тилегә чутлыйлар. Сине әле акыллы дип әйтеп булмый, үзгәрергә уйламыйсың—Зиннәт көлеп куйды.—Кызларның яннарыннан үтеп булмый, сүзләреннән генә түгел, үзләреннән тизәк исе килә башлады. Акыл житми, авылдан жыелган инсафлы кызлар, егетләр «яңа йола» дигән булып шундый түбәнлеккә төшсеннәр инде. Ата-аналары ишетсә, акылдан шашырлар, билләһи.

—Болай булмый, егетләр,—диде Әхмәтсафа тәвәккәл тавыш белән.—Чыннан да, берничек тә әлеге гыйбрәтне тыя алмадыгызмы?—дип кайтарып сорады.

—Дөресен әйтәм, без чарасыз идек. Галинны акылга утырта алмадык тәки. Губком исеменнән сөйли, кесәсендә—резолюция. Анда акка кара белән: «Яңа совет йолаларына каршы төшүчеләрне институттан куарга»,—дип язылган. Авызны ачсаң, хәзер томалап куя. Каршы килеп буламы губкомга?

—Тапкан, совет йоласы, имеш. Ул өйрәткән йола, гореф-гадәтләр белән барсак, ерак китәрбез инде.

Озакка сузмыйча, Әхмәтсафа Гайшә белән Саимәне ияртеп комсомолның губерна комитетына китте. Монда аны Оренбурда, Каргалыда яшьләр эшләрен оештыручы буларак яхшы беләләр иде, шуңа күрә ачыктан-ачык сөйләште. Егет губком житәкчеләренә институтта гына түгел, гомумән, яшьләр жыелган һәр жирдә Галинның зарарлы «йолалары» тамыр жәюен, әгәр вакытында чик куелмаса, яшьләрнең көтелмәгән күңелсез хәлләргә тарып бетәчәкләре хакында дәлилләр китереп, кайнарланып аңлатып бирде. Житәкчеләр эшнең тирәнгә киткәнлеген аңлап алдылар бугай, егет белән килештеләр, кичекмәстән мондый нәрсәләрне тыя башлау хакында карар кабул ителәчәгенә ышандырдылар.

Әхмәтсафа карар кабул ителгәнне көтмәде. Институтка кайту белән Нургали Надиев янына кереп, институтның гомуми жыелышын жыйнарга рөхсәт алды.

Жыелышта исә, мөгаллимнәр генә түгел, моңарчы башка фикердә булса да күпчелек тә Әхмәтсафаны яклады. Мондый сөмсезлек, тупаслыктан барысы да гарык булганнар. Моңа кадәр Галинга каршы төшүчеләр булса да, эшне ахыргача житкерүче булмаганга гына «яңа йола» шул дәрәжәдә институтта тамыр жәеп өлгергән икән.

Ахырда, жыелыш шундый карар кабул итте: 1. «Шушы көннән соң Галинны институт бинасына кертмәскә. 2. «Сүгенүчеләр оешмасы»на кергән студентлар барлык мөгаллимнәрдән, сабакташларыннан гафу үтенеп, тупас мөгамәләдән баш тартырга тиешләр. 3. Яңадан мондый фактлар кабатланса, андый студентларның алга табан институтта белем алуын махсус комиссия карарга тиеш.» Сүз генә булып калмасын өчен шундук комиссия дә төзеп куйдылар. Комиссия составына, Гайшә, Зиннәт һәм моңарчы Әхмәтсафа күзенә бер генә күренеп калган Рабига Сарымсакова, ягъни чибәр һәм тыйнак Атбасар кызы да керде. Комиссия рәисе итеп Әхмәтсафа сайланды. Шул көннән башлап егетнең күңел түрендә якты йолдыз кабынды Бу йолдызның сүнмәс-сүрелмәс исеме—Рабига атлы иде. Рабига да егетне бер күрүдә үз итте. Шул көннән башлап ике яшь йөрәк бер-берсен уйлап типте, бер-берсен сөеп яшәде.

## XIV

Рабига, Рабига... Әйе, Әхмәтсафаның күңелен биләп алган йолдыз ул. Шушы кыз белән танышкан ике еллап вакыт эчендә егет аңа шулкадәр ияләште, әгәр дә бер көн Рабиганы күрми торса, яшәүнең яме, ризыкның тәме китә, дөньясы асты-өскә килә, үзенә урын табалмый интегеп бетә.

Жәйге каникул чорында абыйсы Гомәрхан белән хәллерәк кешеләргә ялланып печән чабуда эшләде, ә уе—Рабигада, кыз кайтып киткән Атбасар якларында йөрде. Кояш та Атбасар ягыннан чыга төсле тоела иде, төн

житеп, истә-оста юкта күк түрендә пәйда булган чекрәеп янган йолдыз да Рабига яшәгән яктан һавага чөелгәндер, ул гына да түгел, аның җем-җем итеп янып торуы үзе үк Рабиганың якты карашы төсле тоела башлый. Каяндыр, Җаек аръягыннан тәгәрәп чыккан түм-түгәрәк ай да, кызның үзеннән нурлар җыйгандыр да, хәзер менә якты нурларын мул итеп Әхмәтсафа яшәгән Сакмар буйларына таратадыр. Егет үзенен нинди халәттә йөргәнен үзе дә аңлап бетерә алмый. Дөньясы үзгәрде, моңарчы яшәүнен ямен бөтенләй күрмәгән икән лә ул, кылган һәр эшендә, һәр гамәлендә Рабиганың да катнашы бар сыман. Егеткә тормыш гаме инде. Гамьсез кеше—ямьсез кеше. Мәхәббәт белән өретелгән гамь исә гүзәл гамь, егетне алга әйди, аны һаман-һаман биеклекләргә җилкендереп тора иде. Әхмәтсафа Рабига белән танышкан ике ел эчендә олыгаеп китте, һәр гамәлен, үзе янында булмаса да, Рабига күреп торадыр, сүзен ишетәдер, бәя бирәдер кебек. Ул сабырлана төште, кылган һәр эшен мәгънәле итәргә тырышты. Яшереп торасы юк, егетнең йөрәгендә мәхәббәт уты кабынды. Инде Әхмәтсафага Рабигадан башка тормыш юктыр шикелле тоела. Гаҗәбе шул—егет белән кызның бер-берсенә ярату, мәхәббәт сүзләрен әйткәннәре юк иде әле. Тик үзләре генә түгел, бөтен институт, хәтта бөтен кала белә кебек—алар бер-берсенә үлеп гашыйк, алар бер-берсеннән башка яши алмыйлар. Күпләрнең күз алдында туган, аңлашу-газаплардан азат, саф, якты мәхәббәт иде ул..

Бергәләп «әдәплелек кичәләре» үткәргәндә аралары тагын да якынайды. Ныклап танышулары да шул кичәләрдә булды бугай.. Рабига, һәрхәлдә, Әхмәтсафага шулай тоелды, мандолинада искиткеч оста уйный икән. Кылларны чиртүче медиаторны кысып тоткан озынча, аксыл бармакларына, җылылык бөркелеп торган (егеткә шулай тоела) кулларына карый да, Әхмәтсафа дөньясын оныта. Менә Рабига «Салкын чишмә» көен уйный. Егет үзен шунда ук урман аланында итеп хис итә. Алан читенә тезелешкән ямь-яшел гөләп куаклары, аллы-гөлле чәчәкләр, шул аланның түрендә чикләвек куаклары каплап алган биек яр астыннан челтер-челтер агып яткан чишмә. Бу илаһи күренешне мандолина кылларыннан түгелгән моң аерымачык күз алдына китереп бастыра: чишмә сулары көмештер, ул суының салкынлыгы, сафлыгы, ул суның ирекк৙ чыгып йөгергән уенчак җан иясе шикелле гөрли-гөрли шаярып-чабулап мул сулы инешкә табан ашыгулары, ул суын иренгә тигезгән унайга җанның чистарып китүләре, күңелнең очынулары, яшәүнен мәңгелегенә инану, аның кабатланмас мизгелләрдән җыелган төс-манзараларын, ямен тою—кыз уйнаганда менә шулар уйга килә. Ул арада моң егетне үзе белән хыял дөньясына алып китә. Менә Рабига чишмә суын учларына алып Әхмәтсафага эчертә, имеш. Тешләре камаша Әхмәтсафаның, бөркүдән кысылган тыны кинәя, дөньясы яктыра. Кыз аңа карап тыенкы елмаеп тора, ә күзләрендә сихри нурлар уйный. Әхмәтсафа үзендә тыелгысыз дәрт сизә, әллә нинди яхшы гамәлләр кыласы, илләрне, җирне үзенең матур эшләре белән сискәндерәсе килә. Рабиганы да гаҗәпләндереп, дөньяны яңгыратып кычкырасы иде: әй, кешеләр, җирем, күгем, мин әле бик матур эшләр, гүзәл гамәлләр кылачакмын! Чөнки мине һәрдаим дәртләндереп, көч биреп торучы гап-гади җир кызы, җанымны яулап алган шаһинәм—Рабигам бар. Их, сез аның гүзәллеген күрәсез микән, мин кичергән тойгыларны сизә аласыз микән, гомумән, дөньяда ул яшәгәнне беләсез микән?!. Юктыр, белеп бетермисездер, күрмисездер, мин янган сихри-рәхәт утларда янмыйсыздыр, киресенчә булса, җир әйләнүдән туктап, аңа мөкиббән калыр иде, кошлар сайраудан туктап Рабиганың уйнавын гына тыңлар иде, бер мәлгә чишмәләр агуыннан туктап торыр иде, барысы да кызның сихри моңнарына әсир калырлар иде дә табигатьнең шушы илаһи затына гына табынып яши башларлар иде. Яхшымы бу, әллә сәер, гайре табигый хәл булыр идеме, егет аны уйлап бетерә алмый, аның җилкәсенә кемдер кагылып, колагына пышылдый:

—Егет, дөньяңны оныттың бит. Рабиган уйнап бетерде, чиратта сәхнәгә кем чыга? Халык көтә, чыгып әйт, син бит кичәнең хуҗасы!

Гайшә икән. Татлы уйларыннан аерылып бетмәгән хәлдә Әхмәтсафа сәхнәгә, декламация сөйләргә чыгып китә...

Институтта укыган соңгы елы шундый сихри халәттә үтте аның.

... Ленин үлгәч, комсомолның губерна комитеты тәкъдиме буенча, ТИНО да укучы күп кенә яшьләр, комсомоллар инде, әлбәттә, «Ленин призывы» дигән хикмәтле исем астында коммунистлар партиясенә әгъзалыкка кандидат итеп кабул ителделәр. Әхмәтсафа Дәүләтъяров—унтугыз яшьлек егет бу адымының мөһимлеген, тормышында нинди урын тотачагын уйлап житкердеме, юкмы, анысына үзе дә ныклап торып җавап бирә алмас иде, әмма гомуми шаукым аны үз эченә бөтереп алып кереп китте, ул инде шушы ташкын көченә тиң инанулар ихтыярында иде. Егет үзен һич икеләнүсез яңа дөнья төзүчеләрнең иң алгы сафында баручы яшь көч дип уйлый, гаризасына да шулай дип язды: «Дөнья пролетариатының җинүе, илебезнең чәчәк атуы өчен гомеремне дә кызганмам!». Бирә, һичшиксез бирәчәк гомерен Әхмәтсафа. Әгәр дөнья пролетариаты, ил фәкать аның гомере бәрабәренә иң гүзәл тормыш—коммунизм кора ала икән, нигә бирмәскә гомерне?! Билгеле, ул яңа, бәхетле Киләчәкне бергә-бергә төзеп, анда сөенеп-шатланып бергәләп яшәсәң яхшырак булыр иде дә, гариза укыганда әнә шул «гомеремне дә бирәм» дигән сүзләргә аеруча нык игътибар итәләр шул. Күрәсен, комиссия әгъзаларына ике дә уйламыйча гомерләрен фирка хисабына тапшыручылар кадерлерәк. Күп, бик күп кадерледән кисәк кенә кадерсезгә әйләнгән гомерләр кирәк фиркага дөнья байгышларын рәхәткә чыгару өчен.

Гомәр абзый егетнең үз гомере хисабына фиркага керүен өнәмичә чәпчеп алды алуын.

—Шулай да фиркага керүеңнең асыл максатын ничек аңлатасың?—дип сорады ул Әхмәтсафадан, кискенрәк итеп.

Моңарчы йомшак кына сөйләшә торган картның шулай зәһәрләнеп китүенә сәерсенә төшеп, егет җавап кайтарды:

—Социализм төзү, халыкны рәхәт тормышка тиендерү...

—Аннан ни кылмак буласыз бу «рәхәткә тиенгән» халык белән?

—Коммунизм төзү...

—Анысы ни-нәмәрсә була инде?..

—Анысымы?.. Ни инде—барлык кешеләр дә тигез, мул тормышта яшиләр. Дөньяда хәерчеләр, байлар дигән аерымлану булмаячак. Болай кешене җиде тиресен салдырып эшләтү, көчләү булмаячак. Һәркемнең үз ихтыяры...

—Һи җүләр баш, җүләр баш! Һәркемнең үз ихтыяры белән эшләвенә калгач, нәмә булып чыга соң инде ул? Юк, татар холкына коммунизм дигән нәмә туры килми. Һич кенә дә туры килми. Эше барның, ашы бар, ди татар. Татар беркайчан да кеше күзенә карап яшәмәгән, кулы эшкә ятып тора аның. Синнән әлегә эш вә гомер таләп ителә. Коммунизм дигән нәмә әкият ул. Тиле Иван турындагы әкиятне Лилин дигән бәндә икенче төрле итеп кенә язып биргән. Шул әкияткә ышанып йөрүче сезнең кебекләрнең булачагын алдан күреп язган ул аны. Ни генә әйтмә, акыллы, хәйләкәр бәндә ул. Ялганның кеше ышанмастаена гына ышанганнарын белеп ут йөгертә...

Әхмәтсафа шундый бөек төшенчәләрне көлке дәрәҗәсенә төшереп аңлатырга маташкан Гомәр абзыйга үпкәләр дәрәҗәдә чыгып китте ул чакта.

Рабига, нигәдер, губком кыставына бирелмәде, «әле мин мондый зур эшкә өлгермәдем», дип, «Ленин призывы»ннан битараф рәвештә төшеп калды. Әмма Әхмәтсафаның партиягә керергә омтылышына каршы килмәде—«дөньясы шул инде» дию белән чикләнде.

Партиягә керү уен-муен түгел, иң элек, бер ел дәвамында кандидатлык стажы үтү шарт иде, шушы чор эчендә үзеннең партия эшенә тугрылыклы булуыңны расларга да тиешсең әле. Моның өчен, һичшиксез, партия

поручениеләрен үтәргә кирәк. Әхмәтсафаны тире-күн эшкәртү фабрикасы эшчеләренә партия, хөкүмәт карарларын аңлату бурычын йөкләделәр. Килгән саен эшчеләр клубында концерт оештырырга кирәк, монда да алар гел Рабига белән бергә булдылар. Клуб каршында «Татар бүлеге» оештырып, төрле бәйрәмнәрдә эшчеләр арасыннан сәләтлеләрен сайлап алып, концертлар, спектакльләр куя башладылар. Ару-талуны белмичә үтәде фирка кушканны. Булачак яшь әгъзасы эшеннән партия канәгать булырлык иде, югыйсә, әмма алда тагын бер сынау кичәргә туры киләчәк икән әле. Монысын башына да китереп карамады Әхмәтсафа—1925 елның апрель аенда, педагогия институтын тәмамлыйм, кулга диплом алып, зур тормыш юлына аяк басам дип йөргәндә, партиянең губерна комитеты юлламасы буенча яшь коммунистларны Урта Азиягә совет хакимияте урнаштыру эшенә ярдәм итү өчен җибәрергә дигән фәрман житкерделәр. Исемлектә Әхмәтсафа да бар иде.

Губком секретаре, калын күзлекле хәрби киемле кеше, Әхмәтсафа Дәүләтъяров, Саттар Ишбулдинга дивар янына тезеп куелган шактый йончылган урындыкларга утырырга ишарә ясап алгандай кыланды да, егетләрнең утыру-утырмауларына да игътибар итмәстән, түшәмгә карап бераз торды. Сизелерлек тын алганнан соң, инде аларга кадәр дистәләрчә мәртәбә сөйләп, ятлап бетергән сүзләрен тезәргә керешге:

—Иптәшләр, мөһим эш—партиянең җаваплы заданиесен үтәү йөзеннән чакырдым сезне. Белгәнегезчә, совет хөкүмәте Советлар иленең барлык почмакларында да ныклап аякка басты, бөтен илдә яна тормыш төзелә. Халык партиягә ышана, эшчеләр сафы ныгый, партия сафларына меннәрчә яшь көрәшчеләр килә. Ленинның васыятьләре соңгы ижегенә кадәр үтәләчәк! Менә хәзер беркемнең шиге юк. Бүгенге көндә хәлиткеч фронт—Урта Азиядә, иптәшләр. Аңлыйсыздыр, анда совет хакимиятен урнаштыру жиңел булмады. Кызганычка каршы, милли республикаларда совет хөкүмәте ныклап аякка баса алмый. Анда дошманнар әле корал ташламадылар. Алар мәкерле. Алар әле һаман үзләрен көчле итеп сизәләр. Иң нык аяк чалган нәрсә—халыкның наданлыгы, дошманнарга сукырларча иярүе. Муллаларның, контрреволюцион көчләрнең, байларның һәм буржуаз милләтчеләрнең йогынтысы гаять көчле. Белемле кадрлар житешми, бөтен Урта Азия буйлап басмачылар, бандитлар йөри, алар жирле халыкны кылыч йөзендә, наган мушкасында тоталар. Авыр хәл, бик авыр, иптәшләр. Ә Урта Азиясез совет хакимияте юк, дөнья пролетариатының жиңүе юк. Менә шундый шартларда үзәк комитет сезгә ышана, сезгә таяна. Урта Азиядә яшәүче миллионнарча үксезләр коммунистларга, ягъни сезгә (губком секретаре нигәдер «безгә» димәде) мөрәжәгать итәләр—«Килегез,—диләр алар,—төзеп бирегез яна тормыш, аң-белем бирегез, өйрәтегез,—диләр.—Аннан без өлгереп житкәч, кире туган якларыгызга кайтырсыз, завод-фабрикаларда эшегезне дәвам итәрсез, укуларыгызны тәмамларсыз, безнең иксез-чиксез рәхмәтләребезне тоеп яшәрсез!»—диләр. Менә ни дип җавап бирә алабыз. Фәкать утвердительно, иптәшләр! Фәкать эш белән генә җавап бирә алабыз. Каршы килә алмыйбыз һәм менә бүген хакыбыз да, хокукыбыз да юк. Без бит партия солдатлары!

Бу сөйләшү апрель аенда булып, күп тә үтмәде Әхмәтсафага Хива өлкә комитеты карамагына жибәрелүе хакында белешмә тоттырдылар. Егет юлга әзерләнә башлады.

Белешмәне күргәч, Рабига бер сүз дә дәшмәде, бары керфек очларына яшь тамчылары эленде. Кызны мондый хәлдә беренче мәртәбә күргән Әхмәтсафаның жаны кузгалып куйды. Хәзер инде ул Рабиганың үзе өчен никадәр газиз, никадәр якын икәнен бөтен барлыгы белән тоеп алды, моңарчы гашыйк булып, иләсләнеп йөрүләре күнелнең очыну-жилкенүе, якты хисләр кабынган мәлләр генә булган икән. Чын хисләр эчтәрәк, һәм Рабиганың, һәм егетнең күңел түренә яшеренгән, бикләнгән булган. Менә хәзер, аерылышу якынлашкан көннәрдә хисләр дулап өскә бәреп чыктылар, аларны яшереп торасы юк, Әхмәтсафаның нинди сәфәргә чыгасы билгеле,

авыр, утә куркыныч аның сәфәре. Аулакта очрашкач, Рабига сүзсез генә егетнең муенына сарылды һәм мышкылдап елап җибәрде. Егет кызны юатырга тырышып, иңнәреннән алып, сак кына күкрәгенә кысты, Рабига исә тыелырга уйламый да, елавы елау...

—Елама, Рабига,—диде Әхмәтсафа, күнелендәге авыр ташны кузгатырга теләгәндәй еш-еш тын алып—Исән-имин кайтырга, тагын күрешергә язсын.— Ул беренче мәртәбә кызның яшь чылаткан кайнар битләреннән үбеп алды.— Көтәрсең бит?

—Көтәрмен...—диде Рабига егеткә сыенып

Китәр вакытлар зур тизлек белән якынлаша тора. Егетнең күнелендәге баштагы иләслек, ашкыну сүрелә төште. Ул Рабиганы Ак абзыкай—Гомәр абзый белән таныштырырга да өлгерде. Аннан бер генә көнгә булса да Каргалыга кайтып килде. Монда барысы да исән-имин, йорт гөр килеп тора—Гомәрхан өйләнергә, туй итәргә җыена икән. Энесенең шундый вакытта ерак сәфәргә китеп баруына ул һич кенә дә риза булмый, тәртәгә тибеп азапланды:

—Нәмә калган сиңа анда?—диде ул кайнарланып.—Үзләре теләгән тормышны үзләре төзесен. Менә мин ничә ел окопларда бет симертеп яттым. Халыкны бәхетле итәм, имеш. Берәрсе килеп рәхмәт әйткәне бармы? Шунда алган авырулардан берүзем саргаям менә... Йөрмә дүнгәләк кебек, җил унаена себерелеп. Кайт та эшли башла. Укуың җитәрлек, иншалла, югалмассың.

Әхмәтсафа авырлык белән генә инде мәсьәләнең губерна җитәкчелеге дәрәҗәсендә хәл ителүен, кире уйларга юлның калмаганлыгын аңлата алды.

Абыйсы үз эше белән каядыр чыгып китте. Әхмәтхан белән Бибкәй сабактан кайтып җитмәгән иде, ул эче пошып, ян бакчадан әйләнеп керергә булды. Бакчаны тәртипкә китерергә өлгермәвенә үкенеп, куптәнге янгыннан кара көеп, тырпаеп утырган алмагач кәүсәләренә—кара кисәүләргә карап торды. Күнеле тулды, күзләренә яшь тыгылды. Шул чагында болытлы язгы көн ачылып, тирә-юнь яктырып китткән кебек булды. Әхмәтсафа бакча түрендә бер алмагач кәүсәсенең тернәкләнеп килүен күреп алды. Яшел яфраклы ботак өскә үрмәләп маташа. Ботакта күз явын алырлык ап-ак чәчкә балкып утыра. Егет шуңа сабыйларча сөенеп, чәчкәдән бик озак күзен ала алмый торды.

Икенче көнне таң белән юлга кузгалды ул. Бүген үк кич белән поездга өлгерергә кирәк. Аны Рабига озатып калырга тиеш... Болдырдан төшүгә игътибар итте—мул итеп иртәнге кырау төшкән, аяк өсте шакранлап каткан. Егетнең йөрәге тибүеннән туктап калды сыман, аяклары ирексездән бакча ягына атлады. Менә кичә генә сокланып торган алма агачы... Алсу төстәге чәчәкләрне боз элпәсе каплап алган. Алар шул элпә аша сүрән иртәгә боек кына багалар кебек. Юк, ачыргаланып кычкыралар, салкыннан, боздан аралап алуны үтенеп ялваралар, инриләр кебек. Әхмәтсафа йөгереп барып кайнар тыны белән боз элпәсен эретеп төшерде. Чәчәк таҗыннан җанны чеметтереп салкын тамчылар тәгәрәште. Әткәсе әйтергә яраткан сүзләр исенә килде: «Табигать ялгышмый ул, кешеләр ялгыша. Саташып таң атмый, бәндәләр саташа...» Ул әкрен генә чыгу ягына борылды. Табигать тә ялгыша, ахрысы. Менә бит—шундый авырлыклар, газаплар аша терелергә, җимеш бирергә азаплана алмагач, ә... иртәсен кырау суккан чәчәген. Табигать үзе тудырганны үзе һәлак итә, кешеләр дә аннан калышмый, һаман көрәш, һаман дау уйларында. Күпме уйланса да яшәешнең асылын аңлый алмый әле Әхмәтсафа...

*Беренче китап тәмам*

# ЙӨРӘК КАРУРМАННАРЫН ҖЫРЛАУЧЫ



*Шагыйрә Флера Гыйззәтуллина үзенең быел, «Рухият» исемле яңа нәшрият юбилеена дип бастырып чыгарган затлы, калын бертомлыгын «Йөрәгемдә шаулый карурман» дип атаган. Бу—шагыйрәнә исем һәм шул ук вакытта авторның иҗат рухын, юнәлешен шактый дөрес чагылдыра. Әйе, шагыйрәгә нәкъ менә шундый халыкчан, җырга, дастаннарга якын тойгылы, сурәтле күтәренкелек, киңлек хас. Бу—шәхси язмышын йә ил-халык тарихын җырлауда булсынмы,—һәрвакыт зур гомумиләштерүләргә омтылуда, хәтта гади генә күренешләрне, вакыйгаларны да олы язмыш иясе, күпне күргән, кичергән хатын-кыз күзеннән, күңеленнән үткәреп, шигырьгә, мәгънәле сүзләргә әверелдерүдә чагыла. Нәкъ хатын-кызларга гына хас самими, мөлаем, яшьлегендә шагыйрәгә хәерхаһ булган, аңа багышлап шигырь дә язган Сажидә Сөләйманова әйтмешли, «энә күзеннән үткәрергә» сәләтле шигъри күрү, үзенчәлекле рух, тоем бу!*

*Азнакай районының Әсәй авылында туып-үскән Флера Гыйззәтуллинага сугыш чорын һәм аннан соңгы четерекле, авыр «карурман»нарны күп күрергә туры килә. Ятимлек, яшьтән эш, хезмәт, хәтта михнәт юлы... Уналты яшеннән Кемерово якларында шахтада эшли ул, аннары Омск—Томск тимер юлын төзүдә катнаша.*

*Кузбасстан соң—Донбасс, «Калиновка» шахтасы, откатчица хезмәте. Шунда ук—җир астында эшләүче, «күзләре мөлдер-мөлдер» яшь тулы атлар... кешеләр. 1952 елда—туган якларга кайта ул, гаиләсе белән. «Бал апаның үги килене» Лениногорск районы Карабаш поселогында яши, шундагы ательеда тегүче булып эшли. 1970—1979 елларда тагын сәфәр—алар Самара өлкәсе Тольятти шәһәрендә яшиләр. Һәм инде 1980 елдан—Казанда, мәркәзебездә, шигырьле, моңлы борынгы бәйләмен махсус безгә дип язды. Без бу санда укучыларыбызга әнә шул шигырьләрне тәкъдим итеп, авторыбызны мөбарәк бәйрәме белән котлап, аңа яңадан-яңа уңышлар, исәнлек, иҗат бәхете теләп калабыз.*

# Флера Гыйззәтуллина

## Хаклык ихтыяры ача йөзне

Иманымны, вөҗданымны барлыйм,
Дәрья-дәрья шигырь язамын да...
Милләт гаме—вөҗдан газабымда!—
Ничек йөклим гомер азагымда?

Минем вөҗдан—милләт вөҗданыннан...
Хис дәрьясы миндә татарымның—
Үзем ни авырлык кичерсәм дә,
Җырга салып аны кайтарырмын.

Милли чынбарлыкны кимсетергә
Вөҗдансызга әмма куймам ирек...
Хисси камиллеккә ирештерә
Хак Тәгалә безгә Иман биреп.

Кичерешнең, эшнең иң авыры
Гомер азагында баса безне...
Әмма, авыр килеп, йөгәнгәндә
Хаклык ихтыяры ача йөзне.

Баскан саен гүя:
«Хаклык!!!»—диеп,
Җире иңри Казан каласының.
Гомер иткән саен җиргә күчә
Җан әрнеше адәм баласының.

Әмма һич туктамый адәми зат
Җирдә сугыш уты кабызудан...
Бер Казанны гына ничә кабат
Ут эченә салган явыз Иван!

Әйе, Казанымны чаларткан шул—
Тарих зиһеннәрен тараткан ут!..
Шуңа, ахры, җирдә вәхшилекләр
Кабатланып тора,
кабатланып...

Берөзлексез эчтән яна торгач,
Милләт, Ватан хәле аңлашыла.
Ялган тарихчылар күпме! Ләкин...
Тарих чынбарлыгы!—алга чыга.

## Инде мәхәббәт яры буш...

Хисләрне күчереп чиккәндә
Мәхәббәт мендәренә:
«Яратам!.. Сөям!»—дип, безгә
Әйтмәде кемнәр генә?!

Кем белән, нинди көймәдә
Иделләр кичелмәде?—
Тик, башта уйлар саегып,
Кәефне төшермәде.

Берәүләр котып кочканда,
Сөюен күмеп зарга...
Без чиштек сөю серләрен,
Учаклар ягып ярга.

Ләкин булмады бу серне
Тормышта саклап калып:
Давыллы нәфрәткә ашты
Сөюгә җайланган ут...

Ятышкан, яраклашкандай
Йокысыз төннәреңә—
Төс җуйды мәхәббәте дә,
Чигүле мендәре дә.

... Инде мәхәббәт яры буш!—
Җил искән көймәбездән.
Шашкан хис, адашкан сөю
Бот чабып көлә бездән.

*

Гомер уза...
Ә мин алга барам;
Яргаланам язмыш ярыдай.
Сөембикә алкасына охшап
Баш очыма калка ярым ай....

Гомер уза.
Узган гомер өчен
Айлы кичләр—моңлы тамаша!
Айның яктыртуы—борынгыча,
Моңаюы гына яңача.

...Гомер уза.
Еллар аръягына
Аударыла гомер олавы...
Сөембикә елавына охшаш
Җилләрнең дә быел елавы.

## Томаннарга булмый чик салып...

...Ил язмышы шау томанда һаман,
Илнең ирек юлы караңгы.
Илебезгә ятлар хуҗа булды,
Нужа арты нужа ялгалды.

Нужа безне куды, без нужаны,
Томаналык буды бугаздан.
Ят коенә яшәп,
нәсел-затны
Корытмыйча калдык бик аздан.

Ирексездән алган бума чире
Буыннарда менә тартыша.
Яшәвенең соң чигенә җитеп
Бишектәге сабый кан коса.

Шушы сабый хөкемендә, әйе,
Безнең ил дә, милли ирек тә...—
Бәхеткәең кулдан бер ычкынса,
Табалмыйсың—җаның биреп тә.

Җиде үлеп җиде терелсәң дә
Кире кайтмас җуйган асылың.—
Азатлыкка бәйләп өйрәнмәсәң
Туккән хезмәтеңнең ахырын.

...Ил язмышы шау томанда һаман!
Торган саен томан куера.
Ил башында торган ир башына
Һай, авырга килә бу йола.

Яшь буынга, һай, авырга килә
Кан яңарту—әчтән чистарып,—
Кан юлларын табып, ябып була,
Томаннарга булмый чик сабып...

## Күзгә карап сөю гөле шиңә

...Кайный дөнья—
Тезләр, түшләр ләмдә!
Йөзләр кара канга манчылган.
Нишләдек соң?..—
Без бит беребез дә
Кара түгел идек асылда.

Күзләребез безнең зәңгәр иде,
Тәңгәл иде күлләр төсенә...
...Кискен искән җилгә баш идекме?
Исердекме гөлләр исенә?

Алпан-тилпән килеп гомер үтә,
Уйлар китә тормыш төбенә.
Күзгә карап сөю гөле шиңә,
Гомер күле ярдан чигенә.

Безгә мәңгелек бер гыйбрәт булып,
Яр читендә җәйрәп ләм кала.
Асыл җаннар тормыш ләмен сөзеп,
Чисталыкта йөзеп тәм таба...

Ә шакшысы куа дан артыннан,
Мал артыннан куа—
такырдан—
Һәм шыңшыган була асылларның
Асылганын күреп ахырдан.

Асыл затлар бетсә, дөнья йөзен
Ләм басар дип мин дә кайгырам.
Асылына тигән бу кайгыдан
Кайсы шагыйрь әле айныган?!

Кайсы халык ләмгә манчылмаган
Хаклык яулап тормыш төбеннән?
...Кайный дөнья!..
Каный-каный кайный,
Түземлеге тулып түгелгән.

## Булмагач төпле ирегең

Үстек без кызыл заманда
Зурлап чор кызыллыгын.
Киңәйтеп, иңләп ил чиген
Үрчеде кызыл борын!

Кызылдан текте күлмәген,
Чорыбыз иренмәде...—
Кызарды хәрам кан эчеп
Телләре, иреннәре...

Инде шул кызыллык безнең
Ирекне ялмап ала.
Бәгырьдә кайный катыш кан,
Карында—ала бала!

Булмагач төпле ирегең
Төсеңдә... колачыңда...
Йөклисең илдә тумышның
Аласын, коласын да.

«Үзгәрер балам—үскәчтен,
Түз сана, йөрәк!..»—дисең.
Үскәч... бу гарип токымга
Ләкин син кирәкмисең.

Бу токым өчен син инде
Күптән чалынган корбан!..—
Безгә тик шушы хис кала
Ала-колалы чордан.

## Үкенеч тулы хисләрем

Кан-яшьле гасыр иңенә
Баш салыр тарих сыман
Мин бүген гомер үремә
Таудан таш ярып чыгам.

Җырларга салам тормышның
Ак ягын, кара ягын.
...Мин сине сөюем белән
Карадан араладым.

Син менә шушы сөюне
Үлемгә иттең дучар...
...Үкенеч тулы хисләрем
Янып көлләргә очар.

Куарсың—тота алмассың
Гомернең искән җилен.
Йөрәк түремдә тетрәнә
Тауларны ишкән үлем.

...Мин бүген гомер үремә
Таудан таш ярып чыгам...
Мине аңлаган бер Ходам
Ташларга бирсен чыдам!

**Әдип Маликов**

# ТЫЛСЫМЛЫ ХАТЛАР

## Мәскәү безне очраштырды

Без аның белән Мәскәүдәге Казан вокзалында июнь ахырында очраштык. Көтелмәгәнчә, уйламаганча булды бу.

Метро авызыннан килеп чыгуга, тизрәк кырыйдагы бетон платформа ягына күз ташладым. Телеграммада номеры күрсәтелгән Свердлов поезды әле килеп җитмәгән иде. Сирәк-мирәк көтеп алучылар күренә. Якыная төшкәч, шулар арасыннан ялгызы боегып басып торган сары чәчле кызга игътибар иттем. Өстендә гади генә кофта, тез башыннан аз гына түбәнрәк зәңгәр юбка. Аягында тәбәнәк үкчәле ак босоножкалар. Юл сумкасын аяк астына куйган. Ул, башын түбән иеп, бер ноктага текәлгән. Иптәшләреннән аерылып калганмы икән, адашып йөриме? Кызганыч булып китте мина бу кыз бала.

Гәүдәсенә, өс-башына караганда, күп булса, унынчы сыйныфны тәмамлагандыр. Шулай дип фараз кылдым.

Янына килеп җитүгә, йөзендә бик якын таныш сызыклар күреп алдым. Ул бит...

—Сажидә!

Кыз кинәт сискәнеп куйды. Башын күтәреп, күзләрен зур ачып, миңа карады:

—Әдип...

Кечкенә кулын сузып, күңелсез генә күреште ул. Елап җибәрмәскә тырышкандай, аскы иренен тешләде. Беренче сүзләрен үк мине шелтәләүдән башлады:

—Тагын биш минут көттерсәгез, кире кайтып китәргә риза идем...

—Соң... Поезд әле килеп җитмәде түгелме соң?

—Ничек җитмәсен, ди, дүрт сәгать көтәм инде сезне. Әллә ниләр уйлап бетердем. Институтыгызга телеграмма да җибәрдем.

Еларга вакыт бирмәс өчен, җирдән сумкасын алып, бала сыман җитәкләдем дә тиз генә үзен зур расписание янына алып килдем.

—Менә, карагыз!..

Ул тынып калды. Бераздан хатасын аңлады, ахры.

---

Ахыры. Башы 8 санда.

—Ярый әле, җүләрләнеп, кайтып китмәгәнмен,—диде, сөенечен белдереп.

Ул Магнитогорскидан башлап, ике шәһәрдә—Чиләбе һәм Свердловта поездлардан поездларга күченә икән. Соңгысында, бераз көтәсе урында, алданрак килгән Мәскәү поездына кергән дә утырган. Авызын ерып торган ир кондуктор билетын тикшереп мәшәкатьләнмәгән. Ә плацкарт вагон эчендә бер яшь егет шунда ук урын тәкъдим иткән. Сажидә поезд номеры белән кызыксынып та тормаган. Алып кына барсын башкалага!

Шулай да күз яшьләрен тыеп кала алмады ул:

—Ашыкканмын икән,—диде дә яшь аралаш көлеп җибәрде.

Мин ана бертуган сенелемә караган кебек карадым.

Аксәет (Башкортстан) мәктәбендә, ул беренче, ә мин алтынчы сыйныфта укыганда, без бергәләп физкультура түгәрәгенә йөри идек. Мин аны ике кулыннан тотып, баш өстенә күтәрә идем. Яки «ат булам» да, билемә атландырам. Бала чагындагы «абый, күтәр!», «абый, ат бул!»—дигән сүзләре исемә төште. Үзалдыма елмаеп куйдым. Ул моны шунда ук сизенде. Хатында язганны кабатлап:

—Буем бәләкәй, әйеме, Әдип?—дип сорады. Күзләремә шундый ышаныч белән карап, сабыйларча беркатлы сорау биргән кызны кысып кочаклыйсым килде.

—Син кечкенә түгел,—дидем «син»гә күчеп,—тугыз бала үстергән минем әнидән калкурак та, көчлерәк тә.

—Ә каян беләсез көчле икәнемне?

—Хатларың буенча...

Без, күптәнге дуслар сыман, ничектер, шул көнне үк бер-беребезгә якынаеп, үз булып киттек. Хатлар, күрәсең, юкка гына йөрмәгәннәр, үз вазифаларын әйбәт башкарганнар, безне якынайтып бетергәннәр.

—Планнарыгыз ничек, Әдип? Имтиханга кайчан керәсе?—дип сорады ул, берьюлы ачыклык кертергә теләп.

Мин ана барысын да сөйләп бирдем. Үзәктән квартир тапканымны әйттем. Зур театрга—«Иван Сусанин»га көч-хәл белән бер билет юнәтүемне дә онытмадым. Ул сөенмәде шикелле.

—Тагын берне табып булмасмы соң?—дип сорады.—Мин бише белән түләргә әзер. Отпуск акчасы әтәч булып кычкыра...

—Анысын карарбыз...

Юл унаеннан, бер киосктан Мәскәү планын, метро сызымнарын сатып алып, Сажидәнең үз кулына тоттырдым.

...Квартир хуҗасы—ялгыз маржа карчыгы безне якты йөз белән каршы алды. Электр плитәсенә чәйнеген куйды, чынаякларын шылтыраткалап, урыннан-урынга күчерде.

—Менә бу киң караваг сезгә булыр,—кайгыртучан тон белән шулай диде,—теләгәнчә яшәгез!

Сажидәнең йөзенә алсулык йөгерде:

—Аның тулай торагы ба-а-р,—тамагына төер утырган сыман шулай дип куйды.—Мин өстемне алыштырыр идем, ә?

Коридорга чыгып озак та тормадым, «булды» дип, шунда ук чакырып та кертте ул мине. Эре чәчәкле крепдишин күлмәге үзенә бик килешеп тора иде. Билдәмәсен бугач, биле тагы да нечкәреп калган. Йөзе әйтеп бетергесез шат.

Без хуҗа карчыктан чәй белән мәшәкатьләнмәүне үтенеп, рәхмәт әйтеп, Мәскәүне карарга чыгып киттек. Әлбәттә, беренче чиратта, Горький урамы буйлап, Кызыл Мәйданга таба юл алдык.

Мәскәүдә халык чуар, күп төрле. Күбесе читтән килгәннәр. Мәскәүлеләр үзләре бик гади киенеп йөри. Ирләр галстук та такмый, изүләре һәрвакыт ачык була. Хатын-кызларның, әлбәттә, төрлесе бар. Сажидә, һәрхәлдә, башкалар арасында ким-хур булырлык түгел иде. Әле, киресенчә, нәфислеге белән аерылып тора. Мәскәү хатын-кызлары бит алар таза гәүдәле бәндәләр. Андыйлар янынан тизрәк читкә китәсе

килә. Янәшә бассаң, үзеңне кимсетелгән итеп сизә башлыйсың. Матурлык һәм буй-сын ягыннан безнең татар хатын-кызларына җитмидер, мөгаен...

Революция музее почмагыннан Ленин мавзолее каршына килеп чыккач, Сажидә, кулын күкрәгенә китереп, бер мәлгә тын алалмыйча торды кебек. Аннары:

—И, бар икән, Ходаем, боларны да күрәселәр!—дип, бу күренешләргә гаҗәпләнеп, сокланып карап куйды.

Шул вакыт, бөтен дөньяга ишетелерлек итеп, Кремль курантлары суга башлады. Бәйрәм парадларын кабул иткәндә, маршаллар чыгып йөри торган Спасс капкасы ягыннан ике часовой һәм алдан барган разводящийның килгәннәре күренде. Шома чуер ташларга чек-чек баса-баса, тантаналы адым белән Мавзолейга таба юнәлде алар. Смена алышыну тәмамлануга, күгәрчен кәтүләрен ера-ера, безнең янга бер фотограф килеп җитте. Рөхсәт сорап тормады ул, әйтте генә:

—Әйдәгез, матур парлар, истәлеккә төшереп алыйм үзегезне!

Без карышырга җыенмадык та. Ленин Мавзолее каршында парлап рәсемгә төштек.

—Иртәгә мин шунда булырмын,—диде фотограф, безгә хәерле юл теләп. Акча-мазар сорап та тормады.

Сажидәнең дулкынлануы миңа да күчте. «Ни дигән сүз бу, чал Кремль шаһит булып торганда, парлап фотога төшү?» Мин мондый сорауга әле өзеп кенә җавап бирә алмас идем. Ул да шулайдыр. Әле барасы, атлыйсы юллар төсмере яңа ачылып кына килә иде.

Без ашауны да оныткансыз икән. Горький урамындагы кафега кереп, аяк өсте генә капкаладык та, зур театр мәйданына таба юнәлдек.

—Фонтаннар, чәчәкләр дөньясы икән монда!—дип, гаҗәпкә калды Сажидә.—Нинди генә төсләр юк!

Кичке кояш нурларыннан һәр нәрсә сихри төс алган. Фонтаннар исә ярсулана төшкән сыман. Ак коляскаларда балалар тирбәлә. Салмак кына атлап йөргән горур аналарга карап сокланып куясың. Сажидәнең дә игътибары шуларга күчте. Яшь аналарга көнләшеп карый сыман ул.

Берәрсендә артык билет юк микән дип, Зур театр вестибюленә кадәр менеп җиттек. «Билет» сүзен ишетүгә, киресенчә, үзебезгә ябырылдылар.

—Сатыйк булмаса,—диде Сажидә, һич көтмәгәндә,—булыр әле караган чаклар, боерса...

Бер-беребездән аерыласы килмәгәнен үзебез дә сизеп торабыз. «Иван Сусанин»дагы ише генәмени күнелдәге билгесез ашкынулар. Бөек рус шагыйре әйткән канатлы сүзләр искә төште: «Она почти моя...» Шуна ышанасы килә.

Без билетны бер ялгызак хәрбигә үз бәясенә биреп, әлеге биек, шаулы фонтаннар янындагы утыргычка барып утырдык. Монда, ничектер, сөйләшмичә, күңелендәгеен тыңлап кына утырасы килә. Кулга-кул тотышып кына. Анысына кыюлыгым җитми әле. Инбашыңа кунган асыл кошны өркетеп җибәрерсең сыман. Фонтаннар җырын тыңлап утыра торгач:

—Кузгалыйк, Әдип,—диде Сажидә, дерелдәп куеп,—сезгә бит әле Переделкинога кайтып җитәсе бар. Минем дә күрәсем килә сез яшәгән урынны. Бер алып барырсызмы?

—Әлбәттә. Ә бүген сездә кунарга туры килер, ахры...

—Анда мин хуҗа түгел,—диде Сажидә,—анысы сезнең ихтыярда.

Без «Балалар дөньясы» кибете янынннан узып, тар гына урам буйлап, Пушкин мәйданы ягына күтәрелдек. Юл унаеннан бер гастрономга сугылдык, төрле ашамлыклар җыйдык. Акчасын тиз генә Сажидә түләп өлгерде. Миңа унайсыз да булып китте. «Студентның хәлен аңлар әле» дип, тынычландырдым аннары үземне. Элекке укучым алдында студент булып йөрү шулай да оятрак шикелле тоела иде. Дөнья куласа, бер әйләнә—бер баса, дигәннәре дөрес инде ул.

Биек-биек йортларда инде күптән ут алынган. Башкала урамындагы

фонарьлар, ярышкандай, берсеннән-берсе яктырак яна. Урамда халык азая төшкән. Без алдагы планнарыбызны ачыклап барабыз. Сажидәнең, әлбәттә, Мәскәүне карыйсы килә. Беренче чиратта—Третьяков галереясе. Аннары тарих һәм революция музейлары. Исәбе миннән башка гына йөрү. «Мине үз иркемә куярсың»,—диде. Икебез дә ирек яратабыз, иреклe кошлар, янәсе. Имтиханнарымны унышлы итеп бирдерәсе килә аның. «Эгоист»лыгы әлегә сизелми. Түзәдер инде, нишләсен. Мин алдагы переспективамның ачык булмавын аңлатырга тырыштым.

—Шагыйрь Гали Хужи мине «Яшь сталинчы» газитенә эшкә чакыра,—дидем,—ләкин...

—Ә нигә «ләкин?»

—Бу хәлемдә көчем житмәс, дип куркам. Бәла генә булырмын коллективка. «Үзәк нерв системасы...» «Контузия...» дигән сүзләр бар бит комиссия биргән справкада.

Сажидә моңа бик жиңел карый сыман. Хатларында язганча, һаман юата:

—И, Әдип, уза ул,—ди,—ышанчйк әле шуңа. Борчылмагыз, зинһар, тыныч булыгыз.

Аның шушы сүзләре күңелемә тынычлык биргәндәй була. Их, шундый таяныр кешең булсачы!

—Профессорлар да нәкъ шулай диләр, юк-бар турында уйламаска, борчылмаска кушалар. Әллә соң син әүлиямe, Сажидә?!

Ул кинәт ачылып, көлеп жибәрде:

—Әүлия булмасам, теге чакта сез кайтасы поездга төшмәс идем. Кирәк бит шулай туры килүе?—диде Сажидә, ихлас күңелдән.—Шунда әтиегезне күрмәсәм, әле Аскарга хатыгыз да килмәс иде, әйеме?

«Әйе» дип тә, «түгел» дип тә жавап бирүе кыен. Ә шулай да язмыш алдамас дип ышанасы килә.

—Ташбулат ничегрәк калды соң?—дип сорап куйдым, үзем дә ни әйткәнемне абайламыйча.

—Без аны юри уйлап чыгардык, Зина белән,—диде Сажидә, башын аска иеп,—хатыгыз килмәде бит бер ай буе.

—Шуннан соң килдеме?

—Аллы-артлы ике хатыгыз килде.

—И, бу кызларның хәйләкәрлеге,—дигән булдым, үзен култыклап алып,—нечкә урынга кагылырга осталар соң. Ә балалар турында язганнарыгыз? Алары да уйлап чыгарылганмы?

—Балаларны уйлап чыгарасы юк,—диде Сажидә,—алар бит үзләре фантазиядән, әкияттән тора. Яратам мин шул «шайтаннар»ны.

Без кайтканда маржа апа әле йокларга жыенмаган да иде. Өчәү утырып, бик тәмләп чәй эчә башладык. Өстәлгә Сажидә хужа булып алды. Кыстый-кыстый, безне сыйларга тотынды. Һәр хәрәкәте үзенә килешеп тора тагын. Баштагы оялчанлыгы да, тартынуы да юкка чыкты. Гүя без бүген генә очрашмаган. Барысы да гади, бернинди ясалмалылык сизелми. Шул табигыйлек калганнарыбызга да күчте.

Мине тар койкага салдылар. Үзләре пәрдә эченә, киненә кереп чумдылар. Сажидә эчке якка, стена буена ятты.

* * *

Икенче көнне, аның теләгeн исәпкә алып, Сажидәне үз иркенә жибәрдем. Бөтен игътибарым—ике профессорга—Реформацкий белән Дынникка (моңсы өлкән яшьтәге ханым), ягъни «Языкознание» һәм «сәнгать тарихы»на юнәлгән. Шуларны жиңеп чыга алсам, II курсны тәмамлаган дип исәплә. Академик ял аласым гына кала. Ә алдагысын, картлар әйтмешли, Алла белә. Сажидәдән ниндидер киңәш соравы да уңайсыз. Без бит әле сүз куешмаган, вәгъдәләшмәгән. Икебезнең ике якка китеп баруы да ихтимал. Әмма күңелләребезнең бер-берсенә нык

тартылган булуын икебез дә сизеп торабыз. Тик моны ачыктан-ачык әйтмибез генә. Ничегрәк чишәргә соң күнелләге шул серле төеннәрне? Беребез алма, беребез хөрмә, дигәндәй, икебез ике дөнья кешеләре. Тормыш дингезендә чайкалып кына калмаска, их, бергә йөзеп китәсе иде!

* * *

Профессор Дынник имтиханнарны өендә кабул итә икән. Институт стенасындагы белдерүләр тактасына анын адресын язып элгәннәр. Коридорда мина канцелярия хезмәткәре Лида ханым очрады, сәламәтлегем турында сорашты. Институтта нибары 150 ләп кенә студент булгач, алар барысын да белеп торалар, күрешкәндә, үз итеп исемнәребез белән генә дәшәләр.

—Барырга ашыкма, Эдип,—диде Лида ханым,—анда яулары белән киттеләр.

Бераз узгач, ул артына борылып, тагы бер кинәш бирде мина:

—Верандасында бозау кадәр эте булыр, син курыкма, студентларга тими ул.

Бу сүзләрне ишеткәч, кинәт көлеп жибәрдем:

—Ә зачетканы күрсәтергәме эткә?

Ул да көлә-көлә китеп барды.

Күбебез Дынникнын исемен-отчествосын да белми идек. Лекцияләр вакытында без ана «профессор жәнаплары» дип кенә дәшәбез. Ул шуна бик канәгать.

Адресы буенча, тәвәккәлләп, өенә киттем. Мәскәү елгасы буендагы борынгы йортларнын берсендә яши икән. Ишегалдына узганда, ни булмас дип, зачеткамны кулыма тоттым. Бер кырыйдарак, елкылдап торган тюленьгә охшаган эт сузылып ята. Зур башын алгы аякларына салган. Колаклары әрекмән яфрагы сыман, сәлперәеп төшкән. Бу мимылдап торган симез жанвар мине күрүгә соры күзләрен шар итеп ачты да, фоторәсемгә төшергәндәге сыман, аннары кысып куйды. Исәнләшүе булды микән? Танышу шунын белән тәмамланды. Кыю гына звонокка үрелдем. Ишек ачылуга, өстенә озын яшел халат кигән, муенына эре-эре сары гәрәбә төймә таккан, күркәм кыяфәтле профессор жәнаплары күренде.

—Ә-ә, студент Маликов та килде,—диде ул, французчага тартым йомшак анкау авазы белән,—әйдәгез, рәхим итегез!

Килми торучылар арасыннан мин генә калганмын, күрәсен, шуннан хәтерләгәндер инде фамилиямне дип уйладым.

Китаплар белән тулган зур бүлмә аша, анардан да иркенрәк якты залга килеп кердем. Безнен курстан өч студент утыра иде анда: берсе—сокланып, күз төшереп йөрсәм дә, үзенә сүз кушарга кыя алмаган поляк кызы Тереза, чем кара күзле болгар кызы Лилиана һәм чандыр гәүдәле румын егете. Залда борынгы төс, борынгы ис дигәндәй, барысы да музейны хәтерләтә. Алтын жепләр белән чигелгән биек артлы урындыклар, хан заманындагы кин диван, борынгы шкаф башында—сәмруг кош рәсеме төшерелгән зур мәрмәр ваза... Ә стеналарны бөек рәссамнарнын портретлары, картиналары бизәгән. Болар барысы атаклы галим, профессор Дынниктан—хужа хатыннын иреннән калган булырга тиеш. Шулайрак дип ишеткән идем.

Имтихан дигәне үзара ирекле әнгәмә тәртибендә бара икән. Чит ил студентлары русча анлатып бирә алмаган фикерләрен французча житкерәләр. Профессор да шунда ук французча сөйләшеп китә. Мина монда битарафлык күрсәтергә һич ярамый. Бирешмәскә кирәк, дип уйладым. Аз гына паузаны файдаланып, бөек якташыбыз Иван Иванович Шишкин турында сүз кузгаттым. Бәхеткә каршы, стенада анын «Арыш кыры» һәм «Нарат урманы иртәсе» дигән мәшһүр, һәркем сокланып

карый торган картиналары эленеп тора иде. Рәссамның шушы картиналары турында сөйләп киттем. Хәтта язылу тарихларын һәм бөек рәссамның Алабуга шәһәрендәге музеен искә төшердем. Бер башлагач, Казан, Татарстан турында бераз мәгълүмат бирдем.

—Кызыклы бу, кызык бу,—диде профессор елмаеп.—О, Казан тарихи шәхесләргә бик бай шәһәр бит ул!

Румын егете шунда:

—Ә татарлар Себердә яшиме?—дип сорап куйды.

—Татарлар Румыниядә дә бар,—дигәч, ул мина гаҗәпләнеп карап торды.

...Профессор җәнаплары, беребезне дә аермыйча, барыбызга да «яхшы» билгеләре куеп чыкты. Ә «урта»ны, гомумән, берәүгә дә куймый ул. Болай да ярлы студентны стипендиясез—сукыр бер тиенсез калдырасы килми, күрәсең.

Сажидәгә житкерәсе бер сөенечем артты. Шуна куанып, ул төшкән квартир тарафларына юл тоттым.

Ләкин звонокка җавап бирүче булмады. Шулай итеп, бу көнне без очраша алмадык. Ишек ярыгына язу кисәге кыстырдым да, Переделкинога кайтып киттем.

* * *

Сажидә Мәскәүне үз иткән, йөрисен йөргән, югалып калмаган. Йөзе шат иде. Шундый әсәрләнгән. Тәэсирләре сөйләп бетергесез. Ике көн эчендә ул, Кремль янындагы экскурсия бюросы автобусына утырып, бөтен Мәскәүне әйләнеп чыккан. Күп кенә музейларны, әллә нинди борынгы храмнарны карарга да өлгергән. Алып җыйган китапларын, брошюраларын таратып ташлады. Барысы да тарихи темага. Әткәсенә чигүле күлмәк, әнкәсенә мамыклы бик матур джемпер, туганнарына тагын төрле бүләкләр сатып алган.

—Акча тормый миндә, Әдип,—диде ул, акланган сыман,—и, боларны тутырырга чемоданым да юк бит әле...

—Әнә, минеке буш,—дидем, аны-моны уйламыйча гына. Чөнки кышкы киемнәремне, төрле вак-төякләрне посылкаларга төреп җибәргән идем инде.

—Ә сез бит кайтканда Казанда төшеп калам, дидегез?!

—Һмм...

—«Һмм»... шул менә,—диде Сажидә, мине ирештергән сыман. Аннары сүзне икенчегә борып җибәрде:

—Әй, имтиханыгыз турында сорамый да торам. Йә, ничек соң?

—Сәнгатьтән «яхшы» алдым.

Ничек-ничек булганын, хәтта бозау кадәрле этк<br>ә зачеткамны күрсәтеп керүем турында да сөйләп бирдем. Сажидә шатланып көлеп җибәрде:

—Рәхмәт, булдыргансың, Әдип! Укучым булсагыз—үбәр идем...

Урынсыз сүз ычкындырдым, дигәндәй, йөзенә жинелчә алсулык йөгерде аның. Хәтта каушап калгандай итте.

Хатында язганча, Аскар урта мәктәбендә, имтиханын уңышлы биргән бер баланы коридорда үбеп алуы күз алдыма килде. Без хужа апа өендә икәүдән-икәү генә идек. Их, мин җебегән, үбәсе, үптерәсе булган бит шунда, дип, бу турыда әле күп еллар узгач та уйлап йөрдем.

—Дайте мне, дайте свободу!—дип көйләгәндәй әйтеп куйды Сажидә, мине ирештергән сыман. Нигәдер очына бу кыз дип уйладым. «Ирек» турында сүзләр булган иде бит безнең хатларда. Аның шундый булуы миңа ошый иде.

—Переделкинога кайчан барабыз?—дип сорадым үзеннән.

—Профессор Реформацкий белән арагызны өзгәч,—диде ул, бәхәскә урын калдырмыйча,—мин сезгә комачауламаска тиеш. Шуна ант итеп

килдем. Әле Третьяков галереясендә булмавын да искә төшерде. Әйтәм очына кызыкай, бер сюрпризы бар икән бит:

—Беләсезме, Әдип, мин бит «Иван Сусанин»га ике билет таптым,— диде ул, билетларын миңа сузып.—Зур театрның администраторы янына кердем. Шушы операны күрер өчен дип, Башкортстан даласыннан килүемне, тарих укытучысы икәнемне әйткәч, өстәл тартмасыннан чыгарды да бирде.

* * *

«Языкознание»дән имтихан бирәсе көнне институт коридоры шомлы иде. Шиккә калып сөйләшүләр...

—Болай булгач, бүген кәефе шәптән түгел профессорның,— диештеләр курсташларым.—Тискәре ягы белән торгандыр... Коридорда аның, кызып-кызып, кем беләндер бик каты әйтешкәнен ишетеп калганнар икән. Төрле чагы була иде Реформацкийның. Ярты еллыкка имтихан биргәндә икенче курсның күбесен, зачеткаларына билге куймыйча, аудиториядән куып чыгарды. Җавабында ык-мык итә башласа, кулын гына селти студентка. Аннары атна буе артыннан йөртә. Аны эзләп, хәтта Мәскәү университетына барган чаклары да булды, стипендиясез каласы килми бит.

«Прокурор»ның килгәнен көтеп, һәммәсе аудитория ишек төбенә җыелган. Мин бер читтә, стена буендарак торам. Әнә, бәләкәйрәк кенә гәүдәле, кулына зур портфель тоткан—үзе дә килә. Йөзе кызарынган, маңгай тамырлары бүртенгән. Димәк, тузынуы хак. Әллә соң башы авырта микән?

Ул мине күрде дә, кинәт туктап калды:

—Авырыйсыз дип ишеткән идем... Әйдәгез!—диде, буш кулын алга сузып, артыннан иярергә кушып. Аудиториягә башка берәүне дә чакырмады. Мин пошаманга төштем. Белемем чамалы, байтак кына лекцияләрен калдырдым бит. Группалап кергәндә, ичмасам, сорау билетын алгач, баш кашып, уйланып утырырга вакыт була. Әле китапка да күз төшереп аласың. Хәзер миңа кара-каршы, күзгә-күз терәп сөйләшергә генә кала.

Профессор, өстәл янына килеп утыргач, озаклап күзлеген сөртте. Портфеленнән ниндидер кәгазьләр, брошюралар тартып чыгарды. Кулына ручкасын алды. Тик шуннан соң гына миңа сорау бирде:

—Казанга кайчан кайтасыз, иптәш Маликов?

«Менә сездән котылгач та...»—дип, аз гына ычкындырмадым.

—Бу соңгысы инде,—дип мыгырдандым, башымны иеп.

Алдында яткан ак кәгазьгә ул нидер язарга тотынды. Аннары шуны брошюралар белән бергә төреп, миңа сузды:

—Менә, рәхим итеп, профессор Латыйф Җәләйгә тапшырыгыз әле амәнәтемне!

Мин, әлбәттә, унай җил искәнен тоеп, сөенә-сөенә алдым төргәкне. Шунда ук зачеткамны сорап алды ул:

—Аванс белән «яхшы» куям сезгә, тизрәк терелегез,—диде, кулымны кысып,—татарларны яхшы беләм мин, алар бурычлы булып калмыйлар... Хәерле юл телим, Казанга сәлам тапшырыгыз! Әйтегез, керсеннәр.

Менә шулай саубуллаштым мин сонгы имтихан белән. Бер елгамы, ике елга булырмы әдәбият институтыннан аерылуым, әллә бөтенләйгәме— анысы минем өчен караңгы. Һәрхәлдә, әдәбият дөньясына сукмагым өзелмәсенә ышана идем.

* * *

Переделкино Сажидәгә бик ошады. Электричкадан төшүгә, без бормалы шоссе белән, зират үренә күтәрелә башладык. Сулда әрәмә эченнән саф сулы йөгерек елга ага. Унда, куе агачлыклар арасында,

каберлек корылмалары уртасында бәләкәйрәк кенә ак чиркәү күренә.

—Эшли торган чиркәүме?—дип сорады Сажидә, алтын гөмбәзләргә кунган чәүкәләргә игътибарын юнәлтеп.

—Ул чаң кага башласа, нарат урманнары үрә тора,—дидем.

Сажидә дәшмичә, бераз уйга калып барды:

—Мәскәүне карап йөри торгач, югалып калдым әле,—диде аннары, басынкы тавыш белән,—үземнең наданлыгымнан гарьләндем. Йә, миннән нинди тарихчы булсын инде?!

—Нигә алай дисез?

—Китаплардан белү бер, ә тарихны үз күзләрең белән капшап карау бөтенләй башка. Һай, русларның нинди бай тарихлары бар!

—Безнеке дә бик бай, ләкин аны ком баскан.

—Беләсезме нәрсә, Әдип, аспирантурада уку теләге уянды миндә, тарих буенча. Казан, Ленинград архивларында казынасым килә.

Үземнең институттан китү алдында торуымны искә алып, эчемә шом йөгерде: «Бу хыялый кыз белән борчагым пешәр микән?»

Кичә минем соңгы имтиханымнан соң, икебез дә сөенә-сөенә «Иван Сусанин»ны барып карадык. Әкиятләрдәге патша сарайлары сыман бизәлгән мәһабәт бина эченә аяк баскач, Сажидә бер дә югалып калмады. Гардеробта торучы ак чәчле карчыктан шунда ук бинокль сорап алды, театр альбомнары белән тулган киоск янына сугылырга да өлгерде. Үзе белән мине дә әйди. Сылу гәүдәсен бизәп торган чәчәкле күлмәге, Мәскәүгә килгәч алып кигән биек үкчәле туфлие бик килешеп тора үзенә. «Кычыткан чыпчыгы» димәссең бер дә.

Ә операны тын да алмыйча тыңладык. Икебезгә бер бинокль—кулдан-кулга күчеп йөрде. Шул кичәге тәэсирләре әле бүген дә сүрелмәгән икән:

—«Иван Сусанин»ны карау бәхетенә дә ирештем,—дип куйды Сажидә, тирән канәгатьләнү белән,—нинди гаҗәеп картиналар! Ә артистлар уены, ә музыкасы! Ну, прямо, күккә ашасы килә.

—Халыкчанлык шул буладыр инде,—дип куәтләргә тырыштым мин аны,—ә сюжеты нинди гади. Бер гади авыл крестьяны, юл күрсәтмәкче булып, поляк баскынчыларын сазлыкка илтеп кертә бит, туган җирен коткару өчен, шунда үзе һәлак була, җәзалап үтерелә. Герой язмышы ил язмышы белән үрелеп бара!

—Безнең тарихыбызда да аз түгел андый мисаллар,—дип куйды Сажидә,—ник яңгырамый берсе дә?!

Бу авыр сорауга икебез дә ачык кына җавап бирә алмас идек, мөгаен.

Переделкинодагы һәр урам язучылар исемен йөртә: Лермонтовтан, Гогольдән башлап, Горький, Серафимович, Тренев, Погодин, Вишневскийларга кадәр. Язучылар шәһәрчегенә 1934 елда нигез салына. Ягъни, язучыларның беренче Бөтенсоюз съезды булган елны. Дачалар төзү өчен хөкүмәт иң әйбәт җирләрне, наратлыкларны бүлеп бирә. Бар һәм булачак классиклар, кулларына балта, пычкы тотып, үзләре дә эшли шунда. Мин үзем белгәннәрне Сажидәгә сөйләп барам. Ул һәр таныш фамилияне ишеткән саен, «Их!» дигән сыман аваз чыгарып, кулын күкрәгенә китерә.

—Әйдәгез, карап йөрик әле...

Вакыт төштән соң иде. Кояш кыздырыпмы-кыздыра. Җилнең әсәре дә юк. Бөдрә каеннар, зифа буйлы яшел наратлар рәхәткә талып, йокымсырап утыралар шикелле. Анын каравы, без яшәгән Тренев дачасы алдында тыныч түгел. Волейбол мәйданы шау-гөр килеп тора. Уенчылар, спорт трусигыннан гына калып, дөньяларын онытып, туп сугалар. Һәммәсе бакыр сыман булып, кояшта кызынырга өлгергән.

—Каян килгән бу шау-шулы халык?—дип сорады Сажидә, бераз гаҗәпләнеп,—әллә берәр ярышмы?

—Булачак классиклар инде. Безнең студентлар...—дим мин көлеп,—имтиханга «әзерләнәләр».

Ә анда, Фадеев дачасыннан арырак, урман буендагы аланда икенче бер төркем кычкырыша-шаулаша туп тибә, футбол уйный.

—Мина таныш дөнья,—диде дә, елмаеп куйды Сажидә,—их, студент чакларымны сагынам хәзер. Җәйге имтиханнар житсә, мин дә Агыйдел буеннан кайтмый идем. Агыйделне инләп-буйлап, йөзәсен үрдәккәем, диләрме әле. Ә сез йөзәргә яратасызмы, Әдип?

—Татар бугазында гына йөзгәнем бар,—дидем көлемсерәп,—анда да хәрби өйрәнүләр вакытында гына. Тозлы су батырмый. Тик акулалар күп анда.

—Юк, кирәкми андый урында,—диде Сажидә, кинәт жинемнән тотып. Үзенең ялгыш хәрәкәтеннән йөзе алсуланып куйды.

Төне буе төрле классикларны укып, гыйбрәтләр, образлар, античный дөнья әкиятләре белән саташып, башлары тубалдай булган студентлар, балаларча азартка кергәннәр, тән язалар, тузаннарын коялар. Берсе, зур каен күләгәсендә шакмаклы одеалын җәеп ятканы, кинәт сикереп торды да, чирәмдә тәкмәрлек ата башлады, нинди дер ят тавыш белән «улап» жибәрде. Сажидә сагаеп калды:

—Нишли у-у-ул?

—Безнең курс студенты Абдижәмил Нурпеисов бу. «Кан һәм тир» дигән романының беренче китабын тәмамлаган. Шул шатлыгы исенә төшкәндер, мөгаен.

Кинчә йөзле, зур гына авызлы, чем-кара чәчле казакъ егетенә таба ымсынып куйгандай итте Сажидә, соклануын белдерде.

—Бик бәхетле кеше!

Студент халкы кайнар була. Бигрәк тә иҗат эше белән «авырган»нар. Алар макташырга да юмартлар, кайнарланып, бәхәскә керергә дә, үз принципларын яклар өчен якалашырга да әзерләр. Бу, мөгаен, үткәннәрдән киләдер. Сөйлиләр бит әле, без укып йөргән Герцен йортында, ягъни хәзерге әдәбият институтының подвалында элек «Илһам» кафесе булган, Блоклар, Есениннар, Маяковскийлар заманында, кайнар бәхәсләрдән соң, урындыклар оча торган булган, имеш.

Каршыбызда Рәми Гарипов пәйда булганын сизми дә калдык. Һаман елмаюын белә. Йөрәгемдә ут янса да елмаям мин, дигәне бар аның. Сонгы вакытта безнең дача тирәсендә бик күренмәде ул. Әллә берәр үпкә саклый микән, дип тә уйлаган идем. Юк, анысын сиздерми. Ләкин каушаганлыгы йөзенә чыккан.

—Исәнмеһегез!—диде дә, унайсызланып, башын түбән иде егет. Сажидә шунда ук нидер сизенеп, «танып» алды үзен:

—Рәми дип беләм,—диде шатланып,—менә нинди икән һин!

Егетнең йөзе кып-кызыл булды.

—Кызарма, кызарма!—диде Сажидә, аны тынычландырып,—шигырьләрең бик ошады мина, рәхмәт!

—Үзегезгә рәхмәт инде...

Мин, берни аңламыйча, аптырап калдым. Кай арада танышып өлгергәннәр әле? Яшереп тормады Рәми, оялып кына анлатып бирде:

—Мәхәббәт шигырьләрен ебәргәйнем Сажидә апайга... Һезгә әйтмәй генә... Гафу итегез инде, Әдип агай!

Менә нидә икән хикмәт. Монда мин үзем «гаепле» инде. Сажиданең хатлары эзсез калмаган, димәк. «Апай бик тә шигъри күнелле икән»,— дигән иде лә Рәми.

Шунда ук ул безгә үзенен тагын бер серен ачты:

—Шигырьләремне мин, подстрочник яһап, үзебездең поэзия семинары етәксеһенә биргәйнем башта,—диде.

—Ә кем сон житәкчегез?—дип сорады Сажидә.

—Шагыйрь Михаил Светлов.

—О, менә ничек! Ә ул ни диде сон?

—Һүззә-һүз тәржемәлә лирик хис, мон югала тине. Берәр башкорт шагыйрәһенә укытып карарга киңәш бирде.

—Мин шагыйрә түгел бит, балакаем...

—Булмаһа ни,—дип көлеп җибәрде Рәми, тагы кызарына төшеп,—бер булырһыгыз әле.

Без ул көнне Сажидә белән кичкә кадәр диярлек Переделкиноның тын почмакларында, саф һавалы, хуш исле наратлыклар арасында йөрдек. Без бер-беребезгә чит-ят түгел идек. Ни әйтсән дә, якташлар, хәтта авылдашлар бит әле. Нindидер якынлык, туганлык хисләре өстенлек ала башлаган. Мин ана үземнен укучыма, сенелемә караган кебегрәк карый идем.

Телем бер чишелсә, күбрәк сөйләшеп ташлый торган гадәтем бар. Ул да, әткәсе сыман, бик ачык күнелле. Моны инде анын хатларыннан ук белә идем.

—Мин бар булганымны язып бетердем бугай инде,—диде Сажидә, уйларымны сизгәндәй,—сөйләгез әле институт тормышы турында?!

Мин ана сөйләдем. Александр Твардовский кичәсеннән алган тәэсирләрем, Илья Эренбург, Александр Фадеев, Константин Симонов белән очрашуларыбыз турында сөйләдем. Симонов фамилиясен ишетүгә, Сажидә анын «Жди меня, и я вернусь» дигән халыкка кин таралган шигырен хәтеренә төшерә башлады:

..................
Жди меня, и я вернусь,
Всем смертям назло.
Кто не ждал меня, тот пусть
Скажет:—повезло.—
..................
Ожиданием своим
Ты спасла меня.

Бу шигырьне без сугыш башланган дәһшәтле елда, солдатлар белән җыйнаулашып, үзәк гәзиттән укыган идек. Шуннан бирле һәрвакыт күнелдә йөри. «Вставай, страна огромная...» дигән җыр шикелле, тетрәндерерлек көче бар анын. Инде менә ун ел узгач, институт кичәсендә Симоновнын үз авызыннан ишеттек шуны. Үз яшенә караганда бер ун яшькә олы күренде ул безгә. Авторнын «р» авазын бераз йотып, сакау итеп әйтүе дә, шигырен, артык көйләмичә, тонык һәм талгын тавыш белән укуы да—барысы да яратып кабул ителде. Бик каты кул чапкан идек...

—Симоновнын үзеннән ким укымыйсын, Сажидә,—дидем, шул үткәннәрне искә төшереп,—бу бер дә комплемент түгел.

—Мин бит институт конкурсында ул шигырьне укып, беренче урынны алдым!

Анын шулай мактау сүзен, бер дә кыланмыйча, гади генә кабул итүе, мина калса, бик табигый чыкты.

Бәйрәм демонстрациясе вакытында, Мавзолей канатында торган бөек юлбашчынын ничек кинәт «югалуы» һәм төтене генә чыгып торуы турында сөйли башлагач:

—Ничек, ничек?!—дип, Сажидә бөтенләй җанланып китте. Бу турыда мин хатыма язмаган идем. Хәзер барысын да түкми-чәчми, сөйләп бирдем.

—Ләкин Сталиннын үзен күргәч, бөтенесе бик гадигә әйләнеп калды,—дидем,—кинода күргән артист сыманрак тоелды...

—Әллә «двойнигы» булды микән? Юк, алай булмас, сугыш вакыты түгел бит хәзер.

Чын юлбашчыны күргән булуымны бик тели иде шикелле Сажидә.

Без тулай торакка кайтып кергәндә, ашханә буфеты ябылган иде инде. Мин яшәгән бүлмә ишеге каршына килеп баскач, Сажидә кыюсызланып, икеләнеп калды. Ләкин озакка түгел. Мәскәүдәге квартирына инде кайтып булмасын белә иде ул. Без ишектән кергәндә, бүлмәдә берәү дә юк иде. Өстәлдә—ике тәлинкә тары боткасы, колбаса кисәкләре, ипи, ике стакан сөт...

Дусларым, мендәрләрен алып, күрше бүлмәгә чыгып тайганнар, агач стена аша аларның сөйләшкән, көлешкән тавышлары гына ишетелеп кала.

Студент табынына Мәскәү кучтәнәчләре өстәлде. Бүлмәдәшем Жора нидер оныткан булып, тиз генә безнең янга кереп чыкты. Кыстасак та утырмады. Бераздан, бүлмә аша: «О, сары чәчле кызга мин гашыйк!»— дигән сүзләре ишетелеп калды.

Кичке аштан соң, Сәҗидә савытларны юу хәстәрен күрә башлады. Без икәүләп, аскы каттагы юынгычка төшеп киттек. Кавказ егетләре, үз бүлмәләрендә, дөньяларын онытып, шау-гөр килеп сөйләшеп утыралар. Хатын-кыз тавышлары да ишетелеп куя. Гел күңел ачып яшәүдән ничек туймыйлар диген! Кайчан хәзерләнәләрдер имтиханнарына.

Бүлмәгә кергәч, Сәҗидә, арыган кыяфәттә, ике кулын иягенә куеп, уйга калды. Киң итеп ачылган тәрәзәдән волейбол мәйданы ягына күз салды. Анда хәзер тынып калган. Караңгылык эченнән ниндидер серле шәүләләр генә күренеп кала. Кайдадыр еракта, бер ир затының моңлы итеп җырлаганы ишетелә. Әйе, Переделкинода туган җыр ул. «Ялгыз гармун». Сүзләрен Михаил Исаковский язган.

—Минем бүген йоклыйсым килми,—диде Сәҗидә, басынкы тавыш белән,—ә сез йоклагыз, Әдип, сезгә режим сакларга кирәк.

Кайгыртучанлык тойгысы белән әйтелгән бу сүзләрне мина карата ирония билгесе дип тә аңларга мөмкин иде. Авыл аулак өйләрендәге шикелле, кочаклашып ятарга гына кирәктер дә бәлки. Юк, ярамый да, булмый да ул миннән. Безнең эшләр бик җитди. Киләчәккә төбәлгән. Арабыздагы тирән барьер әле алынмаган.

Мин ана үз койкамны тәкъдим иттем. Сәҗидә рәхмәт әйтеп, моңа риза булды. Үзем, баш астына одеал салып, стенага карап, Жора Гагиев койкасына бөгәрләндем. Бик арылган икән. «Икебезгә бер мендәр калдырганнар, шайтаннар», дип уйлап куйдым йокыга китәр алдыннан.

Төнлә уянып, Сәҗидә ягына күз салдым. Үзенчә пәрдә корып, урындык артына күлмәген элеп куйган булган. Салмак, тыныч кына сулаганы ишетелә. Янында ышанычлы иптәш барын тоеп, сабыйларча, шулай гамьсез генә йоклап ятуы күңелемә әйтеп бетергесез рәхәтлек бирә иде.

* * *

Мәскәүдән китәсе көнне без роза чәчәкләре сатып алдык. Пушкин мәйданына бөек шагыйрь белән саубуллашырга бардык. Ерак юлга чыгар алдыннан, шушы изге урында утырып, нидер әйтәсе, теләк телисе килә. Сәҗидә иреннәрен сизелер-сизелмәс кенә кыймылдатып, шигырь пышылдый, ахры. Пушкин шигырьләрен, әлбәттә. Монда бер без генә түгел, илебезнең төрле якларыннан килгән кешеләр күренә. Укалы түбәтәй кигәннәре дә, «аэродром» кадәр баш киеменнән йөргәннәре дә бар...

Уйга бирелеп, моңаеп калган Сәҗидә кулындагы чәчәкләрен Пушкин һәйкәле янына илтеп куйды. Без анда тып-тын гына басып торганнан соң, Тверь бульвары буйлап әдәбият институты ягына юл тоттык. Сәҗидә шунда әйтеп ташлады:

—Боже мой, хәзерге татар шагыйрьләреннән кемне генә беләм соң мин?! Юк бугай...

Аны акларлык та, аңларлык та иде. Җиденче класстан соң, урта мәктәпне ул рус телендә тәмамлый. Аннары ике ел рус теле укытучысы булып эшли. Уфа педагогия институтында тагын русча уку. Хәзер башкорт ягында яши. Хатларын да мина башта гел русча язды. Ахырга таба татар, башкорт телләрен бутап, туган телгә күчә башлады.

—Татар шагыйрьләрен дә укырсыз әле башыгызга төшсә,—дидем мин ана көлеп.

Сәҗидә мона каршы сорау белән җавап бирде:

—Һм, шулай ук булыр микән?

* * *

Без вагонга кергәндә, икебезгә бер чемодан иде. Әтигә Чүгәчәк шәһәреннән ияреп кайткан борынгы (тарихи) чемодандагы әйберләрнең күбесе Сажидәнеке. Кинәшә торгач, без шундый фикергә килдек: йомышларымны үтәү өчен мин Казанда төшеп калачакмын. Ә чемодан Сажидә белән китә. Оркыяды стансасында каршы алсыннар өчен, ул әткәсенә телеграмма сукты. Мин кайтып житкәч тә, Тәтешледә очрашырга сүз куештык. Әле шуннан башка кычкырып әйтердәй уй-ниятләребез юк иде. Дулкынлануын яшерергә тырышып кына, Сажидә беренче мәртәбә миңа «син» дип дәште. Шунысы хак, икебез ике якка аерылып китмибез. Бер поездга утырдык. Мин Казанда озак тормаска вәгъдә иттем. Профессор Латыйф Җәләйне һәм шагыйрь Гали Хужины күрәсем бар, дидем.

Хәерле юлга!

## Язмыш кочагына

Җиде ел солдат ләмкәсен тартканнан соң, кемнең студент булып аласы килмәс. Уку бик тә тансык, шундый сагынылган иде. Җитмәсә, Мәскәү ВУЗы, илдәге бердәнбер әдәбият институты... Ләкин ике елдан соң язмыш миңа арты белән борылыр дип кем уйлаган? Барлык хыялларым чәлпәрәмә килде. «Табигать кочагына, урманга китегез,—диделәр врачлар,—нерваларыгыз ял итсен. Хәтта урманчы булып эшкә керсәгез дә ярый...» Киңәш бирүе ансат. Хәзер кая барып сугылырга?

1951 елның җәендә мин Казанга шундый авыр уйлар белән кайтып төштем. Дөресрәге, «сугылырга» гына булдым. Өметләрем, хыялларым Сажидә утырган поезд белән китеп барды. Шул ук узган елгы 12 номерлы Мәскәү-Свердловск поезды. Туры килүен әйт тә куй.

Аякларым Матбугат йортына тартып китерде. Язучылар Союзына кермәскә уйладым. Унайсыз да, бераз оят та шикелле. «Өметебезне акламадың»,—дип әйтмәсәләр дә, шулай уйлаулары бик мөмкин.

«Яшь сталинчы» редакциясенә кереп, туп-туры редактор кабинетына уздым. Мине туктатучы да, «Ни йомыш?»—дип сораучы да булмады. Күз алдымда фәкать Гали абый гына. Атаклы «Россия» поэмасы, Салих Сәйдәшев музыка язган «Халисә» җырының авторы, утлар-сулар кичкән солдат, яшьләрне үз итүче бик кече күңелле кеше...

Ул, мәһабәт гәүдәсен турайтып, өстәл артыннан чыкты, гаҗәеп бер җылылык белән көлә-көлә исәнләште:

—Ялга кайттыңмы, Әдип? Әйдә, утыр әле.

—Мөгаен, бөтенләйгә булыр,—дидем мин, бераз шөбһәләнеп,—«табигать кочагында» яшәргә киңәш итәләр...

Тавышымда өметсезлек билгесе сизеп, ахры, Гали абый тынып калды. Ул өстәл янына килде дә, күзләрен чекерәйтеп, юеш гранкалар өстенә иелде. Ниләрдер төзәткәләп газетага кул куйгач, миннән сорады:

—Әйберләрең, чемоданың мондамы? Безгә кайтырбыз...

—Поездда китте, туган ягыма,—дигән җавапны ишетүгә, Гали Хужи каядыр почмакка сәер генә карап әйтте:

—Шаяртасың?!

—Юк, шаяртмыйм, Гали абый, чемоданымны сары чәчле бер кызга биреп җибәрдем.

—Кайтасыңны ишеткән идем,—диде ул, һәм кинәт сорап куйды:—Өйдә кемнәрең бар?

«Кемнәрең» сүзен мин «Таяныр кемең» мәгънәсендә аңладым һәм сорауга ачыктан-ачык җавап бирдем:

—Әти карт белән әни карчык. Яннарында шар күзле, тамакка таза биш малай һәм тагын ике кыз...

—Син сигезенче «бала» буласың,—диде Гали абый, күзлек пыяласын сөртә-сөртә,—карале, алай ярамый бит инде. Уйлашыйк әле...

Гали Хуҗиның кеше язмышы турында борчылып, хәсрәткә төшкән, кара кайгыга калган чагын күрү мине хәтта тетрәндереп җибәрде. Ил язмышы белән яшәгән кеше, күрәсең, аерым шәхесләргә карата да битараф кала алмый. Бераз уйланганнан соң, ул миңа тәкъдимен әйтте:

—Ике урында хәбәрчеләр кусты оештырабыз. Бөгелмәдә һәм Минзәләдә. Мәсьәлә обкомда хәл ителгән. Кайсын сайлыйсың?

Мин уйга калдым. Маңгаемнан бөрчек-бөрчек тир бәреп чыкты. Бу хәлемдә хәтта биш юллык хәбәр дә яза алмаячагым турында әйтергәме, юкмы? Әйтмәсәң алдау була. Түкми-чәчми, барысын да сөйләп бирдем. Диагнозы куелган медицина справкасын күрсәттем: «Үзәк нерв системасының ялыгуы». Латинча тагынниләрдер язылган.

—Редакция җилкәсендә яшәп булмас, Гали абый. Бигрәк тә сезгә аркаланып. Куандыра алмам...

Ул кабинет буйлап йөренеп алды. Үзен бераз тынычландыргач әйтте:

—Кәнфитләнү килешми безгә, аңлыйсыңмы? Без—солдатлар. Гали абый аннары көлемсерәп аягымдагы киндер туфлиләргә күз төшерде, иң гади материалдан тегелгән пиджагымның кайтармасын күзенә терәп, костюмны мактаган булды:

—Ничего бу, малай. Туйга киярлек... Йә, нишлибез соң?

Гали Хуҗи Минзәлә якларын, ямьле Ык буйларын мактарга тотынды. Үз йөзен тапкан, илебезнең төрле почмакларын урап чыккан Минзәлә татар дәүләт күчмә театры турында сүз кузгатты. Аның баш режиссеры гына да ни тора, диде. Сабир Өметбаев—чын мәгънәсендә иҗат кешесе. Аннары, син анда баргач, педучилищеның тел-әдәбият укытучысы Мөхәммәт абый Гарифуллин белән таныш. Ихлас күңелле бик һәйбәт фикердәш...

Гали абый тагын Минзәләдә авыл хуҗалыгы техникумы, Фельдшер-акушерлар курслары, русча һәм татарча ике урта мәктәп барлыгын әйтте. Мин күңелемнән Саҗидә турында кайгыртып куйдым. Кушыла-нитә калсак, янәсе, аңа тарих сәгатьләре табылмый калмас әле. Ике телне дә яхшы белә бит. Русчасы хәтта шәбрәк тә. Баштарак русча язган хатлары буенча да чамалыйм моны. Ах, бу хыял дигәнең! Чынга ашар микән ул? Әллә өйләнү дигәнең сөйләнү генә булып калырмы? Серләр килешердәй үз тиңеңне табу бик зур бәхеттер ул. Ул бит яңа дөньяга ишек ачып керү белән бер булырга тиеш. Районыбызга кайту белән, күзне йомып, сүз кушарга шул кызыкайга...

Редактор Минзәләнең тагын кайбер «сер»ләрен ачып салды:

—Ә сырасы Казанныкыннан шәбрәк, малай,—диде мөлаем генә елмаеп,—ликер-аракы заводында балык ысландыру цехы да бар. Безнең Галимҗан аннан сирәк-мирәк күчтәнәчләр алып кайткалый.

«Дирбия»ле балык турында сүз чыккач, Гали абый да, мин дә төкерекләребезне йотып куйдык. Шунысын да белдем: Галимҗан Сәгыйдул-лин газетада авыл хуҗалыгы бүлеген алып бара, бераз драматург та икән. Минзәлә районында туып үскән кеше. Театры белән элемтәдә тора. Минзәлә авыл хуҗалыгы районы булгач, димәк, миңа күбрәк аның белән эш итәргә туры киләчәк. Ахыр чиктә Гали Хуҗи мине Минзәлә төбәгенә—«табигать кочагына» китәргә ризалаштырды. Үзе аннары, «хәзер керәм» дип, каядыр чыгып китте.

Киемнәремә игътибар бирде. Әдәбият институтына япон гәләфиен-нән, каты кирза итектән китүемне хәтереннән чыгармаган, күрәсең. Гали Хуҗи ул чагында Буада яши, «Кызыл Татарстан» газетасының үз хәбәрчесе булып эшли иде. Ул Казанга килгәндә, без аның белән вакыт-вакыт очрашкалый идек.

Редактор ниндидер кәгазьләр тотып кереп тә җитте. Җитди, эшлекле кыяфәт белән сүз башлады:

—Безнең егетләр сине нефть чирәменә кодаламакчы,—диде ул, бераз икеләнә төшеп.—Дөрес сөйли алар. Ул яктан безгә материаллар тамчылап кына килә. Ярый, бая уйлаганча килештек. Әлмәт шәһәре аякка баса башлагач та, сине шунда күчерербез. Менә сине эшкә алу турында приказ. Монысы шәһәр советына, квартир мәсьәләсендә... Борчылма, барысын да рәтләрбез.

Ул минем беләгемнән кысып, үзенә генә хас якты, эчкерсез бер елмаю белән елмаеп куйды:

—Чемоданыңны кайдадыр куып житәрсең бит инде. Теге сары чәчле кызга бездән сәлам әйт. Ничего, рәтләнер, малай. Дөнья ул...

## «...Бездән дә бәхетле кем бар бу дөньяда!»

Мин Аксәеткә, Гали Хужи шул «ничего бу» дигән костюмнан, кулыма портфель тотып, жинелчә генә кайтып кердем. Ике кул биреп аркабыздан сөешеп исәнләшкәч, әни гажәпсенеп бераз күзләремә карап торды:

—И, Ходаем, әллә урлаттыңмы чамаданыңны?!—диде ул аннары, аңына килгәндәй (юлда әйбер урлатуның әчесен татыганы бар бит). Мин бер дә исем китмәгәндәй, портфельдәге бүләкләрне өләшә башладым: әни белән Лена сеңелемә зәңгәр крепдешин яулыклар (боларын Сажидә сайлашты), әтигә чыртлап ябыла торган күн пыртманник, ә малайларга—кемгә пистолет, пәке, кайсына резин туп, буяулы китаплар...

Гадәттәгечә, мангай тирен сөртә-сөртә, әти кайтып керде. Көлемсерәп, шат күңел белән күрешкәннән соң, серле генә карап куйды миңа:

—Сөләйманов телефонга чакырган,—диде авызын тәмләп,—Сажидәнең исән-сау кайтып житкәнен хәбәр итте... Чемоданың анарда икән.

Алар, күрәсең, хәбәрләшеп кенә калмаганнар, төбенә тоз коеп сөйләшкән булырга тиешләр. Чемодан эчендәге безнең әйберләрнең аралашып бетүе турында да әйтми калмагандыр Гаделша абый. Шулай тоела әтинең күз карашыннан. Ул, нindидер зур яңалык алдында торган сыман, дулкынланып түргә узды. Миннән бер жавап көтте. Ә минем әйтер сүз юк иде. Чөнки өйләнешү турында Сажидә белән ике арада килешү булмаган, аны жаныбызда гына тоя идек әле.

Ана кеше сизмәми каламы соң! Балалар Мәскәү бүләкләре белән мактанышырга урамга чыгып сибелүгә, әни мине «тотарга» уйлады, ахры:

—Кичә түбән оч Салихәттәй килеп утырды,—диде, сүзне башкага борган сыман,—и, кызы Әминәсен мактый, «безнең Әдип белән Әминә бигрәк парлар» дигән була. Бер самавыр чәйне эчеп бетергәнче телennән төшмәде шул сүзләр...

—Булмастайны сүләмә-сәнә-ә!—диде әти кырт кисеп.

—Ния, бүген Әдипнең кайтасын белеп килгән ул, безне кунакка чакырып китте...

Тәки сүземне әйттерде әни:

—Миңа бүген үк Тәтешлегә китәргә кирәк,—дидем, сүзне озынга сузмаска тырышып,—мин хәзер юлда исәпләнәм, кулымда приказ бар.

—Приказ?! Ниндәй приказ?

—Тагын армиягә алалармы әллә, Ходаем?

Әти дә, әни дә, гажәпкә калып, тынып тордылар. Мин аларга уку буенча институттан академик ял алуымны да, Минзәләгә корреспондент булып эшкә китәргә тиешлегемне дә аңлатып бирдем.

—Чемоданны да барып алырга кирәк,—дип өстәдем. Калганын әйтеп бетермәдем.

—Әллә соң Тәтешлегә бергә барыйкмы?—диде әти, кинәт дәртләнеп,—Сөләйманов та ым какты телефоннан...

Шул сүзләрне ишетүгә, әни «лып» итеп, сәкегә утырды:

—Кара, кара боларны! Миннән башка гына... Кинәт яшь аралаш елмаеп куйды ул. Утыз яшькә житеп тә өйләнмичә йөргән улының тормышында бүген кискен борылыш буласын күнеленнән тоя иде әни, әлбәттә. Күп сүзле Салихәттәй янадан килеп житкәнче дип, мин Марс энемнең (үзе Владивосток янында дингез флотында хезмәт итә) велосипедына атланып, Тәтешлегә китү ягын карадым. Әти дә, әни дә моңа каршы килмәделәр. Киресенчә, җинел сулап куйдылар шикелле. Мин «сәпит»не «житәкләп» урамга чыгуга, алар парлап тәрәзәдән башларын тыктылар:

—Сөләймановларга сәлам әйтә тор!—диде әти, тамагын кырып.

Әни дә сүзсез калмады:

—Берүк кенә сакланып йөр, бәла-казага эләгә күрмә!

Мин тизрәк чемоданымны «куып» житәргә тиеш идем. Кайчандыр Сажидәне өч көн укытып калган Түбән Тәтешледә, бер танышымда велосипедымны калдырдым да, тау итәгендәге бормалы сукмак буйлап, Сөләймановлар өенә юл тоттым. Сажидә минем килгәнемне ерактан ук күреп, тыкрык башына чыгып торган. Сагынышырга да өлгергәнбез, күрәсең, тизрәк бер-беребезнең каршына ашыктык, кул бирештек.

—Безне күзәтәләр,—дип куйды Сажидә, ишегалдындагы биек күтәрмә ягына ымлап,—телеграмманы алуга Биби апа да килеп житкән...

Гаделша абыйның сеңлесе ул. Мин аны Аксәеттә чагында ук беләм. Кәжә сакаллы, авызыннан «хуш ис» өзелмәгән фельдшер дядя Ванычның ярдәмчесе булып эшләде. Әнине бик хөрмәт итә иде. Хәзер ул шагыйрь һәм драматург Кәрим Әмири туган авылда, Бүл-Кайпанда бер ялгызы яши. Белмәгәне, күрмәгәне юк, күрәзәче белән бер. Авылның атаклы кендек әбисе. Бәетләр дә чыгара, Коръәнне дә су урынына эчә, диләр...

—Ни ди соң Биби апа?

—Чемоданны ачып җибәрүгә үк, «боларның эшләре төгәлләнгән» дип, йөземне кызартты. Кая керер тишек тапмадым. Әнкәй дә аптырап калды.

Моменттан файдаланып, шунда мин ныклы сүземне әйтергә булдым:

—Минзәләгә китәбезме, Сажидә? Менә приказ... Редактор Гали Хужи сәлам әйтте сиңа.

—Алай куркытмале, Әдип,—диде Сажидә житдиләнеп,—ашыкмыйк. Без бит бер-беребезне бик аз беләбез. Әнкәй дә риза булмас...

«Юк, булмый!»—дип кистереп әйтмәде ул. Типография хәрефләре белән мангаена «Яшь сталинчы» дип язылган приказ бланкасын кулында әйләндергәләп торганнан соң, көлемсерәп куйды:

—Моны әткәй күрсә, «буйсынырга кирәк, кызым»,—дияр инде...

—Биби апа да каршы килмәс дип уйлыйм...

* * *

Ул кичне мин Сөләймановлар өендә озак тормадым. Бер тустаган чәй эчтем дә, зурлап сөйләшүне икенче көнгә калдырып, энем велосипедында кайтыр юлга чыктым.

Калган ягын укучы сизеп торадыр. Туганлашырга тиешле ике зур гаилә (Сөләймановлар—тугыз жан) арасында әллә ни каршылык чыкмады. «Әллә ни» дигәне шул:

—Кызымны туйсыз бирмим, Малик абый,—диде Сажидәнең әнкәсе Галимә апа, икенче көнне миңа таяныч булып килгән әтигә төбәлеп,—икесе дә бәрәр ел эшләсеннәр әле. Биреп жибәрергә мендәрем дә юк ичмасам... Кая ул кыз бирү!

Бер караганда Галимә апа хаклы иде: ике йортта да ярлылык күзгә бәрелеп тора. Балалар өстендә—олырагыннан калган ямаулы иске-москы киемнәр, аяклары ялангач диярлек. Өйдә күз кызыгырдай затлы әйберләр калмаган. Барысын да сугыш йоткан. Өстәвенә, Сажидәнең кышкы яна

пальтосы, язгы-көзге киемнәре, башка кирәк-яраклары Аскардагы күршеләрендә торып калган. Анын әле отпуск акчасы да «очып» беткән булырга тиеш. Туганнарына бүләкләр жыйды бит. Ә мина жәйге каникул өчен стипендия биреп тә тормадылар. Әтиләрнен барлы-юклы пенсиясенә ничек кунак жыеп, туй ясап ятасын инде...

Уйларымны Гаделша абый бүлдерде:

—Галимә, тынла әле мине,—диде ул, кыза төшеп,—килгәндә мендәрен барыемы сон синен? Икебезгә менә шушы дүрт эшче куллар иде. Башлары, кул-аяклары исән булсын балаларнын.

—И, алтын сүз әйттен, абзыкай,—диде Биби апа, тын да алырга ирек бирмичә,—әйдә, үзләре риза булгач...

Ә әти, янәшәсендә утырган кода булачак кешене кочаклап ук алды:

—И-и-и, Сөләйманов, бергә булаек әле! Гомергә!

—Шулай язсын, Гарифуллин, шулай гына язсын! Без бит... Ни бит... Бездән дә бай, бездән дә бәхетле кем бар бу дөньяда! Мин бит әнкәгезне, сезне ятим итмәс өчен исән калдым сугышта, балалар! Язмыштан узмыш бар ул...

Өстәл башында ике тарихи карт утыра. Чәчләре ап-ак, йөзләре жыерчык белән тулган. Кул аркаларында кан тамырлары бүртеп, кабарып тора. Башларыннан күпме хәсрәтләр, авырлыклар кичкән дөнья картлары, изге картлар. Алар бөтен гомерләрен халык өчен багышлаганнар. Тормышка рәнжемиләр үзләре, булганына канәгатьләр, Өмет канатында очалар... Берсе—хезмәт, икенчесе—сугыш инвалиды. Алмашка кияргә күлмәкләре дә юк дияр идем, Сажидә әткәсенә Мәскәүдән хаки төсендәге ярым хәрби күлмәк алып кайтты бүләккә. Сөендереп, бәхилләтеп яшисе иде бит шул сабый күнелле жаннарны!

Күнеле тулып ташкан Галимә апа эш бүлмәсе ягына чыгып китте. Әти ин яраткан жыры—«И, мөкатдәс, монлы сазым...»ны сузарга ниятләде. Аны гажәеп матур бәрхет тавыш белән Сөләйманов күтәреп алды:

«Уйнадын син ник бик а-а-аз? Син сызасын, мин сүнәме-е-н»...

—Сүнмибез әле, Гарифуллин кода,—диде Гаделша абый, теленнән очкан «кода» сүзен тотып калалмыйча,—әле безме... без... Яулыгын бу юлы ни өчендер ияге нә төшереп бәйләгән Галимә апа (әллә «әби» булырга жыенамы) өстәлгә тавык ите китереп куйды:

—Кода булырга иртә әле!—диде ул үзсүзлеләнеп.

* * *

Өстәл артыннан кузгалып, әтине озатуга, өйдәгеләр каядыр чыгып киттеләр. Без Сажидә белән икәүдән-икәү генә калдык. Бераз сөйләшеп утыргач, мин тоттым да кистереп әйттем:

—Тимерне кызуында сук, диләр. ЗАГС йорты ерактамы, Сажидә?

—Урам аша гына...

Шаһитлар тиз табылды. Авыл советы секретаре Сажидәдән:

—Кем фамилиясен аласыз?—дип сорады. Мин ык-мык итеп калдым. Сажидә мина сораулы караш ташлады да:

—Сөләйманова,—дип әйтеп салды. Һәм гомерлеккә шулай булып калды да. Кул куешканнан сон, шунда беренче тапкыр үбештек тә.

Сажидә, мәктәптән азат итүләрен сорап, Әбжәлил РОНОсына гариза язып жибәрде, телеграмма да сукты.

Өч көннән сон Аксәеттә, матур хыялларга бай безнен кечкенә өебездә мәжлес сыман нәрсә жыеп алдык. Туй түгел иде бу. Кода-кодагыйлар, килен белән кияүдән башка, тагын Биби апа бар иде.

Кулларына болын чәчәкләре тотып, туганнарым кайтып керде. Кара, кызыл карагат (карлыган), жир жиләге дә жыярга өлгергәннәр. Өй эченә болын исе, Әри буе әрәмәләренен хуш исе таралды. Беренче букет жингәләре кулына күчте.

—Жингәшәй!—дип, биленнән кочаклап ук алды Сажидәне, алгы

тешләре коелган, оялуны белми торган җиде яшьлек энем Одер.

Чәчәкләргә бик сөенде Сажидә. Чәчәкләрдән дә бигрәк, туганнарымның балкып, елмаеп, үз итеп торуларына куанып бетә алмады ул:

—Ничаклы байлык бу өйдә!—дип, керфек очындагы яшен сөртеп алды.

Әни белән Галимә апа, әке-чөке килеп, көлешеп сөйләшә дә башладылар. Алар бер-берләрен электән үк яхшы белә һәм аңлый иделәр.

...Безне туган як чәчәкләре белән күмеп, авыл советының абруйлы атында Оркыяды стансасына озатып куйдылар.

## Әйдә киттек Минзәләгә

*Минзәләне күрер өчен*
*Үзәгем өзгәләнә...*

Мин бу җырны беренче тапкыр Зифа Басыйрова башкаруында ишеткән идем. Тирәннән чыккан моң чишмәсе агыла, йөрәк өзгеч моң.

Күз күрмәгән шәһәргә әйләнеч юллар белән барып җиттек. Башта Сарапулга кадәр поездда. Аннан Кама пароходына утырдык. Кама буйларының гүзәллеген күзәтеп бару үзе ни тора. Кинодагы сыман, яңадан-яңа күренешләр ачыла. Беренче класслы каюта. Сажидә спорт киеменнән калып, төрле фигуралар ясый, кыскасы, күнеле көр.

Чаллы пристанена җитәрәк, сискәндереп сигнал ишетелде:

—Каршы-ла-гы-з-з-з!

Алдыбызда гаять текә яр. Урау юлдан күтәрелеп, автобус тукталышына киттек. Озак көтәргә туры килмәде.

Минзәлә кебек эчкәре шәһәрләрне руслар «глубин-городок» дип йөртәләр. Тимер юлга йөз чакрым чамасы икән. Кама елгасы Минзәләгә кагыла язып китсә дә, ул борылышта пароходлар туктамый. Пристань да юк.

Минзәләгә якынаюга, каршыда биек-биек торбалар пәйда булды. Күршебез, бер дә иренми, аңлатып бара: спирт-ликер заводы, сыра, балык заводлары...

Шәһәрнең үзәк өлешенә җитәрәк, кызыл кирпечтән салынган мәһабәт бина күзгә ташлана. Педагогия училищесы икән. Ә юлның сул ягында мангаена «Район культура йорты» дип язылган зур гына агач бина. Янәшәсендә үк партия райкомы.

Автобус нәкъ кунак өе янына килеп туктады.

Уртак тормыш кечкенәдән башлана. Өйдән ияреп килгән агач кашыклар, чәчәкле кружкалар да ярап куйды.

Без яшәгән бүлмәне хуҗалар үзләренчә шаяртып «люкс» дип йөртәләр. Шыгырдавыклы ике тимер карават, ике урындык һәм өстәл хезмәтен дә үтәгән зур гына тумбочка. Стенада түгәрәк көзге. Сажидәнең ана буе җитми, урындыкка басып бизәнә. Бизәнә дип инде, болай да алсу, чиядәй тулышкан иреннәренә бик аз гына кызыл йөгертеп ала, чәчләрен рәтли. Иркәләнәсе килгәндәй, инбашыма авырлыгын салып, идәнгә төшә. Хатының матурмы дигәндәй, зәңгәр күзләрен тутырып, мина күз сирпеп ала.

Шәһәр советында безгә тиз генә квартир вәгъдә итмәделәр. Җавап кыска:

—Монда төзелеш юк,—диде ак чәчле, ак кашлы Тихоновский дигән председательләре,—кеше өстендә кеше яши бездә. Казаннан шалтыратып әйттеләр киләсегезне,—диде аннары ул уйга калып,—бер чарасын күрергә тырышырбыз. Көтәргә туры килер.

Кунак өе турысыннан карасаң, үзәк урамның очлары баштан-башка күренеп тора. Күбесе агач йортлар. Ичмасам, бер генә төзелеш краны да күзгә чалынмый. Каян тусын квартир!

Урам аша гына шәһәр бакчасы. Яшь каеннар аз гына жилгә дә сизгерләр, монсу гына талпынышып куялар.

Сажидә шуларга карап, Аскарны сагынадыр сыман. «Бахыркайларым», дип куйды ул.

—Уф, андагы каен урманнары төшләремә керә башлады,—дип тә ычкындырды,—укучыларым ни уйлар икән минем турыда? «Хыянәтче апа, безне ташлап китте»,—димәсләр микән?

—Әйтмәсләр. Монда бит сине яна укучыларын көтә. Алар монаерга ирек бирмәсләр...

Әйе, Сажидә мәктәптән, балалардан башка яши алмаячак, мин аны хатлары буенча беләм.

Сажидә РОНОга кереп, эш урыны белеште. Яңа уку елы башланганчы, ана РОНО инспекторы булып эшләргә тәкъдим иткәннәр. Әле бит Аскардан документлары да килеп житмәгән. Документлар гына түгел, кышкы кием-салымнарын, өр-яна пальтосын, юрган, мендәрләрен вакытлыча күршеләренә куеп калдырган.

Аларын соратып тормады инде. «Үзләренә истәлеккә калыр,—диде ул, бераз уңайсызланып,—әйбәт кешеләргә жәл түгел. Ә хатларынны соратырмын. Мин аларны жыеп барган идем».

Сажидә Минзәләдә яши башлау белән, мине режимга куймакчы булды.

—Синең бит жәйге каникулларың бүлгәләнеп беткән. Әле командировкада, әле юлда. Август—отпуск аен синен.

Чыннан да, Казаннан китәр алдыннан Гали абый да:

—Минзәләгә баргач, берәр ай үз иркендә йөр. Ык, Кама буйларына бар, балыкчылар белән дуслаш,—дигән иде. Минем рөхсәтемнән башка сиңа шалтыратмаслар дип тә өстәде. Кая шалтыратсыннар инде, эзләп тә таба алмаслар мине. Тизрәк фатир табарга, телефон куйдырырга кирәк булыр...

Өстән-өстән генә булса да, шәһәр белән танышуыбызны дәвам итәбез. Һәр хужалыкнын бәрәнге, жиләк-жимеш бакчасы, мунчасы, абзаркурасы бар. Кичләрен үзәк урамны тутырып көтү кайта. Имчәкләре сөт белән тулышкан бурадай сыерларның машина сигналына исләре китми, койрыкларын гына болгыйлар.

Вахитов урамыннан Минзәлә елгасына таба барганда Сажидә ташландык таш складларга игътибар итте. Түбә калайлары ачылып, алабуталар үсеп чыккан. Таш стеналарын яшел мүк сарган. Сажидә түзмәде, юлда очраган бер әбидән сорап куйды:

—Әйтегезче, әбекәй, каян калган икән бу борынгы складлар?

—И-и, балалар, Астахи байдан инде,—диде чәчәкле яулыгын иягенә төшереп бәйләгән карчык,—даны үзеннән алда йөргән. Таш пулатлар салдырып жыйган.

Сүзгә юмарт булып чыкты беренче танышыбыз.

—Астахи бай тирә-юньдәге икмәкне арзанга сыпырып алган да, баржаларга төяп, Рәсәй базарларына озаткан, балалар. Безнеңчә әйтсәк, искепүлән булган.

Биек дамбаларга таянып, Минзәлә елгасы аша әллә ничә метрга сузылган челтәрле тимер күпер, кайбер чыганакларга караганда, Әби патша заманында ук салынган булган. Бөгелмәдән Минзәлә аша Әгерҗегә тимер юл сузарга жыенганнар, имеш. Дәрт бар, дәрман юк дигәндәй, азмыни гамәлгә ашмаган планнар.

* * *

Ишек шакып, бүлмәбезгә олпат гәүдәле, зур башлы, ак чәчле бер абзый килеп керде.

—Төкле аягыгыз белән, коллега! Корреспондентлар бит бер-берсен күрешмичә дә таныйлар,—диде ул исәнләшеп.

Габдрахман Галиәкбәровның Минзәлә кустында, «Совет Татарстаны» хәбәрчесе икәнен ишетеп белә идем инде. Ә ул:

—Тапшырулар редакторы Әдип Маликов,—дип, шаяртып көлеп җибәрде, минем радиода эшләгән елларымны искә төшереп.

—Хатыным Сажидә,—диюгә, Габдрахман абый:

—И-и, Сажидә—керләр чайкый сай җирдә,—дип рифмалап та алды.—Сәждә кылучы ягъни, башын җиргә куеп, ольлаучы хатын.

Үзенең Минзәлә килене икәнен акларга тырышкандай, Сажидә ак самавырны терелтергә тотынды.

—Юк, юк, кызым, почтадан кайтышлый сезне үзебезгә чакырырга дип керүем,—диде Габдрахман абый.—Берәр сәгатьтән безгә рәхим итегез. Күршедә генә йортыбыз.

Ул кирәкле координатларны әйтеп, чыгып та китте.

Хуҗаларның фатирын табып, ишек катына килеп туктауга, эчтән сузып-сузып кычкырган авазлар ишетелде. Икеләнеп калдык. Әллә соң ялгыш киләбезме? «Җанҗалчы» тынгач кына ишек шакыдым.

Шунда ук хуҗаның айдай нурлы йөзе күренде:

—Казанга материал тапшырдым әле,—диде ул, бик зур эш башкаргандай сөенеп,—иң беренче бәяне бит стенографистка бирә: «Әйбәт» диде.

—Аның тавышы урамга ишетелә инде,—дип, ягымлы хатын кулларын сузды безгә,—Рокыя апагыз. Хәерле сәгатьтә, балалар.

Хуҗабикә кыстыбый кыса икән. Җитеп килгән кызлары да мич тирәсендә кайнаша.

Фатирлары ындыр табагыдай зур. Кухня өлешен берничә такта белән генә бүлеп алганнар. Түрдә телефон, эш өстәле. Хуҗа кеше мәкалә иҗат иткәндә, аяк очларына гына басып йөриләрдер инде дип уйладым. Алай гына түгел икән. Уемны сизгәндәй:

—Өйдә кеше калмаса, каләмем тәртелә,—дип куйды Габдрахман абый, ләззәтләнеп көлә-көлә,—бигрәк тә Рокыя апагыз юк чагында.

—Сүләмә сәнә,—диде апа, моны шаяртуга алып,—эше бик ашыгыч булса, куып чыгарганын көтмибез алай...

Өстәлгә кыстыбый килгәнче, Габдрахман абый Татарстан картасын җәеп салды.

—Менә киртекләп бетергәннәр бит! Камышлы шикелле чын татар районнарын башка өлкәләргә кушып куйганнар... Ә синең маршрутлар нинди булачак соң?

Мин санап чыктым:

—Матвеевка, Красный бор, Сарман, Ворошилов, Мөслим... Барлыгы җиде район.

—Берьюлы барысын да йөреп чыга алмассың,—диде Габдрахман абый,—син чагыштыру өчен дип командировканны Матвеевкадан башла, аннан Сарман, йә Мөслимгә юл тотарсың.

Калганын әйтеп тормады ул, үзең анларсың, янәсе...

Кыстыбый янына «чүлти» килеп утырды. Яртының яртысы, ягъни.

Сажидә кечкенә рюмкаларны читкәрәк этәреп, икебезгә дә карлыган согы салды.

Габдрахман абый көлеп үк җибәрде:

—Менә рәхмәт, кызым. Шулай тәрбияләрене. Рокыя апагыз бер «чүлти» алып кайтса, утызар граммнан миңа бер атнага җитә. Стенографистка мактаса гына тотам мин анысын да. Минем өч темам бар,—диде ул,—мәктәпләрдә татар телен укытуның торышы, мораль тема һәм авыл хуҗалыгы мәсьәләләрен яктырту. Ә промышленность юк диярлек монда...

Алдан ук әйтим, бу гаилә киләчәктә безнең иң якын таянычыбызга әйләнде.

* * *

Тихоновский башта: «Кунак өендә яшәгән өчен тулай торак бәясе белән түләрсез»,—дисә дә, бер айдан соң бездән «люкс» хакын каерып алдылар.

Бердәнбер таяныч—үз газетам. Хәлебезне аңлату өчен Казанга—редакторыма шалтыраттым. Гали абый авыру кеше шикелле салмак кына исәнләште. Сүземне ахырга кадәр тыңлады. Бер мәлгә тынып торды, тоңык кына булып, кемнәрнеңдер ни турындадыр үзара мыгырданганнары ишетелеп куя. Аннары шактый күтәренке тонда сүзен дәвам итте:

—Гафу ит, Әдип, безнең «летучка» бара монда,—диде ул,—менә сезнең хакта бераз кинәшләшеп алдык. Сәлам әйтәләр иптәшләр, әлеге дә-баягы—нефть ягын каералар. Карале, син бит бездән «подъемный» да алмый киткәнсең. Бүген үк телеграмма сугабыз, борчылма...

Икенче көнне үзәк почтага керсәм, күзләрем шар булды: бухгалтерия ике айлык хезмәт хакына тиң перевод җибәргән. Сажидә ни әйтергә дә белмичә, «моны нишләтәбез инде?»—дигән сыман, аптырап миңа карады. Шунда ук җавабын да тапты:

—Бер өлешен Аксәеткә җибәрик, яме?!

Без юлга чыгасы көнне әти авыл советыннан пенсия алып йөргән иде. Аны үзе ясаган конверт эченә салуын хәтерлим. Менә шул конверт чемоданыбыз төбендә, акчасы белән бергә, Минзәләгә ияреп килгән. Соң, ачлы-туклы балалар өлеше бит бу! Бик кызганыч хәлдә булдык микәнни? Оят булса да тоттык шул акчаларны. Менә шулай, ата-анага без гомер буе бурычлы булып калабыз.

Әтиләргә акча салу өчен почтага без Сажидә белән бергәләп киттек. Редакторга рәхмәт укый-укый, икебез дә җинел сулап куйдык.

* * *

Яңа уку елы башлануга, Минзәләдә хәрәкәт, ыгы-зыгы артты. Чөнки педучилищеда, авыл хуҗалыгы техникумында, ФАШта укучы студентлар килеп җыелды. Гастрольләрен түгәрәкләп, күчмә театр артистлары отпускага кайтты.

Сажидәгә Вахитов исемендәге татар урта мәктәбендә атнасына утыз сәгать тарих, конституция дәресләре бирделәр. Рус классларыннан да баш тартмады. Өстәвенә, класс җитәкчесе. Укытучылар комсомол оешмасы секретаре итеп сайларга да өлгергәннәр үзен. Күрәсең, җигәргә, сынап карарга булганнар яңа кешене. Теләгенә ирешкәндәй, үзе моңа сөенеп кенә йөри. Уртадагы «окно»лары белән бергә, ике смена эшләргә туры килә аңа. Кичләрен соңгарып кайта. Октябрь бәйрәменә класслары белән нинди дер спектакль хәзерлиләр икән. Хатлары буенча беләм бит, нәкъ Аскардагыча тотынды бу эшкә.

Кеше өстендә яшибез хәзер. Фатирыбыз мәктәп янында гына. Зур, иркен залда яшибез. Ирле-хатынлы хуҗалар безгә түр якларын бирделәр. Ә үзләре яртысына якынын урыс миче биләп торган алгы бүлмәгә дә ризалар. Зал ягы парланмасын өчен урта ишекне ябып йөрергә тәкъдим иттеләр.

Сажидәгә мәктәптән бер машина каен утыны китереп аудардылар. Аларны бергәләп кисеп, ярып, лапаска кертеп тутырдык. Ә андагы утын запасы тагын ике елга җитәрлек. Нәселле сыер асрыйлар, бик күп печән хәзерләгәннәр. Безгә көн саен бер литр сөт биреп барырга булды тәмле телле хуҗа хатын. Базар хакы белән, әлбәттә. Фатир өчен дә, бәясеннән тормыйча, бер ай алдан түләп куйдык. Вакытлыча булса да, үз куышыбыз бар дип куанабыз. Телефон да керттеләр.

Көннәр салкынаюга, без зал ягында туңа башладык. Хуҗабикә гөлләрен үз ягына күчереп куйды. Киез итектән, бәйләгән киемнән йөрибез, төнлә одеал өстеннән ике пальто ябынып йоклыйбыз. Хуҗалар

яшәгән бүлмә жылы була. Чөнки мич авызы да, учак плитәсе дә шул якта.

Монысына түзәр идек әле. Әмма хужа хатынның, «туганнар кайта» дигән сылтау белән, салкын кыш уртасында бүтән фатир эзләргә кушуы сискәндереп жибәрде безне. Сизеп торабыз, сәбәбе башкада: Сажидә бит, күз тимәсен, күренеп юаная, тулылана бара. Икебез дә канатланып, үзебезчә чиксез дулкынланып, татлы борчуга талып йөрибез. Дөньяга яна аваз алып киләчәк нәниебезне ничегрәк каршы алу хәстәрен күргән булабыз. Ә Сәлмәниянең, күрәсең, үз исәп-хисабы. Ул көтелмәгән хәл алдында калудан курка. Көлеп кенә булса да:

—Мин бит нервынный, бала тавышын яратмыйм,—дип тә ычкындырды. Акчага чукынып яши торгач, кешелеген дә, иманын да жуйган икән бу адәм актыгы, дияргә генә калды безгә. Ичмасам, яз житкәнен көтсен иде. Сер бирмәскә тырыштык, «ярар»дан башканы әйтмәдек.

Тихоновский ягымлы булып күренә башлады. Безнең хакта Казаннан ниндидер телеграмма килгән, ахры. Райкомнан да шалтыратканнар үзенә. Май бәйрәменә фатир вәгъдә итте ул. Моның буласына үз күзебез белән ышанып кайттык. Иске агач йортны ремонтлап, шунда бер бүлмә арттырырга булганнар. Ишегенә акбур белән минем фамилияне язып куйганнар. Шуны белсәләр дә, йорт хужаларының түземе житмәде. Март башында безгә чыгып китәргә тәкъдим ясадылар.

Хәлебез турында мин Габдрахман абый Галиәкбәровка сөйләдем.

—«О-hо-hо!—дип куйды ул, моңа куангандай, очынып китеп,—хәзер үк безгә күчеп киләсез!

Һәм урта мәктәптә укучы улы белән кызына әмер биреп тә өлгерде:

—Барыгыз, балалар, булышыгыз, ярыймы!

Габдрахман абыйларда ике ай чамасы яшәдек. Үзләре дүрт жан, безнең белән алты, жиденчесе карында тибешә. Күңелләре иркен булгач, бернинди кысанлык сизмәдек анда. Өйләре эреп китәрлек жылы. Рокыя апа утынны кызганмый. Юантык гәүдәле, сабыр холыклы Габдрахман абый, изүен ачып, түр башында мәкалә яза. Аннары, һәр сүзенә басым ясап, кычкырып-кычкырып, Казанга материал бирә башлый. Саваплы һәм жаваплы эшеннән бушауга, бик канәгать кыяфәт белән кулына мандолина ала. Бер арада Сажидәгә күз салып, кайгыртучан тон белән әйтеп куйгалый:

—Әнә чаршау артына кер дә ят, кызым, ял ит.

Тегесе дә жавапсыз калмый:

—И, Габдрахман абый, күбрәк йөрергә кушалар бит, хәрәкәт кирәк, диләр.

—Йә, үзегез беләсездер инде...

Мандолина моңы дәвам итә.

* * *

1 Май бәйрәме көнне, фатир күрсәтергә дип, Габдрахман абый белән Рокыя апаны кунакка дәштек. Анда күчкәнче үк балта остасыннан жыйнак кына эш өстәле (аш-су өчен дә шул), дүрт бүкән-урындык һәм бала караваты ясатып алган идем инде. Караватыбыз да булды. Өйдә бер уен коралы кирәк дип, Сажидә мандолина сатып алган. Өстәлгә телефон менеп утырды. Болай булгач, эшләр жайга салына дип сөенәбез. Сажидә «Алла боерса» дип тә өсти. Әле бит иң зурысы алда...

Үзе жылы яраткан Габдрахман абый, өй котларга дип, бәләкәй генә тимер мич күтәреп килгән. Рокыя апа савыт-саба тоткан. Сөйләшеп туя алмыйча, бик күңелле утырдык без ул көнне. Бераз кызып алган Габдрахман абый, яна мандолинаны көйләп, моңын тапкач, бию көе уйнап жибәрде. Рокыя апа мине биергә чакырды. Аннары Сажидә кушылып китте. Мин, куркып, биюдән туктап калдым. «Туарылырга

тора бит, нишли бу җүләр маржа!» Әмма аны туктатырлык кына түгел иде. Башын артка ташлап, бармакларын чыртлатып очына гына... Бәйрәмнәр узды. Шәһәр кырыендагы үзәк колонка янында озак кына чират торып, ике чиләк су алып кайткан арада, Сажидәмнән җилләр искән. Күршеләр дә берни белми. Шулай да бер кыз бала күреп калган икән: «Апа менә шушы тыкырыктан менеп китте,—диде ул,—кулында таягы бар иде.»

Бу тыкырыкның очы бала тудыру йортына барып төртелүен белә идем мин.

Тизрәк телефоннан шалтыраттым. Җавап бирүче юк. Борчыла башладым. Мин суга киткәндә берни сиздермәде, бала кулмәге белән мавыгып калды Сажидә. Бәйрәм кызулатты микәнни? Арттырыбрак җибәрде шул «хәрәкәт»не. Бәлки, консультациягә генә киткәндер әле.

Телефоннан җавап ала алмагач, Сажидә киткән тыныч тыкырык буйлап больницага юнәлдем. Юк, бер дә тыныч түгел монда хәзер. Чын мәгънәсендә казлар ярминкәсенә әйләнгән. Яңа төртеп чыккан яшел чирәмгә сап-сары бәпкәләр сибелгән. Гайрәтле ата казлар, озын муеннарын сузып, ысылдап, узган-барганны йөгерә-йөгерә озатып калалар. Аннары бик хәтәр куанышып, каңгылдашырга тотыналар. Баланың ни дәрәҗәдә кадерле икәнен шуннан аңла инде. Миңа да шул ата казлар куанычын кичерергә язсын дип, елмаеп куям.

Тудыру йортының ишегеннән барып керүгә, ак халатлы чибәр туташ шатлыклы хәбәр белдерде:

—Малаегыз бар, абый, котлыйбыз,—диде,—барысы да тәртиптә. Бүгенгә берни дә кирәкми...

Бер катлы бик озын агач бина. Тәрәзәләре җигүле ат кереп йөрердәй зур. Челтәр пәрдәләр аша эчтәге бөтен хәрәкәт күренеп тора. Әнә баягы шәфкать туташы пәйда булды. Авызына ак марля каплаган, беләгенә курчак сыман төргәк салган. Күзләребез очрашуга, ул елмаеп, курчакның баш ягын миңа таба борды. Алсу нәрсә күренде. Авыз турысы кыймылдап ачылгандай итте. Малай кинәт көр тавыш белән кычкырып елап җибәрде. «Әттәгә сәлам!»—дип көлешеп алдылар эчтәгеләр. Сажидәнең караваты тәрәзә янында гына икән. Ул да башын калкытты. Ак яулык бәйләткәннәр үзенә. Йөзе бераз агарынган, тагы да чибәрләнә төшкән. Берни булмагандай елмаеп ята. Барысы да әйбәт. Шулай була күрсен! Кайтканда аякларым җиргә дә тимәде.

Бер бүлмәле кечкенә фатирда ниндидер унайлыклар өмет итеп булмый иде. Эш өстәле янында гына бала караваты. Аны ишек катына илтеп куймассың бит. Телефоннан сөйләшә башласам, йокыдагы Илдарыбыз дерт итеп уяна да, авызын почмакландырып, үпкә белдереп, еларга тотына. Планнарым сүтелә дә китә. Сажидә үз чиратында әбәт әзерли. Бала минем кулга күчә.

Кичләрен «ут» күршебез—район «Сельхозтехника» начальнигы Хәйдәровтан тынычлык юк. Эш сәгатьләре бетүгә ул исереп кайта. Кайчагында бортлы машинага сузып салалар да, колга буе гәүдәсен икегә бөкләп, өенә кертәләр. Андый очракларда ыңгырашу авазлары тынып тормый. Такта стенаны штукатурлаудан да файдасы тимәде. Йокы аралаш, күрәсең, күсәктәй кулын стенага аудара. Бала сискәнеп уяна, үкси башлый.

—Гәзиткә язгыгыз әле ичмаса шул пьянчукны, тәмам йөземне саргайтты,—дип хатыны ялынып та керде. Бу хакта мин Габдрахман абый белән киңәшләшеп карадым. Ул кинәт башын кашып алды да:

—Мин күптән күзегеп йөрим аңа,—диде,—эше әйбәт бара бит, чукынганның. Запчастьлар вакытында кайтып тора. Казанда тоткасы бар, ахры. Ярдәмчеләре дә бик үткен егетләр.—Габдрахман абый тагын чал башын кашып алды.

—Әйдә, бу эшне без хатын-кызга тапшырыйк,—диде,—андый четерекле мәсьәләне бездән остарак чишә белә алар.—Өстәп тә куйды:

—Сажидә аша, «ут күршеләр» дигән булып, кунакка чакырыгыз сез аларны. Сизмәстән генә шунда мин дә сугылырмын. Калганын үзем хәл итәрмен...

Күрше хатын белән Сажидә шунда ук уртак тел тапканнар. Зөбәрҗәт дигәнебез хәтта моңа сөенгән генә:—Только эчемлексез генә...

Ял көнне Сажидә белән бергәләп бәлеш пешердек. Анын борынны кытыклап торган тәмле исе, мөгаен, стена аша күршеләргә дә барып житкәндер. Билгеләнгән сәгатькә керделәр. Хәйдәров ап-аек иде. Кырынган, хәтта галстук таккан. Тактадан әмәлләгән өстәл, утыргычларны күргәч, бераз гажәпкә калды. «Нигә миңа әйтмәдегез? Ярдәмчеләрем бар минем»,—дигән булды.

Бәлеш өстәлгә утыруга, берни белмәгәндәй, Галиәкбәров килеп керде. Корреспондентны күрүгә, Хәйдәров кинәт сискәнеп куйды.

—Әйдәгез, Габдрахман абый, мактап йөрисез икән!—дип, сөенә-сөенә Сажидә каршы алды аны. Кунагыбыз буш кул белән килмәгән. Кулында бик матур уенчык. Габдрахман бабасын күрүгә улыбыз авызын ерып көлеп җибәрде. Икесенең дә авызлары ерылды.

Сүзне озакка сузмас өчен шуны гына әйтим. Хәл-әхвәл сорашып, бераз утырганнан соң:

—Очрашуыбыз бик әйбәт булды але,—диде Галиәкбәров, күршебезгә текәлеп,—сер итеп кенә әйткәндә, «Техснаб»ны райком бюросында тыңларга җыеналар бит. Миңа да берәр атна сезнең тирәдә чуалырга туры килер...

Хәйдәровның маңгаеннан кинәт тир бәреп чыкты. Кульяулыгын алып, битен сөртергә тотынды.

«Димәк, беткән кеше түгел бу,—дип уйлап куйдым эчемнән,—просто, азындырганнар моны»...

Шул көннән соң күршебез майлаган кебек йөрде. Аз-маз салып кайтса да, урынын идәнгә җәеп бирергә кушкан хатынына.

* * *

Минзәлә педучилищесының тел-әдәбият укытучысы Мөхәммәт абый Гарифуллин гажәеп тыйнак, ягымлы кеше иде. Гел елмаеп сөйләшер. Күз тирәләрендә нурлы вак җыерчыклар өзелми. Баштарак урамда очрашып үзара хәбәр алышкалап йөрдек. Газетада чыккан әйберләремне күзәтеп бара икән. Фикер алышу өчен дип, ул мине училище каршындагы әдәбият түгәрәге утырышына чакырды. Әдәбият кабинеты студентлар белән шыгрым тулы иде. Әлбәттә, араларында каләм тибрәтүчеләр алай ук күп булмагандыр.

Мөхәммәт абый берәм-берәм таныштыра башлады:

—Менә монысы безнең Газиз Мөхәммәтшин була, соңгы курста укый. Яна Бикчәнтәй авылы егете,—диюгә, зур гына башлы, нечкә муенлы, кара тутлы берәү торып басты. Карар күзгә бик житди. Басынкылыгы йөзенә чыккан. Сәер генә елмаеп куйды. Шигырьләр, хикәяләр яза икән.

Аннары ап-ак йөзле, көлсу чәчле, бәләкәйрәк кенә буйлы Марс Шабаев дигәне торып басты.

—Баскач-баскач, бер шигырь укыйм инде, абый,—диде дә «р» авазын гөрелдәтеп, дерелдәтеп дигәндәй, шигырь сөйләргә тотынды. Тагын, тагын...

Әдәбиятка ыргылучы яшь талантларга шактый бай икән Минзәлә районы. Шулар көче белән район культура йортында әдәби-музыкаль кичәләр уздырыла. Түгәрәк житәкчесе Мөхәммәт абый Түбән Тәкермән укытучысы Габделхәй Сабитов, шул ук авылдан Гөлшат Зәйнашева, Малтабар авылы егете, инде «Беренче хисләр» дигән шигырь җыентыгын чыгарып өлгергән Рәшит Гәрәев исемнәрен, тагын кемнәрнедер санап күрсәтте.

Гарифуллиннар ике бүлмәле җыйнак кына фатирда яшиләр иде. Аралашып тордык. Керә-керүгә үк Нәгыймә апа Сажидәне кочагына

ала. Шунда ук чөкердәшеп сөйләшергә тотыналар. Икесе дә тарих укыталар, хәтта бер-берләренен дәресләренә дә йөрешә иделәр. Аларны күбрәк тарих темалары кызыксындыра, сүзләре шул тирәдә йөри. Сажидә, гомумән, әдәби китапларны бик сайлап кына укый, башлыча тарихи әсәрләр белән кызыксына иде. Аларнын да фәлсәфиләре булсын. Жанны тетрәндерә торган шигырьләргә юлыкса, күчереп ала, күнеленнән ятлый.

Мөхәммәт абый безне чаршау эчендәге бер кешелек тимер караватбелән таныштырган иде. Бизәкле яшел жәймә уртасында биек мендәр кабарып тора. Шунын өстендә тагын кечкенә чигүле мендәр. «Ялгызаклар мендәре» дип тә йөртәләр андыйларны. Мөхәммәт абый уйга калып, дәшми-тынмый, беравык шуна карап торды. Ул вакытта анынниләр кичергәнен без сонынннан гына белдек.

—Менә бирдә...—дип сүзен башлады да ул, кинәт тынып калды.—Ярар, бер сөйләрмен әле.

Бөек юлбашчы үлеп, ай ярым чамасы үткәч, мина Мөхәммәт абый шалтыратты. Тавышында тирән дулкынлану сизелә. Хәтта тотлыгып та куйды:

—Күр-күрдегезме «Литературная газета»ны? 25 апрель санын...

—Юк, карап чыгарга өлгермәдем әле...

—Муса Жәлил шигырьләрен бастырган бит Константин Симонов! Әйе, Симонов ул чагында «Литературка»нын баш редакторы иде. Мин тиз генә өстәлдәге гәзит битләрен актара башладым. Әйе: «Маобит дәфтәреннән. Муса Жәлил шигырьләре»... диелгән.

Бу яналык мине шатлыктан тетрәндерде. «Сатлык жаннар» дигән кара тамга ничә еллар буе мәсхәрәләп торды жәлилчеләр исемен. Менә хәзер «Маобит» шигырьләре дөнья күргән. Әйе, бөтен дөньяга таралган.

Муса Жәлилнен сугышка Минзәләдән киткәнен белә идем мин. Аны күргән-белгән кешеләр Жәлил турында гел яхшы яктан гына сөйләделәр.

Шунда ук Мөхәммәт абыйларга йөгердем. Гарифуллиннар гаиләсе, әлбәттә, чиксез дулкынланган. Нәгыймә апа мин элегрәк күргән матур жәймәле кабарып торган карават янына килеп, елап та алды:

—Менә Муса Жәлил йоклаган карават... Занятияләреннән сон безгә еш килә иде, кунып та китәләде...

Истәлекләр, истәлекләр...

Мин Муса Жәлилнен Минзәлә тормышын ныклап өйрәнеп, «Кайнар эзләр» дигән әдәби очерк яздым. Аны 1953 елда баш редактор Гази Кашшаф исеменә «Совет әдәбияты» журналына жибәрдем. Ике-өч ай көтәм. Бернинди жавап юк.

Шагыйрь Муса Жәлил үзенен әдәби мирасын күренекле тәнкыйтьче, ышанычлы дусты Гази абыйга васыять итеп киткән булуын каян белим сон мин ул чагында?

Казанга баргач, мин редакторым Гали Хужи янына кердем. Очеркым турында сүз чыгардым, анын хәзергә билгесез язмышы турында әйттем.

Гали абый күзлеген бер киеп, бер салып сөртергә тотынды. Йөзен читкә борып, тәрәзәгә карады...

—Синен урында башка берәү булса, беләсенме нишләтер идем?!—диде ул, кинәт тураеп басып. Беразга тынлык урнашты бүлмәдә.

—Нишләтер идегез сон?—дип сорадым мин редактордан, бер дә исем китмәгәндәй.

Гали абый ирен чите белән генә елмайгандай итте, аннары йомшара төшеп:

—Менә шушы тәрәзәдән ыргытыр идем!—диде.

Редактор:

—Үз гәзитебезнен абруе турында уйларга иде башта,—диде дә сорап куйды:

—Караламасы үзен белән юкмы?

—Бар,—дидем,—чиста, кулдан күчергәне.

Папкадан кулъязманы чыгаруга, редактор аны йолкып диярлек кулымнан алды, тиз-тиз генә битләрен актарып чыкты.

—Миңа калдыр,—диде кискен генә һәм шул арада машинистканы да чакырып алды:—Ашыгыч!

Аннары ул:

—Казанда ничә көн булырга исәп?—дип сорап куйды.

—Ике-өч көн...

Казанда шактый буталып йөргәннән соң, Әгерҗегә кадәр поезд белән, аннары бер тәүлеккә якын трактор чанасында «шуып», Минзәләгә кайтып керүемә, кулына гәзит тоткан Сәҗидә сөенә-сөенә каршы алды мине:

—«Кайнар эзләр»еңне басканнар, дәвамы да бар, дигәннәр! Котлыйм!

Өстәлгә Казан күчтәнәчләрен чыгарып тездем. Аяклары җиргә тимәгән хатынымның тирәмдә бөтерелеп йөрүе, ике яше тулып килгән улыбыз Илдарның шунда ук кочагыма талпынуы куаныч өстенә куаныч өстәде.

* * *

Дәресләр бетүгә—нинди дер җыелыш. Яки үзешчәннәр түгәрәге репетициясенә кала Сәҗидә. Үзе җитәкләгән сыйныфын тәмам «аздырып» бетерде. Шигырь сөйләргә, җырларга, биергә ашкынып тора балалары. Дәресләреннән дә өлгерәләр. Концерт кичәләренә ата-аналары килеп, алары да шунда канәгать хис белән, авыз ерып утыра. Сәҗидәне бөтенләй үз иттеләр. Урамда очрашсалар, сөйләшеп сүзләре бетми. Тик Сәҗидә генә бик җәелеп китә алмый. Һаман ашыга. Сүзен матурлап түгәрәкли дә, ни өчендер рәхмәт әйтеп, барасы юлына ашыга. «Үзенә мең рәхмәт, кызым!» дип, аның артыннан күзләре белән озатып калалар.

Укучыларның ата-аналарына да тынгылык булмый иде. Яңа инсценировка яки кечкенә бер спектакль кисәге хәзерләгән саен, «артисләр»гә рольләренә карап, кием тегәргә кирәк. Иренмәделәр, зарланмадылар алай. Шулай ди иде Сәҗидә. Урта кул укытучы булуны күз алдына да китерә алмый иде ул. Бер-бер эшкә алынса, дөньясын оныта, аны җиренә җиткермичә туктамый да. Әйе, ярты-йорты булалмады. Аскардан җибәреп торган кадерле хатлары да моның тере шаһите. Шундый юллары искә төшә: «Миңа балалар җене кагылды, ахры. Шулар белән саташып яшим. Бүтәнчә булдыра алмыйм».

Минзәләгә инде ияләштек сыман. Сәҗидә белән Ык буенда, болыннарда йөрдек. Хәтта яр башыннан кармак белән балык тотарга да насыйп булды. Солдаттан ияреп кайткан әлүмин котелокта уха пешереп ашадык. Алай-болай балык эләксә дип, мин Сәҗидәдән яшереп кенә лавр яфрагы, суган, кара борыч кебек хикмәтләрне дә тыккан идем. Аш пешерергә миңа куш. Хатынның эштән кайтуына әбәт әзерләп тору минем гадәти эшемә әйләнгән иде.

Ык елгасы Камага кушылган урында үзен-үзе танымаслык хәлгә килә. Агымы сизелми дә диярлек. Киң дә, тирән дә. Әйтә төсле елга: «Күпме басу-кырларны, тугайларны урасам да, суым кимемәде. Киресенчә, арта гына барды. Ярларыма тулышып, сиңа кушылам, бөек Чулман. Ничек бар, шулай кабул ит».

Буа буйларында уйнап, үрдәк сыман, суда йөзеп үскән Сәҗидә биредә дә тыелып калалмады. Мин абайлап өлгергәнче, күлмәген салып ал купальниктан суга сикерде. Талгын гына колач сала-сала, аргы якка таба йөзеп китте. Елганың киңлеге монда кимендә өч-дүрт йөз метр бар. Әле артыграктыр да. Алай-болай бата гына күрмәсен дип курка калдым. Әкияттәге тавык сыман, яр башыннан гына күзәтәм. Чөнки йөзә белүем чамалы. Безнең авыл малайлары бит бала чактан ук инеш суында гына пычтырдап үсте, шул исәптән мин дә. Ул көнне Сәҗидәне көчкә алып кайттым Ык буеннан.

Көзгә таба, томанлы вак яңгырлардан соң, Минзәлә елгасының челтәрле тимер күпере аша чыгып, каен урманына гөмбәгә баруыбыз хәтердә. Күз явын алырдай шигъри, пөхтә ак каеннар арасында гөрeждә җыйдык. Икебезнең дә кулда үткен пәке. Тамырына зыян китермичә, гөмбәне иплəп кенә сабагыннан кисеп аласың. Очраган берсенә алтын тапкандай сөенәсең. Бүтән берни турында да уйлыйсы килми. Шуннан да әйбәтрәк ялны каян табасың тагын.

Өяләмә ике кәрзин гөмбә күтәреп кайтканда безгә берничә татар хатыны очрады. Базарчылар иде, ахры. Үзара шаулашып сөйләшкән арада, берсе әйтә куйды: «Менәү чибәр сары маржа ник юан? Мәшкә ашап симерәләр алар».

Без көлемсерәп кенә узып киттек. Ул вакытта Сажидәнең икенчесенә авырлы булып йөргән чагы иде.

* * *

Белем, мәдәният нурлары чәчеп торган педучилище, күчмә татар драма театры, үзенә күрә оркестры һәм музыка мәктәбе булган Минзәләне, аның ачык күңелле, сүзгә һәвәс кешеләрен якын итеп өлгерсәк тә, барыбер монда төпләнеп каласы килми иде. Мин—Казан һәм Мәскәү, Сажидә Уфа рухы белән яшәп караган кешеләр буларак, безгә нидер җитми бирәдә. Нәрсәнедер юксынабыз. Ничектер үзенне ерак утрауда яшәгәндәй тоясың. Гүя күге дә тәбәнәк, кичен йолдызлары да сүрәнрәк яна сыман. Мин үземне әдәби орбитадан ычкынгандай тоеп яшәдем.

1955 елның башында, әнисенең нәкъ күчермәсе булып, зәңгәр күзле, житен чәчле кызыбыз дөньяга килде. «Менә безнең алтын байлыгыбыз!»—дип куандык икебез дә. Ана Миләүшә дип исем куштык. Сажидә бала отпускасы алу турында уйламады да. Ул чагында булды микән әле андый отпускалар? Бюллетене ябылуга, әнисе янадан мәктәп эшенә чумды. Миләүшәне ул күршедәге бик ягымлы татар хатынына куеп йөри иде.

Өй эшләрен без бергә башкардык. Кем нигә сәләтле, нәрсәгә өлгерә ала. Кышкы салкын иртәләрдә, күз ертып, карангыдан торасың да, кат-кат төрелгән малайны бәләкәй «кашевка»га утыртып, балалар бакчасына юнәләсең.

## Институт дәште

Онытып бетермәгәннәр икән әле. 1953 елның апрелендә Әдәбият институтыннан хат килеп төште: «Академик отпускагыз төгәлләнеп килә. Алда нинди планнарыгыз бар?»—дигәннәр.

—Укуыңны читтән торып дәвам итәргә кирәк,—диде Сажидә икеләнергә урын калдырмыйча,—контроль эшләреңне язганда аз-маз үзем дә булышырмын.

Ни әйтсәң дә, Уфа пединститутының тарих факультеты дипломын «отлично»га яклаган укытучы бит.

Көтелгән июнь урталарында, топольләр мамык очырган чакта, Мәскәүгә килеп җиттем. Исәнме, Тверь бульвары! Исәнмесез, Башкортстан шагыйре Рәми Гариповның Переделкино урманнарыннан күчереп утырткан яшь үсентеләре!

Бу юлы безне, ягъни читтән торып укучыларны Переделкинога түгел, ә институт ишек алдындагы бер катлы таш бинага урнаштырдылар. Өчме-дүртме бүлмә. Мин урнашканында унбиш карават тезелеп киткән иде. Күбесе әле буш. Үзең теләгәнне сайлап ал.

Бераз тын алып, үземне тәртипкә китерүгә, бәй, күземә ялгыш күренәме дип торам, кулына чемодан тоткан Шәрәф Мөдәррис килеп

керде. Ул да заочник икән бит. Янында тагын берәү. Очучылар формасыннан. Миңа артык игътибар итмичә, болар теттереп чуашча сөйләшәләр. Мөдәррис чуаш классигы Константин Ивановичның «Нарспи» поэмасын оригиналыннан татарчага тәрҗемә иткән шагыйрь, янәшәдәге чуаш авылы үсмерләре белән бергә укып үскән малай шул. Тиз арада без кочаклашып күрештек тә.

—Кичә чибәр булып төшемә кергән идең,—диде Шәрәф, дусларча шаяртып.—Ә менә бу иптәш чуаш язучысы Владимир Садай.

Тегесе ачыклык кертте:

—Әтием буенча Цырульников...

Бераз сөйләшә торгач, шунысы ачыкланды: Садай сугышта очучы булып катнашкан, хәрби хезмәтен хәзер дә дәвам итә икән. «Очучылар» дигән романы рус теленә тәрҗемә ителгән. Шәрәф аны чуашчадан татарчага әйләндерергә җыенуын белдерде.

Мин инде Шәрәф Мөдәрриснең Шекспир сонетларын турыдан-туры инглиз теленнән татарчага аударып, китап чыгарганын белә идем. Немец телен сугышта өйрәнгән. Бик кирәк чагында дивизия штабында аны тәрҗемәче итеп тә файдаланганнар. Казанда яшәгәндә Шәрәф белән еш аралашырга туры килде. Усал, туры сүзле, икейөзлеләрне җене сөйми. Өлкәнрәк язучыларны үз дәрәҗәсенә куеп, «син» дип кенә сөйләшә. Кеше буларак, гаҗәеп тугрылыклы, намуслы иптәш. Җыеп әйткәндә, батырлык җырчысы, кайнар канлы трибун шагыйрь. Дулап китәргә дә күп сорамый.

1949 елда институтка китәр алдыннан, ахры, мине ул:

—Солдат погонын салгач, язмый башладың, лодырь!—дип шелтәләде. Шул соңгы сүзе йөрәгемә ук булып кадалды, маңгаемнан салкын тир бәреп чыккан иде. Нинди шартларда яшәвемне белә иде югыйсә. Шунда ук юаткан да булды:

—Мин бит яраткан, ышанган, өметле каләмдәшләрне генә сүгәм. Ә җәфа булып, әдәбият тирәсендә буталучыларга сәлам дә бирмим.

Ләбибә Ихсанованы исә университетның геология факультетында укыган вакытыннан белә идем. Аның «Көмеш елга» исемле повестен радиода эшләгән чакта инсценировка ясап тапшырдык. Кат-кат сорап хатлар килде. Гел елмаеп сөйләшә торган шул Ләбибә артыннан «чапкан» чагы иде Мөдәрриснең. Лекцияләре беткәнче үк университетка барып торыр иде...

Шәрәф Мөдәррисне күргәч, күңелемдә шул истәлекләр янарды.

Бүлмәбез шыгрым тулды, Шәрәф белән Садайдан башка бер танышым да юк. Төрле өлкәләрдән, автономияле республикалардан җыелган ят заочниклар. Көненә сигезәр сәгать лекция. Өстәвенә, кичләрен имтиханнарга хәзерләнергә, калын-калын томнарны күздән кичерергә кирәк.

Читтән торып уку, бигрәк тә әдәбият институтында, җәза белән бер икән ул. Эттәй арый башладым. Күп укудан баш-күз сызлый. Йокының рәте бетте. Төнлә ачык күз белән ятсаң, иртән торуга, әлбәттә инде син кеше түгел. Менә кайчан кирәк булды теге барбамил дарулары. Шәрәфнең дә хәле шәптән түгел, ахры, йокысызлыктан зарлана. Бер көнне иртә белән сүгә башлады бу мине:

—Йокым начар дигән буласың, фәлән-фәсмәтән. Яту белән мышнап, әвен базарына олагасың.

Дәшмәдем. Китапны куеп ятар вакытлар житкәч, «нишләр икән бу?»—дигән сыман, Шәрәф мине күзәтә шикелле. Тумбочка эченнән теге йокы порошогын алдым да, артым белән борылып авызга койдым.

Төн урталарында сискәнеп уянсам, майка, трусиктан кемдер минем тумбочкам эчендә актарына. Шәрәф булып чыкты.

—Дустым, авызыңа кабып яткан теге ниеңне бирче,—дип, ялына башлады бу.

—Бирүен-бирәм, ә уяна алмый калсаң?!

—Давай-давай, мин сиңа караганда чыныкканрак!!!

Чыныгуын-чыныккан да бит. Ә иртән лекциягә бара алмыйча калды. Төрткәләп тә карадым—икенче ягына борылып кына ятты. Ярый, исән икән әле дип, институтка киттем. Көндез хәлен белергә дип кайтсам, сәгатенә карый-карый, киенеп ята бу.

Античный әдәбияттан имтиханны иң ахырдан биргән.

—Кырып салдым сорауларын. Античный әдәбияттан Варфоломей төне ясадым, малай,—дип мактанган була. Кыш буе җыйган кадерле даруымны дустым белән кап урталай бүлешергә туры килде.

Профессор Поспеловтан студентлар бераз шүрли иде. «Бәйләнчек, артык пунктуальный» дигән сүзләр йөри. Әдәбият теориясе бит. Һәр галимнең үз карашы бар ана. Ә Поспелов исә гел үзенекен сөрә.

Шәрәф тә төшеп калганнардан түгел. Әдәбият теориясе мәсьәләсендә үз фикерендә нык торуын профессор Поспеловка ныклап исбат итә. Бик озак бәхәсләшәләр. Ишек төбендә чират көтеп торучы студентлар, бүртенеп, кызарынып чыккан Мөдәррисне күргәч, шиккә калалар:

—Куып чыгардымыни?!

—Ну, Шәрәф, без керер алдыннан гына кәефен кыргансың икән профессорның!

Шәрәф Мөдәррис эре генә зачеткасын күрсәтә:

Анда «Отлично» билгесе куелган. Гомумән, Шәрәф барлык имтиханнарны да отлично һәм яхшы билгеләренә генә бирде. Мин дә алай аңардан бик калышмаска тырыштым.

* * *

1955 елның августында Әлмәткә күченергә булдык. Ул кинәт кенә килеп чыкты. Гәзит редакциясендә штат кыскарту башланды. Өч урынына, бер генә хәбәрче кала икән. Һәм ул нефть төбәгендә яшәячәк. Бу турыда Казаннан яна редакторым шалтыратып әйтте: «Йә, нишлибез?»—дип сорады.—Бүтән эш табып Минзәләдә каласыңмы, әллә сон Девон хәзинәсе ургыган якка юл тотасыңмы?»

Сәҗидә белән бер-беребезгә карашып алдык. Ул елмаеп, балаларча кулларын чәбәкәйләде: «Күчәбез, Әдип, күчәбез!»

—Кайсы шәһәргә? Әлмәткәме, Бөгелмәгәме?

—Энә каян—җеп шуннан. Син булгач, миңа кайда да ярый.

Әйе, монда кысанлыкта яшәп, тәмам туйган идек инде.

Разведка ясап кайту өчен, очраклы машинага утырып, Әлмәт ягына кузгалдым. Эссе август кояшы астында көне буе кузовта чайкалдым.

... Яна калкып килгән Әлмәт шәһәрен берничек тә аңлый алмадым. Кая карама—кызыл балчык өемнәре, озын траншеялар. Кичкырын Бигәш белән Әлмәт арасында машинадан төшеп калгач, озак кына аптырап тордым. Кая барып сугылырга? Җыелма агач йортлар, фин коттеджлары... Бетон баганаларда электр утлары балкый. Узган-барганнан: «Шәһәр кунакханәсе кайда?»—дип сорагач, аптырадылар. Әле ул төзелеп кенә ята икән.

Ике катлы таш бина янына килеп туктауга, эчемә җылы керде: «Бурконтора кунакханәсе» дип язылган бит ишек башына.

...Иртән торып, эшчеләр ашханәсендә тамак ялгап алгач, шәһәр редакцияләрен эзләп таптым. Әлмәт белән танышуны шунда дәвам итәргә уйладым. Урыс, татар редакцияләре һәм типографияләре дә бер агач баракта урнашкан. Коридорда борылыр урын да юк. Идәннән түшәмгә кадәр кәгазь рулоннары өелгән. Шулар арасында кызыл тырнаклы бер хатын-кыз папирос көйрәтеп тора. Абайлап алып:

—Таисия Ивановна!—диюгә, ул сискәнгәндәй итте һәм мине шунда ук таныды.

—Ой, кемне күрәм, әйдә минем кабинетка!—дип, култыклап та алды.

Менә бит җае килеп тора. Әллә бәхетем бар инде дип, сөенеп тә

куйдым. Без бу ханым белән Казанда, радиода өч ел бергә эшләп, хезмәт буенча нык аралашып яшәдек. Таисия Ивановна Зарогацкая шагыйрь Мөнир Мазунов белән бер бүлмәдә утыра, икесе дә «Соңгы хәбәрләр» редакторы иде. Иң беренче яңалыкларны алардан ишетә идек.

—Нинди язмышлар ташлады?—дип сорау ала башлады Таисия Ивановна.—Минзәләдә икәнеңне ишетеп беләм, ничек яшисең анда? Әлмәткә күчәргә уйламыйсыңмы?

Иң кирәкле ноктага кагылды бит бу, рәхмәт төшкере!

—Кил, теләсәң, бүген үк квартир була!

Үз акылында микән бу, әллә мин саташаммы дип аптырадым. Берберебезне сынагандай, күзгә-күз карашып куйдык.

—Дөресен әйт, Әдип, бу бик важно минем өчен, хатының әйбәтме?—дип, көтелмәгән сорау бирде ул шунда.

—Кешелекле, сабыр холыклы,—дидем, мондый кызыксынуның төбендә ни ятканын аңларга тырышып.

—Гафу ит, тагын бер сорау, балаларыгыз ничәү?

—Икәү.

—Менә нәрсә,—диде ул, эшлекле сүзгә күчеп,—зур гаиләле нефтьче өйдәш күршеләрем яңа квартирга күченергә торалар. Төенчекләре төйнәлгән. Үзем зал якны алсам, калган ике кырый бүлмәләр бушап кала. Ялгыз икәнемне беләсең, Әдип, мин бит белмәгән-күрмәгән теләсә кемне кертә алмыйм янымa. Бер кухняга ике хатынның сыюы да кирәк бит әле...

—Ике куллап риза!—дидем мин, күктән төшкән көтелмәгән бәхет елмаюына куанып.—Ә шәһәр Советы ни әйтер?!

—Шәһәрнең чын хуҗалары юк хәзергә. «Тайга законы» монда. Кем ничек булдыра ала. Калганын үзем җайлармын. Только бик тиз, шушы ике көн эчендә хәл итәргә кирәк.

—Сезгә ышанам мин, Таисия Ивановна!

Ялгыз хатынның күзләренә яшь килде:

—Рәхмәт яхшы сүзең өчен. Кешегә ышанычың булмаса—бергә яшәп тә булмый бит.

Башка беркем белән дә күрешеп тормыйча, юл унай туры килгән йөк машинасына утырып, тизрәк Минзәләгә сыздым. Тәвәккәллек алдамас, төянеп килсәк, балалар белән урамда калдырмаслар әле, дип ышандырдым үземне.

Минзәләгә кайткач, Сажидә белән бер-ике сүз алыштык та, шәһәр Советына чаптым. Фатирны тапшырырга кирәк бит. Ак чәчле шәһәр башлыгы, шуны гына көтеп торгандай, кулымны кысып, рәхмәт белдерде, хәерле юл теләде. Төзелеш бармаган Минзәлә шәһәрендә бер бүлмәле фатир бушап кала бит. Димәк, мин дә кемнедер бәхетле итә алам.

Автоготадан ике тәүлеккә түләп алган «полуторка»га төядек тә, ярты лаш буш кузовта шалтор-шолтыр килеп, юлга кузгалдык.

«Юл газабы—гүр газабы»на ук әйләнмәде алай. Көн аяз, август әле җәй көчендә, иң мөһиме—күнелләребез киләчәккә өмет белән тулы иде. Миләүшәбез, әнисе алдында тирбәлеп, күбрәк вакытын йоклап уздырды.

Без төялгән машинаның шоферы Әлмәттә күп тапкырлар булган икән. Берәүдән дә сорап тормыйча, туп-туры редакция янына килеп тә туктады. «Знамя труда» газетенең җаваплы секретаре Зарогацкая безне каршыларга үзе йөгереп чыкты. Минем төгәллекне эш буенча белә иде ул. Көтеп, күзәтеп торган, күрәсең. Аның беренче карашы матрац, мендәрләр арасында җайлы оя корып утырган Сажидәгә һәм әниләренә елышкан Илдар белән Миләүшәгә төште.

—Ай, какие хорошенькие!—дия-дия, хәтта берәм-берәм күрешеп тә чыкты. Редакциядән тагын кемнәрдер күренде.

—Төкле аягыгыз белән!—дигән сүзләр ишетелде.

... Әле үзебез күрмәгән, аяк басмаган «сборно-щитовой» йорт Грибоедов исемендәге урамда икән. Ул язучының монда ни бәйләнеше

бардыр? Урам әле төзелеп кенә ята. Кая карама—сары ком, вак таш өемнәре. Машинадан төшүгә, Илдарыбыз томырылып, шул тарафка йөгерде. Бер «тау»ның башына менеп басты да чәрелдәп кычкырып җибәрде: Ур-р—ә-ә-ә-!

—Сыбызгы!—диде Зарогацкая, яратып кына.

—Беренче биеклек алынды!—дип, шатланып көлеп җибәрде әнисе. Мин, солдат акылы белән: «Сугышта сугышмыйча гына стратегик биеклек алуга тиң инде бу яңа урын»,—дигән нәтиҗәгә килдем.

—Фатирыбыз беренче катта икән.

—Әйдәгез, үз өегез дип белегез. Сез бүгеннән Әлмәтлеләр!—диде булачак күршебез, безне артыннан ияртеп.

Иң әүвәле үзебез яшәячәк бүлмәләргә күз салдык. Алар әлләни зур түгел. Әмма һәркайсы Минзәлә фатирына торырлык. Стеналарга чәчәкле яшел обойлар ябыштырылган. Күзне иркәли, ял иттерә торган төсләр. Кухня, ванна краннарыннан гөҗләп су килә. Таисия Ивановна шунда ук газ плитәсен кабызып җибәрде: «Башта чәйләп алабыз»,—диде.

Үзәктән җылына торган йорт булгач, үзебезгә ияреп килгән күмер чүлмәгенең дә, соскы һәм ухватның да кирәге калмас. Чәчәкле көянтәнең дә... Әйдә, Минзәлә истәлекләре булып калырлар.

Киртләч-киртләч Зәй таулары, биек нефть вышкалары белән бергә, Яңа Әлмәт безне яңача каршы алды. Шушы төбәктән Сажидә сихри шигърият мәйданына юл сапты...

Шәһәр төзелешендә бөтен ил диярлек катнаша. Арзанлы девон байлыгын тизрәк чыгару, суыртып алу һәм озату өчен хөкүмәт техниканы кызганмый. Бәйрәм демонстрацияләре уза торган трибуналы урамны эзли торгач, сөңгеле тимер рәшәткәләр белән уратылган яшь парк янына килеп чыктым. Тигез рәтләр булып тезелгән нәзек каеннар, яшь имән, тирәк агачлары сизелер-сизелмәс искән йомшак җилгә дә башларын чайкап куйган булалар.

Парк башында ике катлы өр-яңа мәдәният сарае масаеп утыра. Яшь шәһәрнең бердәнбер бизәге, йөзек кашы. Булачак урам мәйданында—тактадан ясалган бәйрәм трибунасы.

Горький исемен йөрткән клуб алды белдерүләр белән чуарланган: беренче сентябрьдән хор, баян, тегү-чигү, драма... түгәрәкләренең эшли башлавы турында язылган анда. Шулар янына күңелемнән әдәбият-иҗат түгәрәген дә өстәп куям. Нигә әле ул гына ятим калырга тиеш. Эчкә узам. Тынлы оркестрчылар репетициягә җыйналган икән. Клуб мөдире Мөнирә Шәйхетдинованы (мин аның белән танышып өлгергән идем инде) күреп, оркестр турында кызыксынгач, ул киң елмаеп, горурланып җавап бирде:

—У-у, шәһәребезнең беренче оркестры туа бит! Бәйрәм демонстрациясенә хәзерләнәләр.

«Беренче оркестр»... Шигырь темасы бит бу! Мин моны хәтеремә салып куйдым. Әйе, җырсыз, моңсыз, музыкасыз нинди шәһәр инде ул! Культура йорты каршында әдәбият-иҗат түгәрәге учагын да кабызып җибәрү турында сүз башлагач:

—Соң, әйдәгез, күңелебез киң,—диде Мөнирә апа, йөзен балкытып—ничек тә сыярбыз.

Миңа шул ризалык кына кирәк иде. Тәҗрибәм юк түгел. Пермь татар педагогия училищесында укыган елларда ук әдәби хәрәкәтнең уртасында кайнадым. Ә Горький институтында укыганда поэзия семинарларында катнашу, Михаил Светлов, Евгений Долматовский, Михаил Луконин кебек олы шагыйрьләрнең эмоциягә бай чыгышларын тыңлау, ярсый-ярсый шигырьләр тикшерү... Тегермәнгә керсәң, онга буялмыйча чыкмыйсың, диләр бит.

Клуб директоры Мөнирә апа Шәйхетдинова белән сөйләшкәннән соң, тагын бер белдерү эләргә урын табылды. Шәһәр гәзитендә «1955

елның 15 сентябрендә Максим Горький исемендәге культура йортында татар әдәбият-иҗат түгәрәгенең беренче утырышы була» дигән белдерү дә басылып чыкты.

Күзге караңгы кич. Резина итекләрдән пычрак ярып, клуб янына килеп туктауга, каршыма кыяр-кыймас кына ике егет килеп басты. Танышабыз:

—Җәмит Рәхимов.

—Илдар Әхсәнов.

Корреспондент гадәте буенча, шунда ук төпченә башладым. Беренчесе—киң кашлы, түгәрәк йөзле, эрерәк сөяклесе—Иске Шөгер авылыннан булып чыкты. Бәлки яшьлек романтикасы белән җилкенеп килгәндер. 1935 елгы. Колхозчы гаиләсеннән, урта белеме бар. Промыселда оператор булып эшли икән.

—Язасызмы соң?

—Аз-маз маташтырам,—диде Җәмит, игътибар күрсәтүгә канәгатьләнү тойгысы белдереп,—вакыт кына җитми.

—Ә сез, Илдар?

Бу сорауны бирүгә, егет кызарынып, башын аска иде:

—Әллә шунда...

Әле сакал-мыеклары яңа төртә башлаган егетләрне ияртеп, клубка кердек. Ул кичне безгә түгәрәк утырышы өчен аерым бүлмә эләкмәде. Булган кадәресен үзешчәннәр «яулап» алган. Әле ярый, икенче катка күтәрелә торган бетон баскыч астында бер куыш бар икән. Аны клуб рәссамы, фанердан стена корып, үзе әмәлләгән булып чыкты. Түшәмдә (ягъни баскыч астында) балкып зур лампочка яна.

Борчуга төшкән клуб директоры шунда кереп сөйләшүгә, башына буйлы кепка чәпәгән, ачык киң маңгайлы, чандыр гәүдәле берәү:

—Әйдәгез, әйдә, көтелмәгән кунакларга мин бик шат,—дип, ике куллап күрешеп чыкты,—зинһар түрдән рәхим итегез!

Очкылык тоткан сыман, көлә-көлә сорап та куйды:

—Сез ризамы мондый комфортка?!

Риза булмый хәлең юк. Ничек кирәк алай җайлашып утырышкач, хуҗа тантаналы поза алып, үзе белән таныштырды:

—Республиканың атказанмаган драматургы Кәлмәди! Аннары тонын киметеп, төзәтмә кертте:

—Монысы юмор өчен генә, иптәшләр. Сәет Ганиевич Кальметов дигән кеше булам мин.

Мин сагая төштем. Татар академия театрында сугыштан соң шаулап барган «Тын Алан шаулый»ның авторы була түгелме соң бу?! Менә кайда күмелеп ята талант!

Сөйләшергә, аралашырга сусаган, күрәсең. Кальметов дилбегәне шунда ук үз кулына алды. «Без Берлинны штурмлаганда...» дип, сугышта үзенең танкист буларак катнашканлыгын да, Иске Әлмәттә кыйшайган өйдә кеше өстендә яшәүләрен дә, кара мунчада, сукыр лампа яктысында яңа әйбер «әмәлләвен» дә... бер-бер артлы хәтеребезгә салып куйды:

—Гениальный әйберләр төнлә туа, егетләр,—диде.

Сәет, рәссам буларак, Әлмәт күчмә театрында да эшли икән, театрга ияреп, гастрольләргә дә чыккалый.

Шулай итеп, Әлмәттәге иң беренче «утырыш»ыбыз яшь драматург Сәет Кальметов белән танышудан башланды...

Көтмәгәндә Татарстан Язучылар союзыннан хат килеп төште. Өметемне ныгытып җибәрде ул. Күңелем алдан ук нидер сизенеп, дулкынланып, хатны укырга тотындым:

«Хөрмәтле Әдип иптәш Маликов!

...Үзегезнең дә язучы кеше булуыгызны һәм әдәбиятка хөрмәтле карашыгызны искә алып, уртак эшебездә—әдәбиятның алмашчы көчләрен хәзерләүдә Язучылар союзына ярдәмгә килүегезне үтенәбез. Шундагы җитәкче иптәшләр һәм әдәбият укытучылары белән сөйләшеп, язу дәрте

булган яшьләрне барлап алсагыз һәм редакция каршындамы, татар урта мәктәбе янындамы әдәбият түгәрәге эшләтеп җибәрүне оештырсагыз икән.

...Ничек кенә булмасын, без сездән бу турыда үзегезнең конкрет фикерләрегезне көтеп калабыз.

Сәлам һәм хөрмәт белән:

Татарстан Язучылар союзы правлениесе председателе урынбасары—С. Хәким

Правлениенең җаваплы секретаре—Ф. Хөсни.

28.IX. 55 ел.»

Яшь язучыга карата ихтирам һәм ышаныч күрсәтү ярылып ята иде бу хатта. Өстәвенә «үтенәбез!» дигәннәр бит әле. Ун ел элек Сахалинга, мин фәкыйрегезгә әдәби кулын сузган, «Атаудагы хисләр» поэмасын журналга тәкъдим итеп, мина канат куйган Фатих Хөсни, сугыштан кайткач, Тукай клубында бергә әдәби кичәдә очрашу үткәрергә насыйп булган Сибгат абыйлар дәрт өстенә дәрт өстәделәр.

Форсаттан файдаланып, шул көнне үк партия шәһәр комитетының пропаганда бүлеге ишеген шакыдым. Ул чагында бүлек мөдире булып, янарак кына килгән Наилә Закировна эшли иде. Очраштык, сөйләшеп киттек. Казаннан килгән хатымны күрсәттем. Наилә Закировна хатны укып, кулында әйләндергәләп:

—Барыбызга да кагыла бу хат,—диде сөенеп,—әйдәгез, бергәләп уйлашыйк. Бер баракта укмашкан ике редакция һәм типографиядә урын табылмас. Ә менә татар урта мәктәбен күз алдында тотсак?!

—Мин Горький клубы директоры белән килешкән идем инде. Безгә шәһәр масштабы кирәк бит,—дидем.

Наилә Закировна йөзен балкытып, көлеп җибәрде:

—Әлбәттә инде! Сезгә колачны кинрәк җәяргә кирәк. Дөрес әйтәсез. Әйдәгез, бердәнбер үзәк клубны файдаланыйк. Мин аларга хәбәр итәрмен... Мәсьәлә хәл ителде дип саныйк.

* * *

Масштаблы, озакка исәп тотылган төзелешләрне мин сугыш кырына охшатам. Берөзлексез машиналар ыгы-зыгысы, көндез дә, төнлә дә тынып тормый торган мотор тавышлары. Тауларны шартлаталар. Җирне телгәләп, озын траншеялар уза, тирән чокырлар казыла. Төннәрен офыкларга үрләгән, болытларны кызарткан газ факеллары балкышы, җир тулы тимер-томыр өемнәре... Әгәр солдат күзлегеннән карасаң, каты һөҗүм вакытында авыл-калаларны кызганып тормыйлар, җиңү хакына бөтенесен утка тотып, җимереп узалар. Юк, монда калалар җимерелми, алар төзелә. Ә менә урыны-урыны белән уңдырышлы җирләрнең структурасы җимерелә бара. Нефть белән аралашкан туфрак дистә еллар буе уңыш бирмәячәк...

Бер яктан—шулай, ә ил масштабыннан карасаң—хөкүмәтебез хаклы булган бит. Менә, күз алдында алма тәгәрәтердәй асфальт юллар сузыла. Алар безнең төшебезгә дә кермәгән. Әкияттәге сыман яңа калалар калкып чыга. Йортларга газ керә, утын кайгысы бетә. Нәтиҗәдә урманнар янга кала. Яңа ачылган кибетләр күз күрмәгән байлык, нигъмәт белән тулган. Хаклары да кыйммәт түгел. Эшләгән кеше акчаны да «көрәп» ала. Кемгә зыян монардан?

Сугышта җимерек хәленә килгән Илне тергезергә, аякка бастырырга кирәк иде. Димәк, мондагы бөек һөҗүмне туктатып булмаячак хәзер...

Шушы төзелеш шау-шуында, үз тавышын таба алмыйча, күпме талантлы яшьләр адашып, югалып йөриде. Очрашасы, барлыйсы, күңелләренә оеткы саласы иде шуларның. Тиешле игътибар, нигндидер этәргеч булмаса, талант дигән тылсымлы көч йомылып, сүнеп калырга да бик мөмкин.

Казан буенча ук таныш Миңлебай егете Шамил Бикчуринның биредәге төзелешләрнең берсендә эшләгәнен беллем. Республика гәзитендә

анын ачынып язылган тәнкыйть мәкаләсен дә укыганым бар иде. Адресын белеп, Шамилне эзләп таптым.

...Киң һәм озын баракның уртасыннан баштан-башка ярым караңгы коридор сузылган. Ике яктан да ишекләр, ишекләр... Сөйләшкән тавышлар ишетелеп тора. Кемнеңдер гармун уйнаганы да, балалар елаганы да...

Мин кергәндә, Шамил, җылылык батареясы ягына артын куеп, идәндә бөгәрләнеп ята иде. Чигәләренә аерылып төшкән көлсу чәчләре, зәңгәр күзләре белән Такташны төсмерләткән егет—шул үзе бит бу! Мин бит Казанда радиода эшләгәндә аны, театр училищесы студентын, Тукайның «Шүрәле»сен укырга микрофон алдына чакырган идем. Аны тыңлаганда урынымда утырып тора алмадым. Булачак артистның эфирдагы шүрәлесе күз алдыма килеп басты.

—Әдип абый!—дип, ул шунда ук мине танып алды. Урыныннан кузгалырга итте, ләкин уфылдап, янадан ятты:

—Төзелештә билемне кузгаттым,—диде ул гафу үтенгән сыман, уңайсызланып.—Врачлар «хондроз» ди. Хандрит итәм, янәсе. Хәзер ышаныч бетте миңа...

—Төзүчеләрнең тетмәсен теткән теге усал мәкаләң өченме әллә?—дип сорадым мин,—гәзиттә укыган идем.

Шамил аклану ягын каерды:

—Мин бит анда төзүчеләргә таш атмадым. Трест башындагы җитәкчеләрне камчылаганыем. Менә үз сыртыма төште ул камчы. Эш горком бюросына барып җитте...

Бикчуринны бик теләп тотынган комсомол эшеннән гади ташчы итеп күчерәләр. Ул югалып калмый. Лепщик һөнәрен үзләштерә, Чупай ташыннан салынган яңа йортларның эчке стеналарын, түшәмнәрен, извест һәм үзле балчыктан «коеп» ясалган чәчәкле орнаментлар белән бизи башлый...

—Әлмәт барьерларын гына сикереп узарга көч табарсың әле,—дип, аны үземчә юатырга тырыштым. Горький исемендәге клубта булачак алдагы әдәбият түгәрәге утырышына чакырдым.

—Рәхмәт, рәхмәт җылы сүзегез өчен,—диде Шамил, ышаныргамы-юкмы дигәндәй, башын кашып,—ничек тә килергә тырышырмын, Әдип абый...

Чираттагы утырышыбыз клуб китапханәсе бүлмәсендә узды. Унбишләп кеше җыелды. Шулай итеп, беренче беркетмәбез дә барлыкка килде. Шунысына сөендем, Шамил Бикчурин да бирердә иде...

* * *

Әлмәттә татар әдәбият түгәрәге барлыкка килгән дигән хәбәр тиз таралып өлгерде. Юк, түгәрәк кенә түгел, әдәби берләшмә хәзер. Төзүчеләр, нефтьчеләр белән бергә, республика корреспондентлары, редакция хезмәткәрләре дә катнашып, аралашып китте. Миңлебай, Тайсуган авылларыннан да киләләр.

Мәскәүдәге Горький институты белән Әлмәттәге Горький клубы ничектер кардәшләр, аваздашлар булып тоела иде миңа. Бирердәге иҗат атмосферасы шуңа дәлил. Яшь рәссамнар, үзешчән артистлар, яңа туып килгән оркестр... Бигрәк тә әдәби берләшмә утырышлары... Соңгысы институттагы поэзия семинарларын сагындырып искә төшерә. Илдә танылган шагыйрьләрнең семинарларында катнашу олы иҗат дөньясына күземне ачты. Шулар йогынтысын көчемнән килгән кадәр, азмы-күпме бирергә дә күчерәсе иде.

Шигъри детальләр арзан гына бирелми шагыйрьгә. Аны йөрәк каны белән түләп алалар. Яшь авторларны ничек тә шуңа ышандырасы килә иде. Үз эченә йомылып йокымсырап йөргән талантларны уяту, хәрәкәткә китерү өчен уңай атмосфера тудырырга кирәк. Горький клубында җыйналып сөйләшү бигрәк тә шуның өчен тансык иде безгә.

* * *

Ире кыек юлда йөрсә, хатын-кыз моны бик тиз абайлый: күз карашыннан, үз-үзен тотышыннан, хәтта сулышыннан да сизә. Кичләрен минем соңлап кайтуымны Сажидә алай шик астына куймый иде. Ышана, димәк. Ә шулай да отчет алмыйча калмый: «Берләшмә утырышына кемнәр килгән?» «Ниләр укыдыгыз?» «Сөенердәй әйберләр бармы?» һәм башкалар.

Андагы тәэсирләрем белән иркенләп уртаклашам, әдәби бит өчен дип сайланган шигырьләрне күрсәтәм. Ул аларны кухня өстәленә таратып, бер кат күздән кичерә, уйланып тора. «Дулкынландыра торганнары аз шул»,—дип куя.

Сажидәнең таләпчәнлеген беләм инде. Классик әсәрләр югарылыгыннан торып фикер йөртсән, яшь авторларның кульязмаларын укып торасы да түгел. Үзләре язарга батырчылык итә алмаганнар аеруча таләпчән булалар.

Бер кичне, мин җыелыштан кайткач, уены-чыны белән:

—Прозагыз юк бит, үзем тотынам әле булмаса,—дип куйды Сажидә.

Чыннан да, Фатих Хөсничә, Ибраһим Газича йөгерек телле, коеп куйган шигъри хикәяләр әле безләрнең төшләренә генә керәдер.

1963 елның март аенда Татарстан Язучылар союзының Әлмәт бүлеге дә ачылды. Казаннан Гариф Ахуновны бүлеккә җаваплы сәркатип итеп җибәрделәр. Ул 1963-1965 һәм 1967-1968 елларда эшләде. Эшләр гөрли башлады безнең. 1968-1972 елларда бу вазифаны Равил Фәйзуллин башкарды. Мин дә 1965-1967 һәм 1972-1982 елларда җитәкчелек иттем.

Командировкадан кайткач, җилкәндә редакциянең кайнар сулышын тоеп, блокнотыңны «сыгарга», күнел заказын үтәргә тотынасың.

Әдәби берләшмәбезнең дә офыклары киңәя башлады. Күрше районнарда оешкан әдәби түгәрәкләр хәзер Әлмәт ягына тартылалар. Яшь каләмнәрне кабул итәргә бүлмәбез дә, штатлы кешебез дә юк. Ул турыда әле хыялланабыз гына. Кульязма тотып килгән һәрберсе «бу мин генә» дигәндәй, кыю гына ишегеңне кага. Үзләре яшәгән районнарга барып чыгасың.



*Әлмәт язучылары Казаннан һәм Уфадан килгән кунаклар белән. Сулдан уңга: С. Сабиров, М. Хәсәнов, М. Кәримов, Ә. Маликов, Г. Саттаров, З. Нури, Г. Афзал, Ю. Әминов. 1971 ел.*

Алда—диплом яклау мәшәкате. Андый-мондый гына түгел. Яңа әсәрләренне институтның иҗат кафедрасы өстәленә китереп сал. Ә кафедра мөдире—«Бронепоезд 14-46» пьесасы белән ил театрларын гөрләткән, «Берлинны алганда» романы белән шөһрәт казанган күренекле язучы, профессор Всеволод Иванов! Иҗатың буш булса, «кәҗә билеты» тотып кайтуынны көт тә тор.

Бөек Ватан сугышыннан соң әдәбиятта төзүчеләр темасына өстенлек бирелде. Шулай булырга тиеш дип кабул иттек. Сугышта җимерелгән калаларны, янган авылларны торгызырга, яңаларын салырга, яңа нефть мәйданнарын ачарга кирәк. Ансыз дөнья—сансыз. Кайнар тормыш үзәгендә яшәгән дипломанттан ни сораячакларын сизеп торам.

Рәшит Саттаров җитәкләгән ташчылар бригадасы белән якыннан таныш идем. Коллективында күбесе хатын-кызлар. Оста аларга «иркәм» дип кенә дәшә. Шуны ишетүгә йөзләрдә елмаю балкый.

Рәшит Саттаров үз кул астында эшләүчеләргә җанын ярып бирергә, кеше хакын яклыйм дип, үзе нужа күрергә дә әзер. Ансыз эш бармый да.

Күз алдында яңа шәһәр туа бит.
Ул балаң сыман кадерле:

...Яшәү дәвамнары булып,
Телеп туа бәгырьне.

Миллиардлар яулап кына чикләнми республикабыз. Девон сулышы халкымның талантына нур өсти. Менә ничек уйлый Саттаров шикелле хезмәт батырлары. Әйе, илең көчле булса гына синә сан бар, син—батыр.

* * *

Диплом эшенә мин Әлмәткә күчкәч язылган, яңарыш рухын чагылдырган поэмамны һәм шигырьләрне керттем. Әлбәттә инде, солдат шигырьләрен дә ятим итмәдем. Алар бит минем җанымда яши, канымда кайный. Һәм гомер буе шулай булып калырлар да.

Мәскәүдә диплом яклау көне дә килеп җитте. 1957 елның июнь ае иде бу. Тирәкләрдән очкан ак мамыклардан институт ишек аллары ап-ак булган.

Диплом яклаган көнне институт залы шыгрым тулы иде. Таныш йөзләр байтак күренә. Мәскәүдә яшәүче Әхмәт абый Ерикәй белән алдан ук күрешеп куйган идек. «Каушама, Әдип,—диде,—барысы да тәртиптә булыр. Диплом эшең белән дә, рецензияләр белән дә танышып чыктым».

Безгә лекцияләр укыган профессорлар да килгән. Тел галиме Реформацкий кәҗә сакалын сыйпап куя. Барып күрештем. Мине онытмаган икән. Сөенеп куйгандай булды.

—Иске бурычымны түләргә килдем,—дигәч, профессор торып басты да, аркамнан сөйде:

—Рәхмәт, дустым!

Беренче булып, трибунага Смоленский прозаигы күтәрелде. Бераз кырын төшеп, төссез, бәйләнешсез фәлсәфә сата башлавына, залда тынычлык югалды. Ярты сәгать буена «әкият сатканнан соң», чәбәкәйләп трибунадан төшерделәр үзен. Залдан кемдер «үтерде!» дип куйды.

—Дипломыңнан укырга иде, ичмасам.

Чират миңа килеп җитте. «Тынычлан, бирешмә...» дидем үз-үземә. Чыннан да, трибунага менсәм, дулкынланудан туктыйм мин. Әллә яшерен тормозым бармы соң?..

Диплом эшеннән сайлап алынган шигъри детальләрне, масштаблы күренешләрне ходка җибәрдем. Кыскасы, Девон нефте якларының сулышын бирергә тырыштым:

Биш минут сөйләгәнмен. «Мөгезеннән эләктерден, рәхмәт!»—дип аваз салды берсе. Шагыйрь Василий Федоров икән. Кыска сөйләвем өчендер, бәлки, әйбәтләп кул чаптылар.

Арадан ике студент «отлично»га яклаган булып чыкты. Ни гаҗәп— берсе мин. «Уртача»га да риза идем югыйсә. Аспирантурага керәсем юк бит әле.

Залдан чыгуга, тизрәк почтага ашыктым, Әлмәткә шалтыраттым. Трубкадан Сажидәнең «рәхмәт, булдыргансың!»—дигән сүзләрен ишетү, мина калса, иң зур бүләк иде.

Бу мактау сүзе артында күпме кичерешләр, борчылулар ята. Күнел кылымның өзелергә житкән чаклары да булды бит. Тормышка ябышып, тырнак канатканчы тырмашулар... Аскар—Мәскәү арасында йөргән эчкерсез хатлар мина яшәү өмете бирделәр. Сажидәнең аналарча кайгыртучанлыгы, сирәк-мирәк куйган кырыс таләпләре мине ныклап аякка бастырды дисәм дә артык булмас.

* * *

«Отлично» дигәннәре киләчәккә рухландыру өчен аванс кынадыр дип уйласам да, дипломны уңышлы яклау Мәскәү нәшриятларына азмы-күпме юл ачты мина. Шул көнне «Дружба народов» журналының поэзия бүлеге мөдире институт залында утырган икән. Соныннан минем диплом эшем белән танышкан. Күпмедер вакыт узгач, журнал редакциясеннән хат килеп төште: «Бездә «Ташчы» поэмасы белән кызыксыналар. Подстрочнигын жибәрә алмассызмы?»—дигәннәр. Сөенә-сөенә жибәрдем, әлбәттә. Инде онытканнардыр, булмас, ахры, дип йөри торгач, поэмам шагыйрь Николай Старшинов тәржемәсендә кыскартусыз-нисез дөнья күрде.

Мәскәүдә бер очрашуда Старшинов уены-чыны белән бергә: «Без сине әдәби орбитага чыгардык,—дип куйган иде,—«Дружба» иләгеннән үтү жинел түгел, дустым.»

Тиз арада аңлашып, чыннан да дуслашып киттек аның белән. Фронтта рота запеваласы булган икән Николай. Шундый бер шигыре дә бар: «Старшинов, запевай!»

Аның бер аягын тездән түбән пуля тишеп чыккан, сөякләре чәрдәкләнгән булган. Чалбар балагын күтәреп, җөйләрен күрсәтте мина. «Кисәргә бирмәдем»,—диде. Атаклы хәрби хирург чәрдәкләнгән сөякләрне тәтәй урынына тезеп, оста гына оештырып куйган булган. «Мен рәхмәт ана, менә аксамыйм да, йөрүемне беләм»,—диде Старшинов.

Минем рәхмәтем зур иде солдат-шагыйрьгә. Аның тәржемәсендә бит «Дружба народов» журналында соңрак «Альметьевские стихи» дигән шигырьләр циклым да басылды. Старшинов инициативасы белән, «Молодая гвардия» нәшриятында «Первый оркестр» исемле поэма һәм шигырьләр китабы дөнья күрде. «Детгиз»да «Мы солнце встречаем в пути», «Современник» нәшриятында «Остров моей юности» дигән повестьларымның басылып чыгуына да, мөгаен, шулар этәргеч биргәндер.



## Шамил Маннапов

### ШИГЪРИ ВӘХИЛӘР

Риваятьләр сөйли:
Фәрештәләр
Мәрьям анабызны, гарешләргә
Алып менгән чакта, бер мәлне,
Туктатканнар, имеш, изүендә
Җир җәсәден күреп—энәне...

Теләсәк тә, әйе, җиңел түгел
Күккә ашу безнең җаннарга,—
Энә генә түгел, бинибая
Дөнья гаме тулган аларга.

Шулай да мин көтәм Җәбраилне
Килер, диеп, Бурак атында.
Төне буе бүлмәмдә ут яна,
Күңел капкам шәрран ачылган...

Канга баткан бу гөнаһлы Җирне
Фәрештәләр, бәлки, оныткан?
Җире өчен оялгандай, Кояш
Алсуланып чыга офыктан.

Ә мин барыбер көтәм Җәбраилне,
Килер әле, килер, бәлки, бер.
Күңелемә иңгән төнге уйлар—
Мөгаен, дим, шигъри вәхидер...

---

Шамил МАННАПОВ *(1938) —шагыйрь, прозаик; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе; татар һәм рус телләрендә басылган дистәдән артык китап («Хәят көндәлеге», «Тугрылык алиһәсе», «Кайту», «Әти урманы», «Мәңгелектән елмаю» һ. б.) авторы. Казанда яши.*

## Серле мизгел

Зиһен җитмәс серле хикмәт булса туу,
Мең мәртәбә хикмәтледер—инсан булу.
Яшәвенең кадерен белсен дипме икән,
Яралтучы бу дөньяны фани иткән.

Яшәүне Ул көчле иткән,
һәм Үлем дә
Көчсез түгел, көтсә дә ул картлык көнең.
Кайчак көтми, җаны нығымаган килеш,
Адәмнәрнең кисеп куя яшәү җебен.

Яшәү—Үлем. Шул ике көч арасында
Сират кичү язган адәм баласына.
Ахыргача өмет уты сүнми җанда
Дөньялыкта үлмәс эше каласына.

Әй, җирдәшем, яшьлегеңнең кадерен бел,
Исән чакта—саулыгыңның кадерен бел,
Тере чакта—яшәвеңнең кадерен бел,
Карилыкта—һәр көнеңнең кадерен бел!—
Бүтән булмас, кабатланмас
Серле мизгел...

## Сөйгән яр һәм гомер юлдашы турында

1

Шау чәчәкле урман аланында
ак каенны кочып,
уйга баттым.
Ак күлмәкле яшьлек мәхәббәтем,
хыялыма кабат кайттың.

Балта алып,
ак каеннар кистем,
чәчәкләргә күмелеп бер ял иттем...
Чүмеч тутырып бирәү су китерде,
ул—хатыным, гомер дустым иде.

2

Кичләрен мин йолдызларга карыйм,
алар аваз бирми,
алар серле,
алар ерак—
мин аларга карап,
искә алам яшьли сөйгәнемне.

Үзем җирдә яшим.
Зарланмыймын,
суык булсын яки эссе булсын.
Җиргә басып эшкә киткән чакта
озата мине хатыным, гомер дустым...

## Кыяматтән ник шүрлисе?

Яхшылык бар, Явызлык бар бу дөньяда,
Шулар һаман сугышалар бөтен чорда.
Иблис куәт биргәнгәме, бу Явызлык
Күп вакытта Яхшылыктан өстен чыга.

Явызлык ул Иблис кебек гомерледер,
Чик куячак, имеш, аңа Кыямәт көн.
Ә Яхшылык, шул көнгәчә исән калса,
Сират кичеп, чыгачак, ди, барыбер өстен.

Шулай булгач, Кыяматтән ник шүрлисе?—
Тергезер ул Җир йөзендә гаделлекне.
Тик шунысы: яхшы кешеләр түгел анда,
Күбрәк «тәмуг кисәүләре» калыр төсле...

## Юаталар

Сизелми дә уза гомер,
Ә мин һаман сабый.
Ориентир өчен алдымда
Абыйлар бар ярый.

Өлкәнәям, ахры, диеп,
Кайчак моңсулансам,
«Синең яшь—егет чак!»—диеп
Юата күк Туфан.

Чибәр ханымнар сораса,
Яшем ничек әйтим?—
Диеп нәүмизләнгән чакта,
«Минем яшькә җит син башта...»—
Дип елмая Хәким.

Картаюлар урманына
Җителә бит тәки!—
Дисәм, «Әй, малакасус!..»—дип,
Көлә сыман Бакый.

Абыйлар кадәр эшләргә
Гомерләр бир, Ходай,

«Хикмәт яшьтәмени?!»—диеп,
Моңсу гына карап тора
Рәсеменнән Тукай...

Әллә өндә, әллә төштә булды:
Зәңгәр күктә очып йөргәндә
Кинәт кенә авырайган гәүдәм
Өстерәде мине түбәнгә.

Җаным һаман күккә талпынса да,
Җирдән яратылган җәсәдем
Җир үзенә тартты,
Искәрткәндәй,
Мində генә, диеп, яшәвең...

Җир—җир инде,
Монда бар да гади,
Кызлары да түгел хур кызы,
Мин үзем дә хур егете түгел,
Гөнаһлы бер гади юлчымын.

Әмма җаным, хыялына төреп,
Алып төшкән оҗмах хурларын.
Карашымда—офык киңлекләре,
Күңелемдә—йолдыз нурлары...

Һаман күккә баккан җанымны мин
Юатамын: «Артык уфтанма,
Канатлары талгач, хәл алырга,
Оя корып, бала чыгарырга
Куналар ич җиргә кошлар да...»

Очар кошлар озак кунакламас,
Яратылган алар очарга,—
Насыйп булыр микән кабат миңа
Яшьлектәге хыял канатында
Зәңгәр биеклекне кочарга?..

Үз гомеремдә мин еш гашыйк булдым,
Һәм урлаттым ихлас хисләрем.
Инде хәзер калган тойгыларым
Акыл-йозак белән бикләдем.

Әмма акылга баш бирмәс йөрәк
Һаман сизгер: юкмы шакучы?
Әй, Мәхәббәт, тагын килер булсаң,
Табылыр сиңа ишек ачучы...

*Бу дөньядан киткән чакта шунысы*
*Үкенечле булыр барсыннан:*
*Язылачы, язылмаган җырым*
*Елап калыр сыман артымнан...*

Васыятьнамә яза кемнәрдер,
Малы бардыр, димәк, җитәрлек.
Ә мин андый мәшәкатьтән азат,—
Байлыгым юк мирас итәрлек.

Васыять язмасам да, сезгә калыр
Җан җырларым—күңел байлыгым.
Язылмаганнарын калдыралмам,
Үзем белән бергә алырмын.

Сезгә калыр сандугачлы таңнар,
Кояшлы көн, айлы төн яме:
Бабайлардан калган туган җирне,
Васыятьнамә язмый-нитми генә,
Исәннәргә мирас итәмен...

## Мизгел хисләр

Ут белән су айрылгысыз,
Гел янәшә бу дөньяда.
Яңгыр да бит күк күкрәтеп,
Яшеннәр яшьнәтеп ява...

Сөекленңне елатудан саклан,—
Күз яшьләре сытылып чыккан саен,
Йөрәгендә тозы утырып калыр,
Ачы була барыр аның җаны.

Һәр күзленең әле күрмәгәнен,
Һәр сукырның сукыр булмавын,
Чын дигәннең һәрчак чын булмавын,
Әкият дигәннәрнең чынлыгын
Яши-яши генә аңладым...

Син кайгырма, дустым,
Бу дөньяда
Без генәме әллә алданган,
Алданмыйча ничек яшәп булсын
Заманасы торгач ялганнан?!

Элек гамәлләрен
Цитат белән
Раслата иде ул Лениннан,
Инде гөнаһларын ярлыкауга
Аять эзли ислам диненнән.

Өлкәнәйгән саен дус-иш кими,
Ялгызлыктан җаның сызыла.
Әллә язмыш шулай күнектерә
Бакый дөнья ялгызлыгына?..

Күрешалмабыз, яшьли сөйгән яр,
Күрми торалмамын, дигән яр:
Ирең көнләр, син бит чибәр, яшь,
Ә соңыннан... картлык җибәрмәс...

Әти, әни китте мәңгелеккә...
Дус-ишләрем китте, туганым.
Алар белән бергә китте сыман
Бар шатлыгы фани дөньяның.

Йөрәгемдә ике тирән яра:
Ике яра—ике ятим бала.
Үзем белән янә ике ятим:
Берсе—җаным,
Берсе—Шигъриятем.

Аһ, бу картлык! Кыяфәтне боза,
Кыяфәтсез—ни пычагыма!
Шулчак ишетәм кебек Җир тавышын:
«Нинди генә булсаң да син, балам,
Алырмын мин үз кочагыма...»

Бу Хакыйкатьне кем әйтте?
Кем әйтсен, йөрәк әйтте:
«Күпне кичергән Мәхәббәт
Кичерми Хыянәтне...»

Әниең алтын сүзләре
Сызылып искә төшә:
«Мал малга җиткәнче, балам,
Газраил янга җитә...»

## Күбәләк гомере

«Күбәләкнең гомере бер генә көн,
Бигрәк тә кыска ич инде...»
И җирдәшем, әллә үзебезнең
Гомерне соң озын дисеңме?

Кеше дә бит уза шул ук юлны...
Җитми әле аңа бер гомер.
Кеше гомере, бәлки, Галәм өчен
Күбәләкнекедәй—бер көндер...

Шуңа микән әллә
Күбәләккә
Карыйбыз да ямансулыйбыз?—
Бер үк Табигатьнең баласы бит,
Кечкенәме, әллә зурмы без...

**Фатих Урманче**

# ГАСЫРЛАРНЫ КИЧКӘН ГҮЗӘЛЛЕК

## ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ШИГЪРИЯТЕНДӘ СӨЕМБИКӘ ОБРАЗЫ

### Манарада сакланган исем

Сөембикә исеме татар халкы күңелендә якты бер нур—изгелек нуры булып яши. XX гасыр башында, бигрәк тә 1905-1907 еллар революциясеннән соң, илдә беркадәр хөррият нурлары да күренә башлагач, Сөембикә исеменә игътибар бермә-бер арта, аңа багышланган яңа әсәрләр иҗат ителә. 1912 һәм 1915 елларда Г. Рәшидинең «Сөембикә хәлләре» дөнья күрә. 1913-1918 елларда хатын-кызларга багышланган «Сөембикә» журналы чыга (мөхәррире—Якуб Хәлили). 1907 елда Мәҗит Гафури үзенең «Хан мәчете» («Сөембикә манарасы») шигырен яза. Татар халкының милли азатлыгы символы булган бу гүзәл манара белән бәйләнгән шигырь тирән һәм күңелне тетрәтерлек хисләр, кичерешләр белән сугарылган. Чөнки ул манара—татар халкының 1552 елгы милли фаҗигасен тулысынча үзендә саклаган бердәнбер һәм чыннан да тарихи һәйкәл:

Һәр бинадан биек улып күкләргә чыккан башың,
Мин беләм белдермәсәң дә—агадыр күздән яшең.
Бу хәленнән шикаять кылды синең һәрбер ташың.
Кальбеме[1] мең парә кылды шул гүзәл Хан мәсҗеде.

Шагыйрь үзенең бу манара белән бәйле кичерешләренә генә тукталып калмый. Ул—ил вә халык, Казан ханлыгы, аның мөстәкыйль ил булгандагы даны-шөһрәте турында уйлана, үз халкының данлыклы тарихы белән горурлана:

Бер заманда синдә намаз укыганнар хан иде,
Кауме татар һәм төрекнең мәскәне[2] Казан иде.
Ул вакытны тасвир ирсәк, ни гүзәл заман иде!
Кальбеме мең парә кылды шул гүзәл Хан мәсҗеде.

Тарихның кырыс законнары буенча, татар халкының милли азатлыгын

---

Фатих УРМАНЧЕ *(1936)—татар халык авыз иҗаты буенча күренекле белгеч, филология фәннәре докторы. «Дастаннарга лаек замана», «Ак бүре эзеннән», «Идегәй», «Нурсолтан», «Сөембикә» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

[1] Кальбеме (кальбемне)—күңелемне.

[2] Мәскәне—торган җире.

һәм мөстәкыйльлеген гәүдәләндергән манараның тарихи язмышы берара кызганыч хәлдә кала: «Шәүкәтең[1] бетте бүгендә, калмады меңнән бере. Башкаларның йире булды ошбу көн Ислам йире».

Әмма ни кызганыч, Октябрь инкыйлабыннан соң бу әсәр кинәттән һәм һич көтмәгәндә «юкка чыга», укырга ярамый торган әсәрләр рәтеннән санала башлый. 1918 елда «Сөембикә» журналы, шуның белән бергә гүзәл ханбикәнең исеме дә тыела; аны һәм башка күп кенә изге исемнәрне халык күңеленнән кысрыклап чыгару буенча берничә дистә елга сузылган кырыс диктатура башлана. Тарихчы галимнәр белән бергә язучы-шагыйрьләр дә Идегәй, Нурсолтан, Сөембикә исемнәрен, гомумән, «онытып торырга» мәҗбүр ителә. Шундый хәл тоталитар режим шартларында берничә дистә ел дәвам итә. Тик кайдадыр тирәндә, халык күңеле түрендәге җыр-бәет вә риваять-легендаларда гына һәм шулай ук кайдадыр биектә—Сөембикә манарасында гына—әлеге изге исем сакланып кала. Аллага шөкер дип әйтергә кирәк: Казан ханлыгы чоры архитектура һәйкәле буларак әлеге изге манара үзе генә сакланып калмый, гүзәл ханбикә исемен дә безнең көннәргә кадәр алып килә. Большевиклар тарафыннан илдәге йөзләрчә, меңнәрчә манаралар рәхимсез җимерелгән егерменче-утызынчы һәм илленче-алтмышынчы елларда, ни хикмәттер, Сөембикә манарасы исән-сау кала. Моның могҗизалы сере дә бәлки гүзәл ханбикә исеме белән бәйләнгәндер: әлеге манараның төп иҗтимагый милли вазифасы—Сөембикә исемен саклап калуда булырга тиеш!

Бу фикерне турыдан-туры раслап торган конкрет фактлар да бар. Сүз соңгы елларда Разил Вәлиев тарафыннан язылган «Сөембикә манарасы» шигыре турында бара. М. Гафуридан аермалы буларак, Р. Вәлиев күбрәк манара турында түгел, ә бәлки татар халкында әле безнең көннәрдә дә киң таралган риваять хакында сөйли:

Сөембикә моннан ташланган, дип,
Риваятьләр йөри халыкта.
Онытса да тарих күп нәрсәне,
Бардыр кебек монда хаклык та.

Риваятьнең эчтәлеге нинди генә булса да, шагыйрь аңа тирән ышану белән карый. Һәм бу бик табигый: чөнки халык та үзенең риваятенә ышана, әш нәкъ менә риваятьтә сөйләнгәнчә булгандыр, дип гөман кыла. Ә менә үзенең гүзәл ханбикәсе, хурлыклы хәлдә калып, Явыз Иван тоткынлыгына алып кителгәндер, дигән тарихи фактка халыкның һич тә ышанасы килми. Ул хәтта Сөембикәне батырларча һәлак булу юлына этәрүгә дә барадыр төсле.

М. Гафури шигырендә күтәрелгән мәсьәлә турында сүз барганда хәзерге шигъриятнең тагы бер үрнәге—Харрас Әюпнең «Сөембикә манарасындагы Айны сәламләү» (1990 ел) шигырен читләтеп үтү дөрес булмас. Сөембикә манарасының тәүге исеме Хан мәчете булган. Мәчет—манарасыз, манара—изге айсыз булмый. Әмма 1917 елгы инкыйлабтан соң манараның ае алына: халыкның 70-80 ел дәвам иткән «Кояшсыз вә Айсыз» тормышы башлана. Бу хакта Харрас Әюп болай ди:

Ни гомерләр Айсыз булдык—
Абынды, ауды ирләр.
Дәшми торсаң, бу дөньяда
Кояшсыз калдырырлар!

Төрле халыкларның милли азатлык өчен көрәше нәтиҗәсе буларак, соңгы елларда безнең илдә дә җылы җилләр исеп алды. Шуның гамәли бер күренеше—Сөембикә манарасының Ае яңадан үз урынына кайтарылды. Халык моны, әлбәттә, зур канәгатьләнү белән каршылады.

Шагыйрьнең төп фикере—Сөембикә манарасында ай булганда, татар халкы милләт буларак яшәр. Һәм шуның өчен әнә шул айга карап, безнең бик борынгы ата-бабаларыбыз үрнәгендә, без дә дога кылырга тиеш:

---

[1]Шәүкәт—көч, бөеклек.

Яктырасың—
Ничә гасыр
Татар яше юганмы?
...Кабул кыл, Ай: сиңа карап
Кылдым шигъри догамны...

*Гамил Афзалның «Сөембикә сылу» легендасы*

Берничә дистә ел буенча хөкем сөргән тоталитар режим системасындагы «беренче чатнаулар» алтмышынчы еллар башында, илдә билгеле бер «җылы җилләр» исә башлагач барлыкка килә. Шуның нәтиҗәсендә халкыбыз өчен изге булган кайбер исемнәр дә яңадан кайтты. Бу очракта сүз Татарстанның халык шагыйре Гамил Афзалның «Сөембикә сылу» дип аталган легендасы турында бара. Ул 1968 елда—әле тоталитар режим тулысынча үз көчендә булып, берсүзсез хөкем сөргән чорда язылган. Дөресен әйткәндә, Г. Афзал Сөембикә исемен халыкка яңадан кайтару юлында беренче һәм гаять тә җитди адым ясый. Белүебезчә, Г. Афзалның талантлы һәм үзенчәлекле, чын мәгънәсендә милли рухлы шагыйрь булуы турында, гомумән, күп кенә язылса да, аның әлеге әсәре утыз ел буена күләгәдә калып килде. Аны ашыкмыйча гына, җай гына укып чыккач, татар халкының урта гасырлардан безнең көннәргә кадәр дәвам иткән моңлы һәм ифрат та фаҗигале тарихы кабат күз алдыннан үтә. Сөембикә исеме, моңсу бер әләм булып, әнә шул тарихны әйдәп бара.

Әсәр халыкның риваять-легендаларында кабул ителгәнчә, берничә һәм ярыйсы ук төгәл билгеләнгән бүлекләрдән тора. Сүз горур Казаннан башлана:

Идел ярларында
Казан—кыя кебек.
Тирә-якларында
Балкып тора кебек.

Сәүдә юлларында
Кәрван йөртә Казан.
Килер елларыннан
Ниләр көтә Казан!

Әсәрнең тарихи хакыйкатькә тулысынча туры килә торган юлларын язгач та, шагыйрь: арттырыбрак җибәрмәдемме икән дигәндәй, легенданың эмоциональ яңгырашын бөтенләй икенче яссылыкка күчерә. Әсәргә татар халык җырларында киң таралган һәм халыкның чыннан да авыр язмышын чагылдырган «Идел ярларындагы сары камыш», һәркемгә мәгълүм «кара урман», «шомлы язмыш», «төнбоеклы күл», «ятып елар җирләр» кебек, чын мәгънәсендәге традицион һәм халкыбызның авыр тарихына багышланган шигъри образлар тезмәсе килеп керә. Әлеге образларның шигъри һәм тарихи көче, аһәңе укучы күңелен тыныч калдырмый: «Нишләп соң әле әсәргә бер-бер артлы борын-борыннан кайгы-хәсрәт, фаҗига символы булган шигъри образлар системасы ургылып керә башлады?!»—дип уйлана ул. Баксаң, шагыйрьнең киләсе сүзләре чыннан да кырыс хәлләр, куркыныч вакыйгалар турында икән: Казан ханлыгы тарихы үзенең иң авыр бер чорына кергән икән. Илдә кемнәрдер мал җыя, кемнәрдер кан коя. Ачу-фетнә үсә, тарала: «Шанлы Казан таҗы кулдан-кулга күчә». Сөембикә ханбикә идарә иткән елларда ханлыкның хәле чыннан да авыр, катлаулы, фаҗигале була. Өлкән яшьтәге шагыйрь Гамил Афзал ул елларның афәтен яхшы белә, аңлый, үзенең шәхси язмышына кагылган фаҗига кичергәндәй борчыла, яшь сылу ханбикәгә ярдәмгә килергә тырыша, аңа акыллы киңәшләр бирә. Шуның белән шагыйрь яшь һәм сылу ханбикәне безнең арага алып керәдер төсле, аңа карата үз укучыларында әйтеп бетергесез җылы хисләр уята. Шагыйрь, аерым шигъри штрихлар белән генә булса да, ханбикәнең гомумиләштерелгән, әмма һәрбер татар укучысына ифрат та якын шигъри портретын биреп үтә.

Күлмәкләрең ефәк,
Камзулларың бәрхет,

Җаныңа юк тынгы,
Үзеңә юк бәхет.

Илем, диеп ела,
Илем, диеп көен,
Хәлең авыр синең,
Сөембикә килен.

Шул ук вакыт шагыйрь әсәренең баш өлешендә берничә тапкыр искә алынып үткән шомлы юлларын да онытмый: нинди генә тырыш, тыйнак, уңган һәм акыллы булса да, яшь-яшь ханбикәнең киләчәге караңгы. Бу исә барыннан да элек Мәскәүнең халыкара сәясәте белән бәйләнгән.

Г. Афзал шигыре язылган 1968 елда Сөембикәгә багышланган күп санлы материалларның, фәнни мәкалә һәм әдәби очеркларның әле берсе дә яңадан дөнья күрмәгән иде. Сөембикәне әсирлеккә алып китүнең конкрет сәбәпләрен дә, шартларын да без рәтләп белми идек. Ул елларда әле Мәскәүнең баскынчылык сәясәте, Казанны хәрби көч белән яулап алуы турында да авыз тутырып сөйләргә ярамый иде. Шагыйрь моны бик яхшы белә. Шулай да тарихи вакыйгаларның барышын, аларның Сөембикә язмышындагы ролен ул шактый төгәл чамалый.

Сөембикәне әсирлеккә сатуга, ил башында торган бу ханбикәне илдән кууга да ишарә бар әсәрдә.

Шагыйрь мәсьәләне, аның асылын, сәяси нигезен яхшы аңласа да, ул елларның идеологик таләпләре басымы астында «эшне» шәхси мөнәсәбәтләр яссылыгына күчерә. Ул ханбикәгә «мөлаем сораулар» белән мөрәҗәгать итә, аңардан туган илне ташлап китмәвен үтенә. Әсәргә халык бәетләрендәге аерым мотивлар да килеп керә.

Ил эчендә фетнә,
Ил тышында фетнә,
Илгә авыр чакта
Илне куеп китмә!

Нугай юлы тузан,
Мәскәү юлы—томан...
Сандугачтай сылу
Яшьлегеңне кызган.

Сөембикәнең, Казанны авыр хәлдә калдырып, Мәскәүгә китүен ханбикә үзе дә, шагыйрь дә теләми: автор аны китмәскә үгетли; ханбикә исә елый. Димәк, мәсьәләне ханбикә үзе генә хәл итә алмый; бер якта—аның Казаннан китүен теләгән, чынлыкта хәтта таләп иткән биләр торса, икенче якта—Мәскәүнең кырыс сәясәте. Шулай булгач ул, елый-елый булса да, кадерле һәм хәвефле Казанын ташлап китәргә мәҗбүр. Аңлашыладыр, шагыйрь тарих кануннарын да, Сөембикәнең фаҗигале хәлен дә дөрес аңлаган. Яшь-яшь килеш тол калган ханбикәне сабый улы белән тоткынлыкка озату—бу ифрат тирән мәгънәгә ия булган шәхси һәм тарихи фаҗига. Аның шулай булуын беркем дә, хәтта Казан ханлыгының һәм Сөембикәнең дошманнары да инкяр итә алмый. Казан тарихының бу фаҗигале мизгеле һәрвакыт зур һәм тирән кичерешләр, кайгы-хәсрәт, күз яше, елау-сыктау белән бергә бара. Аны башкача сурәтләп тә булмый.

Гамил Афзал да әлеге күренешкә нәкъ әнә шул ноктадан килә һәм, гадәттәгечә, бик тыйнак, шул ук вакытта хәтердә калырдай шигъри образларга мөрәҗәгать итә:

Казан елгасына
Киң Иделдән кереп,
Матур кораб кәтә,
Җилкәннәрен киереп.

Кирмән капкасыннан,
Казан-су ярына
Биләр келәм җәя
Үтәр юлларыңа.

Шулай да Гамил Афзал легендасының иң көчле һәм тәэсирле өлеше— аның йомгагы булса кирәк: анда сүз нигездә халык күңелендә изге бер истәлек булып сакланган хисләр турында бара. Гүзәл ханбикәнең чыннан да рәхимсез коллыкка озатылуына шагыйрь ышанмый. Сөембикә язмышын ул башкача күз алдына китерергә тырыша һәм татар халкы күңелендә берничә гасыр буена яшәп килгән легендага туктала: анда сөйләнгәнчә, дошман кулына тоткынлыкка төшмәс өчен, Сөембикә үз манарасыннан сикереп һәлак була. Шагыйрь халык легендасының эчтәлеген сөйләп тормый, аның аерым мотивларына гына тукталып үтә.

Халык иҗатында да, язма шигърияттә дә шундый бер закончалык бар: әсәрдә берәр кош образы пәйда булдымы (сандугач, күгәрчен, аккош), димәк, анда котылгысыз рәвештә берәр фаҗига да булачак. Җырлардагы сандугач сайравы кебек илаһи бер күренеш тә—барыннан да элек булачак фаҗига символы. Әйтелгәннәр күке образына да кагыла: кеше бит үзенең калган гомерен юкка гына күкедән санатып яшәми. Күрәсең, шуның белән бәйле рәвештә Сөембикә-чибәр дә безнең күңелгә күке булып кайта.

XVI гасыр уртасыннан Сөембикә образы халык йөрәгендә, аның риваять-легендаларында, җыр-бәетләрендә бетмәс кайгы-хәсрәт, ачы язмыш символы булып яши:

Кайда күңел сынык,
Кайда күңел боек
Сөембикә йөри
Моңлы бәет булып.

Әсәрне башыннан ахырына кадәр җентекләп күзәтү шуны күрсәтә: Гамил Афзалның «Сөембикә сылу» легендасы—татар шигърияте ндә Казанның соңгы ханбикәсенә багышланган иң җитди, көчле һәм Сөембикәнең үзе кебек моңсу әсәрләрнең сирәк үрнәге.

## Зөлфәт—«Сөембикәнең хушлашу догасы»

Гамил Афзалның әлеге шигыре язылганнан соң Сөембикә образы безнең шигърияткә яңадан «ныклап аяк басарга» һәм төрле шигъри әсәрләрдә чагылыш табарга тиеш иде. Юк шул! Мәсьәлә катлаулырак, хәтәррәк булып чыга. Илдә тоталитар режим дәвам итә. Шуңа карамастан, Г. Афзал әсәре язылып нәкъ ун ел узгач, талантлы һәм милли рухлы шагыйрь Зөлфәт «Сөембикәнең хушлашу догасы»н иҗат итә (1978 ел).

Башка бик күп шигырьләре кебек, Зөлфәтнең бу әсәре дә ифрат көчле язылган: татар халкының дүрт ярым гасырлык тарихи трагедиясе шушы зур булмаган шигырьгә сыеп беткәндәй тоела.

Шагыйрь Сөембикә елавының эчтәлеген яхшы белә. Шигырь әнә шул елауда кат-кат тәкърарланган төп мотивтан башланып китә:

Алар җиңде... Безнең
кулдан кылыч төште.
Миңа—әсирәгә—әзерләнде бөят.
Алып китә алар мине түгел, халкым,
Китә алар синең шөһрәтеңне төяп.

Чыннан да, ил башында торган Үтәмеш Гәрәйне (гәрчә ул сабый булса да) һәм аның васыяте (регенты) булып, илне идарә иткән Сөембикәне тоткынлыкка алып китү—бу барыннан да элек илнең азатлыгын, мөстәкыйльлеген юкка чыгару дигән сүз иде. Моны Сөембикә бик яхшы аңлый һәм үзенең елавында бу хакта ачыктан-ачык әйтә: ханбикәне үз фаҗигасе генә түгел, ил трагедиясе борчый, тетрәндерә. Әнә шуның белән бәйле рәвештә, шагыйрь Сөембикәнең мәгълүм елавында аерым җөмләләрне хәтта сүзгә-сүз кабатлый.

Хуш, бәхетсез халкым! Мин калдырам сине
Алларыңда торган мең афәтле килеш,

Киләчәксез килеш мин калдырам сине,
Йөзең канлы килеш, җәрәхәтле килеш.

Казанның фаҗигале язмышы—әсәрнең үзәген тәшкил иткән идея, дидек. Сөембикә заманнарында да ул шулай булган. Хәзер дә шулай:

Соңгы өметләр дә беттемени янып?
Кайнап бетте Казан... Җиңүчегә—табын!
Ташланмадың текә, биек манарадан—
Очты манарадан, халкым, синең даның.

Татар халкының тарихи риваятьләренә караганда, Казанның фаҗигале киләчәге шәһәр салынганда ук билгеләнгән була. «Минем шәһәрем этләргә әләгер» дигән риваятьтә, әйтик, бу хакта тәфсилле сүз алып барыла. Риваятьнең эчтәлегенә тулысынча тукталып тормастан, аның Зөлфәт шигырендә чагылыш тапкан соңгы бүлегенә генә игътибар итик. Казан каласын төзү өчен урын сайлангач, хан төзүчеләренә әйткән: «Нигез салганда, сезнең яныгызга кем беренче булып килсә, җиргә тереләй шуны күмегез». Бик борынгы карашлар буенча, җир ияләренең күңелен күрү өчен төзеләчәк корылма нигезенә кеше корбаны салу кирәк булган. Әнә шул йолага нигезләнгән риваять болай тәмамлана: «Төзүчеләр янына хан малае килгән. Алар аны җиргә күмәргә батырчылык итмәгән, аның урынына эт күмгәннәр. бу турыда белгәч, хан: «Димәк, минем шәһәрем этләргә әләгер»,—дигән»... Борынгы мифологик күзаллаулар белән тыгыз үрелеп барган бу шигырьдә риваятьтәге мотив та бик урынлы чагылыш таба.

Билгеле булганча, Зөлфәт үз шигърияgreтендә борынгы миф, әкият, дастан, бәет төсмерләрен кирәк дәрәҗәдә мул, бәрәкәтле һәм чын шагыйрьләрчә оста куллана. Күзәтелә торган шигырьдә дә шул ук хәл күренә.

Күп кенә халыкларда бик күптәнге заманнардан бирле шундый бер миф яшәп килә: үлгәннәрнең, бигрәк тә ил азатлыгы өчен канлы сугышта шәһит киткәннәрнең җаны илаһи күккә аша һәм шунда кояш кыйпылчыгына, бигрәк тә йолдызларга әверелеп, үзенә лаек урын ала. Әнә шундый мифологик легендаларга мөрәҗәгать итеп, шагыйрь аларның эчтәлеген тулысынча диярлек үзгәртә һәм Казанның азатлыгын саклап калу өчен барган канлы сугыш күренешләренә бәйли. Нәтиҗәдә шигырь ифрат та тәэсирле юллар белән тәмамлана:

Кичерә күр, халкым! Сау гына бул, халкым!
Тәхетең дә китте, бәхетең дә бетте—
Хагын-нахакларын чорлар үзе әйтер—
Күк гөмбәзен тишеп безнең уклар үтте.
Чорлар үткәч,
күккә
карап искә төшер—
Ук эзләре анда җем-җем җемелдәшер...

Чыннан да, бик борынгы миф белән бүгенге шигырь эчтәлеген бергә кушып, безнең Казан өстендәге күккә карасаң, тирән уйга каласың: ни җемелди икән анда? Казан мөстәкыйльлеге өчен сугышта шәһит киткәннәрнең җаннарымы? Яисә аларның укларымы?! Бусын инде һәркем үзенчә аңлар...

## Сөембикәгә багышланган поэмалар

Поэмалар дигәндә безгә шунысы мәгълүм—дөнья әдәбиятында Сөембикә исеме белән турыдан-туры бәйләнгән һәм Казанның иҗтимагый, ханбикәнең шәхси язмышын ярыйсы ук тулы яктырткан ике поэма язылган. Аларның беренчесе «Россияда» дип атала. Аны урыс әдәбиятының классигы М. М. Херасков иҗат итә. 1779 елда ул зур форматлы һәм 288 битле китап булып басылып чыга.

Поэмаларның икенчесе 208 елдан соң, 1983-1987 елларда иҗат ителә. Аның авторы—татар шагыйре Әхмәт Рәшит. Әле илдә иректе фикер чоры

башланмаган 1983 елда ук татар әдәбиятында беренчеләрдән булып бу темага күләмле поэма язарга алыну—заманасы өчен шагыйрьнең зур тәвәккәллеге итеп аңлатылырга тиештер. Шуңа күрә Ә. Рәшит поэмасының хәзерге татар әдәбиятында Сөембикәгә багышланган беренче зур күләмле әсәр булуын басым ясап әйтергә кирәк. Әсәрнең уңышлары да, кимчелекләре дә әнә шуңа бәйләнгән, ахры.

Поэма ерак җирләрне һәм ерак чорларны сурәтләүдән башлана: Һиндстан, Таҗ-Махал, Җәмуна... Ә. Рәшит әсәрендә Һиндстан белән бәйләнгән күренешләр бары тик шагыйрьнең шәхси кичерешләренә нисбәтән генә бирелә. Таҗ-Махал, Мөмтаз турындагы мәгълүматлар белән танышу, аңлавыбызча, шагыйрьне Сөембикәгә багышланган махсус поэма язарга рухландырган.

Поэма нигездә сиксәненче еллар уртасында язылган, дидек. Билгеле булганча, ул елларда тоталитар система идеологиясе әле җимерелергә һич җыенмый иде. Шулай булгач, күзәтелә торган поэмага да бу идеологиянең билгеле бер йогынтысы килеп керә. Бу бигрәк тә «Шәкерт дәфтәрендә сакланып калган борынгы бәет» бүлегендә ачык күренә. Башта бәетнең исеме турында. «Борынгы» дигәндә без, гадәттә, Болгар чорын һәм хәтта аннан да элеккерәк дәверләрне күздә тотабыз. Казан ханлыгы чоры исә урта гасырлар тарихына карый. Әнә шул урта гасырларга караган вакыйгаларны сурәтләгән әсәрне шагыйрь нигәдер «Борынгы бәет» дип атый. Моның чын мәгънәсе аңлашылмады. Шулай да мәсьәләнең асылы анда түгел, ә бәлки башкада. Бәеттә урыс тимерчесе Иванның фаҗигале язмышы сурәтләнә.

Әйе, урыс кенәзлекләреннән Казан ханлыгы җирләренә качып китүчеләр урыслар Казанны яулап алганчы да җитәрлек була. Тик Иван үзенең Новгород якларында нинди дер афәткә дучар булуы турында сөйли:

> Сөйләде зур гаскәр килгәнне—
> Башлыгын ничек җир күтәргән!—
> Кызганмый ни картын, ни яшен—
> Һәммәсен кылычтан үткәргән.

Урыс тарихыннан мәгълүм булганча, шагыйрь сурәтләгән вакыйгалар Новгородта 1570 елның февралендә була. Бу елларда Казан ханбикәсе Сөембикә күптән инде фани дөньядан киткән. Димәк, шагыйрьнең түбәндәге сүзләре берничек тә тарихи дөреслеккә туры килә алмый: «Ул ярлык күрсәтте дәлилгә—ярлыкка Сөембикә кул куйган».

Бер уйласаң, шагыйрьнең нияте изге кебек: ул үзенең поэмасында урыс һәм татар халыкларының дуслыгын күрсәтергә тели. Новгород якларыннан Явыз Иван явыннан соң күчеп килгән Иван: «Ул елны тимерче Иван да ясады йөз сука тимере...» ди. Бу сүзләрне укыгач та, гомер-гомергә утрак тормышта яшәп, үзләре дә тимерчелек белән бик күптәннән шөгыльләнеп килгән болгар-татарлар үзләре сука тимере ясый белмәде микәнни?—дип аптырап каласың.

Шул ук вакыйгаларга шагыйрь Явыз Иванның мәшһүр опричнинасы башында торган Малюта Скуратов исемен дә китереп кыстыра. Ә конкрет тарихтан билгеле булганча, М. Скуратовның сәяси эшчәнлеге XVI гасырның алтмышынчы еллары ахырына таба гына башлана.

Поэманың «Тимерче Иван бәетенең дәвамы» дип аталган бишенче бүлегенә шагыйрь тарихта мәгълүм, әмма XVIII йөзнең икенче яртысында—Пугачев вакыйгалары вакытында—яшәгән Бәхтияр исемен дә китереп куша (сүз Бәхтияр Канкаев турында барамы, әллә башка берәр шәхес күздә тотыламы—бу очракта моның бернинди дә әһәмияте юк. Бәхтияр исемен без тик Канкаев фамилиясе белән бергә кулланырга гына күнеккән). Бу җәһәттән поэманың түбәндәге юлларын укыгач, тагын бер тапкыр гаҗәпләнәсең:

> Кузгалды иң алдан уйнаклап
> Бәхтияр батырның бүз аты.
> Ул атның Бәхтияр угланга
> Йөгәнен Сөембикә бирде бит.

Күрүебезчә, поэмада төрле чор вакыйгалары, төрле дәвер сәяси эшлеклеләре—барысы да бер ханбикә Сөембикә «тирәсенә өелгән». Әсәр

шагыйрь тарафыннан «тарихи поэма» дип аталган икән, конкрет тарих мәгълүматларына игътибарлырак буласы иде дә бит...

Аерым урысларның гади татарлар белән дуслашуы турында Сөембикәгә багышланган башка кайбер әсәрләрдә дә язылa. Әмма бу идеяне беренче буларак Ә. Рәшит күтәрә. Тик аның позициясе аңлашылмады. Телиме моны шагыйрь—юкмы, XVI гасыр вакыйгаларын сурәтләгәндә ул үзенең поэмасына 70-80 ел буена илдә туктаусыз тәкърарланып торган «интернационализм» идеяләрен дә куша. Мәгълүм ки, конкрет тарихта беркайчан да булмаган бу идеяләр—XX гасыр галәмәте. Аларның барлыкка килүе тоталитар идеологиянең марксистик-ленинчыл тәгълиматы белән генә бәйләнгән. Ә XVI гасыр вакыйгаларына ул, ничектер, ятышып бетми кебек. Ул чакта Русиянең төп идеяләре һич тә халыклар дуслыгы түгел иде! Империя буларак әле оешып кына килгән һәм үзенең беренче зур корбанын (Казан ханлыгын) йотарга торган Русия ул елларда халыклар дуслыгы турында уйлагандыр дип берничек тә күз алдына китереп булмый. Русиянең ул чордагы төп максаты: ничек тә булса башка илләрне, башка мөстәкыйль халыкларны хәрби көч белән яулап алу һәм тулысынча үзенә буйсындыру иде. Ә инде XVI йөздә урыс кешесен мөселман зиратына күмүне, гомумән, күз алдына китереп булмый.

Шулай да шагыйрьдән мондый кимчелекләр эзләү—төп максат түгел, әлбәттә. Тоталитар идеология тулысынча хөкем сөргән сиксәненче елларда кем генә башкача яза алды икән? Ни әйтсәң дә, Ә. Рәшитнең «Сөембикә» поэмасы—шул сиксәненче еллар җимеше бит.

Тагын шуны да искәртеп үтмичә мөмкин түгел: татар халкының «Сөембикә бәете»ндәге ялгыш бер мәгълүмат, нишләптер, Ә. Рәшит поэмасына да килеп кергән. Әсәрдә Сөембикә үзенең елавында казанлыларга түбәндәге сүзләр белән мөрәҗәгать итә:

> Килсәм дә кырыйдан—Кырымнан,
> Мин сезгә ят түгел идем бит!
> Сеңелем, дидегез, абыйлар,
> Әбиләр, дәштегез, кызым дип.

Безнең мәгълүматларга караганда, ирек сөючән Нугай далаларында туып үскән Сөембикә Кырымда беркайчан да булмаган!

Әмма ничек кенә димик, Ә. Рәшит поэмасы турында сүз барганда, без бер гаять тә әһәмиятле факторны истән чыгармаска тиешбез: 1987 елда басылып чыккан әсәр буларак, татар әдәбиятында ул Казанның соңгы ханбикәсенә багышланган беренче һәм әле безнең көннәргә кадәр—бердәнбер поэма булып кала. Моннан ун ел элек Сөембикә турындагы һәрбер әдәби сүз яңалык иде. Шул исәптән Ә. Рәшитнең «Сөембикә» поэмасы да. Әйтик, анда ханбикәнең Казан каласы һәм казанлылар белән саубуллашуына зур урын бирелә. Мәсьәләнең бу ягына тукталып, шагыйрь үз әсәрендә мәгълүм елауларның иң җитди өлешләрен файдаланган дип әйтеп үтәсе килә.

Поэмасында шагыйрь Иван Грозный гаскәренең Казанны алуы белән бәйле вакыйгаларның кайберсенә тәфсилләп туктала. Моннан ун ел элек алар билгеле яңа шигъри сүз буларак, бик актуаль яңгырагандыр. Әмма хәзер без ул вакыйгаларның барышын ярыйсы ук яхшы беләбез. Шуңа күрә алар турында яңадан сөйләп тору кирәкмәс. Тагын шуны да истә тотыйк: Казанны яулап алудан бер ел элек Мәскәүгә тоткынлыкка алып кителгән Сөембикә бу вакыйгаларда катнаша алмый. Димәк, аның исеме дә поэмадан төшеп кала.

## «Аждаһалар аягүрә баскач»

Күреп үткәнебезчә, соңгы егерме биш ел эчендә Сөембикә турында Г. Афзал, Р. Вәлиев, Ә. Рәшит, Зөлфәт, Р. Ягъфәров, Ф. Бәйрәмова һ. б. шигъри әсәрләре басылып чыкты. Хәзер инде Казанның соңгы ханбикәсе образы бүгенге татар шигъриятенең аерым, халык тарихының иң авыр бер чорын гәүдәләндергән юнәлешен билгели башлады кебек. Чыннан да, соңгы еллар шигъри әсәрләрендә Сөембикә исеме әледән-әле күренгәләп тора. Бу яктан

Разил Вәлиев әсәрләре аеруча игътибарны җәлеп итә. Менә «Казан поезды» шигыре. Ул гадәти хикәяләүдән башлана: «Мәскәүдәге татар зиратыннан чыккач, Казан вокзалына килеп, мин һәрвакыт поезд көтәм». Әйе, кайсыбыз гына шундый мизгелләрне кичермәгән! Әмма шагыйрьнең фикере төптәрәк: Мәскәүнең бик үзенчәлекле, Шәрекъ архитектурасы рухында төзелгән Казан вокзалы шагыйрь фикерен тирәнгә—XVI гасыр вакыйгаларына алып китә:

Вокзал өстендәге
«Мәскәү» дигән язуларны,
Сөембикә манарасы шәүләләрен,
Ерактагы азаннарны уйлап,
поезд көтәм,
Казан поезды.

Аерым очракларда Р. Вәлиев Сөембикә исемен шаян, юмористик рухта кулланырга да «батырчылык итә». Шагыйрьнең туган як моңнарына багышланган «Җырлыйк әле» җырында да шуңа якын шигъри алым кабатлана:

Сөембикә манарасын
Дәштек без юлга.
Ләкин безнең белән юлга
Чыкмады ул да.

Әнә шул рухтагы әсәрләр белән танышкач: «Сөембикә исеме тик юл уңаеннан гына телгә алына торган персонажга әверелмәгәе!»—дигән шомлы фикер дә килә күңелгә. Юк, Аллага шөкер, алай ук түгел икән! Шул ук Разил Вәлиевның «Сөембикә» җыры белән танышкач, күңел тынычлана. Бу җырында шагыйрь XVI гасыр уртасы белән безнең көннәрне—XX гасыр ахырын тоташтырадыр төсле: шигырьдә Зөлфәтнең «Сөембикәнең хушлашу догасы» белән күзгә күренеп торган аваздашлык та бар кебек: анда да, монда да Казан күгеннән нинди дер изге вә илаһи истәлекләр эзләү.

Бик борынгы заманнардан бирле кеше үзенең изге өметләрен, хыялларын, теләкләрен илаһи Күктән эзләгән; чөнки аллалар да, фәрештәләр дә Күктә гомер кичерә; пәйгамбәрләр исә, бу фани дөньядан киткәч, Күккә аша; мөселманнарның иң изге китабы Коръән дә Күктә, Аллаһы Тәгаләнең үзендә саклана...

Сөембикә гомеренең соңгы еллары ифрат та авыр, рәхимсез шартларда узганын без хәзер яхшы беләбез. Шагыйрь ханбикәнең ачы язмышы белән безнең хәзерге тормыш арасында ниндидер уртаклыклар эзли кебек:

Сагышларны сүтә-сүтә
Айлар үтә, еллар үтә.
Безнең язмыш синең белән
Мәңге бергә, Сөембикә.

* * *

Хәзерге талантлы шагыйрьләребездән берсе Мөдәррис Әгъләмов Сөембикә образына үзенчә килә һәм шулай ук аңа берничә шигырен багышлый. Бу җәһәттән аның «Мәңгелек ут» балладасы аеруча үзенчәлекле. Биредә бик борынгы мифология һәм фәлсәфә хакында тулы бер трактат язып булыр иде. Әмма безнең бурыч башкада. Балладада сүз сугыштан соңгы вакыйгалар нәтиҗәсендә гомерлеккә тол калган яшь хатын турында бара. Әнә шул кызганыч язмышны мөмкин кадәр төгәл билгеләү өчен шагыйрь сүзне Сөембикәдән башлый: «Сөембикә кебек гүзәл хатын, Кыйссаларга кереп калырлык...» Тирән фаҗигале юллардан башланган баллада шундый ук трактик сүзләр белән тәмамлана:

Сугыш дәвам итә, тамгаланып
Яңа буын килә дөньяга.

Күпләр күмер булды, ә ул гына менә
Мәңгелек ут кебек,
Ул—яна!

Мәдәррис Әгъләмовның «Син дә әкиятмени?» шигыре дә, исеменнән үк күренеп торганча, тулысынча халыкның бик борынгы мифологиясенә нигезләнә. Ләкин шулай да... шигырь баштан ахырга кадәр заманча яңгырый. Аның төп фикерен шулай ук Сөембикә образы күтәреп бара.

Күрүебезчә, әлеге мифологик образ шагыйрьгә шунда ук халыкара хәлләргә күчеш, Русиянең баскынчылык сәясәте турында тәфсилләп сөйләү мөмкинлеге бирә: Казан алынгач та Русия үзе өчен Нугай даласына, Әстерханга, бер-ике гасырдан соң Кырым ханлыгына юл ача бит.

Мәскәүнең XVI-XVIII йөзләрдәге халыкара сәясәтенең төп юнәлешләрен билгеләгәннән соң, шагыйрь хәзерге заман хәлләренә күчә. Сүз әкияти-мифологик Аждаһа турында барса да, укучы шагыйрьнең төп фикерен яхшы аңлый:

Әнә бүген аягүрә баскан...
Ахырзаман килеп җиткән мәллә?
Ышанмагыз: аждаһаның башын
Чабалар, дип, бары әкиятләрдә.

Бер карасаң, шагыйрь үзенең бу сүзләрендә һичшиксез хаклы: безнең заман чыннан да «аждаһалар аягүрә баскан» коточкыч бер чорны хәтерләтә. Илдә шундый авыр заманалар башлангач, төрле халыкларның милли азатлык хәрәкәте көчәеп киткән иде. Кырыс тарих законнары буенча, бер селтәнүдә элеккеге Советлар Союзының яртысы диярлек «кителеп төште». Заман җилләренең кая таба исүен сизгән, әмма әлегә Мәскәү карамагында калган башка халыкларда да, шул исәптән татар халкында да, милли азатлык хәрәкәте дәвам итте. Дөнья һәрвакыт бер урында гына тормый. Шулай булгач, без дә үзебезнең киләчәккә ышаныч белән карарга тиеш. Табигый, шагыйрь фикеренчә, безнең бу якты хыяллар Сөембикә исеме белән дә бәйләнгән.

Шигырь, бик борынгы мифология таләпләре буенча, Җирдәге Иман, илаһи Күктәге Ай һәм һәрвакыт шулар белән бергә атлаган якты өметләр белән тәмамлана:

...Күпме куерса да вакыйгалар,
Җирдә әле Иман,
Күктә Ай бар!

* * *

Күзәтелгән материаллар күрсәтүенчә, Сөембикә образы хәзерге татар прозасының да (Р. Батулла—«Сөембикә», М. Хәбибуллин—«Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный»), бик тыйнак кына булса да, драматургиясенең дә (Р. Хәмид—«Хан кызы») һәм шигъриятенең дә үзәгенә күчә бара. Ләкин шулай да безнең язучылар, бигрәк тә шагыйрь һәм драматурглар, Сөембикә алдында зур бурычлы булып кала бирә. Ни үкенеч: әлегә кадәр безнең әдәбиятта, гомумән сәнгатьтә, Сөембикә хакында чын мәгънәсендәге эпик-трагик поэма, тарихи трагедия, опера яисә балет иҗат ителмәгән!

# ЧЫН СӘНГАТЬ ӘСӘРЕ БУЛСЫН

## БҮГЕНГЕ ПРОЗАГА БЕР КАРАШ

Соңгы елларда «Казан утлары» редакциясе проза турында, туксанынчы еллар әдәбияты турында сөйләшүләр һәм рецензияләргә конкурслар оештырып, аларга вакытында җыйнак кына булса да йомгаклар ясап, язучылар өчен генә түгел, укучылар өчен дә бик кирәкле һәм файдалы эш башкарды. Күп кенә әдипләребезнең һәм тәнкыйтьчеләрнең бу өлкәдә үз фикерләре белән уртаклашулары, һичшиксез, бүгенге прозабызга уңай йогынты ясаячак. Бу инде үзен сиздерә дә башлады. Соңгы вакытларда дөнья күргән чәчмә әсәрләрнең иң уңышлыларын күрсәтеп, матур әдәбиятны укырга яратучыларның саны да күпкә арткандыр. Шактый арзаная һәм чүпләнә башлаган әдәбият дөньясыннан үзенә кирәген сайлап алырга, талымлы укый белергә һәм шул әсәрләр аркылы әдәби зәвыгыңны да үстерергә юнәлеш бирде әлеге чаралар.

Бигрәк тә Рифат Сверигиннның фикерләре бер генә укучыны да битараф калдырмагандыр. Ул прозаның уңышлы һәм уңышсыз якларын зур игътибар белән анализлап барды. Менә аның кайбер фикерләре: «Проза өлкәсендә берничә исемне атар идем. Бу исемлекнең иң өстенә башкалардан үзгә әдип Ф. Яруллинны куяр идем. Бу әдип турында сөйләгәндә үзәккә жанр мәсьәләләрен түгел, ә шәхес мәсьәләсен куярга кирәк. Әдип һәрвакыт үзе булып—халык, милләт, җәмгыятебезне борчыган заман, тормыш проблемаларын йөрәге аша үткәрүче, кичерүче һәм сынмас, буйсынмас рухлы шәхес булып кала»,—дип, ул аны Лев Толстойга тиңли, олы зат буларак бәяли. Бу олы затның тулы иҗатын өйрәнеп җәмәгатьчелеккә житкерергә чакыра. *(«К. У», 6 сан, 1999.)* Ул шулай ук зур язучыларыбыз Миргазиян Юныс, Әхсән Баян, Айдар Хәлим иҗатларының да өйрәнелмәгән булуын искәртә.

Р. Сверигин укучыны борчыган «негатив проза» үрнәкләренә дә үзенең мөнәсәбәтен белдерә: «Тормыш күренешләрен гел карага, пычракка манчып укучыга тәкъдим итү... Тормышта явызлык, әшәкелек аз түгел анысы. Ләкин әлеге хәл әдипләребезгә, тормыштагысын язам дип, начарлык күренешләрен күп тиражлар белән тарату хокукы бирми бит». Җитмәсә, кайбер мондый әсәрләр мәктәп программаларына кертелә башлаган икән. Бу хәлгә дә тирән борчылуын белдерә автор *(«К. У.», 5 сан, 1997 сан).*

Кызганыч ки, кайбер әдипләребезнең күңелне сискәндереп җибәрә торган фикерләре белән дә очрашырга туры килде. Мисал өчен Рафаэль Сибат болай яза: «Үзләрен «писательская братия» дип йөртсәләр дә, күңел җепләре белән тоташкан үзара рухи туганлык, эчке якынлык язучылар арасында аз, йә яшерен хөсетлек үзен шактый сиздерә. Бу бигрәк тә бер-берләренең язганнарын укымауда һәм укыса да, күрмәмешкә салынуда нык сизелә. Без битараф. Арттан үзебезгә ошамаганын хурлап йөрсәк тә, ошаганнарын күтәреп-мактап чыгарга көч җитми, күңел көзгесе каралган. Гомумән, ихласлык җитми. Шуннан ясалмалык та *(«К. У.», 8 сан, 1997 ел).*

Укучы гомер-гомергә язучыларга зур ихтирам белән карады. Кеше рухын тәрбияләргә алынган бу җаннарның үзара мондый мөнәсәбәттә булулары милләтебез өчен дә, әдәбиятыбыз өчен дә аяныч хәл бит.

Аллага шөкер! Әдәбият әһелләре арасында бер-берләренең күңелләрен күтәрә, иҗатларына канатлар куя, яңадан-яңа әсәрләренә рухландыра алырлык эчкерсез, ярдәмчел, олы йөрәкле шәхесләребез дә бар икән әле. Мәсәлән, күптән түгел чын татар дөньясын чагылдырган, искиткеч матур телдә язылган «Хәтер аланы» повесть-кыйссасы белән Тәбриз Мөбәрәков пәйда булды. Аны күрделәр, укыдылар, яраттылар. Әсәрнең сюжет корылышына, теленә соклануларын да белдерделәр. Шундыйлар арасында милләтебезнең күренекле әдибе Айдар Хәлимнең «И куандым!» дип исемләнгән, үтә дә

ихластан язылган зур һәм тирән эчтәлекле мәкаләсе беркемне дә битараф калдырмады. А. Хәлим, ул вакытта Чаллының үзәк мәйданында, чечен һәм татар халкының мөстәкыйльлеген яклап сәяси ачлыктан тәмам хәлсезләнгән булуына карамастан «Хәтер аланы»н укып кына калмый, шунда ук кулына каләм дә ала. «Әсир итте мине бу әсәр. Дөресен әйтим, соңгы 30-40 елда мин хәзерге татар әдәбиятында телне, стильне, вәзен-ритмны бу кадәр нечкә тойган чәчмә әсәр язучыны күргәнем булмады. Ялгышмасам, Фатыйх Хөснидән соң безнең чәчмә әдәбиятта телгә бу кадәр игътибарлы, чалгы кебек үткер, имән кебек олпат, бернинди шик калдырмый торган телле язучыбыз юк иде шикелле әле.

Юк, минем классикларыбызга тел тидерәсем килми. Киресенчә, мин, һич күпсенмичә, алар даирәсенә физика-математика галиме Т. Мөбәрәковны да кертәсем килә»,—дип язды ул *(«В. Т.», 30 апрель, 1995).*

Мондый ихлас һәм олы бәһадән соң Т. Мөбәрәковның ничек куанганын күз алдына китерү кыен түгел. Күп тә үтми, берсеннән-берсе оста язылган дүрт хикәясе, М. Мәһдиев истәлегенә күләмле матур язмасы, аның иҗатында тагы да рухланып, канатланып киткәне турында сөйли иде.

«Казан утлары»ндагы «Туксанынчы еллар әдәбияты» турында сөйләшүдә дә А. Хәлим тагын бер кабат «Хәтер аланы» повесте хакында «Тетрәтте ул әсәр мине! Бүтән бер генә дә әсәр алай тетрәтә алмады. Кызганыч, даһилыгы белән ихлас, ихласлыгы белән даһи бу каләмдәшебез озак та үтми дөнья куйды...»,—дип язды ул *(«К. У.», 4 сан, 1999).*

Язучы А. Хәлимнең үзенең чәчмә әсәрләре, шигырьләре дә, туры сүзле, кыю карашлы публицистикасы да аның илаһи талант иясе булуы турында дәлилли. Милләт өчен янып хезмәт итүче бу олпат әдибебез халкыбызның горурлыгы булып тора. Тик без бу шәхесне бәяләп бетермибез шикелле.

Арча төбәгеннән тагын бер талантлы язучы тууга халык язучысы, иллә дә эчкерсез Гариф Ахуновның да куанычы эченә сыймады. Үлеменнән соң булса да, ул аны Язучылар берлегенә кабул иттерүгә бөтен күңелен һәм көчен куйды. Бу изге эштә Ф. Яруллин, Ш. Галиев, А. Гыйләҗевнең да өлеше зур булды. Әмирхан ага Еники: «Т. Мөбәрәковның исеме, һичшиксез, безнең арада булырга тиеш, чөнки ул безгә тиң язучы. Ә киләчәктә, исән булган булса, бәлки әле бездән дә көчлерәк язучыга әйләнгән булыр иде. Мин моны һич икеләнмичә әйтә алам»,—дип бу эшкә үзенең хәер-фатихасын бирде. Киләчәктә дә язучыларыбызның бер-берләренә карата менә мондый матур мөнәсәбәтләре дәвамлы булса иде.

Проза турындагы әнә шундый сөйләшүләр әдәбиятта җанлы бер хәрәкәт башлап җибәрде кебек. Ул инде «Казан утлары» журналы белән генә чикләнмәде, башка журналлар, көндәлек матбугат битләрендә дә чагыла барды. Мәсәлән, «Мирас» журналында филология фәннәре докторы Фәрит Хатиповның соңгы елларда әдәбиятыбыз үсешендәге төп кимчелекләрне күрсәткән язмасы бик күп сорауларга ачык җавап булды. Шуннан бер өзек: «Хәзер тематик чикләүләр бетерелде. Кайбер талымсызрак язучылар моннан үзләренә нәтиҗә чыгарып куйдылар, реалистик әсәрләрдә дә чынбарлык кануннары, логика белән исәпләшмәскә мөмкин дигән фикергә килделәр, тормышка хилаф күренешләрне, җинаятьчел гамәлләрне табигый хәл итеп сурәтләргә керештеләр, җинаять өчен хөкемгә тартылуны, җәзасын алуны тасвирламыйлар. Тәнкыйть әнә шундый күрәләтә йомшак әсәрләргә игътибар итми, кимчелекләрен күрсәтми башлады. Әдәби тәнкыйтьнең көрәш дәрте, кыюлыгы сүрелә төште. Ул җитди генә эстетик чатаклыклар тирәсеннән күз йомып үтте, битарафлыкны кулайрак күрә башлады. Кайбер каләм әһелләренең әдәби сыйфат җәһәтеннән уртачадан түбәнрәк иҗаты хакында тоташ мактауга корылган язмаларның басыла торуы, йомшак әсәргә укымаган килеш унай бәя бирү күренешләре, әнә шул хакта сөйли. Әдәби мөлкәт өчен бу бик хәтәр хәл. Тәнкыйтьнең сүлпәнәюе әдәби хәрәкәткә тискәре йогынты ясый, зәгыйфь әсәрләрнең ишәюенә киң юл ача.

Әдәби тәнкыйть—демократик жанр. Аның абруен күтәрәсе бар. Бу җәмәгатьчелекнең мөһим бурычы булып кала».

Бу теманы «Мәдәни җомга» газите дә «түгәрәк өстәл» формасында күтәреп чыкты. *(18 июль, 1997 ел).* Әмма анда әйтелгән кайбер фикерләр бик үк аңлашылмады. Мәсәлән, «... Тәнкыйтьнең кадере бетте. Ул, ничектер, типкәләп йөртелә торган бер жанрга әйләнде». Бу элеккеге кайбер тәнкыйтьчеләрнең тәнкыйтьтән читләшә баруларына сәбәп итеп күрсәтелгән.

Ә менә әдәби тәнкыйтьне фәкать фән докторларына гына йөкләү дөресме соң? Китапны сатып алып укучы гади халык вәкилләре теге яки бу әсәр турында үз фикерләрен әйтергә, язарга хаклы түгелмени?!

Әлеге әңгәмәдән тагын бер мисал: «Психологик романнар өчен хәзер замана башка, җәмгыятьтә Толстойның «Яңадан туу»ы язылган халәт юк, шуңа күрә хәзерге укучының кеше күңелендә казынган әсәрләр укырга вакыты да, ихтыяҗы да юк һәм аларны укый да алмый. Хәзер информация заманы».

Ә ни өчен алайса Зөлфәт Хәкимнең «Гөнаһ» романы йотылып укыла? Әсәрдәге төп персонаж Фәезнең эчке кичерешләре Достоевскийның «Идиот», йә булмаса Толстойның «Яңадан туу»ы кебек укылмыймыни? Ничек кенә укыла әле! Теле дә йөгерек, җөмләләре дә төзек. (Сүз уңаенда әйтеп китим: шул ук Зөлфәтнең Камал театрында барган «Килә ява, килә ява» спектаклен гаиләбез белән кабул итә алмадык).

«Мәдәни җомга»дагы шул ук әңгәмәдән «Эче пошкан һәркем тарихи роман язды. Аларның эчтәлекләрендәге дөреслекне бер Хак Тәгалә үзе генә беләдер»,—дигән фикер бөтенләй аптыратты. Тарихи романнар язучы Нурихан Фәттах, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Флүс Латыйфи, Рабит Батулла, Җәмит Рәхимов, Вахит Имамовларның әсәрләре безгә милли тарихыбызны кайтарды бит. Без шул романнар аркылы милли азатлык өчен көрәштә башларын салган халкыбызның батыр уллары белән таныштык. Гомумән, үз тарихыннан мәхрүм ителгән татарның күзен ачты бу әдипләр.

Кайбер авторларның мәхәббәт күренешләрен тасвирлаганда натуралистик мавыгулары—соңгы елларда, әдәбиятка шактый кыю үрмәли башлаган бу алым милләтебезне кимсетә.

Ләкин матбугатта әйтелгән тәнкыйтьтән соң да язучы Мансур Шаһимәрдәнов мәхәббәт күренешләрен генә түгел, хәтта җенси азгынлык маҗараларын да натуралистик алым белән тасвирлаган «Татлы агу» исемле романын бер дә тартынмыйча укучыга тәкъдим итте. *(«К. У.», 11-12 саннар, 1998 ел.)*

Авылда туып-үскән, татар урта мәктәбен тәмамлаган Кадрия исемле кызның яшүсмер чорында ук башланган җенси талымсызлыгы әсәрнең башыннан ахырынача дәвам итә. Үз гомерендә исемен дә өч мәртәбә үзгәртеп—Кадрия, Шәфкать, Екатерина Павловна һәм янә Кадрия булып ул—теләсә кайда, теләсә кем куенына үзе ташланып йөргән коточкыч пычрак хатын. Инде бөтенләй акылга сыймаслык хәл—үз малае, ире кул астында эшләүче, кибетче Актимер белән... Шул кабахәтлекне кылганда, ирне шашып назлау хәрәкәтләрен ясап муенына үрелә һәм кинәт бармаклары ике зур миңгә төртелә. Шунда ук бу егетнең тууга балалар йортына ыргытылган үз улы, игезәкләренең сыңары икәнен таный һәм «Улым!»—дип кычкырып җибәрә. Авторга бу вакыйга гына җитмәгән: шул вакытта ук Актимернең хатыны да үзенең бертуган сеңлесе, ягъни Кадриянең кызы булуы ачыклана. Кешелек дөньясы каршында иң олы җинаятьләрнең берсе булган мондый фәхишлекне Актимер күтәрә алмый, асылынып үлә, хатыны Айгөл гарип бала тудыра, ә ана—Кадрия исән.

Романның соңгы битләрендәге хәлләрне тасвирларга кул бармый. Фәкать автор андагы вакыйгаларны язганда ак кәгазь битләре ничек түзгән дә, ничек күтәргән дип кенә уйлыйсың. Хатын-кызларыбызның, башка милләтләрдән аерылып тора торган тыйнак, гөнаһтан курку, оялчан булу кебек—горурлыгыбыз булган гүзәл сыйфатларны саклап, аны буыннан-буынга җиткерә алу каләм әһелләренең иң изге бурычы саналса иде!

Проза турындагы сөйләшүләрдә әдәби телебезнең хәленә игътибар аз бирелә кебек. Кайбер әсәрләрдәге агач теллелекне татар авылларының үзләренең дә табигыйлеген, миллилеген югалта баруы белән аңлаталар. Дөрес, бу фикер белән килешмичә булмый. Ләкин нәкъ менә шушы хәлне искә алып,

әдипләр телгә таләпчәнлекне тагын да арттырырга тиешләр түгелме соң?

Дөрес, соңгы вакытларда әдәби телебезнең фәкыйрьләнә, чүпләнә баруына һәм җөмләләрдәге мәгънә төгәлсезлегенә, эпитет, чагыштыру кебек сурәтләү чараларындагы талымсызлыкка борчылып язылган мәкаләләр очрый башлады. Мәсәлән, Әхәт Фазылжановның (Балтач) «Берәүгә дә ташлама юк» дигән тәнкыйть мәкаләсе адрессыз булса да, тел гыйлеменнән яхшы хәбәрдар булган бер язучының әсәрләрендәге җөмлә төзексезлекләрен конкрет мисаллар белән дәлилләп күрсәтә. Әсәр эченнән алынган кайбер җөмләләрдән, сурәтләү чараларыннан чәчләрең үрә торырлык. Мисаллар китереп тормыйм, чөнки алар бик күп һәм әдәби әсәр өчен берсеннән-берсе гайрәтне чигерә торганнар. Автор: «Укучы теләсә нәрсәне талымсыз кабул итми—язучыларыбыз шуны онытмасыннар иде»,—дип нәтиҗә ясый. *(«М. Ж.», 12. 1. 2001.)*

Язучы Әхәт Сафиуллин «Укучыны хөрмәт итик» дигән мәкаләсендә *(«В. Т.», 26. 1. 2001)*: «Ни кызганыч, илдә бара торган тәртипсезлек, җимерү процессы телебезгә дә бәреп керде. Хәзер кем ничек тели, шулай яза... Дөрес язу кагыйдәләрен, сүзлекләрне бер селтәнү белән юкка чыгардык ...»— дип, гәзит-журнал һәм китаплардагы тел чатаклыкларын бәхәссез мисаллар белән дәлилләп яза.

Танылган шагыйребез Әхмәт Рәшит тә «Әй, бу каһәр суккан тел!» дигән мәкаләсендә төрле сүгенүләр, оятсыз сүзләрнең әдәбиятка үрмәли башлавына, искиткеч бай ана телебезнең матур мөмкинлекләреннән файдаланып иҗатыбызны бизи алмавыбыз турында борчылуын белдерә. «Әдәбиятта һәм сәнгатьтә «сасы авызлар»га урын булмасын иде»,—ди ул. Бу очракта Аяз Гыйләҗевнең «Телгә янаган хәвеф, табигый рәвештә әдәбиятка да яный!»— дигән сүзләрен искә төшерәсе килә.

Тел мәсьәләсендә, моңарчы ишетелмәгән, сәер карашлар белән дә очрашырга туры килде. «Прозада гыйльми тел», «Галәти булмаган галим теле» кебек фикерләр һәм аны әдәбиятта зур яңалык итеп хуплап чыгу булды. *(Н. Хисамов. «В. Т.», 31 декабрь, 1997 ел.)*

Соңгы вакытларда матур телле чын милли әсәрләрне сагынудан Әмирхан Еникинең һәм Тәбриз Мөбәрәковның повесть-хикәяләрен кабат укып чыктым. Әйтерсең лә, мин милли телебезнең гүзәл бакчасына килеп әләктем дә, ләззәтләнеп сәяхәт кылып, челтерәп аккан чишмәләрнең тәмле суларын эчтем. Ә. Еникинең кайбер хикәяләре әллә ни зур сюжетка да корылмаган. Ә теленең байлыгы, нәфислеге, сыгылмалыгы аркасында тәмле ризык ашаган кебек, укып туеп булмый. Хәтта аерым өзекләрен күңелдән ятлыйсы килә.

Ни шатлык: күптән түгел мин Индус Сирматовның һәм теле, һәм сюжеты белән сокланып туя алмаслык «Ак бишек» повестен уку бәхетенә ирештем. Ул гаҗәп матур тел белән, укучы соңгы елларда үтә дә тансыклаган, чын татарның рухи дөньясындагы аклыкны, матурлыкны ачып, йокыга талып баручы милли хисләребезне уята алырлык итеп язылган. Ләкин ни өчендер тәнкыйтьчеләребезнең игътибарыннан читтә, күләгәдә калды бу әсәр.

Бу повестьның бәхетенәдер, «Ак бишек»кә кереш сүзне халык язучысы мөхтәрәм Аяз Гыйләҗев язган һәм әсәргә бик югары бәя биргән.

Иң актив язучыларыбызның берсе Радик Фәизов, әдәбиятта матур алымнар табып, күңелендә булган уй-фикерләрен армый-талмый укучысына җиткерә бара. Һәр язган әсәре җиңел укыла, җөмләләре бик тә төзек, гади. Гомумән, минем уйлавымча, язучы Радик Фәизовның бөтен әсәрләре үзенең чиста, керсез күңелле, үтә дә тыйнак, кешеләргә игътибарлы олы шәхес булуын исбатлый кебек.

Әдәбиятыбызның хәле, үсеше турындагы сөйләшүләрне «Казан утлары» журналы киләчәктә дә дәвам итсен иде. Андый чараларның берсе дә эзсез калмый бит.

**Гөлчәчәк ГАЛИЕВА**

Тarix
Тарих

## БЕР ГЫЙБРӘТЛЕ ТАРИХИ ХЕЗМӘТ ХАКЫНДА

1995 елда Финляндиядә булган чагымда кайбер галим-голәмә, фән әһелләре белән дә очрашып, әңгәмәләшү вакытында финн халкының борынгы тарихы, чыгышлары, гомумән "финн-угор халыклары" дигән төшенчә һәм финнарның венгрлар (мажарлар) белән якынлык дәрәҗәсе хакында да сүз чыккан иде. Әңгәмәдәшләрнең берсе финн-венгр якынлыгы хакындагы мәсьәләгә, мыек астыннан елмая-елмая, мондыйрак "аңлатма" биргән иде:

—Кайчандыр Азиянең бер төпкелендә, кайдадыр Урал арты тирәләрендәме, финн һәм угор дигән үзара якын кардәш, телләре уртак ике кавем яшәгән, диләр. Бер заманны болар, ниндидер сәбәпләр аркасында, көнбатышка таба күченергә мәҗбүр булалар. Аларның берсе, финн дигәннәре, төньяккарак, ә угор исемлесе, ягъни мажарларның бабалары, көньякка таба юнәлүне кулай таба. Бертуган кардәшләр төп йорттан аерылып чыккан чакта, галәттә, уртак милекне үзара бүлешәләр. Боларның иң кадерле уртак байлыгы—телләре генә булган икән. Ничек итеп аны бүлеп алырга соң? Бу сүз—сиңа, монысы—миңа, дипме? Болай барып чыкмый эшләр—бәхәс куба. Уйлана торгач әмәлен дә табалар: болар телнең гамәли кулланылышта булган сүзләрен түгел, бәлки шул сүзләрне ясый торган "чималны", ягъни авазларны бүлешергә булалар. Җирәбә салу юлы белән, диләр. Нәтиҗәдә, сузык авазларның күбесе финнарга эләгеп, ә угор-мажарларга исә тартык авазлар мулрак тигән, имеш... Шуңа күрә хәзерге венгрлар белән бүгенге финнар арасындагы борынгы кардәшлекнең тамырлары нык яшеренгән, телләребез өлкәсендәге аермалыкның табигате дә менә шулай бик үзенчәлекле булып чыккан!..

Бу хикмәтле хикәяттә, шаяру элементлары "кычкырып торган" шикелле, тарихи якынлыкны, әлеге ике тел арасындагы үзенчәлекләрне дә күрсәтә торган тапкыр ишарәләр образлы итеп бирелгән, әлбәттә. Чыннан да финн телендә *аа, оо, уу, ии ...* кебек сузык авазлар икеләтелгән, ао, оу ... кебек безнең телгә ятып бетми торган дифтонглашкан катлаулы сузык авазларның актив кулланылуы да мәгълүм. Венгр-мажарларда исә киресенчәрәк ...

Хәзер әллә кайчан ишеткән хикмәтле шаяртуны искә төшерүем очраклы түгел. Чөнки, дөньядагы күп халыкларның борынгы тарихлары томанлы булган кебек, финн-угор кавемнәренең бер тармагыннан гыйбарәт булган хәзерге мажар-венгрларның ерак узганнары да үзендә күп серләр саклый. Әкрен-әкрен чишелә, зур кыенлыклар белән ачыклана бара торган серләр алар. Моның шулай икәнлеген профессор Андраш Рона-Ташның яңа китабы мисалында да күрергә мөмкин[1].

* * *

Иң элек журнал укучыларын китап авторы белән кыскача таныштырып узу кирәк булыр. "**Венгрлар һәм Урта гасырлар башындагы Аурупа: борынгы венгр тарихына кереш**" исеме белән, Үзәк Аурупа Университеты нәшриятында инглиз

[1]Ил һәм халык исеме Аурупа телләрендә *Hungary, Hungarian* рәвешендә (русча *Венгрия, венгры*) кулланыла. Халыкның үзатамасы булып *мадьяр — мажар* гамәлдә йөри. Безнен текстта әдәби традициядәге *мажар* белән безнең илдә кин таралган *венгр* вариантлары синоним рәвешендә кулланылыр.

теленд басылып чыккан бу зур күләмле хезмәтнең[1] авторы **Андраш Рона-Таш** 1955 елда Будапешт университетын тәмамлый. Ориенталистика фәннәре буенча бөтен Аурупа күләмендә киң мәгълүм галимнәр—тюркологлар, иранистлар, монголистлар, синологлар ("кытайчылар") укыткан университетта ул шәрекъ халыкларының этнографиясе, археологиясе, тарихы һәм телләре буенча этрафлы һәм төпле белем ала. Беренче (безнеңчә кандидатлык) диссертациясен ул 1964 елда тәмамлый. Алтай телләре буенча чагыштырмалы тикшеренүгә багышланган икенче, ягъни докторлык диссертациясен 1971 елда төгәлләп, уңышлы яклый. (Алтай теле дигән төркемгә төрки, монгол, манчьжур телле халыклар керә; шул телләрдә сөйләшүче кавемнәрнең узганын һәм бүгенгесен төрле яклап өйрәнүче махсус гыйлемне—ориенталистиканың бер тармагын **алтаистика** дип атыйлар.)

Үзе эшли торган белем тармагы буенча яңа юнәлеш ачып җибәрә алган профессор А.Рона-Таш 1974 елдан башлап озак вакыт Сэгед университетындагы алтаистика кафедрасы белән җитәкчелек итә, шунда берәмтекләп дигәндәй, тирән белемле кадрлар әзерләүгә зур көч куя (бу кафедра белән Казан университетының элек СССР тарихы, аннары татар халкы тарихы кафедралары арасында хезмәттәшлек буенча 1987 елда килешенү төзелгән иде). Галимнең тарихи алтаистика өлкәсендә, бигрәк тә алтай телле халыкларның борынгы язмышларын, телләренең үсү-үзгәрү үзенчәлекләрен өйрәнү буенча ирешкән казанышлары ориенталистика фәне дөньясында киң танылa. Моның шулай икәнлеген, хезмәтләренең төрле илләрдә, төрле телләрдә еш басылуыннан тыш (исемлек 300 дән артык), аның чит илләрдәге университетлар тарафыннан профессор сыйфатында эшкә чакырылуыннан да күрергә мөмкин. Мәсәлән, 1971 һәм 1985—1986 уку елларында ул Бонн һәм 1982—1983 елларда исә Вена университетларында контракт буенча лекцияләр укый. Профессор Рона-Таш 1990 елдан Венгрия фәннәр академиясе әгъзасы.

Ниһаять, махсус билгеләп үтәргә кирәк, профессор Рона-Таш, алтай төркеменә карый торган телләрдән тыш, "урал" төркеменә керүче финн-угор һәм башка Себер-Урал халыкларының телләре буенча да тирән белемгә, киң эрудициягә ия тикшеренүче. Телләрне ул академик алымнар белән, ягъни китап-дәреслек, сүзлек-кулланмалар ярдәмендә үзләштерү белән генә чикләнмичә, аларны табигый тормыш шартларында өйрәнүгә дә әһәмият бирә. Моның шулай икәнлеген 1957, 1958 елларда Монголиядә этнографик һәм лингвистик материаллар туплавыннан, 1965 һәм 1973 елларда исә Урта Идел буена сәяхәтләр ясап, төрки телләрнең кайбер борынгылык сыйфатларын күбрәк һәм ныграк саклаган чуаш телен җентекләп тикшерү мисалыннан да күрәбез.

Профессор А.Рона-Таш, өйрәнү вә тикшерү объекты булган күпсанлы урал-алтай халыклары телләреннән тыш, шул телләргә теге яки бу күләмдә мөнәсәбәте булган башка кавемнәрнең тарихлары һәм телләреннән дә яхшы хәбәрдар. Мәсәлән, ул төрки-монгол халыклары белән борынгылыкта якыннан аралашкан кытайларның, тибәтлеләрнең борынгы чор телләрен, язуларын махсус өйрәнгән. Узган дәверләр буенча бай мәгълүмат саклаган латинча, юнанча (борынгы грекча) чыганаклардан да галим оригиналда иркен файдалана. Шулай ук ул хәзерге Аурупа халыклары телләреннән немесчә, инглизчә, французчаны да яхшы белә; русчаны иркен аңлый һәм җиңел сөйләшә; хезмәтләренең зур өлеше инглиз телендә нәшер ителгән. Галимнең татар теле хосусыятларын нечкәләп аңлавын XVII гасыр исәлеге булган "Дәфтәри Чыңгызнамә" текстына карата (фикер алышулар вакытында) ясаган күзәтүләреннән, нәтиҗәләреннән күрергә мөмкин иде. Җыеп кына әйткәндә, Рона-Таш сүзнең чын мәгънәсендәге полиглотлардан, ягъни күп телләр белүчедән санала ала. (Юл уңаенда тагын бер гыйбрәтле күренешкә игътибар итик. Гомумән, Венгрия ориенталистлары, бигрәк тә тюркологлары күп телләрне практик белүләре белән аерылып торалар. Аларның күпчелеге башка илләргә барып, анда инглиз, немец, француз, төрек һәм рус телләрендә гыйльми эшләр башкарырга, озаклап лекцияләр укырга сәләтлеләр. Шуңа күрә, чит ил университетларында эшләр өчен конкурслар

[1]Rona-Tas Andras. Hungarians and Europe in the Early Middle Ages: An Introduction to Hungarian History. Central European University Press. Budapest, 1999, 566 p.

игълан ителгән чакта, ярышта венгр тюркологлары да актив катнашалар һәм еш кына җинеп чыгалар, хәтта кафедралар белән җитәкчелек итәләр. Шул сәбәпле ярышларда уза алмаган көндәшләр арасында Венгрия тюркологларына карата ачу белән әйтелә торган, асылда гадел булмаган "мажар мафиясе" ише гыйбарәләрне ишетергә туры килгәли.)

Венгрия галименең мондый сыйфатлары хакында тәфсилләп сөйләвем очраклы түгел: түбәндә махсус күзәтелә торган китапның гомум әһәмиятен, гыйльми кыйммәтен гаделрәк бәяләр өчен авторның төрле тарихи чыганакларга таянуда нинди колач кинлегенә, белем күләменә ия икәнлеген төгәлрәк күзаллау зарур. Моның өчен шулай ук хезмәтнең эчтәлегенә, бигрәк тә аның нәзарый, ягъни теоретик, методологик өлешләренә һәм безнең үз мәнфәгатьләребезгә күбрәк якын торган тюркологик сюжетларга кагылышлы сәхифәләренә иркенләбрәк тукталу кирәк булыр. Бер уңайдан кайбер мәсьәләләр буенча үзебезнең уйларны, өстәмәләрне дә теркәп баруны кирәк табабыз. Тик, авторның бу китапта башкалар белән бәхәскә керүдән рәсми рәвештә баш тартуын исәпкә алып, без дә сүз көрәштерүдән сак булырбыз.

* * *

А. Рона-Ташның югарыда аталган хезмәте мажар телендә язылып, беренче мәртәбә 1996 елда дөнья күргән; яңа материаллар өстәлгән, күләм ягыннан да киңәйтелгән икенче басмасы 1997 елда нәшер ителгән. 1999 елда чыккан инглизчә варианты менә шул венгрча соңгы басма нигезендә эшләнгән.

Китап, фәнни тикшеренүләр өчен зарур булган алгы сүз, махсус гыйльми аппараттан тыш (иллюстратив материал, таблица һәм карталар, библиография, конкрет искәрмәләр һәм күрсәткечләр—аларның гомум күләме китапның өчтән бер өлешен тәшкил итә), дүрт зур кисәктән, болары исә уртача өч-дүрт тематик бүлектән гыйбарәт.

Хезмәт, авторның тарихны аңлау һәм аңлатуда нинди юл тотуын, төрле характердагы мәгълүматлардан ничегрәк файдалануын тәфсилләп аңлата торган "сүз башы" белән ачыла. Алты гына биттән гыйбарәт кечкенә күләмле, ләкин тыгыз эчтәлекле сүз башы галимнең тарих дигән гаҗәп хикмәтле вә искитәрлек катлаулы күренешне яктыртуда гадәттәгечә җиңел юлдан китмәвен, бәлки һәр мәсьәләнең күпмегә катлаулы, каршылыклы, хәтта буталчык икәнлеген аңлап эш итүен күрсәтә. Аның инануынча, популяр схемалардан, шул исәптән марксистик догмалардан арыну, төрле типтагы чыганакларның информациясеннән кинрәк, әтрафлырак файдалану белән бергә, моңарчы да мәгълүм булган материалларны да яңача тәнкыйть күзлеге аша бәяләү мөмкинлеген тудыра. Бары шулай гына хакыйкатькә якынлашып була, ди автор.

Шул ук вакытта фәнни тикшеренү уңышлы башкарылсын өчен бер төп принциптан тайпылмау зарур. Ул принцип иң элек төрле фән өлкәләренең, шул фәннәргә вәкиллек итүче галимнәрнең хезмәттәшлегеннән гыйбарәт булып, дүрт зарури шартның үтәлүен таләп итә. **Беренчедән**, мондый хезмәттәшлек тәнкыйди методны танып, шул тәнкыйди алымның төрле белем өлкәләрендә дә кирәклеген аңлау. **Икенчедән**, фараз-гипотезалар белән мавыкмаска, дөресрәге гипотезаларны факт белән бутамаска (чикләнгән күләмдәге, ачык әйтелгән фаразларның яшәүгә хаклары бар) һәм белемчен бер өлкәсендә барлыкка килгән гипотезаларны икенче өлкәләргә күчермәскә. **Өченчедән**, артык кырыс тәнкыйдилек белән мавыгып, һәр карашны да кире кагып бармаска; җитди тәнкыйди алым мәгълүматлар аз булган очракта күбрәк файдалы; чишелеп бетмәгән мәсьәләләрне ачык калдыру һәм шул ачыклыкны икърар итү мөһим—аларның киләчәктә ачылуы ихтимал. Ниһаять, **дүртенчедән**, үзара кардәш булган һәр белем өлкәсенең үзенә генә хас методологиясе булуын танып, берсенең алымнарын икенчесенә механик рәвештә күчермәү зарур.

Тел факторларының әһәмиятен тулаем кире какмаган хәлдә, Рона-Таш фикеренчә, лингвистик мәгълүматлар, бигрәк тә этимологик "чишелешләр" белән мавыкмау хәерле. Чөнки кайбер "этимологик шаккатыризмнар" венгр халкының борынгы тарихын яктыртуда буталчыклар китереп чыгарды. Мәсәлән,

борынгы мажарларда төркичә яки грекча сүзләрнең, ялгызлык исемнәренең очравы белән мавыгу. Чынлыкта андый алынма сүзләр этник нигезнең алмашынуын түгел, бәлки күрше кавемнәр белән тыгыз мөнәсәбәтләрнең дә нәтиҗәсе булырга мөмкин. Шуңа күрә бу китапта кайбер хезмәтләрдә күп кулланыла торган кебек лингвистик, этимологик этюдларга артык киң урын бирелми. Тарихны аңлар өчен тел фактлары мөһим булса да, күп мәсьәләләрне хәл итүдә аларның мөмкинлекләре шактый чикләнгән.

Шулай ук археологик материаллардан файдаланганда да зур саклык кирәк. Мәсәлән, мәетне күмү йоласы үзгәрүдән чыгып, теге яки бу территориядә халыклар этник яктан үзгәргән, ягъни алмашынган, дип раслау фәнни әдәбиятта киң таралган. Йола үзгәрүнең этник алмашыну түгел, бәлки идеологик һәм матди үзгәрешләрнең нәтиҗәсе булуы да ихтимал. Әйтик, 1960 еллардан алып, бездә мәетнең үзен күмүдән бигрәк, аны яндырып, җиргә көлен тапшыру киң тарала башлады. Мондый үзгәрешне 1945 елда Венгриянең Кызыл Армия тарафыннан басып алынуы белән бәйләп, "этнос алмашынды, яңа халык килеп утырды" дип расларга мөмкин түгел бит! Кыскасы, чикләнгән археологик материаллар нигезендә генә этник үзгәрүләрне төгәл билгеләп булмый икән. Кызганычка каршы, күп очракта моның киресе, ягъни теге яки бу археологик материаллар белән билгеле бер этнос арасына тигезлек билгесе кую гамәлгә кереп киткән...

Этнографик мәгълүматлардан файдаланганда да зур саклык сорала. Кайбер гореф-гадәтләрнең, матди культура элементларының тиз үзгәрә торганнары булган шикелле, аларның тотрыклылары да шактый. Димәк, андыйларны үзара аера белү зарур. Кыскасы, барлык этнографик фактларны да абсолют хөкем рәвешендә куллану кулай түгел икән.

Тел материаллары мәсьәләсенә килгәндә борынгы халыкларның этнонимнары, ягъни исемнәре уртаклыгыннан гына чыгып аларны үзара тәңгәлләштерү дөрес булмас иде. Минемчә, ди автор, төрки телле Идел буе болгарларын славянлашкан Дунай болгарларыннан аерып карау, һәрберсенең үз язмышын җентекләбрәк тикшерү дөресрәк булыр иде.

Мажар тарихындагы актуаль проблемаларның берсе ул венгр телендәге борынгы төркичә элементлар мәсьәләсе. Бу хакта автор үзенең махсус монография өстендә эшләвен әйтеп, укучылар хөкеменә тәкъдим ителгән китапның исә борынгы мажар-венгр тарихына багышланган булуын күрсәтә һәм аның киң җәмәгатьчелек өчен файдалы булуыннан өмет итә.

Монда китерелгән мәгълүматлардан күренгәнчә, А.Рона-Таш, узган чорлар хакындагы материалларны гадәти теркәп бару белән генә чикләнмичә, төрле типтагы чыганакларның материалларын тәнкыйть иләге аша уздырып, теоретик планда үзләштерүне дә максат итеп куйган икән. Ягъни безнең алда гадәти генә "сүз башы" түгел, ә төгәл бер концепциягә ачкыч та икән.

Хезмәтнең "**Методологик кереш һәм чыганаклар**" дигән беренче кисәгенең баш өлеше (3-41 бб.) тарих фәнендә еш кулланыла торган атамалар һәм төшенчәләргә багышланган. *Тарих, борынгы тарих, тарихның элгәргесе* (proto-history), шулай ук *халык, этнос, тел, этноним, милләт* төшенчәләренең кулланылышы, авторның исә кайсысына кайчан нindirәк мәгънә салуы ачыклана. Аннары тарихи чорлар, дәверләр, тарихта вакыт һәм киңлек, халыкларның килеп чыгышы, даирә, табигый чынбарлык кебек борынгы узганны аңлар өчен зарур булган шартлар, категорияләр аерым-аерым күзәтелә. Болардан безнең өчен халык һәм этноска, тел һәм милләткә караган бүлекчәләрдәге кайбер фикерләре кызыклы булыр шикелле.

Галим уйлавынча, киңрәк эчтәлеккә ия *этнос* аңлашу чаралары (шул исәптән телләре) уртак, гомум үзатамасы, үзләренә хас яшәеш туфрагы, сәяси оешмасы, дини карашлары булган кешеләр җыелмасыннан торса кирәк. *Милләт* исә, этнос белән чагыштырганда, соңрак барлыкка килгән иҗтимагый-сәяси категория булып, аның нигез элементлары бик борынгы заманнарда барлыкка килгән "әзерлеккә" барып тоташа. Әгәр борынгылыкта берәр халыкның *дәүләт һәм этник чикләре* бер-берсенә якынча туры килгән булса, андый халык Урта гасырларда ук милләт булып оешып җиткән.

Галимнең соңгы аныкламасы, фикеребезчә, махсус игътибарга лаек. Чөнки совет чорында бездә хөкем сөргән, хәзергә кадәр аңнарыбызда яшәп килә торган теоретик күзаллау буенча милләт оешуда һәм яшәүдә *дәүләтчелекнең әһәмиятенә* тиешле игътибар бирелми килде сыман.

Беренче кисәкнең "**Чыганаклар**" дигән икенче бүлеге (43-168 бб.) мажар тарихын өйрәнү өчен кирәкле чыганакларны барлауга һәм кыскача бәяләүгә багышланган. Бүлекнең баш өлешендә нәрсә ул *тарихи чыганак* һәм аны ничек *тәнкыйть итәргә* (ләкин безнең көнкүрештәге кебек сүгәргә түгел, бәлки дөреслек дәрәҗәсен сынау аша бәяләргә) дигән мәсьәләләр карала. Гадәттә күпчелек тарихчылар чыганакларның берәр төре (тибы) белән эш итеп, калганнарын читләтеп узарга яки аларга өстән-өстән генә кагылырга яраталар. Чынлыкта *тарихи чыганак* дигән категория күпкә киңрәк һәм гаять катлаулы нәрсә. "Безнеңчә,—ди автор,—борынгы чорлар буенча информация бирүгә сәләтле фактик материалларның һәммәсе дә чыганак, дип исәпләнергә тиеш "(43 б.).

Язма чыганаклардан тыш тел фактлары белән археологик материаллар да, физик антропология белән этнографик күренешләр дә тарихи чыганаклар җыелмасын тәшкил итәләр. Ләкин мондый мәгълүматларның күп булуы, бигрәк тә аларның гел ишәеп, күбәеп торулары вакыт һәм "колач житмәү" кыенлыгын да тудыра. Мондый төрле характердагы информация "чишмәләреннән" уңышлы файдалану өчен махсус белем тармаклары барлыкка килгән. Тик бер белем тармагы вәкиленең икенчерәк (ләкин кардәш) белем өлкәсендә ирешелгән табышлардан, казанышлардан тиешле дәрәҗәдә файдаланмау күренешләре дә очрый. Ул гына аз дигәндәй, кайбер галимнәр үзләренә "ошаган" яки үз фаразларына туры килгән табышларны гына сайлап алып, "ошамаганнарын" читләтеп узу фактлары да житәрлек. Нәтиҗәдә фактлар белән "уйнау" кебегрәк күренешләр барлыкка килә.

Чыганакларның һәр төре (тибы) үзенә хас тәнкыйди анализга мохтаҗ. Шул ук вакытта аларның һәммәсе өчен дә уртак принциплар бар. Әйтик, теге яки бу чыганакның безне кызыксындырган вакыйгаларны турыдан-туры яисә кыеклап кына яктырту мәсьәләсен ачыклау кебек. Язма чыганакларның тәнкыйте бары үзенә генә хас алымнар сорый (текстның төп нөсхә булу-булмавы, язу-шрифт һәм текстның редакцияләнү үзенчәлекләре, соңрак өстәмә рәвештә эшкәртелү-эшкәртелмәү, фактлар өстәлү яисә кыскартылу мәсьәләсе һ.б. һ.б.).

Чыганак информациясен тәнкыйть иләге аша уздыру белән аны аңлау һәм аңлату, файдалану, ягъни интерпретация арасында да аерма бар. Шул ук вакытта интерпретация тәнкыйть итү алымнарына да тәэсир ясаячак. Ягъни, файдалану максатыннан, аның сыйфатыннан чыгып, гыйльми тәнкыйтьнең таләпләре дә үзгәрергә, билгеләнергә мөмкин.

Автор, борынгы заман мажар тарихының һәр чоры өчен дә язма чыганакларның бер дәрәҗәдә булмавын билгеләп, үзе танышкан, файдаланган чыганакларның этник чыгышлары, телләре буенча аерым-аерым төркемнәренә махсус күзәтү ясый.

Китапның бу өлеше белән танышкач, борынгы чор һәм Урта гасыр башы мажарлар, аларның кардәшләре, күршеләре хакындагы мәгълүматларның теге яки бу күләмдә күп телләрдәге язма истәлекләрдән табылган булуын күрәбез. Андый чыганакларның анализлану тәртибе борынгы венгр тарихына кагылышлы хәбәрләрнең күләм һәм сыйфат дәрәҗәсеннән чыгып билгеләнгән. Шуңа күрә беренче урыннарны юнанча (борынгы грек) һәм латинча истәлекләрнең алуы артык гаҗәп түгел. Хәзерге венгрларның бабалары Дунай-Балкан якларына күченеп килгән чорлардагы Аурупа мәдәниятендә шул ике тел фән һәм әдәбият теле булып хезмәт иткән. (Җөмләдән христианлашкан мажарларга да.) Латин телендәге чыганаклар исә үз нәүбәтендә авторлары венгр булмаган һәм венгр булган төркемнәргә бүленеп карала.

Славян телләрендәге истәлек төрләрендә—бик борынгы риваятьләрдән алып, соңрак туган елъязмаларга кадәр—теркәлгән хәбәрләрдән соң игътибар "урта фарсы" һәм мөселман авторларыннан калган язмаларга юнәлә. Аннары борынгы сүриячә, әрмәнчә, грузинча, борынгы төрки һәм тибәтчә, ниһаять, кытайча, яһүдичә (хәзәр тарихына караган) истәлекләргә күзәтү ясала. Югарыда

бер мәртәбә махсус билгеләнгәнчә, профессор А.Рона-Таш бу телләрнең күпчелеген белә, шуңа күрә турыдан-туры аларның оригиналлары белән эш итә. Мәсәлән, борынгы кытайча чыганакларның тел-язу үзенчәлекләренә, анда теркәлгән сүз-атамаларның укылышы, транскрипциясе буенча махсус бүлекчәләр бирелүе шул фикерне раслый. (Будапешттта чакта А.Рона-Ташның аспирантлар белән үз өендә борынгы тибәтчә истәлекләр буенча махсус дәресләр уздыруына үзем дә шаһит булган идем—*М.Г.*)

Чыганаклар буенча галим башкарган күзәтүләрдән мажар тарихы белән кайбер төрки кавемнәрнең ерак узганын өйрәнү өчен дә уртак истәлекләрнең шактый булуын күрәбез. Мәсәлән, борынгы төркичә эпиграфик текстлардан тыш, Ибне Фазлан, Ибне Рустә, Әбү Хамид әл-Гарнатый, әл-Истәхри, Мәкъдиси, Якут әл-Хамави һ.б. әсәрләре кебек. Моннан Урта гасыр гарәпчә географик-тарихи язмаларның күп халыклар тарихын өйрәнү өчен нинди әһәмияткә ия икәнлеген тагын бер кат күрергә мөмкин.

Төркичә чыганакларга багышланган бүлекчәдә (80—82 бб.) VI-IX гасырларга караган руник истәлекләрне классификацияләү—чор һәм эчтәлекләре буенча төркемләп чыгу игътибарны җәлеп итә. Шунда ук кыскача Уйгыр каганлыгы чорына караган язмаларга да бәя бирелә. Әлбәттә, мажар тарихчысы күзлегеннән.

Борынгы һәм Урта гасыр Үзәк Азиядә зур, тәэсирле көчләрнең берсен тәшкил иткән **Тибәт империясе** тарихына, тибәт телендә язылган һәм сакланып калган язма истәлекләргә дә автор махсус туктала (82—84 бб.). Тибәтлеләрнең ут күршеләре, хосусан Төрки каганлык белән мөнәсәбәтләре каралып, тибәтчә теркәлгән кайбер хәбәрләрнең гомум Үзәк Азия тарихы, димәк, тамырлары белән шул регионга бәйле күп кавемнәрнең узганын өйрәнүдә әһәмияте билгеләнә. Ә борынгы мажар-венгр тарихын төрки дөньядан башка карау мөмкин булмаса кирәк.

Бу моментка махсус игътибар итүебез очраклы түгел: борынгы төркиләрнең тарихына караган хезмәтләрдә тибәтчә чыганакларга монарчы тиешле күләмдә мөрәҗәгать итү булмады дип әйтергә мөмкин. Гәрчә борынгы төрки мәдәниятнең, бигрәк тә дини инануларга караган рухи культураның кайбер тамырлары Тибәт тауларына барып тоташуларына кызыклы ишарәләр булган тәкъдирдә дә!.. Кыскасы, тарихи тюркология өчен киләчәктә тибәтчә чыганакларны махсус өйрәнү ул актуаль мәсьәләләрнең берсе, дип әйтергә була.

Борынгы кытайча чыганаклар хакында да, гәрчә алар белән русча, французча һәм алманча тәрҗемәләр аркылы, беркадәре таныш булсак та, шундый ук үкенечлерәк хөкем белән чикләнергә мәҗбүрбез. Дөрес, бу юнәлештә соңгы вакытта өстәмә мөмкинлекләр дә барлыкка килә башлады. Мәсәлән, әле генә узган XX гасырның 80—90 елларында борынгы кытайча язма истәлекләрнең төркиләр тарихына караган кайбер мөһим үрнәкләре хәзерге уйгырчага тәрҗемә кылынып, Шенҗаң халык нәшриятында Өремчәдә басылып та чыктылар (*Сыма Чиян.* Тарихи хатирәләр, 1989, 672 б.; *Бэн Гу.* Хәннамә, 1994, 972 б.; *Фэн Йи, Сыма Биау.* Кэйинки хәннамә, 1996, 692 б.) Тәрҗемәләрнең бу өч җыентыгы кытайча атаклы "24 тарих" исемле мәшһүр туплам буенча эшләнгән. Борынгы хуннулар, алардан соңгы төркиләр хакында мул мәгълүматлар сакланган, гарәп язуындагы бу басмалардан тарихчыларыбыз киләчәктә активрак файдаланса иде дигән теләк белән канәгатьләник хәзергә.

Профессор А.Рона-Таш тел чыганакларына да шактый күләмле бүлекчә багышлый (92—16 бб.). Мажарчага борынгы һинд-аурупа, җөмләдән "урта иран" һәм соңрак дәверләрдәге Аурупа халыклары телләреннән күчләп кергән элементлардан аерым лексик берәмлекләрне, исемнәрне барлап, ул аларның тарихи язмышларын (беренчел, икенчел мәгънәләрен, үзгәрү үзенчәлекләрен) шактый тәфсилле итеп күзәтә. Әлбәттә, анда алтай, бигрәк тә төрки һәм монгол телләреннән кергән сүзләрне анализлауга да тиешле урын бирелә. Бу темага А.Рона-Ташның махсус хезмәт багышларга җыенуын истә тотып (аның хакында югарыда бер әйтелгән иде инде), кайбер нәтиҗәле фикерләрен кыскача билгеләп үтү белән чикләник.

Көнчыгыш Аурупа халыкларына, шул исәптән мажар теленә, галим фикеренчә, төркичә элементлар күбрәк болгар һәм хәзәрләр аркылы кергән.

Чөнки "V гасырның икенче яртысыннан алып унугыр-болгарлар Көнчыгыш Аурупа тарихына актив катнашканнар" (112 б.). Кубрат хан житәкләгән Болгар империясенең таркалуына шул болгарларның үз эчләрендә ике тармакка бүленүләре дә сәбәп булганга охшый.

Дөрес, Дунай буйларына килеп урнашкан, соңра славянлашып беткән болгарларның телләре хакында, гәрчә аның төркилеге шик тудырмаса да, төп сыйфатларын билгеләп, төп-төгәл әйтеп булмый. Мәгәр, Ибне Фазлан хәбәрләренә һәм болгар эпитафик истәлекләренең бер өлешенә караганда, Идел-Чулман буе болгарларыннан бер кавемнең телләре хәзерге чуашчага якынрак диалектта булуы шик тудырмый. Ләкин бу факт болгар теле хәзерге чуаш теленең турыдан-туры элгәргесен түгел, бәлки чуаш теленә якын, дөресрәге аңа кардәш һәм соңра "үлгән"—онытылган бер диалектның үзенчәлекләрен чагылдырса кирәк (113 б.).

Кайбер мәгълүматларга караганда, хосусый үзенчәлекләре һаман серле булып кала бирә торган хәзәр теле дә үзенең типологиясе ягыннан чуашчага якынрак булганга охшый (114 б.). Шуннан чыгып, галим әлеге чуашчага якын дип билгеләнгән истәлекләрнең болгарлар арасында яшәгән хәзәр кешеләре каберләренә куелган булуы да ихтимал, дигән фикерләрнең барлыгын искәртеп куя.

Монда Рона-Таш фикерләренә шуны гына өстәргә кирәк: хәзәр теленең чуашчага якынлыгы, дөресрәге хәзәр-чуаш кардәшлеге хакындагы фаразлар монарчы академик В.В.Бартольд һәм башкалар тарафыннан да әйтелеп, Л.Н.Гумилев күзәтүләре белән дә беркадәре куәтләнгән иде.

Сүз уңаенда тагын бер мәсьәләгә тукталып узыйк. А.Рона-Ташның болгар теле үзенчәлекләренә карата элек тә әйткән әлеге фикерләре кайбер татар тел белгечләре тарафыннан (мәсәлән, М.З.Зәкиевнең) кискен рәвештәге каршылыгына очраган иде. Фикер белән килешергә теләмәү бер нәрсә, ләкин болгар эпитафияләренең бер өлешендәге чуашчага якынрак элементларның реальлеге бөтенләй икенче нәрсә. Мондый сыйфатларны бернинди "югарыдан төшкән" күрсәтмәләр яисә төрлечә тартып-сузулар белән дә үзгәртеп булмады хәзергә һәм булмас та кебек. Заманында татар кешесе Хөсәен Фәезханов тарафыннан ачылган, соңрак күпчелек компетентлы лингвистлар тарафыннан да кабул ителгән караш киләчәктә дә аерым шәхесләрнең ихтыярларына (теләү-теләмәүләренә) буйсынмас шикелле. Болгарчыларның бер бәласе, фикеребезчә, Болгар дәүләтендәге халыкларның һәммәсе дә бер генә диалектта сөйләшкән кавемнән булган дип, тар карашлы позициядә торулары белән аңлатылса кирәк. Рона-Таш исә, күргәнебезчә, реаль чынбарлыкка төртеп күрсәтә торган конкрет фактлар нигезендә мәсьәләгә киңрәк карап фикер йөртә—бер дәүләт эчендә төрле диалектларда сөйләшкән кардәш кавемнәр булу идеясен алга сөрә... Ниһаять, шуны да өстәргә кирәк, язма чыганаклар да, археологик истәлекләр дә, антропологик материаллар да ачык күрсәткәнчә, Идел-Кама Болгар дәүләте күпэтнослы, ягъни, хәзергечә әйтсәк, күпмилләтле дәүләт булган. Шуңа күрә "болгар мирасы" өчен талашып, ызгышып ятуның мәгънәсе бик чамалы. Чын гыйльми бәхәс исә реальлеге расланган фактлар нигезендә булырга тиеш...

Чыганакларга багышланган беренче кисәктә шулай ук археологик, этнографик һәм антропологик материалларга да киң урын бирелгән (116—163 бб.). Бу үзенчәлекле мәгълүматлар да борынгы мажарларның башка халыклар белән аралашулары, күчү-күченү юллары хакында шактый мул информация бирә икән. Төрле типтагы чыганакларны шул рәвешчә әтрафлы өйрәнү нәтижәсе авторга борынгы мажарлар яшәгән даирәне төгәлрәк ачыклап, киңрәк, тулырак күзаллау һәм яктырту мөмкинлеген биргән.

Китапның икенче зур кисәге "**Кардәшләр һәм күршеләр**" дип атала (169—249 бб.). Аның беренче өлешендә (гомум тәртип буенча III бүлектә) автор "урал тел" төркеменә киңрәк тукталып, шул зур төркемгә кергән күп халыклар һәм кавемнәр, аларның тарихи язмышлары, телләре хакында аерым-аерым белешмә бирә. Мәсәлән, "урал" телләренең элгәргесеннән (proto-langua) башлап, самоед вә об-угор, пермь һәм финн-угор, аннары балто-финн телләренә кадәр—ягъни Себердәге *хант, манси* (бу исемне хәтерләп алыгыз) һ.б. кебек, бездә

әйтелгәнчә, "вак халыклардан" алып, Балтыйк дингезе буйларында яшәүче мөстәкыйль финнарга, эстоннарга хәтле—үзара теге яки бу күләмдә якын, **кардәш** халыклар хакында. Идел буендагы мордва, чирмешләр, аларның этнографик өлешләре дә, шулай ук *мэри, мищер, мурома* исемле, күптән "үлеп беткән" (дөресе "йотылып" беткән) дип исәпләнә торган кавемнәр дә читтә калмый.

Әмма хезмәтнең "**Күршеләр**" дип исемләнгән чагыштырмача зуррак күләмле IV бүлеге (187—249 бб.) үзенең материаллары, авторның фикерләре белән тюркологлар өчен дә кызыклы һәм файдалы булыр дип уйлыйбыз. Шуңа күрә бүлекнең мажарларга борынгы "күршеләреннән" булган һинд-аурупа кавемнәре, соңрак әйләнә-тирәдә яшәгән славяннарга караган бүлекчәләрен (187—203 һәм 239—249 бб.) бер читкә куеп, борынгы төрки халыклар хакындагы бәлешмәләргә киңрәк тукталып узыйк (203—239 бб.).

"Хуннулар һәм гуннар" дигән бүлекчәдә (203—208 бб.) безнең эрага кадәр өченче гасырда тарихи сәхнәгә чыккан *хуңнулар (хуннулар)*[1] империясе, аларның борынгы Кытай дәүләте белән дәвамлы көрәшләре, ахыр чиктә көнбатышка таба күченүләре, Аурупада исә *гуннар (гунны)* исеме белән танылуы карала.

Автор хунну-гуннарның этник чыгышларына карата үзен бик сак тота. Һәм бу хәл очраклы түгел: Үзәк Азия төпкеленнән *хуңну* сыйфатында чыгып, ике-өч йөз ел дәвамында үз составына Бөек Ауразия киңлекләрендәге күпләгән башка халыкларны буйсындыра-буйсындыра Аурупага килеп житкән *гуннарның* этник йөзен бер сүз, бер атама белән генә билгеләү, чыннан да, кыен һәм бик җаваплы эш. Чөнки Аурупаны айкап-чайкап йөргән гуннарның эчендә төрле этник кавемнәрнең булганлыгы бәхәссез. Мәсьәләне категорик рәвештә хәл итәр өчен, галим фикеренчә, тел фактлары житеп бетми. Археологик истәлекләр исә, кайбер Казан авторларының гуннарны гел төркиләр дип исәпләүләренә карамастан, (208 б.), бик каршылыклы. Шуңа күрә автор гуннарның этник йөзен билгеләү мәсьәләсен тулаемы белән ачык калдыра. Әмма IV—V йөзләрдә аларның мажарларга тәэсире шик тудырмый.

Безнең фикеребезчә, күпэтнослы зур империянең халкы эчендә төрки кавемнәрнең булуы да бәхәс тудырмаска тиеш. Чөнки борынгы төркиләрнең бабалары хуңнулар киткәч кенә күктән төшкән яисә җир астыннан чыккан халык булмаса кирәк. Хунну-гуннар "ташкынында" аларның теге яки бу күләмдә катнашканлыклары шик тудырмый. Хәер, моның шулай икәнлеге Рона-Таш китабының үзеннән дә (209 биттән үк) күренеп тора. Димәк, чын гыйльми бәхәс, безнең уебызча, кайсы чорда нинди этнос вәкилләренең чуар халыклы гуннар союзында өстенлек алуы, гегемон булуы хакында гына барырга мөмкин.

Төрки кавемнәрнең борынгы Аурупадагы ачыграк билгеле булган язмышларына китапта шактый күләмле бүлекчә багышланган (209—239 бб.). Башта борынгы төркиләрнең Үзәк Азиядәге хәлләре хакында кыскача гомум мәгълүмат бирелгәч, аларның Аурупада күренгән беренче вәкилләре сыйфатында *аварлар* һәм *сабирлар* атала. Болардан сабирларның тарихы шактый буталчык икән. Аларның төркилекләре гомумән әлләни шик тудырмый шикелле, әмма телләренең нindирәк төр-диалектка караулары әлегә ачык түгел. Сабир сүзен ерактагы Себер топонимына да, яисә *Сувар* дигән шәһәр исеме аркылы Идел буе болгарларына бәйләп карау омтылышлары да юк түгел. Кайбер *согдча* чыганакларда Үзәк Азиядәге Турфан якларындагы бер кавемнең *сапири* рәвешендә аталуы да мәгълүм. Һәрхәлдә, мәсьәлә караңгы килеш кала бирә (212—213 бб.).

*Аварларга* килсәк, монда инде чыганаклар, бераз буталчыграк булса да, шактый мул һәм эзлеклерәк хәлдә сакланган. Бу халык хакындагы фәнгә мәгълүм иң борынгы мәгълүматлар безнең эраның 385 елына карый. Кытай чыганакларында хәзерге Монголия туфрагында яшәгән бер кавемгә карата *руанруан* дигән исем кулланылган. V гасырда аларның шактый зур территорияле империя оештырулары билгеле. Аларга буйсынган халыклар арасында 460 еллар тирәсендә беренче мәртәбә исемнәре язуда теркәлгән *тэлэ* исемле кабилә дә була. 546 елда шул тэлэләр руанруаннарга каршы баш күтәрә. Гыйсъянчыларны

---

[1]Атаманың беренче иҗеге "ң" авазына бетүенә кытайча чыганаклар күрсәтә, рус телендәге әдәбиятта, белгәнебезчә, бу хосусият чагылмый—*хунну*.

бастыру эшенә чак кына соңрак тарихта *түрк* исеме белән киң мәгълүм була торган бер төрки телле кабилә актив катнаша. Алар, язма чыганакларга караганда, Алтай таулары ягында яшәп, руанруаннарга тимерчелек эше белән хезмәт иткәннәр.

Әлеге жинүдән соң *түркләрнең* житәкчесе руанруан императорының кызын үзенә хатынлыкка сорый, диелә. Һәм ул, теләге үтәлмәгәч, Кытай иленең ярдәменә таянып, 552 елда баш күтәрә, бәхәссез жиңүгә ирешә. Тар-мар ителгән руанруаннарның хакиме үзен-үзе үтергәч, элекке күпсанлы вә көчле кавем бөтенләй таркалып, аның зур өлеше качарга—көнбатышка таба күченергә мәжбүр була. 555 елда аларның үз составына төрле кабиләләрне алган зур өлеше инде Кавказның төньягындагы киңлекләрне биләп тора. Бу еллардагы руанруаннар, дөресрәге *аварлар* составында, борынгы сүрияле бер чыганак күрсәткәнчә, *уногур, огур (угор), бургар (болгар), куртагур, хәзәр, сарогур* дигән һәм башка кабиләләр дә була. Моннан күренгәнчә, руанруаннарның Азиядән күченеп, Аурупага килеп чыгулары бик кыска вакыт эчендә була. Һәрхәлдә 561 елда *авар* исемендә күбрәк мәгълүм булган руанруаннарның Аурупадагы *франклар* белән дә конфликтка керүләре документаль рәвештә мәгълүм.

*Руанруан* исеме белән *авар* этнонимының тәңгәллекләре фәндә расланган факт. Дөрес, ди автор, Азиядәге руанруаннар белән Аурупадагы аварлар арасына абсолют дәрәжәдәге тәңгәллек билгесе куеп булмый. *Хуңнуларның* этник составы үзгәрә-үзгәрә *гуннарга* әверелгәне шикелле, руанруаннарның да күченү юлы уңаенда башка кабиләләрне буйсындыру, үзләренә кушу нәтиҗәсендә, этник сыйфатлары катлаулана төшкән булуы табигый хәл.

Менә шул катлаулы процесс, А. Рона-Ташның фикеренчә, хәзерге венгрларның бабалары сыйфатында карала торган *угорларның* Азиядәге руанруаннар белән Аурупадагы аварлар язмышында да шактый мөһим роль уйнаганлыгын күрсәтә икән (213—214 бб.).

Әле генә аварлар составында дип саналган кабиләләр хакында шундый сорауның куелуы ихтимал: аларның барысы да качкан руанруаннар белән бергә килгәннәрме, яки кайберләре элегрәк күченгән гуннардан ук калганнармы? Бу мәсьәлә, безнеңчә, киләчәктә махсус тикшеренүне сорый. Чөнки фәнни әдәбиятта Рона-Таш китабында тәкъдим ителгән аңлатмага туры килеп бетми торган хәбәрләр дә очраштыргалый.

Бу әйтелгәннәргә без, аңлатма рәвешендә, түбәндәге кайбер мәгълүматларны өсти алабыз. Руанруан этнонимы кытай теле һәм кытайча чыганакларның жимеше ул. Хәзерге рус телендәге ориенталистик әдәбиятта аның *жуан-жуан* рәвешендәге варианты кулланыла. Һәм бу аңлаешлы: борынгы кытай телендә һәм аның кайбер диалектлары арасында *р — ж* күчеше киң таралган күренеш. Мәсәлән, "кеше" дигән төшенчәне аңлата торган гап-гади иероглифны, чор һәм диалектның үзенчәлегеннән чыгып, "рың" дип тә, "жың" рәвешендә дә янгыратырга мөмкин. Ә инде борынгы төркичә руник язмаларда исә кытайча руанруан (жуан-жуан) атамасына *апар* дигән этноним тәңгәл килә икән. Димәк, этнонимның бу соңгы варианты кавемнең үзатамасы (самоназваниесе) булганга охшый. Соңрак шуннан *абар, авар,* борынгы славянча *обр, обры* вариантлары барлыкка килгән.

Бүлекчәнең **"Төркиләр Аурупада"** дигән кыска гына, мәгәр тыгыз эчтәлекле өлешендә (214—215 бб.) 552 елда оеша башлап, 553—572 еллар арасында көчәеп, ныгып өлгергән **Төрки каганлыгының** сәяси тарихы, иленең чикләре көнбатышка таба киңәеп, бөек империя барлыкка килү процессы шактый эзлекле күзәтелгән. Бу чорда угорлар Иделнең көнбатышында яшәп, төркиләргә буйсынып торганнар. Каганлыкның көнбатыш чикләре бик үк тотрыклы булмаганга охшый. Нәкъ шушы чорда Идел-Чулман бассейнына көнчыгыштан күпләп көмеш әйберләр китерелә. Аерым археологлар Идел-Урал буйларына кыпчак кабиләләре үтеп керүен, киләчәктә аларның татар һәм башкорт халыкларының этногенезына катнашуларын шул чорга кайтарып калдырырга омтылалар. Ләкин бу фараз, автор фикеренчә, тиешле дәрәжәдәге дәлилләр белән ныгытылмаган.

Аурупадагы болгарлар хакында гомум, шулай ук Кубрат чорындагы Бөек Болгар империясенә, ниһаять, Идел һәм Дунай болгарларына багышланган хосусый бөлешмәләр өчен китапта шактый киң урын бирелгән (215—228 бб.).

600 еллар башында угорларның, болгарлар белән берлектә, төрки каганлыктан бүленеп чыгуларын әйткәч, профессор А. Рона-Таш болгарлар элек яшәгән җирләрнең чикләрен билгеләп, тәүбашта аларның күпчелеге Кубань елгасының төньягындагы киңлекләрдә торган, дигән фикергә килә. Тагын бераздан, әрмән чыганаклары хәбәрләре буенча, Иделнең түбән агымында хәзәрләр торуы, алардан көнбатышта *түрк*[1] дип аталган мажарлар яшәве, болардан соң, Дон һәм Буг елгаларыннан көнбатыштарак, болгарлар булуы беленә.

635 елда авар хакимиятенә каршы баш күтәргән Кубрат мөстәкыйль империя оештыруга ирешә. Гомере шактый кыска булган бу империя чорында дәүләтнең туфрагы төньяк-көнбатышка таба киңәйгәнлеген Кубрат хан зиратының хәзерге Украина җирендәге Полтава шәһәре янында табылуы раслый. Кабердән чыккан нумизматик материаларга караганда, үзеннән соң биш угыл калдырган Кубрат хан 650 еллар тирәсендә үлгән булырга тиеш. Ул төзегән дәүләт 670 елда хәзәрләр һөҗүме нәтиҗәсендә тәмам таркала шуннан соң, болгарларның төрле якларга күченүләре барлыкка килә.

Бу уңайдан бер мөһим мәсьәләгә махсус тукталу артык булмас. Полтава янында табылган бай хәзинәле кабернең кемнеке булуы хакында соңгы вакытларга кадәр төрле фикерләр яшәп килде. Берәүләр, мәсәлән, аның борынгы кучмәннәрдән кемнекедер булуын фараз кылсалар, икенчеләре бөтенләй башка бер халыкка нисбәт итәргә тырыштылар; өченчеләре Кубрат чорындагы төркиләргә бәйләп карадылар. А.Рона-Таш хәзинәдә сакланган мөһер-йөзектәге юнанча "серле" (аңлар өчен гаять авыр) язуны яңадан укып, хәзинәнең һичшиксез Кубратныкы дигән фикерне куәтләде. Әлеге сүз, әгәр ул латин хәрефләре белән транскрипцияләнсә, *Hovratu* рәвешендә янгырый икән. Сүз башындагы латинча "H" хәрефенең борынгы венгрча исемнәрдә гел "K" авазына күчүен исәпкә алсак, *Kovrat* килеп чыга икән (сүз ахырындагы "U" латинча күрсәткеч, ул укылмый). Шуна күрә китап авторы үз хезмәтендә ханның исемен инглизчә гел *Khuvrat* рәвешендә яза (217—218 бб.; китапта кыскача әйтелгән карашның киңәйтелгән варианты 1999 елда, махсус доклад рәвешендә, Прага шәһәрендә уздырылган PIACта—алтаистларның Халыкара конференциясендә укылган иде — *М.Г.*).

Болгарларга багышланган сәхифәләрдә аларның Идел-Чулман төбәкләренә кайчан, ни өчен һәм нинди юллар белән килеп утыруларына багышланган өлешләре, безнеңчә, аерата игътибарга лаек. Чөнки бу мәсьәлә бездә (Идел буе һәм татар тарихы буенча хезмәтләр күздә тотыла) хәзергә кадәр махсус яктыртылмыйча, бары кайчандыр булган процессның нәтиҗәсе буенча гына бәхәссез факт рәвешендә икърар итүдән ары узмады диярлек. Кайбер очракта күченү Кубрат үлгәч үк барлыкка килгән күренеш кебек яктыртылды...

Чыганаклар күрсәткәнчә, дәүләт башына килгән һәлакәттән соң күпмедер вакыт узгач, болгарның бер өлеше Аспарух җитәкчелегендә көнбатышка күченеп, Балкан ярымутравы, Карпат төбәге һәм беркадәре Италиядәге тарихи вакыйгаларга да катнаша. Икенче зур өлеше, Баян исемле хан җитәкчелегендәгеләре, хәзәрләргә буйсынып, элекке урыннарында чикләнгән автономия шартларында яши. Бу өлешенең элегрәк Болгар империясенең төньяк-көнбатышында, Днепр белән Дон арасындагы җирләрдә яшәгәнлегенә ишарәләр бар. Әмма Доннан көнчыгышка таба булган җирләрдә хәзәрләр контрольлек иткәнлеген дә беләбез. Димәк, 670 еллар тирәсендә Баян җитәкчелегендәге болгарларга төньяк-көнчыгышка таба күченергә мөмкинлек тә, җитди сәбәпләр дә булмый диярлек. Андый шартлар 60 ел узгач кына барлыкка килә (220 б.).

Күпләгән язма истәлекләр күрсәткәнчә, 723 елда гарәп-хәзәр сугышлары башланып, хәзәрләрнең башкалалары булган Сәмәндәр, Баланҗарлар яулап алына. Хәзәрләр үзләренең мәркәзләрен хәвефсезрәк булган Идел тамагына күчерәләр, анда Әтил исемле яңа **ханбалык**—хан шәһәре нигезләнә. 737 елдагы икенче һөҗүм нәтиҗәсендә хәзәр каганы Иделнең көнчыгыш ягына качарга мәҗбүр була, гарәпләр исә Иделнең көнбатышы буйлап күтәреләләр. Үзенең тәмам җиңелүен аңлаган каган, Ислам динен кабул итеп, хәлифәгә тугрылыкта ант итә.

---

[1]Атаманың мондый әчтәлеге хакында алга таба махсус сүз булыр әле—*авторлар*.

Шул рәвешчә, Иделнең көнбатышында үзенчәлекле сәяси вакуум—хәзәрләрдән бушаган җир барлыкка килгәч, хәзәр җәбереннән котылырга теләгән болгарлар өчен төньяккарак күченү өчен юл ачыла. Һәм алар, Идел белән Дон арасындагы тар корылыктан узып, төньякка таба юл тоталар. Бу хәрәкәтнең 737 елдан соң барлыкка килүе үзенчәлекле гарәп-болгар килешүенең нәтиҗәсе булырга да мөмкин. Һәрхәлдә 750 еллар тирәсендә болгарларның Җигули таулары тирәсенә житүләрен, анда бераз ныгып торуларын, ныгытмалы шәһәрчек-кальга төзүләрен археологик әдәбияттагы "Муром шәһәрлеге"—Х гасырга кадәр яшәгән шәһәр урыны расласа кирәк (220—221 б.).

Хәзәр экспансиясенең яңадан башлануыннан шөбһәләнгән болгарлар Иделнең көнбатышы буйлап, тагын төньяккарак елышалар. Моны Татарстандагы VIII гасырның ахыры белән IX йөзнең башына караган **Олы Тархан** каберлеге да раслый: анда табылган гарәп дирһәмнәре 755—809, ә харәзем акчалары исә 762—787 елларда сугылганнар. Ә инде IX йөзнең ахырында аларның Идел-Чулман регионында ныгый башлаган булулары да шик тудырмый. Шул ук Татарстандагы **Танкеев** каберлекләрендә табылган материалларның 846—902 еллар арасындагы чорга караулары шуны күрсәтә (222 б.).

Менә бу әйтелгәннәрдән чыгып, гарәп-болгар мөнәсәбәтләренең 737 елдан ук башланган булуын фараз итәргә, 921—922 елгы Ибне Фазлан миссиясен исә шул процессның билгеле бер дәвамы, нәтиҗәсе, дип карарга да мөмкин икән. Дөрес, Алмышның атасы мәҗүси булганлыгы да бәхәссез. Ләкин Ибне Фазланның 921 елда Болгарда мөселманнарны күпләп очратуы да мәгълүм факт (222—224 бб.). Һәрхәлдә, фаразларга урын бар әле...

Идел буе Болгар дәүләтендәге төркиләр, шәрекъ чыганакларына караганда, нигездә дүрт кабиләдән торган: *сувар, баранҗар, барсула* һәм *эсэгел*. Аларның исемнәрен, шәркый истәлекләрдә төрлечәрәк язылса да, бизанслы (византияле) язмалар буенча да шулайрак укырга мөмкин.

*Суар* сүзен *Суаз* дип укып, аннан *чуаш* этнонимын ясау белән А. Рона-Таш килешми. Чөнки төрки телләрдәге авазлар арасындагы күчеш закончалыклары болай уйларга җитәрлек нигез бирми. Калган этнонимнарның кытайча, тибәтчә, бизансча чыганакларда очраулары да беркадәре күзәтелә; автор ялгызлык атамаларыннан *Алмыш, Шилки* кебек исемнәргә дә тукталып, боларның беренчесенә якынрак вариантларның венгр-мажар ономастикасында очрауларын күзәтә. Ниһаять, *Сувар, баранҗар, барсула, эсэгел* кабиләләре кешеләренең барысының да чуашчага якын шивәдә сөйләшмичә, башка берәр төрки диалектта сөйләшкән булулары да бик ихтимал, ди. Шулай ук болгарлар арасында башка төбәк һәм төрки диалект вәкилләренең сәүдәгәрләр, качаклар сыйфатында яшәгән булулары да табигый. Җыеп әйткәндә, Идел буе болгарлары Ауразия күләмендәге бөек сәүдә мөнәсәбәтләренә актив катнашкан халыклардан (224—227 бб.).

Бүлекчәнең соңгы өлеше *хәзәрләр* һәм *бәҗәнәкләр* хакындагы белешмәләрне эченә ала (228—239 бб.). Этнонимнарның чыганакларда яктыртылу үзенчәлекләре, халыкларның язмышлары беркадәре яктыртылгач, боларның мажар-венгр тарихында тоткан урыннары да кыскача билгеләнә.

Төрле славян кабиләләре, аларның венгрлар белән мөнәсәбәтләре хакында кыскача мәгълүмат туплаган сәхифәләр (239—247 бб.) белән "күршеләр" дигән үзенчәлекле һәм гыйбрәтле темага нокта куела, дип әйтергә ярый. Мантыйк буенча инде автор тикшеренүенең төп максаты булган мажар-венгрларның үзләренә күчәргә тиеш иде кебек. Ләкин профессор Рона-Таш икенчерәк юл сайлый: моңарчы аерым-аерым каралган хосусыйрак темалардан гомумирәк мәсьәләгә, ягъни конкрет **анализлардан** мәгълүматларны тулаем **синтезлау** юлына күчә. "IX һәм X гасырларда Ауразия" дигән махсус бүлек (251—266 бб.), күләме әлләни зур булмаса да, безнеңчә, узганны таныр-белүдәге менә шундый теоретик әһәмияткә ия. Анда шул ике гасыр эчендә "иске дөньяның" Ауразия дигән зур өлешендә барлыкка килгән вәзгыять һәм үзгәрешләр карала. Мәсәлән, Уйгыр каганлыгының җимерелүе, Кытай һәм Хитай мәсьәләсе, Караханилар һәм Каракытайлар[1], угызлар вә сәлҗуклар, хәзәрләр белән Русь мөнәсәбәтләре, Бизанс империясе һәм Дунай болгарлары, Рим һәм франклар, аварлар белән Карпат славяннары, ниһаять, "яңа ватан яулап алу" алдыннан Карпат җирләрендәге

хәлләр күзәтелә. Әлбәттә, шушы аталган илләр һәм халыклар башыннан кичкән хәлләрнең Урта гасырлардагы угор-мажарларга теге яки бу күләмдә мөнәсәбәтләрен, тәэсирләрен ачыклау максатыннан.

Укучы игътибар иткәндер, профессор Андраш Рона-Таш хезмәтенең кушымталардан башка 390 биттән торган төп текстының якынча **өчтән ике өлеше** угор-мажарларның үз тарихларына түгел, бәлки аларның узгандагы хәлләрен аңлау өчен зарур чыганакларга, аларның төрләренә, аннары яшәгән даирәләрендәге башка халыкларның—кардәшләр һәм күршеләрнең тарихларына багышланган икән. Нәтиҗәдә, угор-мажарларның борынгы язмышын аларның үз "кабыгы" (тар милли кысалары) эчендә генә карау түгел, бәлки киң тарихи фонда—гомум **кешелекнең, бөек Ауразиянең аерылгысыз бер өлеше** итеп күзаллау мөмкинлеге туган. Бу—һичшиксез гыйльми ачыш дәрәҗәсендәге киң карашлы зур казаныш.

Китапның **өченче** кисәге, үзенә күрә төп өлешләрнең берсе, "**Урал тауларыннан Карпат җирләренә кадәр**" дип атала (271—311 бб.). Аның беренче (тәртип буенча VI) бүлеге "мадьярларның дәүләт нигезләгәнче исемнәре" мәсьәләсенә багышланган. Автор иң элек этнонимнарның килеп чыгулары, аларның гомум табигатьләре кебек теоретик мәсьәләләргә туктала. Проблеманың гомум әһәмиятен искә алып, аңа да бераз тукталыйк.

Ыру-кабилә һәм халык-этнос исемнәре, галим махсус күрсәткәнчә, нигездә ике төрдән гыйбарәт була: кавемнең үзенә үзе биргән, күп очракта "кеше" дигән мәгънәгә кайтып кала торган **үзатамасыннан** һәм берәүләргә башкалар (якын һәм ерак күршеләр) тарафыннан бирелгән **кушамат рәвешендәрәк** булган исемнәрдән. Мондый ике категориядәге исемнәр арасында, алар бер-берсеннән нык аерылган хәлдә, күчеш һәм алмашыну күренешләре дә була: кайчандыр читләр тарафыннан бирелгән исемнәрнең тора-бара үзатамага әверелүе, яки бөтенләй башка исем кабул ителүе кебек. Мәсәлән, элекке герман кабиләләре исеме булган *франк* сүзенең *галларга* күчеп "француз" килеп чыкканы яисә викинглардан (Скандинавия норманнарыннан) кергән "рус" сүзенең славяннарның бер өлеше тарафыннан кабул ителеп, үзатамага әверелүе кебек.

Күп очракта этник исемнәрнең халыкның географик урынына яки сәяси, иҗтимагый төзелешенә, дәүләт башлыгы исеменә дә бәйле булуы ихтимал. Әйтик, *америкалылар, оногурлар (ун угорлар), отузогузлар (утыз угызлар), нугайлар, үзбәкләр* (тарихи шәхесләрдән Нугай һәм Үзбәк ханнар исемнәреннән) шикелле. *Хәзер, татар* кебек кайчандыр лидерлык иткән кабилә һәм этносларның исемнәре башкаларга, гадәттә, аларга буйсынган халыкларга күчү күренеше дә киң таралган. *Хунну* һәм беркадәре *авар* исемнәре белән дә шулайрак килеп чыкканга охшый.

Күпчелек этник исемнәрнең чыгышлары караңгы булуы да табигый. Чөнки аларның борынгы бер телдән икенчесенә, аннары өченче-дүртенчеләренә күчкән, шул рәвешчә беренче тамыры әллә кайлардадыр "күмелеп" калган булуы ихтимал. Халыкның үзе башкалар арасында эреп юкка чыкса да, аның исеме сакланырга мөмкин. Мәсәлән, *алеманнарның* эзләре дә калмаган хәзер, ләкин аларны күздә тотып *германнарны франклар* дип атаганнар, шуннан, югарыда күрсәтелгәнчә, галларга күчеп, "француз" барлыкка килгән. Шулай ук "ялгыш" тагылган исемнәр дә була, әйтик, Америкадагы кызыл тәнлеләрнең Һиндстан ярымутравында яшәгән халыкларга бернинди бәйләнеше юк (275 б.).

Ялгыш кулланылган исемнәрнең барлыкка килүендә борынгы язма чыганакларның катнашы да зур икән. Мәсәлән, юнаннар (борынгы греклар), кытайлар һәм фарсылар үз күршеләренең саннары күплегенә, хәрби куәтләренә генә игътибар итеп, аларның этник яктан кем булулары хакында төпченеп тормыйча, барысын да, әйтик, "грек түгел", "кытай түгел" дигән кебегрәк мәгънәдә булган бер исем белән атаганнар. Моның иң характерлы мисалы ул

[1]Хәзер без "Кытай" дип белә торган сүз элекке монгол телле *кидан* кабиләләренә төрки халыклар биргән, соңрак *чин* (china татар телендәге *чынаяк—чинаяк* сүзен, *Чин-мачин* атамасын искә төшерик) халкына күчкән исем (*Чин илендә* тәхеттә *кидан династиясе* хөкем сөргәне өчен). Киданнарның көнбатышка күченгән, Урта Азиянең бер өлешендә, нигездә хәзерге көнчыгыш Казагыстан һәм Шәркый Төркестан җирләрендә, XII йөздә яңа империя оештырган өлешләрен төркиләр *каракытай* дип атаганнар.

"грек түгел" дигән мәгънәдәге "варвар" сүзе. (Аның "кыргый, вәхши" кебек эчтәлеге соңгы заманнарда барлыкка килгән күренеш.) Шулай ук әллә ничә төрле кавемнәрнең "скиф" дигән бер генә атама белән билгеләнүе дә бәхәссез факт. Борынгы *Иран* мөхитенең төньягындагы зур, чуар дөньяны элек *Туран* дип бер сүз белән атаганнар.

Кытайлар исә күчмәле тормыштагы үз күршеләренә карата, гадәттә, күчмән дигән мәгънәле бер этнонимны актив кулланырга яратканнар. Бер күчмәннәр китеп, аларның урынын икенчеләре алсалар да, соңгыларына карата элекке этноним кулланыла биргән һ.б. һ.б. (271—275 бб.).

Галимнең бу фикерләре, бигрәк тә соңгылары без татарлар өчен аерата кызык һәм мөһим булса кирәк. Кытай чыганаклары буенча, мәсәлән, *дала татарлары, урман татарлары, ак татарлар, кара татарлар,* хәтта *су татарлары* ише биш-алты төр "татар" кавеме булганлыгы мәгълүм. "Бер халыкны" шулай әллә ничәгә бүлгәләүнең гел географик шартлар яисә социаль үсеш дәрәҗәләре белән генә бәйле булмыйча, этник үзенчәлекләргә барып тоташулары да ихтимал. XII гасырда лидерлыкка дәгъва кылган *татар* кабиләсе исеменең XIII йөздән алып киң таралуы, XIV гасырдан соң хәтта бөтен Ауразиянең ярты халкына карата диярлек кулланылуы (гадәттә, башкалар, күршеләр тарафыннан!), күрәсең, очраклы түгел икән.

*Татар* этнонимының XIII—XVI йөзләрдә, хәтта аннан соң да, яшәеш шартлары үзара якынрак булган күпсанлы халыклар җыелмасына карата кулланылган булуын борынгы "татар" дигән кавемнән монголчыларның да, тюркологларның да үзләренә мул "азык" (лингвистик дәлилләр) таба алу фактлары, бүгенгә хәтле бетмәгән бәхәсләре дә тулысынча раслый. Димәк, этнослар белән этнонимнар арасында һәрвакытта да тигезлек билгесе куеп булмый икән. Икенчерәк итеп әйткәндә, һәр этносның үз тарихы булган шикелле, кайбер (бәлкем, күпчелек) этнонимнарның да үзенә генә хас язмышы бар икән. Профессор Рона-Ташның югарыда тасвирланган махсус күзәтүе, безнеңчә, менә шушы хакыйкатьне раслауга, ныгытуга хезмәт итә.

Шул рәвешчә А.Рона-Таш күпсанлы, төрле-төрле "милли исемнәр" тарихын күзәтү нәтиҗәсендә угор-мажарларга карата төрле чорда кулланылган төрле этнонимнарны барлау, һәрберсенең язмышын ачыклауга ирешә ала. Мажарларга тагылган мондый исемнәрнең кызыклысы, дөресрәге, беркадәрле сәеррәге ул *түрк* дигән этноним икән. Әйе, бизанслы (византияле) авторларның шактыенда *мажарлар* шулай *түрк* дип аталган. Мондый хәл кайбер гарәп чыганакларында да күзәтелә. Профессор Рона-Таш фикеренчә, болай килеп чыгуда берничә сәбәп булганга охшый. Мәсәлән, угор-мажарлар үзләренең Көнчыгыш Аурупага килгәннән соңгы гомерләренең ике-өч гасырга якын чорын төрки кавемнәр лидерлык иткән дәүләтләр составында уздырган.

Шулай ук, соңрак төркиләрдән бүленеп чыккан мажарлар арасында да төрки кабиләләрнең булганлыгы мәгълүм.

Ниһаять, бу этнонимның Төрки каганлыкның, хәзәрләрнең башында торган, чыгыш тамырлары буенча *сак* дигән халыкка барып тоташкан *Ашина* династиясе[1] белән мажар корольләре арасындагы союздашлык, туганлык-кодалык ише табигый багланышлардан килеп чыккан булуы да ихтимал. Мажар корольләренең Византиядә эшләнгән алтын таҗларында *түрк короле* дигән сүзнең булуы шуңа өстәмә бер дәлил[2]. Бер үк вакытта шунысы да характерлы: юнанча да, гарәпчә дә чыганаклар төрки дөньяның бары көнбатышындагы мажарларны *түрк,* дип атаганы хәлдә, аларны чын төрки булган хәзәрләр, бәҗәнәкләр, болгарлар белән һич тә бутамыйлар (275—282 бб.).

Юнанча, латинча һәм башка язма истәлекләрдә шулай ук чыгышлары белән *угор/огур* тамырына барып тоташа торган *оногур, унгар, һунгари, һунгарус,*

[1]Династия исеме *сакча* **asseina** (зәңгәр), дигән сүздән дип исәпләнә. Төрки каганнарның үз язмаларында *күк түрк* гыйбарәсен кулланулары шуның белән бәйле булса кирәк.

[2] 1989 елда, Будапештта булган чакта, дәүләт музеенда тантаналы шартларда халыкка күрсәтелә торган бу таҗны миңа да күрергә туры килгән иде. Андагы рәсми тасвирламада *түрк короле* дигән сүзләр ачык язылган—*М.Г.*

*һунгариан* кебек этнонимнар, аларның вариантлары да очрап, гадәттә, бары тик мажарларга карата гына кулланылган. Боларның кайберләре славяннар, икенчеләре Аурупадагы башка халыклар тарафыннан кулланылганга охшый (282—289 бб.).

Мажарларга карата *башкорт (басҗырт)* этнонимы да кулланылган икән. Мәсәлән, X гасыр вәкиле Ибне Фазлан, XII йөздә сәяхәт иткән Әбү Хамид әл-Гарнатый язмаларында. Чыганакларны җентекләп тикшерү бу исемнең мажарларга карата гомумән болгарлар, бигрәк тә Идел буе болгарлары тарафыннан кулланылган, шулардан гарәпләргә күчкән булуын күрсәтә. Бу факт үз нәүбәтендә Идел буе болгарларының мажарлар белән күрше булып торуларына, мажарларның бер өлеше Идел буенда XIII гасыр башына кадәр яшәгәнлекләренә ишарә итеп күрсәтсә кирәк (289—294 бб.).

Бер төркем гарәп һәм фарсы чыганакларында, соңгыларының оригиналлары сакланмаса да, угор-мажарларга карата *мажгар* рәвешендәге этноним да очрый. Бу исемнең хәзәрләр тарафыннан кулланылганлыгы һәм аның төрки тамырлы булмавы ихтималга якынрак. Сирәк кенә булса да, кайбер соңгы дәвер чыганакларында мажарларга карата *скиф, хун, авар* һәм башка борынгы исемнәрнең кулланылу очраклары, ягъни иске традициянең янарак чордагы язмаларга күчү күренешләре дә бар. Ә инде *мадьяр-мажар* дигән рәвешкә килсәк, ул венгр чыганакларына хас һәм чагыштырмача соңрак дәверләрдә кулланылышка кергән **үзатама** булып, башка телләр тарафыннан да кабул ителгән. Этноним үзе угорча ике тамыр-сүзнең кушылуыннан ясалган: *mancha*—**maja** + **er**—*majer—madyer—madyar* ... рәвешендә үзгәрү юлы белән. (Югарыда телгә алынган *mansi* исемен һәм күпчелек төрки этнонимнарда очрый торган *ar-er* "кушымчасын" искә төшерегез.) Һәрхәлдә аның VIII гасырда этнос тарафыннан үзатама сыйфатында кулланылышта булганлыгы мәгълүм. Шуннан чыгып, ди автор, мажар-венгрларның нигезен ике финн-угор, дөресрәге, *Manshi* һәм *Er* исемле ике угор кавеменең кушылуы тәшкил иткән, дип нәтиҗә чыгарырга мөмкин (294—311 бб.).

Югарыда шактый мул итеп китерелгән мәгълүматлардан күренгәнчә, этнонимнар, тирән тамырлы тарихка ия булганы хәлдә, һәр дәвер өчен конкрет эчтәлеккә ия икән. Димәк, аларның "үсү", үзгәрү үзенчәлекләрен, соңрак барлыкка килгән формалар эченә яшеренгән борынгы төп, асыл тамырларын да табу мөһим икән.

Хезмәт алдына куелган төп проблемаларның берсенә, ягъни мажар-венгрларның килеп чыгышлары хакындагы сорауга шул рәвешчә әтрафлы итеп җавап бирелгәч, А.Рона-Таш үз халкының тарихы өчен төп мәсьәләләрдән булган башка темаларга— "беренчел ватан" һәм "күченү", миграция юллары, Урал тауларыннан Карпат җирләренә кадәр һәм "яңа ватан яулап алу", дигән проблемаларга туктала (тәртип буенча VII—VIII бүлекләр, 315—338 бб.). Монда безнең өчен авторның халыклар күченү, аларның миграциясе мәсьәләләренең табигате, үзенчәлекләре буенча күзәтүләре, теоретик фикерләре кызыклы булса кирәк.

Галим фәнни әдәбиятта еш кулланыла торган "беренчел ватан", "төп ватан" дигән төшенчәләрнең шактый шартлы һәм төгәлсез булуын искәртә. Мондый караш халыкларның оешу, үсү вә үзгәрү процессының бик озак һәм хәтта туктаусыз дәвам итүен исәпкә алып бетерми. Рона-Ташның бу фикеренә шуны да өстәргә кирәк: этногенез дигән процессның башын бер конкрет чор белән генә чикләү мөмкин түгел: ул чорның элгәргеләре тагын да үз элгәргеләренә барып тоташа. Чөнки, галим дөрес күрсәткәнчә, безгә билгеле чорлардан элек тә халыкларның җир-ватан алмаштырган булулары бәхәссез. Шуңа күрә "төп ватан" төшенчәсенең күплек санында кулланылуы чынбарлыкны төгәлрәк чагылдырыр иде. Димәк, әлеге төшенчә халык язмышына теге яки бу күләмдә тәэсир иткән конкрет этапларның **берсен генә** күрсәтә дигән сүз.

Күченү-миграцияләр күп төрләре булырга мөмкин һәм ул шулай булган да. Миграциянең гел дәвам итә торганнары да, бер зуррак вакыйга нәтиҗәсендә килеп чыкканнары да була. Кайберләре махсус уйлану, оештыру нәтиҗәсендә барлыкка килсәләр, икенчеләре көтелмәгәндә, кинәт кенә башланып киткән. Күченеп йөрүләрнең даими гадәткә әверелеп, күченүчеләрнең үзләре өчен аларның шул хәрәкәтләре табигый, нормаль тормыш булып тоелуы да ихтимал. Борынгылыкта берәр төбәктә даими яшәүче аерым кавемнәр очраса да, халыкларның

күченеп йөрүләре киңрәк таралган күренеш булган. Аерым этносларның бер төбәккә беркетелеп, төпләнеп яшәүләре ул яңарак заманнар өчен күбрәк хас.

Урта гасырлар башында, зур күчмә империяләр оешу чорларында, лидерлыкка дәгъва иткән берәр халыкның өстенге катламнары башка халыкларны яулап алу, буйсындыру процессында гомум күченү, барлык халыкларның да миграциягә бирелүе кебек иллюзияләрнең тууы ихтимал. Ләкин чынлыкта, элекке халыкларның зур өлешләре үз җирләрендә яши биреп, аларның хакимлек итүче даирәләре генә үзгәргән, алмашынган була.

Мондый күченүләр, җир-ватан алмаштырулар белән тулы заманнарда халыкларның үзаңнарының, ягъни үз-үзләрен тануларының, димәк, нәсел-нәсәб тикшереп, кардәшлек-якынлык дәрәҗәләрен тикшерү омтылышының әһәмияте зур булган. Ләкин күченү-миграцияләр тәэсирендә боларда да үзгәрешләр, яңалыклар килеп чыккалаган (315—317 бб.).

А. Рона-Таш махсус яктырткан бу гомум нәзарый-теоретик мәсьәләнең бер карауга әлләни хикмәте юк сыман: күченү-миграцияләрнең төрле типлары, рәвешләре булуы да, кайберләренең гадилеге, икенчеләренең исә, киресенчә, катлаулыгы да шик тудырмас. Әмма сүздә бик гадәти, аңлаешлы булып тоелган мәсьәләнең дә гамәлдә катлауланып, буталып китүе мөмкин икән. Татар тарихын яктыртуда моның мисаллары житәрлек.

Әйтик, элегрәк, VI—VIII йөзләрдә тудырылган борынгы төрки "руник" язма истәлекләр табылып, эчтәлекләре аңлашылгач, аларны калдырган төрки кавемнәрнең "төп ватаннары" Үзәк Азия, хәтта конкрет Алтай таулары, дигән караш барлыкка килгән иде. Идел-Урал буйларындагы татарларның бабалары бу якларга шул тарафлардан күченеп килгән кабиләләрнең нәселләре, дигән ышану хөкем сөргән иде. Хәтта инкыйлабка кадәр матур әдәбиятта "төп ватан" сыйфатында Алтай тауларының "культын" тудыру омтылышлары да булмады түгел.

Дөрес, бер үк вакытта татар тарихы башын Идел-Чулман төбәгендәге болгарлардан башлау тенденциясе дә тудырылып, яшәтелеп килгән иде. Ләкин ул заманнарда бу соңгысында тарих башы IX-X гасырлардан әлләни ары уза алмаган иде.

Шактый вакытлар тарихи фикеребездә үзара "әрләшмичә", плюралистик кагыйдәгә хас рәвештә тыныч кына янәшә яшәп килгән бу ике юнәлешнең икесенә дә 1944 елдан соң, дөресрәге ВКП (б) Үзәк комитетының мәгълүм карары тәэсирендә, шактый нык үзгәрергә туры килде. "Алтайчылар" (шартлы рәвештә шулай атыйк) юашланып яшеренергә, "эзоп теленә" күчәргә мәҗбүр булдылар. "Болгарчылар" исә (чынлыкта аларның бер өлеше), киресенчә, большевикларча ажгырган сугышчанлык юлына бастылар, башка караштагыларны "сәяси ялгышларда"—кичерелмәслек гөнаһларда гаепләргә тотындылар.

Әлбәттә, мәсьәлә асылда, болай ирония белән сурәтләнгәнчә, бик үк гади, примитив түгел иде. Татар халкының чыгышын болгарлар аша бары ***автохтон*** (тамырлары буенча ***җирле***) кавемнәрдән чыгарырга омтылу ул Кырым татарлары язмышын уртаклашу куркынычыннан качарга теләүнең нәтиҗәсе иде. (Ул елларда Кремльдә Идел-Урал татарларын да Себер сазлыкларына, яисә Тува тауларына сөрү хакындагы фикерләрнең булганлыгы мәгълүм; тик бөтен Русия буйлап сибелгән зур халыкны җыеп алу мөмкин булмаганлыктан, Сталинның бу омтылышы тормышка ашмыйча кала; шуңа күрә Алтын Урда чорын тарихтан сызып ату—татар халкын аның тарихындагы мөһим бер дәверен юкка чыгару аркылы җәзалау юлын сайлаганнар иде...)

Үзгәртеп кору процессы башланып, сүздә, фикердә, димәк, фәндә дә бераз иркенлекләр туа башлагач, "алтайчылыкның" яңа вариантлары баш күтәрде. Әйтик, тамырларны янә Үзәк Азиядән эзләү, яисә татар дигән кавемнең Идел буйларына түгелмичә-чәчелмичә дигәндәй, ягъни күптән формалашкан бер этнос рәвешендә, Байкал якларыннан ук күченеп килгәнлеге хакында яза башладылар. Җучи Олысы (Алтын Урда) империясенең барлык җирләрен дә татар җире, бөтен халкын да гел татарлар итеп аңлата башлау, гадиләштереп әйткәндә, шул теориянең үзенчәлекле (дөресрәге, "бәйдән ычкынган") бер варианты иде. Бу юнәлешнең төп сыйфаты ул кайчандыр Үзәк Азиянең бер

почмагында туган, аннары киң таралган зур эчтәлекле этноним белән соңрак оешкан конкрет этнос арасына тигезлек билгесе куюга, шул рәвешчә борынгылыкка дәгъва итүгә кайтып кала.

Дөрес, үз нәүбәтендә болгарчыларда да "бәйдән ычкыну" галәмәтләре житәрлек. Мәсәлән, очы очка ялганмаган, гел ярты дөреслек белән ярты ялганны буташтырудан, ягъни тарихи теркәлгән реалийларны—исемнәрне, атамаларны, күренеш төшенчәләрен уйдырма контекстка салган фальсификациядән гыйбарәт "Җәгъфәр тарихы", "Шан кызы" ише, мәгәр әдәби җәһәттән шактый оста башкарылган нәрсәләрнең барлыкка килүе, шул ялганнарны күрә торып күз йоммыйча яклаучыларның да табылуы моны артыгы белән раслый. 1944 елгы карар тәэсирендә көчәйгән болгарчылыкның төп максаты, әгәр мәсьәләне "чишендереп" карасак, татар халкы этногенезын гел автохтон—жирле тамырлардан гына башлауга кайтып кала. Аларның фикеренчә, бернинди халыкларның күченүе—миграцияләр, шулар нәтижәсендә этник харита үзгәрүләр булмаган һ.б. Шул ук вакытта алар үзләре дә, "киң колачлылыкка" дәгъва иткән "алтайчылардан" артта калмаска тырышып, болгар-татарларның бабалары, дип әллә нинди биармияләрне дә, составы күпкә катлаулы, серле скиф-сарматларны да атыйлар.

Бу ике карашның бәхәсле, хәтта зәгыйфь урыннары, безнеңчә, иң элек мәсьәләне гадиләштерү, "туры сызык" сыманрак хәлгә генә кайтарып калдырырга, аннары ясалма рәвештә булса да, тамырларны артык тирәнәйтергә омтылудан гыйбарәт.

Борынгылыкта халыкларның күченүләре, миграцияләре булмаган, дигән тезис асылда кешелек тарихын тулаем күзаллау, узганны **тарихи дөрес танып-белү** булмаудан килеп чыккан нәрсә. Мондый раслауларның шактый мантыйксыз икәнлеген кешелекнең яңа заман тарихыннан да күрергә мөмкин. Әйтик, XV гасырга кадәр рус этносы вәкилләре зур Идел буена да килеп житмәгән иде. Ә XX йөздә алар Камчатка, Сахалинга кадәрге аралыктагы халыкның күпчелеген тәшкил итә башладылар. (Тагын берничә дистә елдан, ягъни киләчәктә, Уралның көнчыгышында нинди этнос күбәячәге хакында да айнык фаразлар юк түгел хәзер...)

Колумбка кадәр Америка кыйтьгасендә дә гел кызыл тәнлеләр яшәгән булса, хәзер анда ак тәнлеләр күпчелекне тәшкил итә. Киләчәктә исә кара тәнлеләр белән сара ырык (раса) вәкилләренең күпчелеккә әверелү тенденциясе реаль икән... Австралияне бер читкә куеп, Аурупа илләренең дә демографик яктан үзгәрә баруына күз салыйк... Димәк, булган ул, булган халыкларның күченүләре. Хәзер дә үзенчәлекле рәвештә дәвам итә ул. Элек кешеләрнең азрак санлы, жирләрнең күп өлеше аз халыклы булган чорларда андый хәрәкәт бигрәк тә көчле булган.

Шул ук вакытта алтайчыларның, "саф болгарчыларның" да татар этногенезында жирле кавемнәрдән финн-угорларның өлешләрен житәрлек дәрәжәдә исәпкә алып бетермәүләре—хәзерге татарларның антропологик төрлелегенә житди игътибар итмәүләре дә бик сәер. Антрополия исә шәрекъка да, жирле "өлешләргә" дә тартеп күрсәтә.

Шулай итеп, "булмаган ул миграцияләр!"—дип, өстәлгә төрәләрчә шапылдатып сугу белән генә мәсьәлә хәл ителми икән.

Бер үк вакытта әле генә бәяләнгән һәр ике юнәлешнең дә, безнеңчә, яшәргә хаклары булды һәм бар. Төрле юнәлеш вәкилләре ижади ярышып эшләсәләр, хакыйкать өчен файда гына булачак. Чөнки язмышы гаять катлаулы татар тарихында аларның һәр икесенә дә үзләренә "яраклы" дәлилләре житәрлек. Чөнки татар халкы формалашуда һәр ике башлангычның да өлешләре булган һәм бар. Тик "яраклылык" һәм "өлешнең" берсе белән генә чикләнмичә, үзенә ошап бетмәгән дәлилләрдән күз йоммыйча, гыйльми бәхәстә бер-беренне суд хөкеменә тартырлык дәрәжәдә әрләшү түбәнлегенә төшмичә, аерым фактларны анализлаудан узып, барлык мәгълүматларны, каршылыклы күренешләрне дә синтезлау—бергә туплау, кушу югарылыгына омтылырга кирәк. Каршылыктан куркырга ярамый, бер акыл иясе әйткәнчә, "капма-каршылык ул иң чын дөреслек". Чөнки ул реаль тормышның чагылышы.

Мондый таләп үтәлсен өчен, әлбәттә, төрле "милли" чыганаклардан

иркен файдалана алырлык дәрәҗәдә күп телләр белү, тел-язу белү өстенә тарихи тикшеренү өчен мөһим методик һәм методологик алымнарны да үзләштерү зарур. Ни кызганыч, безнең чыганаклар укудан тыш, тәҗрибә уртаклашу өчен дә кирәкле хәзерге заман телләрен белүебез чамалы. Методологиябез дә теләсә нинди мәсьәләгә карата күп заманнар: "классиклар менә шулай өйрәтә", яисә "директорыбыз менә шундый карашны хуплый",—кебек күсәк-дәлилләр тирәсеннән әлләни ерак китмәгән. Ахыр чиктә, фикерләү үзенчәлегебез, шулайрак. Моның тәэсиреннән, хакыйкатьне монополиягә әверелдерү омтылышыннан бик әкрен арынабыз. Ә хакыйкать исә бер төркем, бер шәхес милкенә әверелмичә, уртак байлыгыбыз булырга тиеш.

Профессор Рона-Ташның хезмәте, гәрчә аның төгәл хәл ителеп бетмәгән, хәтта бәхәсле урыннары да булганы хәлдә, күргәнебезчә, колач киңлеге, анализ тирәнлеге, синтезлау алымының көчлелеге белән аерылып тора.

Шул рәвешчә, миграция мәсьәләләре теоретик планда каралганнан соң, автор чама белән элгәрге "баба мажарларның" (прото-мажарларның) кайчандыр Көнбатыш Себер якларыннан чыгу ихтималын билгели. Аннары аларның Чулман белән Урал тавы араларында торуларын, моннан соң Көньяк Уралга, янә "бераздан" Дон-Кубан тирәләренә барып чыгуларын, шул төбәкләрдә төрки һәм башка халыклар белән төрле мөнәсәбәткә керүләрен, аралашуларын беләбез. Мажарларның азмы-күпме дәрәҗәдә мөстәкыйль тарихлары, галим фикеренчә, безнең эраның V—VI, хәтта VII—VIII гасырларында башлана икән. Димәк, Рона-Таш үз халкының тарихын ясалма рәвештә борынгылаштыру идеясе белән мавыкмый.

Болгар-хәзәр бәрелешләре чорыннан соң мажарларның тагын да көнбатышкарак күченүләре күзәтелә. IX гасырның ахырында алар Карпат тауларына, X йөзнең нәкъ башында исә Дунай буйларына барып җитәләр. Үзләре белән кайбер төрки кавем ярчыкларын да ияртеп киткән мажарлар бу якларда славян кабиләләре һәм башка илләр, халыклар белән дә төрле характердагы мөнәсәбәтләргә керә (317—338 бб.).

Хезмәтнең Карпат чорына багышланган бүлегендә (IX, 339—370 бб.) мажар кабиләләре конфедерациясе оешу, илнең сәяси һәм социаль структурасы, икътисады, дини инану һәм белем дәрәҗәләре, ниһаять, мәдәни казанышлары карала. Мажарларның Аурупада төпләнүләре, җирле шартларда үз урыннарын табу мәсьәләләре дә кыскача күзәтелгәч, автор тыгыз эчтәлекле гомум нәтиҗәләр белән китапның өченче кисәген тәмамлый (X—XI, 373—391 бб.).

Бу соңгы дәвер мажар-венгр халкы тарихында "ватан яулап алу" дигән үзенчәлекле гыйбарә белән атала. Һәм 1001 елда яңа җирләрдә үз дәүләтләрен оештырулары белән мажар-венгр тарихының борынгы чоры тәмамлана.

Шулай итеп, тарихи язмышлары кайдадыр Көнбатыш Себердәме, Урал таулары тирәсендәме башланса да, Көнчыгыш Аурупаның нәкъ үзәгендә тамырларын тирән җибәрә алган, әйләнә-тирә халыкларының берсенә дә телләре, милли аңнары белән охшамаган хәлдә, гомум Аурупа цивилизациясендә үз урынын тапкан үзенчәлекле "мажар утравының" бу тарафларга килгәнче узган озын юллары, профессор Рона-Таш китабы буенча, менә шулайрак күз алдына килеп баса...

Китапның соңгы **дүртенче** кисәге "**Хәзерге заман тикшеренүләре**", дип аталып (XII—XIII, 395—422 бб.), анда борынгы чор мажар-венгр тарихына багышланган, төрле илләр һәм телләрдә чыккан махсус хезмәтләргә тәфсилле күзәтү ясала. Җөмләдән Идел буе археологиясе буенча актив эшләгән Татарстан галимнәренең исемнәре дә ихтирам белән телгә алына. Гомумән, А.Рона-Ташның стиленә, авторның үз фикерләрендә нык торуына, ул фикерләрнең күпләрнекеннән башкачарак булуына карамастан, салмаклы әдәплелек, корректлылык хас. Җае чыккан саен галим үзенең кайбер элекке фикерләренә төзәтмәләр, өстәмәләр кертүдән дә тартынып тормый. Чөнки кешенең үз фикере дә үсәргә, үзгәрергә мөмкин.

Мондый сыйфат, күрәсең, плюрализм дигән нәрсәнең фикердәге тәрәккыят өчен зарурлыгын аңлаудан киләдер.

Ниһаять, мажарча тарихи традицияләр, "хунн—мажар дошманлыгы"

мәсьәләләре, этнонимикада мажар-башкорт параллельләре кебек хосусыйрак, мәгәр шушы өлкәләрнең белгечләре өчен мөһим проблемаларга багышланган кечкенә бүлекләр белән китапның төп өлеше тәмамлана (XIV—XVI, 423—443 бб.).

Югарыда әйтелгәнчә, хезмәт күләмле һәм гыйльми әсәр өчен зарурый кушымталар (библиография, күрсәткечләр) белән дә тәэмин ителгән (445-566 бб.). Китапта алтмыштан артык югары сыйфатта башкарылган махсус хариталарның берелүе хезмәттә каралган вә тасвирланган социаль-иҗтимагый процессларны, мәсәлән, күченү һәм миграцияләрне, халыклар аралашуы һәм ил-дәүләтләр арасындагы мөнәсәбәтләрне күргәзмәле рәвештә аңлау, бәяләү өчен зур уңайлыклар тудырган.

* * *

Китапка багышланган күзәтүнең максатын текстка кертелеп барган безнең уйланулардан укучы үзе дә аңлагандыр, дип өметләнәбез. Шулай да бер нәрсәгә махсус күрсәтү артык булмас шикелле. Кыскача итеп әйткәндә, ул чын фәнни компетентлыкка, ягъни тарих өлкәсендә гыйльми хезмәтләр башкарыр өчен һәръяклап төпле әзерлеккә, махсус белемгә ия булу мәсьәләсе. Чөнки тарихи белем дигән нәрсә ул аннан-моннан чүпләнеп җыелган фактларны үзең теләгәнчә генә бер җиргә өеп куюдан, бигрәк тә аларның үзеңә, үз карашыңа җайлыларын гына сайлап алып, шулардан гына чыгып фикер йөртүгә— раслауга яки кире кагуга кайтып калмый. Чын гыйльми тикшеренү процессында тарихи хакыйкатькә ирешү дигән нәрсә ул бер мәсьәләгә (күренешкә) караган, шул ук вакытта каршылыклы булып күренгән фактлар белән фикерләрнең үзара "аңлаша", килешә алуыннан чыга торган кире каккысыз объектив нәтиҗәдән гыйбарәт. Хис һәм субъектив омтылышлардан өстен чыга торган нәтиҗәдән. Профессор Рона-Таш китабында, безнеңчә, шушы юнәлештә шактый алга китү барлыкка килгән.

Бу күзәтүгә бирелгән исемдә "гыйбрәт" дигән сүз дә бар. Андый төшенчәне куллану очраклы түгел—сәбәпләре күп. Аларны түбәндәгечә төркемләп булыр иде:

**Беренчедән,** хезмәтнең чын комплекслы гыйльми тикшеренү сыйфатына ия булуы; бу сыйфат төрле телләрдәге чыганаклардан компетентлы рәвештә файдалану белән бергә, чыганакларның да төрле типлары һәм төрләре бертигез дәрәҗәдә җәлеп ителү белән тәэмин ителгән.

**Икенчедән,** кавем-этнос тарихының хәрәкәттә, динамикада, башка илләр, халыклар белән тыгыз мөнәсәбәттә каралуы; шул ук вакытта кайбер милли тарихлардагы кебек мәгънәсез бөеклекне дәгъва итеп, башкалардан гел дошман эзли торган эгоистик чирләрдән азат булуы һәм **тарихи хакыйкать** дигән олы нәрсәнең борынгылыкка карата бүгенге милли интерес кебек эчтәлеге дә таррак, әһәмияте дә нисбирәк омтылышлардан өстен куелуы.

Ниһаять, **өченчедән,** һәм иң гыйбрәтлесе, профессор Андраш Рона-Ташның үз халкының тарихи юлында очраган төрле күренешләрне, "начаррак яткан" барлык фактларны үзләштерергә, тартып-сузып "миллиләштерергә", янәсе "үз тарихын баетырга" тырышмыйча, дәлилләрнең гыйльми таләпләргә тәгәл җавап бирә ала торганнары нигезендә мантыйкка иң муафыйк нәтиҗәләргә омтылуы; хезмәтнең бөтен эчтәлегеннән, стиленнән күренгәнчә, галимнең: дөньяда халыклар—күршеләр һәм кардәшләр—күп, без шуларның берсе һәм башкалар белән тигез хокуклысы, дигән һәм гади, һәм бик гадел принцип белән гамәл кылуы.

Тарихи белем өлкәсендә шушындый айнык табигатьле гыйльми эзләнүләрнең, ягъни акча девальвациясе тәэсирендә сүз вә фикер девальвациясенә бирелмәгән, чын таләпчәнлек рухы белән сугарылган әхлакый тотрыклы хезмәтләрнең күбрәк булуын теләп каласы килә.

Җөмләдән безнең милли тарихыбызда да...

**Миркасыйм ГОСМАНОВ**
**Алсу АРСЛАНОВА**

## 13—РӘГЫЙД (КҮКРӘҮ) СҮРӘСЕ

**(Рәгыд сүрәсе 43 аятьтән тора. Мәккәдә һәм бер өлеше Мәдинәдә иңгән, дип язучылар бар. Сүрәнең 13 нче аятендә күк күкрәү мәгънәсенә туры килә торган «ер-Рәгыд» сүзе бар, шул сүз сүрәнең атамасы булып киткән.)**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Әлиф. Ләм. Мим. Ра. Болар *(изге)* Китапның аятьләредер. Аллаһтан сиңа иңдерелгән *(Коръән)* хактыр, ләкин адәмнәрнең күбесе моңа ышанмый. **(2)** Аллаһ шулдыр ки: күкләрне сез күреп торганча, терәксез биектә тотучы; соңыннан Гарештә хаким булды; Кояшны, Айны үзенең әмеренә куйды. Билгеләнгән вакытка чаклы алар йөреп торырлар. Раббы белән кавышачакларын яхшы белеп торсыннар, дип Алла, һәр эшне җиренә җиткезеп идарә итә һәм аятьләрен аңлата. **(3)** Ул—Җирне ясаучы, анда тауларны, елгаларны барлыкка китерүче вә Ул—җимешләрнең һәрберсен, үз орлыкларыннан пар-пар итеп яралтучы. Төн белән көнне каплаучы. Аңлый белгәннәр өчен бу хикмәтләрдә гыйбрәтләр бар. **(4)** Җир йөзендә бер-берсенә күрше кыйтгалар *(икълимнәр, материклар)*, йөзем бакчалары, игеннәр, бер тамырдан вә төрле тамырлардан үсеп чыккан хөрмә агачлары бар. Боларның барысы да бер су белән сугарыла. Шуңа күрә, җимешләрен дә берсеннән икенчесен өстенрәк куябыз. Менә боларның барысы да уйлый белгәннәр өчен бер гыйбрәттер.

**5.** *(Ий, Мөхәммәд, кяферләрнең иман китермәүләренә)* аптырасаң, тагын да аптырарлыгы бар:

—Үлеп туфрак булгач, без яңадан терелечәкбезмени?—дип әйтүләре. Менә шулар бит инде Аллаһны инкарь итүчеләр. Кыямәт көнендә аларның муенында чылбырлар булыр. Алар—тәмуг кисәве. Алар анда мәңгегә калачак. **(6)** Алар синнән игелек түгел, ашкынып яманлык көтә. Гәрчә, алардан элек тә гыйбрәт булырлык байтак кына газап вакыйгалары булып узды. Чыннан да, инсаннар яманлык кылса да, Раббың аларны ярлыкады. *(Ләкин)* Раббыңның җәзасы да бик хәтәр булачак. **(7)** Кяферләр әйтте:

—Раббыңнан бер могҗиза иңдерелсә иде,—диделәр.—Син бит бары тик вәгазь укучы гына. Һәр халыкның бар үзенең вәгазьчеләре. **(8)** Һәр ана *(хатын, бия, сарык...)* ның карынында ни яралганын һәм яралгының кимчелеклеме, әллә мөкаммәлме икәнлеген Аллаһ белеп тора. Аның һәр эше төгәл үлчәнгән.

**9.** Аллаһ күренгәннәрне дә, күзгә күренмәгәннәрне дә белеп тора. Аллаһ мәртәбәле һәм бөек.

**10.** Тел яшергән кеше дә, ачыктан-ачык сөйләгән дә, төнлә яшертен-пошыртын йөргән дә, көндезен гамәл кылган кеше дә Аллаһ өчен барыбер *(Ул барысын да күреп, белеп, ишетеп тора.)* **(11)** Һәр кешенең алдында да, арка тарафында да Аллаһ әмере белән сакларга *(һәм ни кылганнарын язып барырга)*

Журнал өчен **Рабит БАТУЛЛА** әзерләде.

куелган фәрештәләр бар. Берәр халык үзе үзгәрмәсә, Аллаһ аларны үзгәртмәс. Аллаһ берәр токымга җәза бирергә теләдеме, ул җәза, һичшиксез, биреләчәк *(кире чигенү булмас)*. Аллаһтан башка зат аларга ярдәм итәлмәс.

**12.** Ул сезне курку белән өмет арасында тотар өчен, яшенле, дәһшәтле, яңгырлы болытлар хасил итте. **(13)** Күкләр күкрәп, Аллаһны мактый һәм Аны мәртәбәли. Фәрештәләр дә Аның дәһшәтеннән куркып, тәсбих әйтә. Аллаһ турында зарарлы сүз көрәштергән вакытта, Аллаһ яшен яшьнәтә, теләгәнен яшеннән суктыра. Аның җәзасы бик тә хәтәр. **(14)** *(Кул сузып)* ялварырга бары тик Аллаһ кына лаек. Аннан башка берәү дә *(таш сыннар да, потлар да, тимер-бакыр һәйкәлләр дә)* кул сузып ялварганга ярдәм итмәс. Андыйлар: авызыма су килсен, дип суга карап, ике кулын сузып ялваручылар кебектер. Алар никадәр генә ялварса да, су үзе килеп, аларның авызына кермәс. Кяферләрнең догалары буш саташу гына. **(15)** Күкләрдә вә Җирдә булганнар иртә-кич, теләсә-теләмәсә дә, Аллаһка сәҗдә итә, алар белән бергә күләгәләре дә. **(16)** Сора син алардан:

—Күкләрнең һәм Җирнең хуҗасы кем?—диген дә, җавабын әйт:

—Аллаһ!—диген.—Аны инкарь итеп, файда да, зыян да эшләрдәй көче булмаган дуслар *(башка ясалма илаһлар)* эзлисезме?—диген.

Тагын әйт:

—Сукыр кеше белән күзе күргән кеше бер була аламы?—диген.—Яки караңгылык белән яктылык берме? Әллә соң алар табынган *(сыннар, ташлар)* Аллаһ яралткан кебек нәрсәләрне ярата ала кебек күренәдеме? Әйт син:

—Бөтен нәрсәне яралтучы бер Аллаһ. Ул—берәү генә. Аңа каршы торылык кодрәт иясе юк.

*(«Сукыр кеше белән күзе күрә торган кеше», «караңгылык белән яктылык» чагыштырмалары, әлбәттә, күчермә мәгънәләрдә алынган. Надан кеше, Коръәнне белмәгән, дөнсез кешенең күңел күзе сукыр; иманлы кеше, белемле кеше—күзле. Караңгылык исә томаналык, наданлык; яктылык—Аллаһның нуры, Коръән, иман нуры, дип аңларга кирәк.)*

**17.** Ул Күктән су иңдерде дә, елгалар-ермаклар үз ярларында ташкын булып акты. Бу ташкын кайнап өскә чыккан шакшы күбекне дә үзе белән алып китте. Бизәнү әйберләре, кирәк-ярак кораллары эшләгәндә эретелгән алтын-көмеш өстендә дә шундый күбек хасил була. Менә шулай итеп, Аллаһ яман белән яхшыны аерыр өчен мисаллар бирә. Күбек *(ашлык өстендәге кибәк тә)* кибеп-очып китә. Инсаннар өчен файдалысы Җир өстендә кала. Менә Аллаһ шундый чагыштырмалар бирә.

**18.** Раббының әмеренә буйсынганнар өчен иң гүзәл *(әҗер)* бар *(җәннәт)*. Аңа буйсынмаганнарга килгәндә, алар Җир йөзендә булган байлыклары өстенә тагын да шуның кадәр малларын фида итеп котылыр иде *(ләкин ул маллар кабул ителмәячәк)*. Аларның барасы җире—җәһәннәм. Ул бик тә хәтәр урын.

**19.** Раббыңнан сиңа иңдерелгән *(Коръән)* нең хак икәненә инанган кеше белән *(күңел күзе)* сукыр кеше *(инкарь итүче)* бер булырмы? Ләкин моны зиһенле кешеләр генә аңлый. **(20)** Алар Аллаһның әмерләрен җиренә җиткезеп үтәүчеләр вә сүзләрендә торучылар. **(21)** Алар Аллаһ кушканны җиренә җиткезүчеләр *(кардәшләр, мөселманнар белән дус булу—бергәләшү, үзара ярдәмләшеп, хөрмәт итеп яшәүчеләр)*, гөнаһ кылудан сакланган, *(Кыямәт көнендә)* җәзадан курыккан кешеләр. **(22)** Янә алар Раббының ризалыгын алырга теләүче, чыдам-сабыр кешеләр, намазны калдырмыйча, дөрес итеп укыганнар, үзләренә бирелгән ризыкны яшереп тә, ачык рәвештә дә *(Аллаһ юлында)* сарыф иткәннәр, игелек белән яманлыкны каплаган кешеләр. Менә шулар өчен Ахирәттә гүзәл йорт хәзерләнгән. **(23)** Ул—Гаден җәннәтләредер. Анда саф мөселман булган аталар, аналар, хатыннар вә балалар гына керә алыр. Фәрештәләр барча капкалардан алар янына узар. **(24)** Һәм әйтерләр:

—Сабырлыгыгызга җавап буларак, сезгә сәламнар булсын. Дөнья йортының соңгы нәтиҗәсе *(оҗмах)* нинди гүзәл урын,—диярләр.

**25.** Аллаһка ант итеп тә, сүзләрендә тормаганнар, Аллаһ тарафыннан *(кардәшләрен, мөэминнәрне хөрмәт итеп, берләшеп яшәргә)* кушылганны үтәмәгәннәр *(мөселманлыктан аерылганнар)* вә Җир йөзендә фетнә чыгарганнар өчен ләгънәт булыр һәм яман йорт *(тәмуг)* аларның урыны булыр. **(26)** Аллаһ Үзе ихтыяр иткәнгә ризыкны мул бирер яки аз микъдарда бирер. Алар дөнья тормышында масайдылар. Дөньядагы тормыш, Ахирәттәгесе белән чагыштырганда, мәшәкать белән узып китүче *(ләззәт)*.

**27.** Кяферләр әйтә:

—*(Мөхәммәдкә)* Аллаһтан бер могҗиза иңдерелергә тиеш иде бит инде,—диделәр.

Әйт:

—Һичшиксез, Аллаһ Үзе теләгәнне *(кирелəрне)* юлдан яздырыр, Үзенә буйсынганнарны тугры юлга күндерер,—диген. **(28)** Болар иманлы кешеләр, күңелләре белән Аллаһны зикер иткәндә, тын калучылар *(гыйбадәт кылучылар)*. Мәгълүмдер ки, Аллаһ турында уйлаганда күңелләр рәхәт тынычлыкка ирешә. **(29)** Иман китереп, игелек кылучылардан да бәхетле кем булыр! Гүзәл йорт *(җәннәт тә)* алар өчен.

**30.** *(Ий, Мөхәммәд)* шулай итеп, килеп-киткән башка халыкларга пәйгамбәрләр җибәргәнем кебек, үзенә күндерелгән Китапны аларга укысын дип, сине дә үз халкыңа Пәйгамбәр иттек. Алар Рахмәнны инкарь итә. Әйт син аларга:

—Ул—минем Раббым. Аннан башка тәңре юк. Бары тик мин Аңа гына тәвәккәл иттем вә бары тик аның хозурына гына барачакмын,—диген.

**31.** Китап кодрәте илә таулар кучерелсә дә, Аның көче белән Җир шартласа да, Аның куәте белән мәетләр сөйләшә башласа да—бөтен эшләр дә Аллаһ ихтыярында. Иман китергәннәр әле һаман аңламадылармыни? Әгәр Аллаһ ихтыяр итсә, барча халыкларны да тугры юлга күндерә алган булыр иде. Кяферләр, Аллаһның әмере килгәненә чаклы кылган гөнаһлары өчен котмәгәндә, өзлексез бәлага тарачаклар. Яки афәт аларның баш очында гына, өй түбәсендә генә сагалап торачак. Һичшиксез, Аллаһ Тәгалә вәгъдәсеннән кире кайтмас.

**32.** Чыннан да сиңа кадәр килгән пәйгамбәрләрне дә мыскыл иттеләр һәм Мин инкарь итүчеләргә *(иманга килү өчен)* форсат бирдем. Ләкин соңыннан *(алар иманга килмәгәч)* барыбер җәзам белән тоттым. *(Сезгә)* андый газапны күрергә язмасын.

**33.** Һәр җан иясенең ни казанганын күзәтеп, белеп торучы *(Аллаһ)* боларны эшли алмаган зат *(ягъни ясалма тәңре)* белән тиң булырмы? Алар *(таш сыннарын)* Аллаһка тиңләп маташтылар. Әйт:

—Аларның исемнәре ничек, *(ул ташларның, агачларның, һәйкәлләрнең)* кодрәте нидә? Әллә сез Җир йөзендә Аллаһ белмәгән серләрне ачык итеп сөйләп бирә аласызмы? Әллә сез буш сүз лыгырдыйсызмы?

Чынында инкарь итүчеләргә аларның яман эшләре яхшы булып күренде вә алар тугры юлдан язды. Аллаһ юлдан яздырган кешене тугры юлга беркем дә күндерә алмас.

**34.** Фани дөньяда алар өчен бары тик бер җәза бар. Ахирәт газабы исә тагын да хәтәррәк. Аларны Аллаһның җәзасыннан коткаручы зат булмас. **(35)** Саф мөселманнарга вәгъдә ителгән җәннәтнең сыйфатлары менә болардыр. Арыкларыннан сулар агып торыр. Җимешләре, агач күләгәсе мәңгелектер. Тәкъвалар *(яманлык кылудан тыйлыкканнар)* өчен бу—бәхетле нәтиҗәдер. Кяферләрнең ахыры тәмугтыр.

**36.** Үзләренә китап иңдерелгәннәр сиңа иңдерелгәнгә *(Коръәнгә)* сөенделәр. Ләкин фиркалар *(төркемнәр)* арасында *(Коръәннең)* кайбер өлешләрен инкарь итүчеләр дә бар. Әйт:

—Миңа бары тик Аллаһка коллык итәргә һәм Аңа иш сайламаска

боерылды. Мин бары тик Аны *(ярдәмгә)* чакырамын һәм кайтуым да Аның хозурына гына булачак,—диген. **(37)** Шулай итеп, Без аны хөкем *(хикмәтле сүз)* сыйфатында гарәпчә иңдердек. Әгәр сиңа килгән бу гыйлемнән соң, аларның йогынтысына бирелсәң, Аллаһ тарафыннан сиңа ярдәм дә, сине яклаучы дустың да булмаячак. **(38)** Хактыр ки, синнән алда да Без пәйгамбәрләр күндердек вә аларга хатыннар һәм балалар бирдек. Аллаһның рөхсәтеннән башка һичбер пәйгамбәргә могҗиза эшләү сәләте бирелмәде. Һәр заманның үз китабы *(үз тәкъдире)* бар. **(39)** Аллаһ Үзе теләмәгәнен *(искергән кагыйдәләрне)* юк итәр, теләгәнен бар кылыр. Бөтен китапларның китабы *(китапларның анасы—Ләүхел Мәхфүз)* Аның янындадыр.

**40.** Без аларга вәгъдә иткән *(җәзабызның)* бер өлешен *(бу дөньяда)* күрсәтербез дә, сине аңа чаклы вафат иттерербез. Синең вазифаң фәкать *(Аллаһ әмерләрен кешеләргә)* житкезү генә. Исәп-хисап өзү Безнең ихтыярда.

**41.** Без Жир йөзен як-якларыннан киметә барганыбызны алар үз күзләре белән күрмиләрмени соң? Аллаһ Үз ихтыяры белән хөкем чыгара. Аның хөкемен боза ала торган зат юк. Аллаһ бик җәһәт исәп-хисап итә. *(«Җир йөзен як-яклардан киметәбез» гыйбарәсен төрлечә шәрехлиләр. Имеш, мөселманнар күбәя барып, аларның били торган җирләре-туфраклары да арта, кяферләрнең җире кими бара. Бу—бер шәрех. Икенчесе исә, эрозия, су басу, җил-давыллар аркасында яраклы җирләр кими. Җир шарының кабыгы, як-яклары үзгәрә бара.*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**42.** Алардан алда яшәгәннәр дә *(үз араларыннан чыккан)* пәйгамбәрләргә тозак кордылар. Гәрчә, бөтен тозаклар да Аллаһ ихтыярында. Чөнки Ул һәркемнең ни кылачагын, ни казаначагын белеп тора. Бу йортта *(фани дөньяда)* кылганнарның әҗере булачак, ни булачагын кяферләр озакламый беләчәк.

**43.** Кяферләр:

—Син пәйгамбәр буларак күндерелгән кеше түгелсең,—диләр.

Әйт син аларга:

—Минем белән сезнең арадагы бәхәсне хәл итәр өчен бер Аллаһның шаһит булганы һәм *(пәйгамбәрлек билгесе булган)* Китап житәр,—диген.

## 14—ИБРАҺИМ СҮРӘСЕ

**(Ибраһим сүрәсе 52 аятьтән тора. Бер өлеше Мәдинәдә, бер өлеше Мәккәдә иңгән. Ибраһим Пәйгамбәрнең догаларын үз эченә алганга күрә, сүрә шулай аталган.)**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Әлиф. Ләм. Ра. Раббының рөхсәте белән инсаннарны караңгылыктан яктылыкка әйдәп, һәр нәрсәне жиңүче, мактауга лаек Аллаһның юлына чыгару өчен сиңа иңдергәнебез бер Китап ул—Коръән.

**2.** Аллаһ ул шундый, күкләрдә һәм Жирдә ни булса, шуларның барысы да Аллаһныкы. Дәһшәтле газап кяферләргә кайгы китерәчәк. **(3)** Дөнья тормышын Ахирәттәгесенә караганда өстен куючылар—Аллаһ юлыннан яздыручылар; шул юлны кәкрәйтергә теләгәннәрнең барысы да Хактан еракта адашып калдылар.

**4.** *(Аллаһның әмерләрен)* Ана телендә яхшылап аңлатсыннар дип, *(үз араларыннан)* пәйгамбәрләр күндердек. Аллаһ *(мөселман булырга)* теләмәгәнне адаштырыр, теләгәнен тугры юлга чыгарыр. Аллаһ көч һәм хикмәт иясе.

5. Мусаны да Без:

—Халкыңны караңгылыктан *(надანлыктан)* алып чык, аларны *(элек яшәгән халыкларның башына Аллаһ китергән һәлакәт көннәре турында)* искәрт,—дип аятьләр биреп күндердек. Һичшиксез, монда *(бу хикмәтләрдә)* чыдам-сабыр, итеп, шөкер кылучылар өчен гыйбрәтләр бар. **(6)** Шуннан соң Муса үз халкына болай диде:

—Аллаһ биргән нигъмәтләрегезне исегезгә төшерегез. Ул сезне хәтәр җәзалар белән җәзалаучы, угылларыгызны суеп, хатын-кызларыгызны гына исән калдыручы Фиргавен токымыннан коткарды. Менә, сезгә сөйләгәннәрдәгечә, Раббыгыз сезне шулай сынау белән сынады. **(7)** Исегездәме, Раббыгыз сезгә:

—Шөкер итсәгез, әлбәттә, сезгә *(нигъмәтне)* арттырачакмын, әгәр дә көферлек кылсагыз, һичшиксез, бирәчәк җәзам бик тә хәтәрдер,—дип хәбәр итте.

**8.** Муса тагын әйтте:

—Әгәр дә Җир йөзендә һәрберегез һәм барча кешеләр дә көферлек итсә, белеп торыгыз *(берегез дә Аңа зыян итә алмас)*. Аллаһ *(сезгә)* мохтаҗ түгел. Ул мактауга лаек,—диде.

**9.** Сездән элек яшәп киткәннәр: Нух, Гад, Сәмуд халыклары һәм алардан соң яшәгәннәр турындагы хәбәрләр сезгә килеп ирешмәдемени? Аларны Аллаһтан башкасы белмәс шул. Пәйгамбәрләре аларга могҗизалар *(аятьләр)* китерде. Алар үз куллары белән шул пәйгамбәрләрнең авызын томалады. Һәм алар әйтте:

—Сез алып килгәннәрне без инкарь иттек вә ышанырга кушканыгызга *(Аллаһка, Ахирәт көненә)* ышанмыйбыз,—диделәр.

*(«Үз куллары белән шул пәйгамбәрләрнең авызын томалады» гыйбарәсе башкача да тәрҗемә ителгән. Мәсәлән,* ***В. Пороховада*** *болай: они ж к устам своим протягивали руки (персты кусая от досады).* ***Ш. Ногманида*** *да шуңар якын тәрҗемә: Рәсүлләренә ачуланып, бармакларын тешләделәр.* ***И.Крачковскийда****: они вложили руки в уста свои.* ***Х. Чантайда****: кулларын авызларына этеп, диелгән. Без С. Гүмүш фаразын алдык.)*

**10.** Пәйгамбәрләре әйтте:

—Күкләрне һәм Җирне яралткан Аллаһ хакында шигегез бармы? Гәрчә, Ул сезнең гөнаһларыгызның бер өлешен ярлыкап, сезне мәгълүм бер вакытка кадәр яшәтер өчен, сезне *(хак дингә)* чакыра.

Тегеләре әйтте:

—Сез дә безнең кебек үк адәми затлар гына. Сез безне аталарыбыз табынган нәрсәләрдән биздерергә тырышасыз. Шулай булгач, безгә ап-ачык *(без ышанырлык)* дәлилләр китерегез,—диделәр. **(11)** Пәйгамбәрләре аларга әйтте:

—Әлбәттә, без сезнең кебек үк адәми затлар гына. Аллаһ Үзе теләгән *(гөнаһсыз)* кешеләргә нигъмәтен *(пәйгамбәрлекне)* бирә. Аллаһның рөхсәтеннән башка без сезгә бернинди дә дәлил китерә алмабыз. Мөселманнар бары тик Аллаһка гына сыенсыннар.

**(12)** Тугры юлны күрсәткән Аллаһка нишләп әле без ышанмаска тиеш? Сез китергән җәфаларга без түзәрбез. Тәвәккәл итәргә теләгәннәр бары тик Аллаһка гына тәвәккәл итсен.

**13.** Кяферләр пәйгамбәрләренә әйттеләр:

—Сезне йортыгыздан каттыян куачакбыз яки үзебезнең дингә кертәчәкбез,—диделәр. Раббы аларга:

—Залимнәрне, һичшиксез, харап итәчәкбез,—диде. **(14)**—Алардан соң ул җирләргә сезне урнаштырачакбыз. Каршымда басып *(җавап биреп)* торудан һәм вәгъдә итмешем җәзадан курыксыннар өчен.

**15.** *(Пәйгамбәрләр)* җиңү теләде *(Аллаһ ярдәмендә алар җиңде)*. Үҗәт-киребеткәннәр исә бөлде. **(16)** *(Үзсүзле ул кирebеткәннәрнең)* артында җәһәннәм тора. Анда аларга эренле кайнар су эчерәчәкләр. **(17)** Суны алар йотымлап эчәргә маташачак, ләкин йота алмаячак *(тамакларыннан узмаячак)*, аларга һәр яктан үлем килгән кебек булыр, ләкин алар үлмәс. Мондый газаплардан

башка да *(алар өчен)* хәтәр җәзалар бар. **(18)** Динсезләрнең язмышы давыллы көндә өермә туздырып алып киткән көл сыман. *(Гаделсезлек белән)* җыйган байлыкларыннан һични калмас. Бу—Хактан еракка китеп адашу булыр.

**19.** Күкләрне, Җирне, чыннан да, Аллаһ яралтканын күрмисезме? Әгәр Ул ихтыяр итсә, сезне юкка чыгарып, урыныгызга башкаларны бар итә ала. **(20)** Моны башкару Аның өчен һич тә авыр түгел.

**21.** Бөтенесе дә Аллаһ хозурына килеп басачак. Фәкыйрьләр тәкәбберләргә *(байларга, көч белән мактанучыларга)* әйтерләр:

—Без сезгә табынып, артыгыздан ияреп йөрдек. Хәзер сез безне Аллаһның җәзасыннан коткара аласызмы?

Алар әйтәчәк:

—*(Берни эшләр хәл юк)* Аллаһ безне тугры юлга күндергән булса, без дә сезне тугры юлдан йөреткән булыр идек. Хәзер сызлансак та, сабыр булсак та барыбер файдасы булмас инде. Чөнки безнең өчен сыеныр урын юк.

**22.** Исәп-хисап беткәннән соң, *(иманлылар—җәннәтләргә, гөнаһлылар җәһәннәмнәргә урнаштырылгач)* шайтан әйтер:

—Һичшиксез, Аллаһ сезгә вәгъдә иткәнне җиренә җиткезде. Мин дә сезгә вәгъдә иттем, әмма сезне алдадым. Сезгә ярдәм итәрлек көч миндә юк. Мин бары тик сезне инкарьга чакырдым. *(Аллаһка ышанмаска өндәдем).* Хәзер мине гаепләмәгез инде, үзегезне гаепләгез. Мин сезне коткара алмам, сез дә мине коткара алмассыз. Сезнең мине Аллаһка тиңләүегездән бүген мин ваз кичәм,—дип әйтер.

Шик юк ки, залимнәр өчен әрнетүле җәзалар бар.

**23.** Иман китереп, игелек кылганнар, Раббының рөхсәте илә арыкларыннан елгалар ага торган җәннәтләрдә мәңге яшәп калачак. Анда барысы да каракаршы очрашкач:

—Сәлам!—дип күрешәчәк. **(24)** Аллаһның нинди мисал китергәнен син белмисеңмени? Яхшы сүзне Ул тамыры җирдә, ботаклары югарыда булган нигъмәт агачына охшата. **(25)** *(Ул агач)* Раббының рөхсәте илә һәрвакыт җимеш бирә. Үрнәк-гыйбрәт алсыннар һәм истә тотсыннар дип, Аллаһ инсаннарга шундый мисаллар китерә. **(26)** Яман сүз *(нахак сүз, яла сүзе, көфер сүз)* төбе-тамыры белән куптарылып, җиргә аударылган затсыз агачка охшаш. **(27)** Пакь сүзләр белән иман китергәннәрне Аллаһ Тәгалә һәм фани дөньяда, һәм Ахирәттә дә ныгытыр. Залимнәрне исә адаштырыр. Аллаһ Тәгалә теләгәнен башкара. **(28)** Аллаһның телгәненә каршы көферлек кылган һәм соңыннан үз халыкларын һәлакәт йортына өстерәгән *(җитәкчеләр)* не күрмисеңме? **(29)** Алар җәһәннәмгә керәчәк. Ул—коточкыч әшәке ятакханә. **(30)** Кешеләрне Аллаһның тугры юлыннан яздырыр өчен, Аңа «тиң» *(уйдырма)* тәңреләр таптылар. Әйт син аларга:

—*(Теләсәгез ничек)* яшәгез. Кайтышыгыз барыбер тәмугка булыр,—диген.

**31.** Иман китергән бәндәләремә әйт: намазларын калдырмыйча, дөрес укысыннар, алыш-биреш һәм үзара дуслык булмый торган Көнгә *(кыяматкә)* чаклы үзләренә тапшырылган ризыкларын *(Аллаһ юлында)* кешегә күрсәтмичә дә, кешеләр күргәндә дә сарыф итсеннәр.

**32.** Аллаһ Күкләрне вә Җирне яралтты. Күктән яңгыр яудырып, дым белән үстереп, сезгә төрле ризык, җимешләр бирә. Рөхсәте белән диңгездә йөзеп йөрсеннәр өчен, сезнең карамакка көймәләр *(ясау сәләте)* бирде. Сезгә кулай булсын өчен елгалардан мул су агыза.

**33.** Төгәл тәртип белән гизүче Кояшны һәм Айны файдалы кылды. Төнне вә көнне сезгә кулай итте. **(34)** Ул сезгә ни теләсәгез шуны бирде. Аллаһның нигъмәтләрен санарга никадәр тырышсагыз да, очына чыга алмассыз. Дөресен генә әйткәндә, кеше ул—залим, үе гел көферлектә булыр *(булганына шөкер итмәүче зат).*

**35.** Исегездәме, Ибраһим галәйһиссәләм болай диган иде:

—Раббым, бу шәһәрне *(Мәккәне)* имин кыл. Мине һәм угылларымны сыннарга *(ташларга, һәйкәлләргә)* табынудан ерак тот. **(36)** Чөнки потлар, сыннар байтак кына кешеләрнең тугры юлдан язуына сәбәпче булды. Хәзер кем миңа иярә, шул минем тарафдарым булыр. Кем каршы төшә... Син, чыннан да, ярлыкаучы, гафу итә белүче. **(37)** Йа, Раббыбыз, әй, Хуҗабыз, намазны дөрес укысыннар өчен, мин кардәшләремнең берничәсен Синең Бәйт-и Харам *(Кәгъбә)* янындагы такырга урнаштырдым. Кешеләрнең күңелләрендә аларга карата мәрхәмәт урнаштыр, җимешләреңнән ризык бир, зинһар. Өмет итәмен ки, алар шөкер итәчәкләр. **(38)** Йа, Раббыбыз, шөбһәсез ки, Син безнең яшерен эшләребезне дә, ачыкларын да белеп торасың. Җирдә дә, Күктә дә Аллаһ белмәгән серләр юк. **(39)** Картлык көнемдә миңа Исмәгыйль белән Исхакны биргән Аллаһка барча мактаулар булсын. Шик юк ки, Аллаһ догаларны ишетүче.

**40.** Йа, Раббым, мине һәм минем нәселдән булганнарның барысын да өзлексез намазлы ит. Йа, Раббым, догаларымны кабул әйлә. **(41)** Йа, Раббыбыз, хисап Көнендә мине, атам-анамны вә мөэминнәрне ярлыка.

**42.** *(Ий, Рәсүлем)* залимнәрнең ни кылганнарын Аллаһ белми, дип уйлама. Ләкин Аллаһ аларга җәза бирүне куркудан күзләре атылып чыгар көнгәчә *(Кыямәткәчә)* кичектерә килә. **(43)** Башлары артка ташланган хәлдә, акайган күзләре, ак-кара күрмәстән, Күккә таба текәлгән килеш, куркудан бушап калган күңелләре белән алар чакыручы *(Аллаһның)* янына йөгерешеп килер. **(44)** Шуңа күрә, син аларны бүгеннән үк киләчәк газаплар турында сөйләп, кисәтә башла. Ул Көн килгәч, алар әйтер:

—Йа, Раббыбыз, ичмасам, безгә кыска гына вакытка форсат бир, Синең чакыруларыңа иярер идек, пәйгамбәрләрне дә кабул итәр идек,—дип әйтерләр. Шул чакта аларга әйтелер ки:

—Теге чакта сез: безгә җәза булмаячак, *(безнең байлыгыбыз чиксез, без Кыямәт көненә ышанмыйбыз)*, дип ант итмәдегезме?

**45.** —*(Сездән элек яшәп, үзләре башына үзләре бәла чакырганнарның)* йортларына урнашыгыз. Аларны нәрсә эшләткәнебез турында сез яхшы беләсез. Бу турыда Без сезгә гыйбрәтле мисаллар белән хәбәр иттек.

**46.** Алар мәкерле хәйлә корды. Хәйләле тозаклары, хәтта тауларны күчереп йөртер кодрәткә ия булса да, бөтен хәйләләр дә Аллаһ хозурында.

**47.** Шулай булгач, Аллаһ пәйгамбәрләренә биргән сүзендә тормый, дип уйлый күрмәгез тагын. Аллаһ мотлак өстендер, кылынган яманлыклар онытылмас *(бер генә гөнаһ та җәзасыз калмас)*.

**48.** Җир башка җиргә, күкләр башка күкләргә алмаштырылган Көндә *(Ахирәттә)* бәндәләр башка бер генә затның да көче җитә алмас кодрәтле Аллаһның хозурына китерелеп бастырылыр. *(Бөтен гаделсезләргә-залимнәргә җәза бирелә торган Көн шул булыр.)*

**49.** Ул Көн гөнаһлыларның муенына чылбыр асылган Көн икәнен күрерсең. **(50)** Алар кигән киемнәр сумаладан булыр, йөзләрен ут алган булыр. **(51)** Кылган гөнаһларының бәһасен түләр өчен, Аллаһ *(аларны Ахирәттә терелтер)*. Һичшиксез, Аллаһ исәп-хисапны кичектермәс.

**52.** Бу *(Коръән)*—Аллаһның бердәнбер Аллаһ икәнен белсеннәр өчен вә зиһенле кешеләр уйлап-аңлап, үгет алсыннар дип, кешеләргә индерелгән белем Китабы.

صَدَقَ اللّٰهُ الْعَظِيمُ

# МОҢ ХИКМӘТЕ

Моң... Бәгырьләрне чеметтереп ала торган, әрнетә-сыкрата, гамь индерә торган моң. Татар моңы... Ул безнең күңелләргә шулкадәрле дә якын, шулкадәрле дә тәэсирле ки, җир йөзендәге һәммә җан иясе, бар дөньясы сихри моңнан мөлдерәмә тулы бу вөҗүдең, бу халәтең белән бербөтенне тәшкил итә сыман.

Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә моң төшенчәсенә берничә төрле аңлатма бирелгән: кайгы, хәсрәт, борчу; йөрәк хисе, тирән хис; көй; хисләр җыелмасы; ниндидер эчке сагыш катнаш моңсулык... Әмма дә моңны сүз белән генә аңлатып була микән аны?! Аңлар өчен исә татар булып туып кирәктер, «Гөлҗамал»ны, «Кара урман»ны, әнкәннең бишек җырларын ишетеп үсүен кирәктер. Һәм ни сөенеч, шул моңың түкми-чәчми халыкка җиткерә белүче җырчыларыбыз бар.

Танылган җырчыбыз Миңгол Галиев хакында Гариф Ахунов: «Әйбәт җырчы Миңгол, талантлы җырчы, халык күңелендә яткан хәзинәләрне үзенчә, янача яңгыратып, халыкның үзенә кайтарып биргән җырчы!»—дигән иде. «Миңгол» исемендә дә «моң» ята икән бит, әй—исемдә дә хикмәт бар! Чын мәгънәсендә моң иясе булган җырчы, Татарстанның халык артисты, Казан дәүләт педагогика университеты мөгаллиме **Миңгол Галиев** белән әңгәмәбез дә моң, моң хикмәте хакында.

*1988 елда, әфган җирендә, реактив снарядлар канонадасы астында Хәмдүнә Тимергалиеваның «Чияле тау»ны җырлавын тыңлаган идек. Госпитальдә шәфкать туташы булып хезмәт итүче татар кызы биргән кассета иде ул. Тетрәндергеч татар моңын мин әнә шул чакта—читтә—бар вөҗүдем белән беренче кат тойдым бугай. Әфганстанда рота командиры булган Вәликам Әхмәдуллин исә (ул әдәбият галиме Азат Әхмәдуллинның туганнан-туган энесе) миңа моңлыйрак вакыйга сөйләгән иде: «Таң алдыннан үзәкләрне өзгеч җыр тавышына уянып киттем. Валлаһи, Илһам Шакиров җырлый дип торам. Баксаң, ерактагы манарадан азан әйтәләр икән».*

**М. Г.:** Әйе, җырның тәэсир итү көче гаҗәеп зур аның. Әйтеп бетергесез. Борынгы мифтагы Орфей үзенең сазына (кифарасына) кагылып, җырлап җибәрүгә, кешеләр генә түгел, хәтта бар тереклек, җан иясе, табигать тынып калган. Ул барган вакытта ерткыч җанварларга кадәр сабырланып, тыңлап, салмак кына ана ияргәннәр. Ничек әле «Рамай» җырында?—«Чишмәләр дә акмый тыңлады...»—ди бит.

Корьәнне алыйк. Аның илаһи авазын көйләп укыганда бар рухың белән Аллаһы Тәгаләгә инанасың. Югыйсә, без гарәпчәне дә белмибез бит инде. Әмма уйландыра. Инандыра! Тәэсир итә!

*Кеше тавышын сулыш юллары, бугаз, тел, аңкау, теш һәм тел оркестры кушылмасы дип тә атап була торгандыр. Тавышның фонетик төзелеше, нигезлә, бер үк төрле. Әмма һәркемнең үзенә генә хас аһәңе дә бар бит әле. Күптән түгел генә япон галимнәре, яңа туган балаларны тикшереп, шундый нәтиҗәгә килгәннәр: аваз генетика кодларына бәйле, һәм ул, кул-бармак эзе кебек үк, кабатланмас үзенчәлеккә ия икән. Хәзер инде японнар бу хикмәтне авыруларны дәвалаганда файдаланмакчы булалар.*

**М. Г.:** Соң, үзең уйлап кара: тумыштан чукрак-телсезләр дә башта—тугач та аваз сала, җылап җибәрә. Аваз интонациясенә карап әнисе аның халәтен, кәефен чамалый. «Иң әүвәл сүз булган»—диләр. Иң беренчел—аваз!

Чит илләрдә хәзер җырга зур әһәмият бирәләр. Японнарны әйттек инде. Алманиядә, мәсәлән, «Canto del mondo» фонды бар. Ул Алман музыка Советы карары белән оештырылган.

*Яһүдләр оештыргандыр инде...*

**М. Г.:** Каян белдең? (көлә) Лорд Ехуди Менухин патронажлыгы астында Башта Мюнстер университеты галимнәре 1000 студент арасында тикшеренүләр уздырганнар һәм кызыклы нәтиҗәләргә килгәннәр. Җырлаучыларны—«моңлы», җырламаучыларны—«моңсыз» дип алсак, моңлы кешенең яшәү куәте бермә-бер зур, ул физик һәм психологик кыенлыкларны җиңел кичерә икән. Социаль һәм иҗтимагый мәсьәләләрдә бик актив, ярдәмчел... «Моңлы»лар «моңсыз»ларга караганда бик күпкә сәламәтрәк тә икән. Галимнәр шундый нәтиҗә ясаганнар: адәм баласы көненә ин кимендә 20 минут җырларга тиеш!

*Сәламәтлеккә файдалы дип кенә, җырлый белмәсән дә җырларга микәнни?*

**М. Г.:** Беркем дә: «файдасы тисен»—дип җырламый анысы. Әмма монда уйланырга нигез бар. Сәясәтчеләргә, югары даирәдәгеләргә дә! Бигрәк тә сәламәтлек саклау министрлыгына!

*Чит ил галимнәренең бу гамәлләре аңлашыла да. Чөнки Европа бүген тирән рухи кризис кичерә. Ә безгә—татарларга—нигә борчылырга әле? Безнең үз Моңыбыз бар. Моңлы халкыбыз бар. Кем әйтмешли, ике кешенең берсе—җырчы...*

**М. Г.:** Америка, Европа дигәннән, аның безгә тискәре тәэсире дә көчле бит. Һәртөрле шоулар (татар аны «шау-шу» ди), «шайтан туйлары» безнең сәхнәгә дә мендe. Кино-фәләннәре телевизорга кереп утырды. Адәм баласы аңлап-аңлатып бетерә алмаган наз хисе бар. Менә шуны пычрак итеп күрсәтүләре—халык өчен фаҗига! Югары интеллектлы кеше аны карамый да анысы. Ул аннан өстен!

Ике кешенең берсе җырчы, дигәннән, Марат энем, чын мәгънәсендәге җырчыларыбыз бик аз безнең, бик аз.

*Алайса: ике кешенең берсе—Моңлы... Һәрхәлдә, моңысы белән, Миңгол абый, килешәсездер. Яһүдләр—бердәм халык, тау халкы—кызу канлы, дуамал, алманнар—төгәл, пунктуаль дигән күк, безнең билгеләмә барыбер «Моңлы татар» дигәнгә туры киләдер сыман.*

**М. Г.:** Моңны тыңлап-ишетеп, сендереп, аңлап була. Әмма аңлатып булмый. Хәтта «Моң» төшенчәсен башка телләргә тәрҗемә дә итә торган түгел. Әйе, ул—фәкать безнеке! Һәр авазның эчтәлеге бар бит. Ягымлы авазлар бар. «Ә»-«ө»- «ү» ләр урыс телендә юк. Татар теленең сөйләмендә үк Моң ята. Моң—бөек хис. Аңсыз Тукай—Тукай, Җәлил—Җәлил, Туфан—Туфан булмас иде. Карале, кызык бит: әсир сүзенең ике мәгънәсе бар икән. Сугышта әсир төшү... Аның моңы әсир итте, дибез. Икесенә ике төрле зур, гаҗәеп зур, капма-каршы мәгънә салынган икән ләбаса.

*Татарның, гомумән, төп мәдәни җәүһәрләре Моңга нигезләнгән. Әдәбиятта, рәсемдә, сынлы сәнгатьтә... Бүген исә без җыр Моңы турында сөйләшәбез. Моң әсирлегенең янә бер мәгънәсе бар: әрнү, ачыргалану, һаман дөньядан зарлану, мескенлек, бетәшкәнлек... Татар моңының асылы шул түгелме соң? Нәкъ менә шул моң әсирлегендә булуыбыз дөнья күләмендә алга киткән милләтләр белән тиң яшәргә комачаулый кебек.*

**М. Г.:** Татар моңының, миңа калса, төп асылы—дәүләтен югалту ачысы. Инде килеп, шул Моңыбызны да югалтсак...

*Америкада ак тәнлеләр белән бертигез хокуклар таләп итүче кара тәнлеләргә мондый тәкъдим ясаганнар: «Әйдәгез, сезнең бөтен бөек җырчыларыгызның акчасын-байлыгын җыеп алабыз да, сезгә тигез итеп таратабыз, тик бер шарт белән: аларның җырын тыңламаячаксыз».—дигәннәр. Кара тәнле халыкның 98 проценты моңа каршы чыккан. «Икмәк булса, җыр да була» дигән гыйбарәне үзгәртеп, «икмәк югында да җыр булган» дисән дә ярыйдыр.*

**М. Г.:** Мин—ятимлекнең дә, черек бәрәңгенең дә тәмен татып үскән буын вәкиле. Безнең халык ин авыр сугыш елларында да Моңнан өзелмәде. Ул, киресенчә, тирәнәйде генә. Адәм баласы күтәрә алмастай авырлыкларны җиңәргә булышты ул. Шуңа күрә дә: «Моң, җыр барында икмәк тә булыр!»—диясем килә. Янә шунысы хак:

Моң—халкыбызның иммунитетына, ягъни чиргә каршы тору сәләтенә әверелгән. Ә чирләребез бик күп безнең. Әйтеп бетергесез күп.

*Туфан ага Миңнуллин әйтмешли, «чын татарның паспортына «татар» дип язмасаң да, аның татарлыгы ярылып ята».*

**М. Г.:** Моңда ул—татарлык! Күңелебездә! Чынлап та, паспортта татар итеп язылмый икән, ана әлләни кайгырмаска да кирәктер. Әнә, яһүд—кайда да яһүд!

*Ә безгә, якут булып ишетелә... Бишенче графаны да яһүдләр бетерергә тырышты ләбаса. Әмма без, Миңгол ага, яһүд түгел бит. Аерма зур.*

**М. Г.:** Яһүдләр балаларын кечкенәдән үк: «Син—әйбәт, син—сәләтле, син—бөек!»—дип үстерәләр. Ә татар баласына: «Әй, ангырабаш, сиңа көтү көтәргә кирәк!»—дип тукый. Аерма шунда гына. Сабый күңеле—буш савыт шикелле бит ул. Нәрсә туры килә, шуның белән туламы ул? Ничек тутырасың инде... Менә бит хикмәт нидә!

*Затлы итальян, испан җырлары бар. Төрекнең дәртле-ярсу көйләре бар. Шулай шул, Сез әйтмешли, аларның дәүләтләре дә бар... Тау халкы түшен киереп, кулларын ике якка җәеп җибәреп, бөркет кебек бии, татар исә тавык шикелле җиргә иелеп, билен бөгеп тыпырдый. Коллык психологиясенең бер чагылышы бу. Миңгол ага, Сез моңнан берничә ел элек милли хәрәкәтнең үзәгендә кайнадыгыз. Сезнең җырларыгыз һәм Вафирә Гыйззәтуллина башкарган «Ком бураны»ннан гайре халыкны күтәрә, ушта торган җырларыбыз да юк бит безнең. Милли күтәрелеш чорында Моңны файдалана алмадык, «сагындым әнкәемне, сагындым авылымны», «миләшләрем—баланнарым»нан ерак китә алмадык... Ә Кояш—җир йөзендәге фәлән миллиард кеше өчен—бер генә. Һәр адәм баласы, һәр милләт әнә шул кояш астындагы бәхет өчен көрәшә. Анда мескенн әргә урын юк!*

*Заманында Хәйдәр Бигичев, сыкранып: «Моң дигән төшенчәне инде газаплап, көчләп бетерделәр. Моң, мескен, кая кунарга белмичә, «кем моңлы сон?!» дип чын иңсен эзләп йөри. Шулай аптырап йөргәндә, Моңны тагын кемдер эләктереп ала...»—дигән иде. Миңгол ага, Сез 40 елга якын балаларга, яшьләргә музыкаль белем бирү, җыр-вокал гыйлеменә өйрәтү юнәлешендә эшлисез. Юнәлеш, өлкә, тармак, димме... Һәрхәлдә, ничек кенә әйтсәң дә, шунысы хак: Миңгол Галиев—бүгенге көндә татарның нәтиҗәле эшләүче бердәнбер Моң педагогы. Шәкертләрегез Луис Шиһапов, Рөстәм Закиров, Рәсим Низамов, Айдар Галимов, янә башкалар—бүгенге татар җыр сәнгатендә әйдәп баралар. Сезнең кулга, игътибарга эләгү һөнәрмәнд җырчы булырга теләүчеләр өчен абруй санала. Татар җырчысы—остаз! Бик сирәк очрый торган күренеш бу...*



*Миңгол Галиев әнисе Миңсылу белән. 1961 ел.*

**М. Г.:** Безнең авылда (Мамадыш районының Иске Комазан авылында) үзәкләрне өзеп җырлый торган Миннәхмәт абый бар иде. Гаҗәеп моңлы, гөрләп торган тавышлы, Илһам Шакировнылыкдай ягымлы күкрәк тавышы иде анда. Иртәнге якта, таң алдыннан кызлар озатып кайтучы Миннәхмәт абый җырлап җибәрә! «И, шушы Миннәхмәтнең тавышы, моңы!»—дип, әни-апаларның сокланып сөйләгәне әле дә хәтеремдә. Менә шушы егет авылда үз урынын тапмады. Читкә китте—тапмады. Үз-үзен табалмады. Күңеле тулы илаһи бер Моң иде аның. Үз вакытында юнәлеш бирүчесе, остазы булса, кем белә, татарның бөек җырчысы да булган булыр иде ул...

Минем беренче остазым Фәхри Насретдинов иде. Ул миндәге табигыйлекне, тавышымны саклап калды. Әмма аның педагогик сәләтен анламадылар, консерваториядә озак эшләргә ирек бирмәделәр. Хискә түгел, техникага гына аерым игътибар юнәлтү заманы иде шул. Бу исә тавышка зур зыян китерә. Минем дә үземне

кая куярга белми йөргән чакларым булды. Остаз юк. Нишләргә? Күнел өзгәләнә. Җырлыйсы килә—җырлап булмый. Бер ел буена укыйм дип ыштан туздырып йөр дә, кире авылга кайтып кит, имеш. Яшем житкән иде, тоттым да, гариза биреп армиягә киттем. 3 ел авиация гаскәрләрендә хезмәт итеп кайткач, янә консерваториядә укый башладым...

* * *

**Белешмә өчен:** Ихтыяр көчен ныгытып, дөнья күреп кайткан егет һич икеләнүсез җырчылыкка укуын дәвам итә. Көндез—укуда, ә кич белән балаларга карусель әйләндерә, төнлә каравылчы булып эшли. Халык театрында уйнарга да өлгерә. 4 нче курста аны хор житәкчесе итеп билгелиләр. «Кеше хәлен кеше белми, үз башына төшмәсә»- ди халык. Зур сәхнәгә тәүге мәртәбә аяк басканда кичергән кыенлыкларын Мингол Галиев та онытмый. Ул яшь җырчыларга юл күрсәтә, ярдәм итә башлый. Бүгенге татар җыр сәнгатендә үз урыннарын тапкан Фердинант Сәлахов белән Венера Ганиеваның тәүге остазы да ул була. 1977 елда Мингол Галиев КДПУның музыка-педагогика факультетында эшли башлый. Музыка укытучысы һөнәрен сайлаган егет-кызлар арасында бик тә монлы, җырга гашыйк, җырсыз яши алмый торганнары да була. Остаз аларның табигый тавышын ачарга, саклап калырга, дөрес якка юнәлтергә тырыша. Әмма факультетта: «Без җырчылар әзерләмибез!»—дип каршы төшүчеләр дә очрый. «Таланты бар икән—җырласын, җырчы булсын, тыймаска кирәк!»—ди аларга остаз. Тора-бара игелекле хезмәтнең матур нәтиҗәләре дә пәйда була: 1989 елда Луис Шиһапов «Татар җыры» конкурсында дипломант, 1991 елда Рөстәм Закиров дипломант исемен, ә 1995 елда «Гран-При» яулый, Закир Шаһбан профессионаллар арасында беренче урынны ала. Пединститут студентлары алга таба да сынатмый. 1997 елда шул ук конкурста 3 нче курс студенты Рәсим Низамов җинеп чыга.

* * *

*Мингол ага, шәкертләрегезнең дәрәҗәле җыр конкурсларында җиңү яулавы бу хезмәтнең никадәр житди булуын да күрсәтә бит.*

**М. Г.:** Мин—аларга, алар миңа ярдәм итте. Үз методикамны исбатладым. Теория китаплары авторлары—алар бары тик теоретиклар гына бит.

*Әдәбият галиме, яки тәнкыйтьчесе үзе әдәби әсәр язмаган кебек...*

**М. Г.:** Җыр сәнгате теоретиклары әзер практика аша, кеше хезмәтен өйрәнеп, шуңа анализ ясап нәтиҗә чыгара. Үз кичерешләрең, үз тәҗрибәң—кыйммәтлерәк.

Безнең һәркайсыбызда Моң бар. Тик аның ачылу сәләте генә төрле югарылыкта. Бер елны Фасил Әхмәт белән Казандагы 67 нче ярдәмче мәктәпкә очрашуга барган идек. Тел сөйләме артта калган бу балалар белән аралашкач, шуны аңладык: чукрак-телсезләрне дә җырларга өйрәтеп була икән ләбаса!

*Бар шундый җырчылар: таланты чамалы, ә үзе сәхнәгә омтыла...*

**М. Г.:** Моңга тартыла икән, ярдәм итәргә кирәк аңа. Әйе, сәхнәгә яшь җырчы чыга. Матур киенгән. Кыяфәтле. Халык—мөкиббән. Җырлый башлый бу. Тамашачы шакката, әсәрләнә: «карале, бу җырлый да икән бит әле!»—ди. Соклана, кул чаба! Яшь җырчы да: «шәп җырлыйм икән»,—дип сөенә. Әмма ул ялгыша. Халык әле өмет баглап кына, аванс белән генә алкышлады аны. Әгәр дә яшь җырчы борының чөймичә генә, шул өметне акларга тырышса, үзен камилләштерә барса—бер хәл әле... Кыскасы, халык—аны, ул халыкны тәрбияли. Күп миллионлы татарга көн саен яңа бер җырчы туып, сәхнәгә менеп торса да ярар иде. Күпсенмик, җәмәгать! Җыр сәнгатенә мәхәббәте бар икән—аны сәхнәдән куып төшерергә кирәкми. Җырласын, өйрәнсен. Талантлылар, моңлылар күп, ә сәхнәгә фидакарьләрчә хезмәт итәргә омтылып торучылары аз.

* * *

«Ни өчен безнең милләт Әрнү, Зарлану, Ялвару кебек хис-тойгылар культы белән нык авырый? Чөнки татарларга, халык буларак, коточкыч авыр язмыш

бирелгән... Газап, жәфа, кайгы, хәсрәт, сагыш—болар барысы да Мон тудыру шартлары. Татар тормышындагы бик күп нәрсә үзеннән-үзе Монга этәрә. Ә шулай да нәрсә соң ул Мон, Монлану? Ерактан килеп кинәт сүз башлау, хис-тойгы-аффектлар жыелмасынын музыка-көйдә, шигырь-көйдә, проза-көйдә үзенчәлекле алмашынып торуы: монда Әрнү, Өметләнү, Юану, Зарлану, Сыкрау, Шатлану гел алышынып тора һәм кеше эчендәге «Илаһи Мин»нен ихлас телен, анын ишетелергә, аңлашылырга һәм юатылырга теләвен тудыралар...

Хәер, Монны төрле яклап аңлатып була. Мәсәлән:

—Күнелгә жыелган авырлыклар, кыенлыклар турында көй аша сөйләп ахыргача бушану...

—Жанны чистарту һәм дәвалау...

—Дошманына үзеннен илаһи әһәмиятен турында хәбәр житкерү...

... Татарлык тышкы дөньяга омтылышында, үсәргә теләвендә кинәт кире кагыла һәм Монга кача... Татарлык—ярымдекаданс чынбарлыгы, анын бу дөньядагы яшәеше яртылаш барып чыкмаган. Чөнки шушы дөньядагы кайбер чынбарлыклар Татарлыкка карата артык тискәре мөнәсәбәттә булып, анын үсеш вә яшәешен чикләгәннәр... Һәм ул Мон аша яхшылыкка, бер-беренне аңларга чакыра. Бу чакыру ачык сүз—текст аша түгел, ә бәлки жан тибрәлешләренә корылган Монлылык аша алып барыла...

Моннын ин олы мәгънәсе шунда: ул кешенен фани дөньядан үзенчәлекле зарланып Илаһига омтылуын һәм Ана сыгынуын аңлата... Мон—ул «яхшырак, сафрак, матуррак дөньяларга», димәк, Ахирәткә ымсыну... бу—Моннын илаһи мәгънәсе.

Әйе, татар декадентлыгы бер яктан татарнын бетәшкәнлеген аңлата, әмма икенче яктан нәкъ менә декаданс Татарлыкнын эчтәлеген кешелеклелеккә, сафлыкка алыштырган. Һәм мондый алышыну татарлар өчен искиткеч югары мәгънәгә ия. Яхшылыкка кайту белән татарлар өр-яңадан Алланын мәрхәмәтен, миһербанын яулап ала алалар... Без, бу сүзләргә дәлил буларак, Коръәнне искә төшерик:

*«Аларга бу газап шул сәбәплеләр. Аллаһ кавемгә биргән нигъмәтен ул кавем үзен үзгәрткәнгә чаклы үзгәртми. Ягъни кавем начарлыкны ташлап яхшылыкка үзе теләп чыкмаса, Аллаһ, әлбәттә, көчләп чыгармый, вә кавем яхшылыкны ташлап яманлыкка чыкмаса, әлбәттә, Аллаһ көчләп чыгармый.» (Коръән, «Әнфәл» сүрәсе—75 аять, 53).*

Бер нәрсә ачык кебек: Алла татар халкына биш йөз елга якын тоташ авырлыклар, кайгы-хәсрәт жибәреп аны сынаган, һәм анын яхшырак, сафрак булуын да теләгән. Һәм, без, бүгенге татарлар, шундый зур корбаннар бәрабәренә табылган игелекне, сафлыкны, кешелеклелекне югалтмыйча саклап калырга тиешбез.

Шуна күрә, үзенен кешелеклелеге белән, Илаһига омтылучы һәм Ана сыгынучы Моны белән татар декадансы илаһи кыйммәткә ия гүзәл чынбарлык булып күз алдына килеп баса.»

Илшат ВӘЛИУЛЛА,
*«Татар декадансы»*

* * *

*Мингол абый, сезнен репертуарда 800 дән артык бәет-мөнәжәт, борынгы, хәзерге халык жырлары бар. Соравым шул: замана шаукымы—япон тактасына (синтезаторга) мөнәсәбәтегез ничек?*

**М. Г.:** Мон—инструмент—кеше тавышы бер-берсенә нык бәйләнгән. Уен кораллары кеше авазына никадәрле якын тәнгәлләшә—шулай яхшы. Фән-техника казанышы шулкадәрле нык үсте хәзер—электр тогын эшкә жигеп, ниләр генә кыйландырмыйлар! Татар жырларын мин джаз оркестры белән дә бик яратып башкарам. Әле менә музыка факультетына гитара кертергә тырышам. Яналыктан курыкмаска кирәк. Хәер, гитара—борынгы уен коралы. Төрки халыкныкы, Аттила заманнарында ук булган ул.

*Менә сина яналык!*

**М. Г.:** Теллә дә хикмәт бар. Жырны кайсы теллә башкарасын—ул жыр шул милләтнен жырына әверелә. Асаф Вәлиев удмурт композиторы язган «Их, сез матур кызлар»ны башкара. Бу жыр удмуртларнын үзләрендә бездәгедәй популяр түгел.

*Яшь, башлап жырлаучылар хәзер кемгәдер охшатып жырлыйлар, кемнедер кабатларга тырышалар сыман.*

**М. Г.:** Бу жәһәттән исемле, абруйлы жырчы үз өстенә зур жаваплылык ала. Охшатып жырлау—кеше күнеленә, хискә бәйле гамәл. Кемнедер Салаватның, йә Зәйнәпнең, йә Айдарның моны җәлеп итә һәм ул аны, үзе дә сизмәстән, кабатлый башлый. Йә булмаса, ул Илһам Шакиров тавышы белән жырлый. Бу—кеше организмының гажәеп сәләте. Мин аны үз практикамда—укыту методикасында кулланам. Минем өчен иң мөһиме—яшь жырчыда матур аваз, ягымлы аһәң табу, шуны көйләү.



Сәхнәдәшләр һәм остазлар арасында.
Сулдан уңга (алгы рәттә):
Сара Садыйкова, Мөнир Якупов, Фәхри Насретдинов;
арткы рәттә:
Миңгол Галиев, Зөһрә Сәхәбиева, Әхмәт Кәримов.

*Бүгенге көндә татар сәхнәсен тотучы популяр шәкертләрегезнең киләчәген алга таба ничек күзаллыйсыз?*

**М. Г.:** Минем дәресләр, юнәлеш бирүләр, кинәшөйрәтүләр—олы юлның башы гына бит ул. Вазифам—олы юлга (сәхнәгә) житәкләп чыгару. Рәсим Низамов бик өметле егет. Киләчәге матур булырга ошаган—үсәчәк. Айдар Галимов элегрәк тенор кебек жиңелчә тавыш белән генә жырласа, хәзер инде көр итеп, төпле баритонга күчә бара. Аның тавышында драматизм башлана һәм ул ягымлылык белән дәвам итәчәк. Кайчандыр Айдар: «Миңгол абый, тора-бара Айдар булуымны югалтмаммы?»—дип борчылган иде. «Нәкъ шул турыда уйлыйм да инде мин»—дидем. Жырчы шәп жырласа, аны мактыйлар, начар икән—укытучыны яманлыйлар.

* * *

Башкортстанның һәм Татарстанның атказанган артисты, жырчы Айдар ГАЛИМОВ:

«Армиядән кайткан гына чагым. Башкортстанда Татарстан көннәре гөрли. Туган авылым Олы Кәркәләгә дә татар сәнгате эшлеклеләреннән зур делегациясе килде. Анда Миңгол Галиев та бар иде. Авыл халкы татарстанлыларны шатланып каршы алды. Миңгол Галиевнең жырлавын бик тә ошаттылар. Бу очрашуда мин дә жырладым. Миңгол абый шунда мина игътибар иткән икән, сөйләшеп, танышып, дуслашып ук киттек. Мин аны автобуста Миякәгә озата бардым. Шунда ул мина: «Айдар, син сәнгать юлыннан китсән, әйбәт булыр иде. Сине зур сәхнәдә күрәсем килә»—диде. Бу сүзләр күңелемә уелып калды һәм алар, сәхнәгә чыккан саен, хәтеремдә янаралар. Миңгол абый белән без әле дә дуслар. Очрашып торабыз. Анардан музыка буенча дәресләр алуымны дәвам итәм. Миңгол абый—беренче кинәшчем дә, олы юлга фатиха биреп озатучым да. Безнең очрашуыбыз тәкъдирдән булгандыр, дип уйлыйм».

* * *

*Мәктәп һәм җыр... Мингол абый, Сез заманында, Казанның 6 нчы мәктәбендә башлангыч сыйныфларда музыка дәресләре алып барган кеше. 7-8 яшьлек сабыйларга танылган җырчы үзе килеп сабак бирә! Радиф Гаташ мәктәптә «Әлифба», яисә татар теле һәм әдәбияты укыткан кебек бит инде бу.*

**М. Г.:** Балаларга нота өйрәтә башлагач, башта анламый тордылар. Музыка әлифбасының нигезе бик гади—нотада нибары җиде генә хәреф югыйсә. Әмма нота грамотасын белми торып, музыка хакында сөйләшү мөмкин түгел. Музыка дәресләре музыкаль тәрбия дәресләренә әверелсен иде. Татарстанда укыту системасын үзгәртү зарур. Алгебра белән музыка бер югарылыкта торырга тиеш минемчә. Музыкаль белеме, зәвыгы булмаган сәләтле яшьләр, дөрес тәрбия алмаганда, җанны рухи бушлыкка әйдәүче шау-шулы арзан музыка колларына әверeләчәк. Моң, җыр, музыка—рухи тәрбия бирү буенча иң көчле, иң тәэсирле чара. Дингә караганда да көчлерәк! Чөнки динне әле аңлату, сеңдерү зарур. Ә буылып яткан Моңны ачып җибәрергә генә кирәк. Чишмә өстендәге ташны алып ыргыткан кебек.

Музыкаль тәрбия мәсьәләләре хакында җитди югарылыкта фикер алышу, карарлар кылу дәвере җитте. Һәр авылда ничә телевизор, ничә машина барлыгын санап мактану заманы үтеп бара. Чит илләрдә яшәүче татарлар да Казаныбызны изге мәркәзләре итеп күрәләр икән, чын мәгънәсендә горурланырлык мәркәз булсын иде ул. Моңлы Казан булсын иде!

* * *

...Сәхнәдә—Мингол Галиев һәм аның шәкертләре. Алты яшьтән алып егерме яшькә кадәргеләр, боларның әле зур сәхнәдә тәүге адымнары гына. «Ил яшәве—моң белән» дип аталган бу кичәне остазлары җыр белән ачып җибәрә:



*Остаз һәм аның шәкертләре*

*...Әнә, җүләр, җырлый диләр,*
*Әйтәләр бит үйла-мыйча...*

Мәгънәле сүзләр. Алар җырчының, Моң иясенең һөнәренә генә түгел, ә бик тә авыр, җаваплы миссия башкаруына да ишарәле ләбаса. Остаз исә шәкертләренә шушы рәвешле фатиха бирә сыман: олы юлга чыгасыз, балалар, үкенерлек булмасын, үсегез, камилләшегез, гел алга барыгыз!

Шәкертләре дә сынатмыйлар. «Татар җыры», «Казан сандугачы», «Ягымлы яз», «Студентлар язы» кебек абруйлы конкурсларда Гран-При алалар, лауреат һәм дипломант булалар. Болар инде «сагындым әниемне, сагындым авылымны»—дип кенә җырлаучы бетәшкән буын түгел, «Моңлы һәм горур татар» билгеләмәсенә тарта торган буын бу! Остазларының исә янә бер зур хыялы бар: ул башкалабызда «Моң» үзәген ачарга хыяллана. «И, Ходаем, мина изге эшләр эшләргә гомер-мөмкинлек бирче»—ди ул. «Изге эшләр эшләргә» диюе һич кенә дә пафослы, буш куык сүзләр түгел аның. Шәкертләре дә чыгыш ясаган әлеге кичәдә рәхмәт әйтергә дип, бу мәһабәт мәдәният йортының директоры да сәхнәгә менде. «Сез, Мингол—татарның бер тиен сорамыйча, бушка җырлаучы бердәнбер җырчысы. Андый фидакарь затка без дә бу сәхнәне, бу залны бушка бирәбез, аренда хакын сорау гонаһ булыр иде. Җырлагыз гына, җырлагыз!»—диде ул.

Җәйнең бу ямьле көннәрендә Мингол Галиев 60 яшен тутыра. Ил агасы яшендә дә ул яшьләрчә дәрт-дәрманлы, ул һаман—юлда, сәхнәдә, эштә-хәрәкәттә. Моң хикмәте бу, моң хикмәте!

*Әңгәмәдәш*—**Марат ЗАКИР**

# «ИСЕМСЕЗ» ОЛУГ ИСЕМ ИЯСЕ

*Алтын утта,*
*адәм михнәттә сыналыр.*

Татар халык мәкале.

«Юктан бернәрсә дә барлыкка килми», дигән борынгылар. Кешеләрнең дә асыл сыйфаты нәселдән, ата-бабадан, кыскасы, хәтсез «ерактан» килә. Һәркем үзенең килеш-килбәте белән дә, саулык-сәламәтлеге белән дә, берәр төрле һөнәр-кәсепкә маһирлыгы, тырышлыгы-уңганлыгы белән дә, күпмедер күләмдә, нәсел-нәсептән килгән үзенчәлекләрне кабатлый, үстерә, дәвам итә. Фән шулай дип раслый, ә тормыш моның шулай икәнлеген һәрдаим исбатлап тора.

Уем-сынчы Альфрет Әбдрәшитов тә, талантлы кешеләргә хас булганча, уңган булганлыкны, кул эшләренә маһирлыкны ата ягыннан ала, ә инде жыр-биюгә, гомумән, сәнгатькә мәхәббәтне мирас буларак ана ягыннан кабул итә; һәм ул искиткеч зур тырышлык белән әлеге сыйфатларны үзендә бергә куша һәм максатлы рәвештә үстереп жибәрә—нәтижәдә, алтын куллы уем-сынчы булып житлегә.

Альфрет Әбдрәшитов Казакъстанның Чимкент каласында 1940 елның 18 июлендә туа. Томскидан Казакъстанга сөрелгән «кулак» малае Хәйрулла белән колхозга кермәгән өчен генә Татарстанның Актаныш районыннан куылган икенче бер «кулак»ның кызы Галия, шул якларда танышып, гаилә корып жибәргән булалар...

Менә шундый «тамга» белән дөньяга килгән малай, 22 яше тулган көннәрдә Алматы сәнгать училищесын тәмамлый. Язмыш эше булгандыр инде, шулай тантанага киенеп-ясанып барган чагында булачак сынчы иләмсез калын (3-4 колачлык булгандыр) юл читендә аунап яткан карагачка юлыга. (Ихтимал, сыннарны нәкъ менә карагачтан уеп ясау нияте хыялый егетнең башына нәкъ әнә шул минутларда килгәндер.) Ничек итсә итә егет, училищега соңарса соңара, әмма үз дигәненә ирешә—күңеленә хуш килгән карагачны хужасыннан арзан гына бәягә сатып ала да «шундый зур байлыкны» өенә тарттырып кайтарта. Урманга сыяр, кырга сыймас, дигәндәй, иләмсез зур агачны кискәләгәч тә әле икешәр метр чамасындагы бүкәннәр килеп чыга; аларны урталай ярганнан соң һәркайсы «инозавр зурлыгындагы», төрлесе төрле кыяфәттәге өлгеләр хасил була. Менә кайда ул ижатка мәйдан, куәткә—дәрман! Һәм сынчы алны-ялны белми эшли дә эшли. Маңгай тирен түгеп, жансыз агачка жан өрә...

Дөньяның бер михнәте, бер рәхәте, дигәндәй, нәкъ әнә шул карагачтан уеп ясалган сын-сурәтләрне—«Ана» портретын Казакъстанның Дәүләт сәнгать музеена, «Көтүче» сурәтен исә Татарстан Республикасының Дәүләт сынлы сәнгать музеена кабул итәләр. Бу инде зур жиңү була.

Әлеге Көтүчене «Казакъстан чабаны» (1964) дип атамаган очракта да аның әллә каян казакъ кешесе икәнлеген танып булыр иде. Аның бөтен кыяфәтендә казакълыгы ярылып ята лабаса: колакчын бүрек кигән картның кинчәрәк битен жыерчык баскан; яңак сөякләре чыгыңкы һәм беркадәр тырпаешып торалар; әмма алар нурланып балкыган йөзендәге миһербанлы гармониягә һич тә хилафлык китерми; кайчандыр бөркетнеке кебек әллә кайдан күргән күзләрендә әле дә нур сакланган, ул сина сынап, туп-туры текәлгән... Шулчак Чабан карт жанлыдыр кебек тоела башлый: чал мыегы белән куе сакалы арасындагы әле дә булса яшәү дәрте сүнеп бетмәгән

иреннәре менә-менә ачылып китәр дә аннан моңлы бер көй булып акын жыруы агылып чыгар сыман...

Шундый зур иждди уңышлар уем-сынчыны, әлбәттә, жилкендерми калмый: ул үзен чит-ят жирләрдә адашып калган татар сынчысы дип сизә башлый һәм туган якларына ашкына. Кызганыч ки, 1965 елда Казан каласында аны берәү дә ачык йөз, якты чырай белән каршыламый.

Ләкин яшь һәм дәртле һөнәрмәнебез бирешергә уйламый да: ташландык хөжрәсендә иждди эзләнүләрен дәвам иттерә, хыялында киләчәкне ямьле итеп күз алдына китерә. Менә ул берзаман жыйнак кына гәүдәле, тыйнак кына кыз баланы очрата, ана гашыйк була, шуннан алар кавышып (ә ул кыз Луиза исемле була), бергә-бергә иждт дингезендә йөзәләр...

Шактый зур һөнәри күргәзмәләргә катнашып, уем-сынчы сыйфатында танылгач та, аны Рәссамнар берлегенә кабул итәргә ашыкмыйлар. Олуг талант иясе, аптырагач-йөдәгәч, үзенә теләктәшлек белдерүче Бакый ага Урманче белән Илдар Зариповтан юлламалар яздырып, Мәскәүгә—ул чакта СССР Рәссамчылар оешмасының житәкчеләреннән булган, әзәрбәйжанлы Таһир Сәләхевкә мөрәжәгать итә. Һөнәри берлеккә аны 1987 елда башкала оешмасында кабул итәләр...

Альфрет Әбдрәшитовның 40 ел дәвамында иждт иткән сыннары бихисап күп. Аның үз кулы белән корган остаханә-сендәге киштәләрдә төрлесе төрле зурлыктагы хезмәт жимешләре тезелеп киткән. Әйе, остаханәгә аяк басу белән, үзеңне әкият дөньясына килеп кергәндәй хис итәсең. Ә инде әлеге әкият каһарманнары белән якыннанрак танышкач, әлеге дәрвишнең әдәбиятка һәм сәнгатькә гашыйк икәнлегенә берниндн шиген калмый. Агачтан уеп ясалган «Күзге симфония» дә нәкъ шуны исбатлый.

Әдәбият әһелләреннән Альфрет Пушкин белән Тукайның сыннарын күптөрле вариантларда иждт итә. Бөек рус шагыйренең агачтан уелган сыны аеруча гайрәтле: аның кыяфәте дәртле, ашкынулы; башы тирәсендәге ореол урынына тырпаешкан кәкре-бөкре ботаклар исә шагыйрьнең шул заманда яшәп килгән рәсми әхлак-әдәп кагыйдәләренә дә, шулай ук шигърият кануннарына да бик үк сыеша алмаганын, үз өлкәсендә революционер иждт иясе булганын хәтерләтә, бик тәкәллефле аристократларга исә беркадәр кыргыйрак күренгәнлеген искә төшерә.

Аның белән чагыштырганда, безнең Тукаебыз күпкә гадирәк һәм тыйнаграк. Бронзадан коелган, биеклеге метрга якын булган вариантын гына алыйк. Шагыйрь әллә тәбәнәк рәшәткәгә, әллә болдыр култыксасына сөялгән, сул кулы рәшәткәгә ныклап ябышкан, уны исә рәшәткә өстендә иркен генә ята; ярыйсы ук озын аякларын чалыштырып баскан; гәүдәсе чандыр булса да, килешле генә; зыялы зат икәнлеге, әлбәттә, шагыйрьнең баш тотышында, йөз-кыяфәтендә—аларда ташып тора дәрт, иждди талпыну.



*XX йөз алиһәсе (бронза).*
*А. Әбдрәшитов эше*

Үзенең каһарманнарына сәнгатькәр һич тә бер үк төрле кыяфәт бирми, бәлки, һәркайсының төп сыйфатларына басым ясый, аның эчке байлыгын, рухи дөньясын мәңгеләштерә. Шушы уңайдан милли мәдәниятебезгә искиткеч зур өлеш керткән гали затларның сыннарына күз салыйк. Ш. Мәржани, әлбәттә, иң әүвәл—имам: башында—чалма, өстендә—яшел чапан, бер кулында—дисбе, икенчесендә—китап; кыяфәтендә аның олуг акыл иясе, философ, әдип икәнлеге ярылып ята. Сәйдәшнең агачтан уеп ясалган сынында исә фотоларында күреп

өйрәнгән мөлаем кыяфәт белән бергә даһи композиторның күзләрендәге моң тулы уйчанлыкны да, иҗади тәвәккәл омтылышны да чагылдыра алган. Мәгърур кыяфәтле Бакый ага Урманче сынында автор аның гаҗәеп киң колачлы шәхес, күпкырлы талант иясе икәнлеген тамашачыга якыннан күрсәтүне төп максат итеп куя. Әлеге өч гали затны сәнгатькяр ихлас яратып, илаһи талантлары алдында баш иеп, даһилыгын тамашачыга үз һөнәре алымнары белән төшендереп бирү максатын күздә тотып иҗат итә. Һәм син бу шәхесләрнең килеш-килбәтләре нәкъ шундый булганлыгына ышанасың, аларның һәркайсысын нәкъ менә сәнгатькяр сурәтләгәнчә кабул итәсең, ягъни сәнгати дөреслеккә тулаем инанасың.

Сәнгатькяр шулай ук мәшһүр Паганини, Фешин, Эрьзяларның да образларын үзе аңлаганча, үзенең күңел күзе күргәнчә гәүдәләндерә алган.

Альфрет Әбдрәшитов бүгенге әдәбиятыбыз һәм сәнгатебез казанышларыннан да яхшы ук хәбәрдар икән ләбаса. Ул иҗат иткән сыннарга карап без шуны аңышабыз. Музей дәрәҗәсендәге остаханәдә без әдәбиятның аксакаллары Гомәр ага Бәширов белән Әмирхан абый Еникинең (сәнгатькяр аларны, соңгы елларында очратып, мәңгеләштергән!) һәм алардан соң татар әдәбиятында «беренче скрипкәне» уйнаучы Туфан Миңнуллинның һәйбәт эшләнгән сыннарын күрәбез. Сәнгать Альфретка тагын да якынрак, шуңа күрә ул аның төрле жанрларында иҗат итүче һәм үз һөнәрендә әйдәп баручы осталарны сайлап алган, гаҗәеп зур маһирлык белән тасвирлап биргән. Монда сынлы сәнгать өлкәсендә мәшһүрлек казанган Илдар Зарипов, театр сәхнәсендә җилкенеп уйнаган Шәүкәт Биктимеров, операларда бәйге тоткан Хәйдәр Бигичев, әле бүген дә (сигезенче дистәсен ваклагач та!) эстраданы гөрләтүче Айрат Арслановларның сурәтләрен күреп сөенәбез.

Әлеге хезмәтләрендә уем-сынчы, әйе, камиллеккә ирешә. Анысы бәхәссез. Әмма шунда бер гаҗәеп хәлгә юлыгасың һәм ирексездән елмаеп куясың: «Йә Хода! Сәнгатькярнең тагын да матуррак, тагын да камилрәк эшләре бар икән ләбаса!» Болары аның әти-әнисе һәм хәләл җефетенең сыннары. Миңа калса, хикмәт менә нидә. Мәшһүр шәхесләрнең сыннарын ясар алдыннан уем-сынчы аларның иҗатын яхшылап өйрәнә, исәннәрен остаханәсенә дәшеп китерә дә әңгәмә корып җибәрә, чөнки берәүнең дә тышкы кыяфәтен генә төп-төгәл китереп чыгару белән чикләнми, һөнәрмән буларак андый «уңышны» үзе өчен хурлык саный. Чын иҗат кешесе буларак, ул һәркемнең эчке дөньясын, рухи байлыгын ачып бирергә омтыла. Аралашу, әңгәмәләр нәтиҗәсендә ул моңа ирешә дә. Тик инде газиз әти-әниеңнең һәм сөекле хатыныңның эчке дөньясын ачу бу инде сәнгатькяргә бетмәс-төкәнмәс мөмкинлекләр бирә. Монысына минем иманым камил. Чөнки белөм дигән чит-ят кешеңнең дә синнән яшертен серләре булуы бик табигый. Ә инде сине дөньяга китергән, йөрәкләрен урталай ярып бирергә әзер торган газиз әнкәң белән әткәңне, янә дә үзеңә кыз бала чагында ук гашыйк булган, сиңа охшаган ике малай бүләк иткән, аларның саулыгы өчен бергә-бергә ут йотып йөргән, гомумән, синең иҗатыңа бөтен барлыгын багышлаган асыл затны синнән дә шәбрәк һичберкемнең белүе мөмкин түгел. Менә кайда яхшыдан-яхшы, камилдән-камил әсәрләр килеп чыгуның сере!

Әйтик, Ана образының гүзәллегенә сокланмый мөмкин түгел. Аңарга сәгатьләр буе карап торырга мөмкин. Бу сурәттә, иң әүвәл, безнең әниләребездә генә булган, аларга исә үткән гасырлардан күчеп килгән, димәк ки, буыннан-буынга мирас буларак бирелгән пөхтәлек, мөлаемлык, тыйнаклык вә затлылык бөркелеп тора. Яулык кырыеннан чак кына күренеп торган чал чәчләре Октябрь инкыйлабы елында туган асыл затның башыннан кайгы-хәсрәтнең бик күп үткәнлеге, михнәтләрнең өсте-өстенә ябырылганлыгы, әмма ананың чыдам булганлыгы, рухын һич тә сындырмыйча саклый алганлыгы хакында сөйли. Беркемнән дә курыкмыйча, туры караган күзләре гомер буе үткенлек вә кыюлык белән эш иткәнен, шундый шартларда да намуслы булып калганын раслый. Шунысы кызык, сәнгатькяр үз әнисенең образын гәүдәләндергәндә, әллә белеп, әллә инде ирексездән, Актаныш—Минзәлә яклары хатын-кызлары типажын китереп чыгара. Бу хәл автор

файдасына сөйли, әсәрнең камиллегенә «су коя».

Луиза ханымга сәнгатькяр ике эшен багышлый һәм икесен дә кече улы Гадел ярдәмендә очлап чыга. Әлеге эшләрнең берсе йомшак материалдан (мастикадан) әвәләнгән. Зифа буйлы, чибәр ханымның өстендә затлы күлмәк; сул кулын ул күкрәге турысында йомарлаган—гүя, бөтен әрнүләрен дә шул йодрыгына төйнәгән; сулында чәчәк бәйләме—сөенеч һәм бүләкләрдән һич тә мәхрүм түгел икән уем-сынчы хатыны. Әмма аның фидакарьлеге, үз гаиләсендә «ана корт» икәнлеге, сөекле ире һәм уллары өчен җан атып гомер кичергәне йөз-кыяфәтендә аеруча нык чагыла.


*А. Әбдрәшитов остаханәсендә уллары Альберт һәм Гадел белән*

Сәнгатькярнең бөтен иҗатында йөзек кашы булырдае, ул әвәләгән, койган, чүкеп ясаган сыннар арасында иң камиле—хатынының күкрәк тиңентен ясалган сыны, бюстыдыр, мөгаен. Луиза ханымның бу сурәте бронзадан коелган. Борынгы мифларда сөйләнгәнчә, гүя, бу әүлиянең башы тирәсендә алтын кайма (ореол); озын матур чәчләре бөдрәләнеп ике иңбашына сибелгән; киң маңгайлы, төз-нәфис борынлы, мөлаем йөзендә җитдилек һәм кырыслык; күзләрендә намуслы караш, аларда, гүя, сабырлык белән бергә кирәксә—тәвәккәллек, кыюлык та чагыла; ниятләре изге икәнлеге, берәүгә дә әшәкелек кылырга җиенмавы аның ике учын бергә кушыруыннан да күренә: гүя бу «ана корт» бәла-казадан үзенең ирен, Чернобыль фаҗигасеннән газап чигүче улы Альберт белән төпчеге Гаделен генә түгел, бөтен-бөтен кешелек дөньясын йолып калырга әзер. Алиһәнең бу сынына бер күз салып кына китү мөмкин түгел, аңа караган саен карыйсы килә һәм шулчак авторның осталыгына кабат-кабат инанасың һәм сөенәсең. Сәнгатькяр бүтән берни эшләмәсә дә, ничәмә-ничә йөз әсәр иҗат итмәсә дә, сынлы сәнгатьнең алтын фондына шушындый камил вә гүзәл әсәр, тулы мәгънәсендә шедевр бүләк итүе белән генә дә олуг хөрмәткә лаек табылыр иде...

Тик гомере буе ат шикелле эшләгән, берсеннән-бере гүзәлрәк вә саллырак сәнгать әсәрләре иҗат иткән уем-сынчыга мактаулы исем бирергә атлыгып торучы түрә-җитәкчеләр күренми шикелле. Гәрчә, аның инде 50 еллык та, 60 еллык та юбилейлары узса да... Әйе, өлкәнәеп килүче сәнгатькярнең юбилейларда бирелә торган мактаулы исем-регалияләре юк бугай. Әмма берни белән дә алыштырып булмаслык олуг Исеме бар: ул—Сынчы!

**Кыям МИҢЛЕБАЕВ**

❧

Kitap küzətü
Китап күзәтү

# АМЕРИКАДА ТАТАР ӘДИБӘСЕ

Әле генә үтеп киткән егерменче гасыр безне тора-тора уйландыра. Һаман ныграк, җитдирәк уйландыра. Вакыт ягыннан инде төгәлләнгән әнә шул дәвернең чын асылын аңлыйсы, аның бары тик үзенә генә хас булган сыйфатларын, билгеләрен беләсе килә.




Минемчә һәм башка бик күп авторлар язып чыкканча, кешелек җәмгыятенең яшәешен тулаем күзаллаган чагында **тизләнеш, актив хәрәкәт, кискен үзгәрешләр** чоры булды шикелле әлеге егерменче гасыр. Кешелек акылы төрле тармакта ясаган зур-зур ачышлар да, социаль тетрәнүләр, революцияләр һәм сугышлар да, галәм киңлегенә чыгулар һәм матдәнең эченә һаман тирәнгәрәк үтеп керүләр дә—һәммәсе, һәммәсе дә истә тотыла болай дигәндә. Гомумән, бу гасырда яшәгән адәм баласының җыелма сурәте еш кына очракта мәктәптәге физика дәреслекләрендә күрсәтелә торган Броун хәрәкәте эчендәге бер бәләкәй нокта буларак күз алдына килә. Бертуктаусыз һәм бик кызу рәвештә арлы-бирле йөренә: ары сугыла-бире бәрелә торган бер бәләкәй кисәкчек сыманрак.

Ләкин, физика дәреслегендәге әлеге күренештән аермалы буларак, адәм баласында Җан, Йөрәк дигән хикмәти бер үзенчәлек бар шул! Һәм әлеге хикмәти хәл кеше башыннан, йөрәгеннән кичкәннәрне бик сизгер кардиограф шикелле ак кәгазьгә теркәтеп, төшереп бардыра.

Менә кадәр талантлы шагыйрә буларак танылган Нурия Измайлованың бүгенге Америка тормышыннан алып иҗат ителгән «Язылмаган хатлар» исемле китабын *(Татарстан китап нәшрияты, 2001 ел)* күңел әнә шулайрак каршылады.

Әйе, «татарлар һәм Америка» дигән темага уйлана китсәң уйланырлык нәрсәләр байтак икән. Әнә бит—соңгы елларда гына да милләтебезнең әллә ничә күренекле улы әлеге илгә китеп барган: галәмне яулау буенча иң зур галимнәрдән саналган белгеч, космик тикшеренүләр институтының элеккеге директоры Роальд Сәгъдиев дисенме, шахмат дөньясының зур талантлы Гата Камскиймы... һәм инде менә танылган химик Вил Мирзаянов белән бергә безнең шагыйрәбез Нурия Измайлова да...

Искә төшкән беренче исемнәрдән генә төзелгән һәм әле һич тә тулы булмаган менә шушы исемлекне укып чыкканнан соң күңелгә килгән беренче уй нинди соң? Яшерен-батырын түгел—бездә инде хәзер утраклык тойгысы шактый ук кочәйгән икән. Шуна күрә хәзер инде без татар кешесен үз җирендә, үз дәүләтендә матур тормыш корган бәхетле зат буларак күрергә телибез икән. Әнә шундый уй-тойгыларның дәвамы буларак әлеге исемлеккә карата минем мөнәсәбәтем дә күңелдә болайрак булып туды—«Читнең чите корысын!» Халык мәкале белән әйтелгән бу үтә катгый карашка нинди газаплы язмышлар һәм фаҗигаләр аша килүебезне барыбыз

да яхшы булә булыр—чөнки милләттәшләребезнең читтә бәхет эзләп йөрүләре хакында инде байтак кына әдәби әсәрләр язылды һәм языла тора, документаль язмалар да шактый гына күренде.

Ләкин, исемнәре югарыда искә алынган атаклы шәхесләргә күз салсак, аларның илне ташлап китүенә китергән объектив сәбәпләр булганлыгын да күрербез. Мисал өчен, Гата Камский шахмат дөньясында ирекле рәвештә көрәшеп карарга теләде, Вил Мирзаянов Россия хәрбиләренең куркыныч химик коралларын дөньяга фаш иткәннән соң ил белән хушлашырга мәҗбүр булды, ә Роальд Сәгъдиевнең исә безгә мәгълүм хәбәрләргә караганда беренче урында гаилә мәсьәләсе торды шикелле... Әлегрәк Европада яшәп калган Рудольф Нуриев мисалы инде ул, гомумән, төрмәдән ирекkә качу сыман иде—моны бөтен демократик матбугат шулай дип бәяләде дә.

Әйе, татарларның берсенең генә дә бу илдән китүе тикмәгә түгел—кайсы берәүләр шикелле дөнья күрәсе, чит илләр күрәсе килүдән генә түгел! Үзебез күнеккәнчәрәк итеп әйтсәк, язмыш кушуы буенча килеп чыкты ул хәлләр. Бер моңлы җырыбызда:

Китәсе килеп китмимен
Туган илдән кем туйган?—

дип әйтеләме әле?!

Әмма, икенче яктан алганда, адәм баласы анысы гел хәрәкәт ярата инде ул: иң әүвәл, тәпи йөри башлап, ишегалды чирәменә аяк баскач аның урамга чыгасы килә; аннары аны «урамнар артындагы яшел болын» үзенә чакыра башлый... тагын да бераз исәя төшкәч инде адәми затны урманнар артында нипәр булуы да кызыксындыра... Китә шулай, китә шулай... Һәм, әнә шулай итеп, кешеләр яңа Америкаларны ачалар. Үзләре өчен һәм кайчагында бик күпләр өчен дә «яңа Америка» була ул ачышлар!

Менә хәзер безнең алда татар шагыйрәсе Нурия Измайлова ачкан Америка ята. Ул нинди икән соң?

Ышанам—мин юк җирләрдә
Могҗизалар барына,—

дип язган иде моннан нәкъ егерме ел элек басылып чыккан «Яратам» исемле беренче китабында Нурия Измайлова. Чыннан да, бу аның бөтен язмышыннан чыгып әйтелгән сүзләр булган икән. Менә үзегез генә уйлап карагыз: Нурия Башкортстанда туып-үсә, Казанга килеп югары белем ала, Үзбәкстанда укыта, Мәскәүдә яши һәм инде менә хәзер, бу елларда, Американың Принсетон дигән кечерәк кенә бер шәһәрендә (Нью-Джерси штаты) көн күреп ята.

Әлбәттә, Америка турындагы бу китапны кулга алгач, аны укый башлаудан элек мин «Нуриянең бу шәһәре кайда икән» дип картага бактым һәм Принсетонның Америка материгының безгә карап торган ягында, ягъни Атлантик океан яры буенда ук—Нью-Йорк белән Вашингтон шәһәрләре арасындарак урнашкан икәнен күрдем. Моны белү белән күңел, ничектер, Нурияне ап-ак күлмәк кигән килеш әнә шул Атлантик океан ярына баскан һәм менә-менә күзгалып китәргә торган җилкән сыманрак итеп, омтылып безгә таба карап торадыр кебек итеп күз алдына китерде.

Нурия үзе китабында бу шәһәр турында бик яратып, хәтта үз күреп яза. «Әйе, оҗмах белән чагыштырыр идем Принсетонны иң беренче чиратта» дип яза ул һәм бераздан безне шәһәрнең менә мондый күренеше белән дә таныштыра: «Иртән торып чыксаң, ялт итеп торган кояш, дымсу җылы, йомшак һава, зәп-зәңгәр күк, ямь-яшел җир, зур-зур агачлар, аллы-гөлле чәчәккә чумган куаклар, уенчык шикелле ялтыр-йолтыр итеп торган кошлар, җәннәттә икәннәрен белгәнгәдер, беркемнән дә курыкмаучы исәпсез-сансыз әрсез тиеннәр һәм... тирән тынлык... Шулкадәр тын, һава хәтта тыңлап торган кебек; шулкадәр тирән ул тынлык, хәтта кое төбендәге кебек. Әкияттә бар бит әле: коега төшсәң дә күз күрмәгән гүзәлләкләр эченә чумасың, яшел үләннәр дисеңме, чәчкә-гөлләр дисеңме, асыл кошлар, алтын-

көмеш сарайлар дисеңме! Сез ничектер, мин үзем югыйсә оҗмахны гел шулай күз алдына китерәм. Менә Принсетонның урамы (төнлә дөм карангы—нәкъ безнең авыл): чип-п-чиста, буп-п-буш, тып-п-тыныч, хәтта жирдә икәненә һәм исән икәненә дә ышанырлык түгел.»

Күрдегезме, Нуриянең шагыйрьлеге хәтта чәчмә белән язганда да күзгә бәрелеп тора—аның җөмләләре хисле, тынычсыз, алар гел уйнап тора: гүяки автор белән безнең татар укучысы арасында яткан тынгысыз Атлантик океан дулкыннары бу китапның эченә дә үтеп кергәннәр! Юк, бу океан дулкыннары түгел—ә океан артында яшәп яткан шагыйрә Йөрәгенең дулкыннары! Китап әнә шул дулкыннарны китереп житкерә безгә.

Бу—әдәби әсәр түгел. Анда үз башыннан зур вакыйгалар кичергән геройлар да, кемнәрнедер гомумиләштереп биргән типик образлар да, сюжет җебе белән тоташтырылган кызыклы вакыйгалар чылбыры да юк. Нурия үзенә бер төрле ирекле язу рәвешен сайлап алган да—болында, табигать кочагында хозурланып йөргән сабый бала сыман, иплэп кенә барысын да күзәтә һәм күнеленә сеңдерә килә. Шулай ашыкмыйча, кабаланмыйча гына йөри бирә.

Татар шагыйрәсе атаклы Американы ничек итеп, нинди итеп күрә соң? Югарыда китерелгән өзектән күренгәнчә, автор бу илне иң башта оҗмах белән чагыштыра, аның бик күп әйбәт якларын тасвирлап үтә. Байлык, матурлык, тәртип, кешеләрнең гел шат йөзле йөрүләре... Әйе, болары шулай. Ләкин тагын менә монысы да бар: Америка иленең әйбәт якларын биредә Нуриягә ияреп санап китү безнең өчен кызык булмас, чөнки без телевизордан да көн-төн Америка киноларын карыйбыз. Аннары, Рәсәйдә Ельцин хакимлеге башлангач, тулаем ил дә әнә шул Америкага йөз тотып килә, бары тик әнә шул илне генә үзенә үрнәк итеп саный кебек.

Әмма бу ил безгә бөтен яктан да үрнәк була аламы соң?

Әнә шул сорауга җавап эзләп Америка тормышына Нурия күзе белән карыйк әле. Ул безнең яңа илгә җибәрелгән разведчигыбыз булсын!

«Бу илдә гариплек дәрәҗәсенә җиткән юан-килбәтсез гәүдәләр (халыкның 73 проценты) арта баруы тормыш стиленең гариплек дәрәҗәсендә гайре табигый булуына бәйләнгән—берсүзсез. Хәрәкәт итү, саф һавада булу, дару шикелле, сәламәтлекне яхшырту чарасына гына әйләнеп калган, ә гадәти тормыш—утыру да яту: өйдә, эштә, машинада. Җәяү йөрү юк дәрәҗәсендә. Тормыш уңайлыкларына күнегеп, чистый ялкаулыкка күнеккән халык барлыюклы физик эшен дә акча түләп эшләтә»... «Ә монда ашаган саен агу йоткандай—бөтен нәрсәдән курык, хәтта үзеңнән үзең дә курык!...» «Елаганыңны да, чирләгәнеңне дә, үлгәнеңне дә кешегә күрсәтмәү—болар барысы да үзенә күрә бер зыялылык, әдәплелек, югары белем һәм культура күрсәткече... Шулай итеп, ихласлык, эмоциональлек, ачыклык каралар өлеше булып, акларга, аристократларга икейөзлелек кала...» «Бокалларын, тәлинкәләрен күтәреп, йөренеп тә торалар, бер-берсе белән сөйләшеп тә алалар, тик бер бик зур нәрсә җитми—күңел ачу юк! «Күңел ачу»—шулкадәр мәгънәле сүз бит ул, бергә җыелуның, аралашуның бөтен гыйлләсе дә шунда бит инде»... «Ярамый шул, монда алай ярамый. Елмаю да, якын итеп эндәшү, ярдәм тәкъдим итү, хәл сорашу да—тик әдәп кагыйдәләре генә... Шуңа күрә ярдәмгә мохтаҗ кешеләр белән бәйләнергә дә тырышмыйлар, бәйләнсәләр дә, елмаеп исәнләшү дәрәҗәсендә генә...» «Безнең күңел күбрәк тели инде ул—әллә киңрәк, әллә комсызрак... Үзебезнең күңелне дә ачып куясы килә, кешенекенә дә кереп чыгасы килә. Ә менә монда нәкъ шушы нәрсә «прайваси» («шәхси тормыш») дип аталып, зур йозак астында тотыла: үз эченә дә кертмисең, кеше эченә дә кермисең, гайбәт тә сатмыйсың. Әйттем бит инде күңелсез дип. Үләрсең!»

Кабатлап әйтәм—Нурия үзе Америка турында язганда уңай якны да, ошамаган якны да бертигез дәрәҗәдә яктыртып бара: күзе ни күрсә, йөрәге ни кушса—шуны яза. Һәм бу китап әнә шул гаделлеге, ихласлыгы белән безгә кыйммәт тә. Ул Америка турында дөрес күзаллау булдырырга тырыша.

Ләкин биредә безне әлеге дә баягы сорау кызыксындыра: Америка бүген безгә үрнәк була аламы икән? Тагын да ачыклабрак әйтсәк: хәзерге

тормышыбызны, яшәешебезне коруда үрнәк була аламы ул безгә?

Иң башта шуны искә төшерик: Америка—ул читтән килгән кешеләрнең жирле халыкны кырып, хәйлә һәм көч, салкын акыл һәм корал ярдәмендә төзелгән җәмгыять. Озак еллар дәвамында, табигый тормыш процесслары нәтиҗәсендә, төрле-төрле каршылыкларның табигый юл белән көрәше һәм үзара керешүе, шулар нәтиҗәсендә органик рәвештә диярлек кушылып китүе процессында барлыкка килгән җәмгыять түгел ул. Тормышта табигый рәвештә барлыкка килмәгән мондый күренешне гадәттә «эклектика» диеп атыйлар һәм күбрәк очракта «минус» тамгасы белән тамгалыйлар.

Америка тормышына мөнәсәбәттә дә әнә шул «эклектика» төшенчәсе бик тә туры килә. Ягъни ясалма юл белән барлыкка китерелгән, табигый юл белән үсмәгән! Димәк, табигый тамырланып үсү булмагач, анда акыл үзе генә белеп, аңлап, сизеп бетермәгән ниндидер бик мөһим нәрсәләр искә алынмый кала дигән сүз. Ә кеше җаны, аның йөрәге һәм гомумән аның табигате, натурасы яши-яши барыбер әнә шул житмәгән нәрсәләрне талымлый, юксына, сагына башлый ул! Ана карынында бәләкәй бала үскән чагында әни буласы кешенең организмы теге яки бу азыкны бик тә теләгән сыман—хәзер Америка җәмгыяте дә үзенә житмәгән нәрсәләрне эзләп капшана, уйлана, баш вата. (Гүяки аның карынында да дөрес яшәү рәвеше житлегеп килә!) Нуриянең бу китабында кайбер галимнәрнең фикерләре дә китерелә: «Бүгенге цивилизация балаларының тормышын «агуланган балачак» дип атап, бик күп дәлилләр китереп, моның дөреслеген исбатлыйлар: физик авырулардан башлап, робот дәрәҗәсенә житкән рухи бушлык... Кушма Штатлардан һәм Германиядән алынган хәбәрләр бүгенге көн балаларының хәле нервлылык, стресс, гиперактивлык, ашау, йоклау авырулары, экзема, аллергия, астманың үсү дәрәҗәсе бик нык югарыга сикерүен күрсәтә...» «Коммерсиализм, технология, хәбәрләшү массакүләм чараларының үсә баручы һөҗүме астында балалар таза булып кала алмый, бигрәк тә болар—бала табигатенә ярашсыз тәрбия һәм белем бирү белән кушылган булганда», «Көчле тавышлы музыка, үтерешле-кан коюлы фильмнар, тиз-тиз компьютер уеннары, күз явын алырдай ачык төсләр, көчле дарулар һәм наркотиклар—безнең заманда сиземлелекне төшерә торган сәбәпләрнең кайберләре шушылар икән»...

Күрәсез, бу хәбәрләрне безгә Америка җәмгыятенең үз эчендәге кешеләр житкерә. Боларны укыгач хәтта мондый фикер дә башка килә. Бүгенге Америка иле ул—кеше җанын үзенчә бер төрле сынап карау полигоны кебек кабул ителергә тиештер инде. Лабораториядә яңа төрле химик эремә ясалганнан соң аның нинди икәнлеген белү, аңлау өчен аңа лакмус кәгазе салып карыйлар бит әле—минемчә бүгенге Америка да кешелек өчен әнә шундый бер эксперимент, тәҗрибә кебек.

...Китаптагы ир-ат белән хатын-кыз һәм гаиләгә бәйле хәлләр дә кызыксынып укыла, безне тирән уйга сала: «Ирләр импотентка яки кыз тәкәгә әйләнеп бетә бара, чөнки тигез хокук, тигез белем, җәмгыятьтә тигез дәрәҗә алган, ә җәмгыять, законнар тарафыннан ныграк якланган хатын-кыз өммәте алардан көчлерәк булып, үзенә тартып торучы гүзәл чәчәк булудан туктап, бер дәһшәткә әверелгән, һәм алар бу кыз тәкәләр каршында үзләрен ир итеп сизә алмый, күп булса, кыз тәкә генә булып кала. Нәтиҗә буларак, хатын-кыз ялгызлыкка дучар...»

Әйе, тыштан караганда барсы да житеш һәм камил тоелган Америка җәмгыятенең дә житди генә житешсезлекләре бар һәм без юри биредә әнә шуларга күбрәк тукталдык. Аны мактаучылар, аңа сокланучылар болай да, бездән башка да байтак булганга күрә шулай эшләдек. Чыннан да, бүгенге Америка безгә тулаем алганда маяк була алмый шул. Безнең өчен күрәсең урта юл кулайрак буладыр—үзебезнең элеккеге традицияләргә ялганыбрак киткән юл, үзебезнең тамырларның дәвамы булган юл. Үзебезчәрәк һәм кешечәрәк булган юл—милли юл!

Нурия Измайлованың «Язылмаган хатлар» китабын укып чыгуга күп тә үтмәде, журналыбызның быелгы июль санында аның тагын «Океанның аръягында...» исемле зур гына күләмле яңа язмасы да пәйда булды. Инде

аталышыннан ук аңлап алгансыздыр— шагыйрәбезнең бу әсәре дә Америка турында, дөнья халыклары теленә «ирекле ил» буларак кергән әлеге җәмгыятьнең тәртипләре, кануннары хакында.

Ике әсәр арасындагы аерма, үзенчәлек тә күренә. Китап булып чыкканында автор яңа илнең көнкүреше, көндәлек тормышы белән күбрәк кызыксына, үзенең күзенә чалынган кызыклы фактларны, яңалыкларны документаль кинодагыдай күрсәтеп, безнең хәтергә сеңдереп бара. Ә инде безнең журналда басылган язмада исә аерым күренешләрдән, фактлардан өскәрәк күтәрелү, гомумиләштерүләр, кайбер нәтиҗә ясаулар күбрәк күзгә ташлана. Биредә публицистик рух, аһәң көчлерәк.

Ә иң мөһиме биредә Нурия Измайлова «чын мәгънәсендә ирекле булган кеше нинди була?» дигән сорауга җавап бирергә тырыша.

Әйе, бу мәсьәлә, бу сорау безнең татар халкы өчен үтә дә актуаль. Ни өчен икәнен укучы үзе дә бик яхшы белә. 450 еллык коллык психологиясе безнең милләткә бигрәк тә нык сеңгән. Шуңа күрә әлеге язманың менә мондый бүлек исемнәре дә татар укучысы өчен чын азатлыкка чакыручы өндәмә буларак ишетелә: «Ирекле Америка», «Дәртлеләр, гайрәтлеләр иле», «Дискриминейшен», «Үзеңә үзең ярдәм ит» һ. б.

Ирек темасы авторны ике яктан уйландыра: шәхес ирегe һәм милләт азатлыгы. Беренчесенә караган фактлардан миңа бигрәк тә менә монысы тәэсир итте. Нурия үзенең малае турында язып, аның хоккей уйнарга өйрәнгәндә аягын кырдыруын әйтә дә, болай ди: «Иртәгә бу аягың белән хоккейга бара алмассың инде»—дигән идем, ул миңа бик гайрәтләнеп: «Ноу гивин ап!—дигән булды: «Бирешү юк!»

Менә бу инде безнең илдән китеп Америкада яши башлаган яшь буын вәкиленең сүзләре. Яңа төр психологиянең, менталитетның яшь кешегә ничек тәэсир ясавын күрсәтүче сүзләр! Җитмәсә, автор үзе дә болай дип өстәп куя бит әле—«Безне дәртсез, гайрәтсез—пассив булырга совет системасы күнектергән.»

Шул ук вакытта шагыйрә үз милләтендәге зур потенциаль мөмкинлекләрне дә исеннән чыгармый: «Хәрәкәттә—бәрәкәт» дип безнең ата-бабалар әллә кайчан әйткән әйтүен, андый гына сабакны алыр өчен Американы өйрәнеп торасы да юк. Шунысына гына эч поша—безнең бабайлар әйткән, болар ишетеп тә алган, хәрәкәт тә итә башлаган. Ә без... без хәрәкәтне дә яратабыз, бәрәкәтне дә яратабыз—хәрәкәт итәргә көч җитми. Хәрәкәте дә һаман бер урында таптану килеп чыккач, бөтенләй җен котыра!»

Америкада күп төрле милләтләр яши. Әмма алар үзләренең тегe яки бу милләттән булуы өчен һич кенә дә уңайсызланмый, оялмый. Шул исәптән кара тәнлеләр дә, африкалылар да үзләрен башкалар белән тигез тоя, тиң саный. Автор ирексездән үзе белгән Рәсәй чынбарлыгын искә төшерә: «Бер чуаш кызының: «Шул нацияны күрә алмыйм, бер авыз чуашча белмәсәк тә, нишләп чуаш диләр икән безне?»—дип зарланганын мәңге онытмам.» Һәм тагын менә мондый җан әрнеткеч вакыйга: «22 яшьтә идем, ял көне, троллейбуста, Уфада. Бер башкорт радиосын ачкан, көндезге башкорт концерты бара. Артымда басып торган хатын очып кунмасынмы бу кешегә: «Это тебе что, татарский клуб?! Может никто не хочет слышать твою дурацкую гармошку! Заткни свое радио сейчас же!—ди. Андый гына тупаслыкларны колакка да элмәскә өйрәнгән, ахрысы, тегe абзый, бер сүз эндәшмәде, радиосын да сүндермәде. Мин әлеге хатынның «татарский» дигән сүзенә чыдамадым: «Не башкиры пришли на русскую землю, русские пришли на башкирскую, пусть слушают!»—дип янгыратып җавап бирдем. Тегe хатын аптырап калды. Интеллигент кыяфәтле хатын иде ул һәм... татар хатыны иде! Валлаһи татар иде! Телен оныткан манкорт! Менә шулай. Милли дискриминация көчле милләтнең көчсез милләтне рәнҗетүе генә түгел ул, ул күпкә шакшырак!»

Рәсәй яшәешен Америка белән чагыштырып күп санлы гыйбрәтле мисаллар китергәннән соң авторга инде үзенең тел төбендәге төп фикерне әйтеп бетерү өчен бер генә җөмлә җитми кала:

—Җәмгыятьтә милләтләргә чын тигезлек урнаштыручы һәм реаль көче булган кануннар яшәргә тиеш!

Әйе, чынлыкта Россия дигән бу ил әле ул яктан алганда һаман ярым кыргый хәлдә яши. Шуңа күрә җанны әрнетә, җенне чыгара торган менә мондый очраклар биредә еш очрый: «Уфада Динә исемле дус кызым белән троллейбуста сөйләшеп утыра идек, чучка кебек пычракка баткан бер исерек урыс: «Чево на весь троллейбус разошлись, татарки наглые!»—дип кычкыра башламасынмы! Татарча пышылдап кына сөйләшергә кирәк икән!»

Шунысы сөенечле: язмада китерелгән менә шушындый тормыш фактларына автор үзенең дөрес һәм публицистик кайнар рухта булган бәясен биреп бара. Димәк, ул укучыларны милли һәм әхлакый, сәяси яктан тәрбияләүдә дә җитди эш башкара дигән сүз.

Менә без Нурия Измайлованың ике әсәрен—«Язылмаган хатлар» китабын һәм «Океан аръягында...» язмасын укып чыктык. Күреп узганыбызча, аларда безнең өчен яңа булган яшәеш, көнкүреш, кануннар... Безнең әдибәбез ул дөньяда үзе яшәп, безгә үзенең күргәннәрен һәм белгәннәрен, уйларын һәм тойгыларын хәбәр итте. Аның әйтергә теләгәннәре безнең аңга, зиһенгә, рухыбызга килеп җитте. Хәзер инде без әнә шулардан чыгып үзебез өчен дөрес нәтиҗә ясарга тиеш. Ә нинди нәтиҗә?

**Беренче нәтиҗә.** Соңгы елларда Россиядә урнашкан демократиянең байтак кына әйбәт яклары белән бергә бик күп начар яклары да булды. Бигрәк тә гади халык өчен. Аеруча яшьләр өчен. Мисалга матбугаттан алынган берничә сан. Хәзер Россиядә яшьләрнең 40 проценты психик яктан тайпылышлы, 70 проценты хроник авыру, 30 проценты эшсез һәм яшь хатыннарның 30 проценты бала табарга кыймый! Җинаятьчелек турында инде әйткән дә юк! Болар барысы да, нигездә, әлеге демократиянең Америкага охшарга азаплануның җимешләре.

**Икенчедән.** Америкадан аермалы буларак, безнең татар халкының ерак гасырларга киткән тамыры: рухи, әхлакый, психологик һ. б. традицияләре бар. Аларның бик күбесе әле хәзер дә исән, кешеләр күңелендә яши һәм алар бүгенге чынбарлыкны искә алганда тагын да өметлерәк, перспективалырак күренәләр. Ислам диненең асылда көчле рухилыкка нигезләнүе дә безнең киләчәккә булган өметләрне арттыра.

**Өченчедән.** Татарның ерак гасырлардан ук килгән даны да бар. Исеме бар. Соңгы елларда безнең республика җитәкчелеге алып бара торган курс—Ауропага «йомшак керү» курсы—бу данны заманча итеп яңартырга, Ауропа мәйданында яңадан да балкытырга мөмкин. Ауропа бердәмлеге илләренең соңгы вакытта Россияне үз кочагына алырга тырышулары фонында безнең мондый омтылыш тагын да мәгънәлерәк күренә, милләтебезгә яңа мөмкинлекләр вәгъдә итә.

Әйе, хәзер без яши башлаган «...беренче гасыр», «...беренче ел» күп яктан сискәндерә, игътибарыбызны уята, яңача уйлый-фикерли башларга куша. Тирә-юнебездәге һәм дөньядагы бик күп вакыйгаларга, тенденцияләргә өр-яңа күзлектән карарга мәҗбүр итә ул.

Язмабызның башында без үтеп киткән егерменче гасырны тизләнеш, актив хәрәкәт, кискен үзгәрешләр чоры булды дигән идек. Ләкин тулы бер гасыр—йөз ел буе—яшәп караганнан соң кешелек җәмгыяте инде үзенә андый гына хәрәкәтнең җитенкерәмәвен нык итеп аңлый башлады. Хәзер кешелек җәмгыяте тормышында эчке байлыкның, рухи байлыкның җитмәве үтә дә нык сизелә. Нурия Измайлованың Америка турында язганнарын укыганнан соң да күңелдә әнә шул фикер ныгып кала.

Әлбәттә, бу уйлар, бу фикерләр иң беренче чиратта безнең татар халкы турында. Башланып киткән менә бу чорда милләтебезне рухи яктан үстерүнең, аны эчтән ныгытуның, активлаштыруның үтемле юлларын, чараларын табарга иде. Шул юнәлештә көчле эш, хәрәкәт башларга иде!

Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ

*Юмор-сатира*

# Рөстәм Зарипов

## Төш

Төш күрәм... Имеш ки мин бер күк хадиме,
Җир язмышы сыйдырылган монитордан,
«Т» атлы төймәгә басып, һәр адымын
Татар милләтенең имеш, карап торам...

Татар—тырыш, башын иеп дуңгыз бага,
Тирес түгә, җир сукалый, күмер чаба;
Вакыты тар, хәтта милли бәйрәмен дә
Кайсы елны оештыра шыксыз көндә...

Гайрәт чигеп, басам башка төймәләргә...
Мониторны карнаваллар биләп ала...
Политика... Экзотика... Эротика...
Мондый поэтикадан җан әреп китә...

Карап ятам хозурланып, хөҗерләнеп
Кяфер кавемнең шаукымлы мәгыйшәтен;
Мөселман... чәчән... фәлән... дип борчысалар,
—Тсс,—минәйтәм,—пажалысты, не мешайте!..

Тәмле төшемне шул мәлдә бүлдерәләр
Сүзнең миңа бирелгәнен белдерәләр.
Депутатлар авыз ачып карап тора,
—Аһ,—минәйтәм,—өн дә пука ярап тора...

❧

Азатлык,—дип нәни милләт тәмуг кичә,
«Бөек» халык аның канын көн-төн эчә...
Җәллад—чара... Хөкемдар—кем? Һәм шул гомер...
Ни өчен төкәнми, кайтмый, кемнең үче?!..
... Өмет өзми тәмуг кичә чәчән халкы,
Янартау йөрәге шулай әйди аны...

## Шагыйрь дуста кунакта

—Кул суз һәм сос, табын күрке
Чикмән кигән бавырсак...
Карап торма, бүтән сый юк,
Аңлыйсыңдыр, авыр чак.

Бер шифа тапмый калмабыз
Әгәренки авырсак.
Әйдә, туган, аша суган,
Ачы торма, сарымсак!..

❀

*(ҫтә актив бер авторга)*

Һәр язганыннан кычкыра
Мин—шәп, дигән фикер.
Әхлаксызлык үрнәге ул
Үз-үзеңә зекер...

❀

—«Тибүчеләр»не фаш итеп,
Кем анда тегә сакал?
Кем булсын, Мәшһүр Тибүче
Фәнзаман ага Баттал...

*«Тибүчеләр»—Ф. Бның шул исемдә күләмле мәкаләсе матбугатта дөнья күрде.*

❀

Диңгезле шигырьләреңнән
Хушлана иде күңел.
Гаташлангач язганнарың
Салмый аңларлык түгел...

## Мин борылып яттым

*пародия*

*Мин оныттым сине. Ә син әрсез,*
*Төшләремә һаман керәсең.*
*Жанның теленгәнен беләсең бит,*
*Арадагы ярны күрәсең.*
*Телгәләнеп беткән йөрәгемне*
*Учка кысып, тагын кабатлыйм:*
*Уйларымнан, төшләремнән кит син,*
*Мин яратмыйм сине, яратмыйм...*

Мөдәмил Әхмәтов

Мин борылып яттым. Ә син әрсез,
Куеныма һаман керәсең
Җанның үртәлгәнен беләсең бит,
Яшь аермасын да беләсең...

Шәлперәйгән, шиңгән йөрәгемне
Учка кысып, тагын кабатлыйм:

**Азаплама мине, кит янымнан,**
**Мин яратмыйм, сине, яратмыйм...**

—Татарстан, әйтче, син соң мөдәм илме?
Ник белмиләр бөек шагыйрь—Мөдәмилне??
—Андый шагыйрь, кызганыч ки, аунап ятмый.
Шуңа күрә аны һичкем күрми, тапмый...

## Биофиллар

*Ялгыш каенны кочканмын,*
*Мин аны син дип торам...*

Роберт Миннуллин

*Как жену чужую,*
*Обнимал березу...*

Сергей Есенин

**Сексуаль азчылык төрләнештә,**
**Бозыклыкка дөнья ничек чыдар?**
**Зоофиллар гына җитми иде,**
**Пәйда булды каен кочучылар?!....**

## Акча мәсьәләсе

*Акчаң булса, гөл сибәләр йөзеңә;*
*Акчаң бетсә, көл сибәләр күзеңә...*

Равил Фәйзуллин

**Чорлар алмашына, калынаймый**
**Шагыйрьләр кесәсе**
**Һаман кискен килеш кала бирә**
**Акча мәсьәләсе...**

**Сергач якларында, концертларда**
**Ялыктырса әгәр берәр җырчы,**
**—Икенчең чыксын!—дип аваз сала**
**Гаҗиз тамашачы.**

**Күп гәҗит-журналда бар даими,**
**Бер сан калмый сару кайнатучы.**
**Мишәр агай, кайда ихласлыгың,**
**Кычкыр пожалысты!**

Көтмәгәндә ишек шакыдылар,
Баштан төшеп китте түбәтәй;
Төксе караш ташлап түргә үтте
Тикшерүче, ике пүнәтәй...

Каян, нәрсә тартып чыгарырлар...
Күңел сагыш белән чүмәкәй...
Әле генә йөрәк бөркет иде,
Инде пыр-пыр килгән чүрәкәй...

*Язучы Флүс Латыйфигә*

«Бәйсез этләрне атарга» икән,
Ничек «Ак-карага тимәскә»?
Җитмеш мең тиражлы «Хыянәтең»
Өнди башны түбән имәскә!

**Искәрмә.** Куш тырнаклар эчендә авторлар язган әсәрләрнең исемнәре.

*Язучы Фоат Садриевка*

«Адәм әүлиясы» дими җай юк,
Кунак итеп «Тозлы бал» ашаттың,
«Таң җиле»нә чыгып, хәл-тын алгач,
«Их, сез, егетләр!»—дип, тел шартлаттың...

Порнобоевикка тарта Җирдә тормыш...
Кем соң безнең вәзгыятьне шулай бормыш?
Кем—режиссер, кем—автор, кем—тамашачы?
Һәм жанрда чагыла кем ихтыяҗы?..

*Нәниләр дөньясы*



*Айгөл—Чаллы кызы. Япь-яшь булуына карамастан, шактый үрләрне яуларга өлгергән инде ул—шәһәрдәге музыка, рәсем сәнгате мәктәпләрендә белем алган, урта мәктәпне алтын медальгә тәмамлаган, аннан соң Казан дәүләт университетының журналистика факультетына укырга кергән.*

*Айгөл дүрт яшендә үк үзе уйлап чыгарган әкиятләрне сөйли торган була. Бишенче сыйныфта укыганда аның беренче шигыре Чаллыда нәшер ителүче балалар газетасы—«Көмеш кыңгырау»да дөнья күрә. Шул вакыттан башлап ул әлеге газета оештырган бәйгеләрдә даими катнаша, соңрак аның яшь хәбәрчесе булып китә.*

*1998 елда Айгөл Нуретдинованың «Хикмәтле тартма» исемле беренче китабы дөнья күрә. Узган ел ул «Алтын каләм» республика фестивалендә катнашып, призлы урынга ия була.*

*Хәзер Айгөл—өченче курс студенты һәм бер үк вакытта «Көмеш кыңгырау» газетасы хезмәткәре дә.*

*Бүген укучыларыбызга Айгөлнең берничә әкиятен тәкъдим итәбез һәм аның яңадан-яңа үрләрне яулавын теләп калабыз.*

## Айгөл Нуретдинова

## АЙСЫЛУ БЕЛӘН НУРСЫЛУ

Борын-борын заманда, әбиемнең әбисе кыз, бабамның бабасы егет булганда яшәгән, ди, Хөснетдин исемле бер агай. Ул бу якларда дан тоткан бик яхшы тегермәнче булган, ди. Әйләнә-тирә авыллардан килгән кәрваннар тузанлы юллардан агылып кына торган. Хөснетдин агай тегермәнендә тарттырылган оннан пешкән ипиләр, күмәчләр ашап туймаслык тәмле була икән. Шуңадыр инде, берәү дә кире борылып китмәгән, сабыр гына үзенең чиратын көткән. Ә кичләрен олаучыларның җырларыннан тирә-як яңгырап торган:

Ерак җирләрдән килдек
Он тартырга без монда.
Кире какмасларын белдек,
Шуңа килдек без монда.

Тегермән ташы әйләнә
Елга суы көченнән.
Хуш исләр генә тарала
Хөснелбанат миченнән.

Хөснетдиннең тегермәне
Шундый он тарта диләр—
Пешкән икмәген ашасаң,
Куәтен арта диләр.

Елга ярлары бормалы,
Бормалы да сырмалы.
Бигрәк унган, бигрәк чибәр
Хөснетдиннең кызлары.

Кара кашлары кыйгач,
Сөрмәләр тартып куйгач.
Яшь йөрәкләр монда тарта,
Чибәркәй монда булгач.

Хөснетдин агайның берсеннән-берсе матур ике кызы булган, ди. Бу кызлар, апалы-сенелле булуга карамастан, бер-берсенә игезәкләрдәй охшаш булганнар икән. Хәтта Хөснетдин агай да үзенең олы кызы Нурсылу белән кече кызы Айсылуны бутый икән. Тирә-як авыллардан килгән яшь егетләр, аларга багышлап, берсеннән-берсе уздырып, янадан-яна җырлар иҗат иткәннәр.

Төскә-биткә охшаш булсалар да, кызлар үзләренең холыклары белән бик нык аерылып торганнар. Нурсылу төптән уйлап, бар эшен дә җиренә җиткереп эшләргә яраткан. Ә Айсылу һәрвакыт шаян, тиктормас, эшләрен дә бик тиз эшләп ташлый, бер урында озак торырга яратмый. Бу кызлар булган җирдә көлү, җыр, моң авазлары ташып торган. Бер-берсеннән аерылып тора алмаган Нурсылу белән Айсылу бер тамырдан үскән ике мәк чәчәгедәй гүзәл булганнар. Килгән егетләр менә шушы саф, гүзәл затларга гашыйк булалар икән, ди. Бер генә минутка булса да кызларны күреп калыр өчен, төрле сылтаулар табып, тегермәнгә килергә ашкыналар, имеш. Бер генә капчык салып килүче егетләрдән Хөснетдин агай:

—Ник берьюлы өч-дүрт капчык алып килмисең?—дигәч, егетләр шаярып:

—Һәр килгән саен онның тәме тәмләнә, көч-сихәте арта,—дип елмаешалар икән.

Хөснетдин агай ышанган булып кылана. Ә үзе мыегын бөтереп, сакалын сыпыргалый-сыпыргалый елмаеп:

—Шулайдыр шул, тәме артадыр, сихәте артадыр, сезне монда шул тартадыр, хикмәтле шул минем тегермәнем,—дип кеткелдәп куя, ди.

Сернең нәрсәдә икәнен төшенгән Хөснетдин агай акрын гына егетләрне күзәтә, холыкларын тикшерә, кызларына кияү булырлыкларын барлый икән. Әмма кызларын кияүгә бирерлек, күңеленә ошаган егетләрне таба алмаган.

Көннәрдән бер көнне иртә таңнан пар ат җигеп авылга олаучы килеп кергән. Шулчак сизгер күнелле Айсылу йөрәгенең чәнчеп алуын, ниндидер сихри көчнең үзенә тартуын сизенгән һәм апасы Нурсылуга:

—Апам, бүген безнең өчен көтелмәгән очрашу булачак! Зур үзгәрешләр көтә безне,—дигәч, Нурсылу:

—Әйе, мин дә бүген төшемдә тәрәзә төбендәге роза гөленең пар чәчәк атуын күрдем. Тик алар икесе ике төсле: берсе ак, берсе кызыл иде,—дигән. Айсылу:

—Бу, апам, беребез өчен бик яхшы, икенчебезгә бик моңсу хәбәр. Синең белән аерылышу минутлары якынлаша. Кайсыбызга яхшы, кайсыбызга моңсу хәбәр буласын бер Ходай гына белә, төшеңне хәерлегә юрыйк,—дип елмайган.

Тегермән капкасы төбенә пар ат җиккән олау килеп туктаган. Арбадан җитез генә сикереп төшкән егет тузанлы чапанын салып каккан, чигелгән билбавын кысыбрак буган, түбәтәен кыңгыр салыбрак кигән һәм ныклы адымнар белән капкага юнәлгән. Ишек алдын себереп йөрүче Хөснетдин агай капканы ачып җибәргән һәм каршысында кыюсыз гына елмаеп басып торган егетне күргәч, сискәнеп киткән.

—Керергә мөмкинме? Зинһар, гафу итегез, тегермәнчене күрергә буламы?—дигән сорауга Хөснетдин агай:

—Рәхим итегез! Тегермәнче Хөснетдин мин булам,—дип, кулы белән керергә ишарә ясаган.

—Мин Күгәрчен авылыннан Әхтәмҗан малае Хуҗаҗан булам. Ун капчык бодай алып килгән идем, тарттырып бирә алмассызмы?—дигән егет, елмаеп.

—Чиратка басарсың, ишек алдына кертеп атларыңны туар, тарттырырбыз. Әле беренче тапкыр гына килүең ахры, мондагы тәртипләрне белеп бетермәгәнгә охшыйсың,—дип сөйләнә-сөйләнә, олы капканы ачкан тегермәнче Хөснетдин агай.

Эш мәшәкатьләре, ыгы-зыгы белән көн узып, кичкә авышкан. Ашалган ташына тешләр уяр өчен тегермән дә туктатылгач, авылда тынлык урнашкан. Тегермән буасы да төсен үзгәртеп, шомлы тынлыкка чумган. Кыр-кырларында үскән камышлар, тал-тирәкләр дә, аларга кунып бер-берсен уздырып сайраучы сандугачлар да шул сихри кичкә буйсынып, тын гына ниндидер могҗиза көтәләр икән. Шулвакыт буа өстеннән вак көмеш дулкыннар йөгереп узган, тал-тирәкләр, камышлар чайкалып куйган һәм яр буена яшеллән киенгән гаҗәеп матур, мәһабәт гәүдәле бер егет килеп чыккан. Тегермән алачыгы кырыена посып, ул авылны күзәтә башлаган. Хәзер генә судан чыгуына карамастан, өстендәге киемнәренең коры булуы әлеге затның кешеләрдән куркып, яшеренеп

торуы аның кеше нәселеннән булмавы турында сөйли иде. Бу—шушы елганың хуҗасы—Субай малае Упкын. Ул унбиш ел буе шулай буадан чыгып, кызларны күзәтә икән. Упкын Айсылуга гашыйк булган, аны күрмичә бер генә көн дә түзә алмаган. Кайбер көннәрдә, Айсылу урамга чыкмаса, ул яшеренеп кенә килеп, аны тәрәзә аша күзәткән. Айсылу аз гына авырып китсә дә, ул аңа сихәтле сулышын өргән. Шуңадырмы, Айсылу авыруларны җиңеп бик тиз аягына баса, тагын да чибәрләнеп, үсеп китә икән. Бервакыт авырып ятканда кыз үзенә карап торучы бик чибәр егетне күргән, саташам ахры, дип кулларын селтәгән һәм йоклап киткән. Айсылуның кул селтәгәнен күргән Упкын моны үзенчә кабул иткән. «Айсылу миннән курыкты, ул мине яныннан куа, ул минем белән сөйләшергә теләми»,—дип уйлаган. Шулай да яшерен генә күзәтүләрен дәвам иткән. «Берәр уңайлы вакыт килер, мин түземле, мин синнән башка яши алмыйм. Син барыбер минеке булачаксың»,—дигән Упкын.

Бу юлы да ул кызны күрү нияте белән, коры җиргә чыккан. Кызыксыну көчле булгангадырмы, бераз посып торгач, Упкын алачык артыннан чыгып, сукмак буйлап атлаган. Уйларына бирелгән егет көтмәгәндә артында аяк тавышлары ишетеп, сискәнеп киткән. Артына борылып караса, Нурсылу басып тора икән. Кызлар бер-берсенә ике тамчы су кебек охшаш булсалар да, күңеле белән аера икән аларны Упкын. Хур егетедәй чибәр Упкынны күргән Нурсылу аңа шул минутта ук гашыйк булган. Оялып, алсуланып киткән йөзен, сөю чаткылары кабынып киткән күзләрен яулык очы белән каплап сукмактан читкә тайпылган. Хәзер инде качып торуның мәгънәсе юклыгын аңлап, Упкын да телгә килгән:

—Сылукай, курыкмагыз, мин сезгә начарлык эшләргә теләмим, юлыгызны дәвам итегез,—дигән, ике кулын күкрәгенә куеп, башын аска игән һәм сукмактан читкә чыгып баскан.

Шулвакыт авыл башында тальян уйнап җибәргән, аңа яшь кызларның, егетләрнең җырлары кушылган.

Якынлашып килүче авыл яшьләре белән очрашудан курыккан Упкын тизрәк китү ягын караган, шулчак Нурсылу:

—Рәхмәт, ә мин курыкмыйм. Сез кемнәргә килдегез, кайсы авылдан?—димәсенме. Каушап калган Упкын:

—Мин буадан,—дигәнен сизми дә калган.

—Андый авыл бармыни? Минем ишеткәнем юк,—дигән Нурсылу.

Кирегә юл югын аңлаган Упкын:

—Әйе, бар, моннан ерак ул,—дигән, үз ялганыннан үзе оялып. Тальян гармунга кушылып җырлаучы яшьләр алар янына килеп җиткәннәр. Гармун тартып килүче Хуҗажан:

—Менә чибәркәй кайда икән. Без аны югалткан идек,—дигән, мәхәббәт тулы күзләрен Нурсылуга төбәп.

—Ә мин сезне бөтенләй белмим. Сез кем буласыз соң?—дигән Нурсылу.

—Гафу итегез, таныш булыйк, исемем Хуҗажан. Күгәрчен авылыннан он тарттырырга килдем. Мин инде башкалар белән таныштым, сезне генә беренче күрүем,—дип, башын аска иеп сәламләгән аны егет.

Нурсылу:

—Мин дә сезне беренче күрәм. Минем исемем Нурсылу, мин тегермәнче кызы булам,—дигән, яулык чите белән йөзен яшерә төшеп.

—Ә бу егет кем?—дигән Хуҗажан, кыз янында каушап калган Упкынга күрсәтеп.

—Мин, мин... Әбүбәкер,—дип ялганлавын сизми дә калган Упкын.

Яшьләр озакка сузылган танышуны тизләтеп, аларны чолгап алганнар һәм җырлый, бии башлаганнар. Шушы ыгы-зыгыдан файдаланып Упкын куаклар арасына качкан. Моны берәү дә сизми калган. Җырлый-җырлый болынга юл алган яшьләрне куаклар арасыннан карап калган Упкын, үзенең алардан җиңел котылуына сөенеп: «Мине үзләре белән тиң күрделәр, миннән шикләнмәделәр, бернәрсә дә сизмәделәр»,—дип сөйләнә-сөйләнә буага кереп киткән. Болынга житеп, җырлы уеннар башлануга, Нурсылу Әбүбәкернең юкка чыгуын күреп алган. Беренче минутларда ук бу егеткә гашыйк булуын аңлаган. Хуҗажанның аның янында басып торуын да, аңа нәрсәләрдер сөйләвен дә сизмәгән кыз. Салкынча җил исеп куйгач, Хуҗажан камзулын Нурсылуның иңбашына салган. Шулчак кыз айнып киткәндәй булган:

—Мина кайтырга вакыт! Минем арттан килеп йөрмәгез, минем егетем бар,—дигән ул, үзе дә сизмәстән.

Камзулны Хужажанга тоттырган да, егетне гажәпкә калдырып, өйләренә таба йөгергән. Каушап калган егет янына Айсылу килеп баскан.

—Кунак егете ниләр уйлый?

Каршында Нурсылуга бер тамчы судай охшаган кыз басып торуын күргән Хужажан бөтенләй югалып калган.

—Сез әйләнеп килдегезмени?—дигән ул, тегермәнче өенә күрсәтеп.

Айсылу егетнең үзен апасы белән бутавын аңлап:

—Йөгереп китүче кыз минем апам Нурсылу, ә мин Айсылу булам,—дигән. Алар күпме сөйләшкәннәрдер, әмма шушы минутларда кыз белән егет арасында мәхәббәт гөле чәчәк аткан.

Алар бергә таңны каршылаганнар, сөйләшеп сүзләре бетмәгән. Көлешә-көлешә буа яныннан узып баручы бу парны Упкын күреп алган. Һәм шунда ук үзенең Айсылуын таныган...

Чираты житеп, он тарттырып, тагы очрашырга сүз биреп, Хужажан авылына кайтып киткән. Гашыйк булган ике кыз да кичке уеннарга чыкмас булганнар. Алар бер-берсенә үзләренең серләрен сөйләп, өйдә генә утыра башлаганнар. Нурсылу Әбүбәкер-Упкынның килүен көткән, ә Айсылу Хужажанын сагынган.

Шулай бер кич Айсылу тегермән буасына кер чайкарга төшкән. Басмадан иелеп чайкый гына башлаган икән, су төбеннән аңа текәлеп карап торучы егетне күреп алган. Кызның кулыннан чиккән сөлгесе төшеп киткән, шуны гына көткән Упкын сөлгене эләктереп алган да, тирәнгәрәк чумган. Каушаудан ни кылырга белмәгән Айсылу басмадан йөгереп чыккан да, яр буеннан буаны күзәтә башлаган. Буа суы төрле төсләргә кереп жемелди икән, вак көмеш дулкыннар камышлар арасыннан тибеп чыккан сихри моңда тирбәлә-тирбәлә хәрефләр барлыкка китергән. Су өстендә ап-ачык булып Айсылу исеме пәйда булуын күргән кыз, бу гүзәллек алдында кузгалырга да, суларга да куркып тораташтай катып калган. Камышлар арасыннан сихри моң агыла да агыла икән. Менә буа өстендә пар аккош барлыкка килгән, алар Айсылу каршына йөзеп килеп баш игәннәр дә, сихри көйгә бии башлаганнар. Бу гүзәллекне берәрсе күрми микән, дип артына борылып караса, Айсылу бик тә таныш егетне күреп алган. Егет кулларын алга сузып, кызга таба атлаган.

—Айсылу, курыкма! Мин сине рәнжетергә теләмим! Без синең белән күптәнге танышлар бит. Исенә төшер!—дигәч, Айсылу авыру чагында янына килгән, буа төбеннән аны күзәтүче һәм янында басып торучы егетнең бер үк зат булуын аңлап алган.

—Әйе, мин сезне беләм кебек. Ә бу могжизалар?

—Болар бар да синең хөрмәткә, Айсылу. Мин бу минутларны күптән көттем. Әйдә, минем белән буага,—дип, Упкын кызны буага әйдәгән.

Сихри көчкә буйсынып алга атлаган Айсылу аяклары суга тигәч кенә айнып киткән.

—Юк! Юк!—дип кычкырып жибәргән һәм артына да әйләнеп карамыйча, өйләренә йөгергән. Тыны бетеп, көч-хәл белән бусагага кайтып егылган. Сеңлесен күтәреп сәкегә салгач, Нурсылу аның янына утырып:

—Сеңлем, сиңа ни булды? Нәрсә куркытты? Барысы турында да сөйлә,—дигәч, Айсылу баягы хәлләрне бәйнә-бәйнә апасына сөйләп биргән.

—Ә исемен сорамадыңмы?

—Юк, үзе дә әйтмәде. Ул кеше түгел, апам.

Бу вакыйгадан соң бер ел вакыт узган. Айсылу белән Хужажан күп тапкырлар очрашканнар. Көз житкәч, туй ясарга жыенганнар.

—Сезнең бәхеткә быел уңышлар да мул булды, амбарларыбыз да ризык белән тулды, балалар,—дип сөенеп туймаган Хөснетдин агай.

Билгеләнгән көн килеп житкән. Туган-тумача, дус-иш, күрше-тирә туй мәшәкатьләре белән мәш килгән. Шатлыгыннан күбәләктәй очып йөргән Айсылу йокы бүлмәсенә килеп кергән. Карашы тәрәзә төбендә үсеп утырган роза гөленә төшкән. Әле кичә генә шау чәчәктә утырган гөл шиңгән, чәчәкләр башларын аска игәннәр. Әйтерсең, алар нинди дә булса хәвеф буласын белгертәләр... Шатлыгыннан исергән кыз, күп уйлап тормаган, гөлгә су сипкән дә, бүлмәдән чыгып киткән. Аның йөрәге ярсыган, ул бәхет мизгелләрен күбрәк татып калырга ашыккан.

Туй башланган. Яшь парларга матур теләкләр телэгәннәр, киңәшләр биргәннәр. Авыл гөр килгән.

Бервакыт Нурсылу яшьләр арасында басып торучы Әбүбәкерне күреп алган. Сеңлесе өчен шатланып, кунакларның күңелен күреп бөтерчектәй бөтерелеп йөргән Нурсылу аңа таба биеп киткән. Әбүбәкер дә кызга таба атлаган, менә алар уртада очрашканнар, бергә әйләнә башлаганнар. Нурсылу Әбүбәкердән күзләрен ала алмаган. Тик Әбүбәкернең генә күзләре башканы эзләгән. Янында бөтерчектәй бөтерелүче гүзәл кызны күрмәгән ул. Менә ул бер генә секундка Айсылуның күз карашын сизеп алган. Бу мизгелдә Айсылу да уртада әйләнүче чибәр егеткә һәм апасына карап алган. Әбүбәкер-Упкынга шушы мизгел җиткән дә инде. Аның сихри көче Айсылуга шунда ук тәэсир иткән. Айсылу аңа бөтенләй буйсынган.

Менә Нурсылу белән Әбүбәкер әйләнүдән туктап, кырыйга чыгып басканнар. Нурсылу һәм башка кызлар ак өйне бизәргә кереп киткәннәр. Упкын акрын гына кешеләр арасыннан чыгып, буага таба юл алган. Озак та үтми, аның артыннан Айсылу да кузгалган. Үзенең нәрсә эшләгәнен дә белмичә ул буага таба атлаган.

Хуҗажанның:

—Нишлисең, Айсылу?—дигән соравына:

—Мине бер генә минутка калдырып тор, мин хәзер киләм!—дигән кыз моңсу гына. Сөеклесенең үтенечен кире кагарга теләмәгән Хуҗажан аны күз карашы белән озатып калган.

Күпме вакыт узгандыр, тирә-якны яңгыратып берәүнең:

—Айсылу буага батты! Коткарыгыз!—дип кычкыруыннан бар халык сискәнеп киткән. Тальян туктап калган, тирә-якта тынлык урнашкан. Бераздан, исләренә килеп, барысы да буага таба йөгергәннәр. Егетләрнең кайберләре суга сикергән. Айсылуның гәүдәсен табып, яр кырыена алып чыгып, яшел чирәм өстенә салганнар. Сөйгәне өстенә иелеп, Хуҗажан бары бер генә сүзне кабатлаган:

—Сула, бәгърем, сула, сула...

Үзе кызның чәчләрен сыпырган, үзенең күзләреннән мөлдерәп яшь аккан. Тик Айсылу гына сулыш ала алмаган шул инде.

Хуҗажанның сүзләрен урманнар кабатлаган, аваз буа ярлары буйлап яңгырап авыл өстенә әйләнеп кайткан.

«Сула! Сула! Сула!..»

Бу вакыйгадан соң бик күп еллар узган, тик елганың исеме авыл халкы хәтерендә «Сула» булып мәңгегә калган.

Кызганыч, әлеге буада батып үлүче кызлар күп була. Әбиләрнең, бабайларның:

—Буа хуҗасы Субай малаена кәләш эзли икән, шуңа күрә яшь кызларны үзенә ала икән,—дигән сүзләрен хәзер дә ишеткәнем бар.

## КАРАТАШ ТОКЫМЫ

Борын-борын заманда, кәҗәләр—кыргый, этләр—бүре, мәчеләр—исемсез, ерткыч җанварлар, кошлар гаять күп булган калын урманда бер гаилә булып бүреләр яшәгән, ди. Көннәрдән бер көнне гаилә башы Карасырт өнендә ике бүре баласы дөньяга килгән. Аларның берсе үзенең житезлеге, чем кара төсе, кызыксынучанлыгы белән барлык бүреләрне гаҗәпләндергән. Ике атна дигәндә, игезәк туганыннан күпкә көчле, хәйләкәррәк икәнен күрсәтеп, зуррак калҗаларны ашый, кирәк булса, туганы авызыннан да тартып ала икән ул. Ай үсәсен көн үскән бүре баласы өлкәннәр белән ауга чыгасы көнне зарыгып көткән. Өлкәннәрнең аудагы маҗаралары, хәвефле хәлләрдән ничек котылулары турында тыңларга бик яраткан.

Карасырт та киләчәктә бу баласының гаилә башы булып каласына ышанганнан-ышана барган. Көн артыннан көн узган. Менә беренче ауга чыгу көне дә килеп житкән.

—Тыңлагыз, бу киңәшләрне сез яхшы белергә, үтәргә һәм мәңге онытмаска тиеш,—дип башлаган Карасырт.—Бүген беренче тапкыр ауга чыгасыз, тормышның беренче сынауларын үтәчәксез, шуңа да безнең алда ант итәргә тиешсез.

—Без бүреләр нәселеннән, бездә бүре каны ага, без хәйләкәр, без явыз! Күмәкләшеп ауга чыгабыз. Кардәшләребезне ташлап качмаска, башкаларның өлешен ашамаска, дошманнарга каршы яуда бердәм көч булып тупланырга ант итәбез! Ант итәбез!

«Ант итәбез!»—дигән сүзләрдән урман яңгырап торган.

—Табигатьнең тагын ике законын аңыгызга сеңдерәм: үзеннән көчлегә ташланма, ул сине юк итәчәк. Сусаган корбаныңа су эчәргә мөмкинлек бир, мондый халәт үз башыңа да төшәргә мөмкин,—дип тәмамлаган карт бүре.

Ниһаять, бүреләр ауга кузгалганнар. Болын тулып кыргый кәҗәләр, сарыклар, кабан дуңгызлары, куяннар һәм башка җәнлекләр йөри икән. Ау кара бүре баласына мажаралы тоелган. Ләкин башка ягы белән күбрәк истә калган: аягын имгәткән кәҗә бәрәнен куып җитеп, үләнгә еккач та, ул аны башкалар шикелле бугазлап атарга теләмәгән, корбаны кызганыч тоелган. Тик чабып килеп җиткән башка бүре торырга азапланган кәҗә бәрәнен бугазлагач кына аңына килгән.

—Корбаныңа хәл алырга мөмкинлек бирү—аны кулдан ычкындыру,—дип ачуланган туганы ырылдап. Бүре баласы шелтәле сүзләргә бик гарьләнгән һәм уртак табыштан бер кисәк ит тә капмыйча, кырыйга барып утырган. Озакламый, корбаннарын күтәреп, бүреләр кайту юлына кузгалганнар. Бернинди табышсыз калган бүре баласы да теләр-теләмәс алар артыннан ияргән. Бу вакыйгадан соң бик күп аулар булган, беренче уңышсызлыктан сабак алган бүре баласы үзенең житезлеге, хәйләкәрлеге белән башкаларны таң калдырып үсеп-ныгып киткән. Аңа хәзер иң катлаулы ауларны да ышанып тапшыра, ә үзенә Караташ дип эндәшә башлаганнар.

Мул ризыклы бу якларга кешеләр килеп урнаша, авыллар үсеп чыга башлагач, бүреләрнең тормышлары кыенлашкан. Кыргый хайваннар урынына кулга ияләштерелгән көтүләр барлыкка килгән.

Гомерләрен монда уздырган, туган җирләрен ташлап китәргә теләмәгән бүреләр гаиләсе ачлы-туклы яшәргә калган. Көннәрдән бер көнне картаеп йөри алмас хәлгә килгән өер башлыгы Акылбаш Карасыртны үз янына чакырткан:

—Минем соңгы көннәрем якынлашты, озак яшәдем... күпне күрдем, шуңа күрә сиңа соңгы киңәшемне әйтеп калдырырга телим... тыңла,—дип башлаган Акылбаш сүзен.—Күреп торам: яшәү кыенлашты, азыкны зур югалтулар бәрабәренә табарга туры килә. Кешеләр безгә каршы төрле мәкерләр коралар... Болай барса, нәсел юкка чыгачак, шуңа күрә берәр хәйлә уйларга кирәк,—дигән ул авыр сулап.—Ята торгач, мин аны уйлап таптым бугай,—дип уйга калган карт бүре. Бераз тынлыктан соң ул сүзен дәвам иткән.—Кешеләргә карата бик зур начарлык эшләп, аларны куркытырга һәм бу урыннарны ташлап китәргә мәҗбүр итәргә, китәргә теләмәсәләр—ясак түләтергә кирәк. Бу турыда яхшылап уйла. Караташ акыл ягыннан башкалардан өстен, аның белән киңәш. Хәзергә хуш. Мине үземне генә калдыр,—дигән карт бүре. Карасырт китүгә Акылбаш җан биргән. Гаиләне күп бәлаләрдән коткарып калган өер башын югалткан бүреләр кайгыдан улап, авыл халкының котын алганнар.

Икенче көнне Карасырт, үзенең баласы Караташ белән киңәшеп, мондый нәтиҗәгә килгән: авыл халкының иң зур көтүенә һөҗүм итәргә, хайваннарны бугазлап атарга, аларны ашамыйча көтүлектә калдырырга һәм бу хәлне күреп курыккан авыл халкына арадашчы җибәреп, ясак түләү мәсьәләсен куярга!

Шулай эшлиләр дә. Көпә-көндез зур сарык көтүенә һөҗүм итәләр. Куркып калган көтүчеләр алдында йөзләп хайванны кырып салалар.

Бу хәл шул ук көнне бөтен тирә-якка тарала, авыл халкы куркуга төшә. Моңа ышанырга теләмәгән күрше авыл кешеләре генә болыннарга көтү чыгаруны дәвам итә. Икенче көнне бүреләр ул көтүгә дә һөҗүм итеп, ике йөзләп сарыкны, кәҗәне кырып сала. Бу хәл өченче, дүртенче көннәрне дә кабатлана. Бугазланган хайваннарын күргән халык көтүләр көтмәс, юлга чыкмас була.

Бу хәлдән соң Карасырт вакыт җитүен аңлап, арадашчы җибәрергә карар кыла. Бүреләр арадашчы итеп Караташны тәкъдим итәләр һәм мөрәҗәгать язуын аңа тапшыралар. Караташ эшкә керешә һәм мондый юлларны хәтеренә сала:

—Арадашчы булып килдем,
Кешеләргә, авылга.
Көтү коткәнегез өчен
Сезгә ясак салырга.

Килешү төзелгән көннән
Без көтүгә тимәбез.
Тик ясакны вакытында,
Алдашмыйча түләгез.

Шушы таләпне җиткерергә дип, Караташ якындагы авылга юл ала. Авылдагы беренче өйнең тәрәзәсен кага:

—Хужа, мин арадашчы. Сөйләшергә кирәк! Авылбаш кайсы йортта? Алып бар мине шунда,—дип гозерен әйтә. Хуҗа башта куркып калса да, явызлык күренмәгән, акыллы күзләрне күргәч, Караташны авылбаш йортына алып китә.

Сөйләшүләр озакка сузылмый. Авылбаш халык белән киңәшеп мондый карарга килә:

—Без риза, тик явыз бүре халкына ышанып җитмибез. Шуңа күрә бер шартыбыз бар.—Син үзең авылга киләсең һәм ай буе иң зур көтүне, көтүчеләрдән башка, югалтуларсыз көтәсең. Әгәр ун сарык югалса, бер айга вакытың озынайтыла.

—Мин урман халкы белән киңәшергә тиеш,—дип, Караташ урманга әйләнеп кайта.

Авыл кешеләре куйган шартны тыңлагач, Карасырт, башкалар белән киңәшеп, ризалыгын белдерә.

—Тик бер ай вакыт. Ризыкны табу нык кыенлашты, ачның ачуы хәтәр,—дип, Караташны авылга җибәрә.

Шулай итеп Караташ авыл көтүчесе булып китә. Үзгәрешләрсез көн артыннан көн узып тора. Ашау-эчү яхшы, торыр урыны җылы булган Караташка мондый тормыш ошый башлый.

Шундый көннәрнең берсендә, билгесез бүреләр Караташның көтүеннән ун сарыкны алып китәләр. Караташка Авылбаш вакытның озынайтылуын хәбәр иткәч, ул үз гаилә бүреләре белән сөйләшергә урманга җибәрүләрен сорый. Авылбаш риза була.

Караташның Карасырт белән киңәшүеннән соң, гаепле бүреләрне аланнан куып җибәрәләр. Тик тагын бер ай буе ач бүреләрне тыеп тору авыр булуын белеп, икесе дә кайгыга кала. Сизгерлекне арттырудан башка чара калмавын аңлап аерылалар.

Озак та үтми, көтүдән тагын сарыклар югала, бирелгән вакыт тагын озынайтыла, Караташ ачуыннан нишләргә белми.

Беркөнне ул көтүгә якынлашып килүче өч бүрене күреп, аларга каршы чыга һәм игезәк туганы Җирәнкашны танып ала:

—Туктагыз, кая барасыз?—ди ул. Күзләрен кан баскан бүреләр, аңа игътибар да итмичә, сарык көтүенә ташланалар. Унлап сарыкны бугазларга өлгергән төркемгә каршы чыккан Караташны тешләп, тырнап, канга батырганчы талыйлар.

Үлем хәлендә яткан Караташка Авылбаш ярдәм күрсәтә. Караташ кешеләргә ышанычы, кан-кардәшләренә нәфрәте артуын сизә.

Кышкы салкын урман, ач бүреләр күз алдына килгәч, Караташ куркып кала. Югалган хайваннар саны арткан саен бирелгән вакытның күпмегә озынайтылырга тиешлеген дә аңламый башлый. Авылбаш әйткәнчә, сигез ел көтү көтәргә кирәклеген белгәч, үзенең кешеләр арасында гомергә каласына төшенә. Бүреләргә ышанычын югалткан Караташ кешеләргә биргән антын үтәр өчен көн-төн хезмәт итә.

Бервакыт ул урман буенда башка бүреләр җәберләп үтергән, канга баткан Карасыртның гәүдәсенә тап була. Шунда ул үзенә бу аланга юл ябылуын, иң ышанычлы яклаучыларының булмавын аңлап ала.

Кешеләргә биргән антын үтәп озак яши Караташ. Ачтан үлеп баручы Актырнакны үлемнән йолып кала, ул тудырган балаларны тәрбияләп, кешеләргә хезмәт итәргә өйрәтә. Ә бүреләр вак төркемнәргә бүленеп, төрле якка таралышалар, үзенең антын бозган, бүреләрне кешеләргә алмаштырган Караташтан үч алырга сүз куешалар.

Шулай итеп бүреләр һәм Караташ токымы булган хәзерге этләр арасында дошманлык мәңгегә калган, ди.

## БЕРЕНЧЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТЕ КАЙЧАН ТӨЗЕЛГӘН?

Соңгы елларда сагышлы, шулай да истәлекле Хәтер көнен үткәрү традициягә әверелде. 1552 ел—татарларның дәүләтчелеге югалган ел.

Былтыр август аенда киң халык катнашында тантаналы төстә Татарстан бәйсезлегенең унъеллыгы, ягъни татар дәүләтчелегенең (киселгән, чикләнгән булса да) яңадан башлануы бәйрәм ителде. Әмма татар дәүләтчелеге ун ел гына яшәми. Татарларның бабалары—болгарлар, борынгы төркиләр һәм һуннар—тамырлары белән меңьеллык гасырлар тирәнлегенә барып тоташалар. Дәүләтчелегебез югалган елны хәтерлибез икән, ул чагында аның барлыкка килү елын да бәйрәм итәргә тиештербез. Һәрбер милләт өчен дәүләтчелек—ул аның өлгергәнлеге, киләчәге, үз-үзен саклау сәләте һәм тулы канлы яңарышы өчен иң кирәкле шартларның мөһим күрсәткече.

Мәсьәлә шуннан гыйбарәт: дәүләт төзелә башлаган ел итеп кайсы датаны сайлап алырга? Мәсәлән, Идел-Болгар дәүләтенең Багдад хәлифәлеге һәм бөтен Ислам дөньясы тарафыннан танылган 922 елны алырга була дип әйтергә мөмкин. Бәлки татар дәүләтчелегенең башлангычы итеп XIII гасырның 40 нчы елларында барлыкка килгән Алтын Урда дәүләтен яки Алтын Урда составыннан аерылып чыгып, Казан ханлыгы төзелгән 1438 елны алырга кирәктер.

Тагын да ераграк чорларга китеп карасак, Кубрат ханның Бөек Болгарстанын искә төшермичә булмый. Бу бай мирастан—Бөек Болгарстаннан без ваз кичә алмыйбыз. Бирелә шулай ук аварларны җиңеп, вассал бәйлелектән котылган һәм тулысынча мөстәкыйльлеккә ирешкән 640 елны таяну ноктасы итеп алырга мөмкин. Шушы исәп буенча дәүләтчелегебезнең 1360 еллыгын бәйрәм итәр идек. Ләкин тагын да борынгырак ярымтүгәрәк дата якынлашып килә. 2001 нче елда Беренче Төрки каханат төзелүгә 1450 ел тула. Борынгы төркиләрнең беренче каханы (императоры) Бумын була. Аны киезгә утыртып күтәреп, 9 тапкыр ставкасы тирәсендә әйләндереп йөртәләр. Бу 551 елда була. Төркиләрнең әлеге беренче бәйсез дәүләтен Кытай таный, ә бу исә шул чакларда халыкара танылуны аңлаткан.

Төркиләргә чаклы Үзәк Азиядә гасырлар буе һуннар хакимлек иткән. Л. Н. Гумилев аларны төрки телләләр дип атый. Борынгы һуннар Кытай тарихында беренче тапкыр безнең эрага кадәр XVIII гасырда телгә алына. Һуннарны «Күк горурлары» дип атаган Кытай шигъриятендә алар турында беренче тапкыр безнең эрага кадәр 822 нче елда языла. Күренекле Питер галиме, Русия Фәннәре Академиясенең шәрекъне өйрәнү буенча Санкт-Петербург институты директоры, тарих фәннәре докторы Е. И. Кычанов «Күчмә дәүләтләр: һуннардан маньячурларга хәтле» дигән китабында: «Һуннарның безнең эрага кадәр III гасыр азагыннан дәүләт булып яшәвендә шик юк»,—дип яза. Аларның үз язулары булуына да байтак мөхтәрәм галимнәр шик белдерми. Әгәр төрки халыклар дәүләте төзелүнең башлангычы итеп һуннар мәмләкәтенең Кытай тарафыннан танылу (мәсәлән, Кытай һәм һуннар дәүләте арасында безнең эрага кадәр 177 елда килешү төзелгән) датасын алсаң, ул чагында төрки халыклар, шул исәптән татар халкы дәүләтчелегенең яше 2177 елны тәшкил итәр. Китерелгән әлеге даталар түшәмнән алынмады. Мин күренекле галимнәр Л. Н. Гумилев, Е. И. Кычанов, С. Г. Кляшторный, М. А. Госманов, М. З. Зәкиев, А. П. Окладников, Л. Р. Кызласов һәм башкаларның фәнни хезмәтләренә таянам. Миңа калса, руслар славян әлифбасын билгеләп үткән кебек үк, төрки-татар язуы көнен дә гамәлгә кертергә кирәк. Төрки-татар рун язуы славяннарныкыннан күп тапкырларга борынгырак һәм славян язуы барлыкка килүгә аның туры мөнәсәбәте булган.

Татар дәүләтчелеге һәм әлифбасы датасын кем расларга тиеш? Моны Татарстан тарихчылары, сәясәт гыйлеме белгечләре, этнологлар, тел һәм әдәбият белгечләре эшләргә тиеш. Алар ук Татарстан хөкүмәте һәм Дәүләт Советына тәкъдимнәр белән чыга алалар. Минемчә, татар дәүләтчелеге төзелүне бәйрәм итү өчен борынгы төркиләрнең беренче каханы Бумынны сайлаган һәм беренче төрки каханаты барлыкка килгән 551 нче елны алу максатка ярашлы булыр иде. Быел төрки халыклар язмышын хәл иткән бу вакыйгага 1450 ел тула. 2005 елда Казанның 1000 еллыгы тантаналы төстә билгеләнеп үтеләчәк. Бу ике күренекле бәйрәм—татар дәүләтчелеге төзелүнең 1450, Казанның 1000 еллыгы татар халкының тантана һәм бәйрәм даталары исемлегенә бик нигезле һәм дөрес кереп урнашырлар иде.

Соңгы һәм хәлиткеч сүзне галимнәр, сәясәтчеләр әйтерләр.

**Рәхим ТЕЛӘШОВ**,
*Санкт-Петербург*

# MƏŊGE YƏŞ XIYAL

ƏZHƏR ĞABİDİGƏ 75 YƏŞ

Radiodan yış qına matur, dərtle-yarsulı ber cır tapşıralar. Rəşit Wahapov, Xəydər kebek bəyek cırçılarıbız yaqtaşı, şundıy uq talantlı «Nijgar mişərebez», bayançı, kəylər də yazıp, üze ük osta başqaruçı Ramil Quramşin cırlıy. Anda, refren bulıp, haman da şundıy yullar qabatlana:

Ex, qaytsa yeget çagım...



Bik uylandıra torğan, fəhemle, ir yərəgeneŋ məŋgelek yəşlege – aŋa tuğrılığı turında cır ul! Süzləren kem yazğan, dip uylap yərgən idem – Əzhər ağa Ğabidineke bulıp çıqtı. Afərin! – dip, səyenep qabul ittem... Şağirneŋ kəygə salınğan utızlap cırı – şiğere barın da beləm. Aŋa da şatmın. Yəşlege suğış çorına turı kilgən əlkən buın, inde bik az qalıp bara torğan azamat irlər awazı bit alar!

Əye, Sarman rayonınıŋ Çuqmarlı awılı (şul uq awılda oluğ ədibebez Ayaz Ğiləcev ta tuğannı küp uquçılarıbız belmi də torğandır...) yegete Əzhər Ğabidine bik yəştən yaw yulları, yıraq cirlər, yat illər kətkən: Yıraq Kənçığış, Koreyalar... Balaçaqtan birle ədəbiyatqa ğaşiq bulıp, Taqtaş, Tufannarnı yatlap üskən awıl malayı, üz şiğerlərenə nigez-zəminne ənə şul çordan ala. Cirlege – çın məgnəsendə cirdən, tormıştan, ul yıllardan... Front gazetalarında basılıp, xətta şul şartlarda keçkenə ber kitap ta çığarıp uza ul suğış yulın. Awır kontuziələr ala... Annan – uqu, tuğan awılında balalar uqıtu. Üze də Şiğriətkə məŋgelek ğaşiq-bala bulu, yazu, uqu, əyrənü. Şuŋa da balalar əçen yaza ul berençe kitapların – «Bez – yaz dusları», «Tapqırcan tabışmaqları» kebeklərne... Lirikanı da onıtmıy – yaza, başqalarnı uqıy, məqələlər, risenziələr bastırıp çığara. Bu turıda berara Çuqmarlıda məktəp direktorı bulıp eşləgən, bulaçaq galim dustım Xatip Minneğulovnıŋ ise kitep, yaratıp səyləgəne xəterdə: «Keşelər uŋışına, yaxşı şiğergə sabıy kebek səyenə», – di ide ul Əzhər ağa turında. Həm bu sıyfat anı ğomergə taşlamadı: rayon, respublika matbuğatında, xətta kürşelərdə – Ufanıŋ «Qızıl taŋ» gazetında, məsələn, – şağirneŋ erele-waqlı yəzlərçə məqələləre basılğanın beləm. Əlməttə, Yazuçılar berlege bülegenə yaqınayğaç, bigrək tə «açıldı» ul. Nacar Nəcmi atlı oluğ zamandaş şağirebezneŋ şundıy şiğer yulları bar: «Barısı da soŋlap kilde miŋa...» Bu, bəlki, Əzhər ağayğa da qarıy torğandır. Xəyer, üzen onıtıp, keşelər əçen yanıp yəşəgənnər əleşenə şul – «kəmeş»ter... Ləkin ədəbiatta, şiğerdə – irtələw yə soŋlaw yuq. Yazğanıŋ ğına şəp bulsın! Əzhər ağanıŋ da, nihayət, üze teləgən lirik-fəlsəfi kitapları dənya kürde: «Taŋ doğası» (1994), «Urman çitendəge naratlar bez» (1997), «Kəzge barlaw» (1999). İsemnəre ük məğnəle, fəhemle bit!

Şulay, Yazuçılar berlegenə də alındı ul, Tatarstannıŋ atqazanğan mədəniət xezmətkəre isemenə də, Əlmətneŋ R. Təxfətullin isemendəge ədəbi premiəsenə

də layıq buldı. Yə, azmını? Dimək, ofitsial' rəweştə şaĝir həm publisist qələmenen tanıluı ide bu! Əzhər Ĝabidi kebek ixlas, saf canlı yawgir aĝalarıbıznın yaralarına da şifa, sixət, bəlki, ul büləklər? Şulay bula kürsen.

«Ex, qaytsa yeget çaĝım!» Əye, bu əzgələnü həmməbezgə də tanış. Ə qayta qalsa? Yə üzebez yəgerep qaytıp yıĝılsaq ana? Şaĝir barıber üz yulınnan barıp, üzençə yəşər ide bit: il-xalıq əçen yanıp, arĝamaq kebek cilep ütər ide ul yana ĝəmerlərne də!

Məxəbbət həm Şiĝer genə—məngegə yəş, məĝayın...

Ex, tınlıyq əle şulay da, tınlıyq əle bez əlege yeget çaqnı saĝınu cırın! Citmeş biştə də...

Rədif ĜATAŞ

# Əzhər Ĝabidi

## Yeget bulsa—cinsen, kükrəsen

Biek bulmasa da tawın bulsın,
Tekə bulmasa da ürləren.
Tar bulsa da üz baqçan da bulsın,
Kükrəp üssen əçen gelləren.

Tar bulsa da üz suqmaĝın bulsın,
Ul suzılsın taşlı ürlərgə.
Suqmaĝında tirən ezen qalsın,
Ullarına saĝınıp səylərgə.

Üzen qorĝan şalaşın da bulsın,
Yul ütkəndə kerep qunarĝa.
Həm yanında çaqma taşın bulsın
Şırpın betə qalsa—çaĝarĝa.

Üzen genə baqqan çişmən bulsın,
Susaĝanda suın eçərgə.
Kəçen betep, xəldən tayĝan çaqta,
Kəç kertsen ul yullar kiçərgə.

İr-yegetkə citmeş hənər də az—
Bəten eşnen belsen üz rəten.
Kirək ikən yəşen bulıp suqsın,
Cinelməsen, cinsen, kükrəsen.

Utqa kersen, sudan batmıy çıqsın,
Tuĝrı bulsın birgən antına.
Şunda ĝına yeget layıq bula
Keşe digən bəyek atına.

## Arınıyqçı

Bəten ĝəmerlərem kətep ütte
Əle ətine, əle duslarnı;
Alar isənlege xərmətenə
Kütərergə tulı tostlarnı.

Əmetlərem genə aqlanmadı,
Alar yawda irtə suldılar,
Ĝəmerləren beznen əçen birep,
Cirdə yəşəw yulı suzdılar.

İzge niət belən suzılĝan yul—
Ul yəşəwnen matur dəwamı.
Bulĝan yazıqlardan arınıyq ta
Təzik inde matur—yananı.

*Beznen kalendar'*

# ƏSƏRLƏRENDƏ–YAQTAŞLARI

YAZUÇI XƏNİF XƏYRULLİNNIŊ TUUINA 70 YIL

Yıllar ütə, çorlar, ğasırlar alışına... Ədəbiatta da şulay. Kemnərder fanidan baqıy dənyağa küçə, ədəbi məydanğa yaŋa isemnər kilə. Kemnərder onıtıla, kemnərder yıllar ütkənnən soŋ yaŋadan qalqıp çıga.

Yazuçınıŋ bu dənyada qaldırğan eze anıŋ icatı belən bəyələnə, ülçənə həm ul icat cimeşlərenеŋ əle tağın küpmeder yəşi aluı əsərlərdə tormış çınbarlığınıŋ niçek çağıldırıluına bəyle. Üzeŋ ülgənnən soŋ kemnər uqıy soŋ ul əsərlərne?! Alarnıŋ yaŋa buınnarğa kirəge bulırmı? Əgər alarnı hiçyuğı ber tar dairə, yəisə ber təbək keşelərə genə də qabat-qabat qulına ala ikən, yazuçını bu dənyalıqta yuqqa yəşəgən dip əytep bulmıydır.

Bu yaqtan qarağanda, Xənif Xəyrullin Sarman yağı keşelərə əçen ayıruça yaqın həm qəderleder. Çənki ul gəmere buyı iseme cırlarğa küçkən şuşı yaqlarda yəşəde, ədəbiatta şuşı yaq keşelərenеŋ yaqtı obrazların gəwdələndererğə omtıldı.

Yazuçı həm jurnalist Xənif Ğizdulla ulı Xəyrullin 1931 yılnıŋ 12 sentəbrendə Sarman rayonı Sarınan awılında tua. Urta məktəpne təmamlağannan soŋ, şul uq rayonnıŋ Azalaq awılında məktəptə balalar uqıta. Belemen kütərü niəte belən, Qazan dəwlət universitetınıŋ tatar tele həm ədəbiatı bülegenə uqırğa kerə. Universitetnı uŋışlı təmamlağaç, tuğan yağına qayta həm rayon gazetasına eşkə urnaşa. Annan soŋ berniçə yıl Bua rayonı «Bayraq» gazetasında eşləp ala, əmma anı tuğan yağı qabat üzenə tarta həm ul yənə Sarmanğa qaytıp təplənə. «Yuğarı uŋış əçen» gazetası redaksiəsendə xəbərçe bulıp eşli başlıy, sonra redaktor dərəcəsenə kütərelə. Ozaq yıllar awıl moxitında yəşəw həm gazeta redaksiəsendə eşləw aŋa awıl tormışı, xezmət keşelərə, alarnıŋ yəşəyeşe, uy-xıyalları belən yaqınnan tanışırğa məmkinlek birə.

Ul grajdannar sugışı yıllarında barğan kərəşne yaqtırtqan «Qanlı yıllar, awır yıllar» (1970); kolxoz awılı citəkçese eşçənlegen surətləgən «Xucida üskən batır» (1972); əç suğışnı başınnan kiçergən, yazmış tarafınnan qat-qat qıynalğan, əmma ixtıyar kəçe sınmağan Xəsən obrazın çağıldırğan «Qartlıq... kemgə şatlıq» (1975); traktorçı Fatıyma Sirayevanıŋ tormış yulı həm xezməttəge batırlıqları turında səyləgən «Fatıymanıŋ bəxete» (1975) kebek dokumental' əsərlər yaza. Balalar əçen «Tılsımlı tayaq tabışı» isemle macaralı povest' h. b. oçerk-xikəyələr icat itte.

Uquçılar tarafınnan ayıruça cılı qarşılanğan həm matbuğatta bəxəslər uyatqan əsəre – "Qanatlar talmasın» (1973) poveste.

Povest'ta avtor altmışınçı yıllar awıl tormışındağı üzgəreş-yaŋalıqlarnı taswirlıy, üz zamanı əçen xarakterlı bulğan qarşılıqlı problemalarnı kütərə.

Xənif Xəyrullin 1974 yıldan Yazuçılar berlege əğzası ide. Ul icat itü belən genə çiklənmiçə, qələmdəşlərenə hərçaq iğtibarlı buldı, ədəbiatqa yəş almaş xəzerləwdə kəçen-təcribəsen qızğanmadı.

Yazuçı Xənif Xəyrullin, qatı awırudan soŋ, 67 yəşendə 1998 yılnıŋ iün ayında arabızdan kitte. Anıŋ icatı Sarman yağı keşelərenə ədəbiatta salınğan həykəl bulıp qaldı.

**Liliə ĞATAULLİNA**



## İctimaği-mədəni tormışıbızdan
## Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### БӨЕК ИДЕЛ ЮЛЫ

Казанның 1000 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек программасы кысаларында 5-16 августта ЮНЕСКО, ИРСИКА һәм Аурупа Советы теләктәшлегендә «Бөек Идел юлы» дигән халыкара фәнни-гамәли конференция үтте. Аны Татарстан Президенты М. Шәймиев үзенең чыгышы белән башлап җибәрде.

Татарстан, Русия, АКШ, Алмания, Швеция, Италия, Финляндия, Төркия һәм Иран вәкилләре теплоходта Идел буе шәһәрләре буенча—Казаннан алып Әстерханга кадәр сәфәр кылдылар. Үзенчәлекле фәнни «марафон» программасы 2005 елга кадәр исәпләнгән. Киләсе елда катнашучылар Әстерханда очрашачак һәм Тәһранга юл тотачак. Шуннан соң Осло һәм Санкт-Петербургка да чират житәчәк. Сәяхәт 2005 елны Татарстан башкаласында очрашу белән тәмамланыр дип көтелә. Халыкара форумның максаты—Бөек Идел юлы буена урнашкан шәһәрләр һәм илләр арасындагы мәдәни, фәнни һәм сәүдә-икътисади бәйләнешләрне ныгыту. Анда катнашучылар шушы төбәктә яшәүче халыкларның рухи байлыкларын саклап калу, борынгы сәүдә юлын күтәрү һәм үстерү буенча чаралар үткәрү, экологияне сәламәтләндерү мәсьәләләрен тикшерәчәк. Бөек Идел юлы шәһәрләренең Халыкара ассоциациясен төзү—дөньяның күпчелек илләре галимнәре һәм җәмәгать эшлеклеләре озак еллар алып барган эшчәнлекнең иң олуг нәтиҗәсе булыр, дип исәпләнелә.

### ХАЛЫКАРА БӘЙЛӘНЕШЛӘР

Вәкиллексез Халыклар Оешмасының (ВХО) 20-23 июньдә Эстониядә, Тарту шәһәрендә узган төбәк утырышында Татарстан вәкиле булып Татарстан халык депутаты, журналыбызның редколлегия әгъзасы, шагыйрь Ренат Харис катнашты.

### СӘЛӘТЛЕЛӘР ҖЫЕНЫ

6-9 июль көннәрендә Биләр тарихи-мәдәни тыюлыгында сәләтле балаларның һәм яшьләрнең V республика фестивале булып үтте. Анда катнашучы балалар-яшьләр республикабызның 30 районыннан, Русиянең 10 төбәгеннән җыелган иде.

Фестиваль башында балалар танылган шәхесләр, әдәбият-сәнгать әһелләре белән дә очраштылар. Алар арасында Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасарлары Р. Миннуллин, А. Демидов, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе И. Таһиров, спорт һәм яшьләр эшләре министры М. Бариев, мәгариф министры Ф. Харисов, галимнәр Ж. Сөләйман, Ә. Мөхәммәдиев, язучы Т. Миннуллин, композитор М. Шәмсетдинова кебек зыялыларыбыз бар иде.

Биләрнең мәшһүр «Хуҗалар тавы» дигән җирендә мондый фестиваль инде бишенче ел рәттән үткәрелә.

### ИСЕМЕ ОНЫТЫЛМАС

15 июльдә Лаеш районында бөек рус шагыйре Гавриил Державин истәлегенә «Исәнме, Державин!» дигән әдәби бәйрәм булып узды. Лаешлылардан тыш бирелә Казаннан килгән кунаклар—Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин, Татарстанның мәдәният министры урынбасары Р. Вәлиев, республиканың Милли музей хезмәткәрләре һәм генераль директоры Г. Муханов, татар махсуслаштырылган фәнни-реставрация идарәсе директоры Г. Сабирҗанов, «ТАИФ» ААҖнең генераль директоры урынбасары Р. Фәсхетдинов һәм башкалар бар иде.

Бәйрәмнең төп вакыйгасы Татарстанның Язучылар берлеге белән район хакимиятенең Державин премиясен тапшыру иде. Былтыр беренче лауреат язучы Владимир Корчагин булса, быел исә бу мәртәбәле исемгә талантлы рус шагыйре, тәрҗемәче, «Идел» журналының бүлек редакторы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Сергей Малышев лаек булды.

Район үзәгенең Державин исемен йөрткән үзәк мәйданында үткән тантанадан соң «Вакыт елгасы: Г. Р. Державин тормышы» дигән күргәзмә ачылды. Мондагы экспозицияләр шагыйрьнең юбилее (2003 ел) хөрмәтенә ачылачак музейның башлангыч нигезе булачак.

### СӨЕМБИКӘ ВАРИСЛАРЫ СЫНАТМЫЙ

Ялтада «Сөембикә варислары-2001» дигән III халыкара төрки-татар балалар иҗаты фестивале тәгәлләнде. Анда Татарстаннан да 100 гә якын бала катнашты.

Фестивальнең Гран-приена Симферопольдән Алим Рамазанов ия булды. Иң оста җырчылар дип Диаз Мөсәллимов

(Семипалат) һәм Илнар Хужиев (Түбән Кама) табылды. Икенче бүләкне исә Мелитопольдән Лиана Муллаянова һәм Симферопольдән Әминә Мостафаева алды. Оста җырчылар дип билгеләп үтелүчеләр арасында Түбән Камадан Гөлнар Гафурова, Чаллыдан Рамил Закиров та бар. Ансамбльләр арасында исә «Ак калфак» (Казан), «Ләйсән» (Киев), «Нур» (Әстерхан) һәм «Кояш балалары» (Казан) иң яхшылар дип бәяләнде.

Биючеләр арасында беренчелекне Түбән Камадан «Нәүрүз» ансамбле һәм Казан хореография училищесының «Казан татарлары» триосы яулады. Икенче һәм өченче урыннарны Симферополь биючеләре бүлеште.

Уен коралларында иң яхшы чыгыш ясаганы өчен Татарстан курайчыларының җыелма ансамбле, Казаннан Азат һәм Алмаз Арслановларның курай дуэты бүләкләнде.

Фестивальдәге чыгышларга Татарстанның атказанган артисткасы Гөлзадә Сафиуллина рәислегендәге жюри бәя бирде. Жюрида Казан консерваториясе ректоры Рубин Абдуллин, Украинаның атказанган сәнгать эшлеклесе Сервер Какура, Россия һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, профессор Җәвид Котдусов бар иде.

## ЯҢА ПРЕМЬЕРАЛАР

Быел җәй Казан театрларында ике яңа спектакль дөнья күрде. Берсе—Ркаил Зәйдулла пьесасы буенча Г. Камал театрында режиссер Марсель Сәлимҗанов сәхнәләштергән «Саташкан сандугач» спектакле. Театрның нигездә яшь талантлары башкарган бу әсәрдә бүгенге җәмәгатьчелекне борчыган күп мөһим мәсьәләләр күтәрелә.

Икенче премьера М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында булды. Ул—композитор Леонид Любовский тарафыннан иҗат ителгән «Йосыф кыйссасы» исемле балет. Либретто авторы—шагыйрь Ренат Харис. Кол Галинен үлемсез әсәре вариантында эшләнгән бу балетны сәхнәләштерүчеләр: хореография буенча—Г. Кавтун, Н. Боярчиков (Петербург), сценография һәм костюмнар буенча—А. Злобин, А. Ипатьева (Киев).

## МӘСКӘҮЛӘРНЕҢ «РӘССАМ» БЕРЛЕГЕ

Фәнгә, мәдәнияткә һәм сәнгатькә теләктәшлек итү өчен төзелгән «Фатиха» фонды һәм Мәскәү өлкәсенең милли-мәдәни мөхтәрияте тәкъдиме белән Мәскәүдә яшәүче танылган рәссамнар Эдуард Шаһиев, Мансур Саттаров, Илдар Мостафин катнашында Мәскәүдә Татар-башкорт рәссамнары берлеге төзелде. «Рәссам» дип аталган бу оешма үзенең беренче оештыру утырышын үткәрде. Анда берлекнең нигезләмәсе кабул ителде, идарә әгъзалары сайланды. Шул ук очрашуда берлеккә әгъза булырга теләгән рәссамнар үзләренең анкеталарын да тапшырдылар. Оештыру комитеты рәисе Фәрит Могътасаров бу яңа оешманың максатлары хакында сөйләде. Эш планнары турында яңа сайланган рәис Эдуард Шаһиев чыгыш ясады. Рәссамнар киләсе елда Казанда үтәчәк Бөтендөнья татар конгрессында күргәзмә белән катнашырга, Казанның меңьеллыгына яңа эшләр иҗат итәргә теләк белдерделәр.

## ГАЛИМ ХӨРМӘТЕНӘ

Министрлар Кабинеты 2001 елның 25 июнендә Саба районы үзәк китапханәсенә Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, филология фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясе академигы Әбрар Гыйбадулла улы Кәримуллинның исемен бирү турында карар кабул итте.

## ӘЗӘРБӘЙҖАН ЛАТИНГА КҮЧТЕ

Президент Хәйдәр Алиев Указы нигезендә Әзәрбәйҗан 1 августтан тулысынча латин алфавитына күчте. Моннан соң барлык китаплар һәм газета-журналлар латин алфавитында гына чыгачак.

Әзәрбәйҗанның латин язуына күчүе төрки җөмһүриятләр арасындагы бәйләнешләрдә бик мөһим вакыйга буларак бәяләнә. Билгеле булганча, Урта Азия җөмһүриятләрендә һәм Татарстан Республикасында да латин графикасына күчү турында рәсми карарлар кабул ителгән.

* * *

2001 елның 16 июлендә танылган әдәби тәнкыйтьче, галим һәм тәрҗемәче **Энгель Галимҗан улы Нигъмәтуллин** вафат булды.

2001 елның 13 августында шагыйрь **Фердинанд Шәйхи** вафат булды.

## *Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** «Күзгә мон»—фотоэтюд.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** шагыйрь һәм галим Рифат Җамал (Корбанов).

# ЯҢА КИТАПЛАР

Наис ГАМБӘР. **Күзләрем яфрак коя**: шигырьләр.—Казан: Татар. кит. нәшр., 2001.—128 бит. Тиражы—2000 данә.




Наис Гамбәр—берәүләргә әдәбият белгече һәм тәнкыйтьче, берәүләргә—тәҗрибәле редактор-мөхәррир буларак билгеле шәхес. Әмма ул әдәби юлын шагыйрь булырга теләп башлаган һәм ул шул юнәлештә утыз елдан артык иҗат итеп килә.

«Күзләрем яфрак коя»—Н. Гамбәрнең икенче шигырь китабы. Беренчесе «Баш очымда—Кояш» 1991 елда дөнья күргән иде. Күләм ягыннан Н. Гамбәр шигырьләре артык күп булмаса да, әсәрләренең камиллеге, эчкерсез-ихласлыгы, лирик-фәлсәфи тирәнлеге, үзенчәлекле формасы белән алар бүгенге шигъриятта аерым бер урын алып тора. Төрле елларда язылган йөздән артык шигырь тупланган бу китапның аннотациясендә тыйнак кына болай дип язылган: «шагыйрь Наис Гамбәрнең бу китабына бераз гына моңсулык, сагыш саркыган уйчан-фәлсәфи шигырьләре тупланган».

Китапның мөхәррире—Р. Корбан, рәссамы—В. Булатов.

Рафаэль БЕЗЕРТИНОВ. **Тэнгрианство—религия тюрков и монголов:** фәнни эзләнүләр.—Чаллы: «Аяз» нәшрияты., 2000.—456 бит. Тиражы—2000 данә.




Кешенең бөек асылы—мәңгелеккә омтылыш. Диннәрнең барлыкка килүен шуның белән дә аңлатырга мөмкиндер. Бүгенге төп диннәрнең дә барлыкка килү һәм таралу дәверләре билгеле. Кайбер диннәр күп мең еллар элек үк таралган, кайберләре—соңрак... Әйтик, борынгы болгар бабаларыбыз ислам динен моннан мең дә бер йөз ел элек кабул иткәннәр. Ә аңа кадәр? Алар нәрсәләрне изге дип санаганнар? Нәрсәләргә табынганнар? Рафаэль Бәзертдиновның бу китабында әнә шул сорауларга җавап табарга мөмкин. Автор белеме буенча тарихчы булмаса да, бу өлкәдә нык әзерлекле галим, аның фәнни дәлилләргә бай «Татары, тюрки—потрясатели вселенной» дип аталган өч томлык хезмәте дөнья күргән иде инде. Чираттагы бу китабы—тарих, фәлсәфә, гомумән, рухият белән кызыксынган һәркем өчен файдалы әсбап.

Индекс 73210



Рифат Җамал

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)